
# Казан утлары

5.1986





## ТУГАН ҖИР ҖЫЛЫСЫ

Кукмара районының «Коммунизмга» колхозында.
Фотохикәянең дәвамы 132-133 битләрдә

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**5**

**1986**


## *Бу санда*


Г. АФЗАЛ. Тагын бер ел... *Шигырьләр* . . . 3

М. ХӘСӘНОВ. Язгы ажаган. *Роман* . . . . 8

ХИСАМ КАМАЛОВКА 60 ЯШЬ

Х. КАМАЛОВ. Яңа шигырьләр . . . . . . 70

Р. МӨХӘММӘДИЕВ. Ачык тәрәзә. *Хикәя* . . 74

ӘДӘБИЯТЛАР ДУСЛЫГЫ — ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫ

Ф. ИСЛАМОВ. Тарихи бергәлек. *Татар-чуваш мәдәни бәйләнешләре турында* . . . . . 88

Я. УХСАИ. Мине татарга саныйлар. *Шигырь* 93

П. АФАНАСЬЕВ. Тизлек. *Шигырь* . . . . 94

Ю. СЕМЕНДЕР. Пинерби. *Шигырь* . . . . 94

Р. СӘРБИ. Ялвару. *Шигырь* . . . . . . . 95

М. ЮХМА. Ай юлы. *Шигырь* . . . . . . 95

В. ДАВЫДОВ — АНАТРИ. Нигә елый каен? *Шигырь* . . . . . . . . . . . . . 96

А. ГАЛКИН. Иделдә. *Шигырь* . . . . . . 96

Х. АГИВЕР. Баллы мыек. *Хикәя* . . . . . 97

В. ЕНЕШ. Ирләр булыйк. *Хикәя* . . . . . 103

Н. МАКСИМОВ. Имтихан. *Хикәя* . . . . . 105

Р. ЗӘЙДУЛЛИН. Күпер. *Поэма* . . . . . . 107

9 МАЙ — БӨЕК ҖИҢҮ КӨНЕ

Р. ГӘРӘИ. Туган җир куенында . . . . . 113

И. БЕЛЯЕВ. Җиңүле яшьлек. *Шигырьләр* . . 121

КПССның XXVII СЪЕЗДЫ КАРАРЛАРЫН — ТОРМЫШКА!

Х. БӘДРЕТДИНОВ. Җиде мең төрле борчак 123

Бер сорауга — бер җавап . . . . . . . . 126

ТАТАРСТАН — ТУГАН ТӨБӘГЕМ

Н. Б. БАКИРОВ. Туфрак туганнары без *(Әлки районы)* . . . . . . . . . . . . . 127

С. ХӘКИМ. Халык хәзинәләрен ачучы. *Фатих Урманчеевка 50 яшь* . . . . . . . 131

Р. ЯКУПОВ. Туган җир җылысы. *Фотохикәя* 132

БЕР ГИПОТЕЗА

Н. ФӘТТАХ. Фест дисбесенең сере . . . . . 134

КОНКУРСКА

Ф. ХАТИПОВ. Яшәеш гаме . . . . . . . 170

Ф. ФӘСИЕВ. Кульязма мирасыбыз сәхифәләре . . . . . . . . . . . . . . 173

Тәрҗемә турында сөйләшәбез . . . . . . 177



КПССның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАР НӘШРИЯТЫ

КАЗАН

ГАБДУЛЛА КАРИЕВНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Ә ХӘЙРУЛЛИН. Ф. ХӘБИБУЛЛИН. Татар театрының рухы . . . . . . . . . . 180
Ш. ХӘЙРУЛЛИН. Атаклы якташым . . . . 185
Р. ГАЗИЗОВ. Кариев турында белгәннәрем . . 185

ГАЛИЯ КАЙБИЦКАЯГА 80 ЯШЬ

Г. КАЙБИЦКАЯ. Бөек иҗатчы рухы . . . 186

Культура тормышы көндәлеге . . . . . . 190

Тышлыктагы сурәтләр . . . . . . . . . . 192

*Баш редактор*
РЕНАТ ХАРИС

*Редколлегия*

МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ
ӘХӘТ ГАФФАР
МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ
АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ
МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ
МӘДИНӘ МАЛИКОВА
САЛИХ МАННАПОВ
*(җаваплы секретарь)*
ТУФАН МИҢНУЛЛИН
ФЛҮН МУСИН
РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ
*(баш редактор урынбасары)*
РӘФЫЙК НӘФИКОВ
НУРИХАН ФӘТТАХ
СИБГАТ ХӘКИМ
РИЗВАН ХӘМИД
НИЛ ЮЗИЕВ
АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН

### В НАШЕМ НОМЕРЕ

Роман М. ХАСАНОВА «Весенняя зарница», рассказ Р. МУХАММАДЕЕВА «Открытое окно», стихи Г. АФЗАЛА, поэма Р. ЗАЙДУЛЛИНА.
В рубрике «60 лет Х. Камалову» — новые стихи юбиляра.
В рубрике «Дружба литератур — дружба народов» — статья Ф. ИСЛАМОВА о татарско-чувашских взаимоотношениях в области культуры, переводы стихотворений и рассказов чувашских писателей и поэтов: Я. УХСАЯ, П. АФАНАСЬЕВА, Ю. СЕМЕНДЕРА, Р. САРБИ, М. ЮХМА, В. ДАВЫДОВА-АНАТРИ, А. ГАЛКИНА, Х. АГИВЕРА, В. ЕНЕШ, Н. МАКСИМОВА.
Ко Дню Победы — очерк писателя Р. ГАРАЕВА и стихи И. БЕЛЯЕВА.
«Решения XXVII съезда КПСС — в жизнь!» — очерк Х. БАДРЕТДИНОВА «7 тысяч сортов гороха».
В рубрике «Татарстан — родной мой край» — статья первого секретаря Алькеевского райкома КПСС Н. Б. БАКИРОВА.
К 50-летию Ф. Урманчеева статья С. ХАКИМА.
Фоторассказ Р. ЯКУПОВА о колхозе «Коммунизмга» Кукморского района ТАССР.
Статья-гипотеза Н. ФАТТАХА «Тайна Фестского диска».
В журнале продолжается дискуссия о проблемах перевода.
К 100-летию со дня рождения выдающегося татарского артиста и режиссёра Г. Кариева статья А. ХАЙРУЛЛИНА и Ф. ХАБИБУЛЛИНА, воспоминания Ш. ХАЙРУЛЛИНА и Р. ГАЗИЗОВА.
К 80-летию со дня рождения Г. Кайбицкой статья юбиляра.
«Дневник культурной жизни».
На наших обложках — творчество художника Л. Фаттахова.

Безнең адрес: 420066, Казань, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар:
баш редактор — 53-07-60,
баш редактор урынбасары — 53-07-09,
җаваплы секретарь — 53-07-09,
*бүлекләр:*
проза, поэзия, очерк — 53-07-61,
тәнкыйть, фән, сәнгать,
хатлар — 53-07-63.

Техник редактор *Р. Сөләйманова*. Корректорлар *Г. Салихҗанова, Ч. Фәтхуллина*.

Производствога бирелде 10.03.1986 ел. Басарга кул куелды 29.04.1986 ел. ПФ 05175. Офсет ысулы белән басыла.
Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8).
Тираж 627 49. Заказ В-104. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе,
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1986 ел.

# Гамил Афзал

## ТАГЫН БЕР ЕЛ...

### Кол Гали

Чәчәк атсын татар иле — болгар иле,
Күңелләрне сөеп иссен тарих җиле,
Онтылмасын яхшылыклар, изгелекләр,
Мәхәббәт турында җырлыйк, бүз егетләр.

Кирәмәт тавы башында җилләр йөрер,
Чапанының чабулары җилбер-җилбер,
Чалмасына орынып ага ак болытлар,—
Айлы төндә шагыйрь уйлар, дөнья йоклар.

Гыйлем җыйган шәкерт чаклар ерак калды,
Зая үткән гомер кебек ага сулар.
Сөйгән яры Айсылуны ятлар алды,
Кол Галинең йөрәгендә ярасы бар.

Аллы-гөлле ефәк чаршаулар артында
Җофар мае сөртеп кенә чәчен тарап,
Унҗиденче хатын булып хан йортында,
Айсылуы еглыйдыр айга карап...

«Амин» дигәч, намазлыктан баш күтәрдек,
Дөньяларны агартырга дәрт җитәрлек.
Туры сүзне тау башында торып сөйлик,
Я, илаһем, иңдер миңа пәйгамбәрлек!

Яраннарга моңлы хикмәт өләшергә,
Залимнарның күзенә карап сөйләшергә,
Ил алдында телсез-тешсез булу гарьлек,
Я, илаһем, иңдер миңа пәйгамбәрлек!

Җабраил төшә дә куна тау башына,
Канатларын җыеп сала иңбашына.
— Гали шагыйрь, нигә сиңа пәйгамбәрлек,
Шагыйрь үзе өммәтенә пәйгамбәр бит!

Гыйлем эстәп, дәрвиш кебек ил буйладың,
Фәрештәнең канатыдай ак уйларың,

---

ГАМИЛ АФЗАЛ (1921) — күренекле шагыйрь, ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, егермедән артык шигырь һәм проза китаплары авторы. Әлмәттә яши.

Бу җиһанда явызлык күп, мәхәббәт аз,
Саф мәхәббәт турында син бер кыйсса яз!

Төтен исле алачыкта чыра яна.
Ярларына тулып-тулып Әтил ага.
Гали хәзрәт уйлап ята айлы төндә:
Ничек итеп бу дөньяны төзәтергә?

Ничек итеп ялган белән көрәшергә,
Ничек итеп акыл, гыйлем өләшергә,
Ничек итеп «ә» дигәнгә «я» димәскә,
Явызлыкка, кыргыйлыкка баш имәскә?

Гали хәзрәт мәдрәсәдә дәрес сөйли,
Кул астында ачып куйган коръән имди.
Әгузе бисмиллаһи дип әйтә теле,
Ә күңелендә Йосыф йөргән Мисыр иле.

Күңел йөри хикмәт эзләп, илләр буйлап,
Пәйгамбәрләр килгән эссе чүлләр буйлап,
Җилләр исәр, еллар кичәр, сулар агар,
Бу илләрдә Йосыф белән Зөләйха бар.

Болгар-татар илләрендә бәхет артсын,
Шат гомерләр Чулман кебек ага торсын,
Йосыф кебек ир-егетләр печән чапсын,
Зөләйхадай сылу кызлар урак урсын.

Кирәмәт тавы башында җилләр йөрер,
Чапанының чабулары җилбер-җилбер,
Ак болытлар ашыгып аккан тау битендә
Кол Галигә илһам иңә айлы төндә.

Бәхет теләп изге кошлар канат какты,
Мәхәббәтнең нуры белән дөнья якты,
Күз алдына гүзәл Йосыф килеп басты,—
Унбер туган арасында берсе яхшы.

Гали хәзрәт шәкертләргә вәгазь сөйли;
Дин-шәригать кануннары изге имди.
Пәйгамбәр дип, изгеләр дип әйтә хәтер,
Ә күңелендә Зөләйханың мәхәббәте.

Төтен исле алачыкта чыра яна.
Боз астында йокымсырап Әтил ага,
Кар себерә, көртләр өя шималь җиле,
Ә күңелдә кайнар комлы Мисыр иле.

Уйлый-уйлый төшләр күрә уяу килеш:
Ягъни, үзе гүзәл егет Йосыф имеш.
Ә Зөләйха аңа карап утлар йота,
Янып-көеп гыйшык тота.

Илһам тулы көннәр килде, төннәр килде,
Ераклардан серле-моңлы өннәр килде,
Җыры белән, хисе белән, төсе белән
Ак канатлы фәрештәләр, җеннәр килде.

Иҗат итү үзе татлы, үзе ачы,
Һәр юлына җанын салып тамчы-тамчы,
Кышлар буе, язлар буе, көзләр буе
Язды Гали, кара чәче агарганчы.

Кышлар үтте, язлар үтте, җәйләр үтте,
Саба җиле урманнарның чәчен тарап.
Егерме ел язды Гали, иҗат итте —
Әтил өсләренә карап.

Җан сөендә очар коштай канат кагып,
Озын кыйсса тәмам булды арып-талып,
Күзләреннән татлы-ачы яшьләр тамып,
Мең ел укыр уйга талып гади халык.

Мәдрәсәдә кичә-көндез чыра ягып,
Шәкертләре күчерделәр хәйран калып:
Менә сабак ичмаса бу, асыл сабак,
Мәхәббәтле, дәртле, моңлы алтын канат!

Хәрефләрен матур итеп, тигез итеп,
Куфи белән күчерделәр исләр китеп,
Укыдылар йөртә-йөртә кулдан-кулга,
«Кыйссаи Йосыф» китте озын юлга.

Шәех морза кызыл атлас чапан кигән,
Хан утыра, йөзе-бите кара көйгән,
Киңәш бара:— Шәригатьне мыскыл иткән...
Китап язып, ханнан көлгән, диннән көлгән:...

Хан сарае каршысында яна учак,
Чыртлап яна коры каен, коры усак.
Көлең куккә очсын, шайтан сабагы, дип,
«Кыйссаи Йосыф»ны ташлыйлар кочак-кочак.

Кылыч аскан каты куллы таза ирләр,
Хан боерыгы, ачуланма, шагыйрь, диләр,
Менә сиңа аулак җирдә кабер, диләр,
Соңгы тапкыр дога укы хәзер, диләр.

Кирәмәт тавы башында агыла болыт,
Соры болыт саубуллаша хәсрәт булып.
Сары яфрак өзеп үкси көзге җилләр:
— Сау булыгыз, туган-үскән җирләр...

Яулар килгән, Әтил буен яулап алган,
Җирләр көйгән, Болгар янган, Бүләр янган.—
Җилләр искән, комнар күчкән, күлләр кипкән,
Ханнар киткән, дәүләт беткән... Китап калган!

❁

Бер көләсе, бер еласы килә,
Күңелләргә тау елгасы килә,
Айга карап ай буласы килә,
Тауга карап тау буласы килә,
Дога булып ил йоласы килә...

Тагын бер ел гомер шаулап үтте.
Офыкларга карап күзләр талды.
Борчылулар, мәшәкатьләр китте,
Моңнар калды.

Әйдә уйна, сикер, бәхетле бул,
Хәерле юл теләп каламын...
Бәлки, әнә шушы малайдыр ул
Яшь даһие килер заманның.

Басу-кырлар сабыр, юаш инде,
Күкләрендә көзге кояш инде.
Уйларыңда күпме сагынсаң да,
Яшьлегеңә кайтып булмас инде.

Сиңа язмыш озын гомер бирде,
Ил данына чәчәк өстәсен дип.
Менә инде алтын көзләр керде,
Нинди алтын туйлар көтәсең бит!

Мин төшемдә матур шигырь яздым,
Шәп китаплар күрдем шүрлек тулы,
Гарип гашыйгы мин көзнең, язның,
Һәм китаплар колы.

Дөнья көтеп, арып-талып,
Күңел яңалык телидер.
Жан сөенгән рухи байлык —
Үзеңнән-үзең көлүдер.

Заман уртасына басып,
Күңелле көннәр киләдер.
Уйлыйсың да елмаясың,
Күңелләр тула нигәдер...

Ил күрүең — илле сум, ди,
Идел суы — илле батман.
И туган ил, синдә генә
Утта янмам, суда батмам.

Яланыңда тай кебек мин,
Үзем усал, үзем шаян.
Уралымда тау кебек мин,—
Кыен чакта миңа таян!

Ургылып урман шауласын,
Каеннар тирбәлсеннәр.
Өздереп кошлар сайрасын,
Җәй үтә димәсеннәр.

Яшел чирәмдә тәгәрә,
Кояшлы, ямьле көннәр.
Кешеләр, илләр үзгәрә —
Яхшыга үзгәрсеннәр!

Урман буйларында сары келәм,
Сары келәмнәргә басып киләм,
Халык әйткән тапкыр сүзне беләм:
«Егет матурлыгы саулык белән,
Кызлар матурлыгы яулык белән.
Көзләр матурлыгы муллык белән...
Илләр түбәнлеге коллык белән».
Сары яфракларга басып киләм,
Яшел үлән юк, яшел үлән...

Көчең, дәртең әлмисакка җитсен,
Тирбәлдереп торсын уй сиртмәсен.
Фән-техника алга китсә китсен,
Тик машина мине кол итмәсен!

Салкын җилләр, эссе җилләр исте,
Бөгелде, сыгылды имәннәрем.
Маңгаема сырлар булып төште
Күргән-белгәннәрем.

Көзен киткән кошлар язын кайтты,
Сөенде, яшәрде каеннарым.
Күз төбенә сырлар булып ятты
Үткән кайгыларым.

Ужымнарым гөжли яңгыр көтеп,
Шаулый карурманым.
Аллы-гөлле бәхет өмет итеп,
Җирдән аерылмадым.

*(Үз-үземә — алтмыш биш яшемдә)*

Казаннарга килеп-китеп,
Кунак йортларында йоклап,
Пәйгамбәр яшенә җитеп,
Язалмадым бер шәп китап...
Фельетон да, мәзәк инде,
Сызгаладым ансын-монсын,
Башка «динсөз» уйлар килде —
«Ходай ярлыкагыл кылсын...»

## Мәхмүт Хәсәнов

# ЯЗГЫ АҖАГАН

РОМАН

## Беренче көн

> Язын аҗаган күргән кешене гомер буе ачы язмыш, фаҗигале хәлләр эзәрлекләр, тормышы тоташтан зар-интизарлы булыр, имеш.
>
> Халык сынамышы.

I



Алар өч бертуган иде: Гази, Таҗи һәм кече энеләре — Һади. Өчесе дә минем балачак дусларым. Өйләребез янәшә генә, бер-беренә орынып ук торалар иде. Бәлки шуңадыр, без үз-үзебезне белешә башлаганнан бирле мәш килеп, әүмәкләшеп бергә үстек. Айкамаган урын, житешмәгән жир, без кермәгән тишек калды микән? Шагыйрь әйтмешли, дөнья белән шулай танышып йөргән идек бергәләп...

Әмма без Бөек Ватан сугышына кадәр үк авылыбыздан китү сәбәпле, араларыбыз искәрмәстән генә өзелде дә куйды. Балачак хатирәләре исә, таң алдыннан күргән могҗизалы төш булып, күңел төбендә гомерлеккә уелып калды.

Балачакны юксыну, аны сагынып искә төшерүне картаю билгесе диләр. Бәлки шулайдыр. Тик ничек кенә булмасын, еллар үткән саен, еш кына туып-үскән жирләрне, туган туфракны, балалык дусларымны күрү теләге яңадан-яңа көч белән кузгала торды. Һәм әйтергә кирәк, уңайлырак чак туры килү белән, газиз туган ягым, балалык дусларым белән араны якынайту, дуслыкны яңарту чарасын күрдем. Уртанчы һәм иң кече Зәкиевлар белән очраштык, хәтта дуслашып киттек. Сирәк-мирәк булса да, анда бер, елда бер дигәндәй, хат яки открытка алышып, хәтер яңартып торгандай итәбез.

Әмма жан дустым, «язмышы тумыштан ук фаҗигале» яшьти Гази белән генә очрашырга туры килмәде. Туган-тумачалары, таныш-белешләре әйтүенә караганда, ул үз тормышын кешечә кора алмаган, кара язмышка тап булган... Барысы да шул каһәр суккан сугышка бәйле. Имештер, Гази фронтта әсирлеккә төшкән, шунда фашистлар белән турыдан-туры хезмәттәшлек иткән... Житмәсә тагын, әлеге хәбәрнең кире

МӘХМҮТ ХӘСӘНОВ (1927) — прозаик, «Саф жилләр», «Юллар, юллар», «Саумы кояш» һәм башка романнар, повестьлар, күп санлы хикәя һәм очерк жыентыклары авторы. Зеленодольскида яши.

каккысыз дәлилләр, хәтта рәсми документлар белән расланганлыгы турында өстәп куярга да онытмыйлар.

Авыр, бик авыр булган иде миңа бу хакта ишетүе. Ә бит Гази мәктәптә укыганда безнең барыбызга караганда да зирәгрәк, акыллырак иде. Нәкъ шул елларда, башлангыч сыйныфларда укыганда ук инде, аның авылыбызның иң сылу кызы Гөлүсә белән чын мәгънәсендә дус булуына без соклана, хәтта чак кына көнләшә дә идек. Аларны «кияү белән кәләш» дип үртәсәләр дә, үсеп җиткәч, ниндидер сәбәпләр аркасында, кавыша алмаулары турында да ишеткән идем.

Дөрес, баштарак Гази яшьтием турында күңелләрне җилкендерерлек, сөенеп туймаслык хәбәрләр дә йөрде. Мәсәлән, Газиның авыл яшьләре арасында бик яшьли комсомолга керүе, ә инде колхозлашу елларында, нәкъ әтисе Хаҗи абый кебек, курку белмичә, кара көчләрнең өненә үк басып кереп, сыйнфый дошманнарны фаш итүе, шунда яралануы турында берсеннән-берсе могҗизалы сүзләр ишетергә туры килде.

Ә инде сугыш башланыр алдыннан Газиның Казанга килүе, рабфакның әзерлек курсларында укып, медицина институты студенты булуы турында ишеткәч, башларым күккә тиярдәй булды. Мин Мәскәүдә укыдым. Каникул көннәре җитеп, Казанга кайткач, балалык дустымны күрим дип, мединститутка барганда, аның авылга кайтып киткән вакытына туры килә идем. Ә инде 1942 елның шыксыз кышында миңа аның, өченче курста укуын ташлап, үзе теләп фронтка киткәнлеге турында хәбәр иттеләр.

Шуннан соң мин: «Эшли алдымы икән ул Ватаны гафу итмәслек шундый җинаятьне?» — дип, еш кына икеләнү тулы уйларга бирелгәләдем.

Аннан соң күп еллар үтте, күп сулар акты. Тормышлар үзгәрде, буыннар алышынырга өлгерде. Газины кабат күрә алуыма өметемне җуя башлаган идем инде. Әмма, гомуми реабилитация елларында аның каяндыр кайтып төшеп, район үзәге больницасында эшли башлавы турында ишеттем. Ләкин әлеге хәбәрләр дә ничектер икеле-микеле иде. Берәүләре хәйраннарга калып: кайда шулай оста хирург була алган, могҗизалар эшли дисә, икенчеләре бөтенләй киресен, тиле-миле кеше турында сүз алып баргандай, җыен тузга язмаганны сөйлиләр иде. Имештер, ул картаеп акылдан язган картлар белән мәш килә, аларны яшәртү турында хыяллана, хәтта бу турыда ниндидер «гыйльми трактатлар» яза...

Һәм менә, чирек гасырга якын вакыт үткәннән соң, бөтенләй уйламаганда-юрамаганда, балачак дустым Гази белән очрашу мөмкинлеге чыгып тора бит, егетләр!

Иртә-таңнан, беренче рейс самолеты белән мин, өлкә газетасының махсус корреспонденты буларак, Мәскәүдән һәм өлкә комитетыннан килгән вәкаләтле комиссия составында, мәшһүр Чулман якларына командировкага чыгып китәргә тиешмен. Бөгелмәдән, «Татнефть» берләшмәсеннән килгән иптәшләр безне Чаллы аэропортында каршы алачаклар. Шулай сөйләшенгән.

Ул вакытта әле даны бөтен җир шарында яңгыраячак КамАЗ да, Түбән Кама комбинатлары да юк иде. Татарстан АЭСы телгә дә кермәгән. Аның каравы, «Икенче Баку» үзәге дип, республикабызның даны күкләргә ашып, борынгы Кама-дәрья буйларында да берсеннән-берсе бай нефть ятмалары ачылган көннәр иде. Әлеге комиссия дә, нәкъ менә шул яңа нефть ятмаларының киләчәген билгеләү, матди базасын тикшерү, Кама буенда да нефть һәм газ чыгару идарәсе төзү мәсьәләсен хәл итәргә дип килгән иде. Нефтьчеләр телендә «Бондюг ятмалары» дип аталган бай нефть чыганаклары әлеге комиссиядән соң «Прикамнефть» идарәсе дип йөртелә башлады.

Командировкамның бер атна чамасы сузыласын белгәч, чыга ашмас хыялларга бирелгән балачак дустым-яшьтием — Газины ничек тә булса күрергә тырышачакмын дип, күңелемә беркетеп тә куйдым. Вакыт сый-

дыра-нитә калса, Чаллы пристаненнән унике генә чакрым ераклыктагы туган авылым Салаязга да сугылып чыгарга булдым.

Кызык, Гази танырмы икән мине? Ничегрәк каршы алыр ул? Хәер, каян килеп танысын ди инде. Унөч-ундүрт яшьлек малай-шалайлар булып аерыл да, кырыктан узгач, чәчләрне чал суккач очраш, имеш!

Гази белән дә очрашасымны уйлагач, дустымның этисе, авылыбызның беренче большевигы Хажи абый белән булган фажигале хәлләр бөтен тулылыгы белән күз алдыма килде дә басты...

Ай-һай, хәвефле булган иде дә соң ул иртә! Кешеләрнең жанына шик-шөбһә салып, иң элек каравыл өе янындагы каланча чаңын суктылар. Авыл халкы чак кына аңга килеп: «Ут-күз чыккандыр, бүтән берни дә түгелдер!» — диеп өйләреннән атылышып чыкканда, кайберәүләр инде түбән очка, каравыл өенә таба чатыр-чотыр килеп чаба да башлаганнар иде. Кешеләр, ни булды, нәрсә бар дип, аңгы-миңге торган арада, урам уртасыннан йөгергән бер хатынның ачыргаланып: «Хараплар гына иткәннәр ич... Комитет Хажиен үтергәннәр!..» — дип сөрән салуы барысын да өнсез итте.

Авылда мәхшәр купты. Хажи абый, орынып торган күршебез булу белән бергә, жан дустым Газиның этисе дә бит әле. Шулай булгач, ничек инде мин генә ул гыйбрәтле хәлләрне күрмичә калырга тиеш ди. Әмма әни минем ниятемне шундук абайлап та алды. «Юк, юк! Йөрисе юк... Аның карарлыгын калдырмаганнар ди. Югыйсә, төнлә күз алларыңнан китмәс, төшләреңә кереп газаплар...» — дип, юлыма аркылы төште. Шундук: «Ходаем ла! Андый фажигале үлемнәрне якыныңа түгел, дошманыңа да язмасын берүк!» — дип авыз эченнән генә дога укыган сыман сөйләнеп куйды.

Аның әлеге шомлы сүзләре кызыксынуымны арттырды гына. Мин өй артына чыккандай иттем дә, як-ягын яшь кычыткан сара башлаган иске читән аша сикереп, әйдә, элдерт кенә Совет йорты ягына! Мин барып житкәндә, каравыл өе каршында мәхшәр иде инде.

Жигүле ат янына ерып кермәле түгел: халык, халык! Һәркем аһ та ваһ итә, һәркемнең йөзендә аптырау галәмәтләре. Бер якта карчык-корчыклар, хатын-кызлар жыелган. Авызларын каплый төшеп, сүз саен диярлек: «И-и, ходаем!» — дип, үзара мыдыр-мыдыр сөйләнәләр. Мин, халык төркемен ера-ера, ир-ат жыелган якка юл тоттым. Анда югары оч Байтимере авылдашларыбыз арасына кереп алган да, кулын болгый-болгый, нидер сөйли:

— ...Ишетәм, ат кешни. Бер кешни бу, ике кешни. Чыгып карасам, күрәм: бикләнгән басу капкасы артында жигүле ат тора. Хужасы күренми. Тукта, мин әйтәм, һич югында, капканы ачып, малкайны кертим. Килеп житеп, арбага күз салуым булды, аяк астында жир убылды да китте...

Колагыма: «Кеше кадәр кешене дә шул хәлгә төшерерләр икән!.. Я-а ходай! Нинди кансызлык...»— дигән сүзләр чагылса да, берни күрә алмадым. Терсәкләрем белән этенгәләп-төртенгәләп алгарак үттем. Кемдер, Совет өе кыегында эленеп торган кызыл әләмне алып, Хажи абый өстенә ябып куйган иде инде.

Шулчак кара болыт сыман жыелган халык өстеннән көчле жил искәндәй булды. Кемдер: «Әнә!.. Зәйтүнә үзе килә...»— дигән хәбәр салды. Бераздан минем жан дустым Газины житәкләгән, кечерәк Тажины кулына күтәргән Зәйтүнә түти күренде. Халык, як-якка чигенеп, аларга юл бирде. Тирә-юньдә янә борчулы пышылдашкан авазлар: «Кыяфәтен генә күр инде мескенкәйнең. Өченчесе буенда бит... И-и, бичара!..»

Зәйтүнә түти арба янына житеп туктагач, моңарчы мин һичкайчан да ишетмәгән тавыш белән, йөрәк итләрен телгәләп, аваз салды:

— Йа-а, раббым! Шулайлар итеп башкайларыңа життеләрмени?!. Үлепләр китим микәнни! Һай-й, аллам!.. Балакайларым ла!.. Шулайлар итеп гомер буена ятимлек азабы чигәрсез микәнни?.. Сынык канатлы ятимкәйләрем лә!..

Шул вакыт әллә нәрсә булды. Зәйтүнә түти кинәт кенә арба урәчәсе өстенә сыгылып төште... Көмдер аны, бөтенләй егылып китмәсен диптер инде, тотып калды. Икенче берәве аның кулындагы баланы алды. Ыгы-зыгы моның белән генә чикләнмәде. Җиргә үк шуып төшкән Зәйтүнә түтине як-яктан җитәкләп Совет өенә алып кереп киттеләр. Ул да булмады, ут капкан сыман итенеп һәм разбой салып, өрү-өшкерү, им-том белән шөгыльләнүче Мәгыйшә карчыкны чакыра башладылар.

Болдырда Совет башлыгы, ярлылар ширкәте рәисе Бәһрам абзый күренде. Сыңар аяклы ул. Бер аягын кайда, ничек югалтканлыгы турында төрле сүзләр йөри. Дошманнары аны «ата бәлшәвик» дип тә, «коммун эте» дип тә атыйлар. Халык арасында исә Чатан Бәһрам дип тә, солдат Бәһрам дип тә, бәлшәвик Бәһрам дип тә йөртәләр. Иманы юлында бөтен дөньясында бер ялгызы калганда да чигенүне белә торган кеше түгел дип өстәргә дә онытмыйлар аның турында.

Өстендә ямаулы шинель. Менә ул, агач аяклары белән идәннәрне шакы-шокы китереп, баскычның алгы өлешенәрәк якынайды. Кискен хәрәкәтләнеп, көрәктәй зур кулы белән башындагы бүреген йолкып алды да, халыкны тынычланырга чакырып булса кирәк, бүрекле кулын өскә күтәрде. Бу минутта җилдә-кояшта янган озынча-чандыр йөзе ифрат та кырыс, эчкә баткан күзләрендә ут иде аның. Шулчак Бәһрам абыйның көчле тавышы һаваны ярды:

— Җә-ә, күрдегезме инде, җәмәгать! Иске, үлеп бара торган сыйныф капылт кына юл бирергә ашыкмый. Юк-к, ашыкмый! Шундый юллар белән бәлки алар безне куркытырга тели торганнардыр? Юук-к, курыкмыйбыз! Аларның җан бирер алдыннан тыпырчынуларына без сафларыбызны тагын да ныгыту белән җавап кайтарачакбыз. Самодержавиене, капиталны җиңгән кеше өчен курку юк ул!..— Бәһрам абыйның йөрәккә төшәрдәй сүзләре тынып калган халык өстендә көчле яңгырый иде: — Бөтен аңлы гомерен изелгән халыкны азат итү өчен соңгы сулышына чаклы аяусыз көрәшкән, бөек пролетар революциясенең шанлы каһарманы арабыздан китеп барды. Нишләмәк кирәк, иптәшләр, авыр, бик авыр... Тик көрәш корбансыз булмый. Әмма Совет власте өчен, халык бәхете өчен үз-үзләрен аямыйча көрәшкән, газиз гомерләрен кызганмаган батырлар, фидаи җаннар, гасырлар буена онытылмас, аларның изге хатирәсе халык күңелендә мәңге яшәр! Халык хәтере — бөек нәрсә! Азатлык кояшы бөтен галәмне яктыртсын, иптәшләр!..

Бәһрам абыйның тавышы тантаналы да, аяныч та иде. Шунда тагын көтелмәгән хәл булды: Совет өенең ярым ачык тәрәзәсе аша, аермачык булып, әле яңа гына туган баланың шәрран ярып чырылдап елап җибәргән тавышы ишетелде. Бу вакыйга барысына да аяз көнне күк күкрәгәндәй тәэсир итте. Бу — дустым Газиның нәни энесе Һадиның дөньяга аваз салуы иде.

Хаҗи абыйны бары тик өченче көнне генә җирләделәр. Шунда мин үз гомеремдә беренче тапкыр җиз торбалар, көмеш быргыларның матәм маршы уйнавын һәм сафка тезелгән кызылармеецларның һавага төзәп мылтыктан атуларын ишеттем.

Бары тик берничә көн узгач кына мин «икмәк комиссары» дип исеме чыккан Хаҗи абыйның дошманнар тарафыннан ничегрәк итеп җәзалап үтерелүен белдем. Явыз контрлар аның эчен ярып арыш тутырганнар. Авыз-борын тирәләрендә дә кан белән арыш аралашып укмашкан иде дип сөйләделәр. Арба төбенә түшәлгән юкә кабыгының буеннан-буена тигезле-тигезсез хәрефләр белән язылган сүзләрнең мәгънәсен дә әйттеләр. Дегет беләнме, кан катыш кара буяу беләнме: «Тыгын, бәлшәвик эте!..» — дип язылган булган икән.

Әлеге фаҗигале хәлләрдән соң ике-өч ай да үтмәгәндер, дошманнарның кулга алынулары, пристаньле волость үзәге — Чаллыда суд булуы турында хәбәр таралды. Аннан соң инде өч кешенең атылырга, берничә кешенең сөргенгә хөкем ителүләре турындагы хәбәрне ишетте халык.

Әмма сүзнең иң кәттәсен, иң хикмәтлесен, күңелемә мәңгегә онытылмаслык булып уелырлыгын чак кына соңрак ишеттем. Имештер, имтом, күрәзәлек итү, багуише нәрсәләр белән шөгыльләнүче Мәгыйшә карчык Газилар гаиләсендә зур фаҗига буласын, ә Газиның гомер буе зур афәтләр, газап-михнәтләр кичерәсен, атна-ун көн элек белгән икән. Янәсе Гази, әтисе үтерелергә атна-ун көн кала, аҗаган балкышын күргән. Күргән дә, имеш, өенә йөгереп кайтып, әнисенә әйткән. Мәгыйшә карчык та шунда булган. Им-томчы әби ишеткән дә: «Ай-һай, балакай, андый көфер сүзләрне авызыңнан җил ала күрсен берүк. Саташа күрмә, Газиулла балакай, бу вакытта, яз башында, нинди аҗаган булсын»,— дип әйтеп әйткән имештер...

Мин үзем җыен килде-китте ырым-шырымга, төрле хорафатларга ышана торганнардан түгел. Әмма Мәгыйшә карчыкның бик тә үтемле гыйбарәләр белән нығытып әйткән әлеге сүзләре минем дә күңел түрендә, ниндидер юшкынга охшап, кара шом булып утырды да калды. Аҗаганның яз көннәрендә булмавын яхшы беләм. Ул, гадәттә, җәй сынып көзгә авышкач, игеннәр җитлегә башлагач була. Халыкта аҗаганны «арыш камчысы» дигән сүз дә яши. Бу турыда хәтта җыр да бар:

Арыш башак кыскан чакта
Уйный диләр аҗаган...

Ул еллардан бирле күп гомерләр үтте. Әмма, аҗаганның ялт-йолт килеп, күңел күген камчылаган әрсез, шыксыз-салкын балкышы, күзләремне чытырдап йомганда да, керфекләрем аша үтеп керә... Теләсәмтеләмәсәм дә, андый чакларда, бичара дустым Гази ниләр кичерде икән дигән уй камчылый башлый.

Һәм менә чирек гасыр буе йөрәк түремдә йөрткән әлеге сорауга җавап табар вакыт якыная. Бүген я иртәгә җан дустым — хыялый балачак дустым Гази белән очрашачакмын...

## 2

Өйдә юраган юлда ярамый, дигән сүз хак булып чыкты. Бернәрсә дә мин дигәнчә булмады. Гази эшләгән больницада да булдым, җан дустымны да күрдем, әмма: «Саумы, газиз дустым! Син дә бармыни әле бу фани дөньяда?!» — дип, кочагыма алып кысарга язмаган икән шул...

Комиссия әгъзалары белән Казан аэропортында очраштык. Монда партия өлкә комитетының промышленность бүлеге мөдире һәм СССР нефть промышленносте министрлыгыннан килгән иптәштән тыш, Дәүләт план комитетыннан килгән кеше дә бар иде. Комиссия җитәкчесен Анатолий Степанович дип таныштырдылар. Фамилиясе Кремнев. Таныштырганда ук: «Бу картлачка ни җитмәде икән? Пенсиясен алып, өендә генә утырса соң...» — дигән фикер килде. Чыннан да, Анатолий Степанович шактый өлкән яшьтә күренә. Сизелерлек юанайган, эре сөякле, салмак хәрәкәтле, әмма гаять дәрәҗәдә ачык йөзле, шат чырайлы бер кеше иде.

Арабызда хатын-кыз да бар: Галина Николаевна Горцева. Аны КПСС Үзәк Комитеты каршындагы Үзәк Статистика идарәсеннән диделәр. Ул да инде яшь түгел. Әмма килеш-килбәтенә, буй-сынына караганда, аңар бер дә үз яшен бирерлек түгел. Акыллы, үткен телле. Анатолий Степановичның күптәнге танышы булса кирәк. Гашыйк булган кешеләр сыман итенәләр: бер-берсенең һәр адымын, һәр хәрәкәтен күздән яздырмыйлар, берсе икенчесе өчен үләргә әзер кебек өф-өф итеп кенә торалар.

Ләкин алар моны уен-көлкегә әверелдереп, ярым шаярып эшлиләр. Тик ничек кенә булмасын, бу ике кешене бик күп уртак хәлләр, уртак язмышлар һәм күп елларга сузылган дуслык җепләре бәйләгәнлеген сиземләве әллә ни кыен түгел иде.

Мәскәүдән тагын ике иптәш бар. Болары урта яшьләрдә. Сүзгә кушылмыйча, Анатолий Степанович белән Галина Николаевна ягына карап: «Ярар, ярар... Теләгән кадәр юаныгыз, безнең эшебез юк»,— дигәндәй, мөлаем генә елмаешып, читтән карап торалар.

Безгә уникә генә урынлы махсус самолет бирделәр. Көннең рәтечираты юк. Барыбер очтык. Шактый вакыт болытлар арасында чайкалырга туры килде. Бары тиқ җиргә төшәр алдыннан гына, язгы авыр болытларны ерткалап, яктылыкка чыктык. Сирәк-мирәк кенә баркаслар, баржалар, кечерәк пароходлар күзгә чалынып калдылар.

Бераздан безнең самолет өй түбәләренә тиярдәй булып астан гына очып үтте дә тип-тигез мәйдан буйлап җилле генә йөгереп узды.

Гостиницага урнаштырганнан соң,безне башта төркемнәргә бүлделәр, аннары «вездеходларга» утыртып, объектларга алып чыгып киттеләр.

Мин, күптәнге танышым — «Татнефть» берләшмәсе начальнигы иптәш Галиханов җитәкчелек иткән төркем белән ярымутрауда урнашкан разведка буровоена барырга булдым. Көнозын сәяхәт иттек. Нинди юллар гына үтәргә туры килмәде. Җитмәсә тагын көн дә бозылды. Күк йөзен авыр салмак болытлар каплап алды, бераздан инде пыскып кына, бик вәземләп, бик сеңдереп кенә, яңгыр сибәләргә кереште. Җиллəп-җиллəп, бик тырышып яуды ул.

Караңгы төшеп, ут алгач кына якты, җылы гостиницабызга кайтып егылдык. Арып-талып, тәмам хәлдән таеп кайтуыбызга да карамастан, безгә иркенләп, рәхәтләнеп ял итәргә язмаган икән. Комиссия җитәкчесе Анатолий Степановичның Чаллы белән Түбән Кама арасында корыла торган үзәк нефть үткәргечне кararга барган җирендә кинәт кенә чирләп китүе һәм больницага салынуы мәгълүм булды.

Без шунда ук больницага шалтыраттык. Галина Николаевна анда иде инде. Ул безгә борчылмаска, әллә ни хафаланмаска кушты. Анатолий Степановичта нибары гап-гади сукыр эчәге пристубы гына булган. «Әгәр дә хәле җиңеләймәсә, операция ясаячаклар»,— дип өстәп тә куйды.

Больница дигән сүзне ишетү белән, кылт итеп: «Гази да шунда бит... Сынықка сылтау дигәндәй, менә, очрашу өчен сәбәп тә булды...»— дигән уй туды. Гостиницада бергә туктаган иптәшләрнең, больницага барыргамы-бармаскамы дигәндәй икеләнеп торуларына карамыйча, киенә дә башладым.

Больница дигән сүзне ишетү белән, кылт итеп: «Гази да шунда бит... сорашып белгән идем. Каманың текә яры өстендә, урман кебек куерып үскән карт тупыллар, йөзәр яшьлек тирәкләр ышыгында утыра ул.

Урамга чыгу белән, әллә кире борылыйммы, дигән уй килде. Аяктан егардай булып зәһәр җил ыргый. Көне буе тоташтан сибәләгән явымтөшем үзенекен иткән, адәм аяклана алмаслык пычрак. Үч иткән кебек, аякларны «тышаулап» ләпек урала. Туфлиләр шулкадәр авырайды, йолкып алыр хәл юк үзләрен. Иртә якта, машиналарга төялеп сәяхәткә чыгып китәр алдыннан гына, теләгән кешеләргә резина итекләр тәкъдим иткәннәр иде, алмавыма хәзер үкенеп бетә алмадым.

Ыргып-ыргып җил бәрә. Вак яңгыр сибәли. Үзе караңгы. Бары тик өйләрнең тәрәзәләреннән төшкән тоныч яктылык кына аяк асларын яктырткандай итә.

Ниһаять, якты тәрәзәле өйләр дә артта калдылар. Бушлыкка килеп чыктым. Монда җил тагын да яманрак булып котырына. Чак кына сулдарак, текә яр астында, язгы ташуның шашкын гөрелтесенә охшап, Каманың уфтанулы сулкылдавы ишетелә.

Чиксез зур дулкынлану белән атлап кердем мин больница бусагасын. Якты вестибюль. Ишек катында мине берьюлы ике хатын-кыз каршылады.

Берсе мөлаем генә карчык. Йөзен җыерчыклар баскан. Авыз тирәләре дә бөрешеп килгән, җыерчыклар бизәгән иреннәре кысылганнар, җөйләнгән яраны хәтерләтеп торалар. Чал кунган кашлары астыннан карап торган ярым тоныкк күзләре дә шактый чепиләнгәннәр. Аның каравы дага кадәрле зур көмеш алкалары җылык-җылык килеп торалар.

Ә икенчесе — бер карауда өнсез итәрлеге — яшь, күп дигәндә егерме җиделәр тирәсендә. Әйе, табигать юмартланса юмартлана бела, кочагы белән бирә. Минем каршыда басып торган сылу да шундый бәхетлеләрнең берсе иде. Өстендә күз явын алырлык ап-ак халат. Килеш-килбәтле горур, буй-сыны зифа.

Минем татарча исәнләшүем, икесенә дә берьюлы җан өргәндәй итте.

Сәламемне беренче булып сылу алды.

— Исәнмесез!— диде ул, миңа таба бер-ике адым ясап. «Әйе, тавышы да нәкъ үзе кебек үк мөлаем, күңелгә ятышлы икән»,— дип уйлап куйдым мин. Һәм сүзне дәвам итү нияте белән:

— Безнең бер иптәшне сезгә китергәннәр икән,— дидем.

— Әйе, бездә,— диде чибәребез.

Ул арада әби кеше дә сүзгә кушылды.

— Сезнең кешеләр менә монда... Баш врачыбыз бүлмәсендә,— диде, каршы яктагы зур гына ишеккә күрсәтеп.

Мине бүлмә буенча әрле-бирле йөренгән Мәскәү вәкиле Галина Николаевна каршы алды. Гаять киеренке халәттә булуы йөзенә чыккан иде аның. Мине күрү белән, эчен бушатырлык кеше табылуына куангансыман, тәкрарлый да башлады:

— Көтелмәгән бәла бездә...

— Зинһар, шул кадәр хафаланмагыз! Бар да яхшы булыр...—Бу сүзләрне зур гына язу өстәле янында басып торган ак халатлы ир-ат әйтте.

— Гафу итә күрегез,— дип, Галина Николаевна елмаерга тырышты.— Сез бит әле танышмадыгыз. Рәхим итегез!..

Район больницасының баш врачы үзен Булат Хәнипович дип таныштырды. Фамилиясе Хәмзин икән.

Шунысы кызык, аның ап-ак һәм песи баласы кебек йомшак кулын кысканда, әле монда кергәндә генә вестибюльдә очраткан, беренче сулышта ук үзенә әсир итәрлек сылу ханымның ире-фәләндәр дигән уй килде башыма. Чөнки алар, бер төптә өлгергәндәй, бик тә пар килгәннәр иде. Баш врач та ачык чырайлы, гаять мөлаем кеше. Аның шул ачык йөзеннән саф күңеллелеге чагылып, ничектер пакьлек бөркелеп тора кебек. Шулай да күз карашлары үткер. Чем-кара чәче һәйбәтләп таралган, түшәмдәге люстрадан төшкән яктылыкта майлап куелганга охшап елкылдап тора. Өстендәге ак халатына кадәр килешле.

Шулай танышкан арада, мин инде җаен китереп, балачак дустым Гази турында да сораштырмакчы идем. Әмма өлгерә алмыйчарак калдым, кабинет ишеге артында кызу-кызу атлап килүченең аяк тавышлары ишетелде. Ир-ат адымнары иде бу. Янә: «Газидыр»,—дигән уй чагылып китте. Йөрәгем дә еш-еш тибә башлады. «Танырмы икән?..»

Ишектә өстенә ак халат кигән, башына ак кәпәч чәпәгән ир-ат күренде. Бу, чыннан да, Гази иде. «Саумы, җан дустым! Исәнме, яланаяк килеш чатыр-чотыр чабып йөргән балачагым!»— дип барып күрешүдән үземне чак кына тыеп калдым.

Әй-йе, бик күп еллар узган икән шул. Газиның авыр, михнәтле тормыш кичергәнлеге йөзенә чыккан. Күз карашыннан чак кына, сизелер-сизелмәс булып, моң-зар саркып тора. Бөтен кыяфәтеннән, үз-үзен тотышыннан, бик нык кагылып-сугылганлыгы, рухи газаплар кичергәнлеге ничектер беренче караштa ук күзгә бәрелә. Ак кәпәче астыннан күренеп торган чигә чәчләрен чал суккан. Йөзендә миңа ят булу дәрәҗәсендәге үзгәрешләр күрмим кебек. Яшьлек елларында кулак ияръченнәре тарафыннан калдырылган «тамга» гына күрер күзгә ташланып тора сыман. Әлеге яра аның уң кашын тип-тигез итеп өстән-аска таба икегә бүлгән. Кашының бер яр-

тысы (сул кашына тоташып торганы) аскарак шуышкан, ә икенче яртысы, киресенчә, кош канатыдай кыйгачланып өскә чөелгән. Бәлки шуңа күрәдер, Газинең йөзе беренче карашка, ничектер кырысрак булып күренә.

Юк, танымады ул мине, хәтта игътибар да итмәде. Хәер, бу минутта анда-монда кайгысы да юк иде кебек аның. Ул җил-җил килеп керү белән, турыдан-туры баш врачка мөрәҗәгать итте. Һәм Газиның бу мөрәҗәгате, мөрәҗәгать булудан бигрәк, ничектер рапорт бирүгә охшашлырак иде...

— Булат Хәнипович, башлыйбыз...— диде ул. Һәм шунда ук, Горцевага мөрәҗәгать итте.— Гафу итегез!.. Сезнең кемегез була ул?

Әмма, «Башлыйбыз» сүзен ишетүдәнме, тәмам югалып калган Галина Николаевна җавап кайтарырга өлгерә алмады. Баш врач, Газига таба нелә төшеп, шактый кискен җавап кайтарды:

— Аның кем булуы Сезнең өчен шулкадәр әһәмиятледер дип уйламыйм...

— Авыруның хәле шактый хәвефле, соңгы приступ түгелме икән, дип сорамакчы идем мин.

— Тем более!..—дип кырт кисте баш врач.— Барыгыз! Авыру янында булыгыз. Ә операцияне чак кына кичектереп торыгыз...

Гази башка бер сүз дә әйтмәде. Әмма баш врачның соңгы сүзләре аны беркадәр сәерсендерде, ахрысы. Ул, дөрес ишеттемме дигән кыяфәт белән, коллегасының йөзенә текәлде. Ләкин сорау-фәлән биреп тормады, борылып чыгып та китте. Күрешмичә калуым, шуның өстенә үзен «Булат Хәнипович» дип таныткан кешенең балачак дустыма шактый каты бәрелүе күңелемне рәнҗетте. Ләкин шунда ук баш врачның бу адымын үземчә акларга да тырышып карадым. «Хуҗа кеше үзенең нәрсә эшләгәнен белә торгандыр. Бәлки Гази җаваплы операцияләр ясарга яраксыздыр»,— дигән уйлар башыма килде. Әмма Газиның кабинет ишегеннән чыгу белән, кемнәргәдер нииндидер әмер бирүен, тавышының шактый ук кыю һәм көр яңгыравын ишетү күңелемдә туган әлеге уйларымны шик астына алды.

Бераз тактсызлык күрсәтүен баш врач үзе дә сизенде ахрысы, бүлмәдә бераз вакыт авыр тынлык хөкем сөргәннән соң, гафу үтенгән төсле болай диде:

— Сез, зинһар дип сорыйм, гаҗәпләнә күрмәгез... Хирург белән шулай кискенрәк сөйләшүем өчен дип әйтүем.

Галина Николаевна, безгә нәрсә дигән сыман, җилкәләрен сикертеп алды. Шулай да авыз эченнән генә мыгырдангандай әйтеп куйды:

— Сәеррәк, әлбәттә.

— Сәбәпләре бар.— Бу юлы инде баш врачның тавышы нык иде.

Шул вакыт Булат Хәнипович безнең икебезне дә сагайтырлык, хәтта каушатырлык сүз ычкындырды. Бик гади итеп, сүзенең һичшиксез хаклыгына ышанып әйтте ул бу сүзләрне.

— Гомумән...— диде ул, әйтергәме әллә әйтмәсәм дә ярармы дигәндәй, бермәлгә тукталып.— Гомумән, мин авыруга... иптәш Кремневка дип әйтүем, операцияне әлеге хирургтан ясатмас идем.

Бу сүзләр Галина Николаевнаны тәмам пошаманга төшерде.

— Шулаймы? Нәрсә?.. Әллә тәҗрибәсезме?

— Алай димәс идем. Шулай да соңгы вакытларда эшендә... чатаклыклар чыккалады. Аннары хикмәт анда гына да түгел... Үткәне турында бик тә яман хәбәр алынды.

Баш врачның бу сүзләре Горцеваны тагын да каушата төште. Ул, ярдәм эзләгәндәй, бер миңа, бер ак халатлы хуҗа кешегә карап, кулларын күкрәк тирәсендә хәрәкәтләндереп, яңадан сөйләнеп алды.

— Ул кадәресен сез яхшырак беләсездер. Тик, зинһар дип сорыйм... Кабат үтенеп сорыйм Сездән...

Булат Хәнипович аны тынычландыра башлады.

— Зинһар, хафаланмагыз. Бар да һәйбәт булыр,— диде ул баягы сүзләрен кабатлап.— Безнең менә дигән яшь белгечебез бар. Үзе югары

белемле. Шуның өстенә ординатура да тәмамлаган. Операцияне дә шул хирургтан ясатырбыз...

Дулкынлануы йөзенә чыккан хатынга шул җитә калды.

— Рәхмәт! Рәхмәт яусын Сезгә...— дип кабатлады ул бер үк сүзләрне.— Тик кабат сорыйм сездән... зинһар дип үтенәм.

Баш врач, биргән вәгъдәсен шул ук минутта тормышка ашырырга җыенган сыман, җәһәт кенә халатының өске төймәсен каптырды. Нәкъ шул вакыт ишек артында яңадан җил-җил атлап килүче Газиның аяк тавышлары ишетелде. Шуны гына көтеп торган кебек, баш врач бик илтифатлы кыяфәт белән бездән гафу үтенде дә ишеккә таба юнәлде. Булачак сөйләшүне чит кешеләргә ишеттерергә теләмичә булса кирәк, үзе артыннан ишекне япты. Әмма буйсынмас ишек бу юлы да тавыш-тынсыз гына яртылаш ачылып китте.

— Керешәбез, Булат Хәнипович!— диде Гази. Тавышы тигез, нык иде аның. Әйтерсең лә баягы кырыс сөйләшү бөтенләй булмаган. Һәм вакытның бер генә минутын да әрәм итәргә ярамаганлыкны аңлатырга теләгән кебек өстәп куйды:— Бар да әзер.

— Анысы өчен рәхмәт,— диде баш врач сабыр тынычлык белән.— Әмма, Гази Хаҗиевич... бу операцияне сез ясамыйсыз.

Бу көтелмәгән хәл Газины аптырашта калдырды, күрәсең.

— Ничек инде?..

— Минемчә, аңларлык итеп әйттем кебек: бу операцияне сез ясамыйсыз!

— Аңламыйм... Ничек инде алай, кинәт кенә?..— Хәзер инде Газинең тавышы баягы кебек үк көчле түгел, әйтерсең лә ул бу минутта зиһенен җыя алмыйча азаплана иде.— Ничек инде?.. Авыруны мин әзерләдем. Мин ясамыйча, кем ясасын ди тагын. Мин хирург. Анда операция өстәлендә кеше ята. Хәле җитди... Ашыгыч операция кирәк. Соңга калуыбыз бар...

— Искә төшереп, кисәтеп куюыгыз өчен рәхмәт, әлбәттә...

Баш врачның һаман да шулай тыныч кына, берни дә булмагандай сүзен дәвам итүе Газины чыгырыннан чыгарды ахрысы.

— Юк-к..— диде ул кинәт тавышын күтәреп.— Мин ясарга тиеш... Мин!

Бу — Газиның чын-чыннан саксызлык күрсәтүе иде.

Галина Николаевна минем якка борылды, торыш-кыяфәтендә, күз карашларында, бердәнбер сорау: «Сез нәрсә дә булса аңлыйсызмы?» Минем дә җавабым бер, җилкәмне сикертү: һични аңламыйм, янәсе.

Хәлем әдәплелек кагыйдәләре белән санашып торудан узган иде инде. Ишек янына килдем, аны тагын да ача төштем. Бөтен вестибюль уч төбендәге кебек. Газиның тавышына булса кирәк, баягы олы алкалы апа белән сылу ханым да чыкты. Болардан тыш ишек катында басып торучы базык кына гәүдәле тагын бер егетне абайлап алдым. Килеш-килбәтенә, киемсалымына караганда, больница шоферы булырга тиеш.

Бу хәлдән баш врач та, Гази да чак кына уңайсызландылар булса кирәк. (Әле дә ярый, ярым ачык ишек аша минем дә күзәтеп торганны күрмиләр.) Әмма хуҗа кеше әллә ни үзгәрмәде, баягы кебек сабыр-тыйнак кына итеп соңгы сүзен әйтте.

— Аңлагансыздыр дип уйлыйм,— диде ул, кешеләрнең тынычлыгын бозганга чын-чыннан уңайсызланган кебек.— Ә инде аңламаган булсагыз, соңрак, башка вакытта, кешеләр юктарак сөйләшербез...

Гази да бу әмергә буйсынгандай булды. Шулай да кисәтеп, хәлне аңлатып куюны үзенең бурычы итеп санады ахрысы.

— Мин ясамыйм икән, әнә, Диса Зиннәтовна ясасын. Авыру операциягә әзер...

Бәхәс тәмамланмаган иде әле.

— Кабат әйтәм, кисәтеп куюыгыз өчен рәхмәт. Калганы турында үзебез кайгыртырбыз.

— Ләкин тиз кирәк...
— Һәм тиз ясалыр да.
— Тиз булса ярар... Тик шулай да... миннән ясатмавыгызның һич югы сәбәбен әйтегез.
— Сәбәбенме? Әйтергә була. Мин тагын, бәлки үзегез үк төшенерсезме, дип уйлаган идем...
— Сәбәбе — узган атнада бораулау мастеры белән булган күңелсезлек түгелдер ич? Ул турыда бер тапкыр сүз булган иде ләбаса.
— Юк. Кызганычка каршы, ул вакыйгага гына түгел...
Булат Хәнипович, бу мәгънәсез бәхәскә чик куярга теләгәндәй, соңгы сүзен әйтте:— Озын сүзнең кыскасы, баш врач буларак, бу авыруга операция ясауны мин сезгә... ышанып тапшыра алмыйм.
— Менә хәзер... хәзер азрак төшендем кебек. Чөнки минем үткәнем күләгәле...— Гази кинәт кенә шиңеп калгандай булды, авыз эченнән генә мыгырданып куйды.— Ә анда Мәскәү кадәр Мәскәүдән килгән комиссия члены... Зур кеше. Ләкин бит чир алдында бар кешеләр дә бер...
Баш врач аңар әйтеп бетерергә дә ирек бирмәде.
— Аның каравы, дәвалаучылар бер түгел. Монда фәлсәфә сатып торасы юк, аңлагансыздыр дип уйлыйм.
Булат Хәнипович бүтән бер сүз дә әйтмәде. Бары тик: «Синең белән эш бетте»,— дигән кебек итеп, Газига яны белән басты да, берике адым алга таба хәрәкәт ясап, баядан бирле дәшми-тынмый гына басып торган хатын-кызларга мөрәҗәгать итте:
— Дисә Зиннәтовна, тиз генә минем янга керегез әле...
Сылу хатын, шундук җитез-җәһәт атлап китәргә җыенган сыман, алга таба өмсенеп куйды.
Ул арада баш врач кабинетына таба юнәлә дә башлаган иде инде. Шул вакыт яңадан Газиның тавышы ишетелде. Ләкин бу юлы инде аның тавышы гади сөйләшүдән бигрәк күтәрелеп бәрелүгә, ачыргаланып кычкыруга, ничектер протест белдерүгә охшаган иде.
— Җитте!.. Һич югында әйтегезче, зинһар... Нәрсә дип шулкадәр каныктыгыз әле миңа? Нинди зыяным тиде соң минем Сезгә? Нинди гаебем бар минем? Кайчандыр булган гөнаһым өчен мин инде күптән җәзамны алдым. Җиттеме сезгә, юкмы, ниһаять!..— Гази, үткен хәнҗәр кадалгандай кискен хәрәкәтләнеп, ике куллап йөрәк турысын каплады. Аннары, башын тагын да ия төшеп, алга таба сөрлегеп куйды. Әмма аягында басып калды. Шулчак әкрен генә башын калкытып, тонган күз карашын баш врачка текәде. Яман иде аның бу карашы, тетрәндергеч иде. Беравык зиһенен җыя алмаган кеше сыман сүзсез торды Гази. Аннары, «Шауламагыз, операция бара!» дип кисәткән кызыл утка күрсәтеп, әйтте:
— Сез оныттыгыз ахры... Анда... авыру ята. Хәле авыр. Мин исә хәзер, теләгән тәкъдирдә дә, кулыма скальпель ала алмаячакмын. Мин үзем ярдәмгә мохтаҗ хәзер...— Гази, исерек кеше сыман чайкалып-сөрлегеп, уң яктагы ишекләрнең берсенә кереп юк булды.
Киеренке тынлыкны беренче булып апа кеше бозды:
— Һай-й, Булат улым...— диде ул, җыларга җыенган сыман итеп.— Туры сүзгә җан корбан дигәндәй, әйтми түзәр чамам юк. Кирәкмәс иде... Һай-й, кирәкмәс иде! Һич кенә дә башыма сыйдыра алмыйм, нәрсә булды соң Сезгә?.. Йөрәк тавышы белән кычкырды бит, бичаракай. Яман нәрсә ул... Бәлки, кабинетыгызга чакырып алып үзенә генә аңлатырга кирәк булгандыр...
Баш врачның ярсуы, ниһаять, тышка бәреп чыкты.
— Юк-к, Гайния түти!.. Әгәр дә кодрәтемнән килсә, андыйларны кабинетыма түгел, больница ишегенә аша да аяк атлатмас идем...
Шул вакыт көтелмәгән хәл булды. Бая Булат Хәнипович мөрәҗәгать иткән сылу ханым, кызу-кызу атлап баш врач алдына килеп басты да кискен хәрәкәт белән марля-битлеген йолкып алды. Зәһәр иде бу минут-

та аның кыяфәтне. Каш астыннан өздереп караган күзләре ут чәчә, борын яфраклары хәрәкәтләнә.

— Эх-х, Сез!..— диде ул, кирәкле сүз таба алмыйча гаҗиз калган кеше сыман.— Хирург Гази Хаҗиевичның сүзләрен мин дә кабатларга мәҗбүрмен. Анда... операция өстәлендә — авыру! Сез аның турында онытгыгыз ахрысы. Бу кадәресен мин дә көтмәгән идем Сездән. Эх-х, Сез!..

Сылу хатын кинәт кенә борылды да әле яңа гына Гази артыннан ябылган ишеккә таба юнәлде. Булат Хәнипович кинәт әмер биргән тонда кычкырып җибәрде:

— Дисә!.. Дисә Зиннәтовна!.. Иптәш Әнәсова!

Сылу туктады. Баш врач, аңа таба бер-ике адым атлап, өстәде:

— Операцияне Сез ясыйсыз. Хәзер үк керешегез!..

— Юк!— диде сылу хатын күзен дә йоммыйча.— Ассистентсыз алынмаячакмын. Уйламагыз да! Теләсәгез нишләтегез... Сүзем сүз, әмма Гази Хаҗиевичтан башка операционныйга аяк басмаячакмын...

— Җүләрләнмә, Дисә! Нишләвең бу?..

— Гомумән, мин сезнең белән бүтән эшләмәячәкмен...

— Дисә, ни диюең бу?..

Күз камаштырырлык сылу баш врачның соңгы сүзләрен колагына да элмәде, яңарак кына Гази кереп киткән ишек артында юк булды.

Баш врач, өлкән яшьтәге апага таба борылып: туктатыгыз шуны, кире борыгыз! дигән сыман, куллары белән кискен хәрәкәтләр ясады. Алай гына эшне җайга сала алуына өметен өзде булса кирәк, җил-җил атлап, әлеге ишеккә таба юнәлде.

Бары тик күз алдында кабынган мәгънәсез, ямьсез җәнҗалдан соң гына, мин бу кешеләр арасында гаять катлаулы, яман да четерекле мөнәсәбәтләр барлыгына төшенгәндәй булдым.

### 3

Гази больница баскычыннан исерек кеше кебек чайкала-чайкала төште. Җиргә аяк басу белән, кинәт авып китә язды. Таш җәелгән киң сукмак буйлап бераз сөрлегеп барды да карт тирәккә килеп сөялде.

Зиһенендә бөтерелгән өермәле уйлар, күңелен айкаган ачы хисләр тәмам кешелектән чыгарды аны. Саф һавада да сулышы буыла, йөрәге кага, чигәсе суга, тәне кызыша, күкрәген, ниндидер биниһая авыр нәрсә басып тора, иркенләп сулыш алырга да бирми.

Әле яңарак кына операция тәмамланды. Аны Газиның беренче ярдәмчесе Дисә Зиннәтовна ясады. Яхшы ясады. Аның төгәл, житез хәрәкәтләрен күреп, хирург канәгать калды, эченнән генә, хәтта, мактап та куйды.

Шулчак ишектә, Газины өенә кадәр озатып куярга тиешле шофер Өлфәт күренде. Биек баскычтан очып кына төште ул.

— Әйдәгез, Гази абый,— диде ул, докторны култыклап. Берничә метрда гына торган машинага кадәр күтәреп диярлек алып барды Газины.

Менә Гази өендә ята. Кара тиргә батып, саташып-бастырылып ята ул. Капкан таблеткалары да, үз-үзенә ясаган уколлары да, әллә ни ярдәм итмәде. Эчендә тоташ ут кайный. Менә ничәнче тапкырлар инде, миңгерәүләнү дәрәҗәсенә җиткән башында: бу әрнү-сызлануларның бер чиге булырмы икән? дигән уй бөтерелә. Шулкадәрле утны-ялкынны бер генә йөрәк күтәрә аламы соң? Әле дә инде аның бер мәртәбә инфаркт кичергән җәрәхәтле йөрәге үз әгъзасы булудан бигрәк, көйрәп-ялкынланып торган ут йомгагын хәтерләтә иде. Юк, әллә ни озак газапланасы калмагандыр инде, тиздән, бик тиздән, йокыга талган сыман онытылыр да, каядыр төпсез упкынга очкандай, билгесез караңгылыкка китеп барыр... Тик менә шулай, япа-ялгыз үләрмен микәнни, дигән уй гына бәгырьләрен өтәли иде аның.

Уйларыннан шулай арып-алҗып, йокы белән өн арасында ята Гази. Тирә-юнендә дөм караңгылык белән шомлы тынлык. Саф һава керсен дип ачып куелган тәрәзәдән шулчак мәет салкынлыгы иңгән шәрә кул сузылып, аның кызышкан йөзенә кагылды һәм сыйпагандай итте. Бу хәл, йөрәген өтеп, бөтен рухын куырып алды Газиның. Бер мәл исен җыя алмый ятты. Урыныннан купкан йөрәгенең ярсып тибүе күкрәк авызын дөмбәсли башлады. Гази үзен пәрдә сыман чайкалып торган куе томан эчендә йөзгәндәй хис итте.

— Кем бар анда?

Әмма Гази үз тавышын үзе ишетмәде.

— Бу мин идем, Гази...

— Кем син?

— Гөлүсә...

— Нинди Гөлүсә? Кайсы?..

Бу юлы әлеге тавыш үпкә белдергән сыман итеп, илереп әйтә салды:

— И-и, Гази, оныттың дамыни инде? Бу мин, Гөлүсә... Синең бергә уйнап үскән балачак дустың, яшьлек юлдашың, беренче мәхәббәтең ниһаять! Алай гынамы соң, ярәшкән кәләшең дә идем... Тик хатының булырга гына язмады. Шунысы һай-й үкенечкә калды ла!..

Әлеге тавыш, соңгы сүзләренең ничегрәк тәэсир иткәнлеген ачыкларга теләгәндәй, бермәлгә тынып торды, аннары өстәде:

— Тиздән, бик тиздән очрашачакбыз, Гази. Чак кына сабыр ит. Кавышу минутларын көтәргә озак калмады инде...

Бары тик шунда гына Гази үзенең саташып ятуына төшенде. Ул да булмады, исенә килә алмас дәрәҗәдә гаҗизләнеп яткан сырхауның күз алдында, тавыш иясе үзе пәйда булды. Кәфенгә төренгән сыман ап-ак озын күлмәктән иде Гөлүсә. Үзе елмая. Соңгы тапкыр, моннан нәкъ чирек гасыр элек күргәндәгечә, акылдан шаштырырлык дәрәҗәдә сылу. Хәзер инде саташулы төшләрендә генә ишеткәләгән тавышы да нәкъ элеккеге — мөлаем-нәфис. Йөз чалымнары да күз алдында.

Әрнү-сызлануларга түзә алмыйча, үлем белән якалашып урын өстендә яткан Гази, саташу халәтеннән ычкынып, ниһаять эзлекле фикер йөртә алыр хәлгә килде. «Уф-ф!» — дип, кул аркасы белән маңгаендагы эре тир бөрчекләрен сөртте. Беренче булып башына килгән фикер Гөлүсәнең тиздән, бик тиздән очрашырбыз, дигән сүзләре булды. Һәм шундук, әй-йе, болайга китсә, чыннан да тиздән очрашырбыз, көтәргә озак калмагандыр, дигән уй чагылып китте. Күптән гүр иясе булган кешенең очрашырга чакыруын һәйбәткә юрамаганнарын яхшы белә иде Гази.

Гомерлек үкенеч һәм үлгәнчегә кадәр төзәлмәс йөрәк ярасына әверелгән Гөлүсәнең менә шулай уй-хыялларында күзаллануына да бик риза иде Гази. Ни хикмәттер, теләсә-теләмәсә дә, Гөлүсәнең нәни чагы гәүдәләнә иде Газиның уенда. Бу — очрашуның гадәти булмаганына күрә шулайдыр, мөгаен. Әле дә хәтерендә, колак артларын, бит-иякләрен, нәкъ чебен йөргән сыман итеп, кемнеңдер нәрсә беләндер кытыклавыннан уянып киткән иде Гази. Күзен ачса, ни күрсен: ул йоклаган сәке өстендә, нәкъ аның баш очында, арык тезләрен янәшә куеп, ямаулы күлмәк итәге белән каплаган, нәни бер кызчык утыра. Тыела алмыйча, бик канәгатьләнеп, бик рәхәтләнеп көлеп тә җибәрде үзе — көмеш кыңгырау чыңладымыни! Кулында әле яңарак кына Газины кытыклаган арыш саламы. Ә күзләре, күзләре тач күкбаш чәчәге — күксел-зәңгәр.

— Син кем? — дип сорады Гази.

Тыела алмыйча чың чәчеп көлгән кызчык, үзенең исемен атады:

— Гөлүсә.

— Каян килдең?

Тезләре өстенә иягеп куеп утырган кызчыкның, кем белән булса да сөйләшергә теләгәнлеге йөзенә чыккан. Менә ул, һаман да әле елмайган көе кулларын чәбәкләп алды да тәтелдәргә кереште.

— Ә мин сине беләм. Әйе, беләм! Синең исемең Гази. Шулай ич? Мин сине электән үк белә идем инде. Без әнә теге өйдә яшәгәндә

үк белә идем...— Кызчык, кайчандыр күршеләр яшәгән, хәзер инде җиргә сеңәрдәй булып кыйшаеп, караңгы төшү белән, бала-чага күңеленә шом салып утырган ташландык йорт ягына ым какты.

Шунда барысын да төшенде Гази. Аңынчы ике-өч көн генә элек булып узган бер вакыйга да күз алдына килде.

Ямау эше белән утырган әнисе, тәрәзәгә күз салу белән, хәйран калырлык нәрсә күргәндәй: «Һай-й, энекәйгенәм!..— дип, чәчрәп урыныннан купкан да тәрәзәгә барып капланган иде.— Шул ич, чәчрәпләр китим шул. Эзсез-хәбәрсез юк булган Иргали ич... Күр инде, исән икән ләбаса, күптән җирләнгән чутында йөртәләр иде ич үзен...»— дип, чөйдәге шәлен йолкып алган иде дә чыгып йөгергән иде.

Үлгән саналып та, терелеп кайткан кешене күрү нияте белән, Гази да ян тәрәзә янына килде. Энесе Таҗи да аңа иярде. Киндер төпле кабык бишектә утырган нәни Һади да, кулларын сузгалап, нәрсәдер тәкелдәп, алар ягына тартылды.

Күрде Гази, әнисе ишелеп төшәргә торган шыксыз өй катында басып торган солдат янына йөгереп килде. Кочакларга җыенгандай итеп, хәтта җилкә-иңнәренә кагылып алды. Шунда ук каядыр алып китәргә теләгән сыман, солдатның шинель җиңнәренә ябышты.

Бераздан солдат үзе дә керде. Әнисе исә, көтеп алган иң кадерле кунагын каршылагандай, күгәрченнәр булып кына гөрләмәде инде.

— Әйдүк, әйдүк, Иргали күрше. Батыплар үләрмен димәсәң, әйдүк, түргә уз. Менә бит, ә! Шул тиклем гомерләр узгач янә очрашырбыз дип кемнәр уйлаган. Ризык булгач, бер кайтасың икән аны. Без бит, Иргали, ут күршеләр генә түгел, якын дуслар да идек. Ә хатының Гөлниса белән — ахирәтләр. Хаҗи абыең да үлепләр ярата иде үзеңне. Әйдүк, әйдүк, Иргали... Менә, мондарак уз...

— Хафаланма, Зәйтүнә апа, борчылма. Мин дә менә, туган нигезгә баш иярмен дә иң әүвәл Хаҗи абыйның гаиләсенә керермен, дип күңелемә беркетеп куйган идем. Яз башында булып узган фаҗигале хәлләр турында Чаллыда, пароходтан төшкәчтен үк ишеттем...

— Шулай язган булгандыр инде, Иргали күрше. Язганны күрмичә гүргә дә кереп булмай ди бит. Кая әле, күрше, чишенепләр утыр әле...— Зәйтүнә иң элек үзе җилкәсендәге шәлен салып чөйгә элде, аннары Иргалине чишенергә өндәп тинтерәтә башлады. Хуҗабикәнең риясыз җылы, ихлас күңелдән кыставын абайлап алган солдат буйсынды, иң әүвәл биштәрен идәнгә шудырып төшерде. Бары тик шуннан соң гына баядан бирле малайларның күзләрен яндырып торган зур аеллы киң каешын чөйгә элде. Шинелен дә салып, гимнастеркадан гына калды. Өс-башы бөтен иде. Аягындагы күн итекләренә генә күз сал син, гомер туздыра алмассың. Җитмәсә тагын дагалылар, атлаган саен, шакы-шокы килеп торалар, идәннәр генә сыгылып кала.

— Әйдүк, Иргали, түргә уз...

Өйнең бөтен түрен иңләп-буйлап алган сәке. Аның өстендә кайчандыр ак булып та, хәзер инде төсен югалткан тула киез. Кече бүлмәне аерып торган такта аралыкка терәп куелган иске сандык өстендә ястыкмендәр, корама юрган, киезләр өелгән. Шунда, сәке өстендә, берсеннән-берсе кечерәк өч бала. Солдатның шул якка карап торуын абайлап алган хуҗабикә, кискен борылыш ясап, сүзне балаларга күчерде.

— Менә тормышымның терәкләре,— диде ана кеше, җәһәт кенә сәке янына килеп.— Куанычларым да, юанычларым да шулар.— Сузылып кына бишектә утырганының аркасыннан сөеп алды.— Ә бу ташбашы — тумас борын ятим, дөнья күргәнче үк сыңар канат булып калганы. Әтисе харап булган көнне туды...

Зәйтүнә, тагын бик әһәмиятле сүз әйтергә җыенгандай, бермәлгә тынып калды, әмма әйтәсе сүзен барыбер әйтте.

— Синең дә, Иргали, әнә генәк, минем уртанчысы чамасында булыр, кызың бар...— Шунда тавышы калтыранып куйды, «иде» дип әйтергә теле бармады ахрысы.

Иргалинең дә йөзенә күләгә кунды. Көрсенгән сыман итеп әйтте.

— Шулай дип ишеткән идем. Тик менә, исәннәр микән соң?..

— Рухыңны сындырма, Иргали, шәт иншалла исән-иминнәрдер әле. Күңелем шулай тоя... Синең бит үзеңне дә гүр иясе итеп сөйлиләр иде.— Янә сүзе өзелеп калды. Әмма күпкә түгел.— Ә менә әниеңә җеназа укылуына үзем шаһит. Узган каһәрле ачлык елның урталарында ярты авыл диярлек кырылды, шунда ул да китте...

Хуҗабикә, күңелсезлекләр турында сүзне дәвам итәргә теләмәгән сыман, каячы, ашарга салып җибәрим әле диң, җәһәт кенә кече якка кереп китте. Анда шаулатып самавырга су салганы, учак астына ут төрткәне ишетелеп торды. Үзе һаман сөйләнүен белде.

Иргали дә кул кушырып утырмады. Капчыгын алып килеп, аннан ярты икмәк, ак янчыкка вакланып тутырылган шикәр чыгарып өстәлгә куйды. Балаларга бирәр телем ипи белән бирәр шакмак шикәр тоттырды. Бер үк вакыт әңгәмәне дәвам итәргә теләгәндәй, болай диде:

— Ничек соң, Зәйтүнә апа, тормыш алып барулары бик кыен түгелме, чыдар-түзәр чама бармы?

— И-и, күрше, син сорама, мин әйтмим, дигәндәй, такы-токы белән тартып-сузып, көн күреп яткан булабыз шунда. Ничек кирәк алай очынчка ялгагандай итәбез инде. И-и, Иргали, йорт башы да, йорт терәге дә ир-ат икән. Ансыз йорт-җирнең дә рәте китте, ачык та тишек, тәрәзә дә ишек, дигәндәй, тормышкай нәкъ иске-сәләмә киемгә әверелә икән: аннан ертыла, моннан сүтелә! Ир-атсыз өйдә кояшлы көндә дә эңгер булыр димәсләр иде аны.

— Ярдәм итәләрдер бит? Ни әйтсәң дә, Хаҗи абый авылның беренче большевигы иде. Совет власте дип башын салган кеше.

— Ярдәм дип, юк инде ул. Мондыен кысынкы заманда кемгә генә ярдәм итеп бетерә алсыннар? Бөтен мир белән шундый хәл бит, Иргали. Аһ-зардан әнә бөтен ил иңрәп-сыкрап тора. Аның бит акчасының да рәте-чираты китте, нәкъ чүпкә әверелде. Ике-өч кадак тоз алыйм дисәң дә, кибеткә берничә миллион тәңкә тотып барырга туры килә. Икмәкнең кадагы ике миллион тәңкәгә җитте бит, адәм мәсхәрәсе. Тирә-юньнең байбәтчәләренә, мулла-мунтагайларына авыз чайкарга бик ярап куйды ул хәл. Әнә, Минһаҗ бай, бугазын киереп, нәрсә дип тора ди: Совет тәки вәгъдәсендә торды, иң актык хәерчене дә, нәкъ Әмрикә капиталисты сыман, «миллионер» итте, дип әйтеп әйтә, ди. Алар бит ил өстенә килгән афәтне, ачлык өянәге котырган чакны да халыкка үзләренчә аңлатырга маташтылар. Имештер, бәлшәвикләргә, алласызларга ияру менә кая илтә! Хәзер дә җыен тузга язмаган коткы тараталар. Әнә чын акча, Совет акчасы чыгарылган ди. Тик хәзергә әле күргәнебез генә юк.

Ниһаять, барын-югын әтмәлләп табын әзерләнде. Өстәлгә табагы белән, һәйбәтләп тозга ярып пешерелгән ярка-ярка ярмалы бәрәңге, бу бөркеп, моңлы көй сузып торган самавыр да килеп кунаклады. Озак утырдылар. Сүз иярә сүз китеп, кемнәрне генә телгә алмадылар, бик күп исәннәрен дә, дөнья куйганнарын да хәтергә төшерделәр. Әмма сүз нинди генә тыкрык-борылышларга кереп китмәсен, ахыр чиктә бүгенге көнгә, узган елгы корылыкка, шуның нәтиҗәсендә туган ачлыкка кайтып кала иде. Шунысына гаҗәпләнде Иргали: авырлыкларга түзәргә, тормыш сынаулары алдында бирешмәскә өйрәнгән хуҗабикә һич кенә дә зарланмады, әлеге фаҗигаларны ул ил өстенә килгән бәла дип саный иде.

Зәйтүнәне тыңлаган саен, җанына ниндидер җиңеллек иңгәнен хис итте Иргали. Аның батыр-уңган хатын икәнлеген ул элек тә белә иде. Башта биана-биата белән шактый авыр гомер кичергәне беркемгә дә сер түгел иде. Хәзер менә итәк тутырып, берсеннән-берсе яшь өч бала белән тол калган. Шуңа да карамастан, зарлану-шыңшуны белми, язмышына күптән инде күнеккән сыман итеп, әңгәмәдәшен үзе тынычландырырга, сабыр булырга өндәп утыра иде.

— Нишләмәк кирәк, Иргали күрше, үлгәннәр артыннан үлеп булмый. Син дә хәсрәт-кайгыга бик бирешмә. Дүрт саның төгәл дигәндәй, сиңамы соң кайгырырга! Авылда да күтәреп каршы алырлар үзеңне. Син бит

хәбәр-хәтерсез зимагурлыкта йөргән кеше түгел, Хаҗи абыең сүзләре белән әйтсәк: революция солдаты, кызылармеец! Бер дә борчылма, күрше, бар да рәтләнер, авыр чаклар узды инде, аллага шөкер. Әнә илдә иминлек — үлмәбез шәт. Әти мәрхүм: сабыр төбе — сары алтын дия торган иде. Җыен тузга язмаган уйларыңны җилгә тузгыт, кем, Иргали. Кара уйлар җанны да каралта ди. Шул инде, илгә килгән афәт иң элек ир-атка тия дип, тикмәгә генә әйтмәгәннәрдер. Шул ук әти мәрхүм: «Адәм баласын дөнья шулай бөгеп тә, сындырып та сыный»,— дияргә ярата иде. Бары рухыңны сындырма, кем белә, бәлки әле синекеләр дә исән-иминнәрдер дип әйтүем...

Шушы гади генә сүзләр дә билгесезлектән әрнеп-сызган күңелгә җан өргән сыман тәэсир итте. И-и, изге җан! дип уйлады Иргали Зәйтүнә турында. Кайгы-хәсрәт, тормыш зилзиләләре үзеңнең дә баштан ашкан ич.

Хуҗабикә җиңнәрен, озынайтырга теләгәндәй, аска таба тарткалап куйды да, күршесенең чак кына тынычлануын тоемлагач, болай дип өстәп куясы итте:

— Хәлләреңне бик аңлыйм, Иргали. Аңламаган кая ул! Яңа-ялгыз калулары әҗәлдән дә битәррәк. Әмма өметеңне өзмә. Өмет үтерү — адәм үтерүгә тиң ди. Әйтәм бит, күңелемнең кай җире беләндер тоеп торам, исәннәр синең газизләрең, исәннәр!..

Иргалинең өметсезлек томаны каплаган күңеле чак кына яктырып киткәндәй булды. Шулай да ул хатыны белән баласының ниндирәк шартларда авылдан китүләре белән кызыксынып куюны кирәк тапты.

Баштарак хуҗабикәдән рәтле-башлы сүз чыгар төсле түгел иде. Авыз ачып бер кәлимә сүз катканда ук, тавышы ничектер калтыранып куюы Иргалине янә пошаманга төшергән иде. Ахыр чиктә хуҗабикә, эчендә ут кайнаса да, түземлеген җыйды, күңеленә юшкын булып утырган хафалардан берьюлы арынырга теләгән сыман, барысын да ачыктан-ачык сөйләде дә бирде.

— Узган каһәрле елның көзе иде шикелле. Әй-йе, көзе иде. Гелән күздә-кашта булып та көннәрнең берендә кинәт юк булды хатының Гөлниса. Бу хәл күңелгә шом салды. Тукта, мин әйтәм, хәерле хәл түгел бу. Ишеккә бардым, күрәм, эчтән бикле...

Шуннан соң Зәйтүнәниләр булганлыгын күз алдына китереп бастырырлык итеп түбәндәгеләрне бәян итте. Ишекне дөбердәтеп тә, җавап ала алмагач, ян тәрәзәгә килә. Аннан берни дә күрәлмагач, түр тәрәзәгә күчә. Шуңа күрә: сәке өстендә, яртылаш юрган ябынып, Гөлниса ята. Чалкан яткан күршесенең бары тик, мәетнекенә охшап, борыны гына очланып күренә. Янында бәләкәче — Гөлүсә. Тәрәзәне шакып карый. Тегеләр селкенми дә. Шунда Зәйтүнә, ду-чат килеп, күрше-күләнне аякка бастыра. Өйалдының салам түбәсен тишеп, ыргак белән иң әүвәл бастырыкны күтәреп, ишекне ачалар. Керсәләр, тегеләр инде ярты мәет. Әмма суынырга өлгермәгәннәр. Шунда күрше-күлән бичараларны саклап калу чарасына керешә. Кемдер хәзрәтләрдән бер җамаяк сөт алып чыга, кайсыдыр күәс төбен чайкап алып керә. Тешләрен каерып ачып, көчләп эчерткәндәй итәләр. Авызына сөт коелган нарасый, тончыга язып, үзенең ризасызлыгын белдереп, беренче ыңгырашып аваз сала.

Зәйтүнә шул ук көнне Гөлнисаның туган апасына хәбәр юллый. Хәбәр изге җанлы кешегә туры килә булса кирәк, икенче көнне үк Миңниса ат җигеп килеп тә җитә. Как сөяккә калган Гөлниса белән баланы күтәреп алып чыгалар да, ястык түшәлгән арбага салып, алып китеп баралар.

Әрнеп, өзгәләнеп сөйләвен Зәйтүнә:

— И-и, бигрәкләр дә, бигрәкләр дә җәл булды инде,— дип түгәрәкләде.

Бу сүзләрдән соң Иргали күңелендә: «Шәт, исәннәрдер...» дигән өмет чаткысы яңа көч белән кабынды. Шундук катгый карарга килеп, бүген үк гаиләсен эзли чыгарга әзерлеген әйтте. Әмма, алда кыш

көтүен, ә өендә торырлык җай калмавын да өстәмичә булдыра алмады. Чыннан да, өенең өй диярлеге юк, хәзер үк инде эчендә җилләр уйнап тора, тәрәзәләре ватык, иданнәре алынган, баскычы җимерек, эчке ишеге хәтта сыңар күгәндә генә асылынып тора иде.

Киң күңелле, ярдәмчел Зәйтүнә монда да җавапсыз калмады.

— Әгәренки тарсынмасагыз, баш-күз алгалаганчы, бездә торып торырсыз. Һәр җәһәттән тигезлек булмаса да, бары бергә, югы уртак дигәндәй, булган кадәресенә шөкерләр итебрәк яшәрбез. Минем әткәй: күрше хакы — тәңре хакы, күршелек кардәшлектән дә өстен дияргә ярата иде. Алай өметсезләнергә әллә ни урын юк. Сиңа да ярдәм итми калмаслар.

Изге җан Зәйтүнә киңәш бирү белән генә дә чикләнмәде, бу олуг эшне нәрсәдән башларга кирәклекне дә өйрәтте: «Туп-туры Ярлылар комитетына бар, ат-олау белән ярдәм итми калмаслар»,— диде. Шундук күршесен исенә китерергә теләгәндәй, Ярлылар комитетының рәисе Бәһрам абзый булуын да, аның кайсыдыр яктан Иргалиләргә кардәш тиешлеген дә әйтүне кирәк тапты.

— Менә ич, күрше, синең әле арка таянычы булырлык кешең дә бар...

ВЦИК чыгарган махсус декрет нигезендә, авылларда Ярлылар комитетлары төзелүе турында Иргали белә иде инде. Шул комитетның рәисе булып әнисе ягыннан чыбык очы тиешле Бәһрам җизнәсе сайлануы турында ишеткәч, Иргалинең күңел түрендә пыскый башлаган өмет чаткысы тагын да яктыра төште.

Иргали шулай итте дә. Иң әүвәл Бәһрам җизнәсен күрергә булды. Юк, өенә бармады ул аның. Кыегына уңып беткән әләм эленгән, кайчандыр каравыл өе булган Совет йортына таба юнәлде.

Хатын-кыз ягыннан туган тиешле булгангадыр инде, Иргали Бәһрам абыен элек-электән якын итеп, үз итеп, «җизни» дип йөртә иде. Заманында Бәһрам җизнәсе чыннан да бик якын кеше иде. Башкача булуы мөмкинмени? Иргалинең әтисе Нургали белән алар яшьтиләр генә түгел, хәтта 1904 елгы рус-япон сугышына да бергә алынганнар иде. Шуннан Бәһрам җизнәсе уң аягын өздереп кайтты, ә Иргалинең әтисе бөтенләй юкка чыкты.

Бер Иргали генә түгел, Бәһрамны бөтен авыл халкы ихтирам итә, башлы, булдыклы, зирәк акыл иясенә саный иде. Чыннан да, курку белмәс йөрәкле кеше иде ул. Гаделсезлек булса, урынсызга кимсетелгәннәр барысы да, хаклык эзләп, Бәһрам җизнәсе янына йөгерерләр иде. Хикмәте шунда, кемнең кем булуы белән санашып тормас иде, кара канга батканчы якалашыр, әмма үзенекен итәр, хаклыкны яклар иде.

Иргали, шундый уйларга бирелеп, Совет өенә юнәлде. Бик күп вакыйгалар шаһиты — янгын каланчасы күләгәсенә елышып утырган каравыл өе дә нык үзгәргән, аскы бүрәнәләре сипләнеп, түбәсе тигезлетигезсез такта белән яңартылган. Урам ягына чыгарып, бик үк яңадан булмаса да, уклау кебек шома, төз бүрәнәләрдән янкорма салынган. Аның тәрәзәләре дә үзгә: рамнары да зуррак, пыяла өлгеләре дә эрерәк.

Иргали болдырга күтәрелде, әмма өй эченнән ишетелгән хатын-кызлар тавышына туктап, икеләнеп калды: керергәме, кермәскәме?

Әмма шул чак ул берничә тамыр, алтымы-җидеме буын аша чыбык очы булган Бәһрам җизнәсенең тавышын абайлаган сыман булды. Тәкатьсезләнеп, ишекне каерып эчкә үтү өчен шул җитә калды.

Аны күргәч, бүлмә эче тына төшкәндәй булды, хәтта түрдәге өстәл артында утырган Бәһрам җизнәсен чорнап алган хатын-кызларның бака түе да кинәт кырт өзелде. Ләкин озакка түгел. Иргалине танып алулары булды, янә барысы берьюлы телгә килде, берсен-берсе уздырып янә базар ясап алдылар. Күрешү, сәламләшү китте:

— Җаныкайларым ла! Күрегезче зинһар...

— Әнекәйгенәм лә! Кем бу... Иргали түгелме соң?!. Шул ич!..

Ул арада Бәһрам җизнәсе дә урыныннан кубып, агач аягы белән идән такталарын санап, Иргали янына килде һәм: «Саумы, туганым!.. Исән-иминме?..» — дип солдатны кочагына алды.

Хатын-кызлар гөрләпме гөрлиләр:

— Я-а, ходай! Менә бит ә!.. Язган мал язын кайтыр диләрме әле?..

— Әйтмә дә! Әнисе генә күрә алмый калды...— Кайсыдыр тирән көрсенде, өзгәләнде, хәтта сыктап җылап җибәрде. Аңа икенче берәве шыңшу белән җавап кайтарды.

Иргали белән күрешкәннән соң, өзелеп калган әңгәмә шактый вакыт үз ызанына төшә алмыйча газапланды. Урынына барып утырган Бәһрам да очрашу тәэсиреннән чыгу әмәлен тапмагандай, һаман да әле авызын җыя алмый иде. Сүзләре дә кичерешләренә тәңгәл: күрдегезме, хатыннар, әнә нинди өрлектәй ир-егетләр кайта авылыбызга, болай булгач яшибез әле, яшибез...

Сүз уңаенда күп нәрсәләрне төшенде Иргали. Монда гомер буе өсләренә юньле кием, тамакларына юньле ризык эләкмәгән, атсыз-тунсыз ярлы-ябагай гына түгел, ирсез калган, тормышны алып барырлык, җан сакларлык чамалары беткән фәкыйрь хатын-кызлар җыелган икән. Үзләрен борчыган, кызыксындырган мең төрле сөальгә җавап табарга дип килгәннәр алар.

Әнә, хатыннарның берсе нииндидер «налог» турында сүз кузгатты. Бәһрам җизнәсе шул бер сыңар сүздән барысын да аңлады. Хатыннар «Продналог» белән «Продразверстка», ни өчен икенчесенең беренчесе белән алыштырылуы, аларның аермасы нидәр гыйбарәт булуы белән кызыксыналар икән.

— Аермасы аның шунда,— дип башлады Бәһрам, колак артын кашыштырып.— Продналог продразверсткага караганда күп ким. Продналог крестьянга үзеннән арткан икмәген сату мөмкинлеге тудыра...

Бичарадан ничара хәленә төшкән хатын-кызларга янә бака туе ясап җибәрү өчен шул житте: Я-а, хода! Син дә, Бәһрам агай, әйттең сүз! Илле алла, кырык мулла ярдәме белән анда бер түтәрәм, монда бер дисәтинә чәчкән без ярлы-ятимәләрдән икмәк арта димени инде! Я-а, ал-лам!..

Бер ач яңаклы, кечерәк кенә гәүдәле хатын барысының да уртак фикерен әйтте, ахры:

— И-и, Бәһрам абзый! Быел язын ике таяк җир тары чәчеп калган идем. Бүгенге көндә өйдә өреп очырырлык ризык заты юк... Ничекләр итеп җан асрамак кирәк...

Иргали, язын һәр хуҗалыкның, биләгән җиренә карап, чәчүлек орлыгы белән тәэмин ителүе, әмма узган яман ачлыктан тәмам өне алынган халыкның чәчү турында түгел, әлеге хатын әйтмешли, җан саклап калу ягын каравы, шуның нәтиҗәсендә күп кенә басуларның кысыр калуы турында ишетеп белә иде инде. Ә ел ифрат та матур килә, игеп котырыпкаерылып уңа, чәчеп калган кешеләр ишеп, моңарчы күрелмәгән уңыш җыеп алалар...

Иргали Бәһрам җизнәсенә игътибар итте. Ул да бетешкән, төс куйган. Заманында сыңар кулы белән дага сындыра дип сөйлиләр иде аның турында. Хәер, хәзер дә әле сокланырлык зур гәүдә үзендә, нык бәдәнле кеше. Тамырлары бүртеп торган көрәктәй куллары әнә өстәл өстендә ята. Куе кашлары, эре яңак калканнары күпереп торган кара тутлы йөзендә егәр генә түгел, ихтыяр көче дә җитәрлек икәнлеген сиземләү авыр түгел иде.

Тагын шул кадәресенә төшенде Иргали: кабыргасы белән куелган сорауларга җавап бирү Бәһрам җизнәсенә дә җиңел түгел. Бар, җавап биреп кара барлык сорауларга да! Вакыт дигән нәрсә берсеннән-берсе четерекле сорауларны бер-бер артлы куеп кына тора.

Әнә, кайсыдыр яңа экономик политика турында сүз кузгатты, аның нәрсә икәнен аңлатып, төшендереп бирүне үтенде.

— Аның хикмәтеме?..— диде Бәһрам, үз-үзенә сорау биргән сыман итеп.— Хикмәте шунда ул яңа экономик политиканың: яллы хезмәт, хосусый милек, һәм дә хосусый сәүдә рөхсәт ителә.

Бу сүзләр ут өстендә ялкын гына булды. Янә берсе икенчесен уздырып тәтелдәргә, бака туе ясарга кереште хатыннар. Бигрәк тә әлеге дә баягы, бик фәкыйрь киенгән чандыр гәүдәле хатынның тавышы аерылып торды:

— Соң безнең газиз ирләребез шул хосусый милекне бетерик, юк итик дип каннарын коеп, башларын салдылар түгелмени?!. Нәрсә бу? Революцияне әлеге шул Минһаҗ байлар яңадан җилкәбезгә атланып канын эчсеннәр өчен ясадыкмыни соң?!. Әнә, яңадан такта яру, май заводлары калкып чыкты, яңа тегермән салып җибәрде. Һаман да шул Минһаҗ байга бил бөгү, аның колы булып яшәү. Күз кerүгә, көнлектән уракка йөрдек, соңрак житенен йолыктык, күлгә баса-киндерен батырдык. Күкрәккә житкән боздай суга кереп, киндер көлтәләрен чыгардык, киптердек, аннан килеп бер караңгыдан икенче караңгыга тиклем талкыйбыз. Кыш кердеме, янә Минһаҗ байга барып тез чүгү — айлар буе ындыр сугу... Үзе әнә күләгәсен дә күрсәтми. Байлыгын кая куярга белмичә, калада хур кызлары белән кәеф-сафа корып ята ди. Элек-электән халыкның җелеген суырды, хәзер дә каныбызны эчә...— Чандыр хатынның бу сүзләрендә рәнжү-иңрәү авазлары да бар иде.

Бәһрам урыныннан күтәрелеп:

— Чак кына сабыр, хатыннар,— диярга мәҗбүр булды.— Дөрес аңлагыз. Бу — бичарадан ничара дип кенә ясалган адым. Илебезнең хәлен үзегез беләсез. Башта империалистик сугыш, аннан килеп, Октябрь революциясе... Янә дә килеп, әле һаман дәвам иткән гражданнар сугышы. Халык хуҗалыгы тәмам чыгырыннан чыккан, ачлык-ялангачлык хөкем сөрә, шуның өстенә тиф ише авырулар, чалгы белән чапкан кебек, кешеләрне кыра. Аннан килеп, ваба үләте мал-туарның тетмәсен тетте. Бүгенге көндә байлык кемдә? Акча кемдә? Шул ук Минһаҗ байлар кулында. Менә шуларның акчасы, байлыгы белән илне торгынлыктан чыгарып булмасмы икән дип күрелгән чара бу. Ягъни, тын алу өчен генә, вакытлыча гына чигенүебез... Партия шулай аңлата.

Шул чак хатыннарның берсе, тирән көрсенеп:

— Кайчан да булса кешечә яшәргә язганмы соң безгә?..— дип ачынып, йөрәге иңрәве белән әйтеп ташлады.

— Яшәрбез, хатыннар, яшәрбез! Менә әйткән иде диярсез, тормышыбыз карап-сокланып туймаслык булачак. Чөнки илгә-җиргә үзебез хуҗа хәзер. Балаларыбызның өсте бөтен, тамаклары тук булыр. Без әле аларга җәннәткә тиң тормыш бүләк итәчәкбез.

Хатын-кызлар таралып, икәүдән-икәү генә калгач, Бәһрам җизнәсе белән Иргали кабат күрешкәндәй, хис уртаклашкандай иттеләр, хәл-әхвәл сораштылар...

Аннары Иргали бернинди хәзерлексез-нисез, сүзне үзенең гаиләсе турында башлап җибәрде. «Хәтта, җәмәгатемнең исәнме-түгелме икәнлеген дә белмисең бит»,— дип, чак кына үпкәсен дә белдергән сыман итте.

Бәһрам җизнәсе дә бу турыда иртәме-соңмы барыбер сүз кузгалачагын көткән кебек, Иргалине башта тын гына, бүлдермичә генә тыңлады, аннары бөтен хакыйкатьне ике-өч авыз сүз белән ачты да салды. Әнисен үтә зәхмәтле узган елны җирләгәннәр. Иргали солдат хезмәтенә киткәч туган кыз баланы һәм аның анасы Гөлнисаны ярым үле хәлләрендә туган якларына алып киткәннәр булса кирәк.

Шунда Бәһрам җизнәсе, сүзне икенчегә борырга теләгән сыман, искәрмәстән генә:

— Фиркалеме? — дип сорап куйды.

— Керергә вакыт тимәде...— диде Иргали бер дә исе китмәгән кыяфәт белән. Әмма шундук акланырга теләгән сыман, солдат юлларының нәкъ чәбәләнгән йомгак кебек булуы, иртәгәсен язмыш кая илтеп ташлаячагын да белмәгән чаклары турында гәп сата башлады. Әүвәл Австрия фронтында булган. Окопларда революцияне каршылаган. Бер-

нинди икеләнүсез Кызыл Армиягә язылган. Шуннан башланган да инде Иргалинең Россияне аркылыга да, буйга да гизүләре.

Кайларга гына илтеп ташламый аны язмыш, кайларда гына булырга туры килми. Аеруча хәтердә калганы, әлбәттә, Петроградта хезмәт итү. Казармалары Петропавловск крепостенда була. Баштарак Монет дворын, Смольныйны саклыйлар. Әмма әлеге тыныч тормыш озакка сузылмый, аларны янә фронтка, бу юлы инде Юденичка каршы алып чыгып китәләр.

Англия-Америка интервенциясе башлангач, инде ничәмә тапкырлар әҗәлнең күзенә караган солдат Иргали Миргалиев хезмәт иткән полкны төньякка озаталар. Архангельскины азат итү өчен барган каты сугышларның берсендә ул беренче тапкыр яралана. Ярасы әллә ни хәтәр булмаганлыктан, хәрәкәттәге армиядә кала. Дошманнан тартып алынган азык-төлек, кием-салымны һәм башка төрле кирәк-яракларны үзәк Россиягә озату эшләрендә катнаша.

Аннан янә көньякка кайта. Иргалигә Латвия, Литва җирләрендә дә булырга туры килә, Польша чикләренә барып чыга. Бер заман Азов диңгезе буена җибәрәләр. Керчь, Краснодар, Ростов-Дон шәһәрләре тирәсендәге сугышларда катнаша. Аннан соң Әзербайҗан, Грузия, Әрманстан җирләрен дошманнан арындыру бәрелешләрендә катнаша.

Бары тик 1922 елның җәендә генә Баку аша пароходта Рыбинск шәһәренә юл тота. Бер төркем кызылармеецлардан торган каравыл отряды белән азык-төлек баржасын озата бара Иргали. Рыбинск каласына якынлашып килгәндә, баржага зур гына бер банда һөҗүм ясый. Кискен сугышта Иргали каты яралана: бандит хәнҗәре аның сул як җилкәсен актарып ташлый.

Рыбинск шәһәре госпиталендә дәвалана Иргали. Инде савыгам, туган якларыма кайтам дип кенә торганда, тиф авыруы белән яңадан аяктан егыла... Иргалинең биштәрендә, Рыбинск каласында берничә ай дәвалануының якты бер ядкаре булып, көмеш кружка саклана. Анда: «Красному воину 158-го стрелкового полка И. Н. Миргалиеву от Рыбинского пролетариата», дигән сүзләр язылган.

— Менә, Бәһрам җизни, шундыерак хикмәтләр күрде газиз башкайлар,— дип Иргали сүзен түгәрәкләп куйды.

— Әй-йе!... Чыннан да күпне күргәнсең, күпне кичергәнсең. Хәер, киткәнеңә дә шактый вакыт үткән иде шул инде. Сугышка озатылганнан соң бер ярты ел чамасы уздымы икән, синең анда ниндидер медаль белән бүләкләнүең турында хәбәр килеп төшкән иде кебек...

— Бүләге дә булды, Бәһрам җизни, кыр суды белән үлем җәзасына хөкем ителү дә булды...

— Шулай да партия сафына керү ягын кайгыртасың калган,— диде Бәһрам җизнәсе, чак кына үзенең ризасызлыгын белдергән сыман итеп.— Синең эше акны карадан аера белә торган, дөнья күргән, ил гизгән кешеләр житенкерәми бездә. Кайтуың турында ишетү белән: әһә-ә, продкомиссар Хажины алыштырырлык кеше табылды, бер арбага ике тәртә булырбыз ичмаса, мин әйтәм...— Ләкин Бәһрам шундук төзәтенгән кебек итеп болай дип өстәде: — Ничава! Әллә ни зарар юк. Монда кабул итәрбез. Безгә синең кебек кан койган революция солдатлары, менә болай кирәк.— Бәһрам җизнәсе кул сырты белән муенына сызып күрсәтте.

Бәһрам ага Чаллы волость Советының мөһерләре белән ныгытылган документ барлыгы турында әйтте. Анда авылларда партиянең беренче ячейкаларын төзү турында махсус боерылган икән.

Бәһрамның тел төбеннән тагын шул кадәресен бик анык аңлады Иргали: җизнәсенең белеме шактый сай, бу яңа эштә тәҗрибәсе чамалы, киңәш-фәлән сорар кеше дә юк. Күп кенә мәсьәләләрдә каушапюгалып кала, яки бөтенләй бутала. Үч иткәндәй, һәрнәрсә ул көткәннән дә катлаулырак, хәл итәсе мәсьәләләр чамадан тыш авырлар. Байларга,

сәүдәгәрләргә контрибуция салганда, ялгышкан чаклары да булгалаган. Гаҗәп тә түгел. Мәсәлән, түләүләр салганда, кулакны урта хәлледән ничек аерырга? Салымнан коткарылырга тиеш булган ярлыларны, фәкыйрьләрне ничек билгеләргә? Бар, белер-белмәс борын тыгылып кара! Китереп кыса башлагач, аның хәлле дигәне дә, нәкъ кәлтә еланы кебек, җиде төрле кыяфәткә керә, унҗидегә бөтерелә... Шуның өстенә, әнә, яңа экономик политикага аркаланып, капиталистик элементлар канат җәя, «Искегә кайтабыз...» — дип төкерек чәчәләр, халык арасында Советка каршы коткы тараталар.

Сүз нярә сүз китеп, Бәһрам җизнәсе яңадан ил өстенә килгән мең төрле сынаулар, афәтләр турында сөйләп китте. Соңгы чиккә җитеп талчыккан халыкның аһ-зарыннан бөтен Рәчәй иңрәп-сыкрап тора дип башлады ул сүзен.

Ярдәм үк булмаса да, һич югы берәр төрле киңәш өмет итеп килгән Иргалинең ахыр чиктә түземлеге төкәнде, Бәһрам җизнәсенең сүзен урта бер җирендә диярлек бүлеп: кайтуын кайттым да, хәзер нишләрмен икән соң мин? — дип, үз хәсрәтен, үз ихтыяҗын кыстырып куйды.

Һәрчак кеше өчен җаны фида булып, кешегә ярты җанын бүлеп бирергә әзер торган олы җанлы, изге күңелле Бәһрам җизнәсен алыштырып куйганнармыни, туганының бу аһ оруына әллә ни игътибар да итмәде сыман, гади нәрсә турында әңгәмә алып барган кебек, болай диде:

— Нишлисең ди инде, Иргали туганкай, безнең эш билгеле: башлары иелгән, изелгән, кимсетелгәннәрне яклап, җиң сызганып, изге көрәшкә керешәсең. Язмыш безгә шундый даулы-шаулы, ялкынлы, дәһшәтле чор бүләк иткән икән, берни белән дә санашмыйча, үз-үзеңне аямыйча көрәшүдән башка чара калмый...

— Минем, Бәһрам җизни, күреп торасың, йорт-җирнең дә карар җире калмаган. Идән-сәкесе, түшәм-матчасы юк дигәндәй.

Тегесе янә күзен дә йоммады.

— Хәзергә миндә торып торырсың. Өем терәүле булса да, берәр кышка шәт чыдар.

Иргали тагын бер гозерен әйтте.

— Аннары, ат табышырга ярдәм итсәң иде икән, Бәһрам җизни. Җәмәгатемне барлап кайтмакчы идем.

— Юлга кайчанрак чыгарга ният?

— Хет бүген.

— Ат мәсьәләсен чамаларбыз. Бедкомның бер түгел, ике аты бар барын. Тик икесенең берсе кул астында юк. Җирән байтал яраланды... Мин бит әле волость җир комиссиясе әгъзасы да. Шуннан кайтканда, Коры елга әрәмәлегендә саклап торганнар. Пуля сыртын тишеп үткән... Икенче атны Чаллыга соратып алдылар. Өяз ревкомыннан килгән вәкилне йөртә. Яңадан талаш, яңадан ызгыш: кулакларда булган артык икмәкне табу һәм тартып алу өчен, янә кызыл гвардеецлардан продотрядлар төзелә.— Сүз белән мавыгып киткән Бәһрам, урыныннан кубып, агач аягы белән идәнне шакы-шокы китереп, тузан кубарып, ишекле-түрле йөренеп алды. Өстәле янына килеп туктагач янә башлады: — Менә шулай яшәп ятыш, Иргали туганкай! Революция ул, күргәнеңчә, иске җәмгыятьне җимереп, яңа дөнья тудырган көч кенә түгел, бик күпләр өчен кемнәрнең кем булуын сыный торган нәрсә дә. Тормыш безгә, күреп торасың, җиңел язмыш билгеләмәгән. Так что, без күргәннәр ике-өч буынга җитәрлек булды...

Иргали, күңелендә ниндидер ризасызлык тууын һәм шул хәлнең торган саен көчәйгәннән-көчәя баруын тойды. «Бу ни бу? — дип уйлады ул.— Бәһрам җизнәсе әллә аны алты ел буена уйнап йөргән дип уйлыймы? Нәрсәгә дип акыл сата ул? Шул ук азатлык, бәйсезлек дип, көн дә диярлек үлем белән якалашкан һәм, ниһаять, кан койган революция солдаты түгелмени соң Иргали? Ул да хаклык өчен җан аямый көрәште түгелме соң?!.»

Иргали үзенең торган саен ярсый, яңак итен чәйни башлавын сизенде. Шунда ул Бәһрам җизнәсенең сүзен урта бер җирендә бүлеп диярлек янә үзенең әнисе, гаиләсе турында сүз башлап, үзенең үпкәсен белдерде:

— Неужели чак кына ярдәм итеп саклап калырга чамагыз булмады шуларны?..— дип ярды да салды ул.

Шушындый ифрат та яман гаепләү сүзен дә җиңеллек белән кабул итте Бәһрам җизнәсе. Күтәрелеп бәрелү түгел, тавышын да үзгәртмәде хәтта. Бик гади нәрсә турында гәп алып барган сыман, болай диде:

— Юк, Иргали туганкай, булмады. Ачлык афәтенең, ачлык өрәгенең иң мәрхәмәтсез, сөякле куллары белән халык бугазын чытырдатып буган чагы иде. Икмәкне ашау түгел, аңа карау белән генә дә күздән яшь чәчрәп чыга торган чак иде.— Авыр итеп көрсенеп куйды да дәвам итте.— Бер синең әниең генә түгел, минем хатыным — Кәримә җиңгәң дә шул ачлык афәтеннән дөнья куйды... Хәтта, продкомиссар Хаҗиның әнкәсе дә ачтан үлде. Мин тиешен яшәдем инде дип, үз өлешен берсеннән-берсе бәләкәч оныкларына каптыра торган булган, бичара. Ә бит күршегез Хаҗи абыеңның кулында, еш кына олавы-олавы белән ашлык булыр иде. Соңгы очрашуыбызда бугай, әйткән сүзләре бүгендәй хәтердә: «Юлым авылыбыз аша узасы булса, Салаязга кермичә әйләнеп үтәм. Каршыма әниемнең ачка кибеккән, өрәккә охшап саргайган, хәлсезләнүдән җилдә тибрәлеп торган гәүдәсен күрсәм, тәки түзмәм, капчык авызын чишеп, тәки алъяпкычы алдына берәр кушуч бөртек салырга мәҗбүр булырмын, дип курыктым»,— дигән иде. Кулда күтәреп йөрерлек кеше иде, мәрхүм. Менә шундый большевик иде ул. Андыйларны замандашлар гына түгел, киләчәк буыннар да онытмас...

Шул вакыт ишекне җилле генә ачып, ыспай гына гәүдәле бер яшь хатын килеп керде. Иргалинең йөрәге дерт итеп куйды. Әлеге хатынның хәрәкәтләрендә, хәтта төс-бит чалымнарында, хатыны Гөлнисаның чалымнарын күргәндәй булды.

Ул арада хатын тартынып-ятсынып тормады, шатлыклы-куанычлы елмаеп, туп-туры Иргалигә таба юнәлде һәм:

— Исән-сау гына кайтып җиттеңме, Иргали абый? — дип, күрешү өчен кулын сузды.

Бу искәрмәгән хәлдән Иргалинең чак кына югалып-каушап калуын чамалаган Бәһрам җизнәсе аңа ярдәмгә килде.

— Син нәрсә, Иргали туганкай, әллә танымадыңмы? Безнең Хәят ич бу. Фәхри күршенең кызы. «Прапорщик Фәхри» дип тә йөртәләр иде әле үзен.

Хәят, авылның партия ячейкасы әгъзасы булу белән беррәттән, бердәнбер мөгаллимәсе дә, избачы да икән әле. Революциянең биш еллыгын билгеләп үтәргә хәзерлек барган бу көннәрдә аңа мәшәкать аеруча күп икән. Уен эшмени, гасырлар буе иренең олтаны астында, шәригать богауларыннан иңрәгән, якты көн күрмичә ирексез гомер сөргән татар хатыннарының хөрриятькә чыгуларына биш ел тула бит!

Һичнигә бирешмичә, сыгылмыйча, бернинди кыенлыклар алдында да югалып-каушап калмый торган хатын икән Хәят. Мәсәлән, узган елда мең газап белән күп көч сарыф итеп ачкан мәктәпне, укуның беренче көннәрендә үк ябарга туры килгән. Аның урынына балалар йорты оештырылган. Дөрес, авылдагы балаларның бер өлешен, бигрәк тә этисез-әнисез калганнарын, пароходлар белән Рәсәйнең туграк өлкәләренә озатырга туры килгән.

— Инде бөтенләй бетәбез икән дип кенә торганда, дөнья пролетариаты ярдәм кулын сузды.— Бәһрам абзый бу сүзләрне эчке бер горурлык белән әйтте.— Беренче булып хәлебезгә керүче Америка эшчеләре берләшмәсе иде. Шулай итеп кыш башларында ук Совет ашханәләре, туклану пунктлары ачылды — җан асрар чама туды.

Бәһрам җизнәсе сылу хатынның уңган сыйфатларын тезгән арада, Иргали дә Хәятнең балкыш иңгән сөйкемле йөзенә, килешле буй-сынына карап чынлап торып сокланды. Аның йөреше-торышы гына түгел, үзен иркен, бер үк вакытта ифрат та ягымлы тота белүе сокландырды Иргалине. Кием-салымнарына тикле үзенә төс биреп тора бит аның. Аягында озын кунычлы ап-ак тула оек белән тирән резин галош иде.

Ул арада Хәят ячейка утырышларының төнгә кадәр сузылуларыннан зарлана башлады.

— Ниндидер бәдбәхет кичә тагын каршыма чыкты,— диде ул.

Бәһрам бу хәбәрне бик тыныч кабул итте. Һәм шунда, Хәяттән гайре Иргалигә дә әйткән сыман:

— Тыныч яшәү безнең төшкә генә керергә язгандыр инде,— диде. Җан талаш, мәрхәмәтсез көрәш, дәвам итү генә түгел, отыры көчәя, отыры кискенләшә бара. Ләкин без теләсә нинди дошман белән сугышырга, теләсә нинди кыенлыкларны җиңәргә әзер булырга тиешбез. Үзең беләсең, көрәшсез бәхет юк, алга барусыз җиңү юк. Сыйнфый дошманнарның, мең төрле контрларның мәкерле ниятләре белән атлаган саен очрашып торабыз...

Әмма Хәят әлеге вакыйганы сөйләп бирүне кирәк дип тапты ахрысы. Ул кайтырга чыга. Ут-фәлән күренми. Бары тик кайдадыр арткы урамнарның берсендә генә яман улап эт өрә. Хәят тыкрыкка борыла. Шул вакыт, кычыткан баскан читән буеннан, бер күләгә калкып чыга... Хәят, ул тирәдән тизрәк шылыйм әле дип, адымнарын кызулата. Арттан ияргән ир-ат та калышмый. Хәят йөгерә үк башлый. Эзәрлекләүче дә дөп-дөп атлап якынлашканнан-якынлаша. Ниһаять, капка. Өйалды баскычы. Хәят җил кебек атылып өйалдына керә дә, үзе артыннан җәһәт кенә ишекне ябып, көч-хәл белән бастырыкны төшерергә өлгерә. Шул вакыт ниндидер бер авыр нәрсәнең гөрселдәп ишеккә килеп бәрелүе төнге тынлыкны боза. Кемнеңдер: «Коммун себеркесе... Өстерәлчек... Барыбер яшәтмибез...» — дип янаган тавышы ишетелә. Иртәгесен чыгып караса, ни күрсен, ишек тактасында бизмән тимере эзе!

Ишектә элек-электән ялкаулык һәм фәкыйрьлекләре белән даны чыккан, «Үшән» кушаматы тагылган нәселдән Халәп күренде. Өс-башы ташка үлчим: ямау өстенә ямау чәпәлгән кыска кайры тун, чите камалы мескен бүрек, төбе асылынып торган ычкырлы киндер ыштан. Аягында, кайчандыр ак булып та, хәзер инде лимон сарылыгы, янә тагын күп төрле төсләр иңгән тула оек белән чабата. Чабатасының да бер сыңары «мыек» җибәргән.

Аның каравы кыяфәт бик әшлекле, горур, түш кабарынкы, баш чөелгән. Иргали белән дә:

— Абау, күземә күренәме әллә?! Былтыр үлгән карга быел башын калкыткан, диләрме әле? Син дә исән икән ич,— дип, эре генә исәнләште.

Иргали дә:

— Җеназамны укырга иртәрәк ашыккансыз,— дип җавап кайтарды.

— Партиядәме? — диде Халәп. Бер дә харап, тавышы һавалы, мәгърур!

— Юк. Өлгермәдем.

— Как так? Шул заман эчендәме?

Сүзгә Хәят кушылды:

— Зарары юк. Иргали абый кебек тормыш сынаулары үткән кеше бездән әллә ни ерак китә алмас...

Халәп аны кырт кисте.

— Какуй-такуй ерак китү?!.— дигән булды ул хәйранга калган кеше сыман итеп.— Дөньякүләм революция булырга торганда, кызылармеец башы белән ни көтеп яткан ул?..

Халәпнең бар кыяфәтендә, үз-үзен тотышында: менә күр, кем идек, кем булдык, дигән нәрсә чагыла иде. Бәһрам абзыйның өстәле янына да бик эре кыяфәт белән узды, тезен-тезгә атландырып, бүреген салып

тезе өстенә чәпәп куйды. Бу минутта борын яфраклары күпергән, сулышын еш-еш ала, тикмәгә генә йөрмәгәнлеге йөзенә чыккан иде аның.

— Бәһрам ага, Хәят, үзара гына сөйләшеп аласы бар иде...

Иргали аның яшьрәк чагында да ярпачланырга яратучы вакчыл бер адәм икәнлеген белә иде. Әмма бу мизгелдә Халәпнең гыжылдап чыккан карлыккан һәм чак кына тыңкыш тавышы әллә нишләтеп җибәрде аны.

— Юкка хафаланма, әйт әйтер сүзеңне,— диде Бәһрам җизнәсе тыныч кына.— Иргали ул күптән үз кеше, тугыз дәрья суы эчкән, ничәмә-ничә ил кичкән фронтовик.

Халәпнең үз тугызы тугыз:

— Мин ячейка әгъзалары белән генә дип әйтмәкче идем...

Иргали күңел төбеннән актарылып кайнап күтәрелә башлаган яман хис якынаюын тойды. Ах-х, беткән җан! Мәхлук җан! Әҗәткана! Хәтер саклыйм дип тә уйламый бит, кабахәт! Әмма Иргали ярсырга ярамавын, вакланмаска кирәклекне шунда ук абайлап алды.

— Нәрсә, мине ят элементка санамыйсыңдыр ич?..

Халәпнең җавабы әзер.

— Шту син! Алай димәдем ич.— Шулай да ирәеп өстәп куюны кирәк тапты ахрысы: — Бары тик партия Уставының төгәл үтәлүен генә таләп итәм мин...

Гарьләнде Иргали. Бу минутта ул үзен читкә тибәрелгән кеше сыман хис итте. Әллә үзәгенә җиткерерлек, үтерерлек итеп берәр сүз әйтимме икән? дип уйланды. Янак итен чәйни башлавын үзе дә сизми иде Иргали. Юк, сабыр итим, түзим дип күпме генә тырышса да, булдыра алмады, әйтте. Моның ише эрсез алабайларга сыя ул дип уйлагандыр инде.

— Бу балак бете шулай башка ук мендемени инде?..— диде Иргали, ачы бер көлемсерәү белән.— Әтәч булып кычкыра башлаган дип әйтүем...

Үшән Халәп корт чаккандай чәчрәп урыныннан ук торды. Көлсу йөзе тагын да төссезләнә төште. Күзләреннән утлар чәчеп яный ук башлады.

— Әй, син! Авызыңны чамалабрак ач, яме. Югыйсә күрсәтермен мин сиңа балак бетен! Баганага сәлам бирерлек итәрмен! Туже миңа, кызылармеец! Миңа калса, сине без бары тик ләгънәт царизмның, падишаһ әгъзам хәзрәтләренең турылыклы колы-солдаты дип кенә беләбез. Шул тугры хезмәтләрең өчен көмеш медаль алуың да безгә сер түгел. Авылдан киткәнеңә дә җиде былтыр. Кем булып кайткансыңдыр бит әле, анысын бер шайтан үзе белә...

— Очынма! — Иргалинең тавышы хәрби команда сыманрак яңгырады: — Синең ише бушбугазларны гына күп күргән мин.

Шулай көтмәгәндә-искәрмәгәндә ут чәчеп, буран уйнатып әйтешә дә башладылар. Бу хәлне күреп, Бәһрам абзый да урыныннан күтәрелергә һәм араларына керергә мәҗбүр булды.

— Иплэп, иплэп кенә! Ниткән хәл бу? Нәрсә бүлешә алмыйсыз? Җитте сезгә! — Бәһрам агай иң әүвәл Халәпне элеп алды.— Син нәрсә, ә? Нишләвең бу?

Тегесе дә чытырдап тора.

— Ә ул нәрсә? Вәт, понимаешь! Кайтып җитмәс борын бугазга баса. Мыскыл итә...

Иргали дә, усал-мәкерле елмаеп, җавабын кайтарды.

— Дөреслекне әйтү — мыскыл итү була алмый.

— Мин дә кеше бит.

— Анысын да исбат итәсе бар әле.

Бәһрам агай, күзләрен ямьсезләндереп, Халәпне кысрыклавын белде.

— Иң элек син минем соравыма җавап бир. Сиңа бөтен ячейка исеменнән сөйләргә кем рөхсәт бирде соң әле? Иң элек шул сорауга җавап бир. Әй-йе!

Халәп тә төшеп калганнардан түгел.

— Миңа ни булган ди? Нишләгән соң әле мин? — диде ул кашын-

күзен җимереп.— Саклык, уяулык дигән нәрсә көн тәртибеннән төште дәмени инде, ә? Үзең үк ике сүзнең берендә: сак-уяу булырга өйрәтә партия дисең ич.— Халәп, Иргали ягына яман караш ташлап, янә кан катырырлык сүз ташлады: — Болайга киткәч, ничек кайтканын, нинди уйлар белән кайтканын иртәгә үк тикшерттерәчәкмен мин аның.

Иргали, һәрнәрсәдән өметен өзгән кеше кебек, Халәп утырган якка кулын селтәде дә, ишеккә таба юнәлде. Ишек шундый көч белән ябылды — тәрәзә пыялалары зыңгылдап, түшәмнән комнар коелды.

Шушы юк кына нәрсә дә Иргалине тәмам кешелектән чыгарды. Бушап калган күңеленә шыксыз елан сыман, ниндидер салкынлык үрләде. Башында төрле килде-китте уйлар хәрәкәтләнде. «Менә бит эт йөз,— дип уйлады ул,— тәки йөрәкне урыныннан кузгатты. Хәл-әхвәл сорашу юк, киңәш итү юк, тот та кешене, чит-ят иткәндәй, эткәли-төрткәли башла имеш. Нәрсә күрёп шул тикле көдрәя ул? Кыланышларына егылыплар үләрсең, һич тә чик-чамасы юк: Узындырганнар, ирәйткәннәр хашәпне...»

Ай-һай ла ямансу, түзә алмаслык авыр иде бу минутта Иргалигә. Ярсуы бераз басыла төшкәч, аеграк акыл белән уйлый алыр хәлгә килгәч: нигә, нигә дип шул йолкыш белән телгә килдем соң әле дип, и-и үкенде дә соң Иргали, и угаланды, үзен кая куярга белмәде.

Шундый уйларга бирелеп атлый торгач, янә туган нигезе янына килеп чыкканын сизми дә калган Иргали. Кичке эңгер иңеп килгәнгәме, бу тирәләр хәзер тагын да шыксызрак, тагын да яманрак булып күренә. Каралтыларның эзе дә калмаган. Базы ишелгән. Ул урыннарда котырып кычыткан, әрекмән, шайтан таягы үскән, як-ягын йодрык-йодрык чәчәкле чәнечкеле меңьяшәр баскан. Чак кына арырак, буш яткан бакча, чүп баскан җир. Шул яктан, елга буеннан, ләм, бака ефәге исе тарала.

Иргали, сәҗдәгә чүккән сыман, тәмам җиргә чүмәшкән өйгә якынрак килде. Тирә-юньгә карарга имәнгеч, һәрнәрсә череп-муртаеп кара көйгән, һәрнәрсә күңел кайтаргыч, тәрәзәләренә аркылы-торкылы каккан такталарга кадәр тузып, коелып беткән. Череп-укмашып тирескә әверелгән салам түбә дә урыны-урыны белән эчкә савылып төшкән. Нәзек бастырыклар янгыннан калган кисәүләр сыман өзгәләнеп ята. Тал чыбыктан үреп ясалган читән өйалдының балчыгы күптән инде коелып беткән. Рәт-рәт булып тезелешкән кабыгы купкан нәзер-нечкә читән агачлары, читтән караганда, үләксә кабыргаларын хәтерләтәләр иде.

Шулай да ишектәге тутыгып беткән йозагы исән. Ничек алып китмәгәннәр диген син аны! Баскыч урынына салган иләмсез зур яссы таш та үз урынында. Ул да, инде күптән кеше аягы җылысын тоймаганлыктан, мүкләнеп беткән. Гомумән, өйнең яшәрлеге калмаган. Агач юнәтеп сипләтеп-яңартырлык та түгел бит ичмаса.

Әле кайчан гына монда, бик үк җитенкедән булмаса да, тигез тормыш хөкем сөрә иде. Газиз әнисе, солдатка чакырылганчы өч кенә ай яшәп калган хәләл хатыны... Соңрак бар да бетте. Күзләреннән канъяшь агызып елап калган әнисе юк, беренче тапкыр: «Сиңа әйтәм, буемда бар...» — дип пышылдап калган Гөлнисаның да язмышлары билгеле түгел.

И-и, шәфкатьсез дөнья, аяусыз тормыш, мәрхәмәтсез язмыш...

— Инде нишләп карарга? Ат сорап, кая барып бәрелергә, кая сугылырга, кемгә кагылырга? — дип, башын иеп, үз-үзенә биргән сорауларга җавап таба алмыйча дөньялардан китеп торганда, Иргалинең каршысында, алар очы мәхәлләсе хуҗасы — Гыйззәт хәзрәт пәйда булды.

— Бәрәкалла! Иргали күрше димме? Сөбханалла, син ич! — дип беренче булып ул сүз катты.

Бу көтелмәгән очрашудан чак кына каушап, югалып калган сыман булды Иргали. Хикмәт шунда: ничек итеп мөрәҗәгать итәргә? Хәзрәт дипме, тәкъсир дияргәме? Бәлки заманча: Гыйззәт абзый, дип атаргадыр. Тәвәккәлләп телгә килде Иргали:

— Мин, мин, хәзрәт!.. Әссәламегаләйкем, тәкъсир!..

— Вәгаләйкем әссәлам, кем, Иргали күрше. Баянак, ахшам намазына килгән картларның берсе шулай дип тора иде шул. Һай-й алла, менә бит, ә! Кайтыр юлларың киселмәсә, җыяр тәгамнәрең, эчәр суларың тартса, бер әйләнеп кайтасың икән аны. Ә бит инде синең турыда тегенди-мондый хәбәрләр дә ишетелгәләгән иде. Әһ-һе-е!..

Иргали дә үз чиратында, хәзрәтне күрергә теләве, юл капчыгында атап хәзерләнгән кечкенә генә бүләге булуы турында да әйтте. Сүз уңаенда мәрхүмә әнисен телгә алды, аны ничегрәк җирләүләрен сорап куйды.

Хәзрәтнең дә теле ачылды.

— Әниең мәрхүмәнең урыны оҗмах түреннән була күрсен берүк, түшәктә чирләп озак ятмады. Ил карчыгы дип, җиренә җиткереп, ясинын чыгып, гүргә иңдердек. Шулай итеп башкалар белән беррәттән дәфен кылынды. Барысы да үз күзәтчелегемдә башкарылды. Ул яктан, ходайга шөкер, ил алдында да, дин алдында да намусым пакь. Үлем алдында, кем, Иргали, барыбыз да тигез, барыбыз да көчсез. Көне-сәгате җиткәч, барыбыз да шунда булачак. Ил өстеннән афәт-зилзилә узган елны, айһай ла үлем-җитем күп булды, ярты авыл кырылды. Ачлык — җир йөзендә иң зур, иң каһәрле афәт димәсләр иде аны. Шуңа да карамастан, күмүчеләрен дә үзем барладым, үзем билгеләдем. Башка авылларда, әнә, мәетләрне аннан-моннан гына кара туфрак белән томалау яки бөтенләй җир өстендә калдыру очраклары булган икән дигән сүзләр йөрде. Этләр авызыннан адәм әгъзалары тартып алу кебек яман хәлләр дә булгалаган дип сөйләделәр. Алла сакласын, алла сакласын! Ул яктан бездә, ходайга шөкер, бар да шәригать кушканча булды. Һәр мәет бөтен шартларын китереп, кабере кызыл балчыкка кадәр җиткерелеп, җир куенына тапшырылды. Халыкның рәхмәте чиксез булды...— Бу сүзләрне әйткәндә, хәзрәтнең тавышы йомшарып кына калмыйча, изрәткеч бер көйләүгә күчте. Ул янә дә тигез, колакка ятышлы тавыш белән дәвам итте.— Ә инде, кем, Иргали, әниеңнең кабере кайдалыгын белергә теләсәң, ай-һай ла, күрсәтүче табылырмы икән?! Авылның ике мәхәлләсенең берсендә, биш вакыт намазның берсен калдырмый үтәп барган мәчет картларының, авыл диндарларының күпчелеге хәзер үзләре гүр ияләре.

Шулчак хәзрәт, Иргали ягына сынаулы караш ташлап, искәрмәстән генә аның сәяси хәле турында сорап куйды: бәлшәвикме, түгелме? Иргалинең, хәзрәтчә әйтсәк: «бәлшәвик» булырга өлгерә алмавы турында ишеткәч, йөзе ачылып китте сыман, ул хәтта: «Бәрәкалла!» — дип, уң кулы белән, очлаеп килгән чал сакалын сыпыргалап куйды.

— Күңелемнең кай җире беләндер, шулайдыр дип уйлаган идем аны. Атаң яхшы кеше иде, бабаң пәйгамбәр өммәтенә алыштыргысыз, анаң изге җан, үзең дә бик тәүфыйкълы булып үстең. Һәм дә шундый булып калырга ходай кушсын берүк. Югыйсә бит адәм баласы илдән-җирдән, диннән-мәчеттән аерылдымы, төрле вәсвәсәгә бирелүчән була. Менә әйткән иде диярсең, синең ул бәлшәвиклеккә язылмавың, бәлки әле мәслихәтрәк тә булыр. Югыйсә заманалар бозылды, илдән иминлек качты, кая карама — талаш-ызгыш, җәбер-золым. Кешеләрдә сабырлык дигән изге көч сынды. Болайга китсә, тагын да зуррак хафаларга төшүебез, әллә нинди яман хәлләргә юлыгуыбыз бик ихтимал. Тәкъдир әманәте дигән нәрсә, аңа турылыклылык дигән нәрсә бетте. Боларның барысы да хәерчелекнең, тормышның артка китүенең башы. Гомумән, кешене рәнҗетү җүнлелеккә илтми ул.

Хәзрәт тагын әллә никадәрле изге сүзләр тезде. Бакый дөнья, хак тәгалә турында да вәгазь укыштыргандай итте. Һәм шунда Иргалине кабат күздән кичерде дә өенә керергә, ризык-тәгамнән авыз итеп чыгарга чакырды.

— Әйдә, кем, Иргали күрше, керик, күз күргән, бер сукмак таптаган кешебез. Үзең мөсафир кеше, солдат кеше, әйдә, тукланып чык, аш иясенә дә савап булыр...

Хәзрәтнең ихлас күңелдән, бик тә үз итеп чакыруы Иргалине әллә нишләтеп җибәрде. Заманында халык арасында Гыйззәт хәзрәтне «Усал хәзрәт» дип йөртүләрен ул яхшы хәтерли иде. Чыннан да, бөтен авылны дер селкетеп, өнен алып торган кеше ул. Бигрәк тә яшьләр шүрлиләр иде аңардан. Хәзрәтнең яшелгә буялган чукмар башлы таягыннан, бөтен авыл халкына ишетелерлек итеп кычкырып каргавыннан, бәддога укуыннан шүрлиләр иде. Иргали Гыйззәт хәзрәтнең, авыл картларын җыеп, мәчет алдында: «Ярман сугыш башлаган»,— дип тәгъбир әйттерүен хәтерли. Ул күренеш, авыл диндарларының кулларын күтәреп тәкъбир әйтүләре әле дә булса күз алдында тора.

Иргали үзе белән янәшә атлап барган хәзрәткә күз төшергәләп ала. Дөнья бетереп зарланса да, яшенле-дәһшәтле еллар әллә ни үзгәртмәгән аны. Бары тик өс-башы гына бүтәнчәрәк. Элек затлырак та, баерак та киенә иде кебек. Бәлки дөнья күрмәгән, дөнья белмәгән Иргалигә генә шулай булып тоелгандыр. Хәзер исә әнә хәзрәтнең өстендә җиңел хәтфә бишмәт. Бишмәт өстеннән түсе уңган җилән киеп алган. Башында җыйнак кына кырпу бүрек. Бу инде яңалык. Элегрәк башыннан ак чалма төшмәс иде аның. Аягында киез ката. Кулында исә гадәттә карткоры таянып йөри торган гап-гади туйра таяк.

Гыйззәт хәзрәтнең өе мәчеткә каршы гына. Бик тиз барып җиттеләр. Биек урыс капкадан керү белән күрде Иргали: бөтен нәрсә җитеш — йорт кына түгел, абзар, келәт, лапас, мунча кебек каралтылар байларча, өр-яңадан булмасалар да, бик ныклар. Мал-туар да ишле булырга тиеш. Абзар тирәсеннән печән, сбруй, ат тизәге исе, муллык исе бөркелеп тора. Иргалинең ялгышмавын раслагандай, ишегалдының буеннан-буена сузылган абзар ягыннан, ат пошкырган тавыш ишетелде.

Аларны унлы лампа белән яктыртылган, җылы итеп ягылган һәм мул булып төрле ризык-тәгам исе чыккан өй каршылады. Бусага аша атлап керү белән, хуҗа кеше шәрран ярып аваз салды:

— Каячы, кайсыгыз бар анда? Самавырны яңартыгыз, олуг кунак бар...

Кече яктагы сәке өстендә ястү намазга оеп тәсбих тартып утырган остабикә, бу сүзләрнең миңа бернинди дә катнашы юк дигән сыман, картының сүзләрен колагына да элмәде. Ак яулыгының ике почмагын җилкәсенә таратып, ике очын ияк астыннан бәйләп куйган остабикә, тәсбих тоткан куш кулын йөзе турысына күтәрә төшеп, сәҗдәгә иелде. Шулчак, каяндыр аралыктан, өрәктәй чандыр бер хатын килеп чыкты. Җилләнеп килеп тә чыкты, иң әүвәл хәзрәтнең өстен салдырып элде. Шундук житез-өлгер хәрәкәтләнеп, табын хәзерли башлады. Иң элек түрге як сәкене тоташтан иңләгән ап-ак тула киез өстенә ак-кызыл шакмак бизәкләр төшереп сугылган киндер ашъяулык җәйде. Шундук поднос белән чынаяктыр, вак-төяк савыт-сабалардыр ташый башлады.

Хәзрәт, ым кагып кына, Иргалигә дә чишенергә кушты. Кунак кыстатмады, шинелен салып элде дә, хуҗаның чишенеп бетүен көтеп, тәрәзә буендагы эскәмиягә килеп чүкте.

Ниһаять, хуҗа да кара хәтфә кәләпүш, озын ак күлмәк, кара камзол, йомшак читектән генә калды. Бары тик шуннан соң гына сәке йөзлегенә килеп утырып, «Ләхәүлә...» дип, йоласын китереп, озаклап дога кылды. Иргали дә битен сыпыргандай итте.

Ул арада табынның түрге өлешенә пар бөркеп торган самавыр, урта бер җиргә тәмле хуш ис таратып, йөзе килеп пешкән кабартма тутырылган агач табак килеп утырган иде инде.

Түр башына менеп кунаклаган хуҗа:

— Әйдә, кем, Иргали улым, булганыннан җитеш,— дип, бисмилласын әйтте дә кабартма тутырылган табакка үрелде. Башта дәшмитынмый гына ашадылар. Чәйне хәзрәт үзе ясады. Иргали ягына да күз төшергәләп алды, итләч ирене белән елмайды да: «Үзең болай, кем, сөбханалла күренәсең»,— дип, соклануын белдерде.

Иргали дә үз чиратында хуҗа ягына күз салгалап алды. Эченнән генә, үзең дә шайтан кебек тазасың икән әле, дип уйлап куйды. Күр син аны, дәү-дәү кабартмаларны ике-өч кенә каба, чәйнәгәндә сакалы селкенә дә җыерчыклы муен тиресе астында бугаз төене генә хәрәкәтләнә.

Иргали, Гыйззәт хәзрәтнең аны бары тик мөсафир солдат булганы өчен генә шул тиклем ихлас теләктәшлек күрсәтеп чәйгә чакырмавын күңеленең кай җире беләндер чамалаган иде инде. «Бәлшәвик» тә булмагач, сере сыярдай кеше дип уйлагандыр, мөгаен. Чыннан да, күңел тоемы алдаламаган икән Иргалине. Хәзрәт: «Яле, кем, Иргали улым, житеш әле, житеш!» дип кыстый торгач, бермәлгә тынып калды. Тик озакка түгел. Менә ул, шаһит булырдай өченче бер кешене эзләгәндәй, ишек ягына күз салгалап алды да, йөзенә рәнҗү билгеләре чыгарып, яңадан зарланырга кереште. Бу юлы инде сүзне шактый урау башлады ул.

— Заманалар бозылды, кем, Иргали улым. Тормышларның көе китте, тегеләй уйларга да, болай юрарга да чама калмады. Өн юк, сан юк, дигәндәй, тәмам аптыраган. Бәндәләрдә уртак иман, дини әдәп, милли гадәт дигән нәрсәләр тәмам бетте. Элегрәк ичмаса борынгылар сүзе, картлар сүзе, ата-ана сүзе дигән төшенчәләр бар иде. Хәзер бары да бетте. Олы дип тору юк, кечене санга сукты юк, бер-берсенең бугазын чәйнәшергә генә торалар. Борынгылар: югарыга карап фикер йөрт, түбәнгә карап шөкер ит, дип өйрәтәләр иде. Хәлләребез яман, кем, Иргали улым. Гөнаһларыбыз баштан ашкан. Шул гөнаһлар өчен хода каршында мәңгелек тәмуг кисәүләре булу ихтималыбызны онытабыз. Кая карама — бозыклык, гөнаһ вә дә азгынлык. Шул бозык җаннар, дәһриләр аркасында ил тулы кәсафәт. Әй-йе! Нәтиҗәсе, әнә, күз алдында: төрле афәтләр, җәбер-золымнар. Илгә-көнгә килгән кайгы-хәсрәт бихисап. Боларны һич кенә дә әгъла эш дип атый алмыйм мин...

Өй хуҗасы Иргали ягына кабат сынаулы караш ташлады: ничегрәк кабул итеlә аның сүзләре? Кунакның йөзендә алай әллә ни зур үзгәреш, хәйран калу галәмәтләре күрмәгәч, тагын да шәрехләбрәк сүзен дәвам итте.

— Хәзер, әнә, ике сүзнең берендә, авыз суларын корытып, яңа тормыш, яңача яшәү турында әгиткә алып баралар. Ничек яшәргә икәнлекне аны, кем әйтмешли, чәнти бармак тырнагына да язып-сыйдырып була: иман пакьлыгыңны сакла, күңелең саф, сүзләрең хак, вөҗданың керсез, хезмәтең, кылган эшләрең гадел булсын. Янә дә килеп, кеше өлешенә тиясе булма, кеше хакына керәсе итмә. Менә, булган чын хакыйкать шул. Ә инде сөягеңә кот кунсын, атлы-тунлы, тук-бөтен яшим дисең икән, рәхим ит, анысы да үз ихтыярыңда, юлы бер — намуслы хезмәт. Дин дә, байлык та, бәхет тә — хезмәт сөюче кулында. Һәркемгә мәгълүм — кеше ризыкка тиенгәч кенә бәхетле. Эшчән бәхетне эшендә күрер, ялкау төшендә күрер димәсләр иде аны.— Хәзрәт тынып калды, әмма озакка түгел, Иргалинең йөзенә туры карап, тавышына чак кына киная өстәп дәвам итте.— Инде килеп, кемнәрнеңдер баштан ашкан хәерчелегенә — үзләренең үк үтә ялкаулыгы, коточкыч мәнсезлеге, үз-үзләрен иҗтиһат иттермәүләре сәбәп. Нәкъ менә шундыйлар, кулларыннан эш килмәгән җыен пүчтәк, җыен хәсисләр кеше малына күз алартучан булалар. Ходай бирмәгәнне башкалардан тартып алырга яраса, теләсә кем шулай итәр иде аны, мең газап белән мал тапмас, тир түкмәс, талау кебек яман шөгыль белән генә мәшгуль булыр иде.

Хәзрәтнең моңарчы сөйләгәннәре-кереш сүз генә булган икән. Ниһаять ул, тавышына мескенләнү халәте чыгарып, хаксызлыкка бик нык рәнҗетелгән кеше сыман, әйтергә җыенган төп фикерен дә чыгарып селекте.

— Әйт әле, кем, Иргали улым, җир-суларыбызны алып дөрес иттеме совет?

Кабыргасы белән куелган бу сорауга җавап бирергә өлгерә алмыйчарак калды Иргали. Йөзенә күз сирпеп алу белән кунагының ниндирәк

җавап бирәсен бер мизгелдә төшенде хәзрәт. Дөрес төшенде. Әһә-ә, бу да җир-суларны халыкка бирү ягында икән. Болай булгач бик үк чишелеп-туарылып ташларга ярамас. Өй хуҗасы, җәберсенгән бер кыяфәткә кереп, болай диде:

— Ярар да ди, алсыннар да ди. Крестьянга җир кирәк тә булсын ди. Дөрес, крестьяннарның күпчелеге җиргә ябышып ята, аңа үзенең тотанагы, өмете, яшәү чыганагы итеп карый. Андыйларның җир-биләмәләрен арттырсыннар да ди инде. Әмма аның бит әле арада җир кадерен белмәгәннәре дә очрый. Нәкъ менә шундыйлары, кулларыннан рәтле эш килмәгәннәре, җир-җир дип, тамак җырталар, акыралар-бакыралар, тәмам котырыналар. Нәрсә, кирәк булганы өчен алдылар дисеңме ул җирне? Һич юк! Бары тик нәфселәрен басар өчен генә алдылар. Ә нәфес, белгәнеңчә, чикне тоймый. Нәтиҗәдә, әнә нәрсә килеп чыкты! Миннән тартып алган җирләр тоташтан диярлек кысыр калды. Күргән саен күз яшьләрем белән елыйдым. Ә бит язын, шул ук җир алган крестьяннар, атлы-тунлы, хәлле-хәстәрле кешеләргә, хәтта миңа: уртакка чәчик, бары бер җир кысыр кала, дип килмәделәр түгел, килделәр. Ялынып-ялбарып йөрделәр. Ник йөрмәсен ди! Аты дисә — аты юк, чәчү орлыгы дисә — анысы юк. Паена-иманасына чәчәр өчен совет биргән орлыгын тартты да ашады...

Бу сүзләрдә өлешчә хаклык та бардыр кебек тоелды Иргалигә. Әллә шушы уй тууы, әллә башка нәрсә сәбәп булды, ул, хәзрәтнең йөзенә туптуры карап, искәрмәстән генә болай дип сорау биреп куйды:

— Әллә бик җәберлиләрме?..

Хәленә кергән сыман әйтелгән бу сүзләр үзенекен итте. Кинәт мескенләнеп калган өй хуҗасы, капылт кына җавап бирергә ашыкмады, бары тик йөзен чытты да, тәмам өметсезлеккә бирелгән кеше кебек, билгесез бер якка кулын гына селтәде.

— И-и, кем, Иргали улым, ходай тәгалә үзе шаһит, җәберләү генәме соң, тәкатемә, җан бәгыремә тияләр. Хак тәгаләдән әҗәл теләргә генә калды инде,— дип көйләп-вәзенләп сайрарга кереште хәзрәт.— Бер тамчы хәрәм кермәгән мал-мөлкәтемә тиюләре бер хәл. Хәер, анысы да җәл. Мал — бәгырь ите димәсләр иде аны. Әмма хода гамәленә тел-теш тидерүләре, динне мәсхәрәләүләре җанны каһәрли. Тәңре каргышы төшәр дип тә уйламыйлар бит. Аның адәм рәтле кешесе золым-җәбер кылса бер хәер иде. Юк бит! Авылның иң затсыз гыйбады, браматы, хәерче әрвахы шулай кылана. И-и, адәм тәганәсе, нәгъләт яугыры! Михнәт татыту өчен яратылгандыр ул иблис токымы. Бигрәкләр дә каныга шул, якты көн күрсәтми.

Иргали, өй хуҗасын бүлеп, сүзнең кем турында баруы белән кызыксынды.

— Кем булсын ди инде! Соң шул адәм рәтенә керә алмаган, иманы качкан бер адәми зат, аяклы каза бар бит инде,— дип дәвам итте кызганнан-кыза барган хәзрәт.— Соң, теге... Үшән Халәп турында әйтүем. Шул зобаный, шул хәсис мине контр дип сөйләнеп йөргән имеш. Теле коргыры! Менә, аш өсте, шулай дигән ди. Казанның карасы, яманның бәласе йогар ди. Соң, хода бәндәсе, каян килеп мин контр булыйм ди?!. И-и, зобаный! Бөтен авыл шаһит: гелән хак тәгалә эше белән мәшгульмен. Үзең үк ишетерсең әле. Беркөн очратып: хата уйлыйсың, кем, бер дә риза-бәхил түгелмен дип караган идем дә, кая ул, колагына да элми. Ул кадәрле эктиф, ягъни сәвит куштаны булдым дигәч тә, кешегә шул тиклем золымлык кылырга, рәнҗетергә димәгәндер. Әдәп юк, низам юк. Җаны җәһәннәмгә олаккыры. Каһәр иңгере! Дөньялар шундый бәндәләр кулына калыр микәнни? Замана бүреләр кулына күчсә, кешеләр эткә әверелер ди китап.— Хәзрәт, саксызлык беләнрәк ычкынган сүзләренең Иргалигә ничегрәк тәэсир итүен сиздермичә генә абайлап алды да төзәтенгән сыман өстәде: — Кеше усаллыктан тәм таба башладымы, бетте, аннан да яман нәрсә юк фани дөньяда. Бөтен ил бәддога укыячагын көт

тә тор шул җүнсезләргә. Кеше күңеленә ут булып керсәң, көл булып чыгарсың ди. Чәнечке чәчсәң — инә урырсың дип тә әйтәләр тагын. Этлек белән игелек тә, изгелек тә эшләп булмый. Елларның казалы килүенә дә, тормышыбызның пыран-заран килүенә дә шул имансызлар гына гаепле.— Хәзрәт, тагын да тынычлана төшеп, болай дип өстәде: — Менә, кем, Иргали күрше, шулай ул. Кулыннан эш килгән түгел, ә тамак җырта белгән җыен этрәк-әләм хуҗа хәзер. Әмма дә ләкин бер хакыйкать бар: кеше рәнҗетү җүнлегә илтми. Кеше каргышы җирдә ятмый дигәннәр борынгылар. Минем ише хәлсез-көчсезләрне бугазлап, нинди ямь таба торганнардыр. Әйткән иде диярсең менә, алла орачак әле үзләрен... Тәүбә-әстәгъфирулла, әйттем исә кайттым!

Янә каргый, яный башлавын бик тиз абайлап алды хәзрәт һәм бөтенләй кайтып төшкән бер кыяфәткә кереп, халыкның явызлыгыннан һәм комсызлыгыннан, хөсетлегеннән зарлана башлады.

— Азынды халык, бозылды. Иман байлыгы турында онытты. Дөнья малы кирәк хәзер кешегә. Мал-мөлкәтнең нинди юл белән керүендә эше юк хәзер аның. Тормышка ашмас өметләр белән яши башлады хәзер кеше. Яман чир бу. Җил биргәнне җил алыр дигән борынгылар. Һич югында, шул изге әманәт булырлык сүзләрне истән чыгармаска кирәк иде. Кешегә изгелек кылырга өйрәнергә кирәк. Шул җитенкерәми. Кеше гомере — искән җил ди. Бу фани дөньяга мәңгегә килмәгәнбез, иман байлыгы турында уйларга кирәк иде кана. Шул турыда ешрак исебезгә төшергәләсәк, бер-беребезгә карата бу кадәр мәрхәмәтсез дә булмас идек без.

Иргали Гыйззәт хәзрәтнең моң-зарын тыңласа да тыңлады, тыңламаса да тыңлады. Солдатка каралганчы ук инде ул аның кем икәнлеген, нәрсәгә сәләтле булуын яхшы белә иде. Хәзер дә күп кенә мәсьәләләрдә хәзрәт белән килешмәсә дә, каршы төшеп, сүз көрәштереп, бәхәс кузгатып маташмады. Аның үзенеке үзенә җиткән иде бу мизгелдә. Шунлыктан Иргали өй хуҗасының сүзләрен җөпләп утырудан узмады. Кунакта, ризыкташ булып утыруын да онытмаска кирәк иде.

Иргали стенага эленгән җиз телле зур сәгатькә күз төшереп алды. Вакыт соң иде инде. Шунда ул чынаягын каплады да, сый-хөрмәт өчен мең-мең рәхмәтләрен әйтеп, кушкуллап битен сыпыргандай итте.

Хәзрәт тә артык кыстамады. Тезләре өстендә яткан сөлгесен бер читкә алып куйды да, оеган аякларын язганда ах-вах килеп, сәкедән төшә башлады.

— Кара әле, кем, мелла, баядан бирле сорарга ниятләнеп торам, кайда туктадың соң син? Кунарга кемгә кердең диюем? Өеңнең рәтечираты калмаган, тәртеп ишәсе генә бар үзен. Ходай сакласын, ишелепнитеп бала-чаганы, килеп елышкан мал-туарны имгәтүе бар. Киртәчитәне юк...— Хәзрәт аякларына киез-ката киеп алды.— Ни өчен әйтәм әле, әгәренки сөйләшенгән кешең булмаса, бүгенгә бездә генә кунып чыгарсың. Әй-йе!..

Иргали мәсьәләнең бу ягы турында бөтенләй уйламаган иде. Җанын ярып бирердәй булып торса да, ялгыз яшәгән Зәйтүнә күршесенә керүе дә кыен бит әле. Шунлыктан, иртәгә барысын да берьюлы хәл итәрмен дип, кабат рәхмәтләр әйтеп, Иргали Гыйззәт хәзрәтләрдә кунарга калды.

Урын хәстәрләгәнче һава алыштырып керик дип, җиләк-җимеш бакчасы буендагы эскәмиягә чыгып утырдылар. Күзгә төн караңгы иде. Аййолдызлар да күренми, күк йөзен тоташтан авыр болытлар каплаган. Тирә-юньне пәрәвез кебек йөзгә-биткә килеп сарылучан дымлы томан чорнаган. Тынлык. Бары тик кайдадыр тыкрык башында кое сиртмәсе шыгырдый да иренеп кенә эт өргән тавыш ишетелеп куйгалый.

Хәзрәтнең әле һаман да сүзе бетмәгән булган икән.

— Бар да һәйбәт булыр, кем, Иргали туган. Тик башкалар котырта дип шайтан вәсвәсәсенә бирелә күрмә. Күңелем тоя, тора-бара тормышларыбыз рәтләнеп җитәр төсле. Әнә заманалар иске юлына төшәргә чама-

лый түгелме соң...— Хәзрәт бик зур сер әйткән кебек итеп, сорау биреп куйды.— Син, кем, мелла, минем туганнан-туган Минһаҗеттинне беләдер идеңме? Белгәнсеңдер, билгеле. Калада ул хәзер. Казанның үзендә. Күптән түгел генә шул кайтып киткән иде. Монда утары бар аның. Үзе кыл да селкетми. Бик үткен приказчигы бар, шуның аша гына эш йөртә. Миндә кунакта чакта шул Минһаҗеттин болайрак дип тора иде. Тормышлар, имештер, яңадан кәсеп итә белүчеләр кулына күчеп бара. Ленин булып Ленин шул хакыйкатькә төшенгән ди хәзер. Сәүдә эше белән әнә сәүдәгәрләр шөгыльләнсен дип әйтеп әйткән ди. Әйтеп кенә дә калмаган, сату-алу эшенә пулный слабуда биргән ди. Кураләтә торып Рәчәй тиклем Рәчәйне хәерчелеккә, бөлгенлеккә төшерергә — Ленинның башына тай типмәгән бит дип торды. Минһаҗеттинне әйтәм әле, бәлшәвикләрнең сату-алуга рөхсәте чыкканнан соң, ай-һай ла канатларын җәйде, Казанның үзендә генә дә яңадан ике-өч зур кибет ачып җибәргән.

Хәзрәт, бу өлкәдә белдеклелеген күрсәтергә теләгәндәй, үтемле гыйбарәләр белән ныгытып, сәүдә турында үзенчә фәлсәфә дә сатып алгандай итте.

— Сәүдә дә сәүдә дибез. Нәрсә соң ул сәүдә? Кара акылым белән аңлавымча, сәүдә — батырлык, тәвәккәллек, тапкырлык сорый торган, Мөхәммәт пәйгамбәрдән калган изге һәм игелекле шөгыльдер. Шуның өстенә, сәүдә — аралашу дигән сүз. Ә аралашу ул — гыйбрәт алу, яңару, үсеш, ниһаять. Бәлшәвикләр моны аңламыйлар дисеңме? Бар, аңламаслар! Әнә, Минһаҗеттин нәрсә дип тора, дәрт иткән кешегә — рәхим ит — юл ачык ди. Үземчә мин болай уйлыйм, хәрам кермәгән кәсепнең бернинди дә гөнаһысы юк: алла каршында да, сәвит каршында да.— Гыйззәт хәзрәт, җаен туры китереп, янә ярым пышылдап, кыстырып куйды: — Халык арасында, әнә, яңадан имеш-мимеш сүзләр йөри: янәседер, җирсулар да элеккеге хуҗаларына кайтарылачак... Димәк, әлеге власның язмышы да әнә очында гына. Дөньялар болайга китсә, һич тә булмас димә. Әгәренки таңре боерып, насыйп булса, сине дә, кем, Иргали улым, читтә калдырмас идек. Вәгъдә итү — бөлдерми дип кенә әйтүем түгел. Әнә, Минһаҗеттин үзенең соңгы кайтуында: кызыл товар ташу өчен бирәр ышанычлырак, күз күргәнрәк олаучы кирәк иде дип торды. Олы сәүдәгәрдә олаучы булуның хикмәтле яклары бар аның. Эше дә әллә ни авыр түгел. Атлары тотып тыйгысыз, арба-чанасы да калача: резин көпчәк тә тимер табан. Тамагың тук, өстең бөтен булачак, боерган булса, баш очыгыздагы түбә турында әйтеп торасы да юк...

Хәзрәт янә Иргали ягына күз сирпеп алды. Бу сүзләрдән соң ул бәлки кунагының мең-мең рәхмәтләр әйтеп, моңарчы бикле күңелен ачып салуын көткәндер. Әмма тегесе, авызына су салгандай, тик утыра бирде.

Ишегалдына чыгып утыру белән, бер кыю фикер килде Иргалинең башына. Шул фикер тынгылык бирми, бөтен барлыгын бимазалый иде аның. Абзардагы бер түгел, ике атның көр пошкыруы тудырды аңарда әлеге уй-фикерне. Хатынының, газиз баласының исәнме-түгелме икәнлеген белешеп кайту өчен ат сорап тормакчы булды Иргали. Баядан бирле шул олуг гозер-үтенечен ничегрәк итеп хәзрәткә җиткерү турында баш вата, кирәкле сүзләр эзли иде. Иң элек, әлбәттә, көнен барып көнен кайтачагы турында әйтәчәк. Ара ерак түгел, күп дигәндә утыз чакрымнар чамасындадыр ул барасы авыл. Ничегрәк итеп әйтергә соң? Ярый ла якты йөз күрсәткәч, синең ямаулык сорый торган гадәтең дә бар икән әле, дип төрттереп куймаса.

Ниһаять, тәвәккәлләде Иргали, хәзрәтнең йөзенә бик үк туры карамыйча гына, бик читенсенеп кенә, үзенең гозерен әйтте:

— Хәзрәт, бер изгелек эшләсәңче...

Гаҗәп хәл, Гыйззәт хәзрәтнең күңеле йомшак чак туры килдеме, берсүзсез риза булды да куйды. Алай гынамы әле, кунагын шул сәгатьминутта үк сәфәргә озатырга җыенган сыман итеп, лапас ягына борылып, катгый-кырыс тавыш белән:

— Саттар! Саттар, дим, кая олактың?..— дип шәрран яра башлады.

Лапас астыннан күләгә сыман гына булып, яман да озын, яман да чандыр, әмма киңчә күкрәкле бер кеше килеп чыкты. Чыкты да, бер сүз дә дәшмичә, читтәрәк туктап калды. Хәзрәтнең боерыгын тыңлап бетергәнче шунда торды.

— Көнен барып көнен кайтыр өчен ат әзерлә. Туры бияне җик. Тимер хут арбаны кара. Печән түшә. Арба башына берәр торыпша солы салырга да онытма...

Әлеге күләгә «ә» дими, «җә» дими борылды да шул ук лапас астында юк булды.

— Бер мәхлук шунда... Телсез. Алла колы бит, әйдә, яши бирсен. Адәм баласы кешегә сыенмыйча кемгә сыенсын ди...

Иргалигә урынны ян тәрәзә буенда торган зур сандык өстенә җәйделәр. Йокы тиз генә алмады аны үз кочагына. Шулай йокыга китә алмыйча көяләнеп, бурсынып яткан арада, башына мең төрле уй килде. Ничек соң әле революция, азатлык, хөррият, яңа тормыш дип кан койган, әгәр дә кирәксә, җанын да бирергә әзер кызылармеец, бернинди тартынусыз революцияне сүккән, аның казанышларын кабул итә алмаган, бүгенге тормышны ачыктан-ачык дошман күргән кеше түбәсе астына килеп эләкте? Башка урында сыймас идемени ул? Юкә белән каешның һичкайчан да бәйләнмәячәген, төенләнмәячәген Иргали белми идемени? Ничек белмәсен ди инде?!.

Яңадан уйлар. Иргалинең күз алдына Гыйззәт хәзрәтнең сынаулы карашы килде... Нәрсә ди? Комсызлыгы белән даны чыккан, тирә-юнь халкының канын эчкән Минһаҗ байга олаучы булып ялланырга диме? Бу ни бу?!. Иргалинең йөрәге янә дөрселдәргә кереште, күңеленә янә шик, икеләнүләр иңде. Шуның өчен күп корбаннар биреп яуладыкмыни соң без азатлык, тигезлек дигән нәрсәләрне? Кайда соң ул без теләгән тормыш? Тагы күпме көтәргә мөмкин ул көннәрне?.. Янә сагаюга, икеләнүгә охшашрак уйлар биләп алды Иргалинең күңелен.

Шулай кыбырсып ята торгач, уй-фикерләре тәмам чуалды аның, эзлекле фикер йөртә алмас дәрәҗәгә җитте.

Ул да түгел, күз алдына каравыл өендә булып узган вакыйгалар килде. Җаны яңадан катып киткән сыман булды Иргалинең. Юк, болайга киткәч, булмас дип уйлады ул. Булырга охшамаган. Монда Халәп кебек әрсез алабайлар белән шәрран ярып талашып-тәмсезләнеп, якалашып ятканчы, башны алырга да кая да булса олагырга. Күр инде, ә! Бүген кереп кунып чыгарлык кына да кешесе юк икән ич аның! Дөрес, үлгәндә дә зарлану, рәнҗү-иңрәү авазы чыгармас изге җан Зәйтүнә миндә яшәрсез дип әйтте дә әйтүен, әмма алар, алачык кебек өйдә үзләре дә дүрт җан. Аннары бит кеше почмагының түренә сыйсаң да, күңеленә сыймассың диләр...

Янә хатыны һәм әле үз күзләре белән күрмәгән баласы турындагы уйлар биләп алды Иргалине. Аның җаннан кадерлеләре исән-иминнәрме икән соң? Әллә газиз әнкәсе кебек алар да күптән инде тигез җирне түмгәк иткәннәрме?..

Алда көткән билгесезлек аның җанын өтә, зиһенен талкый, йөрәген сыкрата. Шулчак солдатка әллә нәрсә булды: иң элек бугазына ниндидер төер күтәрелеп, күкрәк тутырып иркенләп сулыш алырга комачаулый башлады. Ул да түгел, яңакларын көйдереп-әчеттереп, күз яшьләре тәгәрәвен тойгы Иргали.

...Телсез Саттар салкын, караңгы тәрәзә пыяласына килеп чиерткәндә, күңеле алгысыган, йөрәге йончыган Иргали керфеккә-керфек тә какмаган иде әле.

Хәзрәт тә уянды. Торып, авыз эченнән генә мыгырданып, (иман кабатлап, догалар укый иде булса кирәк) чарлакта торган сукыр лампага ут төртте.

— Тордыңмы, кем, Иргали улым? Бик яраган. Сәфәрләрең гел уңышлы, юлларың гел кояшлы була күрсен берүк. Иншалла, мөрәүбәт, ягъни изге юлга чыгасың. Бар да һәйбәт булыр, боерган булса.

Өй хуҗасы самавыр кую турында сүз кузгаткан иде дә, Иргали:

— Юк, юк, зинһар мәшәкатьләнмәгез,— дип, аяк терәп каршы торды. Шунда хәзрәт, күләгә сыман гына булып аралыкта пәйда булган хатынга, мөсафирның юлына ризык хәзерләргә кушты.

Ишегалдына чыктылар. Җигүле ат олы капкага таба каратып куелган иде инде. Озын Саттар мәш килә: күнегелгәнчә җитез хәрәкәтләнеп, һәйбәт күн сбруйларны шыгырдатып, аркалыкны күтәрде, түшлекне тарттырыбрак куйды.

Хәзрәт тә, Иргалине исенә китерергә теләгәндәй, соңгы үгет-нәсихәтне бирде. Ә үзе, әйтәсе сүзен әйтә алмый калудан курыккандай, арба тирәсендә бөтерелде.

— Ярар, кем, Иргали улым... Хәзер Ильяс пәйгамбәр юлдашың булсын. Ул-бу хәлгә тарый күрмә, хәвеф-хәтәргә юлыкма. Иплэп йөргән — имгәнмәс дигән борынгылар. Шәт иншалла, юлларың уңар, якыннарың белән кавышырсың, бәдер көн, ягъни, ай тулган көнне сәфәр чыгасың. Шулай да, ишетсең колагың: олы юлданрак йөрергә тырыш, заманалар бозык, ышанычсыз. Ходай тәгалә сакланганны саклармын дигән...

Ул арада телсез Саттар капканы киереп ачып куйган иде инде. Иргали дә, арба үрәчәсенә җиңел генә менеп утырды да, дилбегәне кулына алып, ат хуҗасына кабат рәхмәтләрен әйтте. Ак бәкәлле зифа-сылу туры бия, чөңгерүне дә көтеп тормады, кузгалып китте. Иргали капка артында калган хәзрәтнең: «Йөрер юлларың уң итсен...» — дигән соңгы сүзләрен генә аермачык ишетте.

Урам уртасына чыгу белән, ак бәкәл юырта ук башлаган иде дә, Иргали капка төбеннән карап калган хәзрәттән уңайсызланып, атны тыярга мәҗбүр булды.

Бик иртә иде әле. Шулай таң атар-атмас борын юлга чыгуына Иргали сөенеп бетә алмады. Як-ягына каранып алды. Авыл сәер тынлыкка чумган. Күк гөмбәзендә ял итәргә туктаган каурый болытлар арасыннан чыккан тулы айның чак кына томанлырак яктысы каршы яктагы өйләрнең тәрәзәләренә төшкән, шунлыктан өй эчендә ут алганга охшаш балкыш чагылып киткәли.

Иргали авыл кырыеннан үтә торган олы юлга чыкты. Ул барасы Чулпанга шул илтә дә инде. Иргали төнге тынлыкка чумган туган авылы ягына күз салды. Йорт-каралтылар, куе эңгер-меңгер аша, өй булудан бигрәк, печән яки салам чүмәләләрен хәтерләтәләр иде. Кайбер йортларның тәрәзәләрендәге утлар, читтән караганда, бик сүрән, тычкан уты сыман гына җемелдиләр.

Олы юлга чыгып, бераз китү белән, Чулман ягындагы күк чите, сизелер-сизелмәс кенә агара башлады. Димәк, таң атарга чамалый. Шул яктан тыгыз җил исеп куйды. Әлеге җил үзе белән җаннарны айкап ала торган иген басуы исен, яңарак кына сөрелгән җир исен алып килде.

Юл һәйбәт, былчырак ерасы юк, каткалак. Андый юл турында халыкта: оекчан йөрерлек, диләр. Ат җиңел генә юырта. Хәрәкәтләре килбәтле, күз иярмәслек тизлек белән аяк алыштырулары бик тә килешле. Алга ыргылу ясаган саен, камыт бавы зыңгылдый да бөят күне генә шыгырдый.

Ялкынланып яныр китә алмыйча газапланган мичне хәтерләтеп, теләр-теләмәс кенә таң ата башлады. Чулман елгасы буендагы өркәч таулар тезмәсе өстендә туктап калган ай да, суга салынган шикәр кисәге сыман, күзгә күренеп төссезләнде.

Ниһаять, кояш чыкты. Җиһан ачылды. Дөнья дәррәү яктырып китте. Һавада сузылып көмеш тоҗымнар очып үткәләде. Тирә-юньне кинәт ниндидер сафлык, җиңеллек биләп алды. Ачы әрем исе, камыл исе, сөреп ташланган туфрак исе Иргалинең җанын айкап алгандай итте.

Әкренләп күк йөзен авыр болытлар сарды. Кояш югалды. Басулар өстеннән аккан әлеге зәңгәрсу-кара кучкыл болытлар Иргалигә полк артыннан полк баруын хәтерләткәндәй булды.

Тимер хут арбаны җиңелчә генә келтерәтеп, бер көйгә юыртып барган ат, тезгененнән эләктереп алдылармыни, кинәт туктады. Күрде Иргали: юл икегә аерылган, акыллы малкай шуңа туктаган икән.

Иргали ат алдына чыкты. Ул да аптырашта: юлларның кайсысыннан китәргә? Ат-арбаның туктап, тирә-юньнең тынганын көтеп торгандай, Иргалинең баш очында ук, бәгырьләрне өзеп, торналар кычкырынганы ишетелде. Әнә алар, тигез өчпочмак ясап, авыр болытлардан калышырга теләмәгәндәй, хәтәр, ифрат та авыр сәяхәткә чыкканнар.

Иргалинең болай да чайпалырга торган күңелен пыран-заран китерү өчен җитә калды әлеге иңрәүле авазлар. Искә төшкәндә генә дә йөрәкне яман чәнчеп-ачыттырып ала торган аянычлы истәлекләр өермәсе купты. Шул мизгелдә ул үзен, юллар чатына басып, кая барырга, кай якка юл тотарга белмичә, адашып калган кеше сыман хис итте. Әлеге шыксыз уй йөрәгенә капты, бәгыре көйрәүгә тәкать тота алмас хәлгә килде.

Ни булса шул булыр дип, атын уңга борды Иргали. Сарман ягынарак каерырга кирәклекне хәтерли иде ул. Күпмедер узгач, алда, дәрьядай үзәнлек ачылды. Шунда төшенде Иргали: дөрес юлдан киткән икән.

Ят кырлар, болыннар, калкулыклар һәм үзәннәр, инешләр һәм урманнар аша үтеп, ниһаять, Иргали үзенә кирәкле авылга килеп җитте. Өйлә вакытлары якынлашкан чак иде. Моннан алты-җиде еллар чамасы элек аның бу авылга кунакка килгәне бар. Яшь хатыны Гөлниса белән — баҗаларына. Әле дә хәтерендә Иргалинең, өйләнешкән айлары гына иде. Беренче һәм соңгы тапкыр парлап өйдән чыгулары булган икән, аннары ай да үтмәде, Иргалине солдатка каралырга чакырдылар.

Бу авыл да тәмам эштән чыккан, күрәсең, еларлык хәлгә төшкән. Заманында сокланып туя алмаслык иде. Тәмам хәрабәгә калган йортлар тарау гына утыралар, шундый да ямьсезләр, шундый да өнсезләр, яман чирү узган диярсең инде менә. Кая карама — салам түбә, җимерек каралты-кура, тал чыбыгыннан үреп балчык белән катырган ихата. Тәрәзә-ишекләренә аркылы-торкылы такталар кагылганнары да байтак.

Иргали үзенә кирәкле өйне бик тиз тапты. Әмма каршысына ук килеп туктаса да, улмы, түгелме? дигән сыман икеләнеп торды. Баҗасы янына кунакка килгән елларда гына бөтен-төзек йорт-җирнең танырлыгы калмаган. Каралтысыз-курасыз, җиргә сеңәрдәй булып, сыерчык оясына охшап, япа-ялгыз йорт тора.

Иргали атын йорт ягына борды. Кайчандыр бизәкләп-чуарлап эшләнгән урыс капканың да хәзер нибары бер баганасы гына тырпаеп калган. Аның да капка баганасы икәнлеген тутыккан зур күгәненнән генә чамалап була.

Иргали үзенең нишләгәнен абайламаган кешедәй, иң элек атын әлеге багананың күгәненә бәйләп куйды, нуктасын бушатты, авызлыгын ычкындырды. Арбага түшәлгән печән астыннан солылы торыпшаны алып, элмәгеннән ат муенына кидерде. Бары тик шуннан соң гына судан кайтып килүче кыз баланың үз турысына килеп җитүен көтә башлады.

Яшүсмер кыз бик тә инде фәкыйрь киенгән иде. Өстендәге, иске буллудан да бигрәк күптән инде кечерәеп калган бишмәтеннән тәмам «чыгып төшкән». Тездән өскә күтәрелгән бишмәте астыннан, ямаулык өстенә ямаулык салынган кызгылт төстәге күлмәге күренеп тора. Аякларында киндерәләрен «суырып» кечерәйтү сәбәпле, башлары кәкрәеп килгән чабата. Иргалине иң гаҗәпләндергәне шул булды: кыз бала җилкәсенә көянтә урынына, чиләкләре шуып төшмәсен өчен, баш-башы киртекләнгән гап-гади каен колгасы салган. Бишмәтенең кыскарган җиңнәреннән терсәгенә кадәр чыккан, күшегүдән күгәрчен тәпиләренә охшап калган куллары, әлеге колга өстендә. Шунлыктан кыз баланың кыяфәте канаты каерылган кошны хәтерләтә иде.

Кыз да Иргали туктаган өй ягына борылды, җигүле ат янына җитәрәк туктап калды. Иргали дә, шул форсаттан файдаланып, үзенең беренче соравын бирергә ашыкты.

— Үскәнем!.. Гаффар дигән кешенең өе шушы бугай бит? — диде ул.

— Өе шушы. Тик, абый, ул юк бит.

— Кайда соң ул?

— Үлде...

— Кайчан?

— Узган елда. Афәт елында...

— Бу өйдә тагын Гөлниса атлы апа кеше булырга тиеш иде...

Сулы чиләкләре астында иелеп төшкән бала җавапны озак көттермәде.

— Ул да юк...

Иргалинең аяк астындагы җир бер яккарак шуышып киткән сыман булды. Миен көйдереп: «И-и, бәгырь! Син дә дөнья куйдыңмыни?...» — дигән хәвефле уйлар өермәсе узып китте.

— Ничек юк? — Иргали үз тавышын үзе танымады.— Ул да үлдемени?

— Юк, үлмәде.

— Кайда соң ул?

— Эштә.

— Кайда эшли?

— Утарда.

— Ә утар кайда?

— Күрше авылда.

Кинәт буыннары тотмас булды Иргалинең, авып китмәс өчен арба үрәчәсенә тотынырга мәҗбүр булды.

— Тагын Гөлүсә исемле бәләкәч кыз да булырга тиеш иде?

— Бар. Ул өйдә...

Ниһаять, Иргали: «Уф-ф!..» дип иркен сулап алды. Әмма бу җиңеллек нибары бер мизгел генә дәвам итте. Шулчак тыны кысылды һәм күзләрен яшь элпәсе томалады.

Солдат бик тиз үз-үзен кулга алды. Иң әүвәл, җәһәт кенә килеп, кыз баланың чиләкләрен алып җиргә куйды.

— Һай-й, сине! Шушындый йомры агач белән җилкәләреңне чиләндерәсең бит. Нәрсә, көянтәгез юкмыни?

— Бар.

— Соң?

— Көянтә белән чиләкләр җиргә тия.

— Исемең ничек?

— Миңсылу.

— Әниең исәнме?

— Әни хаста, йөри алмый.

Чиләкләрне күтәреп өйгә керделәр. Бусага аша атлап керү белән, Иргали аваз салды:

— Имин-аман гына яшәп ятышмы?

— Шөкерана! Исән-аман хәзергә...

Иргали, әллә кайлардан, бик еракатан ишетелгән төсле хәлсез, зәгыйфь тавыш килгән якка күз салды. Сәкенең почмак як буенда, бәләкәй бала сыман гына булып, корама юрган астында яткан сырхауны абайлап алды. Күз чокырлары кара-кучкылланып тирәнәйгән, иреннәре күм-күк. Кара ютәл белән азапланып җаны суырылган хастаны күргәч, кинәт кенә имәнеп китте Иргали. Чыкмаган җаны белән сүнеп бетмәгән аңы гына бар иде сырхау хатынның. Шулчак хуҗабикә Иргалине төсмерләде булса кирәк, эчкә баткан коңгырт-кара күзләре отыры зураеп киткән кебек булды. Сураеп калган йөз-төсенә аптырау галәмәтләре чыкты. Ул да түгел, җәһәт кенә сикереп торып утырырга теләгәндәй омтылыш ясагандай

итте. Әмма көч-егәре нибары башын калкытып, сыңар терсәгенә таяныр өчен генә җитте аның.

— Ай-й, бәгырькәем лә! Иргали... син түгелме соң?!. Әйтче, зинһар, үзеңме бу, әллә изге рухыңмы?

Иргали ятак янына якынайды.

— Мин бу, мин, Миңниса апа.

Авыруның, тау күтәрә алмас кайгы-хәсрәт мөлдерәмә тулы күзләрендә, яшь бөртекләре хасил булды. Суырылып, как сөяккә калган бит-чырае көзән җыергандай тартышып куйды. Сырхау, шулай ярым яткан килеш, ыңгырашып-иңрәп, җаннарны тетрәндерерлек сүзләр тезә башлады.

— Менә... могҗиза юк диген син бу дөньяда! Без бит инде сине, Иргали, күптән җирләгән идек. Андый хәбәр таралганга да шактый вакыт узды бит инде. Я-а, ходай! Нинди рәхмәт җилләр туган туфракларыңа кайтарды үзеңне? Менә бит ризыгың бетмәгән булгач. И-и, дөньялар... Менә бит, ә! Бажаң да гүр иясе инде. Бераз азык-төлек юнәтеп кайтып булмасмы дип, ат җигеп, Чаллы пристане ягына чыгып киткән иде. Юлда үлеп калган, мәрхүм. Кайсыдыр авыл зиратында җирләгәннәр үзен. Кеше шулай, тормыш куа-куа, дөнья куя торгандыр инде. Атын гына да кайтармадылар бит ичмаса... — Авыру тирән борчылган, арыган акрын тавыш белән өстәде.— Минем дә хәзер көткәнем бер генә — гүр. Тик менә кызым кала. Миңсылуым, бердәнберем. Шуның өчен өзгәләнәм...— Сырхау урыны өстенә авып төшеп, сулкылдый ук башлады. Иргали аны юатмак булды.

— Юк өчен борчылмагыз, Миңниса апа. Бар да рәтләнер. Терелерсез менә. Яңадан аякка басарсыз.

Сырхау сыңар кулын гына селтәде.

— Юк инде...— Әмма кабат Иргалигә таба борылды да сорау бирәсе итте: — Гөлниса... Гөлниса беләме соң әле?

— Юк... Юктыр,— дип җавап кайтарды Иргали.— Кичә генә кайтып төштем.

— И-и, куанасылары, дөньялардан китәселәре бар икән әле...

Иргалинең бүтән чыдар чамалары калмады, тәкате бетеп, моңарчы күрергә язмаган газиз баласы турында сорады.

— Әле яңарак кына шушында чуала иде,— диде өй хуҗасы.— Ятсынып качмаган булса...

Миңсылу шушы мизгелне генә көтеп торган ахрысы. «Менә ул!» — дип, почмак яктан дүрт-биш яшьләр тирәсендәге кыз баланы көчләп, кулыннан сөйрәп диярлек түр якка алып чыкты.

Әти кеше, үзенә таба төбәлгән, күкбаш чәчәгедәй елтыр зәңгәр күзләрне күрде дә ах-х итте.

— Кызым минем! Балакаемдыр ла! Кил янyма,— дип үзеннән ятсынган балага таба үрелде.

— Әй-йе-ем...— диде нәни кызчык киреләнеп. Ул да булмады, Миңсылу апасы кулыннан ычкынып, яңадан җәһәт кенә почмак якка, аралыкка кереп качты.

Иргали Миңсылуга арба башындагы төенчекне алып керергә кушты. Өлгер-житез кыз баланың бер аягы анда, икенчесе монда. Тастымалга төрелгән төенчеккә дүрт-биш кабартма, ике пешкән йомырка, бер кисәк ит тыгылган иде.

Ул арада авыру да үзенең катгый сүзен әйтте.

— Гөлүсә! Гөлүсә кызым, курыкма, синең әтиең ул. Бире чык...

Миңниса апасының сүзе үзенекен итте, кызчык, кыюлыгын җыеп, ике бүлмә аралыгына килеп басты.

Иргали иң әүвәл, кабартмаларның берсен алып нәни кызчыгы Гөлүсәгә тоттырды. Шул форсаттан файдаланып, нарасыен кулына алды. Бала арык һәм каурый кебек җиңел иде. Аның сәләмә киемен, тузгыган башын, мич ягында мәш килгәнгәдер инде, корымга буялган бит-йөзен,

кутырлый башлаган ияк тирәләрен күрү Иргалине әллә нишләтеп җибәрде. «Газиз балакаем ла!..» — дип, кабат йөрәгә әрнеп, сызып куйды. Керфек төпләре дымлануын тойды.

Иргали, баланы сәке йөзлегенә утыртты да Миңсылуга да бер кабартма бирде. Ике кабартма, бер йомырка һәм салкын итне алып: «Капкалап алыгыз әле, хәл кереп китмәсме...» дип, авыру алдына китереп куйды. Әмма Миңниса апасы ашаудан баш тартты. Иргалинең түземсезләнеп, кыжрап торуын абайлапмы, кичекмәстән, хәзер үк Гөлниса янына барып килергә кушты.— Куанычлары кочакларына сыймас инде бәгырькәемнең. Иллә мәгәр сагына да иде инде. Үзеңне телләреннән төшерми иде. Урамнарга чыгар иде дә, пристен юлларына, син кайтасы якларга, мөлдерәмәләр итеп карап торыр иде, җаныем. Искәрмәстән иңенә ишелеп төшкән бу бәхеттән аңына зыян-зарәт килмәсә генә ярар иде.— Сырхау Гөлнисаның кайда, нинди эш башкаруы турында әйтте.— Бер сынык икмәк бәрабәренә бер караңгыдан икенче караңгыга чаклы эштә. Мине карап, мине саклап ята алмый бит инде. Авыру бактың ни дә, авырып яттың ни, барыбер. Менә шулай җан асрап ятыш... Кызым, Миңсылу, бар, җизнәңне Гөлниса апаң янына озатып куй. Бар, кызым...

Биш-алты чакрым араны җил уйнатып чаптырып кына уздылар. Иргалинең күңеле канатлануга, берсеннән-берсе татлы уйлар туып, куанычы ташуга һич тә чик-чама юк иде. Хикмәтле хода, юлда барганда ук бөтен булган кайгы-хәсрәтләре коелып беткән сыман булды. Куанычы эченә сыймаган Иргали, янәшәсендә утырган Миңсылуны кочагына алып: үскәнем лә! дип, дөпел-дөпел китереп, аркасыннан сөеп алды.

Ниһаять, аларга кирәк утар урнашкан авыл янындагы калкулык өстенә килеп чыктылар. Иргали бер генә мизгелгә атын туктатты. Аста ифрат та зур, озынча итеп салынган бөркәүле лапас. Бөркәү астында, рәтрәт итеп тезеп куелган талкылар янында бер көтү хатын-кызлар. Алар очып китәрдәй булып җилпенеп, берсен-берсе уздырырга теләгәндәй, киндер талкыйлар. Лапасның икенче башында тау-тау киндер сүсе өелгән. Анда да кешеләр мәш киләләр: сүс бәйләмнәрен үлчәп, олы-олы тюклар ясыйлар. Шунда ук җигүле атлар тезелешеп тора. Арада сүс төялгән олаулар да бар.

Иргали яңадан очынып-очынып киндер талкыган хатын-кызлар ягына күз салды. Аның тынгысыз җанлы эшсөяр хатыны Гөлнисасы да шулар арасындадыр...

Калкулык өстеннән шактый ук җилле юыртып төшкән ак бәкәлен Иргали җигүле атлар торган йортка таба борды. Миңсылу исә, атның туктаганын да көтеп тормады, арбадан очып төшеп: «Гөлниса а-апа-а!.. Җизни ка-айт-ты!..» дип кычкыра-кычкыра, хатын-кызлар эшләгән бөркәү астына ташланды. Аның ачыргаланып кычкыруын өзлексез шакышокы килеп торган талкы авазлары да баса алмады.

Иргали, атын туктатып, өй буендагы киртәгә бәйләргә дә өлгерә алмый калды, лапас астыннан хатыны Гөлниса атылып чыкты. Менә ул шашкан кеше сыман, кулларын болгап, Иргалигә таба ыргылды. Әмма килеп җитәргә биш-алты адым каларак кинәт сөрлегеп китте һәм, һушын җуйган кебек, ава башлады. Ярый әле Иргали үзе йөгереп килеп хатынын тотып калырга, кочагына алырга өлгерде.

Иргали күкрәгенә капланган Гөлнисаның үксеп-үксеп елаудан бары тик җилкәләре генә калтырый иде.

— Я-а ходаем ла, синме соң бу, Иргали? Саташам гына түгелме?..

Иргали, киемнәреннән киндер, сүс исләре аңкып торган хатынының арык гәүдәсен күкрәгенә ныграк кысты. Гөлнисаның йөз-төсе дә шактый сулганлыгын абайлап алды Иргали: ачлы-туклы тору галәмәтедер инде.

— Булды, бәгырь. Тынычлан. Мин бу. Менә, кайттым...

Лапас астында кинәт тынлык урнашты. Эшләреннән туктап бер күчкәрәк җыелган хатын-кызлар, ир белән хатынның очрашуын тамаша кылып торалар иде. Арада күзләрен сөртештергәннәре дә бар.

— И-и, Иргали... Әнигә генә бу көннәрне күрергә язмаган икән. Саклап калып булмады шул, сиңа әйтәм,— диде Гөлниса яман сызланып.— Кызыбыз белән үземне дә мәет булгач терелттеләр...

— Нихәл итәсең, бәгырь, ил белән килде бит.— Иргали елышып торган хатынының киеменә ·кунган киндер чүбе, сүс җепселләрен каккалап-чистарткандай итте.— Инде бу кадәресенә шөкрана кылырга кирәк. Болай булгач, бар да һәйбәт булыр. Еллар отыры уңайга таба бара...

Шулчак, авызларын ачып, хәйран калып торган хатын-кызларга әллә нәрсә булды, кинәт ыгы-зыгы купты, дөнья кубарып талкылар шакылдый башлады, тирә-юнь шау-шу белән тулып хәрәкәткә килде.

Гөлниса да читтәрәк торган ялгыз йорт ягына күз салып, өне алынып: «Хуҗа — үзе!» — дип, җәһәт кенә читкә тайпылды.

Иргали дә шул якка борылды. Караса, башына елтыр козыреклы карасу картуз, өстенә дә шундый ук кара кием кигән, элеватор кадәрле зур гәүдәле бер кешене күреп алды. Өстендәге киемен җилбәгәй җибәргән, симез йөзен сакал-мыек баскан әлеге кеше алар янына якынлаша башлады. Тавышы да гөбедән чыккандай иде аның.

— Здорово, служивый!

— Саумысыз, хозяин!..

Итләч йөз киң итеп елмайды. Шешенке күз кабаклары астыннан Иргалигә сөзеп карап торды да әйтә салды.

— Хәзер бит, солдат, хозяиннар юк. Хуҗалар, совет белән уртак тел таба алмау сәбәпле, үтүт — каядыр китеп олактылар. Ә мин монда ышанычлы гына, ягъни, эшне оештыручы. Исемем Иван Кузьмич.— Шунда ук Гөлниса ягына ым кагып өстәп куйды.— Ә менә сезнең халык Иван дәдәй дип кенә йөртә.

Иван Кузьмич аларның бер-берсенә кем булулары белән кызыксынды. Җавапны Гөлниса бирде:

— Никахлы ирем, Иван дәдәй.

Иван Кузьмич чын-чыннан гаҗәпкә калды, тавышына кадәр үзгәрде аның.

— Как так?!. Иреңне һәлак булган дип әйткәннәр иде ич. Менә сиңа мә! Менә ичмаса шатлык!..— Ул ир белән хатынны бөтенләй үз иткәндәй, кәнсәсенә чакырды.— Шунда иркенләп сөйләшербез...

Контора бусагасын атлап керер-кермәс борын, Иван дәдәй сүзгә дә кереште.

— Әйтергә теләгәнем шул, солдат, әйдә, тот та эшкә кереш. Телисең икән, әнә, төяүче бул, хатының янындарак тулганырга телисең икән, рәхим итеп, тюк бәйлә. Син дә, нәкъ хатының кебек, эш кешесенә охшагансың. Ә хатының берүзе ике кеше кадәр эшли дисәм, һич тә ялган катнашмас. Шуның өстенә бик акыллы, карусыз, итәгатьле. Алак-шалакны мин бер күз төшерүдән таныйм. Әйдә, солдат, алын. Эшче җитми. Бик ашыктыралар, эшне кызурак тотарга кушалар. Калада әнә пролетариат өчен бәһа белмәс авазлар — завод-фабрика гудоклары яңгырый башлады... Димәк, яңа власть яши, тернәкләнә. Тик менә чимал гына җитенкерәми. Казанның эшче халкы безнең җитен-сүсебезне дүрт күз белән көтә.

Яшерен-батырын түгел, Иван дәдәйнең бу сүзләре Иргалинең йөрәгенә сары май булып ятты. Инде кая барып бәрелергә, кемгә барып егылырга дигән кебек уйлар туган туфрагына аяк баскан сәгатьтән бирле аның җанын кыйный, рухын изә иде.

Кара савыты куелган, берничә контор кенәгәсе, кәгазь өемнәре яткан түрдәге өстәле артына барып утырган Иван Кузьмич, бик гадәти нәрсә турында гәп саткандай, сөйләнүен белде.

— Ә бит адәм баласына, тәңренең бирмеш һәр көнендә теш арасына кыстырырга икмәк, җылыда йоклыйм дисә — утын, дөньяга чыгыйм дисә — кием-салым кирәк. Баш очында түбә булу кирәклеге турында әйтеп торасы да юк.

Иргали, авызына су капкандай дәшми торуын яхшысынмады. Иван дәдәйнең сүзләре белән шиксез килешүен белдерде.

— Знамо шулай.

Тегесе дәвам итте.

— Шулай ул, солдат. Кара тир түкмичә, мең төрле мәшәкать күрмичә генә тормыш арбасы үзеннән-үзе тәгәрәми...

Шунда Иргали, Иван Кузьмичның сүзен урта бер җирдә бүлеп, үзенең яраланган булуын, сул кулының бөтенләй диярлек хәрәкәтләнмәвен әйтте.

Бу сүзләрне ишеткәч, Гөлнисаның йөзе агарып, күзләре зураеп киткән сыман булды. Ул: «Ай-й, ходаем!» — дип, иренең терсәгенә үк килеп тотынды. Аның каравы, Иван дәдәй, Иргалинең бу сүзләрен колагына да элмәде: «Дилбегә тотарга бер кулың исән булса, бик җиткән, моннан төяп җибәрербез, пристендә бушатырлар»,— диде.

— Ә түләүгә килгәндә — риза булырсың дип уйлыйм. Яңа кайтып төшкәнлегең дә, кызылармеец икәнлегең дә исәпкә алыныр.

Иргали кинәт кенә ризалык та бирмәде, капылт кына эштән дә баш тартмады. «Кайтып, туган-тумача, таныш-белеш белән киңәшик, әгәренки монда эшләргә ниятләнәбез икән, ике-өч көннән килеп тә җитәрбез»,— диде. Атны да бары тик көнен барып, көнен кайтырга дип алып торганлыгы турында да өстәде.

Шуның белән сүз түгәрәкләнде. Иван дәдәй, кемгәдер кычкырып, ун кадак он үлчәп, бер бөтен икмәк кертергә кушты. Бу берүзе ике кеше кадәр эшләүче Гөлниса белән араны өзүе иде аның.

Иргалиләр шул ук кичне җыенып, арбадагы урын-җир, чүпрәк-чапрак янына баздан чыгарылган ике капчык бәрәңгене дә салып, төнгә каршы юлга чыктылар.

... Беренче тапкыр мена шунда, үзләренә өйдәш булып кайтып төшкән төннең иртәгесен күрде Гази күкбаш чәчәге төсле зәп-зәңгәр күзле бәләкәч кыз Гөлүсәне.

## Икенче көн

### 1

Бүгенге максатыбыз — промыселда булу. Аның да, нефтьчеләр теленә «Бондюг ятмасы» дип кергән, заманында бөтен Рәсәй кавалериясен печән белән тәэмин итеп торган атаклы болыннардагы өлешенә юл тотуыбыз. Комиссия әгъзаларын Түбән Кама ГЭСын корып бетергәч «Чулман-диңгез» сусаклагычы астында калачак йөзләрчә скважинаның язмышы кызыксындыра иде.

Без юлда. Көн аязса да, җил басылмады, аяк астының да рәте-чираты юк: кая карама — уйдык та чокыр, дулкынланып яткан болганчык күлдәвек.

Безнең вездеход әле бер якка, әле икенче якка ава-түнә, һаман алга таба үрмәли. Вакыты белән чабулап шадраланып торган болганчык су эченә шуып төшә. Аннары яңадан җан-фәрман моторын үкертеп, юл өстенә күтәрелә.

Сәгатемә күз салам. Өйлә якынлашып килә, ә безнең әле һаман да тиешле урыныбызга барып җитә алганыбыз юк. Бик соң чыгылды шул юлга. Вак-төяк әңгәмә, сөйләшү белән вакытның үткәне сизелми дә кала.

Кичә больницадан да ярты төн узгач кына кайтып егылдым. Ә Галина Николаевна бөтенләй кайтмады, операциядән соң аерым палатага салынган иптәш Кремнев янында утырып калды. Операция ясалганчы, дәвалаучыларның үзара катлаулы мөнәсәбәтләре ачыкланганчы, шак-

тый гына борчылулар, киеренке минутлар кичерергә туры килде. Яшьлек дустым Газиның сыкранып: «Житте!.. Үтенәм сездән... Кирәкми!» — дигән сүзләре байтак вакыт колак төбемдә чыңлап торды.

Вакыйганың шундый четерекле борылыш аласын көтмәгән баш врач та шактый ук ямьсез, читен хәлдә калды. Иң кирәкле чакта район үзәге шифаханәсе хирургсыз калсын әле, уен эшмени!

Ап-ак халат, шундый ук калфак киеп алган, әмма үзенең бөтен сылулыгын күрсәтергә теләгәндәй, авыз-борынын томалаган марля битлеген ияк астына шудырып төшергән Дисә Зиннәтовна, үзен аеруча кырыс тотты, баш врачның ялынып та, янап та операциягә алынырга әмер биргенә дә карамастан: «Ассистенттан, тәҗрибәле анестезиологтан башка операционныйга ике аягымның берсен атламаячакмын», — дип, ультиматум белдерде. Үзе үк чәчрәп, кара пошаманга төшкән Хәмзин өстенә ябырылды.

— Нәрсә бу? Мин әле һаман да бернәрсә төшенә алмыйм. Уяулык, саклык күрсәттегезме? Операционныйда хәтәр хәлдә авыру ята. Ишетәсезме? Кичекмәстән операция ясауны үтенеп кенә калмыйм, таләп итәм. Гази Хаҗиевичның диагнозы дөрес: бу — авыруның соңгы пристубы. Бераздан операциянең дә ярдәм итмәве бар...

Киребеткән сылу тәки үзенекенә иреште: янымда Гази Хаҗиевич басып тормаса, операциягә алынмаячакмын, дип баш врачны буйсынырга мәҗбүр итте.

Яшерен-батырын түгел, моны мин дә бөтен җаным-тәнем белән тели идем. Бу бит яшьтиемнең һич югында минем алда күпмедер дәрәҗәдә аклануы, «реабилитацияләнүе» иде...

## 2

Яшүсмер чактагы хатирәләр күңелгә бик тирән уелып калучан булалар икән...

Зәкиевләрнең уртанчы энеләре Таҗи белән мин моннан бик күп еллар элек очрашкан идем. Ае-елы хәтердә калмаган, һәрхәлдә сугыштан соңгы авыр заманда. Азык-төлек карточкаларының бетерелгән чоры. Кая карама — очы-кырые күренмәгән чират, талаш-ызгыш...

Мин дә чиратта торам. Нәрсә алырга ниятләгәнмендер, хәзер инде әйтүе кыен, һәрхәлдә, азык-төлек өчен булгандыр. Карыйм: бу да тора. Миннән берничә кешегә генә алда. Өс-башы бөтен: әйбәт бүректән, соры каракүл якалы пальтодан. Аягында — каймалы ак фетр. Кыскасы, егет шәһәрчә киенгән, кыяфәтендә, килеш-килбәтендә авылның әсәре дә калмаган.

Шулай да муенындагы кәҗә мамыгыннан бәйләнгән шарфы, шундый ук күз явын алырлык ап-ак перчаткалары, ничектер, күзгә ташланып, егетнең саладан икәнлеген сиздереп тора.

Аның балалык дустым Таҗи икәнлегенә шигем калмады минем. Ләкин капылт кына барып дәшергә кыймадым. Житмәсә ул да култык астына кыстырган китап-дәфтәрләренең берсен алып, күз йөртә, караштырып маташа иде.

Чиратымнан чыктым да янына килдем.

— Таҗи түгелме соң?..

Теге ялт минем якка:

— Әй-йе... Бу мин...

— Алайса, әйдә, күрешик. — Исәнләшү өчен кулымны суздым. — Танымыйсыңмы әллә?..

Авылдашым чак кына уңайсызланды.

— Фәйзи дисәм инде-е?.. — дип сузды ялгышудан курыккан кеше сыман.

— Нәкъ үзе! — дидем мин.

— Чыннан да, син ич!

Таҗи мине кочаклап ук алды.

Чиратта торучыларның күзләре бездә. Моны икебез дә сизендек. Аннары Тажи:

— Әйдә, чукынып китсен! Күрмәгән консервабыз түгелдер ич,— диде дә мине җилтерәтеп култыклап алды. Без, кибет тулы халыкны ерып, ишеккә таба юнәлдек.

Урамга чыктык. Куе булып сыкы төшкән. Төтенгә охшаган үзе, исе белән җылысы гына юк. Зәһәр салкын тынга каба. Куе томан аша саран гына яктыртылган урамнар буйлап кабаланып, йөз-битләрен каплаштырып, кешеләр йөгерешеп үтә. Аяк астындагы кар әллә кайларга ишетелерлек булып шыгырдап кала.

Тажи да мамык шарфын кабартып якасын күтәрде һәм җил бәргән якка янын куя төшеп, миңа таба борылды.

— Әйдә, Фәйзи, безгә киттек. Әллә ни ерак түгел. Болак буенда гына.

Болак аша салынган агач күперне үтеп, бер тар тыкрыкка борылдык та әллә ни зур булмаган ишегалдына килеп кердек. Як-якта икешәр катлы йортлар. Кайбер тәрәзәләрдән тоныкк кына яктылык сирпелеп тора. Тирә-якта куе сыкы катнаш кар бураны тузгый...

Тажи тактадан гына ясалган җиңел ишек янына килеп, каршыбызда хасил булган караңгылыкка күрсәтеп:

— Әйдә, рәхим ит!..— диде. Шунда ук ничегрәк кирәклеген өйрәтә башлады: — Туп-туры өскә таба күтәрел. Саграк бул, таеп китмә.

Өскә күтәрелгәч, Тажи янә туктады. Ут кабызды. Без инде кара дерматин белән тышланган зур гына ишек каршында тора идек.

Әллә ни зур булмаган ике бүлмәле гади бер квартира иде бу. Беренче бүлмә кечерәк, түрге яктан бары тик пәрдә белән генә бүленеп куелган. Без алдагы бүлмәдә чишендек тә түргә уздык.

Тажи һаман сөйләнде:

— Әйдә, тартынма. Фатир хуҗасы икенче сменада. Төнге уникесез кайтмый.— Стенага эленгән портретларга карап торуымны күргәч, әйтеп куйды:— Хуҗа фронтта һәлак булган. Хатыны хәзер ялгыз яши. Бердәнбер кызы бар, ул да кияүдә...

— Менә анысы шәп булмаган,— дидем мин шаярып һәм шунда ук, уенын-чынын бергә кушып, сорап куйдым: — Тажи, үзең өйләнмәдеңме соң әле?

— Һәй-й, парень!..— диде ул чак кына оялгандай итеп.— Өйләнгәнгә бит былтыр инде. Әнә хат артыннан хат яудырып кына тора. Соңгысында, бәлки әле килеп тә чыгармын дигән.

— Бераз иртәләгәнсең,— дидем мин аны тагын бер кат баштанаяк күздән кичергәч.

Тажи төскә-биткә бик яшь күренә. Хәер, ул чыннан да миннән яшьрәк иде.

Тажи тыз-быз килеп табын әзерли башлады. Үзе һаман сөйләнә. Сүз бер тирәдәрәк чуала, аның өйләнүе турында. Өйләнүенә чак кына үкенә дә булса кирәк. Шулайрак сизелә.

— Тормыш кушты инде,— диде ул акланырга теләгән сыман итеп.— Әти вакыйгасыннан соң әни тәки савыга, кеше була алмады. Озак-озак урын өстендә дә яткалады. Йорт-җирне карардай кеше юк. Кыз туганыбыз да булмаган бит шунда. Тоттым да киленле иттем әнине...

Шулвакыт кылт итеп әниләренең исеме дә хәтеремә төште. Аларны онытмавымны кабат исбат итәргә җай чыгудан файдаланып, аның сүзен бүлеп, сорап куйдым:

— Зәйтүнә апаның хәле ничек соң? Исәндер бит?

— Юк. Узган елның көзендә җирләдек үзен. Йөрәк белән китте. Йөрәге начарланган, бик беткән иде шул. Аның өстенә Гази абый хәбәре өстәлде тагын. Ишеткәнсездер дә инде?

— Әйе, ишеткән идем.— Җан дустым турында бик беләсем килә иде минем. Һәм шулчак аның кайдалыгы белән кызыксынып куйдым.

— Еракта. Кайдадыр Белоруссия ягында...— диде Таҗи, бу турыда сүзне дәвам итәргә теләмәгән төсле итеп.— Урман кисү эшендә диме шунда.

Мин дә моны сизендем. Сүзне иң кече энеләренә күчердем:

— Ә Һади нишләп ята?

— Һади авылда. Механизатор ул хәзер. Тугыз класс тәмамлаганнан соң механизаторлар курсында укып кайтты. Быел көзен тракторда эшләде инде.— Таҗи эшен бетерде дә җилтерәтеп мине табын янына утырырга кыстый башлады.— Син, әйдә әле, утыр. Менә монда, түрдәнрәк уз.

Саргылт төстәге чүпрәк абажур астында торган өстәл ындыр табагыдай зур иде. Тик өсте генә буш. Дүрт кырлы юка гына бер банка консерва, берәр сынык икмәк һәм бер шешә сөт. Аның караВы, күңелләребез киң.

Таҗи яртышар стакан сөт салды. Ә үзе көр тавыш белән сөйләнүен белде.

— Э-х, шушының янына тагын тозга ярып пешергән кайнар бәрәңге дә булса!..

— Әйтерең бармы!

— Әйдә, Фәйзи!..— Таҗи стаканын кулына алып, миңа таба суздЫ.— Очрашуыбыз хөрмәтенә. Киләчәктә дә гел бергә якын дуслар булып яшәвебез хакына!..

— Шулай булсын, Таҗи. Киләчәк хакына!

Стаканнарны, зыңгылдатып, бер-берсенә бәреп чәкештердек. Әмма эчәргә өлгерә алмыйчарак калдык. Шулчак аста кемнеңдер ишекне дөбердәткәне ишетелде.

Икебез дә бермәлгә сагайдык.

— Фатир хуҗаңдыр...,— дидем мин.

Таҗи стаканын өстәлгә кире куеп, җәһәт кенә урыныннан купты.

— Юк, фатир хуҗасы түгел. Ул төн урталары җиткәч кенә кайта.

— Бәлки... берәр чәчбиеңдер?— дигән булдым мин, кабат шаяртырга теләгәндәй итеп.

— Юк!— диде Таҗи, ишеккә таба юнәлеп.— Андый эшкә бит вакыт кирәк...

Таҗи чөйдәге бүреген алып башына чәпәде дә чыгып китте. Күп тә үтмәде аның җәһәт кенә ишекне ачып, гаять шатлыклы хәбәр тапшыргандай:

— Тиз бул, Фәйзи! Монда синең дә ярдәмең кирәк булачак,— дип кычкырды.

Чыгу белән эшнең нәрсәдә икәнлеген шунда ук абайлап алдым. Таҗиның хатыны килеп төшкән икән. Баштанаяк карга манчылган. Керфек-кашларын, башына бәйләгән мамык шәленең йөзне каплап торган өлешләрен ап-ак бәс баскан. Шәле өстеннән батырып колакчынлы бүрек киеп җибәргән. Пальто өстеннән, кайчандыр зәңгәр булып та, хәзер инде төсен югалткан плащ киеп алган. Билен нинди дер каеш белән буган. Аягында олтан салынган киез итекләр. Шакы-шокы килеп торалар. Хәрәкәтләнгәндә, ямаулы сырган чалбар да чагылып киткәли. Кыскасы, әйтеп торасы да юк, кыяфәт хәйран иде. Ирексездән, өйләнү турында сүз чыккач, Таҗиның бая гына ничектер үкенгән сыман итеп: «Тормыш шулай кушты...» дигән сүзләренең асылына, мәгънәсенә төшенгәндәй булдым.

— Исәнмесез!..— дидем мин мөмкин кадәр илтифатлы булырга тырышып.— Исән-сау гына килеп җиттегезме?

Чана янында мәш килгән юан гәүдәле хатын башын калкытты да минем якка каерылып, сәламемне алды. Әйбәт кенә килеп җитүе турында әйтте. Тик көннең генә кирәгеннән артык салкын булуыннан зарланды.

Тышка жиңелчә чыккан Таҗи безнең сүзне бүлде.

— Ярар, ярар, җәмәгать... Әйдәгез, тизрәк! Югыйсә өтәли дә башлады монда суык. Соңыннан танышырсыз. Ә хәзер, әйдә, Фәйзи,— тот чананың мөгезле башыннан.

Өчәүләшеп көч-хәл белән авыр чананы югары катка менгездек. Хатын бик белдекле кыяфәт белән әмерләр бирә башлады.

— Таҗи,— диде ул, ишек тоткасына кулын салгач.— Бәрәңгене өйгә кертерсез. Ә теге капчыктагы ит-майларны чоланга эл. Чана башындагы ак төенчекне өйгә керт. Саграк кылан, анда ватыла торган нәрсә дә бар. Ә мин бу кием-салымнардан бераз арыныйм әле. Югыйсә, селкенер хәлләр калмады...

Хатын кереп китү белән, авыр йөк астында шыгырдап торган чанадан әйберләрне чишеп ала башладык.

— Ай-яй!— дидем мин Таҗиның кәләшен мактагандай итеп.— Ат йөге кадәр бар ич бу, билләһи...

— Күп салган шул,— диде Таҗи, минем белән килешеп.

— Авылдан ук җәяүме?

— Белмим,— диде Таҗи һәм шунда ук, «юкка исең китмәсен», дигән кыяфәт белән өстәп куйды.— Аптырама! Җен кебек таза ул.

Ул арада бүрек-кожаннарын салып өлгергән хатын үзе дә килеп чыкты. «Булдымы?»— дип сорады да, без чишеп куйган төенчекләрне җилтерәтеп күтәреп алып, кайсын чоланга, кайсын өйгә ташый башлады. Безнең өлешкә сырган мамык юрганга төрелгән олы бер капчык бәрәңге генә калды.

Өйгә кердек. Таҗиның хатыны өс-башын рәткә китерергә кече якта калды, без исә, гаять зур эш кырган кыяфәт белән ах-вах килеп, янадан табын янына килеп утырыштык.

Таҗи: «Хәзер барысы да җайланыр»,— дигән рәвештә кулларын угалап алды һәм түземлеген җуеп, кече яктагы хатынына дәште.

— Син тиз буласыңмы анда?

— Хәзер, хәзер! Булдым...— диде тегесе, үзенең шулай тоткарлавына уңайсызланган сыман тавыш белән.

Чыннан да, шул чак ике бүлмәне бүлеп торган чүпрәк селкенеп китте һәм түр якка Таҗиның хатыны килеп керде. Кинәт кояш чыгып, бүлмәне яктыртып алгандай булды. Мин исә авызымны ачтым да хәйран калып каттым да утырдым. Бит алмалары, озак вакыт салкында йөргәнгә, алсуланып янып тора. Түгәрәк йөзендә елмаюга охшашлы үзенә бер төрле мөлаемлык балкый. Менә шундый хатын-кызлар турында инде: кызыллыгы җиргә төшеп тора, диләр. Чәче тигез итеп урталай бүленеп һәйбәтләп үреп куелган, шактый калын һәм озын толымының бер сыңарын күкрәк турысына чыгарып салган. Сырган чалбарын салып аткан. Өстендә исә гап-гади күлмәк. Буй-сыны гаять килешле. Җыйнак, нык балтырлы аякларына ап-ак йон оекбашлар киеп алган. Күкрәкләре мул, әмма килбәтсез түгел. Аның каравы бил тирәләре гаять хәрәкәтчел. Кыскасы, авылыбызның иң сылу, атаклы гүзәле булырга тиеш иде ул. Пар килсәләр дә килерләр икән, дип уйлап куйдым мин. Чөнки Таҗи да ир-ат арасында бик сирәк очрый торган матурлыкка ия зат иде.

— Менә хәзер күрешеп танышсагыз да ярый,— диде Таҗи хатынының матурлыгы мине әсир иткәнлекне кай җире беләндер тоеп.

Бу юлы без куллар бирешеп, исемнәребезне әйтешеп, озаклап күрештек. Исеме дә җисеменә бик муафыйк: Җәүһәрия атлы икән.

Таҗи исә хатынына иң әһәмиятле мәгълүматларны әйтергә өлгерә алмый калудан курыккандай, тезепме-тезә:

— Син әле белми торгансыңдыр: Фәйзи безнең балачак дустыбыз. Заманында күршеләр генә идек... Теге Миңкамал апалар торган нигез кайчандыр Фәйзиләрнеке иде. Ә хәзер ул, беләсеңме, кем? Журналист! Ягъни мәсәлән, язучы...

Шул арада чынлап торып тулы хуҗа кыяфәтенә кереп алган Җәүһәрия табынны кабат күздән кичерде дә көмеш дага кебек тип-тигез ап-ак тешләрен күрсәтеп елмайды. Һәм шунда ук: «Шушы да булдымы табын, шушы да булдымы кунак сые?»— дигәндәй, җил-җил хәрәкәтләнеп, кече яктан ашъяулыкка төргән зур гына бер төенчек алып чыкты. Өстәл янындагы буш урындыкларның берсенә куеп, төенчеген актара башлады. Иң элек тире бияләй эченә бастырып утырткан ярты литрлы ак аракы чыгарып өстәлгә куйды. Аннары инде каклаган каз, камыт бөяте кадәрле казылык, атланмай һәм берничә төрле таба ашлары өстәл өстенә өелде.

Хәрәкәтләре ипле, төгәл иде Җәүһәриянең. Менә ул ярым бушап калган төенчеген бер читкә алып куйды да:

— Чак кына сабыр итегез, хәзер мин сезгә берәр таба казылык булса да кыздырып бирим. Эчегезгә җылы керер,—дип, җил-җил килеп, янә кече якка чыгып китте.

Күп тә үтмәде, теге як бүлмәдән табада май чыжылдавы ишетелә, ашказанын котыртып, тәмле исләр дә килә башлады.

Җәүһәрия тагын түргә узды, сөйләнгәләп, өстәл тирәсендә мәш килде, нәрсәләрдер турады, «чак кына җылынсын», дип, өстәл өстенә чыгарып кую белән томанланып-парланып киткән яртыны да кече якка алып чыгып китте.

Шунысы гаҗәп, Җәүһәриягә карап соклануым торган саен бары тик арта гына барды. Төсе-кыяфәте, йөреш-торышы, сөйләшү рәвешләре — барысы да, барысы да килешле иде. Ходай тәгалә бер бирсә бирә ул дип, хәтта Таҗиның бәхетенә кызыгып та куйдым. Әнә ул табын башында авызын җыя алмыйча утыра. Башы түшәмгә тигән, кулларын угалап, сөйләнеп алгандай итте.

— Болай булгач, Фәйзи туган, бу инде пир на весь мир була...— Табындагы нигъмәт-ризыкларны минем алгарак этебрәк куйды.— Менә бит, ә!..

Бераздан табын бөтенләй түгәрәкләнде. Урта бер җиргә чажылдап торган зур гына таба куелды.

— Ягез, җәмәгать!— диде Җәүһәрия һаман да кояш кебек балкып.— Әйдәгез, житешегез. Кем әйтмешли, хәзинәдә бары.

Табын яны җанланып, бер мәлгә гөрләп торды. Беренче тостларны очрашу, дуслашу, хәтта туганлашу хөрмәтенә күтәрдек. Бераз капкалап, карынны чак кына ялгап алгач, дөнья хәлләре турында да сүз куертыр халәткә килдек.

Таҗи үзенең туган энесе белән кызыксынды.

— Әйбәт кенә эшләп ята,— диде хатыны.— Сәлам әйтергә кушты.

— Һаман шундамы?

— Шунда. Хәзергә әле район үзәгендә эшләп йөриләр. Тракторларына ремонт ясыйлар. Кайтса да, шул мунча кереп, өс-башын алыштырырга гына кайта.

— Ә укуы? Кичке мәктәпкә язылган иде түгелме соң?

— Укуын да ташларга уйламый.

— Һади укый дамыни әле?— Бу сорауны мин бирдем.

— Бик уңган ул! Типсә тимер, басса бакыр өзәрдәй егет ул хәзер.— Җәүһәрия, кинәт тигез тешләрен күрсәтеп, кабат мөлаем генә елмаеп алды да өстәп куйды:— Чын әгәр! Хәтта, җан көйдергече дә бар...

Сүз ипләп-җайлап кына яңадан Таҗига күчте. Сылу хатын иренең күңелен күрергә теләгән сыман итеп, сүзне Таҗиның «сакаллы сабый» булгач сабак укып, белем туплап йөрүенә күчерде. Әңгәмәнең шулай җайга салынуын күреп, мин дә үз чиратымда: «Ә ник үзегез укымыйсыз?»— дип, Җәүһәриягә сорау бирдем.

Аның өчен Таҗи җавап кайтарды:

— Укый иде. Кичен йөреп унынчы классны тәмамлау белән, укырга җибәргәннәр иде үзен. Райкомол аша... А как же! Җәүһәрия бөтен

Чаллы районында берәү ул. Иң алдынгы савымчы дип күтәреп кенә йөрмиләр үзен! Тик менә укуын гына дәвам итә алмады. Институтны беренче курсыннан ук ташларга туры килде.— Һәм шунда ук төзәтенеп өстәде.— Дөресрәге, укуын ташларга мәҗбүр булды...

— Нәрсә, әллә уку бик авыр бирелә идеме?— дидем мин кабат сорау биреп.

Бу юлы Җәүһәрия үзе җавап кайтарды.

— Хикмәт укуның авырлыгында түгел иде.— Аннары әйтергәме-әйтмәскәме дигәндәй бер генә мизгелгә икеләнеп торды да, тезеп китте.— Тәҗи әнисенең, ягъни кайнанамның, хәле кинәт начарланды. Торып йөри алмас булды. Җитмәсә тагын, Тәҗины да укырга өнди башладылар. Киңәш-табыш иттек тә шулайрак хәл кылдык. Шуның өстенә әле тагын, яңа гына өйләнешкән чагыбыз иде...— Бу сүзләрне әйткәндә, Җәүһәриянең күзләре көлә, йөзеннән сөенеч, куаныч нурлары балкый, гомумән, бу сылу хатынның йөзе ниндидер нур, илһам белән өртелгән иде.

Тәҗи дә көлмичә булдыра алмады.

— Ул ягы да бар иде, әлбәттә,— диде ул.

Күңелемнең кайсыдыр бер чите белән, Җәүһәриянең институт хәтле институтны ташлау вакыйгасында чак кына гаделсезлеккә охшашлы нәрсә барлыгын сизенгәндәй булдым. Һәм кабат сорау бирдем.

— Укуыгызны ташлаганга үкенмисезме соң? Күпмедер вакыт үткәч үкендерә ул...

Җәүһәрия капылт кына җавап кайтармады. Күркәм йөзеннән сизелер-сизелмәс кенә күләгә йөгереп үткәндәй булды. Әмма шунда ук эчкерсез күтәренке тавыш белән кырт кисеп әйтте:

— Юк, үкенмим!..— диде ул. Йөзе яңадан нурланып ачылып китте аның.— Юк, һич кенә дә үкенмим. Аның каравы менә Тәҗи укый. Икебез дә укымышлы, икебез дә, мәрхүмә әнкәй әйтмешли, урындагы кеше булсак, тормышны кем алып барыр соң! Син дә мулла, мин дә мулла, атка печән кем салыр, дигән сыман булыр иде ул. Аннары бит, хатын-кызның әле тагын мең төрле башка мәшәкатьләре дә була...— Җәүһәриянең сүзе бетмәгәнлеге, аның тагын нәрсәдер әйтергә җыенуы йөзенә чыккан. Чак кына бүлтәебрәк торсалар да, гаять килешле алсу иреннәре һәм очкынлы күзләре елмаялар иде аның. Бермәлгә сынау карашы белән икебезгә дә күз төшереп алганнан соң, болайрак дип сүзен ялгап китте:— Тагын шул кадәресе дә бар, Тәҗига начальник, ягъни урындагы кеше булу ифрат та килешә. Ул бит инде элек тә, бәләкәй генә булса да, нәчәлник кисәге иде. Соңгы өч елын авыл Советында секретарь булып эшләде. Аның телефоннар, тәти кара савытлары куелган өстәл артында утыруларын күрсәгез, шаклар катар идегез инде менә!..

Җәүһәрия, бу юлы да чак кына арттырыбрак җибәрүен үзе үк сиземләгәндәй булды. Һәм берни дә булмагандай, җәһәт кенә урыныннан кубып: «Ягез әле!.. Җитешегез инде, хәзинәдә бары...» — дип ду китереп безне кыстый башлады. Хәтта кыстап кына да калмады, өлгер-житез куллары белән, табындагы ризыкларны безнең алга шуыштыра башлады.

Бөтен дикъкатем Җәүһәриядә иде минем. Ирексездән аның хатын-кыз өчен бераз эрерәк булып күренгән кулларына игътибар иттем. Хәрәкәтләре төгәл, житез, искитмәле. Куллары кулга йокмый. Сул кулының исемсез бармагында юкарып беткән, өзелеп чыгар хәлгә килгән кашсыз көмеш йөзек. Ә бит тирәнтенрәк уйлап карасаң, бу эшчән, житез-өлгер кулларны җәүһәр ташлары белән бизәсәң дә, аз булыр төсле иде. Чөнки гади куллар түгел иде алар. Шулчак мине ниндидер гаять зур, әйтеп бетергесез соклану хисе яулап алды. Менә шушы куллар бит безнең тормышыбызны алып бара, безне тукландыра, киендерә. Менә шушы куллар, шушы хатыннар бит инде түзә алмаслык авыр сугыш вакытында һәм аннан соңгы елларда тормышның мең мәшәкатен үз иңендә тотып, ярым ташландык, таркау хуҗалыкларны төптән җигелеп

өстерәп барды. Үзләре ачлы-туклы булырлар иде. Эшләгәннәренә бәһасе сукыр бер тиен тормаган хезмәт көненнән башка әйбер бирмәсләр иде. Куллар!.. Менә шундый бер пар кул минем алда... Көннең-көн буе чатнама суыкта булу сәбәпле, алар кызарып, чак кына шешенеп, җилсенеп киткәннәр. Бу куллар үзләре якын күргән кешеләре өчен теләсә нинди эшләр дә башкарырга әзерләр. Киреәксә, алар, күкрәкләре читлегендәге йөрәкләрен дә төбе-тамыры белән йолкып алып, сөйгәненең аягы астына салырга әзерләр. Минем каршымда бер пар кул... Йөз чакрымнан артыграк җирдән, җилкә тамырын чиләндереп, кечерәк ат йөге кадәрле һана тартып килгән куллар. Юк, зарланмыйлар алар. Киресенчә, йөрәк парәсенә, сөйгән кешесенә ярарга тырышалар, аның күңелен күрергә телиләр. И-и, хатын-кызлар! Безнең тиңдәшсезләребез! Никадәр көчкә, ихтыярга ия сез, кайнар йөрәкле, киң күңелле, олы җанлы, бай хисле сез, безнең хатын-кызларыбыз. Рәхмәт, сезгә!..

Шулай утыра торгач, ярты төн якынлашканын сизми дә калганбыз.

— Минем бит әле, дусларым, кайтасы да бар,— дип, киң күңелле, кунакчыл хуҗалар белән саубуллашканда, төнге уникенче ярты җиткән иде инде. Киенгән арада, аларны да парлап кунакка чакырып, адресымны, телефонымны язып бирдем.

Икәүләшеп баскычка кадәр озата чыктылар. Кулларны кысышып, кабат саубуллашып торган арада, фатир хуҗасы да кайтып җитте. Җәүһәрияне абайлап алу белән, иң кадерле, иң якын туганын күргәндәй, күгәрчен кебек гөрли дә башлады. Әйтерсең лә, Җәүһәрия аңа тау кадәрле бәхет алып килгән.

— И-и, җаныкаем ла! Җәүһәрия килгән ләбаса! Менә куандырдың... менә рәхмәт!— дип, хуҗа хатын сайрый калды, мин китеп бардым.

### 3

Гази, әрнү-сызлануларга чыдый алмыйча, ут сулап, урын өстендә ята. Йөрәгеи ялкын өтәли. Сызланулары бәгыренә төшә. Кичәге тәкать тота алмаслык газап чигүләр бүгенгенең күләгәсе генә булган икән дип уйлый ул. Һәркөн шулай.

Өендә ята Гази. Үзе шулай теләде. Врач кешегә шифаханәдә яту килешми янәсе, бигрәк тә үзе эшләгән больницада...

Йөрәген үткен хәнҗәрләр белән актаралармыни, чыдар әмәлләре юк. Чигә тамырлары дык-дык тибә, авыр чүкеч белән суккан сыман. Авырту исә, ярга бәргән дулкын кебек, килә дә кага, килә дә кага. Вакыты белән бу иза чигүләр түзә алмаслык дәрәҗәгә җитә, шундый чакларда Газиның зиһене томаланган сыман була. Андый мизгелләрдә: мөгаен, менә шулай үләләрдер инде дигән шыксыз уй миен өтәләп алгалый.

Бакча ягына караган ачык тәрәзәдән май ае һавасы бөркелә. Аннан, чәчәккә бөреләнгән карлыган, кура җиләге куагы исе белән аралашып, Кама-дәрья исләре, дегет-сумала исләре дә керә. Пароход, буксирларның, бер-берсен сәламләгәндәй яки мәңгегә саубуллашкандай, сузып-сузып кычкыртулары, җим эзләп, бакча артындагы елгачыкка кергән акчарлакларның нәрсәгәдер сыкрап-өзгәләнеп кычкырынулары Газиның ансыз да тәмам эштән чыккан сырхау йөрәген меңгә телгәлиләр.

Пристань янындагы затон тирәсе дә тыныч түгел. Судноларны ремонтлау мастерскойларында көн дими, төн дими хезмәт кайный. Әнә, хәзер дә иллаһи зур чүкеч белән суккандай, нәрсәдер пошкыра, ухылдый. Төн җитте исә, Гази ул якка күз салмаска тырыша. Чөнки аҗаганга охшаган зәһәр балкыш яктылыгы, үзенең дәһшәтле канатын җилпегәндәй, бөтен күк йөзен айкый, актара. Электросварка шулай итә.

Кеше үләр алдыннан бөтен үткән тормыш юлын күз алдыннан кичерә дигән сүз, мөгаен, хактыр. Гази да уй эчендә. Ул секундлар эчен-

дә әллә ни кадәрле вакыйгаларны, шатлык-куаныч, кайгы-хәсрәт тулы гомерен күз алдыннан үткәрә.

Юк, кичә район больницасының баш врачы белән ике арада килеп чыккан низаг, йөрәк приступы башлануга сәбәп булган җәнҗал турында уйларга теләми Гази. Уйлыйм дисәң, җәрәхәтле, кан саркып торган йөрәккә дәва булырлык, хәтер диңгезе офыгыннан калкып килгән кояш кебек, җанны иркәләп-назларлык истәлекләр дә бихисап...

Ни хикмәттер, кеше узган гомереннән истәлекләренә бирелим, үткәннәрне күзаллыйм дисә, еллар томаны эченнән һәркайчан тормышның авыр, ачлы-туклы, ярым-ялангачлыкта үткәрелгән күләгәле яклары түгел, иң кадерле мизгелләре, иң шигърияте минутлары гына килүчән була икән. Газины да уйлары, елларны кире чигендереп, гомер юлының башына — ерак-еракта калган иң кадерле балачак хатирәләренә алып киттеләр. Миенең кайсыдыр борылмаларында, иртән күргән төш сыман гына булып сиземләнгән балачак хатирәләре, якты күренешләр бөтен тулылыгы белән гәүдәләнеп күз алдына килә башлады. Шуннан аңлады Гази: балачак тәэсирләре күңелдән беркайчан да җуелмый, һәрчак аяз, һәрчак бәйрәм булып мәңгегә хәтердә кала, саклана икән. Тикмәгә генә: бала чак — баллы чак, дими торганнардыр шул.

Балачак истәлекләре Газины, үзләренең адаштыргыч сихри сукмаклары белән һаман-һаман бик еракларга, бик кадерле, уйлаганда гына да чиксез ләззәт, татлы зур куаныч бирә торган чакларга алып киттеләр. Җитмәсә тагын ул вакытлар шул хәтле якында — менә генә, кул сузымында гына...

Әле дә булса хәтерендә Газиның: Гөлүсәләрнең аларда өйдәш булып торган кышлары иде. Әниләре ачы таңнан торып эшкә китә. Эшләре җиңел түгел, әнисе белән Гөлниса апасының зарланып әйткән сүзләренә караганда: «җиде тиреләре чыкканчы, беләкләре өзелеп төшкәнче», кайсыдыр байның бөркәүле ындыр табагында җилгәргеч әйләндерәләр. Һаман да әле күңеле ятарлык эш таба алмаудан ут йотып йөргән Иргали абыйлары да өйдә юк. Балалар үзләре генә. Менә бер заман уяналар. Күзләрен ертып ачу белән, әниләре әзерләп калдырган ризыкларын ике кабып, бер йотып, ялт иттереп куярлар иде дә, и-и китәр иде уен! Өйнең яртысын диярлек биләп торган сәке өстендә шайтан аягын сындырырлык. Бала-чагалар тезелешеп йоклаган урын-җир өстенә, сандык башына өеп куелган юрган, мендәр, ястык, киез ише нәрсәләр дә ишеп төшерелгән. Ишек катындагы чөйдә эленеп торган соры сәләмә кайры тун да шунда. Тузган мендәр-ястык сүрүләреннән тирә-юньгә йон оча, тузан күтәрелә. Беркавым уйнап, тәмам хәлдән тайгач, тынычрак уенга күчәләр. Башта «өй-өй» уйныйлар. Аннары «әти» белән «әни» уенына керешәләр. Гази — «әти», аяз күк йөзедәй зәп-зәңгәр күзле Гөлүсә — «әни», Таҗи белән Һади — балалар. Нәни Һадины мәче баласы урынына асып йөртсәләр дә, түзә — елау юк.

«Әни» кеше шактый кырыс. Әнә ул маңгаена, күзләренә төшкән чәчләрен сыңар кулы белән селтәнеп кенә төзәткәндәй итә дә яңарак кына җәеп куйган урынга «балаларын» яткыра башлый.

— Ягез, җәтрәк ятыгыз. Аннары, иртә якта уятыр хәл юк үзегезне. Таҗи, энеңне кысрыклама... Кара әле син аны, нинди хәйләкәр! Аңа гына йомшак булсын да аңа гына җылы булсын икән.

Таҗи белән Һадины иске бишмәт белән баштанаяк томалап куйгач, Газига да чират җитә.

— Әйдә, әтисе, син дә ят, иртән иртүк торасың да бар...

Гөлүсә Гази белән янәшә ята. Үзенең очлы терсәкле арык беләкләре белән Газины муенынnan кочаклап ала. «Әни» кеше анда да тиз генә тынычланмый, әледән-әле: ягез, шаулашмагыз, җәтрәк күзләрегезне йомыгыз дип әмерләр биргәләп куя.

Бу уен да озакка бармый, үлеп ашыйсылары килү «йокыларын» бик тиз ача аларның. Янә дәррәү кубып сикерешеп торалар да, алабута

кушылган арыш онынннан талкан болгатылган казан янына ташланалар. Инде икеме-өчме тапкыр кырылган казанны яңадан ялтыратканчы каезларга керешәләр. Гаҗәп хәл! Яңадан берәр кашык чамасы талкан касмагы кырып алына. Бүлү гадел: мич авызы өстендәге кучкар өстенә тезеп куелган, кырыйлары кителеп беткән чаган кашыкларга дөньяда берни белән дә чагыштыргысыз тәмле ризык — берәр чеметем талкан касмагы салына.

Бар да һәйбәт булыр иде, тик менә Гөлүсәнең әтисе генә җанын кая куярга белмәгән кеше сыман, бик тә күңелсез йөри. Алай гына да түгел, кайтып, тәрәзә буендагы эскәмиягә утыра да, дөньялардан киткәндәй башын иеп, тавыш-тынсыз кала.

Әйе, соңгы вакытларда Иргали үзен, кайнар ком өстенә чыгарып ташланган балык сыман хис итте. Кая барып бәрелергә белмәде ул. Күңеле тулы хәвеф, киләчәге өчен хафалану. Чыннан да, һичбер җирдән фәрман котәрлеге, өмет итәрлеге юк бит, ичмасә. Шулай бәгырь көйрәгәнгә тәкать тота алмыйча, үз-үзенә мең дә беренче кат: инде нишләп карарга? дип сораулар да биреп куйгалады. Әмма, шушы бердәнбер соравына да төпле җавап таба алганы юк. Тормышы актык чиккә килеп терәлгән Иргалинең башы каткан, фикерләре чуалган, зиһене томаланган иде. Типсәң тимер өзәрдәй башың белән, йортсыз йомран кебек сөрлегеп, кеше тупсасын тапта инде, ә! Җил оясына әверелгән өйне, хәзрәт киңәш иткәнчә, күптән инде сүтеп утынга ягалар.

Гомердә булмаган һәм булыр дип башына да китермәгән хәл: күңеле урыныннан купты, өмете өзелде, ихтыяры сынды, дөньядан тәмам җаны бизә башлавын тойды Иргали. Эч пошуның һич тә чыдап булмаслыгы басты. Тормышы тоташтан аязмас көнгә әверелде. Күңелен упкындай төпсез, бер генә мизгелгә дә тынгылык бирми торган борчулар биләде. Андый минутларда ул, инде бер тапкыр узган кара ачлык елында, ниндидер могҗиза белән генә үлемнән котылып калган хатыны, нәни зәңгәр күзен мохтаҗлыкта, киемсез-ризыксыз яшәтүе өчен әрни, изалана иде. Хәзер дә әле алар бик ябыклар, юкарып, хәлсезләнеп калганнар мескенкәйләр.

Иргали менә ничәнче кат инде: әллә чыннан да вак нэпман Иван Дәдәйгә барып эшкә ялланып карарргамы? дип өмсенеп куйгалады. Әнә, дүрт куллап кабул итәчәкмен дип калды бит. Яхшымы-яманмы, яши торырга фатир да бар. Кешенең көче — эшендә, диләр. Иргали дә умыртып эшләр иде. Алар бит бөтен нәселләре белән беләкләре өзелгәнче эшли торганнар. Сул як җилкәсенең яралы булуына да карамастан, аллага шөкер, хәзергә әле дәрт-дәрманга әҗәткә кермәс шат, беләгендә көче, йөрәгендә дәрте ташып торган чагы. Һәрхәлдә, олаучы булып кына эшләрлеге бар.

Ләкин шунда ук икенче бер уй миен кимекли башлый. Көнлекчегә ни көн дигәндәй, Иван дәдәйдән эшләп алган ике-өч кадак он яки пешкән икмәк белән нишли генә алыр соң ул? Кайчан соң, чын адәм баласы кебек, тәмам аякка басачак, атлы-сыерлы булачак, йорт-җир әмәлләп керәчәк? Игенче икәнсең, аты да кирәк, «атсыз кеше — затсыз кеше», димәсләр иде аны!

Менә шулай ут йотып, киләчәге өчен тоташ хафаланып, үзенең болай яшәвен мәхшәргә тиңләп, баш ватып йөргән көннәрнең берендә, тагын бер вакыйга булып алды. Әлеге хәл бөтенләй чыгарыннан чыгарып ташлады аны.

Шәфкатьле хуҗабикә — Зәйтүнә: әнә, тагын бер бичара саилче хәер сорый дип, бер бәрәңге алды да җилкапка төбенә килеп туктаган бичара җан янына чыгып китте. Аннан ул, туңып-күшегүдән тәмам кешелектән чыккан, бер кыз бала иярте керде. Бу — Гөлнисаның бертуган апасы Миңнисаның кызы Миңсылу иде.

Иргали аны ямау өстенә ямау салынган, терсәкләренә кадәр күтәрелгән кыска җиңле сәләмә бишмәте белән, нәкъ әнисенеке кебек ярты йөзен диярлек биләп торган, зур коңгырт кара күзләреннән таныды.

Бичара бала, керә-керешли үк, кулындагы төенчеген ишек катында ташлады да, җан өшеткеч тавыш белән: «Гөл апа-аем!.. Апаем ла!.. Әнисез дә калдым бит!.. Әнием үлде... Нишлим? Кая барыйм?..» дип, мич буенда кайнашкан Гөлниса апасының иңенә барды да сарылды.

Өйдәгеләр тораташ кебек каттылар да калдылар. Иргалине иң тетрәндергәне — Миңсылуның: «Нишлим?.. Кайларга барыйм?!» дип, үз-үзен белешмәс дәрәҗәгә җитеп үксеп тыпыр-тыпыр килеп биюе булды. Кыз баланың үз-үзенә такмак әйткәндәй җылап «биюе» шулкадәр күңел әрнеткеч булды, Иргалинең бөтен тәне чымырдап китте, бәгыре меңгә телгәләнде.

Көч-хәл белән тынычландырдылар Миңсылуны. Гөлниса да җылый иде.

— Чү-ү, үскәнем!.. Нишләвең бу? Тынычлан. Менә, мин бар, әнә җизнәң бар. Тынычлан! Бездә генә яшәрсең. Алай итенмә. Моңарчы бергә-бергә яшәгән идек бит әле. Бар да рәтләнер, әйткән иде диярсең менә. Ялгыз түгел син, үскәнем, түгел. Туганыбыз ич син безнең...

Тормыш, әнә шулай, әле бер, әле икенче хикмәтләрен чыгарып, михнәт-мәшәкатьләрен өстәп кенә торды. Ансыз да өзек тә төтек тормышларына тагын бер ятимәнең килеп өстәлүе казык башына тукмак булды. Иргалинең башы иңрәде, аяк-кулын тәмам тотрыксыз итте. Менә шулай үзен-үзе күрәсе килмичә, кая барып бәрелергә белмичә йөдәп йөргән бер мәлдә, кабат Бәһрам җизнәсе янына барып чыкты. Үзенең хәлен аңлатырга иде нияте. Җизнәсенең нык иманлы, олы җанлы кеше булуына мыскал да шиге юк иде аның.

Билгеле, барып керү белән, аһ-ваһ килеп зарлана башламады ул, шулай ук бик тә ярдәмгә мохтаҗлыгын да чыгарып селекмәде. Алай итәргә ул бит нинди дә әрсез алабай түгел. Бары тик бик тә уңайсыз, ифрат та җайсыз бер хәлдә калуын гына төшендерергә теләгән иде Иргали.

Әмма гелән моң-зар, сорау-үтенү, ялыну-ялвару гына ишетергә күнегеп-ияләшеп беткән Бәһрам җизнәсе аның сүзләрен үзенчәрәк аңлады булса кирәк.

— Әһ-һ, Иргали туганым!— дип башлады ул, шактый үк ризасызлык сизелеп торган тавыш белән.— Күрми, аңламый дип уйлыйсыңмы әллә? Барысын да күрәм, барысын да аңлыйм, тик нишли алам? Кая карама — хәерчелек, бөлгенлек. Күпчелек халыкның тормышы актык чиккә җитеп тәмам коелып төшкән. Башта сугыш, соңрак акгвардиячеләргә, чит ил интервентларына каршы аяусыз көрәш халык хуҗалыгын кара җаяүлегә калдырды. Шуның өстенә, халыкның котын очырып, бугазыннан буып алган ачлык афәте... Так что, туганкаем, мин сиңа ярдәм итү түгел, хәтта вәгъдә дә бирә алмыйм...

Хөкем карарыдай рәхимсез булып яңгыраган бу сүзләр, дуамал холыклы, ярсу хисле, хис-тойгыга тиз бирелүчән Иргалине әллә нишләтеп җибәрде.

— Мин, Бәһрам җизни, синең янга хәер өстәп, таштан юкә суйдырмак булып кермәгән идем,— диде ул йөзенә кара коеп.— Белгән, күз күргән өлкән кеше, берәр җүнле киңәш бирмәсме, дип килүем иде.

— Алайса, кичер.— Бәһрам кинәт үзгәрде, тавышына кадәр йомшарды.— Әһ-һ, туганкай, белмисең хәлләремне!

— Беләм...

— Ай-һай!

Бүлмәдә авыр тынлык урнашты. Тәрәзә артында катып, тәмам бозлавыкланган кантарлы юлдан, буш арбасын яман доңгырдатып, бер атлы узды.

Зиһенен чак кына җыйган Иргали янә телгә килде. Ул менә ничәнче кабат инде: әллә кала тирәләренә сугылып, берәр сезонлы эшкә ялланып карыйммы икән, дигән нияте барлыгын әйтте.

Өлкән кардәшенең моңа да җавабы әзер.

— Бар! Синең кебек эшсез этрәк-әләмнәр, фәкыйрь-фокралар каланың үзендә беткән ди.— Бәһрам үзенең артык турыдан яруын чамалапмы, янә үзгәрде һәм үзенчә бик тә төпле, бик тә урынлы киңәш биргән сыман итеп, болай диде:— Тик шуны бел: берни дә кыйрата алмассың. Ә инде минем киңәшкә килсәк, шул: түзә алмаслык авырлыкка төшкәндә дә, көтүдән, ягъни халыктан аерылма, киресенчә, аңа ныграк елыш. Бәхетне аны читтән эзләмиләр. Аннары, яхшымы-яманмы, алар бит синең авылдашларың... Коелып төшкән тормышны рәткә салу, аякка бастыру өчен көрәшәбез түгелмени соң! Башкалар берни белән дә санашмыйча, кирәксә, җаннарын да бирердәй булып тырышканда, кызыл-армеец башың белән читтә калыр идеңме әллә?

— Минем ишеләр әнә шахтагадыр, анда-мондадыр китеп торалар ич...

— Минем башкаларда эшем юк. Минем алдымда фронтовик, ниһаять, революция солдаты тора.

Иргали дә үз чиратында сүз кыстырып куюны кирәксенде.

— Революция ясалды...

Кызып киткән Бәһрамга әйтерсең шушы сүз генә кирәк булган.

— Әй-йе, ясалды. Әмма, властьны кулга алу — ул әле ярты эш. Менә хәзерге положениедән чыгып кара син. Әнә күр, дөньяны мур кырган диярсең. Ачлык-ялангачлык турында әйткән дә юк... Бөтен нәрсә җимерек тә ташландык хәлдә. Завод-фабрикалар эшләми. Бөтен көч хәзер шул завод-фабрикаларның торбаларыннан төтен чыгара башлауларга юнәлтелгән. Бер көн кайсыдыр, кем икәнен чурт белгән аның: хезмәтсез эшче — шул ук сукбай, җирсез мужик — бандит, дип тора иде. Уйлый калсаң, өлешчә хаклык та бар бит әлеге сүзләрдә. Авыллар турында әйткән дә юк: кая күз салма, тәрәзә-ишекләре кадакланган буш өйләр. Боларны без — большевиклар торгызмыйча, кем торгызырга тиеш соң?!.— Бәһрамның тавышы кырысланганнан-кырыслана барды. Кашларын сөзәк маңгай уртасында җыерып, текәлеп карап, сүзен дәвам итте: — Бәлки, мин партия әгъзасы түгел, дип әйтергә тели торгансыңдыр?..— Әй-йе! Әгәр дә партия әгъзасы булсаң, мин синең белән башкачарак сөйләшер идем...

Шунда Иргалинең күзләре Бәһрам җизнәсенең чабып ташлаган карабодай сабагына охшаш кызгылт-күгелҗем төстәге кан тамырлары белән чуарланган кулына төште. Бу кул яман да нык калтырый иде. Әмма, йөрәге тәмам урыныннан купкан Иргали, каяндыр бик тирәннән, күңел түреннән күтәрелгәннән-күтәрелә барган үпкәсен белдермичә тыелып кала алмады.

— Ярар, Бәһрам җизни,— диде ул, рәнҗү, хәтере калуын яшереп маташмыйча.— Житте! Мин синең янга талашу-тәмсезләнү өчен килмәдем. Гәрчә, күңелемдә сиңа карата үпкә төере булса да... Син бит, туган гына түгел, ә ил агасы була торып, газиз әниемне дә саклап кала алмагансың... Күрше-күләннәр әнә күәс төбен чайкап булса да эчергәннәр. Хатыным белән нарасыемны да шул ук күршеләр, ишекне ватып кереп, үзең әйтмешли, ач үлем афәтеннән йолып калганнар...

Моңарчы Бәһрам җизнәсенең җәберсенү билгеләре, рәнҗү чаткылары гына ярылып яткан йөзе күзгә күренеп үзгәрде, яңак итен чәйнәгәндәй, бит мускулларын, мыекларын селкеткәләп куйды. Яман иде кыяфәте. Менә ул, сирәк шадра бизәгән йөзен Иргалига таба борды һәм кысылган тешләре арасыннан мондыйрак сүзләр сыгып чыгарды:

— Син миңа шул турыда әйтергә дип килгән идеңме? Монда килгәнче иң әүвәл, әнә, зиратка кереп зиярәт кылып чыгасың калган. Шунда күрер идең хикмәтне... Яңа өлеше аркылыга-буйга чакрымга җитә язды... Ике мәхәлләле авыл өчен чамадан тыш бу.

Иргали бу сүзләрне бүтән тыңлый алмаячагын сизенепме, җизнәсен бүлергә мәҗбүр булды.

— Ярар, җизни, бигайбә. Ни уйлаганымны кайчандыр бер әйтергә тиеш идем бит инде,— дип, эскәмия өстендә яткан бүреген йолкып алып

башына чәпәде.— Һәрхәлдә мин, хатыным белән газиз нарасыемның тамагын туйдыру, өс-башын бөтенәйтү әмәлен табармын...

Ул, бәрелә-томырыла, урамга чыкканда, тирә-юньне ак кәфенгә төрергә теләгән сыман, чынлап торып кар ява башлаган иде инде.

Иргали урамга чыккач та, барыр юлын оныткан кеше сыман, чигәләрен угалап, бер мәлгә туктап торды. Зиһене чуалып, башы каткан иде аның. Нәрсә бу? Ни өчен әле Бәһрам җизни аның белән шулай сөйләште? Күрче зинһар, һәр сүзе хөкем карарыдай рәхимсез бит. Ни өчен шулай? Бәлки, кайтып җитеп, туган туфрагына аяк басмас борын, Гыйззәт хәзрәт белән якын мөнәсәбәткә кергән өчендер? Ике сүзнең берендә «контр» дип телгә алалар бит үзен. Хәзрәттә кунакта булуы, кунып калуы, шуның өстенә әле җигүле ат алып торуы аларга ишетелмәгән дисеңмени? Хәзрәт үзе үк кылган изгелеге турында авыл буйлап мактанып йөргәндер. Бәлки җизнәсе аның кайтып җитмәс борын авыл активисты Халәп белән телгә килүен килештереп бетермәгәндер? Яхшымы-яманмы, Халәп бит коммунист кеше. Хәер, уйламаганда-көтмәгәндә дөрт итеп кызып-кабынып, Халәп белән әләгешеп китүен Иргали үзе дә өнәп бетермәгән иде. Бу хәл аның күңелендә кара кан төередәй урнашып утырып калды.

Ничек кенә булмасын, Бәһрам җизнәсе яныннан чыккан минутларда Иргали үзен, ничектер, читкә тибәрелгән кеше сыман хис итте. Ә бит кеше — үзен тормышта чит итеп тоймаганда гына кеше.

Көннәр уза торды. Кеше бусагасына килеп егылудан да яман нәрсә юклыгын шунда төшенде Иргали. Болай күз көеге булып яшәгәнче, канлы яу кырында ятып калган булсамчы, дигән чаклары да булгалады аның. Аптыраган үрдәк арты белән чумган, дигәндәй шулай тәмам йончыгач: берәр эш тәкъдим итүче булмасмы дип, Чаллы тирәләрен дә әйләнеп кайткалады. Бәһрам җизнәсе янында, тамакларын туйдыру әмәлен табармын дип, бик батыраеп күкрәк каккан иде дә, бар, табып кара. Вакыты да шундый бит аның: икмәкне потлап түгел, гәрәнкәләп тә кадаклап үлчи торган заман.

Көннәрнең берендә эш тә тапты кебек. Чаллыда бер артельгә ияреп, затонның өске өлешенә юл тотты. Үз хәлен чамалап, юлда ук эшнең ниндилеге — авырмы, җиңелме булуы белән дә кызыксынды. Янәшәсендә атлаган татар абзыеның җавабы кыска: «Ничава, ияләнгән камыт».

Әмма эш урынына барып житү белән, тәкъдим ителгән әлеге хезмәткә алына алмавы ачыкланды. Бер төркем ир-ат, боз кисәкләре белән аралашкан чал башлы дулкыннар өстендә чайкалган салны сүтеп, бүрәнәләрен ярга чыгарып өяргә тиеш икән. Әмма Иргалинең суга керерлек хәле дә, багор белән бүрәнәләрне ярга таба куарлык чамасы да юк иде. Ахыр чиктә ул яр өстендә эшләүчеләр янына күтәрелде һәм, үзенең көч-егәрен сынап карарга теләгәндәй, озын арканнар, рычаглар ярдәмендә өем өстенә бүрәнә тәгәрәтүчеләр янына килде. Бер юан гына бүрәнә астына барып кергән иде, күтәрә башлау белән, чыраен сытып һәм уң кулы белән сул иңбашын тотып, читкә тайпылырга мәҗбүр булды. Бандит пычагыннан алынган яра үзен шунда ук сиздерде. Хәер, сул кулының күкрәк турысыннан ары күтәрелмәвен ул инде болай да яхшы белә иде. Шулай итеп Иргали, пычрак су агып-тамып торган бүрәнә астына кереп, күз карасыдай саклаган шинелен генә пычратып чыкты.

Түзә алмаслык авырлыкларга, бәхетсезлекләргә тарыкканда да өметен тәмам җуеп бетерми адәм баласы. Әле дә ярый аның гомерлек юлдашы — өмет дигән тормыш җилкәне бар. Шул яшәтә кешене.

Шулай уй иркенә бирелеп атлый торгач, искәрмәстән генә яшен камчысын уйнатып алгандай, миендә бер балкыш чагылып китте Иргалинең. Ул хәтта бер генә мизгелгә туктап ук калды. Күрче зинһар! Соң бит шул ук Казан каласында, ярдәм кулын сузмаса да, һич югында барып киңәшләшерлек кешесе бар икән ләбаса! Кешесе нинди бит әле. Мәшһүр Казанда гына түгел, ә бөтен губернага танылган, үзлегеннән шифаханә тоткан атаклы доктор Клочкинның бердәнбер улы. Исеме дә

хэтерендэ — Илья Олегович. Хәер, ул вакытта Илья Олегович аның өчен бары тик «Ваше благородие!» гына иде. Иргали күпмедер вакыт прапорщик Клочкинда денщик булып торган иде. Офицер булса да, Илья Олегович ифрат та миһербанлы, олы җанлы кеше иде. Иргалине дә кимсетмәде, башкаларга да кыерсытырга ирек бирмәде. Тик шул кадәресе бар, Иргалинең Илья Олегович белән соңгы тапкыр очрашуына да биш-алты ел вакыт үтеп китте. Әлеге утлы-кылычлы, канлы-дәһшәтле дәвердә кемнәр белән ниләр генә булып бетмәгәндер дисең. Дөрес, моннан ике генә ел элек Иргали Клочкинның якын дусты Аркадий Алексеевич Тарановны очратты. Уйламаганда-көтмәгәндә. Шуның аша Иргали Илья Олеговичның исән-сау икәнлеген белде. Алай гына да түгел, Илья Олегович Иргалине хәтерли икән. Хәтта: «Шул татарны күрергә язса, алдына тезләнер идем»,— дип әйтеп әйткән, имештер. Хәер, әйтсә, дә әйткәндер, чөнки Иргали Илья Олеговичның гомерен саклап калган иде. Анысын гына микән? Бәлки үзенекен дәдер...

Иргали, кем беләндер әрепләшкән сыман итеп, үзалдына сөйләнеп алды.

— Пычагымамы миңа синең тезләнүең? Әгәр дә син чын кеше икәнсең, әйдә, ярдәм кулы суз. Бер дә булмаса, җан саклар акча юнәтерлек, кулдан килерлек хезмәт табыш. Менә, ичмаса, булыр эш!..

Күптән узган вакыйгалар искә төшү Иргалинең уй-фикерләрен яңартып җибәрде. Үзенең туган ягы, туган-тумачалары белән саубуллашып, сугышка дип чыгып киткән чаклары күз алдына килде...

Шунда бер бик ачы хакыйкатькә төшенгән иде Иргали: чутка да саналмаган, чүп урынына да тормаган икән солдат гомере. Моны ул солдатка алынуның икенче көнендә үк үз башыннан кичерде. Иң әүвәл, Чаллыга алып килеп, нindидер иске баржаның караңгы трюмына дыңгычлап төяп, Казанга илттеләр. Ристаннар урынына алып бардылар, ачлыктан интектерделәр, Идел-дәрья өстеннән баруларына да карамастан, бер йотым суга тилмерттеләр. Казанда да хайваннар урынына күрән төстәге вагоннарга төяделәр. Шулкадәр тутырдылар, утырып тору түгел, басып барырга да урын житәрлек түгел иде. Җәйге чиллә вакыты. Үзе кызу, үзе тынчу. Шулай булуга да карамастан, томаланган ишекләрне ачты юк, солдат — кеше түгел, дөмекмәсләр, янәсе.

Өч атна чамасы иза чиккәч, ниһаять, вагоннарның ишеге ачылды. Янә көтү урынына куып, каядыр алып киттеләр. Ахыр чиктә аларны урман ышыгына посып утырган казармаларга илтеп яптылар. Менә кайда булган икән ул тәмуг төбе. Миләр кайнап чыгарлык чиллэдә мылтык астырып, төрелгән шинельне җилкә аша салындырып, көрәк, тагын әллә никадәрле тимер-томыр күтәреп, хәлең бетеп, йөрәгең авызыңа килгәнче йөгертерләр, иза чиктерерләр иде. Чак кына хәл алырга дип туктатсалар, каяндыр руханилар килеп чыгып, турылыклы хезмәт итәргә өндиләр, немецлар илебезне коллыкка төшерергә тели дип нотыклар сөйлиләр, «бу соңгы сугыш, сугыш — изге эш», дип өстәп куярга да онытмыйлар. Ул да булмый, солдатлар арасыннан берәве чыгып: бу сугышның безгә кирәге юк, бу сугыш безнең кебек гади хезмәт ияләренә бары тик ачлык, ялангачлык кына китерә, каныбызны коя дип үгет чәчә башлый. Аптыраш белән йөдәш, кемне тыңларга да белгән юк.

Нәкъ шул көннәрдә, хәрби әзерлек, хәрби өйрәтүләрнең иң кызган дәверендә, Иргали солдатның да тормышында житди генә үзгәреш булып алды. Казармага фельдфебель кереп, русча белгәнрәк, дөнья күргәнрәк, төскә-биткә дә чибәррәк, буйга-сынга да таза-ныграк күренгән унлаган татар солдатын сайлап алды. Солдат «үеннары» үтә торган плацка чыгарып тезде. Бераздан нәрсә турындадыр гәп сатып, көлешә-көлешә, иннәренә алтын погоннар таккан, бер төркем яшь офицерлар күренде. Бар да ачыкланды: денщик сайларга дип килгәннәр икән. Иргали каршына да уртачарак буйлы, тар җилкәле, әмма шактый ук сөйкемле бер офицер килеп басты. Күзләре очрашты. Иргали үрә каткан килеш тын да алмыйча торды. «Татармы?» — булды офицерның беренче соравы. Ни-

чегрәк җавап кайтарырга кирәклекне Иргали яхшы белә, беренче көннәрдә үк арт сабакларын укытып өйрәтеп куйганнар иде инде. «Так точно, Ваше благородие!» — «Кайсы яктан?» — «Кама буеннан, Ваше благородие». Сары пошлак елмайды. Мыек чылгыйларына перчаткалы кулы белән кагылып алганнан соң, үзенең нинди йомыш белән килгәнлеген әйтте, Иргалинең ризалыгын сорады. Шулай итеп Иргали өчен яңа тормыш башланды. Бәхетенә каршы, Илья Олегович Клочкин, шактый ук тыйнак, кешелекле, иң әһәмиятлесе — гадел, тыныч табигатьле кеше булып чыкты.

Иргали тормышның искәрмәстән генә шулай елмаюына шөкерана кылып бетә алмады. Чыннан да, соры шинельле солдатка ни кирәк тагын. Аерым фатирда яшәүләре үзе генә дә ни тора. Беркем аның җанына тими, җәберләми. «Айт-два!» юк. Казармада күргәннәре, анда кичергәннәре хәзер инде ямьсез төш булып кына исенә төшә.

Иргалинең тормышы тагын да тынычрак, тагын да ямьлерәк булыр иде дә, тик менә Илья Олеговичның җан дусты Аркадий Алексеевич кына килеп аны кыерсыта, көлә, вакыты белән хәтта кешелеген изә. Төн уртасында аракы таптыруларына да түзәр иде, акчасын биргәч, анысы әллә ни авыр түгел, урам саен диярлек кибет. Төнлә кереп ала торган урыннар да бар. Ул яктан Иргали үзен шактый ук уңган, булган денщик итеп танытып өлгергән иде инде.

Аракы алып кайтып, капкаларга әйберләр әзерләп куйгач, офицерлар бермәлгә тынып калалар. Соңрак белде Иргали: Илья Олегович белән Аркадий Алексеевич Казанда ук дус булганнар, икесе дә Казан юнкерлар училищесын тәмамлаганнар, үлгәндә дә аерылышмаска сүз куешканнар икән. Ут эченә кергәндә дә бергә керергә, кирәксә, бер-берсенә ярдәм итешергә ант иткәннәр.

Ике дус, ике офицер, маңгайларын-маңгайга терәшеп гәп сата. Иргали алгы бүлмәдә, андый-мондый әмер булмасмы дип көтеп утыра. Вакыты белән үз уйларыннан арынып, офицерларның әңгәмәсенә дә колак салгалый. Тыңлый калсаң, харап, чәчләрең үрә торырлык сүзләр сөйлиләр. Бернинди тартынусыз патшаны сүгәләр, сугышны дәвам итү өчен Англия, Франция, Америкадан заемнар алып, Россияне тәмам бурычка батырды, ярым колониаль хәлгә төшерде диләр. Иң гаҗәпләндергәне шунда — патшаны сүгеп кенә калмыйлар, тәхеттән ваз кичәргә мәҗбүр итәргә, аның урынына ниндидер регент, ниндидер бөек князь Михаилны куярга кирәк диләр.

Игътибар беләнрәк тыңлый калсаң, башың бетәрлек сүзләр дә ишетергә мөмкин. Әгәр дә хак булса, бу сугышка, имештер, бары тик Европадан гына да утызга якын ил тартылган, җитмеш миллионга якын кеше мобилизацияләнгән...

Әмма ләкин әлеге тыныч, тук, чиста тормыш озакка бармады, аларны резервтан алгы сызыкка озату, ягъни, сугышка кертү турында хәбәр алынды. Бу —1916 елның җәе көзгә таба авышкан көннәр иде.

Төнлә бик зур саклык белән хәрәкәтләнүләренә дә карамастан, позициягә яңа көч кертелүен дошман белгән, сизенгән булып чыкты. Немец разведкасының кирәгеннән тыш яхшы эшләве турында Иргалинең дә ишеткәләгәне бар иде. Таң атыр-атмас борын, җирнең астын өскә китерергә теләгәндәй, дошман ут ачты. Олы калибрлы снарядлар шартлавыннан җир тетрәнеп кенә калмады, тирә-юнь хәрәкәткә килгән сыман булды. Окоплар өстендә ут өермәсе уйный, мәрхәмәтсез үлем давылы котыра иде. Баш калкытыр, иркенләп сулыш алыр чама юк.

Иргали мылтыгын кочагына алды да окоп төбенә чүмәште. Баш очында гына снарядлар ярылудан колаклары тонып, берни ишетмәс хәлгә килде. Өстенә берөзлексез балчык-ком ишелүен генә тойды ул. Бермәлне окоп эчендә хәрәкәт башланды. Караса, ни күрсен, санитарлар, башларын саклау өчен иелгәләп, йөгерә-атлый яралыларны ташый башлаганнар икән. Яман күренеш иде бу. Берсенең кулы өзелгән, икенче берәвенең эче актарылып чыккан, өченчесенең йөзе карарлык түгел, капкара кан. Кычкыру, ыңгырашу. Дөньясына гына түгел, алласына кадәр

ләгънәт уку. Иргали, җиргә иңеп керергә теләгәндәй, окоп кырыена тагын да ныграк елыша төште.

Туплардан утка тоту тынарга да өлгермәде, окоплар өстендә икенче бер җан өшеткеч хәбәр таралды: «Га-а-аз!.. Га-а-аз!..» Бу яман хәбәр күпләрне өнсез итте, тәмам тетрәндерде.

Иргали дә аякланды. Ышыграк урын сайлап, зур саклык белән дошман ягына күз салды. Әмма, газ дигәннәре дошман ягыннан түгел, ә уң яктагы калкулык өстеннән җибәрелгән икән. Күрде Иргали: сарыяшькелт төстәге төтен, бөтен басу киңлеген иңләп, дулкын тәгәрәвен хәтерләтеп, алар яшеренгән окопларга таба якынлашып килә. Хикмәте хода, төтен кебек һавага күтәрелми, ә җиргә елышып, авыр нәрсә сыман, җиргә сыланып хәрәкәтләнә. Туган якларында кыр бәрәңгесен алганда, сабакларын җыеп яндырганда, төтене шушындыйрак саргылт-яшел төстә булыр иде. Ә исенең тәмлелеге турында әйтеп торасы да юк, хәзер сагынып искә төшерергә генә калды.

Калкулык ягыннан дулкынланып акканга охшап шуышкан газ, ниһаять, окоплар өстенә дә килеп җитте. Иргалинең иң беренче тәэсире — күзләреннән, чыдый алмаслык дәрәҗәдә әчеттереп, яшь ага башлавы иде. Нәкъ шул мизгелдә, эрегән kургашын салгандай тамак төбе өтәләнде. Тончыга башлавын тоеп, күкрәген тутырып һава алмакчы иде дә, искәрмәстән генә бугазына ялкынлы кисәү тыгып куйдылармыни, кинәт күз аллары караңгыланып китте, егылмас өчен янә окоп төбенә чүгәргә мәҗбүр булды.

Шунда ул янәшәсендә генә станоклы пулемет расчеты белән җитәкчелек итәргә тиеш Илья Олеговичны барларга булды. Күрде Иргали: офицерның хәле тагын да мөшкелрәк, һушын җуйгандай, окоп төбенә сузылып ук яткан. Үзе хәрәкәтсез. Иргали, җәһәт кенә сикереп торып, офицеры янына ташланды. Әмма Илья Олеговичның буыла-буыла ютәлләүдән сыны каткан, йөзе күм-күк зәңгәрләнгән, күзләре аларган иде. Иргали аның башын күтәреп тезенә салды, дәшеп карады. Тик инде офицерның аны ишетерлеге дә, сүз катып җавап кайтарырлыгы да калмаган иде. Бераздан авыз-борыныннан, соңрак колакларыннан кан китте. Иргали каушый калды.

Нәкъ шул вакыт авыз-борынын ниндидер аксыл чүпрәк белән томалаган Таранов күренде. Окопның ермачланып беткән борылышыннан атылып килеп чыкканда, кыяфәте акылдан шашкан кешене хәтерләтә иде. Ул каядыр соңга калудан курыккан кебек, килә-килешли үк Илья Олеговичның башын тотып утырган Иргалине төртеп җибәрде. Аннары дусты өстенә иелеп: «Илья!.. Илья... Дорогой мой... Шулай итеп саубуллашабыз дамыни инде?!.» — кебек сүзләрне тәкърарлый башлады. Әмма җан дустының хәле аның сүзләрен ишетүдән узган иде инде. Илья Олеговичның йөзе күзгә күренеп кара-кучкылланды, бераздан, җан биргәнгә охшап, аяк-куллары тартыша башлады.

Таный алмаслык кыяфәткә кергән Аркадий Алексеевич, дустының күкрәк кесәсеннән нәрсәдер эзләгән сыман хәрәкәтләр ясап капшаштыргандай итте дә, аннары җан дустын бу газаплардан азат итәргә теләптер инде, кобурасыннан пистолетын чыгарды. Бермәлгә дустының җан әсәре калмаган йөзенә карап пистолетын Илья Олеговичның йөрәк турысына терәде...

Иргалине ниндн көч урыныннан күтәргәндер, хәзер инде башына да сыйдыра алмый: «Не сме-ей-йть!..» — дип, яшен ташы сыман атылып, Илья Олеговичны үз гәүдәсе белән каплавын сизмичә дә калды.

Бүтәне ничектер үзеннән-үзе эшләнде. Иң элек Аркадий Алексеевичтан аралап алган офицерын, бала урынына күтәреп, окоп кашына салды. Аннары үзе дә мәче тизлеге белән өскә ыргылды. Шундый ук житезлек белән офицерын, лафеты җимерелеп кырын ауган туп ышыгына тәгәрәтеп төшерде. Бары тик шуннан соң гына, мылтыгын иңенә элеп, бушап калган куллары белән җан барлыгы да сизелмәгән Илья Олегович гәүдәсен җил искән якка, куе әрәмәлек белән капланган калкулык булырга

тиешле тарафка сөйри башлады. Як-якта мәетләр, газдан агуланып, яраланудан ыңгырашып яткан яралылар, ат үләксәләре... Соңрак Иргали, шул вакыйгаларны исенә төшерә иде дә, каян килде икән миңа көчегәр дип, хәйран кала иде. Үлем ачысы кешене шулай мөмкин булмаганны да эшләтә торгандыр дип, үзенчә нәтиҗә ясый иде.

Иргалинең бәхетенә, газ зонасыннан азат калкулык та әллә ни ерак булмаган, газ таралуын, атышларның да чак кына тына төшүен көтеп утырган санитарлар да шунда, әрәмәлектә генә посып утырганнар икән.

Илья Олеговичка шундук ярдәм күрсәтә башладылар, ясалма сулыш алдырдылар, укол кададылар, авыз-борынына ниндидер сыекчалар белән чылатылган марля-маскалар куйдылар. Һәм шундук, күләгәдә торган бөркәүле арбага сузып салып, әрәмәлек эчләтеп кенә каядыр алып та киттеләр.

Ниһаять, Иргалигә дә чират җитте. Ул да аягына күтәрелер хәлдә түгел иде. Аңа да укол ясалды. Шыксыз олы, тукмак танавына песне атландырган бер бәндә, мең төрле сорау биреп, аның теңкәсенә тиеп бетте. Илья Олеговичның кайдан һәм кем булуы белән кызыксынганнан соң, Иргалинең дә исем-фамилиясен, кайчаннан бирле хезмәт итүен, кайсы яктан булуын, денщик вазифасын кайчаннан бирле үтәвен бик җентекләп язып алды. Иргалинең бәхетенә, әрәмәлек арасындагы юл өстендә янадан берничә бөркәүле арбалар күренде. Иргалине дә шуларның берсенә утыртып, кыр госпитаlенә озаттылар.

Госпитальдә нибары дүрт көн яткырдылар Иргалине. Шул кыска гына вакытның икенчеме-өченчеме көнендә, онытылмаслык бер вакыйга булды. Иртәнге як иде. Палатада алты-җиде яралы ята. Бер заманны әлеге палатага ут капкандай йөгерешеп госпиталь хезмәткәрләре килеп керде. Керделәр дә барлык солдатларга берьюлы мөрәҗәгать итеп: «Кайсыгыз Миргалиев?» — дип сорадылар. Бу көтелмәгән хәлдән башта югалып-каушап калды Иргали: «Мин булам...» Ике санитар йөгереп килеп, иң элек аны анадан тума чишендереп аттылар, өр-яңа күлмәк-ыштан кидерделәр. Җилкәсенә яраланган офицерлар кия торган һәйбәт халат салдылар. Аягына йомшак чүәк бирделәр. Борын төбендә бритваларын ялт та йолт китереп, сакал-мыекларын кырып аттылар. Күз ачып йомганчы палатаны да рәткә китерделәр: барлык яралыларның урын-җирләрен алыштырдылар. Хәтта уртада торган өстәлгә чиста эскәтерләр җәеп, ваза белән чәчәкләр дә кертеп куйдылар.

Нәрсә булыр бу? дип, озак баш ватарга туры килмәде яралыларга. Бераздан палата ишеге киң итеп ачылды. Аннан берьюлы биш-алты кеше килеп керде. Урталарында күкрәге тәреләр һәм төрле орденнар белән чуарланган генералга охшаган бер карт. Җилкәсенә күз явын алырлык ап-ак халат салынганлыктан, погоннары күренми. Аның бер артына, бер алдына төшеп юргалап торган ике яшь офицер да бар. Шунда ук, графиняны хәтерләткән, бик горур кыяфәттә бер хатын-кыз. Калганнары — госпиталь персоналы...

Әлеге төркем, палатага кереп, ишек катында туктап калды. Яшь офицерларның берсе, палатадагы авыруларны күздән кичергәннән соң, култык астындагы олы папкасын кулына алып, кирәкле урынын ачты да:

— Рядовой Миргалиев...— дип хәбәр салды.

Койкасы янында басып торган Иргали, үрә катты да:

— Рядовой Миргалиев — это я, Ваше высокоблагородие! — дип шәрран ярды.

Олуг кунаклар төркемнәре белән Иргалигә таба якынлаштылар. Генералга охшаган карт хәрби иң әүвәл, каршысындагы солдатның күзенә керергә теләгәндәй, текәлеп карап торды, тамагын кырып, чаларган сакал-мыегын сыйпаштырды. Бары тик шуннан соң гына янына килеп баскан икенче яшь офицер кулындагы ачык тартмага сузылды. Аннан ялтырап торган медаль алып, Иргалинең түшенә кадады. Аннары елмайгандай итеп:

— Благодарю за верную службу! — дип, уң кулын чигәсе турысына күтәрде.

Иргалинең көчле тавышы янә һаваны ярды:

— Рад служить, Ваше высокоблагородие!

Кунаклар палатадан чыгып китү белән, яралыларның йөри алырлыклары Иргали янына җыелдылар. Башта тәбрикләделәр, аннары түшенә тагылган медальне кулдан-кулга күчереп бик җентекләп караштырдылар. Тора алмаган яралыларга да тоттырып караттылар. Бу — 1812 елгы Ватан сугышының 100 еллык юбилее уңае белән чыгарылган махсус көмеш медаль иде.

Офицерын ут, газ эченнән алып чыгып коткарганы өчен бирелгән әлеге медаль төп-төгәл бер елдан соң Миргалинең үзен үлемнән алып калыр дип кем уйлаган? Ул вакыйга көне-сәгате белән хәтерендә аның. Үлгәндә дә онытасы юк.

1917 елның 9 июле иде. Двинск каласы янында хәрәкәт итүче 734 нче полк командованиесе, Вакытлы хөкүмәт күрсәтмәсе буенча, большевик-агитатор Акимны кулга алырга боерык бирә. Ул вакытта инде Иргали үзенең полкташы Аким белән шактый ук якынаеп өлгергән иде. Ул аның солдатлар арасында «Окопная правда» газетасын таратуын да, солдатларның нииндидер рота яшерен комитеты председателе булуын да яхшы белә иде. Шул ялкынлы агитатор-большевик авызыннан бит инде Иргали беренче тапкыр буларак Ленин турында ишетте. Ленинның барлык хосусый һәм дәүләт милкен гомуми халык милке итү турында хыяллануы һәм шуның өчен аяусыз көрәш алып баруы турында сөйләгән иде Аким.

Көтелмәгән әлеге вакыйга шул Акимны кулга алу вакытында булды. Нинди хис идарә иткәндер, Иргали дә озак уйлап тормады, өермә кебек ябырылып, Акимны якалаучы солдатлар арасына барып керде. Кулга алырга дип килгән офицерларның берсе: «Нәрсә, бунтмы бу? Хәзер үк таралыгыз, югыйсә атам!..» — дип, кобурасыннан пистолетын тартып чыгарды. Янап кына да калмады, Акимны яклаучы солдатларга төзи дә башлады. Шунда солдатларның берсе, мылтык түтәсе белән сугып, офицер кулындагы коралны бәреп төшерде. Кулы шартлап сынган офицер, яраланган ерткыч кебек үкереп, сыгылып төште. Штык белән икенче офицерның күкрәген яраладылар.

Бу кораллы бәрелеш бик кыйммәткә төште. Биш солдат кулга алынды. Алар арасында Миргали дә бар иде. Эшне бик коры тоттылар: кулга алынучыларның бишесен дә хәрби кыр суды атарга дип хөкем итте. Әмма, солдат Миргалиевнең аңынчы турылыклы хезмәт итүен, шуның өстенә әле үз офицерын үлемнән коткарып калганы өчен юбилей медале белән бүләкләнгән булуын искәпкә алып, үлем җәзасын 20 еллык каторга белән алыштырдылар.

Хәрби кыр судының бу карары да гамәлгә ашырылмыйча калды. Күп тә үтмәде, зиндан ишекләре ачылды. Иргали солдатны азат иттеләр. Аннары инде тарихта тиңдәше булмаган вакыйгалар — ярларыннан чыккан ташкын кебек Октябрь революциясе башланды. Иргали Октябрь ялкыны эчендә. Кулында корал. Яуланып алынган хөрриятне корал белән саклау еллары...

Давыллы-өермәле вакыйгалар эчендә кайнау сәбәпле, Иргали инде үзенең кайчандыр денщик булып йөрүен дә, Илья Олеговичны да оныта башлаган иде. Әмма, уйламаганда-көтмәгәндә Аркадий Алексеевич Тарановны очрату барлык үткәннәрен яңартты да куйды...

Хәрби эшелоннар килеп тыгылган нииндидер тимер юл станциясендә булды ул очрашу. Иргали Тарановны тавышыннан таныды. Таныды да, аның кызыл командир буларак, атлар белән тулы кызыл теплушкалар янында тезелешеп торган кавалеристларга нииндидер әмерләр биреп йөрүен күреп, авызын ачты да калды. Аркадий Алексеевич чак кына бушау белән, честь биреп, каршысына барып басты.

Денщик Иргалинең кайчандыр кешелеген изгән, канына шактый тоз салган Таранов бер генә мизгелгә югалып-каушап калган кебек булды. Әмма, үзен бик тиз кулга алды. Хәтта: «Дорогой Миргалиев! Синме соң бу? Күр инде, ә... Син дә исәнмени?!» — дип, Иргалине кочагына алгандай итте. Менә, шунда Таранов, җан дусты Илья Олеговичның исән-имин булуын, аның да Кызыл Армия сафларында хезмәт иткәнлеген, әмма, яралану сәбәпле, хәзерге вакытта тыныч кына Казанда яшәп ятуын әйткән иде. Аркадий Алексеевич җан дустына газ атакасы вакытында булган хәлне сөйләп биргән булган. Менә шунда Илья Олегович: «Әгәр дә Миргалиев исән-сау калып, күрешергә язса, алдына тезләнер идем»,— дип әйтеп әйткән имеш.

Таранов белән очрашканда, тагын бер нәрсә гаҗәпләндергән иде Иргалине: этнең эте дип йөргән офицерның үзгәрүе, бөтенләй икенче кешегә әверелүе. Менә йөре син канга сеңгәнне юып та, юнып та ташлап булмый дип.

Менә шулай тигез-такыр юлдан җил-җил атлап, туган авылына якынлашып килгәндә: «Әллә чыннан да Илья Олегович янына сугылып карыйммы икән?..» дигән уй туды да инде Иргалинең башында. Үзе үк аптырап калды. Нишләмәк кирәк, бата башлаган кеше саламга тотына ди бит. Бу уй торган саен ныгыды. Ә ник? дип уйлады ул. Нәрсә югалта соң ул? Нәүбәттән калганчы үләттән кал, диләр ич. Хәзер бит аның дөньясы шундый. Иргали бит элеккеге офицер янына хәер өстәп барырга җыенмый. Гомумән, андый түбәнсенүләр Иргалинең табигатенә ят нәрсә. Кала тикле калада берәр уңайрак эш табыша икән, шул бик җиткән. Төкерә ул нинди дер офицер кисәгенең үз алдында тез чүгүенә.

Бу уй торган саен күңелен ныграк биләде Иргалинең. Ә ник? дип уйлады ул кабат. Ишетмеш буенча белә ул: Клочкиннар черегән байлар ук булмасалар да, киң дәүләтле, бик хәлле тормышта яшиләр. Булмас димә, кулында шифаханә тикле шифаханә тоткан, бөтен губернага атаклы доктор ди бит.

Кыска гына вакыт эчендә башыннан әллә күпме уй үтеп өлгерде Иргалинең. Шул ук кичне ул күңелендә туган исәп-ниятен хатынына да чиште. Чишүен чиште дә, әмма тегесе иренең бу адымын хупларга бер дә атлыгып тормавын белдерде. Вакыйганың бик күптән булганлыгын, шуның өстенә әле патша армиясе «әфисәр»енә бәйле икәнен ишеткәч, тел яшереп тормады, бу эшне бер дә мәгъкуль күрмәвен ачыктан-ачык әйтте дә салды.

— Белмим шул, әтисе, тыныч башыңа хафа гына өстәп йөрүең булмасмы икән?

Иргали дәшмәде. Хатынының сүзендә дә хаклык юк түгел иде. Чыннан да, бик күп еллар үтте шул инде. Тарановны очратуына да ике елдан артык. Кем белә, өермәле-давыллы еллар Клочкиннарның да тормышын пыран-заран китереп ташлагандыр. Ярларына карап елга да агымын үзгәрткән кебек, алар да тормышларын заманага яраклаштырып корганнардыр. Ихтимал, шифаханәләре дә күптән инде үтүттер... Кем белә, элек-электән сәламәтлеккә туймаган Илья Олегович бәлки инде исән дә түгелдер...

Иренең күңеленә яңа хәстәр, моңарчы сизелмәгән гамь керүен, үзүзенә урын таба алмыйча изаланып, эчтән сызып йокысыз төннәр үткәрүен күреп, хатыны Гөлниса да үрсәләнде.

— Артык аһ орма, сиңа әйтәм, ходай кушса, бар да рәтләнер, җайга салыныр. Исән-сау булуыбызга шөкерана кылып яшәргә кирәк. Бер без генә шушындый хәлдә түгел бит, ил белән...

Иргали, без күрәсен кеше күрмәс дип, юлга җыена башлады. Ул көннәрдә күңеленең әрнүле дә татлы да ярсуын тоеп яшәде. Башкача булуы да мөмкин түгел иде. Нинди генә йөрәкле, гайрәтле булма, нәрсәгәдер өметләнгәндәй йөз суы түгеп, ничекләр итеп кеше бусагасын атлап кермәк кирәк? Һай-ла, авыр булачак! Ни бит белән: мин сезнең элек-

кеге денщигыгыз, ниндирәк хәлләр булганын хәтерлисездер инде дип барып сүз катмак кирәк? Дөрес, Иргали алай дип әйтмәс. Әмма Илья Олегович аның ниндирәк уй-ният һәм ниндирәк өмет белән килгәнен сизмәс дисеңмени!

Хәзер инде чигенү юк, сәфәргә икән — сәфәргә! Йөрәгенең ашкынуына да тәкате бетте Иргалинең. Күңеле белән ул инде күптән юлда. Чыннан да, болай өй кошына әверелеп кул кушырып утырсаң, берәү дә китереп бирмәс. Гайрәте ташып торган ир була торып, баш өстендә түбәң, теш арасына кыстырырга бер кабым икмәгең булмасын инде, ыстырам!..

Иргали Кама аша юл төшкәнен генә көтте. Ниһаять, ул көн дә килде. Әмма, хәерчегә җил каршы дигәндәй, юлга чыгарга дип кенә торганда, искәрмәстән көннәр бозылып китте, күз ачкысыз бураннар башланды. Төннәрен аеруча нык котырды, бөтен дөньяны томалап,чал ялларын җилфердәтте, урам якка аяк атларлык түгел иде: һәрнәрсә чайкала, ыңгыраша, гөрелди, хәтта, өй дер селкенеп торды. Бу хәл Иргалигә яу кырында йөргән чакларын исенә төшерде, баш өстеннән генә снаряд очып узган авазлар чыгарып улады әлеге буран.

Ниһаять, бураннар басылды. Таң белән сәфәргә. Төннең икенче яртылары. Өлкәннәрнең йокылары качты. Иргали иң әүвәл күн итеген һәйбәтләп каен дегете белән майлап, аяк чолгауларына төрде дә юл капчыгына салды. Аягына озын куныччлы тула оек белән чабата киде. Өй хуҗасы Зәйтүнәнең, каяндыр юнәтеп алып кайткан тегермән ташыдай олы ипиенең бары тик яртысын гына алды Иргали: юлга чыксаң — юлда тап, дигәннәр борынгылар.

Соңгы тапкыр киңәш-табыш тотып алдылар. Әйтәсе сүзләр күптән әйтелгән, биреләсе әмер-киңәшләр бирелгән иде инде. Шуңа күрә, Иргали хушлашу минутларын бик коры тотты.

— Ярар, бәгырьләр, хәер-догада тора күрегез. Юлларым уңса-уңмаса да, әллә ни озак көттермәм, тулы ай кебек балкып, әйләнеп кайтып та җитәрмен...

Иргали сәкене тутырып йоклаган балалар янына килде. Аларга нәрсә, әнә гамьнәрендә дә юк, таралышып, рәхәтләнеп йоклыйлар. И-и, кайгы-хәсрәтсез балачак! Күңеле тулыша башлаган әти кеше, иң әүвәл үзенең нәниен сөеп, аркасыннан каккалады. Янәшә яткан Миңсылу ятимәнең дә өстен рәтләгәндәй итте. Шулчак мизгел эчендә: «Юлларым уңа-нитә калса, беренче чиратта син ятимәнең өс-башын карар идем»,— дигән уй чагылып китүенә үзе дә гаҗәпләнде Иргали.

— Ярар, бәгырьләр! Хәерле сәгатьтә булсын...

Гөлниса озата чыкты. Яңа көн тууын белдереп, беренче әтәчләр аваз сала башлаган иде инде. Чатнап, зыңгылдап торган салкын иртә, сулу алуларга кадәр кыен, тын юлларын өтәләпме өтәли. Чабата астындагы кар, атлаган саен, әллә кайларга ишетелерлек булып шыгырдый, гүя кемдер артыңнан куа килгән кебек.

Басу капкасы янында туктадылар. Иргали, ак киндер тышлы бияләе белән шул арада бүрек колакчыннарын, шинель якасын, мыегын сарып өлгергән бәсне сыпырып төшерде дә хатынының иңенә кулын куйды.

— Ярар, әнисе, аллага тапшырдык. Бер күреп, бер әйләнеп кайтмыйча, барыбер җан тынмас. Бер тузгымый корт та тынмый ди бит.

Хатын-кызның, билгеле инде, мышык-мышык балавыз сыга башлады

— Карап кына... сакланып кына йөри күр инде, сиңа әйтәм... Хәвеф-хәтәргә юлыга күрмә.

— Куй, әнисе, ул кадәр хафаланма. Хәзергә хуш, сау бул!

— Хәерле юл сиңа, әтисе.

— Берүк, шулай була күрсен.

Иргали, җилкәсен сикертеп, аркасындагы биштәрен җайлагандай итте дә, житез-житез атлап, Чаллыга илтә торган олы юлда, чал томан һәм куе булып төшкән сыкы эчендә эреп юк та булды.

Иргали атлады да атлады. Уйлары үзеннән узып алга йөгерде. Кеше күңеле нәкъ көйсез көн кебек, бик тиз үзгәрүчән. Иргалинең дә жанын янә икеләнүләр, шик-шөбһәләр биләп алды. Чыннан да, нәрсә көтә инде аны кала тикле калада? Иргали, олы сәфәргә чыгарга санаулы минутлар гына калгач, янә бер хата ясады кебек: таралып йоклап яткан бәләкәче белән саубуллашып, аркасыннан сөйгәндә, Миңсылуга да күзе төште. Шунда, алда хәтәр билгесезлекләр көтүен белә торып, адарынып, әманәт-нәзер әйткән сыман итте. Үзенең зур хата эшләгәнен бары тик хәзер генә төшенгәндәй булды. Бу хәл аның чынлап торып җанын кыйный, җанын әрнетә башлады: әманәт уен эш түгел!

Шулай мең төрле уй-хискә бирелеп, җилкенеп-җилпенеп атлый торгач, шактый юл үтелде. Кунарга кергән фатирларыннан да ачы таң белән чыгып китте. Ике тәүлектән соң, көн төшлеккә авышканда, ниһаять, мәшһүр Казанга барып та керде.

Кая карама — халык дәрьясы, мәхшәр көне диярсең инде менә. Әрле-бирле йөренгән халыкны ерып үтмәле түгел. Олырак кибетләр тирәсендә үзе бер тамаша. Кая карама — таш пулатлар, ак диварлар, шунда ук байларның пассажлары, гөр килеп торган кибетләре. Шунда ук бизәнеп-ясанган байбикәләр, байбәтчәләр. Урамның урта өлешендә уенчык төсле матур, өрсәң кузгалып китәрдәй җиңел чаналарга җигелгән атлар. Үзләре каядыр соңга калудан курыккандай, ут капкан төсле чабалар. Ничек итеп бер-берсенә килеп бәрелмиләр диген син аларны.

Печән базарына якынлашкан саен, чәйханәләр, хәрчәүнәләр күбрәк очрый башлады. Әледән-әле бер ачылып, бер ябылып торган ишекләреннән бу бөркеп, тирә-юньгә хуш исләр таратып, һәркемне үзләренә чакырып торалар.

Иргали дә кеше азрак күренгән хәрчәүнәләрнең берсенә кереп, чәйләп чыгарга булды. Тамак ялгаудан бигрәк, аяк киемнәрен алыштырып, сакалын кырып, мыегын төзәтү иде нияте. Кыяк кебек үткен чалгы пәкесе белән беләве һәрчак үзе белән аның.

Иргали ишек катындагы буш өстәлләрнең берсендә урын алды. Иң әүвәл хәрчәүнә эчен күздән кичерде. Аңардан өстәл аша гына утырган бер төркем татар яшьләренә игътибар итте. Гөр килеп утырган әлеге яшьләр, өс-башларына, үз-үзләрен тотышларына караганда, укымышлы, ак сөяклеләр затыннан булырга тиешләр. Тавышлары да көр яңгырый. Бернинди тартынусыз кычкырып сөйләшәләр, вакыты белән башларын артка ташлап, шаулашып, рәхәтләнеп көлешәләр.

Иргали үзләрен ифрат та иркен тоткан әлеге яшьләрнең сүзләренә колак салды. Араларыннан берәве, нинди атаклы татар байгурасы ачкан «Болгар» дигән ресторанда иртәнге өчкә кадәр булуы, ниндидер Рәшидә туташның бик оста җырлавы, кемнеңдер милли биюләр белән чыгыш ясавын, соңыннан милли оркестрның ниндидер көй чыгаручының яңа әсәрләрен башкаруы турында бик тәфсилләп гәп сатты. Тыңлый торгач төшенде Иргали, татар байлары да, рус купецларыннан күрмәкче, төн буе сату итә торган милли рестораннар, «мөсафирханәләр», ашханәләр ачу кебек төшемле кәсеп белән шөгыльләнә башлаганнар. Менә НЭП дигән нәмәстә нинди ниләр китереп чыгарган дип уйлап куйды Иргали.

Тагын бер яңалык турында ишетте ул: завод-фабрикалар туктау сәбәпле эшсез калучыларга ярдәм күрсәтү өчен, хөкүмәт хезмәт биржалары оештырган. Бу биржаларда һәр профсоюзның үз бүлеге булып, алар үз әгъзаларын хисапка алу һәм хезмәткә урнаштыру буенча чаралар күрә икән. Әле гәп сатып, кәеф-сафа корып утырган яшьләр, ниндидер татар артистының хезмәт биржасында исәптә торуын телгә алдылар.

Ул арада Иргали аяк киемнәрен алыштырды. Чолгауларының җайлы-җайсыз уралуын белергә теләгәндәй, күн итекләре белән идәнгә типкәләп алды. Яшьләр җәһәт кенә аның ягына борылып, тынып калдылар. Әмма Иргали моңа игътибар итмәде, кулланылган савыт-сабаны җыештырып, өстәлләрне сөртеп йөрүче егеттән, бер стакан кайнар су сорап ал-

ды да, ишек янындагы юынгычлар янына юнәлде. Күз ачып йомганчы ялт иттереп кырынып та ташлады. Мыек чылгыйларын рәтләгәннән соң, үзен яшәреп киткән сыман хис итте.

Иргали һәйбәтләп юынып өстәле янына килгәндә, шау-шулы яшьләрдән җилләр искән, азык-төлек калдыклары һәм савыт-саба тулы өстәл янында, бары тик бер генә кеше утырып калган иде. Иргалине күздән яздырмаска теләгән бер кыяфәт белән утырган бу татар агай-эненең килде-китте кеше түгеллеген чамалау әллә ни кыен түгел иде. Өсбашы да затлы, кыяфәте дә укымышлы-зыялы кешегә охшаган. Алдында тәртипсез рәвештә ташланган газеталар ята. Күз карашлары үткер. Йөз-чырае да мөлаем. Ияк очында гына калдырылган җыйнак сакалы үзенә бик тә килешеп, йөз чалымнарына инсафлык, риясызлык өстәп тора иде.

Ахыр чиктә агай-эненең тәкате бетте ахрысы, һәрбер хәрәкәтендә көч-гайрәт, ашкыну; килеш-килбәтендә ихтыяр көче һәм әллә ниткән тынгысызлык ташып-бөркелеп торган солдатка мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр булды. Иргалинең кем булуы, кайдан, нинди йомыш белән Казан тикле Казанга килеп чыкканлыгы белән кызыксына башлады.

Иргали үз-үзенә чиксез ышанган бер кыяфәткә кереп җавап кайтарды. Әйдә, белсен солдатның кемнәр белән эш иткәнен. Кеше кайда да үз дәрәҗәсен саклый белергә тиеш.

— Менә ничарадан бичара хәленә төшеп, Казан каласы тарафларын бер әйләнеп кайту нияте белән килгән идем әле,— дигән булды ул. Әмма шундук, бу могтәбәр кыяфәтле кеше белән алай дорфа сөйләшергә кирәк түгеллеген бик тиз абайлап алды. Шундук төзәтенде. Нинди йомыш белән килүен яшермичә ачыктан-ачык сөйләде дә бирде һәм бик дөрес итте.

Доктор Клочкин исемен ишетү белән, әлеге зыялы кешегә охшаган агай-эне Иргали янына ук күчеп утырды.

— Бик беләм, бик беләм, афәрин,— дип элеп тә алды ул,— бик могтәбәр, бик затлы кеше. Доктор Клочкинның исеме мөселманнар дөньясында да зур хөрмәт белән яд ителә.

Иргали үзенә кирәкле кешеләр турында шактый ук тулы, кызыклы, берүк вакытта бик тә кирәкле мәгълүматлар алды. Хәтта, кай тирәдәрәк яшәүләренә кадәр белеште.

Һәм менә ул атаклы докторның ике катлы таш йортының баскычы төбендә тора. Ишекнең тоткасы җиздән, алтын йөгертелгәнгә охшап, елкылдап тора. Шунда ук әллә ни зур булмаган игълан тактасы. Аңа да шундый ук ялтырап торган хәрефләр белән бу йортта фәлән-фәлән атлы доктор яши дип язып куелган...

Иргали, өйнең зур-зур тәрәзәләренә кабат күз төшергәләп алды да, әллә ни биек булмаган, сырлап, чуеннан коеп эшләнгән баскычка күтәрелде. Менә ул сират күперен чыгуга тиң авыр минутлар. Я-а ходай, я-а мәрхәмәтсез язмыш, түземлек бир, сабырлык бир! Һай-й, бу кеше бусагасына килеп йөз ерту, йөз суы корытулары әҗәлләргә тиң бит!

Иргали ни булса шул булыр дип, ишеккә кагылды. Ул бикле иде. Караса — ишекнең уң ягында ак төймә. Шундук «звонок» дип язып та куелган. Иргали янә икеләнә калды, үзе турында хәбәр салырга кыюсызланып торды. Сүзне нидән башлыйсын, үзен ничегрәк тотасын мең дә беренче тапкыр күңелендә кабат яңартты. Һәрхәлдә, җаен белеп, дәрәҗәсен бик үк төшермичә, иң яманы — артык мескенләнмичә генә сөйләшер. Гомумән, Иргали кызгануны күтәрә алмый, үзен һәрчак мескенлектән өстен саный иде.

Ниһаять, тәвәккәлләде. Гәүдәсенең, тез буыннарының җиңелчә генә калтыравын тыярга тырышып, имән бармагы белән ак төймәгә басты...

Ишеттеләр. Ишекне ап-ак алъяпкыч япкан, түше яхшы ук күперенке бер мөлаем генә хатын-кыз ачты. Башына утыртылган биек какошка-




*Тавил Хаҗиәхмәтов рәсеме*

сын күрү белән үк: асрауларыдыр, дигән уй чагылып китте Иргалинең башында.

Иргали исәнләште. Горничная башын кагып җавап кайтарды.

— Миңа хуҗаларны күрәсе иде...— диде Иргали, тавышының ничектер калтырабрак чыгуын үзе үк сизенеп.

Коеп куйган зифа буйлы нәзакәтле яшь хатын башта иңбашын гына җыерды. Бары тик шуннан соң гына Иргали биргән сөальның мәгънәсенә төшенгәндәй, үз чиратында:

— Сезгә Олег Авдеевич кирәктер. Кызганычка каршы, алар өйдә юк. Кичке дүртсез булмаслар да,— дип җавап кайтарды.

— Миңа Илья Олегович кирәк иде,— диде Иргали, әйтер сүзен әйтеп бетерә алмаудан курыккан кеше сыман итеп.

Ыспай-сылу яшь хатынның җавабы кыска:

— Ул да өйдә юк.

— Кайда?..

— Службада.

— Һы-ы, алай икән. Кайчанрак өйдә була соң ул?

Асрауга охшаган хатын кабат иңбашын җыерырга мәҗбүр. Шулай да Иргалинең борыны төбендә ишекне шапылдатып ябарга ашыкмады. Заманасы шундый. Коралы булмаса да, аның каршысында көч-егәре ташып торган, шактый ук үткен карашлы, шинельле кеше, кызылармеец басып тора.

— Сез аның кеме буласыз? Йомышыгыз ни?

Иргали дә үз чиратында, сүз җебен өзмәскә тырышып, кайчандыр Илья Олегович белән бергә хезмәт иткәнлекләре турында аңлатырга тырышты. Дөрес эшләгән икән. Какошкалы ханым: «Хәзер хуҗабикәгә әйтим әле» — дип, Иргалине эчкә үтәргә чакырды.

Хуҗабикә каядыр барырга җыенган булса кирәк, киенгән-ясанган. Өстенә итәкләре идәнгә кадәр төшеп торган, яка-изү тирәләре ялтыравыклы укалар белән каелган күлмәк кигән. Муенына алтын чылбыр белән кыйммәтле ташлар куеп бизәлгән бәләкәй тартма сыман нәрсә асып куйган. Иң күзгә ташланганы — ут чәчәге бәйләменнән үрелгән таҗга охшатып, баш әйләнәсенә тыгызлап чорнап куелган аксыл-сары калын толымнары иде. Әлеге алтын таҗ сыман чәчкә күз салу белән, минем бу хатынны кайдадыр бер тапкыр инде күргәнем бар иң, дигән уй килүеннән Иргали үзе дә гаҗәпләнеп куйды. Шунда ук исенә дә төште: бу хатынны түгел, ә бөтен гәүдәсе, буй-сыны белән, кулына шаһлык таягы тоттырып ясалган «Әби патша» портретын күргәне булган икән.

— Сезгә кем кирәк?..— диде хуҗа хатын. Тавышы төксе, коры иде. Җитмәсә тагын, Иргалинең сәламен бөтенләй ишетмәгән сыман итеп, колагына да элмәде.

Бу хәлдән каушабрак калган Иргали, һушын җыя алмаган кеше сыман, әкрен, шул ук вакытта дәртсез тавыш белән үзенең Илья Олеговичны күрергә теләге барлыгын белдерде.

— Сез аны кайдан беләсез?

Бер урында таптанып торган Иргали, башта бергә хезмәт итүләре турында аңлаткандай итте, аннары барысына да берьюлы ачыклык кертергә теләгәндәй итеп:

— Мин аның денщигы идем...— дип өстәп куясы итте. Һәм шушы саксызлык белән ычкындырган бер кәлимә сүзе бөтен нәрсәне җимерде дә ташлады.

«Әби патша»га охшаган хуҗабикәне алыштырып куйдылармыни! Бөтен йөреше-торышындагы нәфислекне, затлылыкны җил тузгытты диярсең.

— Нинди ахмак сүз сөйләгәнегезне аңлыйсызмы сез?!.— дип җикеренде хуҗа хатын, күзләреннән чаткылар чәчрәтеп. Бу ошбу яман сүзләрне кеше-фәлән ишетмәдеме, дигән сыман як-ягына каранып алды. Аннары Иргалине исенә китерергә теләгәндәй, йөзен-кашын җимереп, зәһәрен көчкә-көчкә генә тыйган хәлдә, тезде дә тезде.— Бу заманда

нинди денщиклар булсын ди, дивана бәндә!..— Шунда ук тегеләй-болай уйларга урын калдырмаслык итеп өстәде.— Минем ирем — Илья Олегович Клочкинның һичкайчан да денщик тотканы булмады. Минем ирем, минем Илюшам, эшче-крестьян Кызыл Армиясендә кызыл командир булып хезмәт итте. Яшь Совет иле өчен җан аямыйча, фидакарьләрчә сугышып кан койган кеше...

Һай-й, бу беркатлылык! дип уйлап куйды Иргали, йөрәгенә гүр салкыны иңә башлавын тоеп. Хуҗа хатынны «денщик» сүзе шулай чыгарыннан чыгарыр дип бик соң абайлап алды шул. Аны ачыну, үкенү хисе яңа көч белән биләп алды. Һай-й, тинтәк җан! Һай-й, беркатлы тилемсә! дип сүкте ул үзен. Эче сыкравына чыдар чамасы калмады. Күр инде, ә! Чак кына, пыскып кына янган өмете дә, шул ялгышлык, хаталану белән ычкындырылган бер сүз аркасында, кинәт пыран-заран килеп гөлт сүнде дә куйды... Шул ук сүзне: янсакчы, ягъни, йомышчысы, дип йомшартыбрак та әйтергә мөмкин булгандыр лабаса. Заманы, заманы шундый бит аның. Кем белә, әле Илья Олеговичның та, әгәр дә мәгәр очрашанитә калсалар, күрмәмешкә салынуы ихтимал...

Иргали муенындагы ниндидер бер кан тамырының тынгысызланып бии башлавын тойды. Ул шул бимазалаган тамырдан котылырга теләгәндәй башын иде, шинель якасына ияген ышкыштырып алды.

Инде кылдай нечкә җепкә генә асылынып торган өмете менә-менә өзелә дип торган арада хуҗабикәнең күңелендә миһербанлык туды ахрысы. Ул бик әһәмиятле нәрсә исенә төшергәндәй, бермәлгә тынып калды һәм, катгый-кырыс тавышын чак кына йомшарта төшеп, янә сөаль бирде.

— Кайчанрак бергә хезмәт иттегез соң? Илья Олегович белән дип әйтүем...

— Күптән инде, революциягә кадәр үк,— диде Иргали, теле көрмәкләнүен тоеп.

Хуҗабикә солдатның бу сүзләренә бөтенләй игътибар итмәгән бер кыяфәттә стенага эленгән телефон янына килде. Боргалаганнан соң, ниндидер учреждениене сорады. Әмма анда иренең юклыгын әйттеләр ахрысы.

Сынаган сыман итеп өстән аска карап торганнан соң, Иргалигә: хәзергә, әнә шунда утырып торыгыз, дип кием-салым шкафы янындагы сыңар креслога күрсәтте дә үзе каядыр түрге бүлмәләр ягына китеп барды.

Бераздан телефон шалтырады. Иргалине күздән яздырмауны максат итеп куйгандай, шул тирәдә чуалган горничная, җәһәт кенә йөгереп килеп, телефон трубкасын алды.

— Әйе... Хәзер, хәзер Илья Олегович!.. Хәзер чакырам...— Ул шунда ук ут капкандай: «Ксения Семеновна!.. Ксения Семеновна... Сезне Илья Олегович дәшә»,— дип, хуҗабикә кереп киткән ишек ягына аваз салды.

Телефон трубкасы хуҗабикә кулында.

— Әйе, Илюша, мин шалтыраткан идем...— дип башлады ул сүзен. Аннары Иргали ягына кырын караш ташлап, чак кына арты белән борылды да, тавышын әкренәйтә төшеп, дәвам итте: — Безгә ниндидер бик сәер бер солдат килеп керде. Әле дә бездә... Сине күрәсем бар, ди. Сүзләре бик сәер... Кайдадыр, кайчандыр синең денщигың булып хезмәт иткән имештер. Нәр-сә?..

*Дәвамы бар.*

# ТУГРЫЛЫК



Хисам Камалов иҗатын чорларга бүлеп каравы кыен. Күргәнне һәм кичергәнне рәттән сөйли баруымы бу? Әллә күңел көндәлегеме? Борчылудан һәм юатудан, сагыштан һәм шатлыктан тора аның лирикасы. Шагыйрьнең укучысы белән күзгә-күз калып эч серен уртаклашуы, мөгаен, шулай буладыр.

Аның шигырьләре һәм поэмалары тормыштагы урының, кыйблаң турында уйландыра. Бу шигъри дөньяда вакыт агышын, дөнья үзгәрешләрен ачык тоясың, аның бөтенлегенә һәм чынлыгына ышанасың. Шагыйрьнең лирик герое иң авыр сынауларны кичкәндә дә сынмаган, көрәш сукмагыннан тайпылмаган. Аның хис-тойгылары саф һәм тыйнак, үзәк өзгеч дәрәҗәдә чын. Беренче шигырьләрендә үк билгеләнгән шушы юнәлешкә Хисам Камалов һәрвакыт тугрылыклы кала. Бөтен иҗаты белән. Бөтен яшәеше белән.

Хисам Нуретдин улы Камалов 1926 елның 14 апрелендә Татарстанның Әлмәт районы, Кама-Исмәгыйль авылында крестьян гаиләсендә туа. 1941 елны үз авылында җидееллык мәктәпне тәмамлый. Аннары колхозда ат караучы булып эшли. Яше тулар-тулмас фронтка китә. «Суслонгерда берничә ай хәрби өйрәнүләр үткәч, безне туры алгы сызыкка — 2 нче Балтик буе фронтының Пушкин таулары дигән урынына китерделәр. Ә 1944 елның июль аенда инде, зур һөҗүмгә күчеп, берничә каланы алдык. Әмма, Латвия чиген үткәндә, мине беренче мәртәбә дошман угы җиргә егып калдырды. Госпитальдән чыккач, Латвияне азат итү сугышында катнаштым. Танкка каршы ата торган 76 мм лы пушка батареясында элемтәче булдым. Шул чакта икенче мәртәбә авыр яраландым. Миңа нибары 18 яшь иде...»

Ел ярым гомерен госпитальдә уздыру да, бер аягы ампутацияләнү дә яшь егетнең рухын сындыра алмый. Госпитальдә алдагы көннәргә әзерләнә: хисапчы һөнәрен үзләштерә. Тормышка, кешеләргә ышанычы яңара, бала чактан ук күңелендә яткан хыяллары уяна. Менә инде ул — Бөгелмә педагогия техникумы студенты. Аннары — Казан педагогия институты. Шуннан соң унҗиде ел Татарстан китап нәшриятында редактор булып эшли.

Бер караганда, тормыш үз эзенә төшкән кебек тә була: сугыш калдырган яралар да эш арасында онытылып тора сыман. Әмма фронтовикның күңеле тынычлык тапмый: илебез азатлыгы өчен яу кырында һәлак булган иптәшләре, башыннан кичкән дәһшәтле көннәр тынгылык бирми аңа. Яшь шагыйрь кулына каләм ала. Беренче шигырьләрендә — сугыш калдырган яралардан әрнү-көенеч һәм яңадан сафка кайту сөенече. Шуңа күрә беренче җыентыгы да — «Яңадан сафка».

Солдат-шагыйрь үзенең иҗаттагы сугышчан бурычын яхшы аңлый. Ул тормыш күренешләренең бик табигый, әмма башкалар күзенә чалынмаган мәгънәләрен эзли. «Газапларга баеп, шатлыкларга саранланса да», әсәрләрендә ул язмышның якты сәхифәләрен ача, укучыны дөньяның кояшлы якларына чакыра.

Юк, канатлары каерылган, басынкы һәм нечкә күңелле кеше күзләре белән тормышка карау җиңел түгел. Аның бик тирәндә яткан рухи көчен тиз генә абайлап өлгермисең. Әнисе кебек үк: «Үзе юаш, үзе тәҗрибәсез, ничек калсын шушы мәхшәрдә?..» — дип чын күңелдән борчыласың... Шулай да гаҗәп бит: шигырьдән-шигырьгә күңелдәге образ ачыклана, зурая, куәтлерәк була бара. Аның газаплванулары да, ихлас шатланулары да сафландыргыч бер ташкынга әйләнеп, безне бөтереп ала.

Заманыбызның яңа күренешләре, кешеләр арасындагы яңа мөнәсәбәтләр турында уйланулар Хисам Камалов иҗатының сулышын киңәйтеп җибәрә. Утлар-сулар кичкән шагыйрьнең бүгенге чыабарлыкка үз карашы бар. Ул әле дә дөньяга авыр елларның канлы-кызыл офыгы, дары исе сеңгән һавасы аша карыйдыр сыман. Заман темасына язылган әсәр-

ләренең драматизмы һәм кешелекле пафосы да шуннан килә: «Шәфкатьлелек арта кешеләрдә». Сугышта үзен «юлбарыстан көчле» итеп күрсәткән халыкның тыныч тормышта да каһарманлык елъязмасы дәвам итә. Иген үстергәндә, нефть ятмалары ачканда, автомобиль һәм энергетика гигантларын күтәргәндә... Шушы сәхифәләр буйлап килә шагыйрь, «Әлмәт эскизлары»н һәм КамАЗдан шигъри репортаж — «Язмыш елмаюы»н иҗат итә, сугыштан соң халыкның тормышында, эчке дөньясында булган үзгәрешләрне аңларга һәм аңлатырга омтыла.

Хисам Камаловның барлык әсәрләре нигезенә үз тойгыларын, үз күзәтүләрен салуы сизелеп тора, ул иң мөһим мизгелләрдә үзен дә шул геройлары арасында хис итә. Бу табигыйлек укучының да күңелен кузгата, тетрәндерә.

Сугыш тәмамланып утыз-кырык ел гомер узгач, Хисам Камалов сугыш турында ике роман язды. Дөресрәге — сугыштагы кешеләр турында. Моны романнарның исемнәре үк расләп тора: «Һәркемнең гомере бер генә», «Безне өйдә көтәләр». Бу әсәрләр кырыс язмышлы кешеләр матурлыгын шагыйранә тасвирлавы белән үзләренә җәлеп итәләр, адәм баласының рухи көчләрен, күңел төпкелендә яткан иң яшерен хисләрен яктыга чыгаралар. Романнарда сурәтләнгән мәхәббәт хисләре дә әнә шундый — окоп читендәге чәчкә кебек гүзәл һәм фаҗигале... Батырлык һәм Ватанга тугрылык сыйфатларын Хисам Камалов үзенчә, конкрет һәм тыйнак төсләр белән сурәтли, сугыш дөреслеген яңа якларыннан ачарга омтыла. Аның әсәрләрендә совет халкының массовый героизмы, халыклар дуслыгы темалары матур лейтмотив булып яңгырый.

Иҗат үсешенә Бөек Ватан сугышының гаять зур тәэсирен һәрвакыт тоеп яшәгән Хисам Камалов үзенең яңа әсәрләрендә дә тормыш дөреслегенә тугрылыклы кала. Аның китапларындагы хакыйкать, еллар узган саен, җетеләнә, зурая, укучыга якынрак була бара.

# Хисам Камалов,

Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге
Дәүләт премиясе лауреаты

## Көчәйткеч

Эшләп чыгаруны көчәйтергә!
Барча егәрләрне өчәйтергә:
Гектар уңышын да күбәйтергә!
Мал-туарны тагы ишәйтергә!
Кимчелекне бик тиз төзәтергә!
Исрафларны кискен әзәйтергә!
Изге ният, изге тырышлыклар.
Яшәүне шул тырышлыклар аклар:
Һәр яшерен көчне эшләтергә!
Исәп-хисап белән эш итәргә!
Әмма тиеш дөрес сүз әйтергә:
Намусны да кирәк көчәйтергә!
Көчәнмәсә намус — тырышулар
Ул максатка бик әз булышырлар...

Шул хакта гәп бара җыелышта,
Җаваплылык тоела бу эштә.
Тик сөйлиләр сәбәпләр күп өеп,
Сәбәп ышыгына поса биреп.
Тайпылалар я бу, теге якка.
Калырмын дип уйламый да оятка.
Боргалана сүзе сулга, уңга;
Сайланмаган намус президиумга!

Сүздән эшкә күчү мәле килде:
Сүздә, эштә бер бул, нык бул инде!
Намус булсын үлчәү барча төштә:
Намус үзе иң зур көчәйткеч лә!

## Агроном

— Мин — «конкрет кеше»,— ди агроном,—
Бер дә сөймим гомум, буш сүзне:
Эш урнына сүз боткасы ясап,
Ялкаулана торган сөмсезне!
Соң чәчәсең диләр. Тагы шелтә
Чәпәделәр, шуңа җан көя:
Нигә соңлыйм? Авсюг тишелсен, дип,
Көтәм. Ясыйм провокация:
Баш тибүгә, тырмалыйм һәм чәчәм
Чиста җиргә, чүп тә күп кими.
Чүпкә хәтле бодай калкып чыга,
Солычага инде хут бирми.

Аның белән шулай көрәшмәсәң,
Уңыш булмый, күпме тырышма.
Ул бит бәла! Провокация ясап
Ирешәм тик һәр ел уңышка.
Ләкин эшкә җиңел караучылар
Формализм белән табалый:
Кыр эше бит завод эше түгел,
Схемалар анда ярамый.
Җир ул ана һәм гел бала кебек.
Һәр үсемлек бер җан иясе:
Вакытында карау кирәк аңа,
Тәрбиясе һәм дирбиясе...

Уракка да соңрак төшәм — шелтә!
Хатын сизә йөздән: түз, дия.
Һәм балалар сизә. Әти, диләр,
Ачыйк маллә шелтә музее?
Шаяруга боргач, күңелдәге
Начар юшкын бетә, юыла.
Шелтәләрдән башка бер рәхмәт тә
Булмас иде кебек тоела...

...Бер шелтәсез калып булмаса да,
Тик калган юк әле уңышсыз.
Уңыш — бүләк тир түгүең өчен,
Шунсыз яшәү булыр йогышсыз!
Шелтә нәрсә?! Без өйрәнгән аңа,
Хатын сизеп, тагын: түз, дия.
Ә балалар: әти, безнең өйдә
Ачыйк, диләр, шелтә музее?

## Җир шары

Чиксез киңлектә Җир шары
Тиз-тиз әйләнә юл ярып...
Космоста ул бик кечкенә —
Космоста ул — бильярд шары!
Әйләнә утлы эз салып,
Йомыры бер җисем бары,
Зәңгәр киңлектә тәгәри
Космосның бер бильярд шары!
Кем суга аңа ни белән?
Кем суга аңа кий белән?
Сугулары бик комарлы —

Әллә нинди үчле-зарлы...
Һәркем үзе ятьмәсенә
Төшерергә итә шарны.
Ә беркемнең ятьмәсенә
Төшмичә ул читкә тайса?
Һәм барып бәрелсә Айга?
Уен яман кыза бара:
Отарга, фәкать, отарга!
Суккалыйлар бире, ары
Космоснын бу бильярд шарын!

## Борын заманда

Борын заманда бер тиран булган.
Бернидән дә куркып тормаган.
Курыккан тик фикерләрдән генә,
Фикерләрне шуңа күп буган.
Һәр фикердән, сүздән курка икән,
Бүредән курыккан куяндай.
Һәр тәгъбирдә букәй утыра гүя
Урыныннан чөеп куярдай.
Фикер — бәла, чөнки һәр фикердән
Ниндидер бер хаклык баш тертә.
Менә шуны бер дә җене сөйми,
Шуңардан ул бигрәк нык өркә.
Һәр көн иртән аңа китерәләр:
Кемнәр нинди фикер, сүз әйткән...
Ул тикшерә, фараз итә барсын,

Астында соң моның ни яткан?
Сүзләр нигә төби, ни ишарә?..
Лупа аша капшап үткәрә...
Әгәр сизсә бер-бер хакыйкатьне,
Ачуыннан бүртә, күгәрә.
Тирги башлый шул бер фикердарны:
«Ник маташа инде, бичара!?
Тик үзенә начар булачак бит!
Аңламый бит шуны, шишара!
Үзе утырган ботакка бит чаба!
Юлын бүлә теле! Юк бер эш!
Иптәшләре әнә бүләк алды,
Ә аңарга булды тик кукиш!
Шәйләми бит адәм баласы,
Үзенә ала акыл бәласе!..»

## Көз көне

Көз инде бу. Көн дә томан төшә,
Оренбур шәледәй соры ул.
Куе томан ерып барган чакта,
Алдан шәйләп кемдер саба юл.
Бер «Беларусь» кырга чыгып килә,
Ера-ера томан кисәлен.
Ә тавышы ишетелә, гүя
Су төбеннән — тонык-күксәүле.

Якынлашкач, кыяфәте калка —
Гигант чикерткә күк! Бик сәер:
Үзеннән зур арба тартып бара,
Ә арбада кызлар һәм бер ир.
Килә алар бәрәңге алыр өчен.
Һәм «Беларусь» тага сукасын,
Ерып китә, сибелә җир алмасы —
Өзгән сыман җирнең путасын.

«Алмалардан» яктырды җир бите.
Керештеләр кызлар җыярга.
Көлешәләр, яшьләргә эш ни ул —
Белми көчне кая куярга.
Томан аша кызлар аквариумда
Кызыл балык сыман тоела.

Шыркылдыйлар, тракторчы сүзен
Һаман саен борып уенга...
...Ә йокылы кояш әкрен генә
Алга манды томан-пәрдәне.
Һәм тавышлар ишетелә барды —
Торган саен җете-ядрәле.

## Шатлыктан

— Күз өстендә каш иде,
Бар җирдә ул баш иде,
Бар җирдә ул власть иде,
Көчле берни булмас иде,
Шешә баш — шабаш иде.
Дустан да ул өстен торды,
Туганнан да өстен йөрде,
Күпме гомерне бетерде,
Күпме өметне үтерде.
Күпме гаиләне аерды,
Күпме канатны каерды,
Күпме күз яшьләре койды,
Күпме бәхетләрне кыйды!..
Шул гыйфрит бетерелде —
Патша төшерелде...—
Ди-ди кыйный бер хатын
Уклау белән буш шешә.
Балалары көлешә...

Ире аек, карап тора,
Алар белән килешә.
Тик нигә йөзе кыек?
Болар шат, аңа кыен...

Бригадир аек, тик чытык,
Тешен кыскан, яңак чыгынкы.
Председатель, уена калып,
Елмая астан тыенкы:
Әле күрербез, дөнья ул!
Өскә ниләр төшәселәр...
Әтисе үлгән баладай,
Ятим карый шешәчеләр.

Хатын-кызга бәхет иңгән,
Хөкүмәткә рәхмәт, диләр.
Аек күзләр, аек сүзләр,
Аек эшләр рәхәт, диләр.

Яралангач,
Начар хәлем күреп,
Җәлләделәр әйбәт кешеләр.
Һәм үлемнән йолды алар җәлләп...
Күбрәк булсын шуның ишеләр!
Җәлләү кешене, имеш, кимсетә, ди.
Мәгънәсез һәм уйсыз ул сүзләр!
Хәлгә керү ничек кимсетсен соң:
Мең игелек тулы нур-күзләр.
Салкын җаннан булсын ни игелек?
Хиссез кеше була някъ өрәк.
Беркемне дә җәлләмәгән адәм —
Кеше сөйми торган таш йөрәк!
Һәркемгә дә эш бүленгән, көчең
Бу катлаулы чорга бирәсе...
Тазалар да кайчагында әле
Сорый җәлләү дотациясе.

# Ринат Мөхәммәдиев

# АЧЫК ТӘРӘЗӘ

хикәя



Җәй башы иде. Якты Яр пристанена теплоход килеп туктады. Аннан ашыга-кабалана пассажирлар төшә башлады. Кунакка кайтучылар байтак икән, олы-олы чемоданнарын күтәреп, сабыйларын житәкләп иң элек алар ашыкты. Ыгы-зыгы башланды, бер-сен икенчесе уздырып куанышу, хәл белешү, күрешү китте. Кулларында машина ачкычларын әйләндерә-бөтерә йөренгән ир-атлар күзгә чалынды. Траптан күтәрелгән сабыйлар әби-бабаларының кочагына менеп кунаклый барды.

Тирә-юньдә яхшы исәптә йөргән ял йорты да бар Якты Ярда. Яңа алмаш килгән көннәр иде. Ниһаять, ял итәргә килүчеләргә дә чират житте. Жыйнак кына чемодан-сумкаларын күтәреп, пристаньга аяк басуга ук, Кама буеның чиста рәхәт һавасыннан авыз итәргә ашыгып, алар бер тын, күкрәкләрен киерә төшеп, як-якларына карангалап тордылар. Кулларына кармак саплары һәм кәржин тотканнары да байтак иде. Якты Ярның балыкка, җиләк һәм гөмбәгә бай як булуы яхшы мәгълүм.

Траптан иң соңгы булып ике кулына ике дәү-дәү чемодан аскан яшь бер ханым чыкты. Тел очына килгәнгә генә әйтү, әле аны «ханым» дип атарга иртәрәк тә булса кирәк... Шулай итеп, теплоходтан иң соңгы булып әлеге кыз чыкты. Траптан төшүе булды, шундук, котылдым дигәндәй, ике чемоданын берьюлы шап итеп бетон идәнгә куйды ул. Кызның аккош мамыгыдай йомшак beләкләре, биек үкчәгә берегеп үскән туры аяклары, билгеле инде, табигать тарафыннан мондый чемоданнар күтәрер өчен яратылмаган. Ул, иркен сулыш алып, сынын турайта төш-те, иңбашына аскан нәни сумкадан көзге чыгарып, күзен-кашын төзә-тенергә кереште. Балан тәлгәшедәй ялтырап торган иреннәрен ипле генә кыймылдатып алды. Маңгаена төшеп торган чәч бөдрәләренә авыз читеннән генә өреп, көзгеле кулы белән янә нәни сумкага үрелде.

Ул да түгел, теплоход өченче гудогын биреп кузгалырга итте. Як-ягына карангалап торган кыз янына килеп, берничә ир-ат бер-бер артлы, үзләренең булышырга әзер булуларын белгертеп, тәкъдим ясарга өлгергән иде инде. Әмма кыз сүзсез генә, күз карашы белән, үзенең алар ярдәменә мохтаж түгеллеген аңлату сәләтенә ия булып чыкты. Баш түбәләре такырая төшкән кавалерлар берәм-берәм читкә тайпылырга мәҗбүр булды.

Пристаньның икенче бер читендә, теплоходтан төшүчеләрне күзәтеп, баһадир сынлы егет басып тора иде. Әлеге кыз трапта күренүгә үк йөрәге

жилкенеп тибә башлаган иде аның. Ләкин кабаланмады, ашыкмады. Якты Ярда яшәгән кешe буларак, ул тәҗрибәлерәк, кайчан ни эшләргә кирәклеген башкалардан яхшырак белә иде. Өлгерлек күрсәтергә теләп кабаланган ир-атларның кыз янына ничек килүләрен һәм ат өстеннән мәтәлгән җайдаклар сыман китеп баруларын ул куе кара мыек астыннан елмаеп кына күзәтте. Һәм, ниһаять, авызындагы фильтрлы сигаретны тел очы белән генә суга чөеп, юлбарыс адымнары белән атлап китте.

— Сәлам! — диде ул, кыз каршына ук килеп туктагач.

Ә кыз исә бер тынга каушап, югалып калды. Тәненә сыланып торган джинсы чалбар һәм футболка кигән бу егет аңар кемнедер хәтерләткән кебек булды. Егетне күрүгә үк аның күзләренә якты нур йөгерде, әллә нидән генә ирен читләре тартышып куйды. Озын гәүдә, киң күкрәкләр, елга җилендә каралган кырыс йөз һәм килешеп торган чем кара мыек дисеңме... Кыска җиңле футболкадан шампан шәрабы шешәләредәй ташып чыккан ул таза беләкләрме... Кинәт күзләрендә кабынган очкынны күпме генә яшерергә тырышмасын, булдыра алмады кыз. Хәтта әле бераз елмая да төшеп җавап кайтарды:

— Сә-лам...

— Ял йортынамы?

— Әй-йе...

— Киттек!

Егет, бармак очларына гына элеп, ике кулына ике чемоданны күтәрде һәм эре-эре атлап биек бачкычка таба юнәлде. Кыз, телен йоткандай, берни дәшмәде, житешер-житешмәс терт-терт атлап егет артыннан ияргүдән башка чара калмаган иде.

Ике баскычны бер атлады егет. Тау өстенә менеп, ял йорты капкасыннан кергәч тә әле байтак бардылар.

— Сезнең корпус,— диде егет, чемоданнарны биек наратлар белән уратып алынган агач дача бусагасына куеп. Йөгереп диярлек атларга мәҗбүр булган кыз, әлсерәүдәнме, берни әйтә алмады, аңлашылды, дигәндәй баш кына кагып куйды. Ул әле һаман үзенең табигый халәтенә кайта алмый аптыраган хәлдә иде. Хәер, кайту өчен вакыт һәм мөмкинлекнең булганы да юк бит әлегәчә. Әллә каян гына килеп калыкты да өермә сыман үзе артыннан ияртеп тә китте бит бу егет.

— Рәхмәт,— диде кыз, булдыра алганча житди итеп.

Егет, үзенең китәргә җыенуын белдереп, кул суздьı. Магнит белән тарттылармыни, кыз үзе дә сизмәстән кулын бирде.

— Альбинос булам. Кичен танцада очрашканга кадәр.

— Альбиноза... Арылган, танцага җыенмыйм.

Егет борылып китеп тә барды. Кызның соңгы сүзләрен ишеттемеюкмы, аңламассың. «Менә синә авыл...» — дип, үзалдына башын чайкап калды аның артыннан кыз. Гомер булмаган, күрмәгән хәл иде бу — аны бар дип тә белмичә, ир-ат үзенекен итеп маташа. Горур, имеш, булмагаең, андыйларны гына беләбез. Карарбыз...

Шулай да кичен, көттереп кенә булса да, соңарып кына булса да чыкты Альбиноза танцага. Чыкмый булдыра алмады. Альбинос аңардан нәкъ биш минутка кичегебрәк килде. Килгәч тә әле бер тын кызны бөтенләй күрмәгәнгә сабышып йөрде. Ул монда күпләрне таный икән, аны да беләләр. Егетләр үзе белән бер-бер артлы кул биреп исәнләшеп чыкты. Күрәмсең, барысы да биредәге егетләр, авылныкылар иде. Һәм алар арасында Альбинос шактый гына авторитетка ия күренә. Егетләр өелешеп торган почмакка карамаска ничек кенә тырышмасын, Альбиноза барын да чамалап торды. Ара-тирә үтеп торган кызлар да, күлмәк җилләре артыннан, егеткә бер чеметем елмаю калдырырга онытмады.

«Ярар, күрсәтермен әле мин сиңа!» — дип кабатлады Альбиноза үзалдына. Егетнең шулай битараф кылануына ˋҗен ачулары чыккан иде аның. Ләкин, Альбиносның урыныннан кузгалып болайга таба килә

башлавы булды, күңеле җилкенергә, күкрәкләре дөньяны тарсынып тибәргә кереште... Үзе дә абайламастан, егеткә каршы талпынырга да өлгергән иде булса кирәк... Ә Альбинос аның белән янәшә басып торган икенче бер кызны кочагына алып биергә, боргаланырга кереште.

Егетнең бу кыланышы шулкадәр көтелмәгән иде ки, хәтта бер тын дөньяны яңгыраткан музыканы колагы ишетмәс булып торды Альбинозаның. Бөтен кеше аңар карый, аның кимсенүен, аның гарьләнүен күзәтеп торадыр сыман тоелды. Чарасыз калудан нишләргә белмичә, әле чәчләрен төзәткәләгән булды, әле ут булып янган колак очларын тоткалап алкаларын барлагандай итте. Җир ярылса, ике дә уйлап тормаслык хәлдә калды түгелме соң... Инде бары бер юл калган иде — кеше-кара күзенә артык чалынмыйча шыпырт кына чыгып шылу. Шуңарга кыюлыгы җитсә, бу «авыл мокытын» бар дип тә белмәс, чыраена да борылып карамас иде бүтән.

Тартылган җеп өстеннән үткәндәй туры атлап, чалулый-чалулый чыгып китте Альбиноза. Махсус шулай үтте. Үзе артыннан карап калган ирләрнең карашын тоюдан аның күңеленә җылы, хәрәкәтләренә ышаныч иңде. Йөзенә кичке Кама җиле килеп бәрелде, баш очында йолдызлы зәңгәр күккә ашкан наратлар шаулады. Ял йортының бер очыннан икенчесенәчә сузылган туры үзәк аллея буйлап китте ул. Булдыра алганча тизрәк барырга тырышты. Үзен мыскыллаган сыман яңгыраучы дәртле бию ритмнарыннан ераклашырга ашыктымы, әллә артыннан егет иярер дип курыктымы... Әллә соң ул аның йөгереп куа килүен көттеме? Ике яктан тезелеп киткән чәчәк түтәлләренә дә исе китмәде, ара-тирә очрап торган ирләрнең сүз кушарга итенүләрен дә колагына элмәде. Капкага барып терәлгәнче артына ник бер тапкыр борылып карасын!

Альбиносның куа киләчәгенә һич шиге юк иде аның. Әнә шул капкага җиткәнче куып җитәчәге, һәм куып җиткәч тә ни дип эндәшәчәгенә кадәр мәгълүм сыман иде аңарга. Ул аның кире борылгач каршысына очравын түгел, ә нәкъ менә артыннан куып җитүен теләгән иде. Ә егет күренмәде. Кире борылып кайтканда да каршысына очрамады — монысы инде кызның башына сыймады. «Ничек шулай мөмкин?!» — дип гаҗәпләнде ул, ир-ат токымында булмаган хәл ич бу. Альбинозаның китеп баруын күрә торып шулай кылансын инде, ә?!

Бүлмәсенә кайткач та ялгыз башын кая куярга белми иза чикте ул. Форточкадан кергән һаваны азсынып, тәрәзәсен киереп ачып куйды. Тәрәз төбенә үк килеп төнке караңгылык аша кошлар тавышын, урман сулышын, дулкыннар шавын тыңлады. Таңга кадәр күзләренә йокы кермәде Альбинозаның. Мендәрен кочаклап та ятып карады, башын мендәр астына яшерүдән дә файда чыкмады — гомер булмаган тынгысызлык биләп алган иде кызны. Берничә мәртәбә урыныннан торып, зур көзге каршына килеп озак-озак кына үзен күзәтеп торды... Элеккечә үк бары да үз урынында иде югыйсә. Күпме ир-атны әйләнәсендә кош булып сайрарга, каршысында аю булып тезләнергә, бөркүдән әлсерәгән бәрән сыман дөньяларын онытып артыннан ияреп йөрергә мәҗбүр иткән матурлыгы була торып, шулай ялгызлыктан тинтерәсен инде! Кешегә әйтсәң, кеше ышанмас — булмаганны...

Альбинозаның Якты Ярга беренче килүе иде. Иртәгесен ашагач-эчкәч, ясанып-төзәтенгәч, ул әйләнә-тирә белән танышырга исәп итте. Ял итүчеләрнең күбесе яр буена ашыга иде. Кемдә нинди кайгы бит: берәүләр ком өстеннән уңайлырак урын алып калыйм дип кабалана, икенчеләрнең нияте — прокатка көймә эләктерү. Кармак сабы тотып йөрүчеләрнең уенда — иң эре балыкны каптыру, ә кәрҗин тотканнары җиләкле аланнарга беренче булып барып җитәргә ашыга. Альбинозаны боларның берсе дә кызыксындырмый, аңа, тегe, кем әйтмешли «до лампочки» боларның һәммәсе. Көне буе ком өстендә аунап, аккош мамыгыдай йомшак тәнен каралтуга исе китте ди... Диңгез дулкыны

төсендәге кимоносын шул көе генә киеп, биек яр читләтеп атлады Альбиноза.

Югарыдан Кама һәм аның аръягындагы күлләр, болынлыклар уч төбендәгедәй ачык күренә. Иркенлеккә, киңлеккә сокланып туймаслык. Елганың урта бер җиреннән, кызның болай да җилкенгән, ашкынган күңелен алгысытып, су өстенә тияр-тимәс йөзеп «Метеор» узып бара. Аның артыннан бөтерелеп калган су өстендә куыша-куыша акчарлаклар уйнаклый. Гомерендә беренче тапкыр үзенә рәссамлык сәләте бирелмәгәнгә офтанып куйды ул шунда. Югыйсә, кечкенә чакта әнисе өч елга якын шәһәрнең икенче почмагындагы художество мәктәбенә йөрткән иде аны. Ә ул яратмады, әнисе шулай теләгәнгә генә йөрде. Һәм соңыннан барыбер үзенекен итте — ташлады ул мәктәпне.

Ял йортыннан инде шактый ерак кителгән иде. Нарат агачларын юкә һәм каеннар алмаштырды. Текә яр читендә үк үскән ялгыз ак каенга килеп сөялде ул. Яшь һәм зифа чагы иде каенның. Үзенең дә шул каен сыман зифа һәм матур булуын тою рәхәт иде кызга. Тик шулай да әлеге каендай текә яр читендә үк үсәсе, торасы килмәс иде аның. Яр читендә торган әйбер ни кадәрле генә сылу һәм көчле булмасын, ул барыбер иртәме-соңмы түбәнгә бер тәгәрәячәк. Ә аның андый язмышка дучар буласы килми. Үз язмышың киләчәген беләсеңме икән син, бичара каен?..

Ә түбәндә — елга читендә дөнья мәшәкатьләре белән ыгы-зыгы киләләр. Торна муенлы краннар бүрәнә бушаталар. Кран тау-тау итеп биргән бүрәнәләрдән бер төркем ирләр сал бәйли. Альбинозага бу кызык булып китте, агып барган салларны күргәндә аның күңеле элек-электән һәрчак тынгысызланып куя торган иде. Шул саллар өстенә утыр иде дә агып кит иде су буйлап ерак-еракларга. Шагыйрь әйтмешли, «Башны салларга салып, китәргә иде агып...» Хәер, ул да ага кебек, тормыш дулкыннары аны да какмады түгел. Тик шулай да саллар турындагысы — хыял иде, һичкайчан тормышка ашмаячак хыял. Ул моны үзе дә яхшы белә. Салда агу өчен түземлек, азмы-күпме ихтыяр көче дә кирәк ич. Ә ул тормышта да, мәхәббәттә дә озакка сузуны яратмый. Берөзлексез яңа тойгылар өермәсендә булырга күнеккән...

Сал бәйләгәнне әле аның күргәне юк иде. Салны бәйлиләрме, яисә башка берәр ничек итеп җыялармы — аның ул хакта уйлаганы да булмагандыр. Хәер, ул, гомумән, үзенә кагылышлы булмаган нәрсәләр турында уйланып баш ватарга яратмый, бар нәрсә белән кызыксынып, һәр нәрсәгә тыкшынып йөрүне ул үзе яшендәге хатын-кыз эше түгел дип саный. Аның бөтен байлыгы — яшьлегендә, матурлыгында. Ул яшь һәм матур булганда көчле дә, булдыклы да, акыллы да. Хатын-кызга акыллы булу өчен күп белү кирәкми дип саный иде ул. Һәм үз карашларының дөреслегенә икеләнгәне булмады...

Шундый уйларга бирелеп... Хәер, Альбиноза уйланырга да яратмый ич, гафу итәсез. Кама яры өстендәге нәфис ак каеннан наз алып, елга өстеннән искән җылы җилдә иркәләнеп, дөнья рәхәтенә чумып тора иде кыз. Кинәт яр буенда кемнәрнеңдер хәвефле авазлары ишетелде. Ул да түгел, югарыдан кран биргән бүрәнәләрне кабул итеп торган сал бәйләүчеләр арасында ыгы-зыгы башланды.

— Трос ычкынды...

— Тизрәк, яр буена...

— Ишелә ич, өстеңә ишелә,— дип кычкырыша-кычкырыша, сал бәйләү белән мәшгуль ирләр төрлесе төрле якка сибелде. Берничә ирнең аны-моны уйлап тормыйча суга сикерүен күрде Альбиноза, әмма ни булганын барыбер аңламады.

Тау сыман өелеп торган юан бүрәнәләр бер-берсенә ышкылудан, тәгәрәшүдән яман тавыш чыгарып, тирә-юньгә шом салдылар. Бүрәнәләр кешеләр өстенә тәгәри иде.

Янә хәвефле тавыш ишетелде, башнялы кран ишегеннән башын чыгарган ир кеше кычкыра иде бу юлы:

— Син нәрсә, тилердеңме әллә?! Бүрәнә читенә, суга, суга сикер!

Шунда гына Альбиноза бер-берсенә бәргәләнгән бүрәнәләр өстендә нидер кармалаган сыман иелә төшкән һәм берөзлексез бер бүрәнәдән икенчесенә сикергәләп торган ярым-ялангач ир-атны күреп алды. Эшнең нәрсәдә икәнлегенә төшенмәсә дә, ир-ат өчен куркыныч янавын аңлады кыз, һәм йөрәге кысылып куйды. Яр буендагылар да тынып калганнар, ни белән бетәр дигәндәй көтеп торалар. Ул да түгел, крандагы тавыш тагын ишетелде. Бу юлы инде ул, яр буендагыларга кычкыра иде:

— Тросның башын эләктерде... Ярдәмгә керегез, ярдәмгә!..

Сал өстендәге теге ир-ат, тартылган җәядәй артка каерылып, ишелергә дип ашкынган бүрәнәләргә ирек бирмичә, берүзе тросны тартып тора иде. Ярдәмгә керүчеләр килеп җиткәнче ычкындырмады ул кулындагы юан тросны.

Ниһаять, барысы да җайланды, ипләнде булса кирәк. Суда чупырдашкан кешеләр дә сал читенә килеп тотындылар. Багорлар күтәреп йөгерешеп кергән ирләр дә ниндидер ашыгыч чаралар күрергә керешге. Башнялы кран ишегеннән чыгып баскан ир кесәсеннән кулъяулык чыгарып маңгаен сөртеп куйды.

Ак каен белән хушлашып, кузгалырга иткән иде инде Альбиноза. Шунда, очраклы рәвештәме, аның карашы яр буена чыгып җиткән әлеге курку белмәс ир-атка төште. Аягы кысылуданмы, ул бераз аксаклый иде кебек, ике уч төбеннән беләкләренә кан тамчылары агып төшкән. Трос уеп кергән, трос җәрәхәтләгән иде, күрәмсең... Шуңа да карамастан, ул кабаланмый да, үрсәләнми дә, ипле генә атлап килүен белә. Нинди дә булса батырлык эшләдем дигән уй башына да килми иде бугай аның. Тыныч кына елга читенә килде дә, тезләнә төшеп, йөзен, беләкләрен юарга керешге. Шунда гына танып алды аны кыз һәм, гаҗәпләнүдән, үзалдына «Альбинос» дип әйтеп куйды.

Кичкә авышып килгәндә, ачык тәрәзәдән чәчәк бәйләме ташладылар. Бу — миләүшә чәчәкләре иде. Андыйларны Альбиноза рәсемнәрдә генә күреп белә, җыю түгел, үз гомерендә кулына тотып, иснәп тә караганы юк иде әле аның миләүшә чәчәкләрен. Әле нәни генә шәмәхә күбәләкчекләрне хәтерләткән миләүшәләргә карады, әле ачык тәрәзәгә текәлде кыз. Һичкем күренми иде. Үз кодрәте белән очып килмәгән ич чәчәкләр... Аяклары аны ишеккә таба тартты. Баскыч төбендә гайрәт чәчеп Альбинос басып тора иде.

— Көттеңме?! — диде ул, үзенең хаклы булуына аз гына да шикләнмичә.

— Көтәр кешем юк ич, көтмәдем.

Кыз алдады. Хәер, нинди алдау булсын, Альбиноза егетләр янында уйлаганның нәкъ киресен сөйләргә күнеккән иде. Шулай иткәндә дә ул бик таманга килә дигән караштa тора иде Альбиноза.

— Беләсең ич, мин көтмәгәндә килергә яратам.

— Шуннан?..

— Киттек.

— Кая?

— Кайдырма тау башына,— дип елмаеп куйды егет.

Кыз аның бу шаяртуын аңламады, иңбашларын гына җыерып алды.

— Көймә сезне көтә, туташ. Зарыккансыздыр,— дип, егет кызның күзләренә әдәпсез карашын текәде.

Кичәге кыланышлары өчен әҗерен кайтарырга моннан да кулайрак вакыт булырга мөмкинме?.. Нәкъ менә шушы мизгелне зарыгып көткән иде бит ул югыйсә. Һәм ничек итеп аны акылга утырту хакында да уйланган, барысы әзер иде. Ни хикмәт, каршы сүз әйтә алмады кыз.

Егет аны көймәгә күтәреп кертте. Итәге суга чыланудан куркып, үз муенына ике куллап чәтердәп ябышкан кызны әллә ни арада үбеп

алырга да өлгерде. Альбиноза сүзсез генә елмая төшеп орышкан булды. Ә үзе, шул куллардан төшми, җир шарын әйләнеп чыгарга әзер иде.

Моторлы көймә, бер тартуга, кузгалып та китте. Көймә борынына менеп кунаклаган кызның чәчләрен җил таратты, беләкләренә тамчылар чәчрәде. Ярдан ераклашкан саен, Якты Яр авылының киңрәк панорамасы ачыла барып, бөтен әйләнә-тирә күз алдына килеп басты. Әнә пристань... Анда килеп төшүгә үк инде Альбинозаның күңеле ниндидер матур, күптәннән көтелгән очрашу булачагын сизенгән иде бит. Һәм ялгышмады булса кирәк... Ял йорты һәм аның корпуслары да уч төбендәгедәй күренә икән моннан. Алар арасыннан ул үз корпусларын һәм миләүшәләр бүләк иткән ачык тәрәзәне эзләде. Миләүшәләрне пристаньнан түбәнрәк урнашкан биек краннар оныттырды. Шунда гына ул, бүген иртән күргәннәрен хәтерләп, Альбиносның кулларына текәлде. Бәйләнмәгәннәр... Әмма уч төпләрен кыздан яшереп азаплана икән — әле генә абайлады Альбиноза. Трос салган җәрәхәтләр ул арада гына төзәлә алмый, әлбәттә. Әнә ич, уч төпләрен яшерә төшеп, бер кулы белән көймә читенә таянган. Икенчесе — мотор янындагы тоткыч-рульдә. Уч төпләре белән түгел, анысын да бармак очлары белән генә тотып бара икән.

Бик шәп фикер килде кызның башына. Тукта әле, кызык итим әле үзен дип куйды ул.

— Альбинос, туктат әле...

Кызның нидер әйтергә теләгәнен аңлады егет, әмма ишетмәде, мотор тавышы көчле иде. «Нәрсә?» дигәндәй, карашын аңар төбәде. «Сөбханалла, күз тимәсен үзенә»,— дигәндәй уй яндырып үтте аны. Шулай көймә башларында гына утырып йөрү өчен яралган кош икән бу Альбиноза. Мөлдерәмә пешкән һәм тулышкан җимеш, нинди табигать хикмәтләренә дә тиңләргә белмәссең үзен...

— Туктат дим, туктат,— дип, йомшак нәзек беләкләрен бер-берсенә аркылы куеп күрсәтте Альбиноза.

Бу юлы инде ишетте, төшенде егет. Мотор шундук сүнде, кызны уч төбендәгедәй югары күтәреп барган көймә борыны су өсте белән тигезләшеп калды.

— Мотор тавышын сөймим,— диде кыз, сөйкемле генә елмая төшеп.

— Ә мине?..

— Тәртибеңә карарбыз...

Ә үзенең күзләре бер дә алай дими югыйсә. Наз ташкыны иде аларда, юмартлык балкышы. Урыныннан иплә генә торып, койрыкка таба килде һәм аннан сак кына, җилдә таралган чәчләреннән сыйпап, каршында ук басып торган егетнең беләгенә кагылды.

— Альбиноза...— дигән иркә аваз чыкты мыек астыннан.

— Юк, Альбинос, ашыкма... Әйдә, әнә теге утрауга чыгабыз,— дип ымлады кыз, кулләр ягына күрсәтеп.

— Булдырабыз кирәк булса, диңгезеңә кадәр илтә минем көймә.

Егет моторын кабызырга дип кузгалганда, янә кызның ягымлы тавышы ишетелде:

— Әйттем ич, Альбинос, мотор тавышын яратмыйм, дидем...— Мин дигәнчә булмаса, хәзер үк елап җибәрәм дигән сабый сыман иреннәрен турсайтып өлгергән иде үзе.— Әйдә инде, ишеп кенә барыйк.

Башка чара калмаган иде егеткә, балтасын суга төшергән әкият героедай кыяфәттә калып, ишкәкләрен барларга керешгте ул. Кыз, үзенең канәгатьлеген белдереп, иркен сулыш алды, балкып куйды.

Аякларын як-якка җәеп, көймә уртасына килеп утырды Альбинос. Ишкәкләрне берәм-берәм урнаштырып, суга төшерде. Һәм шунда күзенә керердәй булып кәмит көтеп утырган кызга карады.

— Әллә үзең ишәсеңме, дим... Ял итәргә килгән кызлар ишәргә ярата торган була...

— О-хо,— дип, иреннәрен турсайткан булды кыз.— Тәҗрибәң зур күренә.

— Егет тә бул, тәҗрибәң дә булмасын,— дип, сер бирмәү жаен каерды Альбинос.— Смена унбиш көн саен алышынып тора ич.

— Син гел шулай кызлар утыртып йөрисеңме?

— Үзләре утыра. Миңа нәрсә...

— Ә мин үзем утырмадым, син күтәреп утырттың,— дип акланырга ашыкты кыз, сөйләшүнең болай ялгыш юлдан китеп баруын өнәмичә.

— Әлбәттә, Альбиноза, син бит бер генә.

Әллә үртәп, әллә чынлап әйтелде бу соңгы сүзләр — Альбиноза артык төпченеп тормады, болай да егетнең берөзлексез үзен күзәткәнен, үзенең аңарга ошаганын сизә иде ич ул. Күзенә төшкән чәч бөдрәләрен янә артка чөеп куйды кыз һәм тез өстенә тезен куеп гәүдәсен турайта, күкрәкләрен киерә төште.

— Көттермә инде, Альбинос, утрауга чыгыйк.— Кызның карашы тагы да иркәрәк, тавышы бермә-бер ягымлырак тоелды егеткә.

Каманың нәкъ уртасында, агым көчле урында тукталган булып чыкты көймә. Бая Альбиноза күрсәткән утраудан инде байтак ерагаелган, шуңа күрә агымга каршы ишәргә туры килде. Кама буенда үскән Альбинос өчен бу алай искитмәле ераклык түгел түгелен. Тик менә уч төпләрендәге яра гына, ишкәк сабына кагылу белән, шул яраның сыкрарга тотынуы гына... Шул авыртуга түзсә, шул авыртуны кызга сиздермәсә, аның беләкләре атналар, айлар буе ишеп тә, ару-талуның ни икәнлеген тоймас иде. «Ишәргә! Ишәргә! Авырту турында уйламаска. Сер бирмәскә. Тешне кысып булса да түзәргә...» — дип кабатлады ул күңеленнән, ишү ритмына туры китереп. Йөзенә берни чыгармаска тырышып, каерып-каерып иште. Авырту, сызланулар турында түгел, арка яктан җылы җил турында, көймә борынына бәрелеп чупылдашкан дулкыннар, шул дулкыннардан сибелгән тамчыларда иркәләнгән кыз турында уйларга тырышты ул.

— Тукта, Альбинос, мин койрыкка үтим,— дип, шунда аның муенына кызның куллары сарылды. Кайнар идеме ул куллар, юеш-салкынмы — берни тоймады егет. Ишкәкләрдән кулын ычкындырмады, ул аларны күтәрә төшеп, кызны койрыкка уздырды. Кулларын ычкындырса, мөгаен, яңадан учлап тота алмаган булыр иде ул ишкәкләрне.

Кызның көймә борыныннан койрыкка күчүен, ишүчегә җиңел булсын өчен, яхшы ният белән кылынган чара дип кабул итте Альбинос. Ә чынлыкта, Альбиноза ул хакта белү түгел, башына да китереп карамаган иде. Егетнең каршысына ук утырып, куллары авыртудан аның ничек өзгәләнүен күзәтеп барасы килгән иде аның. Күзгә-күз утырып, аның йөзендәге һәр үзгәрешне тоеп, туйганчы, күңеле булганчы күзәтәсе...

Көймә борыны күтәрелгәч, ишү җиңеләя төште. Әмма тын гына үзенә текәлеп утырган кызның карашын тою аңарга икеләтә кыенлык тудырды. Аның йөзендәге, бөтен тәнендәге киеренкелекне, аяк табаннарына кадәр үткән авыртуны ул тоймый, сизенми калмас. Нәрсә-нәрсә, әмма үзен шул сөйкемле заттан кызгандырасы килми иде аның. Әллә нинди авыртуларга да түзәргә әзер, янәшәдәге кыз гына сизмәсен бары...

Канәгатьләнү хисендә изрәп утырды Альбиноза. Егеткә төбәп үк карамады каравын, әмма күз чите белән аның һәр хәрәкәтен энә күзеннән үткәргәндәй тикшереп барды. Шундый баһадир гәүдәле, горурлыгы, мин-минлеге ташып торган ир-атның авыртудан бәгыре өзгәләнгәнне һәм шул газапларын әле синнән яшерергә маташуын тагы кайчан шулай күзәтеп барыр идең?! «Чыраен сытмаска тырыша бит үзе»,— дип уйлап куйды кыз. Ләкин, барыбер күренеп тора, сизелеп тора — уч төпләрендәге җәрәхәт сызлана, телгәли үзен. Каерып ишкән саен, кулындагы ишкәкләр түгел, ул үзе тимергә-тимер ышкылган аваз чыгарып сыкрап, чыелдап куя төсле. Әнә ич, ишкәк тоткан кулларын нишләтергә белми, бармаклары тыпырчына, уч төпләре кәкрәеп килә — бушатасы килә кулларын, әмма булдыра алмый. Егетлек ирек куймый — ишәргә кирәк. Вәт тамаша — киноларың, циркларың бер читтә торсын.

— Альбинос, «Метеор» килә. Әйдә, шуның борынын кисик әле,— дип, егетне дәртләндереп, утырган урынында сикергәләп, кулларын чәбәкләп куйды кыз.

Күзләрен зур ачып, җилкә аша борылып карарлык көч тапты егет үзендә. Чынлап та, нәкъ аларга турылап югарыдан тиз йөрешле «Метеор» төшеп килә иде. Ерак та калмаган, йөзеп түгел, суга тияр-тимәс биеклектән очып килә диярсең. Сәрсәнләнеп, дөньясын онытып ишәргә керешә Альбинос. «Әйдә, әйдә, җәһәтрәк бул, бирешмә...» — дип, аның саен ашыктыра төште кыз. Кызык иде аңар: шундый тизлек белән очып килгән тиз йөрешле теплоходның борынын кисәләр ич.

Һәм кистеләр дә... Якынлашып житте дигәндә генә, борын төбеннән үк кисеп чыктылар. «Метеор»ның канатларыннан сибелгән су тузаны һәм салкынча җил Альбинозаның аркасыннан сыйпап узды. Ә егет һаман саен ишүен белә, аның таза беләкләре ишкәк сапларына берегеп үскән сыман тоелды кызга. Егет үзе сизә, тоя идеме икән, аның уч төпләреннән ике беләгенә һәм шул беләкләрнең дәвамын хәтерләткән ишкәк сапларына юл-юл булып кан тамчылары агып төшкән иде инде. Альбиноза берни дәшмәде, терекөмеш бөртекләредәй бер-берсен куышып түбәнгә йөгерешкән кан тамчыларын сокланып, таң калып тик күзәтеп баруында булды.

...Ул кич шундый озын булды. Ул кич таңга кадәр сузылды. Икесенә тулы бер утрау иде бит аларның. Утрауның да нәкъ уртасында җиләк яфракларыннан түшәлгән ялгыз шалаш иде. Шалаш каршында хисләр кайнарлыгы булып учак дөрләде. Казанда балыкның затлысы پеште. Егет кызга кузгалак, какы, юа һәм балтырган җыеп килде. Кыз егетне уч тутырып җыйган җир җиләге белән сыйлады...

— Җир җиләгем,— дип кабатлады егет.

— Альбиносым, бердәнберем...— дип саташты кыз.

Төне буе күл читендә кыр үрдәкләре чупырдашып чыкты, бәкәләрен йөзәргә өйрәтәләр иде булса кирәк. Су өстендә, ай нурларыннан ефәк җәтмә үргәндәй, эреле-ваклы балыклар сикерешеп уйнады. Бытбылдык бытылдады, бака бакылдады, баш очында гына ялгыз чикерткә скрипкасын көйләде. Ә кошлар... Кошлар, Кама буендагы һәммә утраулардан монда җыелган да, кем моңлырак сайрый дип, ярыш, сайрау конкурсы оештырганнар диярсең...

— Җир җиләгем,— дип кабатлады егет.

— Альбиносым, бердәнберем...— дип саташты кыз.

Ул кич шундый озын булды. Ул кич таңга кадәр сузылды...

Санаулы көннәр бер-бер артлы үтә торды. Дөресрәге, аларның исәбе бөтенләй онытылып торды. Көн белән төн буталды. Ул бәхетле көннәр мәңге шулай дәвам итәр, аларның очы-кырые һич булмастыр төсле тоела башлаган иде инде. Яр буенда алар йөрмәгән айлы сукмак, урман эчендә алар булмаган җиләкле аланнар калмады. Үзләрен кавыштырган утрауга да юлны онытмады Альбинос белән Альбиноза — барысына да өлгерделәр, һәммәсенә житештеләр. Ниһаять, аерылышыр көн туды, алар аны утраудагы шалашларында каршыладылар. Башка барлык уртак таңнарыдай кояшлы, аяз иртә иде бу. Тик бер аерма — бүген ял көне, Альбиносның эшкә барасы юк, ул беркая да ашыкмый. Шуңа да ул изрәп йоклавын белә.Ә Альбинозаның исә күзләренә йокы кермәде, ни дисәң дә, бүген юлга чыгасы көне. Димәк, аерылышалар. Шушы көннәр эчендә үз булып, кайсыдыр яклары белән кадерле һәм хәтта кабатланмас та булып тоела башлаган иде бит аңарга бу егет. Ә бүген аерылышалар... Күпкәме?... Бәлки, бөтенләйгәдер. Чөнки аларның ялгышып кына булса да киләчәк көннәре һәм аерылышу сәгатьләре турында сөйләшкәннәре булмады. Ул хакта кыз кешегә беренче башлап сүз катуны урынсыз санады Альбиноза, ә Альбиносның башына да кереп

карамады бугай. Үткән турында булсын, киләчәк турында булсын — кызыксынырга гадәтләнмәгән иде алар. Альбиноза кайда туып, кайда үскән, хәзер кайда яши, аңар ничә яшь, һөнәре бармы, гаилә хәле нинди — боларның берсе дә кызыксындырмады егетне. Хәер, кызның да аңарга сораулар биргәне булмады.

— Альбинос... Аль-би-нос, то-ор,— дип, иркә генә дәшеп карады кыз. Егет уянмады. Авызына тукранбаш яфрагы кабып, аның мыек астыннан, колак артларыннан кытыклап та карады — әйләнеп кенә ятты. Чәчләреннән сыйпап сөйде кыз, егет кыймылдамады да. Өстендәге одеалны тартып алды — һаман йоклавын белде.

Башка чара калмагач, шалаштан чыгып, кичәге учак урыныннан калган көлгә карап торды кыз. Су читенә төшеп, битен-кулын юды һәм, көймәгә сөялеп, карашын каршы як ярга текәде... Якты Яр... Матур исем... Аның күңелендә дә шулай якты яр булып калырмы бу яклар... Ә Альбинос?.. Аны тиз генә оныта алырмы ул? Ансыз ничек яшәр?.. Якты Ярсыз, Альбиноссыз бик күңелсез булмасмы соң аңар?..

Кинәт сискәнеп куйды кыз. Тукта! Нәрсә булды әле сиңа?! Тукта, Альбиноза, син уйлый, кичерә башладың түгелме соң, дип, күңеленә килгән иртәнге уйларыннан арынырга ашыкты ул.

Шунда, арыслан авазлары чыгарып, киерелә-сузыла шалаштан Альбинос килеп чыкты.

— Киттекме?! — диде ул чыга-чыгышка, каядыр ашыккандай, сәгатенә карангалап.

— Мин әзер,— диде кыз, әлеге ашыгуның сәбәбен аңышмыйча.

— Сикер көймәгә, кузгалабыз.

Яр читендәге көймәне суга этеп керткәчтен, иң элек кыз, аннан егет бер-бер артлы көймәгә күтәрелделәр. Моторлы көймә туп-туры каршы ярга төбәп чыгып китте. Икесе дә телләрен йоткандай тын гына кайттылар, бер-беренә дәшмәделәр, дулкыннарның көймәгә сугылып пышылдашканы гына ишетелде. Альбинос кына әледән-әле сәгатенә күз төшереп алды.

Ә бераздан инде алар автобус тукталышында басып торалар иде. Чөнки, киңәш-табыш иткәннән соң, кыз автобус белән китәргә хәл кылды.

— Менә аерылышабыз да,— диде ул моңсу гына, янәшәсендә басып торган егеткә текәлеп.

— Әйе,— диде егет,— аерылышабыз. Ә үзе, каядыр ашыккандай, кул сәгатенә карап алды.

— Әле ашыкмаска да була иде... Соңгы рейс белән дә өлгерер идем,— дип, әллә кире уйлыйбызмы соң дигәндәй, егетнең күзләренә текәлде кыз.

— Юлга чыксаң — иртә чык, дип әйтә безнең бабай... Күпме сузсаң да, аерылышасы инде...

— Безнең якларга килеп чыксаң, кагыл,— диде кыз.— Урамыбыз «Яшел» дип атала. Көнгә каерып ачылган иң якты тәрәзәләр безнеке булыр, уникенче йорт.

— Җай чыгуга карарбыз,— диде егет, аны иңсәсеннән кысып. Һәм кызның яңа кабыгын салдырган бер пар шалкан сыман яртылаш күренеп торган күкрәкләренә күз салды. Көтмәгәндә карашлары очрашып, икесе берьюлы елмаеп куйдылар — үзләре генә белгән хатирәләр яңарып алды булса кирәк.

— Сагынырсыңмы? — диде кыз, җавапның уңай булуына һич шикләнмичә.

— Автобус соңара инде әллә,— дип,тагы вакытка күз салды егет. Әллә ишетте, әллә юк кызның соравын. Күзе Якты Яр пристанена якынлашып килгән теплоходка текәлгән иде үзенең.

— Су белән генә китәргә идеме соң?..— дип, икеләнеп уйга калды кыз.

— Кирәкми, әнә, автобус килә,— дип, куанычын яшерә алмый тавышын күтәрде егет.

— Сау бул, Альбинос. Миңа синең белән шундый яхшы булды... Мин сине көтәрмен, кил, яме,— дип егетнең кочагына ташланды кыз.

— Ярар, ярар,— диде егет, кызны автобуска каршы җитәкләп. Күз чите белән янә су өстендәге теплоходка карады.

Автобус кузгалды. Тәрәз читенә үк утырган Альбиноза, ак кулъяулык чыгарып, күзләрен сөртеп-сөртеп алды. Егет пристаньга таба чигенә-чигенә, аңарга кул болгады.

— Урамыбыз «Яшел», ачык тәрәзәле уникенче йорт, унике...— дип кабатларга өлгерде китеп баручы автобусның тәрәзәсенә капланган Альбиноза.

Якты Ярга килеп туктаган теплоходтан ял йортына килүчеләр төшә башлаган иде инде. Парлылары бар, ялгызлары. Араларыннан берсе дә, пристань читенә басып, үзләрен ипле генә күзәтеп торган баһадир сынлы егетне абайламады. Абайлаган булса да, берәве дә аны агач башында посып үзенең чираттагы корбанын көтеп утырган урман мәчесенә тиңләмәгән булыр иде. Һичкемгә зыяны тимәгән, һичкемнең юлына аркылы төшмәгән — пристаньнарда су буеның матурлыгына хозурланып торучылар бер ул гынамыни.

Килүчеләр арасында яшьләр, җәйге ял вакытлары җиткән студентлар аеруча күп иде. Арадан бер чаясы хәтта аңар таба борылып, ярдәм итәрсең бәлки дигәндәй, иреннәрен серле генә бөреп, кат-кат карангалап та алды. Альбиноска ике дә уйлап торырга калмаган иде, югыйсә, гомерлеккә сайламый ич. Бар да чемоданын күтәр, таныш. Һәм, вәссәлам... Инде анымы соң өйрәтеп торырга!.. Ә ул кадакланган сыман тик басып торуында булды. Үзе дә аңышмады, әллә нәрсә булган иде аңар. Теплоходтан чыккан чибәрләрне түгел, кемнедер башка берәүне көтә икән ләбаса ул. Кемне?.. Үзе дә белми... Әллә соң Альбинозанымы? Траптан әле ул һаман күзен ала алмады. Ә инде шалтыр-шолтыр иткән авазлар чыгарган трапны кире биргәч — ул тетрәнеп куйды, бәгырендә ниндидер кыл зеңләп өзелгәндәй булды. Теге кыска итәкле студент кыз әле һаман көтә иде. Көтеп-көтеп тә нәтиҗә күренмәгәч, иреннәрен турсайтып, юри аның янәшәсеннән үк җил-җил атлап үтеп китте.

Үз-үзенә гаҗәпләнде егет. Кемне көтә иде соң ул? Ниткән Альбиноза тагы, Альбиноза китте ич! Әле генә автобуста китте. Аның сменасы узды, хәзер әнә аңарга яңа алмаш килгән. Болай җебеп торсаң, колак кагуың да бар... Нәрсә булды соң әле аңарга? Нәрсә?!.

Пристань читендәге култыксага сөялеп, суга текәлгән көе байтак басып торган булса кирәк. Теплоход инде күптән китеп барган иде. Пристаньда да шкипер агайдан башка кеше калмаган. Трубкасын төтәтә-төтәтә, ул егет янына килде һәм аның хәленә кергәндәй сорап куйды:

— Нәрсә, энем, бүген чиертмәдеме әллә?

Сорауны ишеткәнен белгертеп карап алса да, берни дәшмәде, җавап кайтармады егет. Кешегә ничек аңлатасың — кеше түгел, үзе аңламаслык бер халәттә торып калган иде бит ул. Дөресен әйтсә дә, ышандыра алмаган булыр иде — шкиперның беренче ел гына эшләве түгел ич...

— Хәерлегә булсын, борчылма, энем,— дип, үзенчә нәтиҗә ясап, үзалдына сөйләргә кереште агай.— Ата-бабада булмаганны кыланасыз. Мин бит барын күреп, үземчә исәпләп торам. Бер чиге булмый калмас дим бу азгынлыкларыгызның. Ял йортын аны ата — улны, ана кызны белмичә буталыр өчен ачмаганнар. Эшләп арган кеше ял итсен, сәламәтлеген ныгытсын өчендер ул.

— Тукта әле, кем... абый. Син бит әллә кая, читкә киттең,— дип туктатырга ашыкты аны Альбинос.

— Туктамый торсын әле,— дип кыза китте шкипер агай.— Туктамый торсын әле... Шкипер гына дигәч тә, әллә күрми, борчылмый дип белә-

сезме... Бик беләсең килсә, мин синең яшьтә фруntta идем инде, өч пар кирзы итек туздырган идем. Әллә безгә күз кысмадылар дисеңме, әллә бездә кара мыек булмаган дисеңме. Кеше дә була белергә кирәк әле... Дөньяда ярату дигән нәрсә дә бар...

— Кем... абый, тукта инде. Дөрес сөйлисең син, дөрес. Нишлим соң?

Егет тәмам югалып, буталып калган иде. Шкипер агай сөйләгәннәр белән аның күңелендә кайнаган, ургыган хисләр арасында ниндидер уртаклык чынлап та бар иде булса кирәк.

Сезгә сөйләп тел әрәм иткән мин юләр дигән сыман, агай бераз тынып торды. Кесәсеннән кадак чыгарып, трубкасын чистартырга кереште. Ләкин барыбер башлаган сүзенә нокта куймый булдыра алмады ул.

— Альбинос... Альбинос, имеш...— дип үзалдына мыгырданудан башлады ул.— Исемнәрегезне әйтер идем, ташка үлчим, бигрәкләр дә җисемегезгә туры китереп биргәннәр инде...Ә син беләсеңме соң, нәрсәне аңлата синең исемең?

— Үзем кушмадым ич, нәрсә булган? Ни аңлатса да бер түгелмени соң?

— Кайтып сүзлектән кара, әнә: витамин җитешмәгәнгә үз төсен югалткан җан иясе дигән сүз икән ул. Үзеңдә булмаса, безгә кереп кара, минем килендә бар аның сүзлеге. Шул төшенә кәнфит кәгазе кыстырып куйдым. Альбинос та Альбинос, имеш... Җүнле-башлы исем беткәндерме?..

Егет үпкәләмәде шкипер агайга. Берни җавап та кайтара алмады. Иплe генә хушлашып, кайтыр юлга борылды.

Егет белән әллә нәрсә булды шул көннән — вакытын ничек үткәрергә, үз-үзен кая куярга белмәде ул. Көндезләрен кич җитми газаплады, төннәрен таң озак көттерде. Ял йортына да барып кайтты, күзенә һичкем күренмәде — бары аны, аны эзли иде күзләре. Өйдә булсын, эштә булсын, ул бөтенләй сөйләшмәс, аралашмас булып калды — күңеленнән берөзлексез Альбиноза белән узган, әмма ул чакта кадерләрен бәяләп җиткермәгән бәхетле көннәрен кичереп йөрде. Сал бәйләүдән аерып, бер атнага болынга печәнгә җибәрделәр алар бригадасын. Чиксез куанган иде ул, бераз булса да онытыла төшәр дип өметләнгән иде. Киресенчә килеп чыкты, нәни генә утрау һәм андагы шалаш төшләренә кереп йөдәтте. Бер атна — бер гомердән дә озынгарак сузылган кебек булды аңар. Билдән югары үскән болын печәнен покосларга аударганда да, шул покосларны кабартканда да, кибән куйганда да — уйлаганы ул, бары тик ул гына булды.

Болай дәвам итә алмый иде башкача. Кем-кем, әмма Альбинос әлегедәй кичерешләргә күнекмәгән, аңарга артык түземлек бирелмәгән иде башка. Әгәр барыр юлны белсә, адресын хәтерләсә, ике дә уйлап тормас, күптән юлга чыккан булыр иде дә бит... Нишлисең, адресын хәтерләми. Кат-кат әйтте югыйсә, ә ул колагына да элмәгән булды. Кирәге чыкмас дип уйлады, кирәге чыкмавына шиге юк иде. «Ачык тәрәзә... Ачык тәрәзә» дигәне генә колакка уралып калган. Адреста идемени соң кайгысы, яңа алмашны каршыларга ашыкты ич... Һич югы фамилиясен, эшләгән урынын белсә икән — эзләр өчен, барып тотынырь өчен бер мәгълүмат юк. Зур кала урамы чатына басып, Альбинозаны эзлим, тәрәзәләре ачык торган Альбинозаны күрмәдегезме дип, һәр үткән кешедән сорап торып булмас бит. Ачык тәрәз һәм Альбинозалар ул калада аз дип беләсеңме?!

Бу кыен хәлдән чыгу юлын язмыш җиңел хәл итеп куйган иде. Печән мәшәкатьләрен йомгаклап болыннан кайтып керүенә Альбиносны өендә бер түгел, ике хат көтеп торган булып чыкты. Аңардан!.. «Сагындым... Әти-әнине диңгезгә озаттым(!) Өйдә бер ялгызым. Тизрәк кил. Көтәм...»,— дигән бер үк сүзләр иде аларның һәр икесендә.

Канат инде егеткә. Җегәр, гайрәт ташкыны килде. Бер сәгать, сәгать ярым ара үзмады, юынып-чистарынып, киенеп-ясанып, ул инде пристаньга төшеп җиткән иде. Хәленә кергән шкипер агай, билет ягы шактый авыр булуга да карамастан, аны беренче рейска ук утыртып җибәрде.

Дүрт сәгать буе аяк өсте басып барды ул. Урын юклыктан түгел, утырырга үзе теләмәде. Тиз йөрешле теплоходның читенә сөялеп, аның канатларыннан як-якка сибелеп калган суны күзәтеп барды. Судан искән салкынлык, рәхәтлек аның күңеленә азмы-күпме сабырлык, түземлек китерә иде. Шундый чакта ничек итеп тыныч кына утырып барырга кирәк... Теплоход түгел, канатлы коштай ашкына ул, үзен зарыгып көткән сөйгәне янына ашыга. «Янача яши башлыйм... Ике дә уйламыйм, иртәгесен үк үзен Якты Ярга алып кайтып китәм... Нараттан йорт җиткерәм... Җитәр... Җитәр!»,— дип, бүген мең ничәнче кат кабатлавы инде аның. Әледән-әле түш кесәсенә хәстәрләп тыгып куелган хатларны капшады. Ул аларны алмаш-тилмәш кулына алды. Югыйсә, бер үк сүзләр. Аларда язылганнарны яттан белүенә дә карамастан, кайтып-кайтып укудан бер тәм тапты. Хатлардагы һәр сүзгә генә түгел, һәр тыныш билгесенә кадәр мәгънә салынгандай тоелды егеткә. Ә инде күп нокталарга һәм җәяләр эченә алынган өндәү билгесенә җиткәндә, аның йөрәге күкрәгеннән бәреп чыгарга ашкынгандай тибәргә тотына иде. Чөнки ул тыныш билгеләрендә алар үзләре генә аңларлык серләр яшерелгән. Альбинозаның да аны сагынуын, аны бер күрергә зарыгуын тою әйтеп-аңлатып бирүе дә кыен булган бер рәхәтлек китерә иде егеткә. Димәк, ул да өзгәләнә, ул да аны, бары тик аны гына көтә... Иртәгесен үк Якты Ярга... Билет юк дип тормас. Җәяүләп... Якты Яргача кулларында күтәреп кайтачак ул аны...

Шәһәр урамнарында адашып байтак йөрде ул. «Яшел» дип аталган урамны белүчеләр очрамады. Кемнән генә сорашмасын, иңбашларын җыерып, авыз турсайттылар. Егетнең инде ашкынуы басыла, дөрләп кабынган өмете, мае бетеп килгән шәмдәй, сүнәм-сүнәм дип калтырана башлаган иде. Шунда хәтеренә төште: Альбиноза ике сүзнең берендә «Маяк» ресторанын искә алырга ярата иде. Ресторан янында аңарга «Яшел» урамына юл күрсәттеләр.

Зур һәм киң урамнан уңга каерылгач та, алма-чия бакчаларына күмелеп утырган бер уязлык башлана икән. Шундагы беренче агач йортның почмагына «Яшел урам» дип язылган калай кадакланган. Шул калайны күргәч тә егетнең йөрәге ничек дөпелди башлаганын белсәгез икән! Көтелмәгән бу куанычтан Альбинос йөгереп китәрдәй булды, әмма күңеленә ташкын булып аккан дәртне дә тыярлык көч бар икән. Алай гынамы соң, ул әле хәтта бер тынга тукталып та торды, күлмәк якаларын көйләгәндәй итте, икеләнү, көтү һәм өметләнүләрнең тузанын кагып бетерергә теләгәндәй, аяклары белән тибенгәләп алды. Туганнан бирле Кама буеның гүзәл табигате кочагында үскән егетне дә сокландырырлык гүзәллек бар иде бу урамда. Иң элек, урам буйлап ике яклап тезелешеп киткән йортларның һәммәсе дә яшел төскә буялган булу җәлеп итте аның карашын. Йортлар гына түгел, өй каршындагы рәшәткәләр, капкаларга кадәр яшел иде. Койма өсләреннән рәшәткәләр аша урамга алма исе таралган. Бакча эчендәге каралтылар, сүз берләшкәндәй, алмагачларга күмелеп утыралар. Яулык читеннән карап торган тыйнак авыл апалары сыман аларның кыек очлары гына күренеп тора. Яшел төс һәм алма исе тантана итә иде бу урамда. Альбинозаның яшьлеге, тупырдап торган матурлыгы менә кайда бөреләнеп, кайда өлгергән икән! Егет, мыекларын да тарап алгач, башын бераз күтәрә төшеп атлап китте.

Икенче йорт, дүртенче йорт, алтынчы... һәм, димәк, әнә тегесе, алма шавына күмелеп утырганы — аларныкы.

Яшел урам... Уникенче йорт... Көнгә каерып ачылган ачык тәрәзәләр... Альбиноза өйдә икән, дип уйлап алды ул шул ачык тәрәзәләрне күрү

белән. Өйдә башка һичкем юк дип язган иде ич үзенең хатында. Димәк, үзе генә... Аны көтә булса кирәк. Ничек итеп килеп керү, иң элек ни дип дәшү турында юл буе баш ватып та, рәтле-башлы бер фикергә килә алмаган иде ул, ә менә ачык тәрәзәләрне күргәч тә туктап калды. Урамда кеше-кара күренми. Аны дәшеп, кош булып сайраргамы икән әллә? Кама буе урманнарында күпме кош булса, шуларның һәммәсе булып та сайрый белә ич ул. Шалашта үткәргән төннәрендә Альбинозага да сайрап күрсәткәне булды. «Кош сайравын ишеткәндә — сине уйлармын»,— дигән иде. Танырмы икән?..

Сандугач булып сайрады. Сабан тургаена охшатып аваз бирде. Чәберчеккә килештерде... Ачык тәрәзәдән Альбиноза балкып күренмәгәч, күке булып кычкырды. Кызның «мәхәббәтең күпме?» дигән шаяруын ишетергә өметләнде.

Күкегә дә җавап кайтаручы булмады. Кыз шаярта, качышлы уйнамак була дип нәтиҗә ясады егет һәм сак кына яшел капкадагы келәгә үрелде.

Тыйнак итеп җыештырылган ишегалдында һичнинди җан әсәре күренми. Аны һәр яклап яхшы нарат бүрәнәләрдән торгызылган каралты-кура уратып алган. Җәйге аяз көннең бөтен яшеллеген һәм яктылыгын үзенә җыйган урамнан күләгәгә килеп кергәч, караңгыланып киткәндәй булды. Җиләс тынычлыкны тоеп, ул бер тын тик басып торды, болдырга кайнар кочакларын җәеп, Альбиноза йөгереп чыгар кебек тоела иде аңар.

Сак кына адымнар белән ярым ачык калган өйалды ишегенә якынлашты егет. Акрын гына шакылдатты. Бер шакылдатты, ике... Җавап бирүче булмады. Үзе артыннан ишекне кысып өйалдына керде. Тынлык һәм караңгылык бермә-бер арта төште. Инде ул шомлана да башлаган иде. Әмма, такта ярыкларыннан төшеп торган яктылык сыман, күңелендәге ышаныч нуры сүрелмәде. Куллары белән капшап, ул башта өй ишеген, аннан ишек тоткычын тапты. Тагы шакыды... Бу юлы да тынлык җавап бирде. Өй ишеге ачык булып чыкты.

— Мин килдем, Альбиноза. Көттеңме? — дип дәште егет, бу сүрән тынлыктан тәмам гаҗиз булып.

Җавап бирүче булмады. Берәр кызык чыгарырга ниятләнеп, Альбиноза түр якта утырадыр, я булмаса шунда качып торадыр дип уйлады егет. Кроссовкасын салырга да онытып, түр якка узды. Чикләвек агачыннан эшләнгән затлы мебель белән җиһазланган зур һәм иркен бүлмә. Һәр җирдә тәртип. Кызыл бәрхет пәрдә белән томаланган тәрәзәләрдән төшеп торган тонык кына яктылыкта өй эче аеруча серле тоела иде.

— Альбиноза, чык инде... Җитәр...— дип дәште егет. Бу юлы инде ул ярымпышылдауга күчкән иде. Ниһаять, кыз артык түзеп тора алмас, аяк очларына гына басып, менә-менә аның арт ягыннан килер дә муенына сарылыр, күзләрен томалар һәм «сөйгәнең кем?» дип дәшәр төсле иде. Һәм, әлбәттә, «Син, Альбиноза, син»,— дими торып, кулларын ычкындырмас...

Күпме генә көтсә дә, аның күзләренә сарылучы булмады. Егет, бераз кыюлана төшеп, аны үзе эзләргә кереште. Идәнгә үк төшеп торган пәрдә артларыннан ачып карады, өстәл һәм карават асларына күз төшерде — Альбиноза күренмәде. Җыелмаган урын өстендә кабарып торган юрганны күтәрде — Альбиноза юк иде. Өстәл читендә торган урындыкка барып утырудан башка чара калмады.

Өй эчендә тагы сәер тынлык урнашты. Хәер, тынлык идеме икән бу... Бер яктан, егетнең күкрәк читлегенә сыеша алмаган йөрәге ашкынып типте. Ә стенада, аңа нидер әйтергә-аңлатырга теләгәндәй, ашыгып-кабаланып, сәгать теле арлы-бирле йөренде. «Альбинос... Альбиноза...», дип, аларның исемнәрен, бер-беренә шул кадәр дә якын һәм тәңгәл килгән исемнәрен, кабатлый сыман тоелды сәгать теле. «Альбинос — Альбиноза...», «Альбиноза — Альбинос...» Карале, чынлап та кызык икән ич... Үзенә күрә мәгънә дә йөртә икән бит әле аларның исемнәре.

Пигментлары җитешмәгән кеше, җанвар яисә үсемлек... диләрме... Ә аларда ни җитешми икән соң? Ни җитешми?.. Күрәмсең, теге чакта шкипер агайның хафалануы да юкка гына булмагандыр. Чын кешеләрчә ярату һәм кичерү бәхетенең ни икәнлеген татымаган булса, ул әле һаман да шулай яшәвен дәвам иткән булыр идеме икән?.. Зарыгып көтәр, сагынып очрашыр кешең булмау — гел мәгънәсезгә яшәү икән ич...

— Альбинос...—дигән, бәхетле шат тавыш һәм чишмә чылтыравыдай көлү авазы сискәндереп җибәрде, уйларыннан бүлде егетне. Күңеленә кинәт бәреп кергән кайнар дулкын аны шундук тавыш килгән якка ашыктырды.

Як-якка пәрдәләрен тартып, кече якның ачык тәрәзәсенә барып капланды егет. Күзләрне чагылдырып, бүлмәгә көн яктысы, кояш нурлары бәреп керде. Тәрәзә артында алма бакчасы икән. Алмагачлар арасыннан дөньясын онытып, чәчләрен тәртипсез таратып ташлаган Альбиноза өйгә таба йөгерә. Ул кагылып киткән ботаклардан җиргә тупыр-тупыр итеп өлгергән алма коелып бара. Кызның алмадай алсуланган бит уртасы һәм кыска җәйге күлмәккә сыешмаган матурлыгын күреп өлгерде егет. Һәм... поши сыман дәү-дәү атлап аны бакча буйлап куып килгән ир-атны да күрде. Тагы бер мизгелдән Альбиноза, кинәт бәхетле чырылдау авазы чыгарып, үзен куып килүченең кочагына кереп чумган иде.

Бакчадагы бәхетле пар дәү алмагач кәүсәсенә сөялгән көе туктап калды. Аяк очларына басып үрелә-үрелә: «Альбиносым, бердәнберем...» — дип саташа иде кыз. Аның ярым йомык күзләре, егет муенына сарылган ак беләкләре һәм сулыш алган саен калкынып-калкынып куйган күкрәкләре чагылып үтте. Алмагачтан аның саен алма коела. Шул алмаларның ничек биешүен күрергә теләмәгән егет, йодрыклары белән ике күзен каплап, ачык тәрәзәдән тизрәк читкә тайпылды. Мөмкин кадәр тизрәк һәм ераккарак китеп качу юлы гына калган иде. Үзалдына: «Альбинос... Альбинос, имеш»..., — дип мыгырдана-мыгырдана, түр якка атылып чыгуын һәм ничек итеп ачык тәрәзә аша урамга сикерүен дә абайламады булса кирәк ул. Артына да борылмады, ачык тәрәзә куа киләдер төсле тоела иде аны.

*Әдәбиятлар дуслыгы — халыклар дуслыгы*

# ТАРИХИ БЕРГӘЛЕК

## ТАТАР-ЧУВАШ МӘДӘНИ БӘЙЛӘНЕШЛӘРЕ ТУРЫНДА

Эчтәлеге белән социалистик, формасы белән милли булган совет культурасының хәзерге үсеш дәрәҗәсе гомуми социалистик культураның состав өлешен тәшкил итүче милли культураларның үсүен, бер-берсенә якынаюын бик ачык күрсәтә. Моңа татар-чуваш халыкларының культура бәйләнешләре дә мисал булып тора. Әлеге халыклар башка тугандаш халыклар — руслар, башкортлар, удмуртлар, марилар һ. б. белән гасырлар буена якын күршеләр булып, үзара дус һәм килешеп яшиләр.

Казан — илебездә иң зур университетларның берсе урнашкан, данлы традицияләре булган шәһәр. Казан Идел буе, Урал ягы халыклары, шул исәптән чувашлар тарихында прогрессив роль уйнаган. Ике халыкның өзелмәс дуслык бәйләнешләре Казаннан башланган. Заманында әлеге чал кала чуваш халкының да культура учагы булып саналган. Чуваш халкының милли культурасын үстерүдә аның роле гаҗәеп зур. Бөек Октябрь социалистик революциясенә кадәр үк Казандагы «инородческая» учительская семинариядә авыл башлангыч мәктәпләрендә эшләү өчен чуваш, удмурт, мари халыкларының милли кадрлары хәзерләнгән. И. Яковлев, В. Хохряков, С. Михайлов, М. Федоров, Н. Бичурин, И. Юркин кебек танылган чуваш галимнәре Казан университетында белем алганнар, Казан белән якын бәйләнештә булганнар. Совет хөкүмәтенең баштагы елларында Казан Көнчыгыш педагогия институтында тугандаш чуваш, удмурт, мари яшьләре өчен махсус оештырылган бүлекләрдә төрле белгечләр хәзерләнә. Казан университеты рабфагында чуваш бүлеге эшли. Чуваш педагогия техникумы яшь укытучы кадрлар хәзерли. 1933 елда бу техникумны күренекле чуваш галиме, әдәбиятчы Н. Дедушкин тәмамлый.

Казан — тугандаш чуваш халкы тарихының мөһим һәм аерылмас өлеше ул. Чувашның беренче басма шигыре 1767 елда Казанда басыла, революциягә кадәр чувашлар турында җитди фәнни басмалар чыга. Бу борынгы шәһәрдә чуваш телендә беренче әлифба туа. 1906 елның 8 январенда Казанда чуваш телендә беренче революцион газета булган «Хыпар» («Хәбәр») басыла, чуваш теленең күптомлы сүзлеге басыла башлый, беренче сүзлек, энтография буенча беренче хезмәтләр, чуваш халык авыз иҗаты буенча төрле җыентыклар дөнья күрә.

Татарстанда туып үскән күренекле чуваш мәгърифәтчесе И. Яковлев (1848—1930) бөтен гомере буена татар культура эшлеклеләре белән якын бәйләнештә булды. Ул бала чактан ук татарча иркен сөйләшкән, татар халкының әдәби һәм халык телен яхшы белгән. 1875 елда Казан университетын тәмамлаган И. Яковлев озак вакытлар Казан уку округына кергән чуваш мәктәпләренең инспекторы булып эшли. Ялкынлы педагог үз карамагындагы мәктәпләрдә барлык халыклар арасында тигезлек һәм туганлык идеясен пропагандалый. Ул милләте белән рус булмаган халыкларның Россия составына үги балалар булып түгел, ә аның тулы хокуклы уллары булып керергә тиешлекләрен яклап чыга. «Руслар, татарлар, чувашлар — барысы да бердәй кешеләр»,— дип яза И. Яковлев «Чувашлар өчен әлифба» дигән китабында.

Беренче рус революциясе татар һәм чуваш мәдәниятләре арасындагы элемтәне үстерүгә булышлык иткән чорда эшчеләрнең революцион хәрәкәте изелгән халык массаларының милли азатлык хәрәкәте белән кушыла. Казан шушы хәрәкәтнең бер үзәген тәшкил итә. РСДРПның Казан комитеты губернада яшәүче төрле милләт халыклары арасында агитация-пропаганда эшен көчәйтә, аларны патша самодержавиесенә каршы бердәм көрәшкә чакыра. Революцион хәрәкәтнең үсүеннән шүрләгән патша ашыгыч рәвештә манифест чыгарырга мәҗбүр була. Шушы форсаттан файдаланып, чуваш интеллигенциясе вәкилләре Казанда «Хыпар» («Хәбәр») дигән газета чыгара башлыйлар. Милли мәсьәләгә килгәндә, газета барлык милләт халыкларының да тигез хокуклы, үзара дус булырга тиешлеген яклап чыга. «Хезмәт халкының интереслары — татармы ул, рус яки чувашмы — һәркайсыныкы бер үк тәсле» дигән фикерне алга сөрә. Чуваш вакытлы матбугатын үстерү, халык массаларын революцион рухта тәрбияләү, милли интеллигенциягә дөрес юнәлеш бирү өлкәсен-

дә «Хыпар» газетасының роле гаять зур була. Бу большевистик матбугат органы чуваш әдәбиятының К. Иванов, Н. Полоруссов-Шелеби, Таэр Тимки, Н. Шубосинни кебек күренекле вәкилләрен формалаштыруда үзеннән зур өлеш кертә.

Революцион «Интернационал», «Варшавянка», «Марсельеза» җырларын чуваш теленә тәрҗемә иткән Тимофей Семенов (Таэр Тимки) беренче рус революциясе елларында ук Хөсәен Ямашев җитәкчелегендәге большевиклар көрәшенә килеп кушыла. Х. Ямашев беренче чуваш шагыйре-революционерының укытучысы һәм якын дусты була. Замандашларының әйтүенә караганда, Х. Ямашев 1905 елның җәйге айларында Буа өязенең күп кенә татар һәм чуваш авылларын йөреп чыга, рус иптәше белән бергә, Әлшәй авылыннан ерак булмаган Свияга елгасы буендагы аланлыкта авыл крестьяннарының җыелышын үткәрә. Биредә уналты яшьлек Т. Семенов беренче татар большевигы Х. Ямашев белән таныша. Ул 1905 елда Казанга килеп, шәһәрнең бер типографиясендә хәреф җыючы булып эшкә керә һәм, күп тә үтми, социаль-демократлар белән аралашып, РСДРПның Казан комитеты боерыкларын үти башлый. Х. Ямашев группасы члены булган Т. Семенов китап басучылар забастовкасында, төрле митинг һәм демонстрацияләрдә актив катнаша, чуваш халкы арасында революцион эш алып бара, легаль булмаган әдәбиятны бастыруда һәм аны халык арасында таратуда өлеш кертә. Яшь шагыйрьнең политик карашлары Казан большевиклары йогынтысында формалаша. Партия оешмасы кушуы буенча, Х. Ямашевның турыдан-туры ярдәмендә, Т. Семенов һәм аның якын дуслары чуваш телендә листовкалар һәм прокламацияләр чыгаралар. Ул Х. Ямашев, Н. Накоряков кебек большевиклардан даими рәвештә марксистик әдәбият алып укый, үзенең шигырьләрендә патша даирәләренә кискен каршы чыга, халыкны ачыктан-ачык көрәшкә чакыра. Аның шигырьләре «Хыпар» газетасында басыла. Кораллы көрәшкә чакырган «Данлы үлем җыры» дигән шигырен бастырган өчен «Хыпар» газетасының 1906 елгы 23 санына арест салына. 1907 елның 31 маенда Т. Семенов кулга алына. 1 июньдә исә «Хыпар» газетасы редакциясе патша жандармнары тарафыннан таркатыла. Беренче чуваш шагыйре һәм революционеры Т. Семенов 1911 елның җәенә кадәр сөргендә була.

Күренекле татар мәгърифәтчеләре Г. Курсави, Ш. Мәрҗани һәм бигрәк тә К. Насыйриларның эшчәнлеге нәтиҗәсендә чуваш халкында мәгърифәт очкыны кабына. Егерменче гасыр башында татар мәгърифәтчеләре чувашлар турында ныклап язарга керешәләр. Әйтик, К. Насыйри, чуваш авылларын җентекләп өйрәнеп, тарихта калырлык хезмәт яза. Революцион-демократик эчтәлекле чуваш әдәбиятының формалашуына рус, татар һ. б. халыклар әдәбиятларының бай традициясе уңай тәэсир итә. Революциягә кадәр яшәгән чуваш сүз осталарының иҗатына Г. Тукайның иҗади йогынтысы аеруча зур була. Тарихи язмышларында татар халкы белән уртаклыклары булган чувашлар өчен Г. Тукай иҗаты гомумән үз һәм якын. Чөнки аның иҗатында, чуваш әдәбияты классигы К. Иванов әсәрләрендәге кебек үк, халыкның уйхыяллары, теләк-омтылышлары, уртак мотивлар яңгырый.

Идел буенда яшәүче татар һәм чуваш халыкларының тарихлары да, язмышлары да охшаш. Авыр чакта да, бәхетле яңа тормыш өчен көрәштә дә алар гомер-гомергә бергә булганнар. Ике халык авыз иҗаты, аерым алганда, бәетләр, җырлар да шул турыда сөйли. Россия азатлыгы өчен канлы көрәштә катнашкан бу ике халыкның җырлары аваздаш яңгырый. Мондый мисалларны халык авыз иҗатының төрле жанрларында табып була.

Бөек Октябрь социалистик революциясе җиңгәннән соң, Совет Россиясе халыкларының үзара дуслыгы моңарчы күрелмәгәнчә үсте һәм ныгыды. Казан белән бәйләнгән һәм тугандаш чуваш халкы өчен әһәмиятле булган революцион елъязмаларның кайберләренә мөрәҗәгать итик. 1917 елның 26 октябрендә Казанда власть Советлар кулына күчә. 1917 елның 30 октябрендә Чабаксарда властьны Советлар үз кулларына алалар. 1917 елның декабрендә Казанда чуваш театры төзелә. 1918 елның 12 январь — 1 февраль көннәрендә Казанда Беренче Бөтенроссия чуваш хәрби съезды эшли. 1918 елның 27 январенда Казанда укучы яшьләрдән, солдатлардан оешкан һәвәскәр группа А. Островскийның «Не так живи, как хочется» дигән әсәре буенча чуваш телендә эшләнгән беренче спектакльне куя. 1918 елның 28 февралендә тулысынча Совет власте платформасында торган «Канаш» («Киңәш») газетасының беренче саны чыга. 1925 елда Казан Көнчыгыш педагогия институтында чуваш теле һәм мәдәнияте бүлеге ачыла.

Бөек Октябрь социалистик революциясе көннәрендә һәм шулай ук совет хөкүмәтенең баштагы елларында ялкынлы революционер Мулланур Вахитов чуваш язучысы, карт коммунист В. Краснов-Асли, шагыйрь-революционер Т. Тимки, күренекле чуваш этнографы профессор Н. Никольский, революционер А. Краснов, язучы П. Осипов һ. б. лар белән якыннан аралаша һәм алар белән дустанә мөнәсәбәттә була. М. Вахитовның профессор Н. Никольский белән бергә «Кызыл байрак» газетасында бастыру өчен өндәмә язулары да игътибарга лаеклы.

Совет властеның баштагы елларында Татарстанда яшәүче чувашлар өчен «Сене парнас» («Яңа тормыш»), «Чухансен сасси» («Пролетариат тавышы»), «Ана» («Чәчүлек»), «Шурампус» («Таң»), «Сене йал» («Яңа авыл») һ. б. газета-журналлар чыгарыла.

Казанда озак еллар дәвамында «Херле ялав» («Кызыл байрак») исемле өлкә газетасы чыгып килде. Аның редакциясе каршында В. Юдин җитәкчелегендә эшләп килгән әдәби берләшмәдә Ю. Айдаш, П. Афанасьев, К. Петров, В. Ахун, Н. Васильев кебек язучылар беренче чыныгуларын алдылар. Кыскасы, Казан Совет властеның беренче елларында ук чуваш дусларга культура күтәрелешендә, югары квалификацияле белгечләр әзерләүдә, фәнни тикшеренү эшләрен киңәйтүдә конкрет ярдәм күрсәтте.

Гимназист Володя Ульянов тарафыннан университетка керергә әзерләнгән Н. Охотниковның шактый еллар басылмый яткан «Чуваш баласының үзенең тәрбиясе турында язмалары» дигән хезмәте 1920 елда Казанда дөнья күрә. Автор алга таба, Казан галимнәре булышлыгында бу этнографик язмаларга таянып, «Чувашлар» дигән ике томлы фундаменталь хезмәт тудырды. Революциядән соң Казанда, Н. Никольский, Н. Ашмарин, В. Егоров, Г. Комиссаров кебек күренекле чуваш галимнәре фәнни-педагогик эшчәнлекләрен җәелдереп җибәрделәр. Чуваш драматургиясенең классигы П. Осипов иҗади эшчәнлеген Казанда башлаган. Атаклы Педер Хузангайга да Казан канат бирде. Казан күренекле педагог, халыклар дуслыгы җырчысы, ялкынлы интернационалист, татар телен туган чуваш теле кебек яхшы белүче Г. Волковны галим итеп үстерде. «Минем Казанга мәхәббәтем, казанлыларга рәхмәтем ифрат зур. Бу шәһәр минем йөрәккә мәңгегә кереп урнашты. Казан — халкымның биографиясендә булган кебек, минем дә шәхси биографиямдә, һәм мондый биографияләр меңнәрчә»,— ди педагогия фәннәре докторы, профессор Г. Волков — «Этнопедагогика», «Чуваш халкының этнопедагогикасы», «Чуваш халык педагогикасы» һ. б. бик күп кыйммәтле китапларның авторы.

Татарстан туфрагы 40 тан артык чуваш язучысын, галимен, сәнгать эшлеклесен тудырып үстерде. Алар арасында Иван Яковлев, Педер Хузангай, Тихон Педерки, Таэр Тимки, Максим Кошкинский, Николай Полоруссов-Шелеби, Николай Дедушкин, Александр Алга, Константин Петров, Владимир Ухли, Валентин Урдаш, Александр Калган, Юман, Юркин, Георгий Тал-мрза, Василий Краснов-Асли, Георгий Краснов-Асли, Георгий Краснов-Казени, Анатолий Ерусланов, Неонила Кузьмина, Григорий Тимофеев, Алексей Афанасьев, Ефрем Еллиев, Василий Юдин, Михаил Белов, Порфирий Афанасьев һ. б. лар бар. Алар, татар халкының тормышын, милли үзенчәлекләрен, гадәтләрен, традицияләрен яхшы белгәнлектән, ике тугандаш халык культураларының үзара йогынты ясашуларына булышлык итәләр.

Татар һәм чуваш әдәбиятлары һәм сәнгатьләре арасында күптәннән тыгыз бәйләнеш яши. Моны раслау өчен фәнни һәм матур әдәбияттан күп мисаллар китерергә була. Чуваш халкының телен, тормыш-көнкүрешен, гореф-гадәтләрен, культурасын яхшы белгән, кыйммәтле этнографик күзәтүләр алып барган З. Бәширри революциягә кадәр үк татар җәмәгатьчелеген чуваш халкының рухи хәзинәсе — халык иҗаты әсәрләренең матур үрнәкләре, тел үзенчәлекләре белән таныштырды. «Чуваш кызы Әнисә» дигән гүзәл повестен, «Чувашлар» дигән фәнни-этнографик хезмәтен бастырып чыгарды.

Күренекле чуваш әдибе Семен Эльгер «Изү астында» дигән поэмасында Иделдә 15 ел бергә бурлак хезмәтен башкарган чуваш Чакки һәм татар Абдул арасында булган соклангыч дуслыкны тасвирлый. Абдул каты авырган дусты Чаккига авыр көннәрдә дә булышлык итә, аңа гомеренең соңгы минутларына кадәр дусларча тәрбия күрсәтә.

Бөек чуваш мәгърифәтчесе И. Яковлев чын мәгънәсендә халыклар дуслыгы җырчысы, чын интернационалист иде. Ул бөек рус халкы белән генә түгел Идел буе һәм Урал ягында яшәүче башка милләт халыклары белән дә дустанә мөнәсәбәттә яшәүне гомере буе хуплады. «Идел-Кама краендагы рус булмаган халыклар турында кыскача язма» дигән фәнни-тикшеренү эшендә татар халкының уңай сыйфатларын билгеләп, аеруча җылылык белән түбәндәгеләрне язды: «Татарлар бердәм, энергияле һәм булдыклы халык, үзенең данлы үткәнен онытмаучы халык». Биредә И. Яковлев татарларның данлы үткәннәре турында сөйләгәндә аларның милли аңнарының үсү этабын күз алдында тота һәм моны башка Идел буе халыкларына үрнәк итеп китерә. Талантлы педагог үзенең шәхси үрнәге мисалында яшь буынны чын патриотлар, интернационалист итеп тәрбияләүгә зур көч куйды. Ул үзенең мөмкинлекләрен исәпкә алып, туган халкыннан тыш, тугандаш милләт халыкларына, шул исәптән татарларга ярдәм кулы сузарга омтылды. Аның 1908 елда Н. Ашмаринга язган хаты бигрәк тә характерлы. И. Яковлев бу хатында Идел буе халыкларына куркыныч янаган холера авыруына каршы көрәшү ысуллары турында татар телендә бер брошюра бастырып чыгару өчен Н. Ашмариннан материаль ярдәм сорый. «Татар теленә тәрҗемә итү һәм текстны корректировать итү өчен кирәк булган очракта,— ди ул,— мин үзем түләргә вәгъдә бирәм».

Чуваш һәм татар халыклары арасындагы эчкерсез дуслыкны чагылдыручы үрнәкләрне татар язучылары иҗатыннан да күпләп китерергә мөмкин. СССР Дәүләт премиясе лауреаты язучы Г. Бәширов чуваш халкы турында менә ничек сөйли: «...Безнең иң якын күршеләребез һәм дусларыбыз булган чувашларны алыйк. Аларның тыйнаклыгы, гадилеге һәм эш сөючән булулары мәкальләргә, әйтемнәргә кергән. Дуслыкка, татулыкка турылыклы булу, әйткән сүзендә тору мәсьәләсендә алар чынчыннан үрнәк була алалар».

Ике тугандаш татар һәм чуваш әдәбиятларының бер-берсенә йогынты ясавы, үзара

баетышуы аеруча Совет властеның беренче елларына туры килә. Бу чорда Г. Тукай һәм һ. Такташның шигырьләре Чабаксарда басыла. Шушы вакытларда татар укучысы туган телендә Н. Полоруссов-Шелеби, П. Хузангай, С. Эльгер кебек чуваш әдәбияты эшлекләренең аерым әсәрләре белән таныша. Утызынчы елларда исә татар-чуваш әдәбиятларының үзара бер-берсен баету процессы тагын да көчәя. Чуваш халык шагыйре П. Хузангай татар әдипләре һ. Такташ, Г. Кутуйларның замандашы булу белән горурланды. Үзенең әдәби укытучысы итеп һ. Такташны исәпләде, һәм аның якты истәлегенә 1931 елда «һади Такташка» дигән шигырен багышлады. Яхшы тәрҗемәче буларак та П. Хузангай чуваш укучысын татар поэзиясе үрнәкләре белән таныштыруга күп көч салды. Татар телен бик яхшы белгән Н. Полоруссов-Шелеби дә Чувашстанда татар әдәбиятын пропагандалау өлкәсендә зур эш башкарды. 1930 елда ул тәрҗемә иткән аерым әсәрләр «Татар матур әдәбияты» дигән җыентыкка туплап чыгарыла.

1936 елда Татарстан җәмәгатьчелеге күренекле драматург, режиссер һәм актер К. Тинчуринның иҗади һәм иҗтимагый эшчәнлегенә 25 ел тулуны тантаналы шартларда билгеләп үтте. Кунаклар арасында чуваш драматургы П. Осипов та була. Ул юбилярга үзенең машинкада басылган «Гадәттәге тормыш симфониясе» әсәрен түбәндәге сүзләр язып бүләк итә: «Азат халыкның җырчысы булган данлы юбилярга, каләмдәшем К. Г. Тинчуринга әдәби-театраль һәм иҗтимагый эшчәнлегенә 25 ел тулу уңае белән. Автордан. 28.5. 1936 ел. П. Осипов». Бу пьеса К. Тинчуринның башка материаллары белән бергә хәзерге вакытта ТАССР Берләштерелгән Үзәк Дәүләт музеенда саклана. Шуны да әйтергә кирәк: бу елларда К. Тинчуринның «Зәңгәр шәл» пьесасы чуваш теленә тәрҗемә ителә, һәм ул 1937 елда Чабаксарда аерым китап итеп чыгарыла.

1941 елда чуваш әдәбияты классигы К. Ивановның 50 еллык юбилеен бәйрәм иткәндә чуваш телен бөтен нечкәлекләре белән белгән татар шагыйре Ш. Мөдәррис аның гүзәл «Нарспи» поэмасын оригиналдан татар теленә тәрҗемә итә.

Шулай ук М. Җәлил дә Татарстанда чуваш әдәбиятын, чувашлар арасында татар язучылары әсәрләрен пропагандалаучыларның берсе булып саналды. Аның Я. Ухсайга Г. Тукайны пропагандалау идеясен биргә дә киң җәмәгатьчелеккә мәгълүм. М. Җәлил Чувашстан халык шагыйрьләре Я. Ухсай, С. Шавлы, П. Хузангай, тәнкыйтьче В. Долговлар белән дустанә мөнәсәбәттә булган. 1973 елның 23 июнендә ТАССР Дәүләт музеена язган хатында Я. Ухсай түбәндәгеләрне хәтеренә төшерә: «Совет язучыларының беренче съезды көннәрендә без Муса белән аерылмас дуслар булып әвереләдек, күп кенә рус шагыйрьләре белән очраштык. Съезд көннәрендә Муса Идел турында язган минем шигыремне тәрҗемә итте һәм аны «Коммунист» газетасының август саннарының берсендә бастырды». Соңыннан үз чиратында Я. Ухсай 1930—1934 елларда Мәскәү университетында уку һәм татар, чуваш телләрендә чыккан «Коммунист», «Коммунар» үзәк газеталар редакцияләрендә эшләгән вакытта Муса белән булган элемтәләр, вакыйгалар, күренешләр, төрле истәлекләр нигезендә 1957 елда поэма язды.

1976 елда М. Җәлилнең 70 еллык юбилеен билгеләп үткәндә С. Шавлы Казанга «Җәлилнең соңгы минутлары» исемле шигыренең кульязмасын җибәрде. Ул чуваш теленә М. Җәлилнең 14 шигырен тәрҗемә иткән. «Рухланып эшләдем,— дип язды ул ТАССРның Дәүләт музеена адресланган хатында.— Ул минем бөтен күңелемне яулады. Моны башкача әйтеп булмый. Зур җаваплылык тоеп эшләдем. Тәрҗемә процессында һич кенә дә ясалмалылыкка юл куймадым».

Ике әдәбиятның алдынгы вәкилләре тарафыннан башланган гүзәл традицияләр бүген дә дәвам иттерелә. Совет власте елларында күп кенә чуваш язучыларының әсәрләре татар теленә тәрҗемә ителде. Татар халкы арасында чуваш әдәбиятын пропагандалауда З. Бәшири аеруча зур эш башкарды. 1928 елда Казанда татар телендә «Чуваш әдәбияты» җыентыгы чыгарыла, аңа З. Бәшири тәрҗемәсендә чуваш язучыларының иң яхшы әсәрләре кертелә. Ә 1954 елда «Чуваш хикәяләре» җыентыгы дөнья күрә. Аны төзүдә һәм бастырып чыгаруда А. Калганның хезмәте гаять зур. Якын араларда чуваш язучыларының хикәяләрен туплаган шундый ук җыентык татар телендә дөнья күрәчәк. Татар язучыларының хикәяләрен туплаган җыентыкның Чабаксарда чуваш телендә басылып чыгуы көтелә.

Күңелле күренеш. Татар язучыларының ике йөздән артык әсәрен чуваш халкы бүгенге көндә туган телендә укый. Алар арасында түбәндәгеләр бар: «Чуваш кызы Әнисә» (З. Бәшири), «Намус» (Г. Бәширов), «Язгы җилләр» (К. Нәҗми), «Моабит дәфтәре» (М. Җәлил), «Тапшырылмаган хатлар» (Г. Кутуй), «Чәчәкләр сөйли белә» (Ш. Рәкыйпов), «Йолдыз тапкан егет» (К. Латыйпов) һ. б. Аларның күбесен оригиналдан татар телен яхшы белүче чуваш язучысы Василий Юдин тәрҗемә иткән.

Чувашстан белән Татарстан әдәбиятлары һәм сәнгатьләре арасында иҗади бәйләнешләр киңәя бара. Моны 1985 елда Чувашстанда үткәрелгән татар әдәбияты һәм сәнгате көннәре генә дә ачык күрсәтте. Татар-чуваш дуслыгына П. Хузангай, Я. Ухсай һ. б. ларның күп әсәрләре багышланган. Шунысы да кызыклы. П. Хузангайның фамилиясендә Татарстан башкаласы Казанның исеме чуваш телендә яңгырый. Әлеге әдип чуваш һәм татар халыклары арасындагы дуслыкны үстерүдә, ныгытуда зур роль уйнаган. Шагыйрь үзенә эшлекле киңәшләр биргән һәм иптәшләрчә иҗади ярдәм кулы сузган татар шагыйрьләренә «Туган Татарстаныма» шигырендә зур җылылык белән түбәндәгечә мөрәҗәгать итә:

Синдә туды, нурлы Казан,
Минем иң беренче җырлар.
Кайда безнең өчәр телдә
Шигырь укып йөргән еллар?
Һади Такташ, Гадел Кутуй
Миңа киңәш биргән чорлар?..

Татар-чуваш дуслыгына Я. Ухсай да зур игътибар итте. Ул «Кельбук бабай» дигән поэмасында чуваш Кельбук авызыннан Әхмәт исемле татар картына карата, «яхшы дустымкунагым», дип әйттерә.

Чуваш язучылары, татар сүз осталары кебек үк, татар каләмдәшләре турында җылы фикерләр әйтәләр. Түбәндәге әсәрләр бу хакта бик ачык сөйлиләр: «Татар шагыйрьләренә», «Һади Такташка», «Туган Татарстанга», «Хәсән Туфанга», «Тукай каеннары», «Муса Җәлилгә», «Котлы булсын», «Сәлам, туган Татарстаным минем» (П. Хузангай), «Муса Җәлил», «Мине татарга саныйлар» (Я. Ухсай), «Казан» (А. Алга), «Син китаптан болай боек карама», «Каләмен штыкка алыштырган шагыйрьгә», «Җәлилнең соңгы минутлары», «Казан Кремле янында», «Җәлил белән икенче очрашу» (С. Шавлы), «Муса Җәлилгә» (А. Канаш) һ. б. Күренекле чуваш язучысы М. Юхманың революционер-ленинчы Мулланур Вахитовка багышланган «Көнгыш — үлемсезлек кошы» исемле документаль повесте 1984 елда «Ялкынлы революционерлар» сериясендә «Политическая литература» нәшриятында басылып чыкты. Бу әсәр, тиз арада тәрҗемә ителеп, татар укучысына да җиткерелде.

Татар язучылары З. Бәшири, Г. Ибраһимов, К. Тинчурин, Ф. Бурнаш, һ. Такташ, Ш. Усманов, Т. Гыйззәт, К. Нәҗми, Г. Бәширов һ.б. лар үз әсәрләрендә тугандаш чуваш халкы вәкилләренең тулы канлы образларын тудырдылар. Чуваш халкының тормышкөнкүрешен, гореф-гадәтләрен, традицияләрен һәм культурасын, телен яхшы белгән К. Латыйпов күрше туганнарыбыз турында күп яза, чуваш поэзиясен туган телебезгә тәрҗемә итә. Чуваш халкының данлы улы, СССРның очучы-космонавты, ике тапкыр Советлар Союзы Герое Андриян Николаевка багышланган «Йолдыз тапкан егет» дигән документаль повесть аның укышы буларак кабул ителде. Гражданнар сугышы герое В. Чапаевка багышланган «Чапаевның яшьлеге» повестен да китап укучылар яратты. Чуваш һәм татар укучысы шагыйрь Р. Харисның П. Хузангайга багышланган «Чуваш җыры» исемле шигырен дә бик җылы кабул итте.

П. Хузангай, башка чуваш язучылары кебек үк, ялкынлы интернационалист иде. Аның бөтен тормышы, иҗаты һәм иҗтимагый эшчәнлеге интернационализм рухы белән сугарылган иде. Мин П. Хузангайны якыннан күреп белмим. Әмма алтмышынчы елларда бу гүзәл кеше белән хат алышa алуыма бик шатмын. Миндә Педер Петровичның берничә хаты һәм автографы белән аның «Дуслык китабы» дигән хезмәте саклана. Анда патриот-интернационалист шагыйрьнең интернациональ характеры, гадилеге, кешелеклелеге, рухи байлыгы турында сөйләүче түбәндәге сүзләр бар: «Игелекле күршем Ф. Исламовка җир шарындагы барлык шагыйрьләр туганлыгы тойгысы белән. П. Хузангай. 17 июль 1967 ел». Шул хакта да әйтеп үтәргә кирәк: халыклар дуслыгы җырчысы П. Хузангайның «Туган Татарстанга» дигән шигыре һәм «Дуслар белән» исемле җыентыгы татар мәктәпләрендә дәрестә һәм класстан тыш уку процессында өйрәнелә.

Чабаксарда һәр ел саен чыгып килгән «Хузан» («Казан») альманахында Татарстанда яшәүче чуваш язучыларының, татар сүз осталарының әсәрләре урын алуы — шулай ук күңелле күренеш.

Ике тугандаш халыкның дуслыгы музыка, сынлы сәнгать һәм театр өлкәсендәге бәйләнешләрендә дә ачык чагыла. Чуваш профессиональ сынлы сәнгатенә нигез салучылардан М. Спиридонов һәм Н. Сверчков Казан художество мәктәбендә белем алдылар. Казан дәүләт консерваториясендә чуваш халкының ихтирам казанган композиторлары — РСФСРның һәм ЧАССРның атказанган сәнгать эшлеклеләре Ф. Васильев, Т. Фандеев, А. Петров, музыка белгече, РСФСРның атказанган культура работнигы Ю. Илюхин һәм башка байтак композиторлар, музыка белгечләре укыдылар.

Казан кинохроника студиясе Чувашстан белән үзара тыгыз бәйләнгән. Чувашстан республикасында күп еллардан бирле РСФСРның атказанган культура работнигы оператор А. Дымич җитәкчелегендә корпункт эшли. Аның катнашуында республика тормышы турында сөйләүче «Ябу», «Минималь биеклек», «Чувашстан юллары», «Исәнме, Чувашстан» дигән фильмнар туды. Казан телевидениесе Чувашстан рәссамнары турында «Чувашстан буяулары», «Чуваш бизәкләре» исемле фильмнар эшләде.

Ике тугандаш халыкның культура бәйләнешләре театрлар бәйләнешендә дә ачык чагыла. Чуваш театрының күренекле эшлеклеләре (Г. Зайцев, П. Федоров, И. Максимов-Кошкинский һ. б.) татар язучыларының драма әсәрләре белән оригинал аша таныша алганнар. 1919—1920 елларда ук К. Тинчуринның «Җилкәнсезләр», Я. Кәримнең «Табылдык» кебек пьесалары чуваш теленә тәрҗемә ителә. Утызынчы елларда Чуваш дәүләт академия театры репертуарына татар драматургларының түбәндәге пьесалары кертелә: «Рупор» (Ш. Усманов), «Зәңгәр шәл» (К. Тинчурин), «Ташкыннар» (Т. Гыйззәт), соңрак чуваш телендә Р. Ишморатның «Ватан өчен», Н. Исәнбәтнең «Зифа», Ф. Бурнашның «Яшь йөрәкләр» пьесалары дөнья күрә. К. Иванов исемендәге Чуваш театрында Р. Ишморатның «Үлмәс җыр» (1958), «Серле моң» (1960), республика яшь тамашачылар театрында Х. Вахитның «Беренче мәхәббәт» (1961), «Соңгы хат» (1965) пьесалары буенча куелган спектакльләрне тамашачылар яратып кабул иттеләр.

Чуваш драматурглары әсәрләре дә үз нәүбәтләрендә татар тамашачалары арасында зур ихтирам казанды. Әйтик, П. Осиповның «Айдар» драмасы, Г. Харлампьевның «Соңгы очрашу», «Язгы моң» кебек пьесалары буенча эшләнгән спектакльләр Татарстан театрлары сәхнәсендә уңышлы куела. Бу фактлар чуваш һәм татар халыклары арасында культура бәйләнешләренең ныгуы, үсүе турында сөйли. Алар бер-берсенең культура үсешендәге уңышларын ныграк һәм тирәнрәк аңларга, казанышларның интернациональ сыйфатын тоярга ярдәм итәләр.

Күргәнегезчә, тугандаш халыкларның культура казанышлары күпмилләтле Ватаныбыз һәм социалистик илләр халыклары, бөтен Җир шарындагы хезмәт ияләренең какшамас дуслыгы турында сөйли, кешеләрне коммунистик идеаллар, Коммунистлар партиясе һәм Совет хөкүмәтенә бирелгәнлек, интернационализм рухында тәрбияләү эшенә зур өлеш кертә.

**Фәнис ИСЛАМОВ,**
педагогия фәннәре кандидаты.

# Яков Ухсай,

Чувашстанның халык шагыйре.

## Мине татарга саныйлар

Мине татарга саныйлар,
кыстыйлар: «Чәйләп алыйк!»
Һәм түбәтәй кидерәләр,
чак кына кыңгыр салып.

Охшаган икән охшаган!
Чуваш нигә тансын соң:
миндә татар кыяфәте —
тумыштан ук анысы!

Зур күзләр, татар күзләре,
нык тупсалы киң яңак...
Татар белән аралаштык,
гасырлап кына санап.

Мәҗит Гафури белән без
Уфада күп көрештек...
Зур шагыйрь булырга шунда
хыялланды бу кешең.

Мин, сагынып, өенә дә
килә идем кайвакыт.
Каршылый иде ул җырчы
самавырын кайнатып.

«Шундый шагыйрь булсаң икән!» —
дип өметләндем күпкә.
Каурый төрткән канатларым
тарттылар мине күккә.

Әле бер билгесез шагыйрь,
унҗиде яшь ул чакта,
татар җырлары җырладым
үз-үземне кочаклап.

Охшарга теләдем аңа —
гаҗәеп шагыйремә.
Шуңадыр шигырьләремдә
гафурилык күренә.

Һич тә ерак тарих түгел,
ул көннәр якын, тере —
Муса Җәлил, балкып, миңа
Мәскәү күрсәтеп йөри.

Мусаның җан яктылыгы
йөрәгемдә чагылды.
Шуңадыр да инде, бәлки,
миндә татар чалымы.

Җәлилсез Казанга да мин
Элеккечә еш киләм.
Шуңадыр чуваш Ухсайны
татарлар яхшы белә.

Яшьлекне искә төшереп
барлыйм урамнар рәтен,
ә янымда Хәсән Туфан —
минем чал ахирәтем.

Аның җаны якын миңа —
ачам бар серләремне.
Аяк асларында ташлар
йомшаклар, мендәрмени!

Туфанча язарга теләп
үзәкләрем өзелә.
Шуңа күрә дә татарлык
саркыгандыр йөземә.

Чын күңелдән үгетлиләр:
«Түбәтәеңне салма!»
Әйтерсең, мине түбәтәй
чын татар итә ала.

Охшаган икән — охшаган!
Чуваш нигә тансын соң:
миндә татар кыяфәте —
тумыштан ук анысы!

Ренат ХАРИС тәрҗемәсе.

# Порфирий Афанасьев

## Тизлек

Туган җирем киңлегенә
Карыйм да калам таңга.
Кая барсам да сагынып
Әйләнеп кайтам аңа.

Сура елгасы буенда
Шаулый кара урманнар:
Алар шаулый — бабамнарның
Зарлы җыры сыманнар...

Урманнардын калка бабам,
Чабаталары тузган,
Ләкин үткен карашына
Өмет нурлары тулган.

Ялангач иңбашларында
Камчы эзләре яна.
Разин, Пугачевлар белән
Бергәләп дауга бара...

Чапаев булып токтан ул
Атының тезгеленнән,
Калышырга исәбе юк
Замана тизлегеннән...

Ә космонавт Андриян
Бабама кул изи — инде
Галәмнәр киңлегеннән!

Шамил МАННАПОВ тәрҗемәсе.

# Юрий Семендер

## Пинерби

Күпме исем! Исемнәрдән
Бер генә исермәдем.
Кояш булып яна җанда
Берсе шул исемнәрнең.

Язгы сулар гөрләп ага —
Пинерби,
Ак йолдызлар дөрләп яна —
Пинерби,
Алсулана Идел таңда —
Пинерби,
Сөйгән ярым көтә анда —
Пинерби.

Һәркемгә таныш ул бездә.
Әмма миңа ул исем
Хәтерләтә сандугачны,
Шомырт чәчәге исен.

Җылыта мине ул исем,
Елата — каен сыман.
Тик мин аның күзенә дә
Карарга кыенсынам.

Язгы сулар гөрләп ага —
Пинерби,
Ак йолдызлар дөрләп яна —
Пинерби,
Алсулана Идел таңда —
Пинерби,
Сөйгән ярым көтә анда —
Пинерби.

Роберт МИҢНУЛЛИН тәрҗемәсе.

# Раиса Сәрби

## Ялвару

И, Кояш-әткәм, яндыр Аны — әйләнсен көлгә!
И, Җир-әнкәм, йот син Аны — калмасын эзе!
Ул бит сезнең аккоштай кызыгыздан көлә...
Ул бит сезнең аккоштай кызыгызны
тиңләштерә йолкыш тавык белән.

Кояш-әткәм, синең утың,
Җир-әнкәм, горурлыгың
укмаштылар кызыгызның күкрәгендә,
янартауга әйләнделәр йөрәгендә...

Хурлыгыннан кызыгыз сезнең
йолкый чәчен,
Күзләреннән елга-елга ага
канлы яше...
И, Кояш-әткәм, яндыр Аны, көл ит!
И, Җир-әнкәм, йот син Аны берүк!

Кояш-әткәм, кара төнне син күрә алмагандай
күрә алмыйм Аны...
Җир-әнкәм, кайнар җилләрне син күрә алмагандай
күрә алмыйм Аны.
...Тукта, тукта! Кемнең аһы күкрәде күк гөмбәзендә?
Тукта, тукта! Кем шәүләсе төшеп китте җир ярыгына?

Сөеклемнең тавышы түгелме соң?
Сөеклемнең шәүләсе түгелме соң?

Аныкы ич, әйе, Аның тавышы...
Аныкы ич, әйе, Аның шәүләсе...

Йа, Кояш-әткәм, утта тотма Аны!
Йа, Җир-әнкәм, йотма, йотма Аны!
Мин Аны сөям,
мин Аны сөям,
мин бит Аны үлеп яратам!

Ренат ХАРИС тәрҗемәсе.

# Михаил Юхма

## Ай юлы

Күз чагыла, хыял уйный нурыннан:
Идел аша ай нурлары сузылган.
Бик сагынган, бик ямансу чакларда
Чакыра мине «Ай юлы» еракларга.

Сөйли халык, әүвәл заман бер егет
Шушы юлдан чал Иделне кичкән дип,
Җидегән йолдыз чүмеченә тутырып,
Бәхет суларын туйганчы эчкән дип.

Сабыры һич җитмәгән ди егетнең
Көймәчене ярда көтеп алырга.
Нигә дисәң, зарыгып көткән ди аны
Җан сөйгәне елганың аръягында.

Һәм бәхетен тапкан ул батыр егет
Юлдаш иткән өчен үзенә таң нурын...
Эх, шулай соң үз бәхетем янына
Җитәргә дим, узып көмеш «ай юлы»н!

## Василий Давыдов-Анатри

### Нигә елый каен?

Уртаклашыйм ничек
Каенның кайгысын? —
Каенның кайсыдыр
Каерган кайрысын.

Ә икенче берсе
Кызганып тормаган —
Каенга зур итеп
Исемен сырлаган...

Себеркегә дип тә
Сындырганнар аны.
Әрнетә — каенның
Күз яше тамганы.

Карыйм да каенга,
Күңелем тырнала —
Ни үле, ни тере,
Ул чак-чак тын ала.

Яз җитсә, яңадан
Яралар ачыла:
Тып та тып каенсу —
Татлы да, ачы да.

Роберт МИҢНУЛЛИН тәрҗемәсе.

## Александр Галкин

### Иделдә

Иртә белән төшәм мин Иделгә —
Иделемнең шундый тын чагы.
Коенам мин Идел кочагында,
Гел кояшлы аның кочагы.

Үз сабыен сөеп иркәләгән
Ана кебек һаман назлы ул.
Хәтерләтә күксел төсе белән
Елмаюлы, якты язны ул.

Күк томанлы Идел киңлекләре
Якынайта миңа җиһанны.
Ватанымны сөеп җырлар өчен
Иделемнән алам илһамны.

Госман САДӘ тәрҗемәсе.

# Хведер Агивер

# БАЛЛЫ МЫЕК

ХИКӘЯ



Умарталык аланындагы иске йорт, чебешләр арасындагы тавыктай, әллә кайдан күзгә бәрелеп тора иде. Әнә шул өйнең сәкесендә биштәрен рәтләп маташкан Иркәй кинәт сискәнә калды. Бакса, менә кем зеңләткән икән тәрәзәне. Ул пыялага бәрелеп имгәнгән йонлач аяклы бал кортын сак кына тотып алып, колаша өстенә куйды. Кәсеп итеп бик еракка очкан ахры бахыр, караңгы иңүен абайлагандыр да тиз-тиз өенә атылгандыр, ашыгудан әнә шулай үз оясын да узып киткәндер.

Иркәй башын күтәрде дә, күктәге тонык сары айны барлаганнан соң, ашыга башлады: келәтенә кереп, биштәренә кәрәзле балын, күчтәнәчен тыкты, аннары эш киемен салып атты да әле кичә генә алты чакрымдагы сельпога барып алган өр-яңа коңгырт костюмын киде. Бүген аның яңа кием кию тикмәгә генә түгел иде, билгеле.

Ыйхалар аның болай ыспайланып юлга әзерләнүен бусагадан игътибар белән күзәтеп торды, әмма Иркәй бик мәгънәле итеп йодрыгын күрсәткәч, маэмай бүген үзенә ялгызы гына умарталыкта төн уздырырга туры киләчәген ачык төшенде.

Күктә тулган ай түгәрәк башын кырыс кына чайкап куйгалый, үлән каплап өлгергән юлда куак күләгәләре тирбәлә, кайдадыр урман ешлыгында шомлы итеп кыргавыл кычкырып куя. Куерган тынлыкта аяк тавышлары да әллә ничек хәвефле яңгырый иде. Әмма Иркәй өчен болар ни бар, ни юк — аяк астындагы җирне тоймый да иде ул бүген. «Һе,— дип акланды ул дүрт аяклы дустына караштыргалап,— син генә җитмисең инде бүген миңа... Ярар, Ыйхалар, үпкәләмә әле. Бүген үз эшләрем дә муеннан, синең белән маташырга бөтенләй чамам юк шул, йонлачкаем, мәшәкатьләрем, ай-һай, зурдан бүген. Әгәр шуларны уңышлы хәл итсәм, кайткач серләшербез әле... Тик белмим шул, белмим, уңышлы башкарып чыгармынмы? Иһи-һи-һи-и...»

Тукта әле, чү! Иркәй әллә кайдан тәгәрмәч тавышын ишетеп алды. Көпчәкләр шыгырдавы һаман көчәя баруын чамалагач, якындагы куак артына кереп яшеренде. Соңга калган олау дөбер-шатыр узып киткәнче, ул күләгәдәге караңгылыкта посып торды. Аннары урыныннан кузгалып, тир бәреп чыккан маңгаен учы белән сөртә-сөртә, эре-эре атлап юлын дәвам итте. Кыюлыгының авызга капкан шикәрдәй эреп юкка чыга баруын тоеп, күңелсез генә: «Их, бу тормышкайны! Күр инде әй, шүрәлемени, кеше күзеннән качып йөрергә туры килә ләбаса,— дип уйлады.— Бәлки мондый олы эшкә көндезен, тирә-як нурга коенганда тотынырга кирәктер? Бәлки төн уртасында тел дә ачылмас? Әллә ничек каракларчарак килеп чыга төсле болай. Хәер, бүтәнчә фикер йөртсәң, артык баш катыру да файдасыз. Утын ватылган, чыра теленгән, мичне тергезеп җибәрәсе генә калды...»

Менә бу соңгы уе Иркәйне нигәдер аеруча дәртләндереп җибәрде. Ул сынын турайтып, күкрәген киереп, җиңеләеп киткән тарантас шикелле, елдамрак бара башлады.

Төнге юлаучыбыз авылга киң һәм нык-нык атлап килеп керде. Почмактан өченче йортка барып җиткәч, бераз сулу алып, як-ягына күз ташлады. Капка бигенә генә үрелгән иде, чиләкләрен шалтырата-шалтырата

күршедән Пылаги җиңги килеп чыкмасынмы. Тапкан икән су ташыр чакны, җенле корткa!

Иркәй юл аркылы төшкән агач күләгәсенә көчкә сикереп өлгерде. «Хатын-кыз теленнән алла сакласын!»

Пылаги җиңги уфылдап үзенең түбән очтагы өенә кире кереп йомылуга, колхоз идарәсе ягыннан шатыр-гөтер трактор килеп чыкты. Менә бәла: Иркәй посып торган агач турысына якынлашуга, дерт-дерт эшләгән моторы кинәт сүнмәсенме. Тракторчысы моңа әллә ни пошынмады бугай: ашыкмыйча гына кабинасыннан төште дә коедан су алды, башта үзе эчте, аннары машинасына салды һәм тәгәрмәч-чылбырга таянып, тәмәкесен кабызды. Нидер мыгырданып, моторда казынып маташты, аннары кулын селтәде дә кире идарә ягына таба атлады.

Күләгәдәге Иркәй ни тере, ни үле дип әйтерлек бер хәлдә иде. Нәкъ ярты сәгать буе кымшанырга да куркып торды. Үзен бу йорт алдында күреп калуларын бөтенләй теләми иде ул. Оятыннан утсыз-төтенсез дөрләп янарга мөмкин ич! «Умарталыгыңда гына йокы симертеп ятсаң ни була инде сиңа, карт юләр? — дип битәрләде ул үзен-үзе.— Юк шул, кәсеп итәргә кузгалдың. Кайда егыласыңны белсәң, шунда мендәр түшәп куяр идең дә... Җитмәсә ничек каршылыйсын да белмисең ич әле. Бәлки тегендимондый бәлаләргә кереп батканчы, кире сыпыртыргадыр?»

Тымызык төн. Җылы. Авылның икенче башыннан гармун моңлануы ишетелә. Аның сузып-сузып алган сулышлары караңгы киңлекләрне гизеп, җирдәгеләргә тәмле тәшләр юрап, кире таныш урамнарга төшеп сеңә. Бу моңнар төрле икеләнү, өркүләрне үз дулкыннарында тирбәтеп, Иркәйне дә яхшы ук тынычландырды. Җитмәсә, ул күзәткән тәрәзәләр дә якты нурлар сибеп кызыктыра иде. «Керәм!»

Иркәй келә бавын тарткалады. Әмма җавапка ләм-мим. Иркәй ныграк шалтыратты — тагын җавап юк. Шуннан соң ул, келәне шакы-шокы китереп, капканы үҗәтрәк кага башлады.

— Кем бар анда?

Бу тавыш Иркәйне сискәндереп җибәрде.

— Мин... Ач әле, Көдери.

— Кем соң син?

— Мин инде... Иркәй, умартачы Иркәй.

— Иркәй? Баллымыекмы?

— Нәкъ үзе.

— Син нәрсә төн уртасында болганасың, юләр сатасың соң әле?

— Нинди юләр сату ди ул, ач әле син.

— Нишләргә дә белмим инде, белмим...

Бик шылдыр-шылдыр этеп куелды һәм Иркәй, ниһаять, бәладән коткара торган капка эченә узып, бөтен тәрәзәләре белән үзенә төбәлгән урамнан яшеренде. Эчке күлмәкчән генә чыккан Көдери йөгерә-йөгерә баскычтан менгәндә:

— Ярар, кер инде,— диде.

Иркәй капканы гына түгел, өйалды ишеген дә бикләргә онытмады.

Көдери өе курчак кебек иде. Юылган, җыйналган, чәчәкле пәрдәләр, чаршаулар элеп бизәлгән. Ә урын-җирен, урын-җирен генә күрсәгез икән! Каурый ыргытсаң, ул да күпереп торган түшәккә төшеп батар иде. Тулган айдай тулышкан Көдери үзе исә шундый йомшак күренә иде ки, күзең төшсә, алырмын димә... Ул тиз арада бүлем артыннан киенеп чыкты да, арт саннарын биетеп, тәрәзә буена узды һәм кунак каршындагы эскәмиягә килеп утырды. Аның канәфер чәчәге төсендәге кыска итәкләре ап-ак йомры балтырларын каплап бетермәгән иде. Ах ул йомры балтырларны — кабартманың үзе иде, билләһи, үзе... Иркәй минуты белән кызышып китте һәм, карашын көч-хәл читкә күчереп, биштәрендәге нәрсәләрен өстәлгә чыгарып тезә башлады.

— Мин монда ни... күчтәнәчләр белән ич әле... Көтмәгәнсеңдер?.. Көдери, син ни... урам тәрәзәләреңне капла әле, тынычрак булсын. Бүген төне дә әллә юри шунда көннән яктырак...

Көдери дәшми-тынмый пәрдәләрне корды һәм, нигәдер көлемсерәп, очкынланган күзләрен кунакка төбәде. Иркәй, тамак кырып, өстәл артына ипләбрәк утырды.

— Мин ни... сиңа күптән кагылырга җыенып йөри идем инде. Өченче көнне дә җыенган идем, үзең әллә кая китеп юкка чыктың. Кайда югалдың соң син?

Көдери, гөнаһсыз елмаеп, һәм шул елмаюыннан кызлар кебек яшәреп китеп:

— Өченче көн дисеңме? — диде.— Өченче көн мин Корнавыш базарына бардым. Тегендә-монда киләп сарып йөреп соңга калдым да бер сеңлемә куна керергә туры килде.

Ах бу мут хатынны, күзгә карап ялганлый бит, әй! Анда синең сеңлең түгел, ботак очы кардәшең дә юк лабаса. Сеңел, имеш. Итәгеңне җилфердәтеп озын торык Көргери Сидирев янына ыргылуыңны беләбез инде. Беләбе-е-ез!

Башында шундый уйлар кайнаса да, Иркәй, үзен тыеп:

— Үзем дә уйлаган идем аны, Көдери,— диде.— Базарга киткәндер дип. Вакыты да бигрәк шуңа кулай иде ләбаса — печән өсте. Көдери, син стаканнар китер әле. Сайрашу җилеме алып килдем, тамакны чылатыйк әле.— Иркәй көмешкәле банкасын өстәл уртасына этеп куйды.— Капкаларга бирәр нәрсә табылса, зыян итмәс иде.

Көдери почмактан ике стакан һәм, әллә кайчан туралганлыктанмы, кырыйларына мае эреп аккан, телемнәре кибә төшкән шыртан — чуваш казылыгы алып килде...

Иркәй йөрәкләнеп китеп:

— Их, Көдери, Көдери, шайтан алгыры, аңламыйсың син мине,— диде.— Бу сәгатьләрне күпме көтүемне генә белсәң икән!

Көдери, йөзенә елмаю чыгарса да, тагын эндәшмәде.

— Әгәр дә мәгәр, аңласаң... Әйе,әгәр аңласаң, син болай яшәр идеңмени? Хараплар иттең син мине, бөтен тормышымны җилгә очырдың. Синең белән күпме ир-ат татлы гөнаһка батмагандыр, бары тик мин генә ябалак кебек...

Көдери йомры иңнәрен сикертеп:

— Үзең пешмәгән булгач, кеше гаеплисең юк,— диде.— Иртәрәк уяналар аны.

— Соң... кешедән яхшы түгел дип...

— Кешедән, имеш... Менә хәзер тупылдап килеп кердең ич әле.

— Бүген эш башка.— Иркәй тора-бара кыюланып эндәште: — Көдери, чык син миңа кияүгә, ә!?

Хуҗа хатын сискәнеп китте:

— Абау, абау... Кияүгә? Сиңа чыгаргамы?

— Кияүгә шул. Нәрсәсе гаҗәп монын?

— Син бераз ычкынып китмәдеңме соң, Баллымыек?

— Юк, юк, мин кем әйтмешли, тулы акылымда.

— Бабай туры киләсең бугай ич син миңа?

— Нинди бабай булыйм ди инде... Абый дисәң әле бер хәл. Алтмышка житкәнче дә нәкъ ике ел теркелдисе бар әле Иркәеңнең. Син үзең дә миннән нибары ун яшькә генә калышасың сыман ич?

— Унга түгел, унөчкә.

— Шулай икән, авыз чайкап торасы да юк... Я, чыгасыңмы?

— Ни әйтергә дә белмим инде. Бигрәк карт төс кергән шул йөзеңә.

— Син, Көдери, тышкы кыяфәткә генә алданма. Аның каравы минем җаным быелгы кәрәздәй яшь. Ни, тартырта ярыймы соң синдә? Нәрсәдер тамакны әчеттерә.

— Тартсана, өйдә ирләр исе таралсын бераз.

«Ирләр исе? Бәлки ул исне моннан инде тәтәсләп үчерергә кирәктер? Шыртаны да шуны гына аңкытып тора... Тик бу хакта соңыннан, эш барып чыккач кына...»

— Койман да тузган инде. Каралтың почмаклары бөтенләй черегән. Сыер абзарың исә яртылаш җиргә сеңгән, күр дә тор, тиздән хуҗасының өстенә җимерелеп төшәчәк... Өч-дүрт көн элек урамыгыздан узып бара идем, карасам, ишегалдыңа бер кәҗә килеп кергән. Көчкә куып чыгардым үзен.

— Ишегалды миңа нәрсәгә? Ашарга аш, кияргә кием булса, шул җиткән. Их, калада урнашырга иде ул. Анда һәммәсе дә уңайлы: фатир казнаныкы, газыдыр, суыдыр — барысы изнигам. Оҗмахта шикелле җырлап кына яши бир.

— Кара син аны! Шәһәр ул, җаныем, шәһәр инде. Аның үз борчумәшәкатьләре, анда да бушлай гына берни дә бирелми. Син, Көдери, үзең булып кал да кешечә яши бир инде.

— Тукта, тукта, син монда акыл сатарга килдең мәллә? Кияүгә чыгарга өндисең тагын. Шушындыйга чәчең бәйләсәң ничек аяк атларга кирәклеген дә өйрәтә башлар.

— Соң мин яхшырак яшәвеңне генә телим ич. Кешечә.

— «Кешечә, кешечә»... Әйдә, чөмереп бетер дә сыпырт моннан, Баллымыек! Бар, бар, элдерт!

— Тукта әле, Көдери, ашыкма бик. Ни, алайсам бүтән акыл өйрәтмәм соң, үзеңә генә колак салып торырмын.

— Менә шулай. Кайчан нәрсә сөйлисен кеше яхшы чамаларга тиеш. Син, умартаңдагы балдай татлы булсаң гына, уңарсың. Шул чак күз күрер.

Бүлмәдә беразга тынлык урнашты. Иркәй, гаебен югандай:

— Син миңа бик сукранма, җанкай, телем кытыршырак минем,— диде.— Мин һаман шул хакта сүз катам инде, Көдери, колак салчы. һаман шул хакта — синең белән уртак оя кору хакында. Умарталыкта, әнә, яңа бура бураттым. Шуны өлгертеп керсәк, безнең гомергә менә болай җитәчәк.— Иркәй башын артка чөеп, кул яссуы белән бугазыннан сызып күрсәтте.— Ялгыз гына хуҗалык алып бару чынлап та туйдыра, әйдә, сат та җибәр син өеңне. Ансыз да яшәрбез. Теләсәң, каз-үрдәк үрчетербез. Акчасы табылыр, җитәрлек мая тупладым инде мин.

— Акча, бура, йорт... Ансыз да яшәрбез, имеш... Син нәрсә, әллә башкага телең әйләнмиме? Һаман бер нәрсәне чәйнисең дә чәйнисең. Әйтерсең лә кешене түгел, йорт-җир кодалыйсың,— дип ачуланды Көдери. Әмма хәзер аның тавышында баягы кырыслык юк иде инде.

— Соң мин ни... мин, өеңне сатсаң, без бергәләп миндә яшәр идек, дип кенә...

— Бергә яшәргә? Атна-ун көн үзеңдә асрагач ук: «Әйдә, дүрт ягың кыйбла!» — дияр идең бугай. Сез ирләрне беләм ич инде мин.

— Нигә болай гел кире сукалыйсың соң син, Көдери? Мин чын күңелдән ләбаса. Күптән күңелемдә огеанны белдерүем ич. Егет чакта ук күзләп йөрдем лә мин сине, авыз ачарга гына базмадым...

— Сез башта барыгыз да шулайрак сайрыйсыз. Йомшак җәеп, катыга утыртасыз.

— Күр инде әй! Бер селтәнү белән, бер буяу белән... Дөресен генә әйтәм мин. Сиңа ул чак уналты, ә миңа, санап карасаң, утыз иде. Төннәрен урам чатларында хыялланып күпме йөрдем. Чынын гына ачсам, курыктым мин. Абыем тормышыннан гыйбрәт алгач, юк инде, миңа да мондый камыт кидерә алмассыз, дип уйладым. Абыемны җиңги утырта язды бит: ирем мине үтермәкче була дип тоткан да әләк язган. Бик кирәк иде инде ул, үтерә, имеш... Ә бәлки абыем да гаепле булгандыр, без ир-атның теле кыска, кулы озын. Абыемның холкы кырыс, минекенә бөтенләй охшамаган иде. Син аны хәтерлисеңдер ич?

— Хәтерлим, билгеле. Колгадай озын, ябык иде үзе. Тиктомалдан күзләрен елдырымдай очкынландырып җибәрер иде дә...

— Дөрес, дөрес, нәкъ өстенә генә бастың. Мин менә шул чакларда ук сиңа гашыйк идем инде. Күземә чалынуың була, паралич сугамыни, баскан җиремдә баганадай катам да калам. Сәбәбе дә җитәрлек иде шул:

алдан карыйсыңмы, арттанмы — син яңа пешкән кабартма кебек. Юк, кабартма гына түгел, баллы тәпән шикелле. Тик кагылырга иртәрәк әле дип уйлап йөрдем. Бал әчемәсен дисәң, мичкәне ачарга ярамый. Үкенечен үкенеч, тик ул чакта шундый яшь кызга якынлашырга базмавым рас.

Көдери, кулларын калку күкрәге өстенә кушырып, мыштым гына елмаеп тыңлап утыра иде. Ә Иркәй, үткәннәрне хәтерендә яңартып, сөйли дә сөйли, һәм, чалгы белән «чыш-ш» итеп селтәгәндәй, авыр сулап куя иде.

— Ул арада сугыш афәте килеп чыкты. Башта абыемны, аннары мине дә яу кырына чакырдылар. Абыем шул китүдән әйләнеп кайтмады, ә абзаң, менә могҗиза, бөтен гарасатны исән-аман кичеп чыкты. Язмыштан шулкадәр уңуыма әле дә шаккатам: дүрт ел буе ут эчендә йөреп, гәүдәмнең ник бер җире тырналсын! Ә сине, Көдери, дары өермәләрен кичкәндә дә онытмадым мин. Кайткач ук өйләнәчәкмен, дип хыяллана идем. Авылга уралгач исә кая ул өйләнү! Яманатың бөтен тирә-якка таралган, исемеңне телгә алганда, һәркем авызын ерып җибәрә. Ниятемне ирексездән авызлыкларга туры килде. Кеше сүзе кеше үтерә диләр. Их, ул имеш-мимешләрне! Барысына да төкерәсе дә өйләнәсе генә калган икән! Әфсен-төфсен, бетте, китте. Синең белән бәйләнү гарьлеген бер күтәрсәм, хәзергә кадәр болай ялгыз азапланыр идеммени инде? Тик ул чакта миңа кияүгә чыккан булыр идеңме икән син, Көдери?

— Белмим шул,— диде Көдери коры гына.— Узган көннәр куе томан артында калды инде. Бәлки чыккан да булыр идем.

— Әйтмә дә инде... Их, якын булса да, терсәкне тешли алмыйсың шул. Бу әйтемне минем турыда гына чыгарганнар диярсең. Ялгызым михнәт чигү тәмам теңкәгә тигәч, еш кына: менә хәзер Көдерине үземә алам да кайтам дип йөрәксенә идем. Нәкъ шул елларда мине сәвиткә секретарь итеп куймасыннармы. Кинәт кенә кеше күзенә чалына торган затка әйләндем дә киттем. Шуннан соң әллә кем белән бәйләнеп, ничек үз исемеңне куләгәлисең инде? — Иркәй Көдеригә күз салып, уңайсыз гына тамак кырып куйды.— Ындыр каравылына күчкәндә чәчләрем чаллана башлаган иде инде. Төннәр буе синең хакта уйлап ятуым да эзен салмый калмагандыр. Ә син һаман кешечә яшәргә өйрәнмәдең, бу юл сине теге... кем белән... Менә шуннан соң Иркәең хатын-кыздан ераграк торырга карар бирде дә инде: умарталыкка җибәрүләрен үтендем. Алты ел эчендә ун баш ояны кырыкка җиткердем, тагын берничә елдан йөзгә тутырырга исәп. Эшкә кулым ята минем. Я, ничек, Көдери, чыгасыңмы инде миңа? Ә?

Иркәй, эштән чыгарылган аттай, һы-ы-ых, һы-ы-ых килеп авыр сулый, авызыннан пар белән күбек кенә чыкмый иде.

Көдери, элеккечә үк елмая биреп, бар сүзне уенга гына боргандай:

— Юу-у-ук,— диде.— Кияүгә чыгу ир-атны кич кунарга кертү генә түгел ул. Бигрәк кабаланасың инде син!

— Нинди кабалану ди ул? Мин гомер буе шушы хакта гына уйланып яшәдем. Калган бөтен тормышыбыз...

— Ышан син ирләргә! Ә бәлки мине алдалыйсың гынадыр? Ялгыз хатынны төп башына утырту кыенмыни?

— Һәй, син тагын юкны сөйлисең дә инде. Әллә миңа да ышанмыйсыңмы? Ялгызыңа йорт тоту кыен, шуны да кайгыртуым ич бу. Искемоскыңны сатыйк та бергәләп умарталыкта төпләник. Анда бәрәңгеме, суганмы — барысын да үстерергә мөмкин. Кеше күзеннән аулакта, ә?

Көдери йөзендәге елмаю секунды белән юкка чыкты.

— Син нәрсә, Баллымыек, һаман бер нәрсәне колакка тукыйсың әле? Сат та сат, имеш. Алай бик теләгәч, тот та үзеңнекен сат! Кеше күзе дисәң, мин аннан бөтенләй курыкмыйм. Кешедә кемнең эше бар? Авызың ни сөйләгәнне колагың ишетми. Ошамыйм икән, алдыңнан артың матур — сыпырт кына. Сине монда төн уртасында чакырып китергән зат юк, үзең килеп кердең.

— Анысы шулаен шулай.
— Алайса ни дип теленә салынасың?
— Соң мин...
— «Соң мин, соң мин»...— дип үчекләде аны Көдери һәм Иркәйгә сынаулы күз ташлады.— Үз кесәңдә җилләр уйнагач, минем дәүләткә нәфес салдыңмы?
— Минемме? Җилме? — диде гарьлеге килә башлаган Иркәй.— Син Иркәеңнең кенәгәсендә күпме мая тупланып беләсеңме соң? Кияүгә чыксаң, иртәгә үк барам да бөтен акчамны алам. Күгәрчен кебек гөрләшеп кенә яшәячәкбез.
Йөзе ачылып киткән Көдери:
— Кара син аны, күгәрчендәй гөрләшеп ди тагын! — дип көлеп җибәрде.— Юмалый-юмалый күндереп тә куюың бар мине, картлач.
— Әйдә, берне генә күтәр инде, ә?
Әмма Иркәй бу юлы да ялгызы гына эчте. Аннары тәмам кыюланды, тәннәре кызышып китте. Көдери янына күчеп утырды да кулын аның беләгенә салып:
— Көдери... Я ничек, калыйммы мин бүген синдә генә? — диде.
— И-и, нишләргәдер инде синең белән...
— Көдери, их син, Көдерикәем! Көдери генә түгел, бал тулы тәпәнем син минем. Бәлки әле син миңа бер ул да бүләк итәрсең, ә?!
Күңеле тулган Иркәй чыдамады, хисләрен җырга салып яңгыратырга керешге:

Юлдаш ит син ерак юлларда
Кара да гынай туры юрганы.

Көдери аңа шулкадәр киң сулышлы югары тавышы белән кушылды ки, Иркәй хәтта тотлыгып китеп, ирексездән тәрәзә яныннан читкәрәк тайпылырга мәҗбүр булды. Өй хуҗасына сыңар күз ташлауга: «Булды, эш уңды»,— дип сөенеп куйды.
Көдеринең зур яшел күзләренә мөлдерәмә яшь тулган иде. Ул хәтта балаларча үксеп тә куйды һәм аның бу үксүе кинәт урнашкан тынлыкта әллә ничек сәер яңгырады. Аннары ул кунагының колагына:
— Күп акча җыйдым дисеңме әле син? — дип пышылдады.
— Күп, Көдери җанкай, бик күп. Мең ярым...
— Кара син аны,— дип сузды Көдери.— Кара син аны-ы-ы... Кыйбатлы товар икән ич мин!
Хуҗа хатын шуннан соң кинәт кырысланып китеп өстәде:
— Я, җитте, тор әйдә, буш чүлмәк. Җитез генә элдерт моннан, табагач алуымны көтеп торма! Кара син аны, ә, мең ярым, имеш... Күрәсеңме, шәфәкъ яктырып килә, таң ата әнә. Бар, бар элдерт, тәкәббер хәсрәт, югыйсә я кеше күреп калыр!
Иркәй сыңар сүз әйтергә өлгергәнче, типкәләнә-типкәләнә өйалдына, аннан ишегалдына һәм урамга килеп чыгуын сизми дә калды. «Ай-яй-яй, бу Көдери беләкләрендәге көчне генә күр әле син, костюм якасын җирлеге белән диярлек өзеп ала язды лабаса...»
Иркәй капка төбендә таптанып һәм яңа костюмын сак кына каккалап: «Их, нәрсәдер тиешенчә килеп чыкмады ич әле бу безнең,— дип уфтанды.— Теләгәнчә оешмады. Бу хатын-кыз халкын юньле-башлы аңлау мөмкинмени? Инде сүзләрнең дә татлысын, ягымлысын гына сайладым кебек югыйсә, акчаны да...»
Якында гына капка шыгырдавы, чиләкләр чыңлап куюы аны тагын исен җыярга мәҗбүр итте. Пылаги җиңги янә суга теркелди икән ләбаса! Иркәй ике дә уйлап тормый агач артына посарга мәҗбүр булды. Пылаги җиңги кире өенә кереп киткәч кенә, ул ашыга-ашыга юлга төште дә, авыр сулап, авылдан туп-туры умарталыкка таба кызуларга керешге!

Көнчыгыштан алсу нур көлтәләрен сибә-сибә шәфәкъ җәелеп килә, ә каршыдагы ай, Иркәйне мыскыллаган сыман түгәрәк йөзен күккә чөеп, тавыш-тынсыз хихылдый төсле иде.

**Виталий Енеш**

# ИРЛӘР БУЛЫЙК

хикәя



Безнең аралар нилектән бозылгандыр — әлегә хәтле төшенеп җитә алмыйм, билләһи. Югыйсә, өчебез дә бер бүлмәдә, бер бүлектә эшлибез, Алексей Васильевич белән дә, Сергей Петрович белән дә серләр уртак иде. Инде менә нишләптер икесе дә минем белән исәнләшми башладылар. Читен, бик читен хәл, әлбәттә.

Башта Алексей Васильевич белән Сергей Петрович арасыннан кара мәче йөгереп үтте. Ярый әле мин килештердем үзләрен. Тик... Үз башыма булдымы соң?.. Чү, барысын да тәртибе белән сөйлим әле.

Бу хикмәтләр узган язда ук башланды. Бүгенгедәй хәтерлим, атнаның беренче көне иде. Эшкә йөгереп дигәндәй килеп керсәм, минем дуслар әллә кайчан исәп-хисапка утырганнар, каләм кыштырдаталар. Күреп алдым: хәлләр булган монда — өстәлләрен үк икесе ике почмакка этеп куйганнар. Шулай да минем кәеф шәп, авыз ерык:

— Сәлам! — мин әйтәм,— нәрсә, урын бүлешә башладык мәллә?

Дәшмиләр. Сәламне дә алмыйлар. Бер-берсенә очып кунарга торган яшь әтәчләр кебек, каш астыннан гына карап-карап куялар.

Шунда да уен-көлкегә бормакчы булам:

— Әллә ялгыш килеп кердем инде? — дим.— Алайса, таныш булыйк: мине Виктор Викторович диләр. Ә сезне, иптәшләр, кем дип белик?

Авызларына су капканнардыр болар!.. Берни эшләр хәл юк, өстәлем янына килеп утырам да эшкә чумам. Мин дә дәшмим. Барыбер телгә килерсез әле, күгәрченкәйләрем... Түземлек бездә дә җитәрлек.

Бер сәгать эшлибез. Ике сәгать... Шылт та юк. Шул чак телефон шалтырый: Алексей Васильевичны директорга чакыралар. Ул кабинеттан чыгу белән, Сергейга ташланам:

— Бу нәрсә инде?! — дип, турыдан ярам: — Алексейга минем ни зарарым тигәне бар? Бәлки, син аңлатырсың? Хәер, син дә минем белән сөйләшмисең бит әле...

Петрович кул гына селтәде.

— Кабахәт! — ди.

— Кем кабахәт?..

— Соң, син түгел инде... Синнән якын дустым юк. Шул Алексей дуңгыз!

— Алексей?! — көтелмәгән сүздән башымны шундый кисәк борганмын, муеннарым шыгырдап китте.— Син нәрсә, дустым, сул аягыңнан тордыңмы әллә бүген? Яз галәмәтедер дисәң... Иплә кенә аңлат әле.

Ләкин Петрович, тагын бер кат кулын селтәп алды да, үзенең кәгазьләренә борынын төртте. Ул арада Алексей Васильевич әйләнеп кайтты, Сергей Петровичка бер акаеп карады да үз урынына барып утырды.

Озак та үтми, директорга Сергейны чакырып алдылар. Мин инде Алексейны сөйләштермәкче булам.

— Карале, Васильич,— дим әкрен генә.— Бу Петровичка нәрсә булган? Син дә миңа кырын карыйсың кебек...

— Әй, юкны сөйләмәсәнә,— дип, караңгы чырай белән генә көрсенеп куйды Алексей.— Синең белән минем арадан җил дә үтәрлек түгел. Бөтен гауганың башы әнә теге ишәктә.

— Нинди ишәк ул тагын?

— Безнең конторада ишәк бер генә: ул да булса — Сергей.

— Фью! — дип сызгырып җибәрдем. Сызгырырсың да шул, абзыкаем... Эшләр болайга киткәч... Мин исемә килә алмый торганда ишектә Петрович күренде. Хәзер инде директорыбыз мине дәшә икән.

— Ярар, хуҗа янына кереп чыгыйм әле, аннары сөйләшербез,— дидем мин дусларыма.— Болай бер дә килешми: дус булып йөрдек-йөрдек тә җиде ятка әйләндекме? Нәрсә бүлешәсегез бар?!

Директор яныннан чыккач, иң элек Алексей Васильевичны тәмәке тартырга чакырдым. Күзгә-күз карап кына сөйләшергә исәбем.

— Дустым! — димен, пинжәгенә ябышкан төкләрне чүпләштергән булып, йон уңаена сыпырам моны.— Сүземә колак сал әле. Сезнең ара бозылудан да мәгънәсезрәк ни бар? Кем белән бәйләнәсең диген әле! Сергей Петрович белән бит. Дөнья бәһасе кеше белән. Кайсы гына яктан карасаң да, әйтергә кирәк, безгә үрнәк булырлык. Хатыны өстеннән йөрми, кеше кесәсенә керми. Ә эштә аннан булдыклырак тагын кем бар? Җәмәгать эшләрендә актив катнаша, үзе — китап сөючеләр җәмгыяте әгъзасы. Исеңдәме, былтыр ул безгә нинди китаплар табып бирде? Купер, Толстой, Куприн, тагын кем соң әле, аты коргыры... Әй, сөйләп бетерерлекмени аның яхшылыкларын? Ичмаса, шунысын гына әйт: нәрсә бүлешә алмадыгыз соң?..

— Шул җәйге ял аркасында инде...— Алексей борын астыннан мыгырдап куйды.— Беләсеңме, минем исәп август аенда ял итү, ул тинтәк тә... Августны сорый. Бер бүлектән икебезне берьюлы директор җибәрми ич инде, ә ул, ишәк, миңа юл куймый, һаман киреләнә. Август миңа кирәгрәк бит. Хатынның ялы шунда туры килә.

— Дускаем! — Мин инде Васильичны кочаклап ук алдым.— Ирләр булыйк! Бездәй асыл ирләргә шундый юк-бар өчен ара бозу данмыни? Аннары, белгәнемчә, Петрович быелгы ялын августта алырга җыенмый да лабаса...

Васильичның авызы колакка житте.

— Кит әле... Юри әйтәсеңдер?

— Чын инде! Миңа әле генә директор үзе шулай диде.

Без кабинетка әйләнеп кайттык, аннары мин шунда ук Сергей Петровичны тәмәке тартырга чакырдым. Килештерергә икән — килештерергә инде!

— Тыңла әле, дустым! — дидем, ишектән чыгу белән, Сергейның иңенә кулымны салып.— Син башта кем белән бәйләнешкәнеңне яхшылап уйла. Башыңны эшләтеп кара да әйт: кем ул безнең Алексей Васильевич? Ә? Я, я, оялма... Шул-шул! Безнең контораның иң шәп шахматчысы — бу булдымы бер. Турысын әйткәндә, шахмат буенча хәтта миннән дә уздыра бит ул... Икенчедән, Алексей Васильевич — үз эшенең остасы, икенче квартал инде директордан бер кисәтү алмыйча эшли. Өченчедән... Ну, ниһаять, ул бит әле безнең иң якын дус!.. Нәрсә бүлешә алмадыгыз соң? Ичмаса, шуны гына булса да әйтә аласыңмы син миңа?

— Ни бит, хатынның җәйге ялы быел августка туры килә...— дип, инде миңа таныш җырны суза башлады Петрович. Үзе шундый гөнаһсыз күзләрен миңа текәгән.— Ә теге дуңгыз...

— Ишеттем, ишеттем,— дип бүлдердем мин аны.— Менә бит ничек, ахмакларча бер-береңнең якасыннан алырга мөмкин. Әле үзебез дуслар имеш... Ирләр булыйк! Син соң, һич югы, Алексейның быел отпускыга августта китәргә уйламаганын беләсеңме? Чү, шаулама: миңа моны әле генә директор үзе әйтте.

— Дөресме шул сүз? — Петрович миңа елыша ук төште.— Әйтеп куюыңа рәхмәт инде, дускай. Чынлап та, бигрәк мәгънәсез гауга килеп чыгар иде бит... Иртәгә үк безнең өстәлләр бергә торыр, болай булса.

Икенче көнне, чыннан да, бүлмәбез элеккеге хәленә кайткан, арабызда ирләрчә нык дуслык уранашкан иде. Ә менә өченче көнне... Өченче көнне иртән эшкә килсәм — минем өстәлне үзләренекеннән аерып, ишек

катына ук китереп куйганнар. Аны кире үз урынына тартмакчы булып азапланган чагымда, Алексей Васильевич белән Сергей Петрович, кочаклашып дигәндәй, тәмәке тартырга чыгып киттеләр.

Менә шул көннән бирле алар минем белән сөйләшмиләр. Инде өчебез дә ял итеп килдек, озын кыш үтте, озакламый тагын отпускыга җыенасы, ә мине дусларым һаман күрмәмешкә салынып йөри... Нәрсә булды безгә, һич аңлый алмыйм!

...Ә, теге чакта директорның мине нигә чакырганын беләсегез киләдер әле... Сүз җәйге яллар турында барды анда. Мин инде өйдәге хәлләрнең шактый киеренке булуын, шуңа күрә отпускыны хатын белән бергә, ягъни август аенда аласым килүен әйттем. Тәки ышандырдым бит ул чакта директорны!

## Николай Максимов

# ИМТИХАН

хикәя



Сөенече эченә сыймады Люданың. Шулай булмыйни, ул бит бүген аш-су әзерләүчеләр мәктәбен тәмамлап чыкты. Тәмамлады дип әйтү генә аз булыр. Бик яхшы тәмамлады ул аны. Димәк, бүгеннән башлап, Люда мөстәкыйль рәвештә эшли башлаячак.

Әмма ләкин Людмила Булочкина эшләячәк ашханә мөдире — ясалма чәче өстенә ак калфак кадап куйган мөлаем гына ханым кыз кулына эш бирергә ашыкмады.

— Хуш-хуш! — диде ул аның документларын караштыргалап.— Болай ару гына күренәсең. Шулай да башта Авдотья Макаровнадан сабак алуың хәерлерәк булыр... Өйрәнчек булып... һәрхәлдә, комачау итмәс.

Нишләр хәл дә юк, яшь белгеч борынын салындырып, мөдир артыннан иярде. Коридор буйлап бераз атлагач, алар бер ак «чүмәлә»гә барып төртелделәр. Бу шул үзе — Авдотья Макаровна дигәннәре булып чыкты.

— Менә, хөрмәтле Макаровна, үзеңә тагын бер шәкерт! — диде мөдир күтәренке тавыш белән.— Безнең коллективның яртысы синең тәҗрибәле кулың аша узды, шаять бу кызга да әйбәт остаз булырсың...

«Ак чүмәлә» кызга өстән аска таба карап:

— Яра-ар,— дип телгә килде.— Мин аны боерган булса, бәк тиз... тефү, шайтан алгыры, би-ик тиз кеше итәрмен.

Мөдир киткәч, Макаровна кызга сорау бирде:

— Мәптегеңдә сабагыңны ничегрәк укыдың соң син, Нечкәбил?

— Бик яхшы,— диде Булочкина, ләкин аның тавышында масаю-мактану әсәре юк иде.

— Алайса анда өйрәнгәннәреңне башыңнан чыгарып ташла, оныт син аларны! — дип киңәш итте яңа остазы.— Шунда гына чын-чынлап аш-су остасы булырсың. Я, башладык. Иң әүвәлтен борщ пешереп карарсың...

Ярый, борщ икән, борщ. Булочкина иң мөһимен белә: беренче адымнан ук сынатырга ярамый. Һәм ул училищедагы яраткан укытучылары өйрәткән иң яхшы рецептларны хәтерендә барларга кереште. Шуларны исәпләп,

пешерү-төшерү эшенә керешүе булды, кинәт артта Макаровнаның ачулы тавышы күкрәде:

— Ни эшләвең бу, ә? Әллә кунаклар каршыларга җыенасыңмы?

Булочкина каушап калды:

— Ник, нәрсә?.. Беркемне дә... җыенмыйм.

— Алайса ни чуртыма казанга шулкадәре нәрсә тутырасың? Рәзе борщны шулай әзерлиләр? Болай итсәң, гомереңә чыра кебек сузаеп йөрерсең! — Артыграк бөгеп ташлавын чамалап, остазбикә тавышын баса төште.— Борщ ни ул, беләсеңме? Борщ ул, җаныкаем, токмачлы аш кына түгел сиңа. Борщ ул — кибәрнәтикә. Барысы да буталган, берсенең дә башын-азагын табалмассың. Шулай булгачыннан ни чуртыма шулхәтле әйбер тутырырга казанга? Ашка нәрсәләр, күпме салынуын билгели торган прибор юк әлегә, шөкер...

Икенче көнне Булочкинаны кофе кайнатырга куйдылар. Кыз мондый вак-төяк эш биргәнгә үпкәләгән иде дә, әмма кофе әзерләү «кибернетик аш» пешерүдән дә кыенрак булып чыкты.

— Әт-тә-тә-тә! — дип кычкырып җибәрде Макаровна, шәкертенең ялгышын бик тиз күреп алды.— Әнә син нинди юмарт икәнсең. Кофе ул бә-әк кыйммәтле нәрсә, җаныкаем. Аны үтә бәрәкәтле тотарга кирәк. Син менә шулай чүт-чүт кенә, чеметем-чеметем генә сал. Юри-мари төсе чыкса, шул бә-әк җиткән. Аның каруы шикәрне, шикәрне җәлләмә. Шикәрнең хакы — шалкан бәясе генә. Татлы су чөмергән кеше чуртымны да сизми ул. Өстәвенә рәхмәт әйтәчәк. Психология... Нибучь, хуш исләр бөркеп торган, куян каны кебек кофены үзең дә яратасыңдыр әле,— дип күз кысты остазбикә.— Вәт шул-шул. Алайсам, өлкәннәр сүзен тот, Нечкәбил...

Шул рәвешчә, Булочкина бу ашханәдә әзерләнә торган һәммәки ризыкны әзерләргә өйрәнде. Хәер, ул ризыкларның саны алай ук күп тә түгел иде түгелен. Шулай да Макаровнаның аш пешерү серләренә төшенеп җиткәнче кызга шактый тир түгәргә туры килде.

Ниһаять, соңгы «сынау» — Люданы аш салып торырга билгеләделәр. Авдотья Макаровнаның әйтүенә караганда, ризык бүлгәндә, ашчының барлык уңай һәм тискәре сыйфатлары берьюлы күренә икән.

— Әйтик, син гуляш салып торасың,— дип смена алдыннан соңгы күрсәтмәсен бирә башлады остазбикә.— Саранланма. Гуляш ул кибәрнәтикә дә, психология дә түгел сиңа. Гуляш ул, җаныкаем, тулы бер математика! Кайбер чүпрәк башлар ни өчен жалобалар кенәгәсенә әләгә дисең? Саранга күрә, карун булган өчен әләгә. Ә син җәлләмә, тутырып сал... гарнирны... Йөз илле тиеш икән, йөз иллене сал. Шулпасын да кызганма. Ә ит...— анысы кыйбатлы ризык... Аңлашыламы?.. Нәтиҗәдә — күләме тиешенчә... Хет министр үзе килеп үлчәсен. Математика!

Әмма Булочкинаны шулпалы ашлар салып торырга билгеләделәр.

Ашханә ишегендәге кисәү агачы кадәрле келәне ычкындыруга, буаны ерган ташу сыман халык агылып керде. Булочкина дулкынлануын сиздермәскә тырышып, чүмече белән шулпаны болгатып тора башлады. Янәсе, күрегез, шау судан гына түгел бу, куесы да бар төптәрәк. Әмма, Макаровнаның утлы карашын тоеп, шулпаның сыеґын гына шурылдатты...

Эштән соң Люданы мөдир кабинетына чакырдылар. Остазы ап-ак чүмәлә булып анда утыра иде инде.

— Я, Макаровна, Булочкинага ышанып эш кушарга буламы инде? — дип сорады мөдир.

Остазбикә калын муенын бөтен гәүдәсе белән борып, Людага карады, майлы пилмән кебек иреннәре елмаюдан әкрен генә ерыла башлады.

— Башы бар бу Нечкәбилнең,— диде ул аналарча йомшак тавыш белән.— Бераз кыюрак та булса... Ярый, анысы инде — тора-бара...

Кызны эшкә ярый башлавы белән тәбрик иттеләр. Люда исә училищедан соң бу ашханәдә әле тагын өч ел чиләнергә тиешлеген уйлап, авыр көрсенеп кенә куйды.

Русчадан **ШАМИЛ МАННАПОВ** тәрҗемәсе.

## Ркаил Зәйдуллин

# КҮПЕР

ПОЭМА

1

*Һич бетәрме тарихи бу бергәлек? —*
*Без туган бер җепкә бергә теркәлеп.*

Г. Тукай

Таш күпердә — бәйрәм!
Ике авыл
Өерелеп чыккан бу көнне,
Бер мин генә ничек читтә калыйм,
Дәшми калыйм әйтер сүземне?
Таш күпердә — халык. Бәйрәм ләса! —
Булгач булсын инде дип әнә
Гали бабай «Әпипә»гә баса,
Һәм такмаклый: «Кай, кай, Ивана!»

Язгы тантана бу. Өләшәләр
Бер-берсенә чиккән кулъяулык.
Бөтерелә күпер уртасында
Чуваш кызы. Ымлый елмаеп —
Егет булса, ташла [1], янәсе, кем...
Булмый... Әмма биһуш мин синнән:
Яңа сикереп төшкәнсеңдер кебек
Бәширинең хикәясеннән [2].
Алкышлаулар нигә? — Барча халык
Тел шартлата: «Вәт бу теттерә!»
Бер пионер әнә сиңа диеп
Йөгерә-йөгерә чәчәк китерә...

* * *

Кайнаганбыз тарих казанында
Алмаштырып гореф-гадәтне.
Халыкларның бүген бердәм булып
Дуслык җырын җырлар сәгате!

---

РКАИЛ ЗӘЙДУЛЛИН (1962) — яшь шагыйрь, «Кояшлы күзләр» исемле китап авторы. «Яшь ленинчы» газетасы редакциясендә эшли.

## 2

*Руслар, татарлар, чувашлар—бертигез. Алар кешеләр.*

И. Яковлев,
чуваш мәгърифәтчесе.

...Китереп бәрә бозлар!
Түзми күпер.
Җыерыла да кабат ычкына.
Багорлар да, колгалар да хәтта
Коткаралмый аны һич кенә...
Сәүдәгәрнең үз кайгысы: тагын
Тоткарлана товар... Сүгенә.
Күпер булып үзе сузылыр иде,
Буе гына кыскарак менә.
Нишләсә дә үз кодрәте ди-ди,
Мулла абзый тора — канәгать.
Сәүдә белән алыш-биреше юк,
Аңа нәрсә...— Җәмәгать, ди,—
Кайгырасы түгел,
Болай да бик әйбәт, иншалла...—
Һәм кузгала... Вакыты юк аның:
Яшь абыстай көтә мунчада.

* * *

Каз тәне чыкканчы коен!
Кем озаграк суда
Тора ала — иң зур бүләк
Чи «Каз боты» да шуңа.
Сибелә көмеш тамчылар,
Чәчри кояшкача.
Берәү куа, берәү кача —
Мәш килә бала-чага.
Сары балчык — сабын монда.
Үзенә күрә юыну —
Нәп-нәзек муеннарыннан
Тама елга дуены.

Бүленмәгән. Беркем әйтми:
«Бу су — безнең ярныкы!»
...Бер якта — чуваш авылы,
Бер якта — татарныкы.
Өйләре эре нараттан,
Тәрәзәдә — гөлләре,—
Төшләренә дә кермәгән
Моннан йөз ел элгәре.

* * *

Ике авыл... Карсак йортлар —
Түбәләре иске салам.
Ике авыл осталары
Елга аша күпер сала.

---

[1] Ташла (чув) — бие.
[2] Зариф Бәширинең «Чуваш кызы Әнисә» повестена ишарә.

Ашыкмый чуваш агае,
Балтасының сабы сынган...
Күпер сук имеш, бай күршең
Тарантасларда узсынга.
Ашыкмый татар остасы,
Уйлары шул ук, күрәсең:
Чукынып китсен! Чуваш белән
Юк кыз алып, кыз бирәсе.
Ә күпер кирәк! Тиз, диләр,
Сәүдәгәрләр, поп һәм дәүләт.
«Кыймылдагыз!» Булмый һич тә
Өстәмә хак-түләү даулап.
Даулап кара — шундый итеп
Бирерләр берне... Янәсе,
Һаман шул ук әле бездә
Мә сүзенең мәгънәсе.

Ачуың ал да агачтан,
Эшлә, туган, башны орып...
Сузыла күпер — сиздермичә
Күңелләрне тоташтырып.

3

*И. Н. Ульянов Чурачыкка*[3] *берничә мәртәбә килә, мәгариф эше белән кызыксына.*

Документлардан.

Чурачыкның кыр капкасы ачык.
Унлап кеше... Кунак көтәләр.
Озаклады никтер. Кәлә-кәлә
Җилләр исә, чыга үтәли...
Каршыларга күптән әзер алар —
Мичкәләрдә сыра күперә.
Нигә озаклады? Тып-тын калып
Текәлгәннәр яңа күпергә.
«Әнә килә, әнә!» — Ишетелә
Бер ыштансыз куштан сөрәне.
Зур сакалын рәтли Хуәдер дәдә,
Алга чыга —
Үзен бай дип белә, күрәсең.

Ә кунакның йөзе кәләч болай...
(Тик шунысы: аты үшән бик.)
Рәхим итегез! — Поп абзый да хәтта
Билен бөккән була кәчәнеп.

Ипи-тоз күтәргән староста.
Киң елмаю чыккан йөзенә.
Пышын-пышын артта: «Зур нәчәльник,
Шәһре Сембернең бу үзеннән!»

Сораштыра кунак. Җавапларны
Куя дәфтәренә теркәп тә...

[3] Чурачык — чуваш авылы. Революциягә кадәр Сембер губернасына кергән.— Р. З.

— Ә мәктәп юк...
Поп тамагын кыра:
— Мәктәп... ы-һы... Мәктәп — чиркәүдә...
Кунак җитди: «Керик берәр өйгә?»
Һәм бер йортка төртеп күрсәтә.
Поп үзенә дәшә. Хуәдер дә
Үзенә әйди, тарта терсәктән.

— Хәерче йорт, ник кирәргә анда? —
Ияреләр эленке-салынкы.
Салам түбә... Тач алачык инде.
Аңлашыла: Ычтапанныкы!
Идәне җир. Өч-дүрт бала шунда.
— Хәлләр ничек?
— Хәллә-әр... Хәл әйбәт.
Түрдән узыгыз, әфәнделәр. Менә
Тормыш җирдә безнең, бигайбә.

...Балалары елый. Салкын, шыксыз.
«Һәркөнне без шундый мәхшәрдә,—
Кулын җәя хуҗа.— Белмим инде,
Алга таба ничек яшәргә?»

Попның вәгазь әзер: «Канәгать бул!
Бигрәк күпне таләп итәсең».

...Ул арада почмактагы бозау
Чәйни башлый ряса итәген.

* * *

Күзе чепи балаларга карап
Йөрәк әрни, үзәк өзелә.
Укытырга кирәк сабыйларны,
Якты кирәк алар күзенә.
Кырыслана мөсафирның йөзе:
— Төшенмәүче монда сирәктер —
Офык яктыруын күрер өчен,
Чувашларга мәктәп кирәген.

Ычтапан да терелә. Пиччә [4],— диеп
Кулына аның барып ябыша:
— Без... Зәйнетдин оста белән!
Эшләр идек, валлаһ, ярышып...
Ташламагыз, зинһар, ярдәмнән Сез,
Чувашларга кирәк таяныч.
Бар бәлабез наданлыктан безнең,
Илья Николаевич!

## 4

*Гомумән, ул[5] Сембер губернасындагы чуваш мәктәпләре өчен күп эшләде.*

И. Яковлев.

Менә тагын җил кузгалды.
Кузгалак-кузгалак карлар

[4] Пиччә (чув.) — олы кешеләргә хөрмәт белән эндәшү.
[5] И. Н. Ульянов күздә тотыла.— Р. З.

Бөтерелә, оча, уйный —
Җилферди кышның туны.

...Чикмәнле чувашларга
Илтә аны юлы.
Эх, күчсә иде һәркемгә
Җанындагы җылы...
Гасыр ахыры гына бу,
Караңгы төн, кысан, тар.
Унжиденче елга кадәр
Шактый юл үтәсе бар.
...Ач-ялангач халыкларга
Илтә аны юлы.
Эх, күчсә иде һәркемгә
Җанындагы җылы...
Кем әйтә: башка халыклар
Акыл ягыннан түбән?
Бирегез кулларга китап,
Һәм баш өстенә түбә!
...Гади кешеләргә илтә
Ульяновны юлы.
Эх, җитсә иде һәркемгә
Җанындагы җылы...
Аракы белән томалап
Күзәнәкләрен минең,
Томана тамгасы сугып,
Алып өнен,
Бетереп булмый халыкны!
Тырышулар әрәмгә.
Уяна ул — тәхетләрне
Китерә чәлпәрәмә.
Махы бирмәс Зәйнетдиннәр,
Ычтапаннар бу көрәштә,
Ирек өчен изге яуда,
Изелгәннәр — янәшә.

* * *

Бәбкәләре торгызылган,
Уйган инде тәрәз дә.
Киң итеп, кояшка таба —
Менә безнең дәрәҗә!

Ашыгалар. Өмә белән.
Монда барысы үз әле.
Кычкыралар: «Бер, ике, өч!»
Һәм кемнәрдер: «Вз-зяли!»
Э-эх, авыр бүрәнәләр! —
Аргы якка чыгасы...
Атлар түзә. Кешеләр дә...
Бары күпер чыдасын!
Нык торсын — ике ярга да
Батырып тырнакларын.
Күрсәтә дөнья, күрсәтә
Безгә төрле якларын.
Ә-әх, авыр бүрәнәләр!
Күпер генә чыдасын,—

Дилбегә белән өстерәп
Аргы якка чыгасы.
Ташып тора Зәйнетдиннәр,
Хуәдерләр кутәрә.
Тырышалар «шәп итәбез!» —
Диган сүзне үтәргә.

Зур булсын ул, булсын биек,
Ике авыл балалары
Белем эстисе диеп,
Эшлиләр. Шундый замана —
Күп әле эшләнәсе:
Офыкларда алсулана
Яңа гасыр шәүләсе.

## АХЫРГЫ СҮЗ

Таш күпердә бәйрәм дәвам итә.
Шундый көндә вакыт әрәмме? —
Килдем менә бии белмәсәм дә,
Карап тордым язгы бәйрәмне...
Тоташтырды күпер ике ярны.
Ярлар бер-берсенә тартылды —
Менә-менә кушылырлар кебек...
Ләкин төрле шау-шу аркылы
Сулар челтерәвен ишеттем мин,
Тавышында аның моң-аһәң.
Нинди моң ул? Белмәс идем, бәлки,
Бу күпергә әгәр кермәсәм...
Субайлары таштан. Ышанычлы —
Әле тагын мең ел торырлык.
Туктый калсаң — күперең булсын икән
Гасырларны тоташтырырлык.

*1985*

**Рәшит Гәрәй**

# ТУГАН ҖИР КУЕНЫНДА

Бер-берләренең кочагына сыенып утырган Минзәлә һәм Актаныш районнарының Ык елгасы буйлап узган чигендә карап-сокланып туймаслык бер урын бар. Олы җанлы табигать, илнең бәйсезлеген яклап, изге яу кырында мәңгелеккә ятып калганнар истәлегенә һәйкәл салу өчен, аны гүя үзе әзерләп куйган. Ул һәйкәл халкыбыз Бөек Җиңүнең кырык еллыгын бәйрәм иткән көннәрдә калкып чыкты. Мондый игелекле эшнең шактый соңга калып башкарылуына илле-алтмыш йортлы Ташлыяр авылының акрынлап таркала башлавы, соңыннан бөтенләй таралып бетүе зур кыенлык тудырган. Бер районнан — икенчесенә, бер авыл Советыннан башкасына күчереп йөртелгән Ташлыяр авылыннан кемнәрнең сугышка китүен, кайсыларының исән-сау әйләнеп кайтканлыгын белү өчен генә дә никадәр эзләнергә, күпме вакыт һәм көч сарыф итәргә туры килгән. Әмма тәвәккәлләр, күңелендәге матур теләкне тормышка ашырмыйча, ярты юлда тукталып калмыйлар.

Һәйкәлнең салыну тарихын сөйләгәндә, иң әүвәл хәзер Брежнев шәһәрендә яшәүче ирле-хатынлы Галина Антоновна һәм Александр Алексеевич Поповларның исемнәрен телгә алырга кирәктер. Төп нигезләреннән кузгалып, авылдан күчеп киткәч, илебезнең төрле төбәкләрендә булырга туры килә аларга. Кайда гына гомер итсәләр дә, яланаяклы балачаклары, чая яшьлек еллары узган туган якларын сагыналар. Ык сулары төшләренә кереп йөдәтә. Ул авылның гүзәллегенә заманында кем генә сокланмаган икән дә анда гомер иткән көннәрен кем генә иң бәхетле көннәреннән санамаган икән?!

Ташлыяр челтерәп агып яткан ике инеш арасындагы алагаем зур мәйданны биләгән. Һәр ике инешнең төбенә һәм ярларына җемелдәвек ап-ак ташлар түшәлгән. Бу тарафларга беренче булып килеп утыручылар үзләре гомер итәчәк авылга Ташлыяр дигән шигъри исемне бәлки әнә шуннан алып кушканнардыр.

Инешләр исә ерактагы Чулман суына юл тоткан моңсу агышлы, тирән уйлы Ык елгасына кушылалар. Елганың аргы ягында хуш исле печәнгә, карлыган, бөрлегән, шомырт, балан ише һәртөрле җиләк-җимешкә бай болыннар һәм әрәмәлекләр, мул балыклы күлләр җәелеп китә. Болай да барлык ягыннан әкияттәгедәй сихри урманнар белән каймаланып алынган авылда һәркем бакча үстерә. Язгы айларда бөтен тирә-юнь алмагач, чия чәчәкләренә төренә. Бакчалар артыннан ук каенлык башлана. Белсәң иде, бер-берләреннән качарга теләгәндәй, төрлесе төрле якка сызылган чирәмле сукмакларда, җир җиләкле түгәрәк аланнарда күпме серләр саклана икән?!

Җәйге тын кичләрдә каенлыкны гармун, җыр тавышлары яңгыраткан. Эштән соң авыл яшьләре ял итәргә шушы урманга чыга торган булганнар. Аларның көр һәм шатлыклы авазларын моннан берничә чакрым ераклыкта урнашкан Пучы авылны яшьләре дә, Ыкның бирге ягында утырган Иске Александровка егетләре һәм кызлары да ишеткәннәр. Кунак булып килгән ул җыр-моңнарга үзләренең дә тавышларын кушар өчен, урман аша үткән юл буйлап, кыңгыраулап җигелгән атларга төялеп. Пучы һәм Айман өлгерләре, Ыкны каек-көймәләрдә кичеп, Матвеевка һәм Александровка җитезләре сукмак салганнар Ташлыярга. Аңа терәлеп үк диярлек үскән каен ур-

маны тора-бара тирә-як авылларда буй җиткергән яшьләрнең очрашу, танышу, сүз куешу-вәгъдәләшү урынына әйләнеп киткән.

Изге җиребезгә гитлерчы илбасарлар бәреп кергәч, Ташлыяр үзәнең сөлектәй улларын яу кырына да шушы урман авызыннан озатып калган. Туган-үскән җирләренә яңадан беркайчан да әйләнеп кайтмас егетләрне каен кызлары әле һаман да көтәләрдер сыман. Шушы илаһи урынны үз теләгең белән ташлап китү мөмкинме соң?

Әнә шулай фикер йөртүчеләр булмый түгел авыл кешеләре арасында. Бу урында шундыйлардан берсенең, кырык елга якын гомерен хәрби комиссариатларда, шуның егерме биш елын Минзәлә район хәрби комиссариатында эшләүгә багышлаган Руфаида Ивановна Гулявцеваның абыйсы Иван Гулявцевның исемен телгә алмый узу безнең яктан бик зур гаделсезлек булыр иде. Бөек Ватан сугышында Руфаида Ивановналар гаиләсеннән биш бертуган Гулявцевлар катнаша. Аларның берсе флотта, Кронштадта хезмәт итә һәм Ленинградны саклау өчен барган сугышларда батырларча һәлак була. Сугышчан дуслары аны Пушкинода җирлиләр. Сугыш бертуган Гулявцевларның дүртесенең тәнендә еллар да, бернинди шифалы дарулар да җуеп бетерә алмас тирән яралар калдыра. Үз өлешенә тигән газаплы яраның бердәнбер дәвасы туган җир кочагы, аның һичнәрсәгә алыштыргысыз татлы һавасы, кайнар сулышы икәнлеген Иван Гулявцев башка һәркемгә караганда да ныграк аңлый, ныграк тоя. Менә шуңа күрә дә Ташлыяр буйларын ташлап китүне ул хәтта күз алдына китерә алмый. Башкалар ишек-тәрәзәләрен аркылы такта белән кадаклап юлга җыенган сәгатьләрдә дә моның чын икәнлегенә ышанасы килми аның. Китсәләр дә, бераздан яңадан әйләнеп кайтмый калмаслар, дип уйлый ул эченнән генә һәм, шул өмет белән үз-үзен юатып, авыл читендәге япа-ялгыз йортта тагын берничә ел яши. Ләкин тормыш аның бу изге өметен акламый. Иң соңгы кеше булып ул да авыл белән хушлаша.

Туган җирнең тарту көченә дөньяда бер генә кеше дә каршы тора алмыйдыр, мөгаен. Шул көч Галина Антоновна һәм Александр Алексеевич Попковларны да ераклардан Брежнев шәһәренә тартып кайтара. Брежнев — Минзәлә — Актаныш арасында яңа салынып яткан асфальт юлның элек үзләре яшәгән Ташлыяр авылы кырыннан ук үтәчәген белгәч, аларның куанычлары эчләренә сыймый. Ялларын алар күбесенчә Ташлыяр тирәсендәге авылларда уздыралар. Бу исә ирле-хатынлы Попковларга төрлесе төрле якта таралышкан авылдашларын, балачак дусларын, инде онытылып барган иске танышларын эзләп табарга, кайберләре белән кабат очрашырга мөмкинлек бирә.

Шундый очрашуларның берсендә алар Руфаида Ивановна Гулявцевага тап булалар. Күптәнге якын дусларның сөйләшеп сүзләре, серләшеп серләре бетми. Сүзләре бик кирәкле фикергә килеп тоташа.

— Беләсеңме,— ди Галина Антоновна,— соңгы елларда без бик күп җирләрдә булдык. Күпме авылларны, күп шәһәрләрне күрдек. Аларның һәркайсында сугышта һәлак булганнар истәлегенә салынган һәйкәлләр үзенә җәлеп итте. Шул һәйкәлләр янына килеп туктыйм да: «Авылыбыз таралмаса, безнең Ташлыярда да шундый кадерле бер урын булыр иде! — дип уйланам. Минем кичерешләремне Александр да аңлый шикелле»...

Ярты Европаны кичкән үлемсез солдатларның якты истәлеге хөрмәтенә калыккан һәйкәлләр каршында басып торганда Александр Попков күңелендә дә шундый ук хисләр уяна, ил бәйсезлеге өчен чит-ят җирләрдә башларын салган авылдашларының исемнәрен мәңгеләштерү теләге туа. Һәм шул уй аларның бөтен җаннарын биләп ала. Альбом актарып утырганда ул бигрәк тә яңарып, яктырып китә. Фоторәсемнәрдән аларга җан дуслары, алыштыргысыз якыннары текәлеп карый. Ярату да, юксыну да үпкә дә чагыла аларның карашларында. «Нинди генә хәлләргә төшсәк тә, нинди генә кайгыларга дучар булсак та, бер-беребездән аерылмаска, аерылырга туры килсә дә, бер-беребезне онытмаска сүз бирешкән идек түгелме соң без? Ничек болай килеп чыкты соң әле бу? Сез инде менә безне онытып та өлгердегез... Югыйсә бит без дә сезнең белән бергә яшәргә, тормышның ямен сезнең белән бергә татырга тиеш идек...» Мәңге унҗиде-унсигез яшендә калган каһарманнар әнә шулай дип рәнҗиләрдер шикелле тоела иде аларга.

Исәннәрнең изге яудан кайтмый калганнар алдында мәңге бурычлы икәнлеген, күпме генә сөйләсәң дә, сөйләп бетерерлек түгел. Аларны онытмавыбызны бары тик кылган эшләребез белән генә расларга мөмкин. Алар

хөрмәтенә һәйкәлләр булдыру — шул эшләрнең иң-иң игелеклесе. Күпләрнең шундый фикердә булуларына да шикләнмибез. Галина Антоновна белән Александр Алексеевич Попковлар да үзләренә тагын бер фикердәш — Руфаида Ивановна Гулявцеваны табалар.

Бу өч авылдашның беренче очрашуларында ук сүз үзләрен борчыган, еллар буена күңел төпкелләрендә сакланып яткан бер үк нәрсәләр турында бара. Тормышны тагын да ямьлерәк, күркәмрәк итү өчен заманында үзеннән күпме өлеш керткән, илгә күпме файдалы кешеләр тәрбияләп үстергән Ташлыяр авылының эзе югалып, кыргый үләннәр астында күмелеп калырга тиеш түгел. Менә шушы теләкне соңгы елларда төрлесе төрле якка сибелгән барлык авылдашларына да ишеттерәселәре килә аларның. Ә моның өчен иң элек барысының да адресларын эзләп табарга кирәк. Бу кыенлыкны алар үз көчләре белән җиңеп чыгалар. Монда инде Руфаида Ивановна Гулявцеваның чирек гасыр буена Минзәлә район комиссариаты хезмәткәре, ә милиция подполковнигы Александр Алексеевич Попковның Брежнев шәһәрендә район эчке эшләр бүлеге начальнигы урынбасары булып эшләүләре зур ярдәм итә. Аларның тырышлыгы аркасында ике-өч ел эчендә авылдан сугышка киткән җитмешләп кешенең, анда һәлак булган кырык сугышчының исем-фамилияләре, сугыштан соң яшәү урынын үзгәрткән гаиләләрнең адреслары ачыклана. Галина Антоновна һәм Александр Алексеевич авылдашларына беренче хатларын язалар.

«Кадерле якташыбыз! — дип башланып китә ул хат.— Бүгенге көндә кайда гына яшәсәң дә, салкын төньякта яки эссе көньяктамы, ерак Себердә яки гүзәл табигатьле Идел буендамы, яңа төзелеп яткан һәм хәзергә әле исеме билгеле булмаган дәү гигант кочагында яки сөекле башкалабыз Мәскәүдәме, син үзеңнең Ташлыяр авылыннан икәнлегеңне онытма! Әгәр сиңа туып-үскән ягың кадерле һәм якын икән, һәр адымыңда исеңә ал син аны. Шунда син үзеңә бәләкәй чагыңнан ук таныш каенлык түреннән агып чыккан салкын чишмәбезнең көмештәй саф тавышын ишетерсең, иреңдә аның дөньядагы барлык шифалардан да шифалырак суының тәмен тойгандай, күкрәкләреңне киңәйтеп җибәрүчән татлы һавасын сулагандай булырсың.

Уйларыңда йөртеп, күз алдыңа китереп кенә калма, үзең бер кайтып кит әле син туган якларыңа, кадерле авылдашыбыз. Бер очрашыйк әле үзебезнең мәрхәмәтле һәм кунакчыл туган җиребездә»...

Бу хатның ахыры тагын берничә ел үткәннән соң гына язылачак һәм ул һәйкәл ачылу тантанасына чакырган сүзләр белән тәмамланачак. Ә хәзергә беренче хатта әле моңа кечкенә бер ишарә генә ясала: «Без сине үз туганыбызны көткән кебек якын итеп зур түземсезлек белән көтәбез,— диелә хатның азагында.— Киләчәктә, бәлки, сезнең һәммәгезне без генә түгел, һәйкәл рәвешенә кереп, Ык ярының иң биек төшенә чыгып баскан аталарыгыз һәм бабаларыгыз, әниләрегез һәм абыйларыгыз каршылар»...

Галина һәм Александр Попковлар имзасы куелган бу хат көне-сәгатендә берничә дистә данәдә күчереп языла һәм илебезнең төрле якларына җибәрелә. Озак та үтми, алар исеменә Мәскәүдән һәм Чиләбедән, Краснодар краеннан һәм Удмуртиядән, Новосибирскидан һәм Казахстаннан, Алтайдан һәм Иркутскидан, Свердловскидан һәм Минзәләдән җавап хатлары килә башлый. Көннән-көн күбәя барган ул хатларда рәхмәт һәм шатлык, куаныч һәм сагыш, юксыну һәм өмет хисе бөркелә. Брежнев шәһәреннән юлланган тәүге хаттагы «һәйкәл» сүзе ташлыярлыларны туган җирләренә дәшеп-чакырып торучы парольгә әйләнә. Инде яшен яшәгән, ашын ашаган әби-бабайлар да, Ташлыяр авылын өлкәннәрдән генә ишетеп белгән үсмерләр дә, сүз куешкандай, шул ук фикерне алга сөрәләр, ике җөмләнең берәнә «һәйкәл» сүзен китереп кыстыралар. Төргәк-төргәк хатлар арасыннан биредә без хәзергә бары тик берсен генә күчереп китү белән чикләнәбез:

«Сөекле якташларым һәм туганнарым,— дип яза Чиләбедән Людмила Михайловна Мыльникова,— сезнең хатыгызны алып укыгач, ничек шатланганыбызны белсәгез иде! Юк, кәгазь битенә күз яшьләремне тамызмыйча аңлата алмам моны мин сезгә... Нинди матур эш башлап җибәрүегезне сез әле үзегез дә ахырынача аңлап бетермисездер... Безне исегездә тотуыгыз, онытмыйча эзләп табуыгыз өчен меӊ-мең рәхмәтләр яусын сезгә...

Ташлыяр шундый язмышка төшмәгән булса, башка җирләрдәге кебек анда да безнең туганнарыбыз хөрмәтенә моңарчы инде һәйкәл салынмый калмас иде. Һәркайсыбыз өчен кадерле исемнәр уелган ул һәйкәлгә без дә

кайтып баш имәс идекмени?! Минем үземнең дә ике абыем сугышта һәлак булды. Әтибез Ташлыяр зиратына җирләнгән. Туган якка кайтсам, ул изге җирнең бер уч туфрагын алып, әнкәм кабере өстенә салыр идем дип хыяллангамаган бер генә көнем дә юктыр. Монда килеп яши башлагач әнкәбез ун елдан соң дөнья куйды. Ата-аналары бер үк туфракка күмелгән кешеләрнең җир-сәү-сагышлары да башкачарак, тизрәк үтүчән була торгандыр кебек тоела миңа.

Авылыбыз исән чагында, анда ешрак кайтмавым өчен хәзер үкенеп бетә алмыйм. Сез хатта телгә алган һәйкәл турындагы матур уй чыннан да тормышка ашса, элек Ташлыяр авылы булган җиргә беркайчан да сукмаклар өзелмәячәк, ул сукмакларда беркайчан да безнең эзләребез суынмаячак.

Сүз дә юк, сез бик-бик зур һәм җаваплы эшкә тотынырга җыенасыз. Аны башкарып чыгу берүзегезгә генә җиңел булмаячак. Шуңа күрә кирәк чакта безнең ярдәмебездән дә баш тартмагыз, безне дә һәрвакыт үз янызгызда итеп санагыз. Ил төкерсә, күл булыр, дигән сүз бар халыкта. Кечкенә генә булса да өлешем керә торсын дип, сезнең исемгә акча җибәрәм...»

Людмила Михайловна хатыннан соң Брежнев шәһәренә, Галина Антоновна һәм Александр Алексеевич Попковлар адресына бер-бер артлы нәкъ шундый ук эчтәлекле дистәләгән хатлар агыла. Ул хатларны юллаучылар да һәйкәл салудан читтә торып калырга теләмәүләрен, бу эшне башларга җыенган якташлары исеменә акча җибәрүләрен хәбәр итәләр.

Бу хатларны укыгач, интәшлек, дуслык, туганлык рухында тәрбияләнгән кешеләребезнең олы җанлылыгына, күңел байлыгына сокланып туя алмыйсың. Югыйсә бит Попковлар үзләренең якташларына язган хатта һәйкәл салуга сизелер-сизелмәс ишарә генә ясалган иде. Акча турында анда бер кәлимә сүз дә әйтелмәгән иде! Хат ташучы берничә ай эчендә генә дә Попковларга җитмеш өч тапкыр акча кәгазе китерә. Бу үзе генә дә ил мәнфәгатен яклап шәһит киткәннәргә халыкның әйтеп бетергесез мәхәббәтен, чиксез ихтирамын чагылдырмыймыни?!

Хатларда да аларның исемнәре зур хөрмәт белән телгә алына. Бүгенге көндә Урал якларында яшәүче Анна Константиновна Окишева үзенең барлык кыз туганнары исеменнән абыйсы Василий Константинович Попковның исемен дә һәйкәлгә язуларын үтенә. Сугышта һәлак булучыларның Актаныш район хәрби комиссариатындагы исемлегенә Василийның исеме теркәлмәгән булуы ихтимал дип борчыла ул. Чөнки 1921 елда Ташлыяр авылында туган Василий Попков сугыш алдыннан Оренбург хәрби училищесында укый. Аны 1941 елның мартында тәмамлап чыга һәм Львов өлкәсендәге Драгобыч шәһәренә җибәрелә. Сугышны шунда зенит артиллериясе лейтенанты дәрәҗәсендә каршылый.

Кайвакытта без, «билгесез», «исемсез» солдат дигән сүзләр ишетәбез. Якты җир өстендә яшәүче яки яшәгән кеше билгесез була аламы соң?! Киләчәк таңнарны яктырту өчен утта янганнарның исемнәрен без һәрвакыт барлап торырга, хәтер түрләребездә саклап йөртергә, аларны килер буыннарга илтеп тапшырырга бурычлыбыз. Һәйкәлләр шул изге ниятне күздә тотып салынмыймыни?!

Бу уңайдан Попковлар гаиләсенә килгән тагын бер хатка тукталып үтүне кирәк саныйм. Аны Минзәлә шәһәреннән Александр Сергеевич Сальников язган. Ул изге яу кырында авылдашларына, туган җиренә биргән антына ахыр сулышкача тугры калып, 1942 елда Сталинград янында һәлак булган әтисе Сергей Лаврентьевич Сальников белән горурлануын һәм һәйкәлдә аның исемен дә күрергә теләвен белдерә. Кыюлар һәм батырлар калдырып киткән эстафета аларның улларына һәм оныкларына әнә шулай күчә, бүгенге көн аша киләчәктә әнә шулай дәвам итә.

Шул эстафетаны кулдан-кулга тапшыручылар алдында без бүген янә бер мәртәбә зур рәхмәт хисе белән баш иябез. Бу хакта сүз чыккач, Галина Антоновна Попкова иң беренче нәүбәттә Николай Ефимович Кучкин, Надежда Александровна Кучкина, Анна Петровна Гурьянова, Елизавета Петровна Герасимова, Александра Алексеевна Касаткина, Сергей һәм Анатолий Касаткиннар, Александр Ильич Легошин, Анна Александровна Чернова, Александра Константиновна Никулина һәм, әлбәттә, Руфаида Ивановна Гулявцеваларның исемнәрен атый. Үз чиратыбызда без боларга тагын Лидия Петровна Кучкина, Сергей һәм Николай Михайлович Кучкиннарны, Таисия Игнатьевна Герасимова, Анатолий Петрович Герасимовны өстәр идек.

Суғышка кемнәрнең кайдан китүләре, кайчан һәм кайда һәлак булулары, кемнәрнең хәбәрсез югалулары — боларның бөтенесен-бөтенесен ахырынача ачыклауда Попковларның иң якын һәм риясыз ярдәмчеләре шулар булалар. Аларның булышлыгы белән кирәкле мәгълүматлар тупланып беткәч, һәйкәл салу мәсьәләсе бөтен тулылыгы белән көн тәртибенә куела. Аңа бәйләнешле барлык чараларны бергәләп хәл итү өчен махсус комиссия төзелә. Төрле урыннарда яшәүләренә карамастан, аның составына А. П. Попков, Н. В. Кучкин, В. Н. Чернов, А. А. Гурьянов, Г. А. Попкова, Н. Л. Легошин, А. А. Филиппов — барлыгы дистәгә якын кеше кертелә. Кагыйдә буларак, алар арасында ил картлары күпчелекне тәшкил итә. Ашыкмыйлар, ут-суларны кичкән түзем һәм уйчан агайлар бу юлы да һәрвакыттагыча сабырлык күрсәтәләр, төптән уйлап, кат-кат киңәш коралар, бер-берләренең сүзләренә колак салып эш итүне мәгъкуль күрәләр. Һәйкәлне кайсы урынга салу турында сүз чыккач, һәркем үз фикерен әйтә. Берәүләр һәйкәл өчен иң кулай җир элекке клуб урыны булыр, диләр. Икенче берәүләр: «Һәйкәлләр гадәттә авылның урта бер җирендә калка, безнең авылның уртасы ике инеш арасындагы калкулык иде»,— дигән фикерне куәтли. Өченчеләре исә... Хәер, алары өчен халык мәкале җавап бирә: «Җиде кат үлчә, бер кат кис»...

Бәхәсле сорауга җавап бирүләрен сорап, кул астындагы адреслар буенча яңадан хатлар җибәрелә. Хатларны иң гадел, иң ышанычлы илчеләр дип юкка гына әйтмиләр икән. Иң гадел фикер әлеге җавап хатларыннан чыга: «Авылдан сугышка чыгып киткән кешеләр арасыннан кайсының үле хәбәре җаннарны беренче булып тетрәткән, һәйкәл шуның йорты нигезендә басып торырга тиеш».

Беренче кайгылы хәбәр Иван Михайлович Белов саубуллашып киткән йортка килгәнлеге бүгенге көнгәчә кемнең генә оныта алганы бир икән?! Мәсьәлә әнә шулай хәл ителә. Ләкин бу әле алда торган зур эшнең башы гына була.

Яшерен-батырын түгел, кемнең дә булса хөрмәтенә беренче карашка күзгә әллә ни ташланып та тормаган кечкенә бер кабер ташы яки мемориаль такта кую өчен генә дә, рөхсәт, эскизлар, материал сорап, түрендә дәрәҗәле агайлар утырган күпме кабинет-бүлмәләрнең бусагасын таптарга, ишекләрен кагарга туры килә. Монда исә һәйкәл кадәр һәйкәл салу турында сүз бара. Ифрат зур тәвәккәллек, түземлелек һәм башлап йөрүченең оештыру сәләтен сорый мондый эшләр. Аларның шактый гына чыгымнарга бәйләнгән булуын да күз уңында тотарга кирәк. Чыгымнар ягына килгәндә, ул чаклысын авылдашларының үз иңнәренә күтәрүе Александр Алексеевич Попковның бу юлдагы эшен бермә-бер җиңеләйтә. Инде калган ягын хәл иткәндә кемгә таянырга? Ярдәм итүләрен сорап иң элек кемгә сүз кушарга? Танышбелешләре арасында аның матур ниятен аңлаучылар табылырмы?

Ләкин юкка гына борчылган икән ул. Уртак эш өчен вакытларын да, көчләрен дә кызганмаучы энтузиастлар табыла. Һәйкәл салу мәшәкатьләренә чын-чынлап тотынгач, Александр Алексеевич Попковка апасының уллары Сергей һәм Анатолий Касаткиннар беренче булып ярдәмгә киләләр.

— Без һәйкәл салыначак урыннан берничә йөз метр җирдә генә эшлибез. Бульдозер да, экскаватор да бар,— ди Касаткиннарның берсе.— Балык үрчетү питомнигы өчен урын хәзерлибез. Геофизик абый да бу якларда еш була. Җир казу, һәйкәл салу өчен ком, цемент, бетон, гранит һәм башка кирәкле материалларны табышу, аларны китертү өчен икебезнең дә мөмкинлекләребез бар шикелле. Мөрәҗәгать итсәк, бер оешма да үтенечебезне кире какмас...

Элеккеге Ташлыяр авылы урынында һәйкәл салына икән дигән хәбәр бөтен якын-тирәгә таралып өлгерә. Мондый эшкә чын-чынлап, ихласланып тотынган кешеләргә ядрәмебез кирәк булмагае, дип фикер йөртүчеләр дә, болай гына һәртөрле яңалык белән кызыксынырга яратучылар да һәйкәл калкып чыгачак тарафка әзләрен суытмыйлар.

Бу җәһәттән Галина Антоновна һәм Александр Алексеевич Попковларның Совет Армиясе сафларында хезмәт итүче уллары Сергейның бер хатына тукталасы килә. Сергей, үрнәк хезмәт иткәне өчен командование тарафыннан бирелгән ялны, хәзер файдаланмыйча, ата-бабаларының туган җирендә һәйкәл ачылу көннәренә күчерүләрен соравы турында яза. Һәйкәл ачылу тантанасында минем дә катнашасым, киләчәккә узып барышлый, Ташлыярга тукталып, постаментка менеп баскан сугышчының аяк очына солдат дусларым исеменнән чәчәкләр куясым килә, ди. Шундый мөмкинлеккә ышанып, әти-әнисенә алдан ук рәхмәт әйтеп куя.

Ата-анасы аның хатындагы бу юлларның укыган минутларда һәйкәлнең нигезе коелачак урында җирнең кара туфраклы иске катламы саклык белән генә бер кырыйга эттерелә. Шуннан соң гына экскаватор беренче чүмеч балчыкны чумырып ала. Нәкъ шушы мизгелдә, язның тәүге йомшак күкрәве ишетелә, гүя табигать бу игелекле эшкә алынган кешеләргә үзенең хәерфатихасын бирә.

Бу күркәм башлангычка үзләреннән өлеш кертергә теләүчеләрнең саны көннән-көн арта, ишәя бара. Гаиләләре белән бергә, чираттагы яки үз хисапларына алган еллары вакытында һәйкәл салышырга теләүчеләр үзләренә бернинди уңайлыклар да эзләмиләр. Үзләре белән алып килгән палаткаларда яшиләр. Ләкин бу очракта гаделлеккә хилафлык кылырга да ярамас. Ике куллап каршы торуларына да карамастан, элеккеге Ташлыяр басуларын үз эченә алган Нур Баян исемендәге колхоз җитәкчеләре (Актаныш районы, Пучы авылы) һәйкәл салуда катнашучыларны азык-төлек белән тәэмин итүне үзләренең намус бурычлары санапйлар. Күршедәш Минзәлә районының Иске Александровка, Николаевка, Матвеевка, Үртамак авылларында яшәүчеләр дә ул җиргә әледән-әле күчтәнәчләрен күтәреп киләләр. Күмәк көч белән эшләнгән эшнең үрчемле булуы да һәркемгә билгеле. Һәйкәлнең нигезе салына башлаганнан алып аның өстендәге япманы ачканга кадәр нибары ике атна чамасы вакыт уза. Һәр яктан бүгенге таләпләргә җавап бирерлек дәрәҗәдә сәнгатьчә матур һәм оста итеп эшләнгән сигез метр биеклектәге һәйкәл ерак араларны якын итеп киләчәк кунакларны каршыларга җыена. Алдан ук сөйләшенеп куелганча, аның кайчан ачыласын, ул салынган урынга ничек килергә мөмкин икәнлеген, тантананың көн тәртибен бәйнә-бәйнә аңлатып язылган чакыру кәгазьләре таратыла, килүчеләрне каршы алу һәм урнаштыру өчен махсус кешеләр билгеләнә. Һәйкәлне тантаналы төстә ачу көне итеп, җирдәге барлык яхшылыкны таптап узарга, ахырынача юк итәргә теләп, гитлерчы баскыннарының илебез чикләренә бәреп кергән һәм совет халкының фашизмның умыртка сөяген сындыру өчен тарихта моңарчы тиңдәше булмаган авыр һәм изге көрәшкә күтәрелгән 22 июнь көне билгеләнә.

Ниһаять, күптән көтелгән ул көн дә килеп җитә. Минзәләдән Актанышка илткән асфальт юлдан бер-бер артлы тезелешеп автобуслар, бөркәүле һәм җиңел машиналар, мотоцикллар уза. Аларның күбесе, Ык күперен чыккач, башка вакыттагы кебек, йөрешләрен тизләтә төшеп, турыга баруларын дәвам итмиләр, ялт кына уң якка борылалар. Моторлар гөрелтесен каршыдагы болыннар һәм үзәннәр буйлап агылган музыка күмә. Ул әле күтәренке-тантаналы, әле моңсу-сагышлы булып яңгырый. Машиналардан төшкән шул музыка тәэсирендә бер-берләренә тартылалар.

Арада ике-өч көн алдан килүчеләр дә бар. Алар инде үзләренең нигезләрендә булырга, анда-санда сакланган элекке бакчалар түрендәге агачларга эч серләрен сөйләргә, еллар буе күңелләренә җыелып килгән шатлык-кайгыларын уртаклашырга, зираттагы каберләргә чәчәк бәйләмнәре салырга да өлгергәннәр. Ерактан кайтучылар да берничә көн элегрәк хәбәр салып куюны мәгъкуль күргәннәр: «Без берьюлы ун кеше кайтырга чыгабыз,— диелә һәйкәлне ачу тантанасын оештыру буенча төзелгән комиссия исеменә килгән телеграммаларның берсендә.— Минзәләгә кайтып төшкәч, базарда яки кибеттә чәчәкләр сатып алырга мөмкин булырмы?»

Туган җирләренә кайтырга ашкынучы башка кунаклар да чәчәкләр турында сүз кузгаталар. Һәйкәл итәгенә һәркайсының да чәчәк бәйләмнәре куясы, шул рәвешле ил улларына карата булган мәхәббәтләрен, хөрмәтләрен белдерәселәре килә аларның. Бу җәһәттән Краснодар краеның Успенское поселогында яшәүче Александра Кучкинаның сүзләре күңелне аеруча җәлеп итә: «Балачакта үзебез шаярып-уйнап үскән җирләрне, беренче укытучыбыз сөекле Анатолий Петровичны кабат күрү бәхетенә ирешәчәгемне уйлап шатланып бетә алмыйм. Ләкин мине менә нәрсә борчый. Кадерле кешеләребезгә бүләк итәр өчен без анда чәчәк таба алырбызмы? Хәзер минем йөрәгем үз урынында түгел шикелле. Һәр көнем ел кебек озын тоела, бер уйласаң, исең-акылың китәрлек бит: бала чагыбызда аерылышкан идек, әбиләр булып күрешәчәкбез. Һинди хисләр кичерүемне хатка язып кына аңлатырга көчем юк...»

Устинов шәһәрендә яшәүче Т. В. Легошинаның хатыннан берничә җөмлә: «Чиләбегә барып кайттым. Аннан да берничә кеше юлга җыена. Брежневка кадәр самолет белән очачаклар. Аннан соң Ташлыярга кадәр

ничек кайтырга икәнлеген белешергә куштылар. Чәчәкләр турысына килгәндә, эш ничегрәк тора? Үзебез белән моннан алып кайтыргамы, әллә анда да табылырмы?»

Хатларда һәм телеграммаларда килгән сорау-үтенечләрне искә алып, төрле яклардан Брежнев шәһәренә кайтып төшүчеләр өчен машиналарга, автобусларга бер ай элек заказ биреп куела. Һәйкәл ачылачак урында аларны Иске Александровка һәм Николаевка, Матвеевка һәм Степановка, Казлы Куак һәм Филимоновка, Дреевка һәм Үртамак авыллары кешеләре, Пучы авыл советы һәм Нур Баян исемендәге колхоз җитәкчеләре, «30 лет Победы» һәм Тукай исемендәге хуҗалык вәкилләре, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм Пучы урта мәктәбе пионерлары каршылый. Сабан туен хәтерләткән бу олы тантанага төрле милләт вәкилләреннән өч йөздән артык кеше җыела.

Митингны кыскача кереш сүз белән һәйкәл салуга үзеннән чиксез зур өлеш керткән Галина Антоновна Попкова ача.

— Кадерле якташларыбыз, хөрмәтле кунаклар! — дип мөрәҗәгать итә ул һәйкәл каршында басып торучыларга.— Гүзәл киләчәгебез өчен сугыш кырында ятып калганнарның якты истәлеген мәңгеләштерү уе тугач, алар турындагы мәгълүматларны берәмтекләп җыюда сез барыгыз да якыннан торып булыштыгыз. Сөекле башкалабыз Мәскәүне, утлы боҗра эчендә калып та дошман алдында тез чүкмәгән бөек Ленин каласын, Иделдә какшамас таш кыя булып калыккан Сталинградны саклаганда, Днепр һәм Одер суларын кичкәндә, Европа халыкларын фашизм коллыгыннан азат итү сугышларында һәм, ниһаять, илбасарларны үз өннәрендә кыйнаганда һәлак булган бабаларыгызны һәм этиләрегезне, абыйларыгызны һәм энеләрегезне, күп санлы якын туганнарыгызны онытмавыгыз өчен мең-мең рәхмәт сезгә! Сезнең тырышлыгыгыз аркасында бүген алар үзләре туган, хезмәттә чыныккан, көрәшкә әзерләнеп үскән җирләренә — Ташлыяр туфрагына һәйкәл булып кайтып бастылар...

Һәйкәл өстендәге япма төшерелә. Оркестр Советлар Союзы Гимнын уйный. Сүз Александр Алексеевич Попковка бирелә.

— Тормыш безнең төрлебезне, ил буйлап, төрле якка тараткан иде. Бүген без үзебез туып-үскән иң мөкатдәс җиргә — ата-бабаларыбыз нигезенә җыелдык. Монда безнең йөрәкләребезгә һәрбер сукмак, һәрбер куак якын һәм кадерле. Бу җир бездә Ватанга, халкыбызга карата кайнар сөю хисләре тәрбияләгән. Бу җирдә безнең иң кадерле кешеләребез мәңгелек йокыга талган. Алар үлмәгәннәрдер, әле һаман да исәннәрдер кебек. Без әле һаман аларның: «Туган почмагыгызны онытып бетермәгез, җае чыккан саен, кайтып башыгызны иегез сез аңа»,— дигән сүзләрен ишетәбез шикелле. Аларның сүзләренә каршыгыздагы һәйкәлгә исемнәре язылган сугышчыларның еракган ишетелгән авазы килеп кушыла сыман. Бер минут тын калып искә алыйк без бүген аларны!

Тирән тынлык урнаша. Һәйкәл янындагылар ни генә уйламагандыр да, кемнәрне генә исләренә төшермәгәндер бу минутта?! Александр Алексеевич үзенең сүзен дәвам итә.

— Исемнәре мәрмәр ташка уелган авылдашларыбыз тормышны, туган җирне, шул җирнең бер өлеше булган Ташлыярны беребездән дә ким сөймәгәннәрдер. Ләкин аларга Җиңү көнен күрергә, үзләре чыгып киткән юллардан кире әйләнеп кайтырга насыйп булмаган... Тормышка яңа буыннар аяк баса. Әмма, еллар үтүгә карап, совет халкының Бөек Ватан сугышында күрсәткән батырлыгы онытылмый гына түгел, киресенчә, күңелләрдә көннән-көн ныграк яңара. Без илебезгә ябырылган дошманга каршы торып, туган җирне кочып, кемнең беренче һәлак булуын да, сугышның соңгы минутында кемнең егылып калуын да ачык белмибез. Ләкин аларның тегесе дә, бусы да ил алдындагы изге бурычларын гомерләрен биреп үтәгәннәр. Аларның батырлыгыннан башка без рейхстаг түбәсенә Җиңү байрагын элә алмаган булыр идек... Дөнья халыкларының күз карашы, өмете бүген дә — бездә. Җирнең иминлеген саклап калу өчен барган көрәштә без бүген дә — алгы сызыкта...

Александр Алексеевич Попковның чыгышын тыңлаганда митингта катнашучыларның карашы һәйкәлдәге сүзләргә төбәлгән: «Бөек сугышта җиңү яулаган маршаллар һәм солдатлар, үлгәннәр һәм исәннәр, беркайчан да онытылмаячак барлык-барлык кешеләр алдында бөтен ил, бөтен халык һәм Җирнең үзе исеменнән баш иябез».

Уйлар — үткәнгә, үткәннең истәлек-хатирәләре аша киләчәккә тоташа. Митингта катнашучыларның чыгышларында бу аеруча тулы гәүдәләнә. Ни-

колай Ефимович Кучкин һәм Александр Архипович Герасимовларның чыгышларында телгә алынган вакыйгалар авылның киләчәктә язылачак тарихына тагын бер сәхифә булып өстәлә.

Галина Антоновна Попкованың әнисе ягыннан кардәшләре — биш бертуган Герасимовларның икесе яу кырында ятып кала. Сугышта очучы булып катнашкан Николай һәм Дмитрий Петрович Герасимовлар араларыннан иртә киткән энеләре өчен гитлерчылардан рәхимсез үч алалар. Халхин-Гол вакыйгалары вакытында ук япон самурайларына каршы көрәшкән очучы Николай Бөек Ватан сугышында да зур батырлыклар күрсәтә. Полковник дәрәҗәсендә отставкага чыккан Николай Герасимов бүгенге көндә — Мәскәүдә, ә Дмитрий Петрович Таллин шәһәрендә яши. Энеләре Анатолий да үзен хәрби хезмәткә багышлаган.

Гомумән, уллары үзләренең тормышларын Совет Армиясе белән бәйләгән гаиләләр Ташлыярда аз булмаган. Александр Нестерович Филипповлар гаиләсендә туып үскән Анатолий Александрович Филиппов та хәрби училище тәмамлаган, подполковник дәрәҗәсенә күтәрелгән. Сугышта һәлак булган этисен хәтерләмәсә дә, ул аның һәм үзенең туып-үскән якларына әледән-әле кайта. Һәйкәл ачылу тантанасында ясаган чыгышында да ул күңелендәге ачып бирде. Аның фикерен башкалар куәтләде.

— Җандай якын күргән авылдашларым,— диде Руфаида Ивановна Гулявцева,— минем дә балачагым сезнең белән бергә шушы җирдә узган. Шатлыгын да, кайгысын да сезнең белән бергә кичергәнмен. Сугыш елларында авылыбызда ишеген кайгылы хәбәр ачып кермәгән бер генә йорт та калмагандыр. Эзе йөрәклэрдән беркайчан да җуелмас ул дәһшәтле сугышта Ташлыяр үзенең дүрт дистә улын югалтты. Без аларны һәрвакыт күңел түрләребездә сакларга, җылы хисләребезгә төреп, исемнәрен үзебез белән киләчәккә алып барырга тиешбез. Утлы елларны хәтерләтеп, йөзе белән Көнбатышка карап баскан бу һәйкәл янында ел саен очрашыйк! Бу көн хәтерләрдә мәңге саклансын!..

Һәйкәлне ачу тантанасы анда катнашучыларның гына түгел, аларның балаларының һәм оныкларының күңелләренә дә җуелмаслык булып кереп калыр. Бу шатлыклы көннең аерым күренешләре килгән буыннар өчен кадерле бер ядкарь булып, кешеләрнең төркем-төркем җыелып төшкән фоторәсемнәренә күчә. Җиргә бездән соң килер яңа кешеләр район Культура сарае каршындагы «Энтузиаст» халык киностудиясенең алышынмас җитәкчесе, оператор-режиссер, Татарстанның атказанган культура эшлеклесе Николай Петрович Петровка исә гомер буена рәхмәт укыячаклар. Ул ташлыярлылар тормышындагы кабатланмас әлеге вакыйганы кинога төшерә. Бу минутларда үзенең дә күңеле яшьлек елларыннан урап кайткандыр.

Николай Петрович Ташлыярда һәйкәл ачылу тантанасын кино сәнгате аша башкаларга да җиткерүне үзенең бурычы санаган. Һәм бу фильм Минзәләдә уздырылган кинофестиваль көннәрендә күп кенә авыллардагы Культура йортларында, клубларда күрсәтелде, тамашачылар тарафыннан бик җылы кабул ителде. Күпләр, фильмның аерым кадрларын үзләренә җибәрүне сорап, авторга мөрәҗәгать иткәннәр. Николай Петрович бу гозер-үтенечләрне вакытында канәгатьләндерергә тырыша. Кешеләргә яхшылык кылу өчен тормышта һәрвакыт мөмкинлек бар. Яшь буынга да өлкәннәрнең нәкъ шундый гадәтләре ныграк тәэсир итә. Һәйкәл ачуда катнашкан ветераннар янында Пучы урта мәктәбе укучыларының да булуы — шуңа бер мисал.

Пионерлар исә, һәйкәл каршына басып, илгә тугры, халык бәхете өчен көрәшкә һәрвакыт әзер булырга ант итәләр. Аннары укучылар Ватан, тынычлык, хезмәт турындагы шигырьләр, җырлар башкаралар. Тантанага катнашучыларга Җиңүнең кырык еллыгына атап чыгарылган истәлек значоклары тапшырыла, һәйкәл итәгенә чәчәк үремнәре куела.

Митинг ябык дип игълан ителгәч тә кешеләр әле таралырга ашыкмыйлар. Ташлыяр авылында туып-үскәннәр кайчандыр үзләренең төп нигезләре булган урыннардан, зират тирәләреннән әйләнәләр. Кичке сәгать унбердә һәйкәлгә исемнәре язылган сугышчылар хөрмәтенә салют бирелә: сугышта үлеп калган һәр ике кешенең исемен әйткән саен күккә ракета чөяләр. Ал, кызыл, яшел төстәге ракеталарның яктылыгы сүнеп тә өлгерми. Ык ярында биниһая зур учак кабына. Аның очкыннары, бөек Җиңү салютының дәвамы булып, йолдызларга таба үрли. Йолдызлар яктырткан күк астындагы яңа һәйкәл куенында, әйтерсең лә, Ташлыярга әле бүген генә сугыштан кайтып төшкән солдатлар йоклый.

*Минзәлә — Актаныш.*

# Ислам Беляев

## ҖИҢҮЛЕ ЯШЬЛЕК

Без яшьлеккә... вокзаллардан киттек,
Калды кызлар озатып тын гына.
Әллә тузгып каз өмәсе узды —
Фронт күмелде бала йонына.
Шинель кидек — гүя канат чыкты,
Шинель икән егет канаты:
Паспорт түгел, унҗидедә шинель
Гражданлыкны безнең аңлатты.
Без яшьлеккә килдек — йөгереп түгел,
Ә шуышып җирдән түш белән...
Гүя бөтен яшәешкә безнең
Төтен исе сеңгән шинельдән.
Көннәр йөгерә ут чыккандай алга,
Кимемәгән тарткан йөгем дә.
Дирбиясе чишелмәгән аттай
Ятармын мин ауган җиремдә.
Өйрәтәләр: инде акыл җый, дип,
Тормышта, дип, артык көчәнмә.
Нишлим: күнеккәнмен тарту көчен
Җиңү көче белән үлчәргә...
Күңел белән яшьлегемә китәм,
Әйтерсең, мин нидер оныткан.
Кире кайтам, гүя, шинель киеп —
Кайткан кебек алгы сызыктан.

## Җыр канатында

Юк, үкенмим иртә туганмын дип,
Соң туганмын дип тә көрсенмим:
Сайлаганмын җанга хуш килерлек
Кырыс заманнарның берсен мин.
Чакырылмаган кунак түгел идем —
Шуннан зурын өмет итмәдем.
Бар чагында илем җәлләмәде
Бәрәңгесе белән икмәген.
Чибәрләргә күзем төшсә төште,
Кызыкмадым малга, чиннарга.
Алсам бары бер өстенлек алдым —
Батырлыкны зурлап җырларга.

---

ИСЛАМ БЕЛЯЕВ (1926) — берничә шигырь җыентыгы авторы. Казанда яши.

Йөрәк калды сугыш кырларында,
Ярасыннан саркый кайнар кан:
Батырларны онытылудан саклап,
Әйтерсең, ул үзен шартлаткан.
Алар исемен, гүя, каны белән
Маңгаена язган ташларның.
Әйтмәс илем, җиңел җырладың, дип,
Икмәкне, дип, бушка ашадың.
Камалулар, чигенүләр булды,
Әсирлекне хәтта татыдык.
Бирелмәгән Брест крепосте кебек
Яши бездә барыбер батырлык...
Юк, үкенмим, иртә туганмын дип,
Соң туганмын дип тә көрсенмим:
Елларны җыр канатында кичкән
Җиңү солдатының берсе мин!

●

Әйткән сүзме — алтын, әйтмәгәнме —
Сынап карамадым һич әгәр.
Тик һәр сүзе солдат антының
Җиңүләргә иде бәрабәр.

Эзләмәдек ул чак агым җаен,
Сайламадык юлның такырын...
Чиреге дә әле түләнмәгән
Яуда исән калу хакының.

## Яшьтәшем

Индустрия белән бергә үстек,
Без кендеккә-кендек берегеп.
Ана сөте миңа кимрәк тигән,
Ә ул «имгән», имеш, җен кебек.
Ай үсәсен көн үсте ул батыр:
Яшьтәшләр, дип безне кем әйтер.
Кем уйлаган, авыр сәгать килгәч,
Түләр дип ул миңа әҗәтен.
Хәтерлим мин фашист яуларының
Күкрәгемә төбәп атканын.

Индустрия, мине аралап,
Куйды шунда корыч калканын.
Ул егылса, мин җан өрдем аңа,
Ул көч бирде миңа, мин аусам,
Яралар тиң. Чакрымнар да тигез,
Үткән юлга борылып карасаң.
Без — яшьтәшләр. Теге ерак чорда
Туган кебек бер үк анадан,
Икебез дә куәт алып үстек
Ил Җиңүгә салган маядан.

## Яшьлек калыр

Май аена керә һәр ел өмет,
Әйтерсең лә, хисләр яңара...
Җиңү тугач, миңа мыек чыкты,
Унтугыз яшь безнең арада.
Сизмәдем дә чал кунганын чәчкә,
Яз арты яз, гүя, яшәртте.
Һәр ел саен Май әйләнеп кайтты,
Җиңү кайтты ияртеп яшьлекне.

Хатирәләр кат-кат яңаралар,
Искә төшә Җиңү юллары.
Миңа инде тиздән алтмыш тула,
Ә Җиңүгә — кырык тулганмы?!
Мин үләрмен бер көн — Җиңү калыр:
Бәлкем мең яшь тулыр аңарга...
Кырык бишнең Тугызынчы мае
Яшьлегемне саклар һаман да.

## Хәмзә Бәдретдинов

# ҖИДЕ МЕҢ ТӨРЛЕ БОРЧАК

Ленин каласында ак төннәр хакимлек иткән көннәрнең берсендә Бөтенсоюз үсемлекчелек институтына Һиндстан башкаласыннан хат килде.

— Борчакның туган җиреннән! — дип, шатланып кулына алды аны Рауза Һадиевна.— Мәскәүдә К. А. Тимирязев исемендәге авыл хуҗалыгы академиясе аспирантурасын тәмамлап киткән Балрам Шарма язган.

«Хөрмәтле Рауза Һадиевна! Бу хатымда сезнең «Борчак», «Борчак генетикасы һәм селекциясе» дигән ике китабыгызны инглиз теленә тәрҗемә итүем турында хәбәр итәргә ашыгам,— дип яза Дәһлидәге Һиндстан авыл хуҗалыгы фәнни-тикшеренү институты хезмәткәре.— Шул уңайдан сезгә берничә соравым да бар: китапларыгыздагы рәсемнәрнең төп нөсхәләрен җибәрә алмассызмы икән?..»

— Яшь белгечнең үтенечен ничек канәгатьләндермисең инде?! — диде Рауза Һадиевна хатны укыгач.— Бүген үк җибәрәм!

Тик, күпме генә эзләсә дә, берничә рәсемне таба алмады ул. Күрәсең, типографиядән кире кайтармаганнардыр. Аларны яңадан ясарга кирәк. Дөрес, аның бу яктан рәссамнарга ялынасы юк. Китапларын үзе бизи ул. Рауза Һадиевна рәсем ясар өчен кирәкле каләмнәрен, кара тушьлы шешәсен алып куйды. Өстәлнең аргы башына борчак гербарийларын урнаштырды. Кузаклы сабакларның сурәте ватманга төшә башлады. Кичен инде Шармага җибәреләчәк хат та әзер иде. Рәсемнәр дә, яңалыклар да Һиндстанга китте.

Рауза элемтә бүлегеннән әйләнеп чыкканда, кичке җиде тулып узган иде инде. Тик шулай да, эш сәгатем тәгәлләнде дип, Н. И. Вавилов исемендәге Ленин орденлы һәм Халыклар дуслыгы орденлы Бөтенсоюз үсемлекчелек институтының өлкән фәнни хезмәткәр-консультанты, авыл хуҗалыгы фәннәре докторы Рауза Макашева өенә ашыкмады. Герцен урамына урнашкан фәнни-тикшеренү үзәгенә кабат килде.

Эш бүлмәсендә аны, башка вакыттагы кебек үк, остазларының рәсемнәре каршылады. Менә дөньяга атаклы ботаник, селекционер академик Н. И. Вавилов. Рауза Бөтенсоюз авыл хуҗалыгы фәннәре академиясенең беренче президенты Николай Ивановичны беренче тапкыр 1939 елны Бөтенсоюз үсемлекчелек институтының фәнни утырышында күргән иде. Бөек галимнең сөйләү осталыгына, фикер киңлегенә таң калды. Аның имзасы белән чыккан һәрбер язманы укып баруны гадәткә кертте. Фәнни эшкә тәвәккәлләр алдыннан Рауза Советлар Союзын иңләп-буйлап чыккан, дөньяның уналты илендә экспедициядә булган Николай Иванович Вавилов хезмәтләре белән таныша торган иде.

Янәшәдә — киң күңеллелеге, таләпчәнлеге йөзенә чыккан Г. Д. Карпеченко фотосы. Рауза Ленинград дәүләт университетының биология факультетында укыганда, ул үсемлекләр генетикасы кафедрасы белән җитәкчелек итте, 1939 елда, Рауза аспирантурада калгач, Георгий Дмитриевич кызның фәнни җитәкчесе булды. Тик, сугыш башлану сәбәпле, диссертацияне тәгәлләп өлгерә алмады Рауза.

Стенадагы өченче фотодан институтның кузаклы культуралар бүлеге җитәкчесе, авыл хуҗалыгы фәннәре докторы профессор Н. Р. Иванов карап тора. Илдә җиңү таңы балкыгач, Николай Родионович Раузаны аспирантурага яңадан чакырды. Борчаклар дөньясы белән таныштырды. Аның турында: «Бу бик әрсез, талымсыз культура,— дип сөйләде.— Илнең теләсә кайсы ягында үсә. Аксымга бай. Саламын органик ашлама итеп тә файдаланалар. Борчак басуларда азотны арттыра...» Аннары алар диссертация турында тәфсилләбрәк сөйләштеләр. Теманы ачыкладылар: «Ленинград өлкәсендә борчакны селекцияләүдә беренче кулланма». Районлашкан сортларның нинди уңай сыйфатлары һәм җитешсезлекләре бар? Иртә өлгерүчән, авыруларга каршы торучан, аксымга бай һәм мул уңыш бирүчән борчак булдыру өчен селекционерлар нинди генетик кулланмага мөрәҗәгать итәргә тиешләр? Аспирант шуңа охшаш сорауларга җавап табарга тырышты.

Тәҗрибәләр Пушкин шәһәрендәге Үзәк селекция һәм генетика тәҗрибә станциясендә үткәрелә. Анда барыр алдыннан, коллекцияләр белән эш итәсен уйлап, Рауза Һадиевна орлык саклагычка керде. Борчак язмышы белән кызыксынып, тимер савытларның капкачларын ачты, кадерле бөртекләрне учына алды. Шул чак аның күзенә ят орлыклар чалынды.

— Николай Родионович, карагыз әле!..

— Люпинны әйтәсезме? — Николай Родионович җитди иде.— Минем «гөнаһ» ул. Ленинград блокадасы вакытында күселәрне шулай куркыттым. Корткычлардан котылыр әмәл калмаган иде. Калай савытларга да тешләре үтте бит, ә менә люпинның үзенә түгел, исенә дә чыдамыйлар, чөнки составында алкалоидлар күп.

Н. Р. Иванов, шул сүзләренә ялгап, институт хезмәткәрләренең сугыш чорында күрсәткән батырлыкларына да тукталды:

— Дежур торганда, бөтен дөньядан җыелган авыл хуҗалыгы культуралары коллекциясендәге ике йөз меңнән күбрәк үсемлек орлыкларына ник бераүнең кулы күтәрелсен?! Сакладык! Чит ил галимнәренең кайберләре моңа ышанмадылар. Англия профессоры Дарлингтон 1935 елда «Табигать» журналына: «Ачлыктан шашкан ленинградлылар атаклы коллекцияне ашадылар»,— дип язып чыкты. Соңыннан, институтка кереп, коллекцияне үз күзләре белән күргәч, аңа кызарырга туры килде.

— Әйбәт сакланган бу орлыклар! — дип, Рауза да әңгәмәгә кушылды.— Тәҗрибәләрне иркенләп үткәрергә була!

Коллекция байлыгы белән яхшылап танышкач, Рауза сынау эшенә керешә. Һәр савыттан йөзәр бөртек санап алды да, берәр квадрат метрлы җиргә чәчте. Үсеш тизлеге турындагы мәгълүматларны һәр көнне дәфтәренә яза барды. Һәр сабакның буыннары исәпкә алынды, чәчәкнең кая урнашуы билгеләнде. Аны җиденче-унберенче буыннарда күрсә, мәгълүм закончалыкка нигезләнеп: «Бу борчак тиз өлгерәчәк»,— дигән нәтиҗә ясады. Чәчәкләрне уникенче-унбишенче буыннарда очрату — әлеге үсемлекнең өлгерү (вегетация) чоры уртача дигән сүз иде. Моннан да югарыракка «сикергән» чәчкәләр исә кара көздә дә орлык бирмәячәк. Уңыш өлгерер чак җиткәч, Рауза Һадиевна башка сорауларга җавап эзләде: һәр буында күпме кузак бар, бер кузакта ничә борчак, авырлыклары нинди? Өч ел кабатлады ул бу тәҗрибәне, һәр сортка өч тапкыр бәя бирде. Борчакның бөтен серләре ачылды кебек: селекционерлар файдалансыннар гына!

Кандидатлык диссертациясен яклагач, Рауза Һадиевна кузаклы культуралар бүлегендә эштә калды. Борчак коллекциясен системалаштыру белән шөгыльләнә башлады. Җитәкчесе Николай Родионович Ивановның әледән-әле кабатлый торган: «Эшләргә генә түгел, язарга да кирәк. Тәҗрибәләр һәм доклад ясау белән генә чикләнмичә, ачышларны фәнни мәкалә хәленә китерергә кирәк!» — дигән сүзләре яшь галимәнең тормыш закончалыгына әйләнде.

Н. И. Вавилов, Г. Д. Карпеченко, Н. Р. Иванов кебек талантлы шәхесләр Рауза Һадиевнаның фәнни эшчәнлегендә гомерлек маяк булып калдылар. Шуңа күрә ул аларның фоторәсемнәрен эш бүлмәсенең түрендә тота. Гомумән, язмышыннан канәгать ул. Коллективтан уңды. Җанының һәр талпынышына таяныч табып була монда. Кайчак туган телдә сөйләшәсе килә башлый. Андый вакытта яшелчәләр бүлегенә керә, лаборант Гали Бәхтиев белән Татарстан турында гәпләшеп алалар.

— Әйдәгез, Гали Харисович, кайтырга бергә чыгыйк әле,— ди еш кына Рауза ханым.— Юл уңаенда туган яклар турында да сөйләшербез!

Гали Бәхтиев бик теләп ризалаша.

— Үзем дә бүген сезне искә алып утырдым әле, күңелне бер сорау кытыклап торды.

— Нинди сорау ул?

— Фамилиягез кызык сезнең. Кайдан алынды икән ул? Күпме йөреп тә Макашев фамилиясен бүтән бер дә очратканым юк.

— Үземә дә кызык тоела иде ул, Гали,— диде Рауза Һадиевна көлемсерәп, аннары ачылып сөйләргә керешә.— Тик, серенә төшенгәч, күңелсезрәк булып калды. Мин туган якта, ягъни Татарстанның Алабуга районындагы Тургай авылында, әтигә таныклык тутырганда, Мөхәммәтша бабай исемен бозып, Макашев фамилиясе ясаганнар.

— Ә-ә! Игътибарсызлык тарихы гына икән.— Алар көлешеп алдылар.— Шулай да якташларыгызга үпкәләргә ярамый: сирәк очрый торган фамилия ясаганнар да куйганнар!..

Рауза Һадиевна кырык ел эчендә борчакка кагылышлы нинди генә мәсьәләләргә тукталмады — борчакның килеп чыгышы, тезелеше, классификациясе, аны үстерү технологиясе, чәчәк ату һәм серкәләнүнең биологик үзенчәлекләре, сортларның сыйфатын яхшырту ысуллары, авыруларга каршы көрәш чаралары — һәммәсен җентекләп өйрәнде. Хезмәтләрен матбугатта чыгарды. 1973 елда «Колос» нәшриятының Ленинград бүлегендә Рауза Һадиевнаның селекционерларга, фәнни хезмәткәрләргә, агрономнарга адресланган унсигез табаклы «Борчак» исемле китабы дөнья күрде.

— Минем докторлык диссертациясенең нигезен тәшкил иткән бу китапның «Үстерү технологиясе» бүлеген Татарстан АССРның атказанган фән эшлеклесе, авыл хуҗалыгы

фәннәре докторы А. А. Җиһаншин язды,— ди Рауза Һадиевна.— Ул Татарстан авыл хуҗалыгы фәнни-тикшеренү институтында еллар дәвамында алып барылган алдынгы тәҗрибәне яктыртты. Әлеге ысулларга хәзер Һиндстан авыл хуҗалыгы белгечләре дә таяналар. Чөнки, ике ил арасындагы махсус килешү буенча, 1983 елда, Балрам Шарма китапны инглиз теленә дә тәрҗемә итте.

Академик Н. И. Вавилов тәкъдиме белән чыгарыла башлаган «СССРның культураланган флорасы» сериясендә дә кузаклыларга багышланган дүртенче томның борчак турындагы бүлегендә (1979) Рауза Һадиевнаның утыз еллык хезмәте чагылыш тапты. Анда искәртелгәнчә, Татарстанда — борчак, Башкортстанда — борсак, Чувашстанда — пурзя яки парса, Мордовия АССРда кенав дип йөртелүче бу культураның күпчелеге РСФСРда, шул исәптән Идел буенда игелә. Бу зонада Татарстан өлешенә киң мәйдан туры килә. Р. Һ. Макашева язганча, республикабыз колхоз-совхозларының борчак силосы хәзерләү тәҗрибәсе дә игътибарга лаек.

Сортның чисталыгын билгеләү өчен агроном-орлыкчыларга, селекционерларга, колхоз-совхоз җитәкчеләренә, авыл хуҗалыгы уку йортлары студентларына тәкъдим ителгән ике китапта — «Авыл хуҗалыгы культураларын агробацияләү буенча кулланма» (1976) белән «Яшелчә культураларын һәм тамыразыкларны агробацияләү буенча кулланма»да (1982) Р. Һ. Макашева кырык сигез төрле борчакка фәнни анализ ясаган.

— Менә аларның берсе,— ди Рауза Һадиевна, савыттагы борчакны кулына алып.— «Казанский 38» сорты бу. Бөтенсоюз үсемлекчелек институты коллекциясе каталогына 5705 нче итеп теркәлде. Туган җире — Татарстан авыл хуҗалыгы фәнни-тикшеренү институты. Авторы — В. З. Шәкүров. Татарстанда 1966 елда районлаштырылды. Ул ямь-яшел булып тишелеп чыга. Сабагының озынлыгы — 80—120 сантиметр. 16—20 буын үстерә. Чәчәкләре ак. Кәкрерәк кузаклары биш-алты сантиметрлы була, кузакта — дүрт-сигез борчак. Ачык-сары, кызгылт-сары төстәге орлыклары түп-түгәрәк, мең данәсе 230—245 грамм тарта. Составында 22—27 процент аксым бар. Уртача — 76—84 көндә өлгерә. Аерым алганда, Татарстан АССРның алты сынау участогында һәр гектардан уртача 22,9—25 әр центнер уңыш бирде...

«СЭВның халыкара классификаторы» (1981) дигән белешмәне төзүчеләр исемлеге дә Р. Макашева фамилиясе белән башлана.

— Миңа, Советлар Союзы вәкиле буларак, Экономик Ярдәмләшү Советының ГДРда 1978 елның октябрендә үткәрелгән утырышында катнашырга туры килде,— ди бу уңайдан Рауза Һадиевна.— Венгрия, ГДР, Болгария, Польша, Румыния, Чехословакия галимнәре белән берлектә, борчак сортларын исәпкә алуның яңа системасы турында сөйләштек. Аннары «СЭВның халыкара классификаторы» проектын карадык. Монда сортларның киңәйтелгән тасвирламасына таянып эш иттек. Бу ысул кәгазь боткасыннан коткарды, информацияне ЭВМда эшкәртергә мөмкинлек туды, селекция өчен кулланмалар әзләүне гадиләштерде.

Электрон-хисаплау машиналарына таяну, әлбәттә, эшне тизләтә. Әгәр Бөтенсоюз үсемлекчелек институты коллекциясендә сакланган борчакларның җ и д е м е ң л ә п төрен гадәти ысул белән генә тикшерә башласаң, күпме вакыт таләп итәләр иде. Бүгенге темплар исә ашыгырга куша. Чөнки авыл хуҗалыгына кузаклы культураларның төп вәкиле булган борчакның иң отышлы сортлары кирәк.

Бүгенге көндә әлеге җитди проблеманы хәл итүдә Рауза Һадиевнаның җиде аспиранты да катнаша. Николай Савкин, мәсәлән, борчакның коелмый торган сортын булдыруны бурыч итеп куйды. Бу мәсьәлә җир хуҗаларын нык борчый. Колхоз-совхозларда: «Борчакны чапкач, яңгыр яуса, кузак ярыла, орлык коела,— дип зарланалар,— орлыклар, тегеп куйган кебек, кузакка ныграк ябышсыннар иде!»

Ольга Романованы исә үсемлекнең гөмбә авыруына каршы тору сәләте кызыксындыра. Дөресрәге, аспирант бу сыйфатны үсемлек организмына күчерергә, зур югалтуларны кисәтергә омтыла. Валентина Зенько культураларны төрле һава шартларында — артык юеш һәм дымы аз туфракта сыный. Кузакларны тизрәк өлгертү проблемасы да игътибар үзәгендә. Бу уңайдан институтка Франциядән кайткан «Орус» сортына таяналар. «Орус» бик кирәкле берничә сыйфатны берләштерә: тиз өлгерә, җимешле һәр буынында ике-өч кузак бирә, тамыры нык. Болардан тыш, борчакка тагын бер таләп куела: егылмасын, җиргә ябышып комбайнчыны интектермәсен! Шуның өчен, Украинада, Польшада, Англиядә районлашкан берничә сортны файдаланып, яфракның авырлыгын киметергә, сабакны ныгытырга тырышалар.

Әлеге мәсьәләне хәл итүне Рауза Һадиевна үсемлекнең нәсел сыйфатларына таянып аңлата:

— Хәзер цитологлар борчак организмындагы һәр генның ролен билгеләделәр. Димәк, киләчәктә геннар төзелешен үзгәртеп, сабак озынлыгын көйләргә, яфракны үзгәртергә, кузаклар санын билгеләргә, борчак составындагы аксым, шикәр күләмен арттырырга, аны салкынга, авыруларга, корткычларга чыдамлы итәргә мөмкин булачак...

Моннан йөз егерме еллар элек Австралия галиме Грегор Мендель башлаган тәҗрибәләрнең дәвамы турында якташыбыз горурланып сөйли. Бу эзләнүләр кузаклы культураларның яңадан-яңа төрләрен ачуга китерде. Туган илебездә борчак селекциясенә нигез салучы Д. Л. Рудзинский, мәсәлән, 1924 елга унбер яңа сорт чыгарды. Ә хәзер Бөтенсоюз үсемлекчелек институты коллекциясендә һәм якташыбыз — Апас районының Янгелде авылында туып-үскән Социалистик Хезмәт Герое, Ленин премиясе лауреаты, ВАСХНИЛ академигы Гайфетдин Галиев эшли торган Кубань тәҗрибә станциясендә йөз егермедән артык районлашкан сорт бар.

— Тик менә колхоз-совхоз җитәкчеләре, агрономнар булган орлыктан нәтиҗәле файдаланмыйлар,— дип борчыла Рауза Һадиевна.— Кайбер хуҗалыкларның аерым кырларында гел бөртекле культуралар гына игелә. Чәчү әйләнешенә борчакны да кертсәләр, Татарстан мисалы исбатлаганча, гектарның нәтиҗәлелеге 2,7 шәр центнерга кадәр арта ала! Өстәлләргә икмәк булып төшәсе бодай белән терлек сыйлауны да хуплыйсы килми. Терлек азыгына борчак оны күбрәк кертелсә, аның составындагы кыйммәтле матдәләр итне, сөтне, майны мулрак җитештерергә мөмкинлек бирәчәк...

Борчылып сөйләсә дә, якын киләчәктә үз ачышларының халык хуҗалыгына нык ярдәм итәчәгенә ышана ул. Шул ышаныч аңа яңа эзләнүләрендә таяныч булып тора.

## БЕР СОРАУГА — БЕР ҖАВАП

СОРАУ:

— КПССның XXVII съезды илебез тормышының һәр тармагында кискен борылыш ясау кирәклеген басым ясап күрсәтте, сезнеңчә әдәбият бу процесста нинди роль уйнарга тиеш? Шул уңайдан үзегезнең нинди иҗат планнарыгыз бар?

ЛӘБИБӘ ИХСАНОВА:

— Съездда М. С. Горбачев сөйләгән политик докладны һәм делегатларның чыгышларын тыңлаганда, күңел җилкенеп китеп, яшьрәк булсаң икән дә хәзер, материаль байлыклар тудыручы берәр өлкәдә җиң сызганып эшләсәң икән, дигән уй күңелгә килеп китте. Үкенечле уй, билгеле. Җырда да бит, яшь гомерләр ике килми, белегез кадерләрен дип җырлыйлар. Ә вакытның кадерен яшьлектә дә, картлыкта да белергә кирәк. Аннан соң шунысы да бар: һәр кеше үз урынында, кулыннан килгән үз эшен җиренә җиткереп эшләргә тиеш. Партиябезнең XXVII съезды куйган таләп шундый. Ә әдипнең эш урыны — язу өстәле, вакыты — берни белән дә чикләнмәгән.

Кешелекнең иң гүзәл сыйфатларын тәрбияли торган әсәрләр бигрәк тә яшь буын өчен кирәк. Безнең балалар хәзер рәхәт яши, алар шуңар күнеккәннәр, шулай булырга тиеш дип уйлыйлар. Ләкин кайчак ул бәхетнең нинди бәяләр бәрабәренә яулап алынуы гына башларына килми. Без — өлкәннәр дә бу турыда үзләренә бик аз сөйлибез, үткән юлларыбызга багышланган әсәрләр дә көннән-көн азрак языла. Ләкин балаларга тарихны оныттырырга ярамый...

Мине күптәннән инде сәнәкчеләр фетнәсе вакытындагы канлы вакыйгалар дулкынландыра иде. Кулаклар тарафыннан һәлак ителгән беренче совет укытучыларының фаҗигале язмышларын балаларга сөйләп бирү теләге туды. Инде шактый гына материаллар да җыелды, шул заман кешеләренең кайберләрен күреп сөйләшенде дә. Әмма бу зур җаваплы темага тиз генә тотынырга әллә йөрәк җитмәде, әллә кул арасына кергән башка эшләр аны артка этәрә килде, бу повесть әле һаман киләчәктәге планнар рәтендә йөри бирде. Шушы көннәрдә ул мине шактый еш борчый башлады. Уйларым әйләнә дә шуңар кайта. Инде артык озакка сузмаска, ныклап эшкә тотынырга кирәк!



**Н. Б. Бакиров,**
КПССның Әлки райкомы беренче секретаре

# ТУФРАК ТУГАННАРЫ БЕЗ

Безнең Әлки яклары белән азмы-күпме танышлыгы булган кеше «Алпар балчыгы» дигән сүзне ишетми калмас. Мәүләшә елгасы ерганагындагы гап-гади күксел балчык инде ул, югыйсә. Әмма аның элек-электән, «ашарга яраклы икән», дигән шөһрәте калган. Һәм ярлы крестьяннар әледән-әле кабатланып торучы ачлык елларында ул балчыкны ашаганнар имеш. Алпарлылар гына түгел, тирә-як авыллардагы ачлар да бу балчыкны алып-алып киткәннәр, ачлыктан шешенгән балаларына биреп, аларның тормышын саклап калырга тырышканнар.

Татар совет әдәбиятының башлангыч елларында иҗат иткән яшь талантларның берсе — шул ук Алпар авылы баласы Фәхри Әсгать үзенең хикәяләрендә нәкъ әнә шул балчыкны ашарга мәҗбүр булган фәкыйрьләр турында язган:

«**Авылда бөтенләе ике йорт (мулла һәм Кәрим бай) икмәк пешерә, ә калганнары** алабута умачы, сөяк оны һәм күк балчык ашыйлар. Көн саен һәр өйгә кырык-иллеләп теләнче кереп чыга. Аларның баштанаяк сәләмәгә төрелгән гәүдәләре, төпкә баткан күзләре, шешенгән битләре йөрәкләрне әрнетә, болай да яралы күңелгә тоз сибә»,— ди ул үзенең «Мәрди» хикәясендә.

Ә бит күк балчыклы ярның тирә-ягы, гомумән, безнең төбәгебезнең барлык мәйданы — икмәк бирергә юмарт җирләр. Шул җирләрдә бик борынгы ата-бабаларыбыз ук иген иккәннәр. Туган якны өйрәнү музеендагы тегермән ташы (XII гасыр) һәм сука тимере бабаларыбызның шул мактаулы шөгыле турында сөйли.

Әмма Биләр-Болгар кебек нык шәһәрләрне дә кырып-себереп узган монгол яулары бу ике шәһәр арасында яткан безнең төбәк халкын да һәлакәткә дучар итеп китәләр. Күп көч куеп урманнардан арындырылган уңдырышлы җирләрне кабат кара урманнар басып китә.

Һәм бары тик моннан өч йөз еллар элек кенә төбәгебезгә җан керә; авыллар ишәя, урманнар төпләнеп, яндырылып, иген кишәрлекләре барлыкка килә, икмәк өчен көрәш башлана.

Гомумән, Әлки ягының тарихы җир эшкәртү, икмәк табу көрәшенә бәйле. Безнең төп байлык — җиребез-туфрагыбыз. Шул җиребез Апанаев, Демидов кебек эре җирбиләүчеләрне алтын-көмешкә күмгән һәм тук башаклар шаулаган шул җирнең төп хуҗалары... ачка интеккән.

Казаннан 140 километрда, су юлыннан — 60, тимер юлдан 72 километрда урнашкан безнең төбәк — республикабызның иң аулак почмакларыннан берсе. Нәкъ менә шул аулаклык Бөек Октябрь социалистик революциясенә кадәр җирнең төп хуҗалары булган крестьяннарның аеруча вәхши изелүенә мөмкинлек тудыра. Үз биләмәләренә еллар буена килеп тә карамый торган Апанаев, Демидовлар, икмәкне олы базарга озаттырып, акчага, алтынга әйләндерү җаен гына карыйлар. Халык караңгылыкта, наданлыкта, ачлыкта кала бирә. Шул ук вакытта халыкның мондый хәле революцион фикерләргә дә уңай җирлек тудыра.

Беренче рус революциясе елларында да, Бөек Октябрь бусагасында да Әлки ягы авыллары патша законнарына каршы чуалышларда аеруча дан казана.

1905—1906 елларда безнең як крестьяннары арасында самодержавиегә каршы «коткы таратып» йөргән Петербург медицина институты студенткасы, дворянка Валентина Владимировна Некрасованың кыю эше сокланугa лаек. Ул авылдан-авылга, өйдән-өйгә кереп, җирсезлектән интеккән крестьяннарга «әгәр җир аз икән, аны алпавытлардан тартып алырга, моның өчен берничә авыл белән бергә берләшергә», дип өндәп йөри. Бу активлыгы өчен ул кулга алына һәм өч ай төрмәдә утырып, кыюлыгы аркасында гына үзен судта аклап, эзәрлекләүләрдән кача.

Әмма кыю кыз эзләрендә чуалышар ишәя, җирбиләүчеләр кулыннан иң зур байлык — җир һәм икмәк шуа башлый. 1917 елның 11 июнендә Бибай Чаллы кулагы Гайнуллин эчке эшләр министрына мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр була: «Волость комитеты членнары, безнең авыл крестьяннарын җыеп, минем милкем булган 960 пот солыны төрле кешеләргә бушлай таратканнар. Шул ук көнне авыл старостасы Хафиз Ризванов һәм авыл комитеты члены Хәбибулла Шәрәфетдинов минем бакчамны җимереп, мин утырткан бәрәңгене башка кешегә файдалануга биргәннәр.

26 майда комитетның шул ук членнары амбардан, йозагын ватып, 3000 пот арышымны алганнар һәм төрле кешеләргә таратканнар. Хәзер барлык сөргән җиремне алабыз дип куркыталар.

Сездән шәхесемне һәм милкемне саклауны, ә югарыда әйтелгән көчләүчеләрне уголовный җаваплылыкка тартуыгызны кичекмичә үтенәм».— дип яза ул.

31 майда Яңа Чаллы авылы крестьяннары, Мәүләшә кулаклары хуторына килеп, пар җирләрен бүлгәләп алалар.

Безнең якларның атаклы алпавыты Демидов та җир һәм икмәк өчен көрәшкә күтәрелгән крестьяннар алдында чарасыз кала. Ул 1917 елның 14 июлендә губерна комиссарына: «Крестьяннарның җирле волость һәм авыл комитетлары боерыгы белән минем Демидовка авылындагы утарымнан крестьяннар үз белдекләре белән атларны, дирбияләрне һәм авыл хуҗалыгы коралларын алып киткәннәр»,— дип хәбәр итә.

Эре җир биләүче Апанаев та үз утарларында халкның мөшкеллегенә аптырый. Ул да губерна комиссарыннан иске тәртипләрне саклауны сорый:

«Миңа килеп җиткән мәгълүматларга караганда, Спасс өязе Кузнечиха волосте Татар Төгәлбай авылы крестьяннары минем милкем булып торган, уҗым чәчү өчен билгеләнгән 16 дисәтинә җирне үз белдекләре белән тартып алганнар.

Сезнең игътибарыгызга шуларны җиткереп, бу эшне тикшерүегезне һәм минем җиремне болай законсыз рәвештә тартып алуда гаеплеләрне законлы җаваплылыкка тартуыгызны, әлеге җирне минем файдалануыма кайтаруыгызны кичекмичә үтенәм»,— ди ул.

Губерна комиссары хезмәтләрен башкаручы Бартольд та эчке эшләр министрына 1917 елның 5 октябрендә җибәрелгән почтограммасында Әлки волостенда «законнарга буйсынмау» очраклары ешлыгын аеруча басым ясап күрсәтә.

Төбәгебездә совет власте урнаштыру контрреволюцион көчләр белән аяусыз көрәштә зур корбаннар белән уза. Көрәшчеләрнең берсе — Яңа Чаллы авылы кешесе Габдулла Денисов. Февраль революциясеннән соң ул Вакытлы хөкүмәтнең чын йөзен ачып бирүдә, революцион пропаганда алып баруда зур көч куя. Ул делегат буларак Спасс өязе крестьяннарының беренче съездында катнаша. Соңрак ул революцион мөселман комитеты члены буларак, авылдашы Ризаәхмәт Хәмитов белән берлектә Кызыл Армия сафларына сугышчылар туплауда бик актив эшли. 1918 елның ахырында акгвардиячеләр өязнең революцион Советына һөҗүм итәләр. Революционерларны эзәрлекләү башлана. Хәмитов белән Денисов акгвардиячеләр кулыннан һәлак була.

1918 елны барлык волостьларда Кызыл Армияне ныгыту өчен хәрби лагерьлар оештырыла. Алпар авылындагы лагерьга гына да 500 дән артык сугышчы туплана. Бу лагерьның командирлары итеп Зыя Вәлиев һәм Петр Демидов билгеләнә.

РКП(б) Үзәк Комитетының чакыруы буенча эчке һәм тышкы контрреволюциягә каршы көрәшкә хәзерге безнең район территориясеннән фронтка 12 меңнән артык кеше китә. Данлыклы якташыбыз (Карга авылы егете), партия һәм совет эшлеклесе, Астрахань мөселман комиссариатының беренче председателе Касыйм Туйбахтин 1918 елның 15 августында контрреволюционерлар тарафыннан ерткычларча үтерелә.

Районташларыбыз арасында бөек Ленинны күргән һәм аның ялкынлы чыгышларын тыңлаган революционерлар да бар. Октябрь революциясендә һәм гражданнар сугышында катнашкан якташыбыз С. А. Герасимов үзенең истәлекләрендә болай яза:

«1917 елның октябрендә мин Төньяк-көнбатыш фронтта, Петроградтан ерак түгел идем. Командир безгә башкалада эшчеләр восстаниесе булуын хәбәр итте. Бу яңалыкны зур шатлык белән тыңладык.

Тиздән безне, солдатларны, Петроградка, восстаниене «бастырырга» озаттылар. Берничә дистә чакрым киткәч поезд туктады — алда юл юк, ул сүтеп куелган иде. Шуннан безнең командирлар качып беттеләр, үз арабыздан яңаларны сайлап куйдык. Петроградка киттек. Шәһәрдә безне зур мәйданга чакырдылар. Митинг булырга тиеш иде.

Менә бер өйнең балконында берничә кеше күренде. Аларның берсе алгарак чыкты һәм бер кулын күтәрде. Сафларда: «Ленин, Ленин!»— дип пышылдадылар. Тынлык урнашты.

Ул озак сөйләде. Без буржуйларның власть башыннан бәреп төшерелүләре, властьның халык кулына күчүе, җирнең крестьяннарга бирелүе, сугышның тиздән бетәчәге турында йотлыгып тыңладык. Ул сөйләгәндә һаман саен алга, халыкка таба омтыла, гүя безгә якынрак килергә тырыша иде.

Ленинннан соң тагын берәү (эсер диделәр аны) сөйләде. Тик аны без рәтләп тыңламадык. Бар да: «Без Ленин яклы! Яшәсен Ленин!» — дип кычкыра башлады».

Районыбызда колхозлашу еллары шулай ук киеренке сыйнфый көрәштә уза. 1931 елда районда машина-трактор станциясе оеша. Авылларга беренче тракторлар кайта. Халык шул елларда:

Урак-сука, тырма-тубал —
Берсе кирәкми алар,
Күмәкләшеп без алабыз
Трактор-машиналар,—

дип җырлый башлый.

Бу елларның кыю улы Вәгыйз Вайсалов истәлеге дә райондашларыбыз хәтерендә тирән уелган. Коллективлашу чорында ул Чуваш Кичүе авылында партоешма җитәкчесе, авыл Советы председателе итеп сайлана.

1931 елның иген уңышын урып-җыю вакытында кызыл йөкләр белән хөкүмәткә ашлык озатырга карар ителә. Әле авылда шактый көч булып торган аерым хуҗалыкларга бу карар аяз көнне суккан яшен кебек тоела. Мөнип исемлесе кара төндә коммунист Вайсаловка балта белән ташлана. 27 яшьлек коммунистның кабере өстендәге сиреньнәр хәзер дә һәр язда чәчәккә күмелеп тирә-якка хуш ис бөркиләр.

Бу елларның тагын бер кадерле хатирәсе бар: 1934 елда районыбызның «Чирмешән-202» совхозында күп тиражлы газета эшен оештыруда ярдәм күрсәтү өчен Чуваш Кичүе авылына Муса Җәлил килә. Ул бу газетага көндәлек булышлык күрсәтү белән бергә әлеге совхоз тормышыннан Мәскәүдә татар телендә чыгарылып килгән «Коммунист» газетасына да материаллар урнаштыра.

Күмәк хуҗалыклар ныгып, авылларыбыз икмәк муллыгына тиенгән рәхәт еллар озакка бармый. Ил өстенә фашизм афәте килгәч, безнең як кешеләре дә, «Барысы да фронт өчен!»— дип, фидакарь көрәшкә күтәрелә. Район 10 меңгә якын ир-егетне фронтка озата. Аларның өчтән бере генә, Җиңү яулап, туган якка әйләнеп кайту бәхетенә ирешәләр.

Әлкилеләр арасында алты кеше — К. Г. Афанасьев, З. Г. Исхаков, С. М. Крайнов, Г. И. Филиппов, Г. Ш. Шәвәлиев, А. П. Чулков Советлар Союзы Герое исеменә лаек булдылар. Сугышчан орден-медальләр белән бүләкләнгән якташларыбыз аеруча күп.

Тылдагыларның фидакарьлеге дә сокланырлык. Ул еллар Әлки ашлыгы төялгән кызыл йөкләр белән истәлекле.

Район халкы хәзер дә җиң сызганып шул изге эшне — ашлык һәм башка төрле азык-төлек җитештерүне дәвам иттерә. Ил табынына район халкы ел саен кимендә 20 мең тонна сөт, 4 мең тоннадан артык ит куя. Узган 1985 елда Ватан амбарларына 43 мең тоннадан артык ашлык озатылды.

Игенчелектәге фидакарьлеге өчен «Салман» совхозы уңганы Василий Прохоров Социалистик Хезмәт Герое исеменә лаек булды. Колхозларыбызда һәм совхозларыбызда фән казанышларына таянып уңышны арттыра баручылар ишәя тора. Татарстан АССРның атказанган агрономы Солтан Хәсәнов эшләгән «Югары Актай» колхозында, мәсәлән, интенсив технология кануннары белән игелгән сабан бодаеннан — 28 әр, арыштан 26 шар центнер ашлык җыеп алдылар.

Бирегә механизаторлар, коллектив подряд ысулы белән эшләп, җиргә һәм игенчелек техникасына яңача караштагы яшиләр. Механизаторлар бригадасын Татарстан АССРның атказанган механизаторы Фазыл Халиков җитәкли. Ул: «Механизатор үзен җирнең туганы итеп тоярга тиеш»,— дигән фикердән чыгып эш итә.

Татарстан АССРның атказанган авыл хуҗалыгы работнигы, «Салман» совхозының баш агрономы Шамил Гатин, «Актай» совхозының атаклы механизаторы Фаик Шәмсетдинов, «Яшь көч» колхозыннан остаз-тракторчы Ислам Галиуллин һәм башка бик күпләр — үз язмышларын җир һәм икмәк белән гомерлеккә бәйләгән кешеләр.

Элекке елларда балчык ашарга мәҗбүр булган алпарлылар хәзер һава шартларына бәйсез рәвештә диярлек тотрыклы уңыш алып киләләр. Совхоз директоры Марс Габдрахманович Хәмитов, эшеннән аерылмыйча, авыл хуҗалыгы институтын тәмамлады. Ул совхоз басуларында фәнни тикшеренүләр дә алып бара, үз тәҗрибәсе белән расланган фәнни казанышлардан хуҗалык итүдә дә кыю файдалана. Совхозның тары игүдәге отышлы адымнарын нәкъ менә директорның эзләнүләре нәтиҗәсеннән санарга кирәк.

Басуларыбызны тагын да юмартрак итү өчен җирләрне мелиорацияләргә тырышабыз. Безнең Әлки районы җирләре дымга туймый. Үсемлекләргә иң кирәк чакта явым-төшем 205—220 миллиметрдан артмый. Еллык явым-төшем дә 405—420 миллиметр гына. Елгалар да күп түгел бездә. Шуңа күрә соңгы елларда районда буалар челтәре булдыруга зур чыгымнар тотылды. Хәзер 7,3 миллион кубометр су туплый алырлык 13 буабыз бар. Алар суга сусаган мәйданнарның өчтән бер өлешен тәэмин итәргә мөмкинлек бирә. Буалар төзү, бигрәк тә хуҗалыкара файдаланудагы буалар буарга перспектив бурычлар билгеләнде.

Буалар һәм сулыклар — игенченең ярдәмчесе генә түгел, туган ягыбызның гүзәллеге дә. Төбәгебездә ике мең ярым гектар урман һәм ике мең гектар куаклып бар. Кече Чирмешән сулыкларында кондызлар уйный, дисталәрчә төрдәге киек кошлар оя кора, чабак-чуртаннар шаярыша.

Урманнарда киек җәнлекләр һәм кошлар ишәя бара. Барлык урманнарда куян, кыр кәҗәсе, кабан дуңгызлары, пошилар бар. Соңгы елларда хәтта пошиларны, кабаннарны хуҗалык, төз ату спорты максатларында аулау кирәклеге дә туды. Урманнардан сувенирлар фабрикасы өчен югары сыйфатлы йомшак агач һәм такта яру өчен чимал да озатыла.

Шул ук урманнар бүләгеннән колхозчылар һәм совхоз эшчеләре матур-матур өйләр салалар. Моннан тыш районда ел саен миллион сумлык торак йортлар төзелә. Бу юнәлештә безнең ихтыяҗыбыз тагын да зуррак. Авыл яшьләрен канәгатьләндерерлек культура-көнкүреш объектлары, торак төзелешне алып барырга кирәк. Мондый чаралар егет-кызларның туган яктан китеп бармавын тәэмин итәр дип өметләнәбез.

Бу өлкәдә башкарылган эшебез дә байтак. Колхоз-совхозларның үзәгендә яхшы мәктәпләр, культура йортлары, кибетләр төзелде. Юллар һәм күперләр төзелеше белән дә җитди шөгыльләнәбез. Хәзер тимер-бетон күперләр салу мәсьәләсен хәл ителгән дип саный алабыз. Соңгы елларда гомуми озынлыгы ярты километр булган 16 тимер-бетон күпер салдык.

Хәзер асфальт заводы төзелешендә эшләр тәгәлләнеп килә. Юлларны, күперләрне яхшыртуда бу заводка зур өметләр баглыйбыз.

Районыбызда 25 мең ярым кеше яши. Шуның биштән өч өлеше — татарлар, руслар — 4446, чувашлар 5756 кеше. Милләтләр, Тукайча әйтсәк, «тормыш кичерәләр сайрашып, тел, лөгать, гадәт вә әхлак алмашып».

КПСС райкомы һәм район Советы башкарма комитеты халыкның культура-көнкүреш ихтыяҗларын канәгатьләндерүне хуҗалык бурычларын хәл итү белән бер дәрәҗәгә куя. Чөнки безнең як халкы әдәбиятка, сәнгатькә гашыйк, җыр-биюне ярата. РСФСРның халык артисты Галия Булатова, Татарстанның атказанган артистлары Әзәл Яһудин, Исламия Мәхмүтова, Рузия Мотыйгуллина — нәкъ менә Әлки икмәге, Әлки чишмәләренең сулары үстергән сәнгать җәүһәрләре.

Әлки ягы әдәбият мәйданына да талантларның эреләрен чыгарды. Карамалы авылы кешеләре күренекле әдип һәм җәмәгать эшлеклесе, Г. Ибраһимовның якын дусты һәм фикердәше булган Фатих Сәйфи-Казанлы турында хатирәләрен кадерләп саклыйлар. «Яшәү белән үлем арасында» да иҗат көчен җуймаган өлкән язучыбыз Нәби ага Дәүли — безнең Мәүләшә авылыннан, чуваш халык шагыйре Педер Хузангай Сихтерма авылыннан. Хәзер бу авыл Хузангай исемен йөртә. Шагыйрь Шамил Маннаповның игенчеләрне данлаучы иҗаты, якташыбыз Мөдәррис Вәлиевнең әдәбияттагы ныклы адымнары безне шатландыра. Җыр мәйданына әле яңа гына Борнай егете Мирсәет Сөнгатуллин күтәрелде. Алар безнең хезмәтебездән илһамланалар без алар иҗатыннан рухи көч алабыз.

# ХАЛЫК ХӘЗИНӘЛӘРЕН АЧУЧЫ

**ФАТИХ УРМАНЧЕЕВКА 50 ЯШЬ**




Соңгы берничә ел эчендә без бик нык баедык, рухи баедык. Минем китап шүрлегендә хәзер Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты тарафыннан чыгарылган Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф»ы, «Татар әдәбияты тарихы», «Татар халык иҗаты», «Дастаннар»... Шулар янына Фатих Урманчеевның «Татар халкының героик эпосы» өстәлде.

Кайдадыр диңгезнең барлыгын тоясың, ерактан җиле биткә бәрелә. Ләкин тоясың гына, бар, син әле аның ярында түгел. Хыялда яшәгәне бер, үзен күрү һәм эченә керү, чуму — икенче. Бу әсәрләр миндә шундыйрак тәэсир калдырды. Алар чәчелгән, сибелгән иде. Хәзер җыелган, тупланган — алар әлеге диңгезне хәтерләтәләр, мин аларны күрәм, алар минем өчен реаль. Мин аларның бер төшкә җыелганнары өчен сөенеп бетә алмыйм. «Кыйссаи Йосыф»ның бәйрәмен иттек, «Татар халык иҗаты» чыгу уңае белән шатлыгыбызны уртаклаштык. Дастаннар томын төзегән, төпле, тирән мәкалә һәм искәрмәләр язган Флора Әхмәтованың зур хезмәте турында матбугат фикерен әйтеп узды. Фатих Урманчеев та — шушы өлкәдәге галим. Аңа илле яшь тулган көндә дәшми каласым килмәде. Минем бөтен гомерләрен бер эшкә багышлаган кешеләргә хөрмәтем зур. Шагыйрьләр шундый: шигырь белән керәләр, шигырь белән чыгалар. Фатих Урманчеев ерак Себердә Кызыл Маяк дип аталган кечкенә генә татар авылында туган. Башта шул авылда, аннан күршедәге казах авылында җидееллык мәктәптә белем ала. Казах педучилищесында укып, соңыннан Омск педагогия институтын тәмамлый.

Үз гомеремдә җырчы, композитор, шагыйрьләренең биографияләрен күп сөйләттем. Кайсының әнисе җыр яраткан, кайсының әтисе гармунда уйнаган, кайсының бабасы яки әбисе әкиятче булган. Хәсән Туфанның табигатькә гашыйклыгы да әнисеннән, әнисе аңа еш кына йолдызлар турында сөйли торган булган. Фатих Урманчеев та нәкъ шушы юл белән фәнгә керә. Ул «әниемнең мөнәҗәтләре, авыл яшьләренең әйлән-бәйлән уеннары вакытында яңгыраган халык җырларына мәхәббәт мине ерак Себердән Казанга алып килде»,— ди. Шуннан бирле татар халык иҗаты аның төп эшенә әйләнә. Мин аны егерме елдан артык беләм. Татар шагыйрьләре иҗатында фольклор темасын кайчандыр ул күтәреп чыкты. Фатих Урманчеевның биографиясе гел институтлардан тора. Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтыннан Казан педагогия институтына, аннан Алабугага, Алабугадан Венгриягә. Эгер шәһәренең пединститутында ул — рус әдәбияты доценты. Ул анда да татар халык җырларын өйрәнүен дәвам иттерә. Читтә ул җырлар күңелне тагын да ныграк кузгаталар. Ул хәзер яңадан Алабугада. Укыта һәм иҗат итә. Аның хәзергә чаклы татар, рус, казах, башкорт, венгр телләрендә татар һәм төрки халыклар иҗаты буенча өч монографиясе, болардан тыш «Советская тюркология», «Советская этнография», «Җолдыз», «Казан утлары» журналларында 70 тән артык зур күләмле мәкаләләре басылып чыккан.

Венгриядә дүрт ел. Аз вакыт түгел. Төрле халык җырларына, моңнарына колагы кечкенәдән үк сак кеше өчен бу аз вакыт түгел. Фатих Урманчеевның күңелендә бу ике халыкның иҗаты — җырлары белән бәйле нәрсә дә булса бардыр әле. Читтә күңелгә уйлар күп керә. Мин яңа хезмәтләр өмет итәм. Татар халкының күңел байлыгы Венгрия чикләренә дә барып җиткәндер дип уйлым. Ә Фатих Урманчеевка, талантлы интернационалист галимгә, иҗатында уңышлар телим.

**Сибгат ХӘКИМ.**



# ТУГАН ҖИР ҖЫЛЫСЫ



Кукмара районында биш авылны берләштерүче «Коммунизмга» дип исемләнгән колхоз бар. Колхозчылар таза, мул тормышта гомер итәләр.

— Безнекеләр алтын куллылар,— ди хуҗалык җитәкчесе Хезмәт Кызыл Байрагы ордены кавалеры, КПСС райкомы бюросы члены Габделхәй Шәмсетдинов зур горурлык белән.

Бу сүзләрдә хаклык зур. Колхоз эшче көченә кытлык кичерми. Аның комсомол оешмасы гына да 400 дән артык егет һәм кызны берләштерә. Авылларда яшәүчеләрдән һәркем берничә төрле һөнәргә ия. Механизаторлар һәм терлекчеләр бер үк вакытта балта осталары, итек басучылар, шәл бәйләүчеләр дә.

Купка авылында, әйтик, менә шундый уңганнар, һич арттыру түгел, һәр йортта. Сәүдә предприятиесенә җитәкчелек итүче Миңнегаяз Мөсәгыйтов та (тышлыкның 2 нче битендәге рәсемдә) буш вакыты булдымы,— кулына нәкыш ясау коралларын ала. Гомумән, йорт-җирен, каралты-курасын һәркем үзе теләгәнчә матурлый, бизәкли.

Авылны ташлап, чит җирләргә чыгып китүчеләрнең бөтенләй диярлек булмавы бәлки, шуңадыр да?! Иөрәк җылысын кушып җиткергән йортны кем инде ташлап китсен ди?! Һәм һәр йортка ел саен диярлек булачак хуҗалар өсталеп тора. Утыз яшен дә тутырмаган Рәхимә Иосыфҗанова, мәсәлән, биш бала анасы. Эльмира, Эльвира һәм Илшат — игезәкләр.

Һәркемнең уңганлыгы, тырышлыгы белән колхоз экономикасы елдан-ел ныгый. Ә уңганнар бик күп. Нургали Сафин, сарык ка-



рауда эшләп тирән ихтирам казанды.

«Коммунизмга» колхозында яшәүчеләр партиянең XXVII съезды карарларын үтәүдә, ил табынын тагын да мулрак итүдә туган җир җылысын тоеп, аннан көч һәм илһам алып армый-талмый хезмәт итәләр.



**Риф ЯКУПОВ** фотолары.
Габделбәр **РИЗВАНОВ** тексты.



**Нурихан Фәттах**

# ФЕСТ ДИСБЕСЕНЕҢ СЕРЕ

## 1. Кереш

Крит утравына урнашкан Фест шәһәре янындагы борынгы сарай калдыкларын казыганда, 1908 елның 3 июлендә, итальян археологы Л. Пернье эшчеләре сарайның төньяк-көнбатыш өлешендә түгәрәк такта (диск) табалар. Кызыл балчыктан изеп, әвәләп ясалган тактаның диаметры 158-165 мм, калынлыгы 16-21 мм. Аның ике ягына да ниндидер рәсемнәр, билгеләр төшерелгән була. Әлеге түгәрәк такта табылган Фест сарае безнең эрага кадәр 1600 елларда җимерелгән дип исәпләнелә. Димәк, түгәрәк такта да шул чорларда эшләнгән булып чыга. Дөрес, аның сарай җимерелгәнчегә кадәр бик күп еллар элегрәк ясалган булуы да ихтимал. Шулай да түгәрәкнең барлыкка килү датасын һәркайда диярлек б. э. к. 1600 еллар дип күрсәтәләр. Икенче төрле итеп әйткәндә, бу серле балчык кисәге моннан, түгәрәкләп әйткәндә, 3600 еллар элек иҗат ителгән диган сүз. Хәзерге көндә Фест түгәрәге Крит утравының башкаласы Ираклейон шәһәре музеенда саклана.

Түгәрәкнең һәр ике ягына спираль сыман итеп сызыклар сызылган. Янәшә сузылган ике сызыкка кыска-кыска гына аркылы сызыклар төшерелгән. Шул рәвешчә, тигез булмаган озынча шакмаклар барлыкка килгән. Һәрбер шакмакка кеше, кош, балык, балта һ. б. ш. рәсемнәр ясалган. Дискының ике ягында да 45 төрдәге 242 рәсем-билге исәпләнелә.

Фест түгәрәгенең уң ягында 31, сул ягында 30 шакмак бар. Рәсемнәр яндырылмаган кызыл балчыкка алдан әзерләнгән агач яисә металл штамплар ярдәмендә төшерелгән. Бу рәсем-билгеләрне дөньяда штамп ярдәмендә басылган иң беренче язу үрнәге дип исәплиләр. Хәзерге типография шрифтлары сыман штамп куллану нәтиҗәсендә, балчыктагы рәсемнәр тигез, ачык һәм матур булып чыккан. Штамп куллану мондый язулы түгәрәкнең үз заманында күпләп җитештерелүе ихтималы турында да сөйли.

Фест түгәрәге табылган көннән башлап бик күп галимнәр аның серенә төшенергә тырышып караганнар. Ләкин әлегә кадәр ул укылмаган килеш кала бирә. Бу түгәрәк балчык кисәге кинәт сөйли башласа, күпме сер, күпме яңалык ачылыр иде дөнья тарихы өчен! Фест язуын укуның әһәмиятен тулырак итеп күз алдына китерү өчен бу хакта әйтелгән кайбер фикерләрне искә төшереп үтик. «Бу язуны уку безнең кулдан килә торган эш түгел»,— ди инглиз галиме Дж. Чедуик (43, 94)[1]. Икенче бер инглиз галиме Дж. Пендлбери бу хакта сүз кузгатып торуны да кирәксез саный. «Бу текстны укырга тырышып караулар турында эндәшми калу дөресрәк булыр»,— ди Пендлбери (67, 191).

Түгәрәктәге рәсемнәргә игътибар беләнрәк күз йөртеп чыксаң, бер дә анда баш җитмәслек нәрсәләр юк сыман. Әнә чүлмәк, әнә кош, балта, калкан... Берсе әнә кулын күтәреп йөгереп бара, берсенең кулы бәйле. Бүгенге газеталарда, журналларда да шундыйрак рәсемнәр белән төзелгән һәртөрле ребуслар, башваткычлар тәкъдим ителә. Беркадәр уйланып утырса, андый

---

[1] Файдаланылган хезмәтләрнең тулы исемлеге мәкалә азагында бирелә. Җәя эчендәге беренче сан хезмәтнең исемлектәге тәртип урынын, өтердән соңгы саннар бит номерын, рим цифрлары — китапның ничәнче том икәнлеген күрсәтә. Бит саны урынына кайбер очракта таблица саны күрсәтелә.

башваткычларны теләсә кем чишә ала. Ә менә бу «ребус»ны хәтта атаклы галимнәргә дә чишү авыр.

Сәбәп нидә соң? Иң беренче сәбәп шул: Фест түгәрәгендәге язуның нинди телдә булуы билгеле түгел. Бит бүгенге ребус-башваткычлар, нинди газета-журналда басылган булса, шул газета-журнал телендә төзелгән була.

Фест түгәрәгенең әле булса укылмавының икенче сәбәбе дә бар. Серле язуны башлыча һинд-европа һәм семит телләре белгечләре «укыганнар» һәм, әлбәттә, «ачкыч»ны да алар үзләре яхшы белгән тел законнарына нигезләнеп эзләгәннәр.

Түгәрәк балчык кисәгендәге серле башваткычны мин төрки телләр ярдәмендә укып карамакчы булдым. Шакмакларга урнаштырылган рәсем-билгеләрне төрки исемнәр белән атадым, кайбер очракта мәгънәсе билгесез рәсемнәрне башка язу системаларындагы мәгънәсе билгеле рәсем-билгеләр белән чагыштырдым. Шул рәвешчә, һәр рәсем-билге аңлаткан «хәреф» билгеле булды. «Ачкыч» шулай табылды.

Ләкин мәсьәләнең үтә җитдилеген истә тотып, уку («сөйләшү») эшен мин бик ерактан һәм бик тирәннән башладым. Уку — бер нәрсә, укылган сүзләргә тиешле фәнни аңлатма бирү — икенче нәрсә. Урта диңгезнең көнчыгышындагы Крит утравында моннан 3—4 мең еллар элек төрки телдәге язу каян, ничек барлыкка килгән? Бит төркиләрнең баба ватаны Көнбатышта түгел, Көнчыгышта булган дип исәпләнелә. Крит утравына алар Көнчыгыштан барып чыкканнармы, әллә, киресенчә, Көнчыгышка Көнбатыштан килгәннәрме? Бик борынгы заманнарда Крит кешесенең аңы, тормыш-көнкүреше, белеме, шөгыле һәм дини карашлары ничегрәк булган? Менә бер мисал. Фест язуының уңнан сулга таба укылырга тиешлеген галимнәр күптән исбат иткәннәр. Ләкин алар моңа формаль күзәтү, башка язулар белән чагыштыру һәм логик фикерләү нәтиҗәсендә ирешкәннәр. Мәсәлән, Алессандро делла Сета шундый нәрсәгә игътибар иткән: балчыкка төшерелгән рәсемнәрнең сул ягы тирәнрәк баткан, уң ягы калкурак булып чыккан икән. Димәк, борынгы кеше штампларны сул кулы белән тотып эшләгән. Болай аңа җайлы булган, чөнки ул рәсемнәрне уңнан сулга таба төшерә барган (57, 57). Борынгы карашлар буенча, уң як Ата һәм ирләр ягы исәпләнелә. Барлык эш-хәрәкәт Атага һәм иргә хас дип уйланыла. Димәк, уку «хәрәкәте» дә бары уңнан гына башланырга тиеш. (Бу мәсьәләгә без алда киңрәк тукталырбыз.)

Шулай итеп, минем төркичә «сөйләшүнең» дөресме-түгелме икәнлеген һәрбер укучы үзе тикшереп карый алачак. Турыдан-туры серне чишә башлаганчы мин кайбер белешмәләр һәм аңлатмалар биреп китәргә тиешмен.



Язучы Нурихан Фәттах 1928 елда БАССРның Яңавыл районы Кучтавыл авылында туа. Яңавыл урта мәктәбен тәмамлагач, 1946—1951 елларда Н. Фәттах Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый. Татарстан китап нәшриятында, аннары Чистайда газета редакциясендә эшли.

1948 елда «Безнең хикәяләр» дип аталган җыентыкта язучының «Утлар» исемле беренче хикәясе басыла. Н. Фәттах «Сезнеңчә ничек?», «Бала күңеле далада» романнары, «Мәдир Саҗидә» повесте һәм берничә хикәя китаплары авторы. 1973 елда Татар дәүләт академия театрында аның «Кол Гали», 1986 елда Әлмәт театрында «Сармат кызы Сәринә» дигән трагедияләре куелды. 1973 елда Казан курчак театрында «Энҗеле үрдәк» пьесасы буенча тамаша күрсәтелде.

Гомеренең күп өлешен язучы татар халкының телен, тарихын, фольклорын һәм этнографиясен өйрәнүгә багышлый. Ул «Этил суы ака торур» һәм «Сызгыра торган уклар» исемле тарихи романнар язды.

## 2. Фест язуын өйрәнүнең кыскача тарихы

Түгәрәктәге язуны уку өчен галимнәр төрле метод кулланып караганнар. Кайберәүләр, мәсәлән, иконография методын артыграк күргәннәр. Бу метод белән эш иткәндә билгесез язудагы рәсем-билгеләр билгеле булган

икенче төрле язу билгеләре-рәсемнәре белән чагыштырып карала. Шулай итеп, билгесез язудагы рәсем-билгеләрнең мәгънәсе табыла. 1911 елда ук инде А. Кюни Фест түгәрәгендәге рәсем-билгеләрне борынгы Мисыр иероглифлары белән чагыштырып укырга тырышкан. Р. Макалистр һәм К. Еппесен дигән галимнәр Фест язуын борынгы Мисыр культурасына якын булган ниндидер Төньяк Африка культурасы язуларына охшаш дип исәпләгәннәр (57, 45).

Фест язуын укуда статистик һәм акрофоник методлар белән эш итүчеләр дә булган. Акрофоник метод кулланганда мәгънәсе билгесез булган язудагы рәсемнәр нинди дә булса мәгълүм тел нигезендә исемләнә һәм шул исемнең беренче авазы яисә иҗеге билгесез язудагы рәсем-билгене чагылдыра торган аваз буларак кабул ителә. 1911 елда Дж. Хемпль дигән галим, Кипр иҗекле язуына нигезләнеп, Фест түгәрәген грекча укымакчы булып карый. Фест язуында сүз башында еш кабатлана торган кайбер рәсем-билгеләрне ул А һәм Е сузыклары булырга тиеш дип исәпли, чөнки грек телендә дә сүз башында А һәм Е сузыклары ешрак кабатлана икән. (57, 46—47). Дж. Хемпль фикеренчә, Фест түгәрәгендә Кече Азиянең көньяк-көнбатыш ярына урнашкан Ксифо гыйбадәтханәсен грек пиратының талавы турында сүз бара, имеш.

1955 елда Эрнест Зиттиг дигән галим, статистик һәм акрофоник методлар кулланып, Фест язуын шулай ук грекча укымакчы булып карый. Түгәрәкнең бер ягына ул: җир биләмәләрен өләшү турындагы сүзләр, икенче ягына — күмү йоласына һәм чәчү бәйрәменә кагылышлы үгет-нәсихәт сүзләре язылган дип исәпли (57, 48).

Америка галиме Сайрус Гордон 60 елларда, акрофоник метод кулланып, Фест язуын семит телендә «укый». 1948 елда грек галиме Л. Ктистопулос та, статистик метод нигезендә, әлеге язуны семит телендә укырга тырышып караган (57, 48).

1948 елда немец галиме Эрнест Шертель, шулай ук статистик методка таянып, түгәрәк балчык кисәгенә латин теленә якын ниндидер һинд-европа телендә Зевска һәм Минотаврга гимн сүзләре язылган дигән фикергә килә (57, 48). Артур Эванс Фест түгәрәгендәге рәсемнәрнең мәгънәсен бөтенләй үзенчә аңлата. Түгәрәктәге сугышчы һәм сугыш кирәк-ярагы рәсемнәренең күплегенә нигезләнеп, Эванс монда җиңү гимны турында сүз бара ахрысы дип исәпли (57, 51).

Француз атлантологы Марсель Омэ түгәрәктә Атлантиданың һәлакәте тасвирлана дип уйлый. Инглиз Ф. Гордон Фест язуын баск телендә язылган булырга мөмкин дип исәпли (57, 52).

1929 елда Г. Ипсен немецча чыга торган «Индогерманише форшунген» дип аталган фәнни журналда үзенең В. Порциг белән бергә эзерләнгән мәкаләсен бастыра. Мәкаләдә Фест түгәрәгенә җентекле формаль анализ ясала. Авторлар, комбинатор методы кулланып, түгәрәкнең теле ниндидер флектив тел булырга тиеш дигән нәтиҗәгә килөләр. Әлеге флектив телдә алар префикслар, суффикслар бар дип исәплиләр. Фест язуында еш кабатлана торган «сугышчы» (таблицада 2) рәсемен алар детерминатив[2] булырга тиеш дип уйлыйлар. Г. Ипсеннең бу мәкаләсе бүгенге көндә дә Фест язуы турындагы иң җитди, төпле һәм җентекле хезмәтләрнең берсе санала (34, 32—65; 57, 59).

Совет галиме А. А. Молчанов та Фест язуын дөрес уку өчен бары тик комбинатор методы гына ышанычлы дип исәпли (57, 52).

Фест язуын өйрәнүдә Л. Пернье, А. делла Сета, Г. Ипсен, В. Порциг, Э. Грумах, Г. Нойман, В. Нам, С. Маринатос, К. Даварас, А. Эванс, А. Маккей, А. М. Кондратов, В. П. Назаров үзләреннән өлеш кертkәннәр (57, 60). Бу исемлеккә А. А. Молчановны да өстәргә була.

Монда шулай ук Болгария галиме Владимир И. Георгиевны да телгә алырга кирәк. В. Георгиев язганча, Фест түгәрәге турында йөздән артык фәнни хезмәт бастырылган һәм йөздән артык кеше аның серле язуын үзенчә укып, үз аңлатмаларын тәкъдим итеп караган (17, 52). (Югарыда без шуларның кайберләре белән танышып киттек). В. Георгиев үзе дә Фест язуын укып

---

[2] Детерминатив дип аталган билге үз янындагы сүзнең нинди категориягә каравын күрсәтә. Детерминатив билгесе авазны чагылдырмый һәм сүзне укуда катнашмый. Мәсәлән, шумер язуында алла исемнәре янына — «дингир» (алла), агач һәм агач әйберләр янына — «гиш» (агач) билгеләре куелган (106, 67).

карый. Ул Фест түгәрәген борынгы һинд-европа телләренә караган луви телендә язылган дип исәпли. Аныңча, әлеге балчык кисәгенә Кече Азиянең көньяк-көнбатышында булган тарихи вакыйгалар турында рапорт урнаштырылган (17, 52—60). В. Георгиев язуны сулдан уңга таба укый.

Г. Гриневич Фест язуын борынгы славян телендә язылган дигән фикергә килә. Ләкин ул да, Болгария галиме кебек, укуны сулдан башлый (72, 4).



## 3. Крит цивилизациясе турында кыскача белешмә

Крит утравында бик күптәннән бирле греклар яшәгән. Борынгы Грециягә, борынгы грекларны дөньяда белмәгән кеше юктыр дисәк, һич тә ялгыш булмас. Җырда-музыкада, сәнгатьтә, әдәбиятта, дин һәм мифологиядә, архитектурада, медицинада, философиядә һәм гомумән фәндә, җәмгыять тормышында һәм спортта — һәркайда, һәрнәрсәдә «борынгы Греция», «борынгы греклар» белән очрашасың.

«Европаның барлык сәнгате киң мәгънәдә үзенең тамырлары белән грек традициясенә барып тоташа: Европа художниклары, язучылары, фикер ияләре ирешкән барлык нәрсәдә антик дөньяның зур булмаган бер халкы ирешкән искиткеч уңышларның тирән йогынтысы чагыла», дип яза Дж. Чедуик (113, 234).

XX гасырда тарих-археология өлкәсендә зур ачышлар ясала. Зур ачышларның берсе Крит утравында була. 1900 елда инглиз галиме Артур Эванс Криттә археологик казу эшләре башлап җибәрә. Утрауның төньягына урнашкан Кнос шәһәре янында, Юктас тавы итәгендә ул бик зур сарай калдыклары таба. Исәпсез-хисапсыз бүлмәләре, коридорлары, баскычлары, кабул итү заллары, җир асты төрмәләре, су үткәрү торбалары, бассейннары, ванналары, канализациясе булган искиткеч сарай калдыкларын күреп, Артур Эванс таң кала. Залларда, бүлмәләрдә, амбарларда өем-өем савыт-саба, эш, сугыш кораллары, җиздән-бакырдан, алтын-көмештән, таштан-балчыктан ясалган бик күп төрле борынгы әйберләр табыла. Стеналарда төрле төстәге буяулар белән ясалган бизәкләр, сюжетлы күренешләр, кеше, хайван, кош, балык сурәтләре була. Ике яисә өч катлы булган булырга тиеш дип исәпләнелгән бу сарайның гомуми мәйданы 16 мең квадрат метр тәшкил итә (51, 406, 409).

Эванс казып чыгарган бу сарайны Кнос сарае дип тә, Лабиринт дип тә йөртәләр. Артур Эванс һәм аның шәкертләре Крит утравының Фест, Маллия, Гурния һ. б. шәһәрләрендә дә һәм шулай ук Эгей диңгезенең башка утрауларында да күп санлы борынгы торак, шәһәр, авыл калдыкларын казып чыгаралар.

Шул рәвешчә, борынгы Греция территориясендә (утрауларда) борынгы греклардан да элегрәк яшәгән, моңарчы тарихта бөтенләй билгеле булмаган һәм ниндидер сәбәпләр аркасында юкка чыккан халыкның бөек культурасы ачыла. Бу культураны фәнни әдәбиятта Крит (Миной) культурасы, Крит (Миной) цивилизациясе яки Эгей культурасы (цивилизациясе) дип йөртәләр.

Крит культурасын Эванс өч чорга бүлеп карый. Иң борынгы чор б.э.к. 3000—2000 елларга, соңгы чоры 1600—1100 елларга туры килә. Димәк, Крит цивилизациясенең иң әүвәлге чоры моннан 5 мең еллар элек башланган була. Бу исә Крит культурасы Шумер һәм Мисыр культуралары белән бер үк вакытларда диярлек барлыкка килгән һәм бер үк вакытларда диярлек яшәгән дигән сүз.

«Крит цивилизациясе грек цивилизациясеннән чагыштырмас дәрәҗәдә борынгырак. Хәтта Соңгы бронза чорында да Крит культурасы классик Греция культурасыннан югарырак була. Легендаларда Афина шәһәренең Крит патшасы Миноска буйсынган булуы турында әйтелә. Анда грекларның котын алып торган башка халык яшәгән» (113, 119—120), дип яза Чедуик.

«Моңа кадәр камиллекнең идеалы исәпләнелгән һәм барлык буын художниклары өчен классик үрнәк булып хезмәт иткән грек сәнгате Урта диңгез буенда үзеннән 2000—1000 елларга элегрәк барлыкка килгән искиткеч дәрәҗәдәге бөек культураның дәвамы гына булып чыга» (76, 134), дип яза совет галиме И. А. Резанов.

Кайчан һәм нилектән юкка чыккан соң Крит культурасы? Бу сорауга җавап эзләп без Платон тасвирлаган Атлантидага мөрәҗәгать итәбез.

## 4. Платон һәм Атлантида

Б.э.к. 427—347 елларда яшәгән грек философы Платон «Тимей» һәм «Крити» дип аталган диалогларында ниндидер серле утраудагы серле Атлантида дәүләте булуы турында язып калдырган. Атлантида турындагы хикәяне грекларга иң элек Солон исемле гыйлем иясе сөйләгән. Солон үзе Платоннан ике йөз ел элек — б.э.к. 640—559 елларда яшәгән. Атлантида турындагы хәбәрне ул Мисырда ишетеп кайта. Мисыр гыйбадәтханәләрендәге дин әһелләре аңа борынгы язмаларда әйтелгән нәрсәләрне сөйлиләр. Солонның нәселен дәвам иттерүчеләр аның гаҗәеп хикәясен буыннан-буынга тапшыра киләләр. Платон шул Солон нәселенең бер кешесе була. Платон диалоглары аша Атлантида турындагы хәбәр бөтен дөньяга тарала.

Платонның әйтүенә караганда, Атлантида Геракл баганалары, ягъни Гибралтар бугазы каршында, Атлантик океанда булган. Аның территориясе Ливия (Төньяк Африка) һәм Кече Азия территорияләреннән дә зуррак булган, имеш. Иҗтимагый үсеше, экономикасы һәм культурасы ягыннан Атлантида дөньяда иң алдынгы ил була. Атлантидада көчле патшалар хакимлек итә.

Атлантида дип аталган дәүләтнең башкаласы Атлантида утравына урнашкан. Утраудагы үзән уртасында изге калкулык була. Калкулыкта, имеш, дөньядагы иң беренче кешеләр яшәгән. Әлеге ирле-хатынлы кешеләрнең Клейто исемле кызлары була. Кыз үсеп буйга җиткәч, атасы-анасы үлеп китә. Ятимә кызга диңгез алласы Посейдон гашыйк була. Клейтоның Посейдоннан биш игезәк ир баласы туа. Посейдон ун улын да тәрбияләп үстерә һәм утрауны унга бүлеп, балаларына бирә. Баш баласын диңгез алласы башка барлык балалары өстеннән хаким итеп куя (71, 553).

Посейдон калкулык тирәсен тәртипкә китерә. Моның өчен ул калкулыкны су һәм җир (туфрак, балчык, таш) боҗралар белән әйләндереп ала. Җир боҗра ике, су боҗрасы өч була. Шулай итеп, изге калкулык боҗралар уртасында торып кала. Монда ике чишмә агып чыга. Чишмәләрнең берсе салкын сулы, икенчесе кайнар сулы була.

Калкулыкта патша сарайлары, гыйбадәтханәләр төзелә. Аллага багышланган гыйбадәтханә алтын койма белән әйләндереп алына. Һәркайда — алтын да көмеш, кыйммәтле ташлар... Гыйбадәтханә эчендә алтыннан коелган сыннар: канатлы алты ат җигелгән арбада, кулына дилбегә тотып, алла бара; шунда ук башка сыннар, һәйкәлләр. Гыйбадәтханәнең тышкы ягында ун изге патша хатыннарының һәм алар нәселенең алтын сыннары куелган була (71, 555—556).

Гыйбадәтханә эчендә орихалк (таш? металл?) баганага аллалар сүзе — һәртөрле законнар, кагыйдәләр язылган була (71, 558).

Биш-алты елга бер мәртәбә ун патша, шушы бинага җыелып, дәүләт күләмендәге эшләрне тикшерәләр. Берәр патша гаеп эш эшләсә, аны хөкем итәләр. Хөкем алдыннан, иректә йөргән үгезне тотып, аны язулы таш янында чалалар. «Әлеге ташта законнардан башка тагын законны бозган кешегә бәла-каза килүен теләгән каргыш сүзләре дә була. Үз кагыйдәләре буенча корбан биргәч, алар, бер савытка шәраб салып, аны сыеклыйлар; һәркем шәрабкә оешкан үгез каны сала, аның калганын утка ташлыйлар һәм язулы ташны бик яхшылап чистарталар. Шуннан соң савыттан һәркем алтын касә белән шәраб ала, шәрабнең беразын утка корбан итеп бирә, һәм алар, язулы таштагы закон буенча хөкем итәрбез дип, законны бозган кешене җәзаларбыз дип, ант бирәләр» (71, 559), дип яза Платон.

«Үзләре өчен, ата-бабаларының бөтен нәселе өчен шундый ант сүзләре әйтеп, аларның һәркайсы шәрабне эчә дә, касәне аллага багышланган гыйбадәтханәнең тиешле урынына илтеп куя» (71, 559).

## 5. Крит цивилизациясе һәм Атлантида

Атлантида булганмы, әллә булмаганмы? Булса, кайда булган? Кайчан булган? Ике мең елдан артык инде күп кенә фикер ияләре менә шул хакта бәхәс алып баралар. Шушы вакыт эчендә Атлантидага кагылышлы 25 мең

том китап язылган. Ул китапларның кайберләренең калынлыгы 500 биттән артып китә икән (33,9).

Атлантида утравы, Платон әйткәнчә, һәлакәтле бер көн һәм бер төн эчендә диңгезгә батып юкка чыккан. Бу хәл, имеш, Солон заманыннан алып исәпләгәндә, 9000 еллар элек булган. Бүгенге чордан алып исәпләгәндә, бу моннан 12 мең еллар элек булган булып чыга. Ләкин, тарихтан билгеле булганча, моннан 12 мең еллар элек дөньяда Атлантида кешеләре ирешкән дәрәҗәдәге бер генә халык та булмый.

Артур Эвансның Крит утравындагы ачышлары Атлантида мәсьәләсенә яңача карарга мөмкинлек бирә.

Тикшерә торгач, Урта диңгезнең көнчыгыш өлешендә урнашкан утрауларның борын-борыннан геологик яктан тынгысыз һәм тотрыксыз булуы ачыклана. Крит утравында һәм Критка якын урнашкан бүтән утрауларда җир тетрәүләр, вулкан атылулар һәм «җир йотулар» була һәм булганда да бик көчле була икән.

Бүгенге көн галимнәре Эгей диңгезе бассейнында берничә мәртәбә көчле җир тетрәү булуын һәм шуның нәтиҗәсендә борынгы сарайларның җимерелүен, җимерелгәннән соң яңадан торгызылуын ачыклаганнар. Мәсәлән, б.э.к. 1700—1500 елларда шундый көчле җир тетрәү була. Кностагы, Фесттәге, Маллиядәге сарайлар һәм башка утраулардагы күп кенә биналар шул чорда җимерелә һәм яңадан торгызыла (67, 165; 76, 86; 5, 106). Ачлык һәм мал-туар кырылу аркасында Крит утравының өч мәртәбә бушап калуы һәм элекке халыклар урынына утрауга башка халыклар күчеп утыруы турында күренекле тарихчы Геродот та яза (18, VII, 171).

Б.э.к. XV гасырда тагын бер җир тетрәү һәм көчле вулкан атылу була һәм Крит цивилизациясе тәмам юкка чыга. «Б.э.к. 1450—1400 еллар арасында күпмедер вакыт эчендә Крит утравындагы барлык шәһәрләр, шул исәптән Кнос шәһәре дә ут тарафыннан юк ителә» (96, 372), ди инглиз галиме Дж. Томсон. «Д. Никонович һәм Б. Хейзен исәпләвенчә, Миной чоры Крит цивилизациясенең җимерелүе, Мисыр хронологиясенә ярашлы рәвештә, б.э.к. 1450—1375 елларда була» (76, 108), ди И. А. Резанов. «Стихия бәла-казасы Миной цивилизациясен юкка чыгарган вакытта Кнос дәүләте үз куәтенең иң югары дәрәҗәсенә ирешкән була» (57, 18) ди А. А. Молчанов. «Күп кенә археологлар, геологлар һәм океанологлар фикеренчә, Эгей диңгезендә б.э.к. 11 мең еллыкның урталарында булган Санторин вулканы атылуы нәтиҗәсендә, Урта диңгездәге бөек мәмләкәт юкка чыга; бу мәмләкәтнең үзәге Крит утравында — Европаның иң борынгы цивилизация бишегендә була» (42, 114), ди А. Кондратов.

Вулкан атылуның энергиясен билгеле бер куәттәге атом бомбасы эквивалентына тигезләп исәплиләр. П. Хейдевари буенча, бер атом бомбасының энергиясе $8{,}4 \cdot 10^{14}$ Дж тәшкил итә (76, 77). 1883 елда Индонезиядә, Кракатау утравында атылган вулканның атом бомбасы эквиваленты 20.000 берәмлеккә тигез. 1815 елда Индонезиядә, Сумбава утравында атылган Тамбора вулканының эквиваленты 200.000 берәмлек тәшкил итә, ягъни бу әлеге вулкан атылганда җир астыннан чыга торган энергия ике йөз мең (!) атом бомбасы шартлаганда барлыкка килә торган энергиягә тигез дигән сүз.

Крит дәүләтен юкка чыгарган Санторин вулканының атылу энергиясе Тамбора вулканы энергиясеннән көчлерәк булган дип уйланыла. «Шул рәвешчә, б.э.к. XV гасырда булган Санторин вулканы иң зур геологик һәлакәтләрнең берсе исәпләнелә» (76, 79), ди геолог И. А. Резанов.

Моның чыннан да шулай икәнлеген күрсәтү өчен бер-ике мисал китерү дә җитә. Мәсәлән, вулкан атканда җир астыннан чыга торган көл 50 километр биеклеккә күтәрелә ала. Санторин вулканының көле мең километр ераклыкка таралган. Бүгенге көн галимнәре диңгез төбеннән алган грунт үрнәкләре күрсәткәнчә, Санторин утравыннан 130 километр көньяк-көнчыгышта 212 см калынлыктагы көл катламы утырган булган. Крит утравыннан төньяк-көнчыгышта, ягъни 212 см ноктасыннан көньяк-көнбатыш ноктада көл катламы 78 см булган (76, 64, рәсем 13, карта).

Вулкан атылыр алдыннан Санторин утравында бик зур шәһәр булган. Утрауда археологик казулар үткәрелә, һәм монда да Крит утравындагы кебек сарай табыла (12, 40). Санторинда Грециянең Афина шәһәре университеты галимнәре бер, ике, өч катлы биналар, Миной чоры һөнәрчеләре ясаган бик күп санлы әйберләр, йорт кирәк-яраклары табалар (10, 32). Шәһәрдә 30 мең чамасы кеше яшәгән дип уйланыла. Шәһәрнең төньяк өлеше юкка чыга, көньяк өлешен көл-туфрак күмеп китә. Бүгенге көндә Санторин утравы-

ның вулканнан соң торып калган вак кисәкләрендә — Тира, Тирасия, Аспрониси утрауларында вулкан көленең — тефраның калынлыгы 30—40 метрга җитә (76, 124; 15, 93).

Санторин утравында вулкан көле астында күмелеп калган борынгы шәһәрдә үлгән кеше калдыклары табылмый. Бу исә кешеләрнең вулкан атылып, шәһәр җимерелгәнче качып котылулары турында сөйли.

Б.э.к. XV гасырда көчле вулкан атылу нәтиҗәсендә юкка чыккан Крит цивилизациясен Платон тасвирлаган Атлантида булырга тиеш дип исәплиләр (76, 128—133; 57, 19; 15, 101—132). Дөрес, Платон әйткән нәрсәләр белән Крит культурасы фактлары һәр очракта да туры килеп бетми. Мәсәлән, Атлантиданың юкка чыгуын Платон Солонга кадәр 9000 ел элек булган ди. Ләкин аның яисә башкаларның бер «нульгә» ялгышкан булулары да бик мөмкин. 9000 санын 900 дип исәпләсәк, чама белән Санторин вулканы аткан еллар барлыкка киләчәк. (Солон б.э.к. 600 еллар элек яшәгән. Вулкан атылу Солоннан 900 еллар элек булган булса, Крит яки Атлантида дәүләтенең юкка чыгуы б.э.к. 1500 елларда булган була).

Крит утравындагы Фест шәһәре янында табылган серле балчык кисәгенең («Фест дискысы»ның) тарихи җирлеге кыскача менә шуннан гыйбарәт.

## 6. Бик борынгы кешенең «тормыш фәлсәфәсе»

Фест түгәрәген иҗат итүчеләр, шулай итеп, бик ерак чорларда яшәгәннәр. Аларның тормыш, көнкүреш шартлары, дөньяга карашлары, аң дәрәҗәләре, әлбәттә, безнең бүгенге тормыш, көнкүреш шартларыннан, безнең карашлардан, безнең аң дәрәҗәсеннән үзгәрәк булган.

Бездән берничә мең еллар элегрәк яшәгән кешеләрнең тормышын, аңын, карашларын өйрәнгәндә бүгенге заман тикшеренүчесе, барыннан да элек, әүвәлге заман кешесенең күңеленә «үтеп керергә» һәм, әлбәттә, үзенең бүгенге кеше икәнлеген дә онытмаган хәлдә, элекке заман күренешләрен дөрес аңлата белергә тиеш. Бу шактый кыен нәрсә. Чөнки моннан мең, миллион еллар элек яшәгән кешенең аңын, дөньяга карашын һәр очракта дөрес итеп күз алдына китерү мөмкин түгел. Бит шуңа күрә дә фән дөньясында кешене өйрәнүгә кагылышлы мәсьәләләрдә бертуктаусыз бәхәсләр дәвам итә. Иң кыены шунда: бәхәс алып бару өчен күп вакытта ышанычлы фактлар җитеп бетми.

Кешегә кагылышлы фактларның берсе һәм иң әһәмиятлесе — тел. Бүгенге кеше үзенең аң үсеше ягыннан элекке кешедән әйтеп бетергесез дәрәҗәдә өстен торса да, кыргый кеше иҗат иткән телнең килеп чыгышы, телнең төзелеше, телләрнең төрлелеге, үзара туганлыгы һ.б. мәсьәләләр турында әлегә кадәр төрле фикерләр яшәп килә.

Билгеле булганча, кешенең маймылдан аерылып, «кеше»гә әверелүе моннан 4—5 миллион еллар элек булган дип уйланыла. Биологик яктан барлык раса кешеләре бертуган. Бәс, шулай икән, димәк, кешенең бик борынгы карашлары да һәм шулай ук аңлы тавыш сигналлары да бер үк төрле булган булырга тиеш. Атаклы инглиз этнографы Дж. Фрезер җир йөзендәге бик күп халыкларның төрле йолаларын, гореф-гадәтләрен, дини карашларын тикшергәч, «үзенең иң әүвәлге һәм бик үк җитлекмәгән тормыш фәлсәфәсен булдырганда төрле илләрдә һәм төрле гасырларда кешенең рухи дөньясы (кайбер әһәмиятсез тайпылышларны исәпкә алмаганда), искиткеч дәрәҗәдә бер төсле булган» (105, 8) дигән нәтиҗәгә килгән.

Борынгы кешенең ышануынча, дөньяны, тормышны, кешене, җирдәге барлык җанлы-җансызны аллалар тудырган. Беренче кешенең беренче анасы — Җир, атасы — Күк яисә Су. Кайбер халыклар (мәсәлән, кытайлар) үзләрен Җир һәм Күк улы дип, кайберләре (мәсәлән, төркиләр) — Җир һәм Су уллары дип исәплиләр. Күпчелек халыкларда кеше — Җир улы. Җирдәге таулар, ташлар, чокыр-чакырлар, урманнар, куаклы агачлар, үләннәр, кайбер хайваннар һәм кайбер казылма байлыклар (мәсәлән, тимер) Җир улы исәпләнелә. Оча торган кошлар, бөҗәкләр, җил-болыт, кайбер хайваннар (мәсәлән, үгез, бүре), озын кәүсәле агачлар, төсле металлар — Күк улы, балыклар, су хайваннары, су үсемлекләре Су улы санала.

Җир үзе Су яки Күк улы (хатыны), Су һәм Күк — Җир улы (ире) буларак аңлашыла.

Кеше кулы белән ясалган барлык әйберләр ике төргә: Җир улы төренә һәм Су-Күк улы төренә бүленә. Монда шуны да онытмаска кирәк: Җир — Анага, Хатын-кызга, Су һәм Күк — Атага, Ир кешегә тиңләштерелә. Шуңа күрә, кеше кулы белән ясалган әйберләр Ана улы һәм Ата улы төрләренә бүленә. Озын һәм хәрәкәтчән әйберләр барысы да Ата уллары, савыт-саба, хәрәкәтсез һәм куыш әйберләр — Ана уллары дип уйланыла.

Күк җисемнәреннән Кояш — Җир һәм Күк улы. Ләкин чынлыкта Кояш ике җенесле. Күктәге Кояш — Ата улы, Җир куенындагы (төнге) Кояш — Ана улы, Җир улы. Айга караш төрлечә. Айны кайбер халыклар Кояш улы, Кояшның төнге «варианты» дип, кайберәүләр Күк улы дип беләләр.

Иң кызыгы шунда: дөньяны тудыручы аллаларның барысы да елан кыяфәтле. Төрле халыкларның мифларында, дини ышануларында, фольклорында һәм сәнгатендә сакланып калган карашлар буенча, Җир — елан, Күк — елан, Су — елан. Ай, кояш, җил, буран — барысы да елан. Изге һәм явыз аллалар, һәртөрле иятәр һәм рухлар — елан. Иң беренче ата-анасы елан булгач, кеше үзе дә елан нәселеннән. Татар әкиятләрендә, мәсәлән, еш кына хатын-кыз юха еланга әверелә.

Бик борынгы карашлар буенча, Су-Күк, Ата, Ир — һәрвакыт өстә һәм беренче урында, Җир, Ана, Хатын-кыз — һәрвакыт аста һәм икенче урында. Шунлыктан барлык уңай сыйфатлар Суга — Күккә, Атага, Иргә хас дип, барлык кире сыйфатлар Җиргә, Анага, Хатын-кызга хас дип уйланыла.

## 7. Телне өйрәнүдә иҗек методы һәм сүзнең төзелеше турында кыскача белешмә

Иң беренче мәгънәле сүзләр дөньядагы барлык телләрдә бер иҗектән генә торган. Бер иҗекле тулы мәгънәле сүзләр бүгенге телләрдә дә очрый. Мәсәлән, татар телендәге СУ, БУ кебек сүзләр. Ләкин, мәгълүм булганча, бер иҗеклеләрнең АТ, ЭТ кебекләре дә актив кулланыла. Иң әүвәлге тулы мәгънәле сүз тартык — сузык (ТС) рәвешендәге иҗектән гыйбарәт. Шунлыктан АТ, ЭТ рәвешендәге кыска сүзләр А — Т, Э — Т дип бүленә һәм ике иҗекле дип исәпләнелә. Сүзнең иң гади күзәнәге СУ, БУ рәвешендәге тартык-сузыктан торган иҗек булгач, А — Т, Э — Т рәвешендәге сүзләрнең элекке формалары теоретик яктан (Т) А — Т (А), (Т) Е — Т (Е) булгандыр дип уйланыла.

Озак вакытлар кулланылышта булу нәтиҗәсендә һәм шулай ук башка сәбәпләр аркасында, сүзләрнең тартыклары яисә сузыклары төшеп калырга мөмкин. АТ, ЭТ тибындагы сүзләрнең, мәсәлән, баштагы һәм азактагы авазлары төшеп калган. СУ, БУ кебек сүзләрнең дә тартыклары төшеп калырга мөмкин. Ләкин мондый сүзләр тел «яралганда» ук бер генә аваздан ясалган булырга да мөмкин. Мәсәлән, борынгы кытай телендә У сузыгы «биш» (50, 395), татар теле диалектларында Ү сузыгы «өй» (91, 556) дигәнне белдерә ала.

Димәк, табигатьтә, кеше телендә ялгыз бер сузык аваз тәмамланган, тулы һәм мөстәкыйль мәгънә белдерә ала икән. Шул ук вакытта бер генә тартыктан торган тулы һәм мөстәкыйль мәгънәле сүз юк һәм була да алмый. Тартык авазлар бары тик сузык авазлар янында гына тулы мәгънәгә ия булалар.

Шул рәвешчә, сүзгә (иҗеккә) бары сузык аваз гына реаль мәгънә бирә дип әйтә алабыз. Барлык телләрдәге сузыклар ике төркемгә: А һәм У төркемнәренә бүленәләр. Ә, Ы, Э кебек сузыклар А төркеменә, Ү, И кебек сузыклар У төркеменә карыйлар. О һәм Ө сыман сузыкларның позицияләре тотрыксыз, шунлыктан алар А төркеменә дә, У төркеменә дә карый алалар. Кайбер телләрдә, мәсәлән, абхаз, абазин телләрендә А һәм У төркемнәренә караган икешәр генә мөстәкыйль сузык бар, ләкин телнең нормаль яшәве өчен мондый хәл беркинди кыенлык тудырмый.

А сузыклы иҗекләр барлык телләрдә Җир һәм Ана, Хатын-кыз, У сузыклы иҗекләр — Су-Күк һәм Ата, Ир төшенчәләрен белдерәләр. А сузыклы иҗекләр шулай ук Җиргә, Анага хас барлык кире сыйфатларны, У сузыклы иҗекләр Суга, Күккә һәм Атага хас уңай сыйфатларны белдерә алалар.

Менә кайбер мисаллар: тибетчә — СА — җир (65, 218), бамбара телендә БА — ана (98, 224), бамана телендә БА — хатын (97, 35), ненец телендә ИА — җир (94, 379), борынгы мисыр телендә ТА — җир (45, 96). Татар телендә СУ — су, глангали телендә ВУ — су (20, 17), селькуп телендә НУ — күк

(74, 69), корей телендә ПУ — ата (19, 130), япон телендә ТҮ — күк (104, 181) дигәнне белдерә.

Ике иҗекле сүзләрдә беренче иҗек Җир, Ана, Хатын-кыз яисә Су-Күк, Ата, Ир төшенчәләрен белдерә. Икенче иҗек «улы» мәгънәсен аңлата һәм һәрвакыт беренче иҗеккә буйсынып килә. Мәсәлән, татарча БАЛА сүзе ике иҗекле. Беренче БА иҗеге Җир, Ана дигәнне, икенче ЛА иҗеге «улы» дигәнне белдерә. Бу сүзне Җир улы дип тә, Ана улы дип тә аңларга була. Татар телендә БАЛА бары тик Ана улы гына була ала. Арнхемленд телендә БАЛА — куыш (шалаш) (111, 39) дигәнне белдерә һәм Җир улы буларак аңлашыла. Татарча ҖИР сүзендә беренче ҖИ иҗеге Суны яисә Күкне, сузык авазы төшеп калган, тулы булмаган Р — иҗеге «улы» дигәнне белдерә. Татарча ҖИЛ сүзендәге ҖИ иҗеге Күкне, Л — иҗеге «улын» белдерә. Русча ЗЕМЛЯ өч иҗекле. Беренче ЗЕ — Җир, икенче М — иҗеге «улы» була: Су-Күк. Өченче ЛЯ(ЛӘ) иҗеге шулай ук «улы», ләкин Су-Күк улы, ягъни тулаем ҖИР була.

Борынгы карашлар буенча, күктәге барлык нәрсә — Күк улы, судагы барлык нәрсә — Су улы буларак аңлашыла дидек. Бу хакта мифларда ап-ачык әйтелә. Телдә дә шул ук хәл чагыла. Мәсәлән, русча «ЩУКА — «чуртан» балыгы була. ЩУ — СУ, КА — «Улы» дигәнне белдерә. Немецча ФИШ — балык (62, 557) була. ФИ иҗеге Су, Ш — «улы» дигәнне аңлата. Русча ТУЧА сүзендә ТУ — Күк, ЧА — «улы». Татарча БАЛЫК сүзендә әүвәлге ике БАЛЫ иҗекләре Суны,— К «улын» белдерә.

Әйтелгәнчә, уңай сыйфат белдерүче сүзләр У сузыклы иҗек ярдәмендә, кире сыйфат белдерүче сүзләр А сузыклы иҗек ярдәмендә ясала. Моңа мисал итеп Тува АССРдагы БИ-ХЕМ, КА-ХЕМ елгаларын күрсәтергә була. БИ-ХЕМ тува телендә Зур Енисей, КА-ХЕМ Кече Енисей елгаларына карата кулланыла (99, 638—639). БИ иҗеге монда «зур», «озын» дигәнне, КА иҗеге «кечкенә», «кыска» дигәнне аңлата. Татарның атаклы энциклопедист галиме Риза Фәхретдинов УФА шәһәре исемен «биек урын» мәгънәсендәге УБА сүзеннән чыгарып аңлаткан (110, 159). Сүзне У — БА дип таркатсак, У сузыгы «биек», «югары» дигәнне, БА иҗеге «җир», «урын» төшенчәсен белдерәчәк.

Хәрәкәт бедерүче сүзләр дә У сузыклы иҗекләр ярдәмендә ясала. Мисалга татарча боерык фигыльләрдән КУ, ТУ, БУ, ТИ кебек иҗекләрне күрсәтергә була. Башка телләрдән: айну телендә КУ — эчү, эчмәк (88, 16), шумер телендә — ДУ — төзү, төземәк (31, 39), буа телендә ТУ — ашау, ашамак (27, 79) дигәнне белдерә.

Без монда бүтән сүз төркемнәренә һәм иҗек методының башка моментларына тукталып тормыйбыз, чөнки Фест түгәрәгендәге сүзләрне тикшергәндә безнең өчен шушы мәгълүмат та җитеп торачак.

## 8. Фест түгәрәген тасвирлау

Балчык дискыдагы язуны, әйтелгәнчә, күпчелек кырыйдан — уңнан укый башлауны яклый. Моның өчен кайбер җитди сәбәпләр дә бар. Мәсәлән, борынгы мисыр язуларында кеше рәсемнәре укучыга таба караган. Сурәттәге кеше, әйтерсең, укучы белән аңгәмә алып бара. Борынгылар һәр сурәтнең җаны бар дип исәпләгәннәр. Фест түгәрәгендә дә шундый ук принцип сакланган: кешеләрнең барысы да уңга караганнар. Алар белән «сөйләшүче» кеше, димәк, сулга — аларның йөзенә карарга һәм уңга таба укып барырга тиеш.

Һәрбер шакмак эчендәге рәсемнәр төркеме бер сүзне белдерә дип уйланыла. Кайбер шакмакларда азаккы (сул яктагы) рәсем астына кыек сызык сызылган. Мондый сызыклар кайбер башка төр язуларда да кулланыла. Һиндстан язуларында мондый сызык «вирама» дип, Көнбатыш семит язуларында «шва», гарәп язуында «сөкүн» дип атала (106, 12). «Сөкүн»нең татарчасы — СӘКЕН. Сәке-н — Ата улы. Без инде беләбез, борынгы карашлар буенча, барлык озынча һәм хәрәкәтчән әйберләр Су-Күк улы яисә Ата улы исәпләнелә. Гади сызык кына түгел, ук, сөңге, пычак, күсәк, таяк кебек кораллар да мифик Атаның яисә Күкнең-Суның мифик әгъзасы буларак аңлашыла.

Сүз ахырындагы СӘКЕН дә ук, сөңге, күсәк, кебек коралларга тиң. Сүз азагындагы сузык авазны ул, әйтерсең, төртеп тишә, «үтерә» һәм юкка чыгара. Шулай итеп, сәкен булса, сүз тартык авазга, булмаса — сузык авазга тәмамлана.

Сәкен шакмакның сул ягында булгач, сүзне, димәк, уң яктан укый башларга кирәк. Югарыда әйтелгәнчә, бик борынгы карашлар нигезендә, Су-Күк, Ата, Ир һәм уң як беренче һәм изге санала. Табигатьтәге һәрбер эш-хәрәкәт Атага, Иргә хас функция дип исәпләнелә һәм шуңа күрә барлык эш-хәрәкәт бары тик уңнан гына башланырга тиеш. Уң кулның сул кулга караганда активрак булуы менә шул карашка нигезләнгән. Татарда, мәсәлән, әле дә иң элек уң аяк киемен кияләр, бусага аша иң элек уң аякны атлыйлар, яңа өй котларга иң элек ир баланы кертәләр.

Фест түгәрәгендәге язуны уңнан сулга таба укырга кирәклеген күрсәтә торган тагын бер әһәмиятле деталь бар. Түгәрәкнең ике ягында да, кырыйда, спираль башланып киткән төштә, аркылы сызык өстенә дүрт-биш төртке (нокта) төшерелгән. Ник кирәк ул төрткеләр? Чәй тәлинкәсе зурлыгындагы балчык түгәрәкне борынгы кеше, күрәсең, карап түгел, бармак битләре белән капшап та «укыгандыр» дип әйтергә була. Карамыйча укыганда, сүзләр тәртибен бутамас өчен, билгеле бер җирдән башлап китәргә кирәк булган һәм шуңа күрә «җөмлә» башында аркылы сызыкларга әлеге төрткеләр (ноктал) куелган.

Фест түгәрәгендәге сүзләрне укый башлаганчы безгә спиральне сүтеп турайтырга һәм шакмаклардагы рәсемнәрне кәгазьгә күчерергә кирәк. Уңнан беренче шакмак А31 дип, икенчесе А30 дип билгеләнә. Соңгы шакмак А1 була. «Тәлинкә»нең сул ягындагы рәсемнәр В30дан алып В1 гә кадәр шулай ук аерым кәгазьгә күчерелә.

Шакмаклардагы рәсемнәр төрлечә аралашып, төрле комбинациядә киләләр. Кайбер рәсемнәр бер яисә ике мәртәбә очрый, кайберләре еш кабатлана. Рәсемнәрнең безгә — бүгенге кешеләргә аңлашылганнары да, бик үк аңлашылып җитмәгәннәре дә бар. Рәсемдә сурәтләнгән һәр нәрсәнең үз исеме-атамасы булырга тиеш. Ләкин исем-атамаларны табу белән генә эш бетми әле. Һәрбер шакмактагы рәсем атамаларының тиешле «хәрефләрен» (күбесенчә баш «хәрефләрен») бергә җыярга, «хәрефләрне» уңнан сулга тәртиптә урнаштырырга һәм сүзне табарга кирәк. Һәрбер рәсем бер генә төрле атала. (Ике рәсемнең бер исем белән аталуы турында сүз алдарак булыр. Шакмактагы сүзләр мәгънә һәм форма ягыннан бер-берсенә ярашырга тиешләр.

Түгәрәктә 45 төрдәге рәсем-билге кулланылган. Ләкин бу әле Фест язуы телендә 45 төрле аваз булган дигән сүз түгел. Кайбер авазларны, иҗекләрне белдерү өчен берәр, икешәр генә рәсем-билге кулланылган булса, кайберләре өчен дүртәр-бишәр төрдәге рәсем-билгеләр кулланылган. Къ һәм К тартыкларына башланган иҗекләр 14 төрле рәсем ярдәмендә белдерелә. Бу исә Фест чоры төрки телдә Къ, К тартыкларына башланган сүзләрнең бүтән тартыкларга башланган сүзләргә караганда күбрәк булуын чагылдыра. Бүгенге татар теле дә, мәсәлән, гомумән Къ һәм К тартыкларына башланган сүзләрнең күплеге белән аерылып тора. 1966 елда Мәскәүдә басылып чыккан «Татарча-русча сүзлек»тә (93) барлык сүзләрнең 15 проценты К хәрефенә (Къ, К тартыкларына), 8,4 проценты Т хәрефенә, 6,1 проценты С хәрефенә, 5,8 проценты Б хәрефенә башлана. Фест язуында С тартыгын белдерү өчен биш, Б һәм Т тартыкларын белдерү өчен дүртәр рәсем-билге кулланыла. Л һәм Р тартыкларына башланган рәсем-билгеләр бөтенләй юк.

Кайбер рәсем-билгеләр калын әйтелешле сүзләр ясауда гына, кайберләре нечкә әйтелешле сүзләр ясауда гына кулланыла. Калын әйтелешле рәсем-билге атамасының иҗеге кайчагында нечкә әйтешлелегә, нечкә әйтелешле рәсем-билге атамасының иҗеге калын әйтешлелегә әйләнергә мөмкин. Мондый хәл бары сүз ахырында һәм сүз уртасында гына була.

Барлык рәсем-билгеләр нигездә бер авазны, бер иҗекне белдерү өчен кулланыла, ләкин кайбер рәсем атамалары сүз ясауда тулысынча катнашалар. Мәсәлән, таблицадагы 25 рәсемдә текә борынлы, текә койрыклы көймә сурәтләнгән. Рәсем КӘМӘ дип атала. «Ребус» кагыйдәсе буенча, КӘМӘ сүзенең К тартыгы гына яисә КӘ иҗеге генә сүз ясауда катнашырга тиеш иде кебек. Ләкин монда КӘМӘ сүз ясауда һәр очракта тулы килеш файдаланыла.

## 9. Беренче авазның табылуы һәм беренче сүзне уку

Түгәрәктәге сүзләрнең укылу тәртибе ныграк аңлашылсын өчен, без хәзер иң беренче авазның ничек табылуына һәм иң беренче сүзнең ничек укылуына киңрәк тукталырбыз.

«Тәлинкә»нең уң ягындагы беренче шакмак А31 дип номерланган. А31 шакмагында беренче рәсем — кеше башы. Таблицада ул 2 дип билгеләнгән. Кеше такыр башлы кебек. Ләкин аның түбә өстеннән чәч сыман нәрсә тырпаеп тора. Шулай да мондый чәчле кешенең булуы мөмкин түгел.

Атаклы Минос патша һәм карилар турында сөйләгәндә Геродот: «Карилар өч нәрсә уйлап табалар... Мәсәлән, грекларны алар сугышчының баш киеменә кош каурыйлары кадарга, калканнарга эмблема ясарга өйрәтәләр һәм беренче булып калканнарга тотка куя башлыйлар» (18,I, 171) дип яза. Бу хакта Страбон да әйтеп китә (85, XIV, II, 27). Б.э.к. XIII гасырда Мисырга күп төрле кабиләләр басып керә. Алар арасында карилар да, ликиләр дә була. Мисыр чыганакларында аларны «диңгез халыклары» дип атыйлар. Аларны шулай ук «филистимлян» дип тә йөртәләр. Библиядә әйтелгәнчә, «филистимляннәр» Криттән килгәннәр. Мисыр истәлекләрендә менә шул «филистимлян» сугышчысының рәсеме сакланып калган. Аның башында А31 шакмагындагы беренче рәсемдәге кешенеке кебек кош каурыйлары тырпаеп тора (96, 162, рәс. 6; 35, 236; 87, 487).

Димәк, әлеге кеше башы сурәте сугышчыны белдерә икән дип әйтә алабыз. Кеше башы янындагы түгәрәк калкан рәсеме (таблицада 12 рәсем) аның чыннан да сугышчы булуын исбатлый. «Кеше башы» белән «калкан» бары тик сүз башында гына янәшә урнашканнар. Сүз ахырында, сүз уртасында «кеше башы» да, «калкан» да аерым-аерым кулланыла. Күрәсең, монда ниндидер кагыйдә бар. Әйтик, «кеше башы» белән «калкан» янәшә килгәндә (сүз башында) бер төрле атала, аерым килгәндә — башкача атала.

«Кеше башы» белән «калкан» янәшә килгәндә, шулай итеп, сугышчыны белдерә булды. Ничек аталды икән соң ул «сугышчы» бик борынгы төрки телдә? Ир, нукер, укчы, чирүче, сугышчы? Крит чоры төрки телдә «сугышчы» АЛАБ дип аталган. Бүгенге татар телендә ул АЛЫП буларак мәгълүм. Татарстанда БИШАЛАБ авылы бар (89, 123). Татар телендә АЛЫП батыр — әкият герое, Себер төркиләре, казах, кыргызларда АЛЫП — батыр дигәнне белдерә (75, 1, 384), карай (караим) телендә АЛП — баш кеше (38, 65), борынгы төрки телдә АЛП — 1) төз атучы, мәргән; 2) батыр, көчле ир кеше (29, 36).

Шулай итеп, Фест түгәрәгенең дөрес укылган беренче ике рәсеменең атамасы АЛАБ (АЛЫП) булды. АЛАБ бары А сузыгын гына белдерә һәм бары сүз башында гына кулланыла. Сүз уртасында, сүз азагында А сузыгын белдерү өчен бүтән төрле рәсем-билгеләр файдаланыла.

А31 шакмагындагы өченче (таблицадагы 13) рәсем НИЖДАГЪ дип атала. Дүртенче (таблицадагы 1) рәсем-билге ТИ, бишенче (таблицадагы 18) рәсем-билге МӨГЕШ дип атала. Сүз калын әйтелештә. МӨГЕШ астына сәкен төшерелгән, димәк, сүз М тартыгына тәмамланырга тиеш. Рәсем атамалары шакмактагы тәртип буенча (уңнан сулга); АЛАБ, НИЖДАГЪ, ТИ, МӨГЕШ. Сүз башындагы авазларны җыябыз, була: А.Н.Т.М. Укыла: АНТЫМ, исем, берлек санда, беренче зат кушымчасы белән төрләнә, баш килештә.

## 10. Фест түгәрәгендәге рәсемнәр һәм аларның атамалары

(Рәсем атамалары таблицадагы тәртип буенча бирелә).

1. ТИ. Сул кулын күтәреп йөгереп барган бу кеше рәсеме түгәрәкнең А ягында 6, В ягында 5 мәртәбә кабатлана. Һәр очракта Т тартыгын белдерә. ТИ не Җир улы, Ана улы,— «кеше» дип аңларга була. ТИнең «кеше»-леге, мәсәлән, татарча ТИРЕ сүзендә күренә. Ләкин ул монда гомумән «кеше» түгел, яшь кеше ахрысы. Татар телендәге ТҮТИ, ЯШТИ кебек сүзләрнең ТИ иҗекләре мөстәкыйль мәгънәле берәмлекләр булса кирәк.
2. Шартлы рәвештә «калкансыз сугышчы» дип атарга мөмкин булган бу рәсем сүз башында гына кулланыла. Түгәрәкнең А ягында 2, В ягында 4 мәртәбә кабатлана. «Калканлы сугышчы» АЛАБ дип атала һәм А сузыгын, «калкансыз сугышчы» — Ә сузыгын белдерә. Рәсемнең тәгәл атамасын тәкъдим итеп булмый.
3. МИҢЛЕ. Түгәрәкнең А ягында 2, В ягында 2 мәртәбә очрый. Рәсемдәге кешенең уң як чигәсендә 8 ле сыман билге бар. Моны миң дип аңларга була. Шунлыктан рәсем шартлы рәвештә МИҢЛЕ дип аталды. 8 ле сыман билге Кипр-Миной һәм Кипр иҗекле язуларында ЛЕ иҗеген белдерә (43, 87).

4. БУЛУН. Рәсем түгәрәкнең А ягында бер мәртәбә кулланыла. Кулы арткa каерып бәйләнгән кешенең әсир, тоткын булуы турында бернинди шик булырга мөмкин түгел. Борынгы төрки телдә әсир БУЛУН (29, 123) дип атала. Рәсем Б тартыгын чагылдыра.

5. МАЛАЙ рәсеме түгәрәкнең В ягында бер генә мәртәбә очрый. Шакмактагы сүзнең мәгънәсе буенча, азакта М тартыгы таләп ителә. Шунлыктан рәсем шартлы рәвештә МАЛАЙ дип аталды.

6. МА. Түгәрәкнең А ягында —2, В ягында 2 мәртәбә кабатлана. Бу — изге Ана, бөек Ана. МА — Кече Азиядә хатын-кыз алла һәм аллалар анасы (56, 132). МА ның бөек Ана булуы татарча АЛМА (апа) сүзендә сакланып калган. АЛМА нократ сөйләшендә «абыстай» дигәнне белдерә, Сергач сөйләшендә шул ук сүз АЛМАЙ рәвешендә кулланыла (91, 35). Сүзне АЛ-МА дип бүләбез. Иҗек методы кагыйдәләре буенча, АЛ — «изге», «бөек» дигәнне, МА — Ана дигәнне белдерә. АЛМАЙ сүзендәге — И артык.

7. ИМИ. Рәсем түгәрәкнең А ягында 3, В ягында 15 мәртәбә кабатлана. Һәр очракта И, ИМ авазларын гына белдерми, кайбер очракта ЫМ булып (В7, В4), кайбер очракта ЭМ булып (А29, В1) килә.

8. КАЛПАК рәсеме түгәрәкнең А ягында 1, В ягында 4 мәртәбә кулланыла һәм Къ, К тартыкларын белдерә. Крит (кари) сугышчыларының баш киемнәренә кош каурыйлары тагулары турында сүз булды инде. Каурыйлары тырпаеп торган баш киеме 2 рәсемдәге «калкансыз сугышчы» башында да күренә. Тик монда (2 рәсемдә) ул схематик рәвештә генә сурәтләнгән. Әлеге 8 рәсемдә КАЛПАК аерым күрсәтелә һәм аның аскы өлеше кыршау сыман тәмамланган. Борынгы Мисыр рәсемнәрендәге «филистимлян»ның да баш киеме маңгай турысыннан нәкъ шундый ук кыршау сыман нәрсә белән тоттырылган (96, 162, рәс. 6; 87, 487). Татар хатын-кызларының баш киеме КАЛФАК (90, II, 34), шулай ук КАЛПАК (93, 216) әлеге КАЛПАКның дәвамы булса кирәк.

9. БАШЛЫК рәсеме түгәрәкнең В ягында 2 мәртәбә кулланыла, һәр очракта Б тартыгын белдерә. Борынгы Грециядә сарык йонынннан тукылган башлыклы ябынчалар булган. Яңгыр вакытында Крит көтүчеләре бүген дә шундый ук башлыклы ябынча (плащ) бөркәнәләр (63, 64).

10. ИШКӘК рәсеме түгәрәкнең А ягында 4 мәртәбә очрый һәм И сузыгын белдерә.

## 11. Иайа рәсеме һәм ук-җәя турында кайбер фикерләр

11. ИАЙА. Рәсем түгәрәкнең А19 шакмагында гына кулланыла һәм сүз азагында ИА иҗеген белдерә. Карай телендә ИАЙА (38, 218), кырым-татар, госманлы-төрек, чыгытай телләрендә ИАИ (75, III, 3), татарча ҖӘЙӘ.

Рәсемдә кереше бушайтылган җәя сурәтләнгән. М хәрефе формасындагы мондый җәяләрне катлаулы җәя («сложный лук»), скиф җәясе («скифский лук»), гуннар җәясе («гуннский лук»), төркиләр җәясе («тюркский лук»), күчмәләр җәясе («кочевнический лук»), Үзәк Азия халыклары җәясе («центрально-азиатский лук») дип йөртәләр. Бу атамаларның һәркайсы шушы типтагы җәянең теге-бу үзенчәлеген күз алдында тотарга мөмкин. Шулай да төп фикер үзгәрешсез кала: М хәрефе сыман җәянең дугасы тигез генә бөгелми; уртадан ул батынкы; батынкы дуганың ике ягында ике «калкулык» бар. Җәя башлары бөгелгән. Җәя агачы берничә кисәктән ялгап ясалган булган. Ныклык өчен агачның тышкы ягына сөяк пластинкалар беркетелгән, сеңер белән уратып, җилем белән катырылган.

Формасы буенча җәя дугасы нигездә ике төрле генә була ала. Аның бер төрлесе М хәрефе рәвешендә булса, икенчесе латинча Д хәрефе рәвешендә була. Латинча Д рәвешендәге җәя катлаулы җәягә караганда борынгырак исәпләнелә.

«Скиф җәясе» Европа-Азия далаларында барлыкка килгән дип исәпли А. М. Хазанов (107, 29). «Скиф җәясе» Көнчыгышта Себергә кадәр таралган һәм Кытайгача барып җиткән, Көнбатышта мондый җәянең ук «тимерләре» Фландриядә табылган (107, 30). «Скиф җәясе» грекларда да була. Бу җәяне б.э.к. VI яисә VII гасырда греклар башка халыклардан күчереп алганнар булса кирәк ди Хазанов (107, 30). Шунысы игътибарга лаек, «Критне исәпләмәгәндә, Грециядә җәя беркайчан да киң таралган корал булмаган» (107, 30), ди шул ук автор. Димәк, корал буларак җәя Криттә генә киң кул-



*Рәсем 1. Фест дисбесенең уң ягы.*

ланылган икән. II гасыр азакларында, III гасырның беренче яртысында яшәгән рим-грек язучысы Элиан да «Крит кешеләре бик яхшы укчылар» ди (116, I, 10). «Скиф җәясе» этрускларда да була, ләкин мондый җәяне алар башлыча ауда гына кулланганнар (107, 30). Катлаулы җәя шумерларда да була (66, 170). Төрки халыклар, шул исәптән казан татарлары М рәвешендәге катлаулы җәя кулланганнар. XVI гасырда Идел буйларына килеп чыккан С. Герберштейн ясаган татар сугышчысының рәсемендә баш-башлары бөгелгән, уртасы батынкы җәя дә бар (53, 129).

Борынгы кешенең сугыш коралы үсешендә катлаулы җәя яңалык булып исәпләнелә. Мондый җәянең ату көче арта. Шул ук вакытта аны сүтәргә, җыярга һәм махсус савытка — садакка салып куярга мөмкинлек туа. Катлаулы җәяне академик А. П. Окладников «җәянең иң соңгы дәрәҗәгә җиткән камиллек үрнәге» дип исәпли (66, 170). «Җәяләр буенча үз заманының иң зур белгече» Ф. Лушан катлаулы җәяне борынгы төрки халыкларның берәрсе яисә Шумер кешеләре уйлап тапкан дигән фикер әйткән (66, 170).

Катлаулы җәя гомумән җәянең ату көчен арттыру теләге нәтиҗәсендә генә түгел, бәлки бик борынгы халыкларның (ихтимал, төркиләрнең) динифәлсәфи карашлары нигезендә барлыкка килгән дип исәплибез без. Әйтелгәнчә, борынгы кешегә барлык куыш, батынкы һәм савыт сыман әйберләр Җир улы, Ана улы, барлык озынча, хәрәкәтчән әйберләр — Су-Күк улы, Ата улы булып тоелган. Мондый караш этнографик фактлар белән дә, тел фактлары белән дә исбат ителә.

Мәсәлән, Төньяк Алтай кабиләләрендә ук һәм җәя белән имләү соңгы вакытларга кадәр дәвам иткән. Хакаслар җәянең сихри көче бар дип белгәннәр




*Рәсем 2. Фест дисбсенең сул ягы.*

һәм яңа туган ир бала бишегенә, чүпрәккә төреп, кечкенә җәя салып куя торган булганнар (32, 11). Тел фактларына килгәндә, татарча ҖӘИӘ сүзен ҖӘ-ИӘ дип таркату да җитә. ҖӘ-ИӘ ул Ана улы, ягъни хатын-кызның җенес әгъзасы дигән сүз. Татарча УК сүзен У-К дип таркатабыз. Бу Ата улы, ягъни ир кешенең җенес әгъзасы дигәнгә туры килә.

Катлаулы җәя ул чынлыкта Фест түгәрәгендә еш кабатлана торган (таблицадагы 40 рәсем) АМ (хатын-кызның җенес әгъзасы) сурәтенең бер варианты булып тора. Катлаулы җәяләр, борынгы Криттән тыш, борынгы Мисыр рельефларында (б.э.к. 4000—3000 еллар) (109, 7, фото; 36, 82), Төньяк Африкадагы кыяларга ясалган борынгы сурәтләр арасында (б.э.к. 5000—1000 еллар) (39, 33, рәс. 5, фото), Көнчыгыш Испаниянең Альпера кыясындагы ау күренешләрен чагылдырган рәсемнәрдә (36, 14) һ.б. истәлекләрдә очрый.

## 12. Фест түгәрәгендәге рәсемнәр һәм аларның атамалары. Дәвамы.

12. КАЛКАН рәсеме «сугышчы» белән бергә дә, аерым да кулланыла. Түгәрәкнең А ягында «сугышчы» белән бергә 12, В ягында 1 мәртәбә очрый. «Сугышчы» белән кулланылганда һәрвакыт сүз башына туры килә һәм, әйтелгәнчә, АЛАБ дип укыла. Рәсем үзе генә А ягында 3, В ягында 1 мәртәбә




*Рәсем 3. Фест дисбесендәге рәсем-билгеләр һәм аларның атамаларын күрсәткән таблица.*

кулланыла. Къ, К тартыкларын белдерә. Кнос сараенда һәм Камарес тау куышында табылган (Беренче Урта Миной чорына караган) чүлмәк савытсаба орнаментында әлеге калканга охшаш рәсемнәр очрый (67, 127). Б.э.к. 1200 елларда, XX династиянең Рамсес III (IV) хакимлеге чорында Мисыр кешеләренең «диңгез халыклары» белән сугышын күрсәткән рельефта Мисыр сугышчыларының калканнары озынча, «диңгез халыклары» сугышчыларыныкы — түгәрәк (68, 355).

13. НИЖДАГЪ. Рәсем түгәрәкнең А ягында 3, В ягында 3 мәртәбә очрый. Тукмак, бәләк, игәү яисә янавыч кебек коралларга охшаш бу коралның җайлы сабы бар. Коралның юанрак, озынчарак өлешендәге төрткеләр вак таш, ком кисәкләрен хәтерләтә. Мәхмүд Кашгари сүзлегендә «кайрак ташы» НИЖДАГЪ дип атала (47, 432). Рәсем һәр очракта Н тартыгын белдерә.

14. КАМЫТ. Түгәрәкнең ике ягында да берәр мәртәбә кулланыла. Рәсемдә парлап җигелә торган үгез камыты сурәтләнгән. Криттә, башка утраулар-

да һәм Грециядә җирне элек пар үгез җигеп сөргәннәр (96, 310). Бу хакта сөйли торган борынгы сурәтләр һәм терракота сыннар сакланып калган (48, 110 бит, рәс. 38, 121 бит, рәс. 44).

15. БАЛТА. Рәсем түгәрәкнең В ягында бер генә мәртәбә кулланыла, Б тартыгын белдерә. Урта диңгез бассейны илләрендә ике яклы балта Күк һәм яшен алласы символы булган (96, 288). Ике яклы балтаны Кече Азиядә барлыкка килгән дип аңлаталар (96, 248; 8,88).

16. САДАК. Түгәрәкнең В ягында ике мәртәбә кабатлана. Бер очракта С тартыгын белдерә, икенче очракта САДАК сүзе тулысынча файдаланыла. Рәсемдәге «садак»ның өске ягында элмәк сыман нәрсәсе бар. Бу аның бил каешына тагылып йөртелүе турында сөйли. Садак җәя яки ук салу өчен кулланылган. Фест чорында аның пычак кынысы сыйфатында кулланылган булуы да ихтимал. САДАК (колчан) сүзе татарда, казахта, алтай, телеут һ.б. төрки телләрдә мәгълүм (75, IV, 383).

17. КАПКАЧ. Рәсем А8 шакмагында кулланыла һәм КЪ тартыгын чагылдыра.

18. МӨГЕШ. Түгәрәкнең А ягында 6, В ягында 6 мәртәбә кабатлана, һәр очракта М тартыгын белдерә. Рәсемдә «почмак» сурәтләнгәнлеге үзеннән-үзе аңлашылып тора. Татар теле диалектларында сүзнең МӨГӘШ, МИЙЕШ вариантлары да билгеле (91, 304, 316). МӨГЕШ (почмак) рәсеме борынгы мисыр язуында да бар (26, рәс. 29).

19. ТА. Ике чаты да югарыга карап торган һәм чатлы багананы хәтерләткән рәсем шартлы рәвештә шулай дип аталды. Рәсемне шулай ук ЧАТ дип атарга да була. Ләкин ул чагында сүзнең беренче авазы түгел, соңгы авазы истә тотылган булачак. Рәсем түгәрәкнең А ягында 3 мәртәбә кабатлана һәм Т тартыгын белдерә.

20. ӘМ. Рәсем В26 һәм В18 шакмакларында урнашкан. М тартыгын яисә ӘМ иҗеген белдерә. Бу рәсемне «чүлмәк» мәгънәсендәге АМ дип тә уйларга була. Тик шулай да бүгенге төрки телләрдә мондый «чүлмәк» юк ахрысы. ӘМ сүзе иҗек методы нигезендә торгызыла. Белүебезчә, чүлмәк, савытсаба — һәркайсы Ана улы. Грек һәм латин телләрендәге АМФОРА сүзенең АМ өлеше әлеге «чүлмәк»не чагылдыра сыман. ФОРА иҗекләрен төрки БОРА белән янәшә куеп карарга була. Куман телендә БОР шәраб (75, IV, 1661), уйгурча ПОР шәраб (75, IV, 1269), куман, карай телләрендә БОРЛА йөзем бакчасы (75, IV, 1664), кырым-татар телендә БОРЛАЛЫК йөзем бакчасы (75, IV, 1665). Крит чоры төрки телдә ФОРА-БОРА йөзем яисә йөзем шәрабен, АМ-БОРА — шәраб савытын аңлаткан булырга мөмкин. Бүгенге көндә бөтенләй башка мәгънәдә кулланыла торган АМБАР белән АМФОРА чынлыкта бер үк сүз булса кирәк. АМБАР-АМФОРА шәраб савыты чүлмәкне дә, шундый ук чүлмәкләр саклана торган бүлмәне, бинаны да аңлаткандыр дип әйтергә була.

21. КЫРГЫЧ. Рәсем А15 һәм А3 шакмакларында кулланыла һәм КЪ тартыгын белдерә. Бу ат яисә башка мал-туар кыргычы ахрысы. Әлеге корал ике яклы таракны хәтерләтә. Сап уртасында кечкенә чөй бар. Сапны кулга учлап тоткач, чөй ике бармак арасында кысылып калырга тиеш. Ат, сыер ябагасын тараганда түгәрәк, шома сап, шулай итеп кулда шуышып, әйләнгәләп тормаячак. Шуның нәтиҗәсендә кыргыч тигез тараячак. Бу хикмәтле коралны бары шулай гына күз алдына китерергә була.

22. ДИ. Чаты аска карап торган багананы хәтерләтүче бу рәсем-билге түгәрәкнең В ягында 5 мәртәбә очрый һәм Д тартыгын белдерә. Рәсемнең чыннан да ДИ дип аталуын В27 шакмагындагы сүз ярдәмендә исбатлап була. Шакмакта беренче рәсем ДИ, икенче рәсем КӘМӘ, өченче рәсем ТУН. Иҗекләрне кушкач, ДИКӘМӘ ТӘ дигән сүзләр барлыкка килә. ТӘ — теркәгеч, ДИКӘМӘ — юнәлеш килештәге исем. Баш килештә — ДИКӘ.

23. Н — ? Агач чөйне яисә кадакны хәтерләткән бу рәсем түгәрәкнең А ягында 5, В ягында 6 мәртәбә кабатлана, һәр очракта Н тартыгын белдерә. Шартлы рәвештә рәсемне НИМӘ дип атарга була.

24. ЭИ. Рәсем түгәрәкнең А ягында 1, В ягында 5 мәртәбә кулланыла һәм Э сузыгын, ЭИ иҗеген белдерә. Бу бик әһәмиятле һәм аеруча игътибарга лаек рәсем. Эйнең түбәсе гөмбәзле, димәк, планда ул түгәрәк. Аркылы сызылган зур «таяк»ны исәпкә алмаганда, эйнең стенасы шакмаклы. Аморгоста табылган һәм түгәрәк өй рәвешендә ясалган савыт әлеге ЭИнең бер вариантын сурәтли (83, 3). Савытның капкачы калку. Капкач өслегеннән дә, түгәрәк стена өслегеннән дә ике катлы итеп ясалган спираль бизәкләре каплаган. Савытның

аскы ягында кыска гына «аяклары» бар. «Аяклар» өчәү. ЭИ рәсемендә дә өч «аяк» күренә. Моны өйнең нигезе дип тә, аны җир өстеннән күтәртеп тора торган махсус тумбалар (баганалар) дип тә уйларга була. Схематик өй рәсемнә аркылы салынган «таяк»ны гөмбәзле түбәне эчке яктан тоттырып торучы терәк дип аңларга кирәк ахрысы. Палестинада, Эйнанда казып табылган һәм б.э.к. IX мең еллыкка карый торган түгәрәк өйләрнең конус сыман түбәләрен эчтән уртадагы терәк тотып торган (54, 28).

Аморгоста табылган савыт-өй моделе буенча фикер йөрткәндә, Фест түгәрәгендәге ЭИ гыйбадәтханәне тасвирлый дип әйтә алабыз. Аморгос савытындагы спиральләр кояш символы булып хезмәт иткән. Өйнең планда түгәрәк булуы да аның дини корылма булуына ишарәли. Арханда табылган һәм б.э.к. 1100—1000 елларга карый торган гыйбадәтханә моделе дә планда түгәрәк (83, 105, 106). Өйнең түбәсе калку — гөмбәз сыман, түбә уртасында төтен чыгу өчен морҗасы бар. 24 рәсем ЭИ түбәсеннән шулай ук морҗа сыман нәрсә тырпаеп тора. Архандагы гыйбадәтханә моделенең ачык ишегендә ике кулын югары күтәргән алиһә (?) күренә. Алиһәнең тәненә, беләкләренә буйбуй сызыклар төшерелгән. Өйнең түбәсендә, стенасында — схематик спираль сурәтләре. Ике спираль нәкъ Аморгос өендәге кебек ялгана. 24 рәсемдә спираль юк, димәк, рәсем чыннан да өйнең конструкциясен чагылдыра. Аморгостагы савыт-өй һәм Архандагы гыйбадәтханә детальләре белән Фест түгәрәгендәге ЭИ детальләренең туры килүенә нигезләнеп, 24 рәсемне дә гыйбадәтханә дип исәплибез.

Югарыда әйтелгәнчә, сүздә О һәм Ө сузыкларының тотрыклы позициясе юк. О һәм Ө сузыклары А төрендәге яисә У төрендәге сузыкларны алыштырып киләләр. Татар телендә Ө сузыгы күп очракта Э(Е) сузыгын алыштыра. Шунлыктан бүгенге телдә ӨЙ булган сүз элегрәк ЭИ рәвешендә әйтелгән. ӨИнең кайчандыр ЭИ рәвешендә әйтелүен грек телендә сакланып калган кайбер мисаллар белән дә исбатлап була. «Мегар акрополе «кари кешесе» Кар патша хөрмәтенә КАРИЕИ дип аталган» (96, 166) ди Томсон. Монда без КАРИЕИ сүзен аерып алабыз һәм аны КАРИ-ЭИ дип таркатабыз. ПРИТАНЕИ сүзе үзенең этимологиясе буенча ПРИТАН ӨЕ, ягъни башлык, рәис («председатель») өе («дом притана») дигәнне белдерә (96, 364). ПРИТАН «башлык» булгач, ЭИ сүзе турыдан-туры «өй» дигәнгә туры килә. Атаклы Троя янындагы бер калкулык ВАТИЕЯ яисә БАТИЕЯ дип аталган (64, 519). Бу калкулык (курган) сугышчы хатын-кыз (амазан) Мирина күмелгән кабер курганы дип уйланылган (64, 519, 524). БАТИЕЯ сүзе БАТИ-ЭИА дип таркатыла, бу исә БАТИ ЭИЕ булачак. Киң таралган МУЗЕИ, МАВЗОЛЕИ сүзләре ахырындагы ЭИ иҗекләре дә ЭИ (өй) дигәнне белдерә. Шумер телендә «өй» мәгънәсендәге сүз Э сузыгы белән генә белдерелә (52, 13). Татар әдәби телендә йонны ТЕТӘЛӘР, ләкин кайбер диалектларда ТӨТӘЛӘР (91, 445). Шулай ук ТЕЗҮ-ТӨЗҮ сүзләрендә дә Э сузыгының Ө гә әйләнүе ачык күренә.

25. КӘМӘ рәсеме түгәрәкнең А ягында 2, В ягында 5 мәртәбә кабатлана. Һәр очракта КӘМӘ һәм КЕМӘ дип укыла һәм сүз ясауда тулы килеш катнаша. Татар әдәби телендә КӨИМӘ булган сүз алтай, телеут, куман, чыгытай h. б. телләрдә КӘМӘ (75, II, 1205), кыргыз, казах, сагай, койбал телләрендә КЕМӘ (75, II, 1206). Уйгурча КЕМӘ — паром (боран), зур көймә, кораб (103, 82). Татар теленең Минзәлә, Бөре, Гәйнә сөйләшләрендә КӘМӘ (91, 269).

Крит кешеләре яхшы диңгезчеләр булалар. Урта диңгездә регуляр рәвештә йөзү б.э.к. III мең еллык башларында ук барлыкка килгән дип уйланыла (11, 45). Крит кешеләрендә сәүдә көймәләре, сугыш көймәләре h. б. көймәләр төзү бик нык алга киткән була (96, 382, рәс. 61; 68, 355; 69, 160-169).

26. ШӨШЛЕ. Түгәрәкнең А ягында 5, В ягында бер мәртәбә кулланыла, һәр очракта Л тартыгын белдерә. Бүгенге төрки телләрдә Л, Р тартыкларына башланган сүзләр бик аз. Крит чорында да, күрәсең, шулай булгандыр һәм шуңа күрә Л, Р тартыкларын рәсемдә чагылдыру кыенлык тудырган. «Ребус» кагыйдәсенең төп принцибыннан читләшеп, Л, Р тартыкларын белдерү өчен, атамалары Л, Р тартыкларына башланган рәсемнәрне түгел, бәлки шундый тартыкларга тәмамланган рәсемнәрне сайларга туры килгән.

27. ТУН рәсеме түгәрәкнең А ягында 10, В ягында 5 мәртәбә кабатлана, һәр очракта Т тартыгын белдерә. Кыска җиңле, озын, киң итәкле бу «тун» хатын-кыз күлмәге булса кирәк. Татарча ТУН, борынгы төрки телдә ТОН (29, 574).

28. КЪОИКЪА яисә КЪУИКЪА. Рәсем түгәрәкнең А17, А11 шакмакларында урнашкан һәм ике очракта да КОТ яисә КУТ сүзен ясауда катнаша.

Рәсемдә «сарык аягы» сурәтләнгән. Татар телендә КЪОЙКЪА мал аягыннан пешерелгән азыкны белдерә (93, 268). КУИКА сүзен иҗек методы нигезендә КУИ-КА дип таркатабыз, бу исә КУИ улы булачак. КЪОЙКЪА азыгын элегрәк халыкта «къойкъа шулпасы» дип атаганнар. «Шулпа» төшеп калган һәм сүз КЪОЙКЪА рәвешендә генә кулланыла башлаган. Карай телендә ТУИАК, ТУИАХ «тояк» һәм «койка» мәгънәләрендә кулланыла (38, 545). ТУИАХ — мал аягыннан әзерләнгән къойка (58, 49). Димәк, ТОИАК та, КЪОИКА да бер үк вакытта «мал аягын» да, мал аягыннан әзерләнгән «азыкны» да аңлата ала икән.

29. ИР. Үгез башын чагылдырган бу рәсем түгәрәкнең А ягында 3, В ягында 8 мәртәбә кабатлана. А 28 шакмагында ике ИР янәшә килә һәм «ирләр», ягъни «ир-ат» мәгънәсен белдерә. Башка һәр очракта И сузыгына тәңгәл килә.

30. КУИ. Рәсем В 4 шакмагында гына кулланыла. Мөгезе түбән таба бөгелеп, түгәрәкләнебрәк торган бу хайванның куй (сарык) булуына бернинди шик туарга мөмкин түгел. Татарча КУИ, борынгы төрки телдә КОИ (29, 453).

31. КОШ яисә КУШ рәсеме А якта биш мәртәбә кабатлана. КОШ-КУШ — гомум төрки сүз. КЪ тартыгын белдерә.

32. САИКА. Рәсемдә басып торган су кошы сурәтләнгән. Түгәрәкнең А ягында 2, В ягында 1 мәртәбә очрый, С тартыгын белдерә. Мисыр иероглифик язуында утырып торган шундый ук су кошы рәсеме СА иҗеген чагылдыра. САИКА сүзе иҗек методы нигезендә торгызыла һәм шартлы рәвештә тәкъдим ителә. САИ-КА ул СУ улы һәм шул ук вакытта, әлбәттә, Күк улы да. Борынгы төрки телдә САИ су, елга мәгънәсендә кулланылган (77, 40).

33. КАРАУЛ. Рәсем түгәрәкнең А ягында 2, В ягында 4 мәртәбә кулланыла һәм Къ, К тартыкларын белдерә. В 26 шакмагында сүз ясауда тулысынча катнаша. Рәсемдә «балык» сурәтләнгән. «Балык»ның бер генә төрки телдә дә КАРАУЛ яисә КАРАУЛЫ дигән атамасы юк ахрысы. Бу — иҗек методы нигезендә тергезелгән сүз. КАРА — Җир улы Су. «Балык» бары Су улы гына була ала, шунлыктан рәсем КАРА-УЛ дип аталды да. Су улы бер үк вакытта Җир дә була ала. КАРАУЛ ӘИЕ — Балык өе түгел, ҖИР ӨИЕ. Бүгенге төрки телләрдә КАРА ярдәмендә ясалган «балык» һәм балыкка катнашы булган атамалар очрый. Каракалпак телендә КАРМА — умачлы балык ашы (6, 286), койбал телендә КАРБА — балык җилеме (75, II, 163), госманлы-төрек телендә КАРАСЫ — нindидер балык (75, II, 163). Татарча КӘРӘКӘ, русча КАРАСЬ балыкларының да атамалары шул ук иҗекләр нигезендә барлыкка килгән.

34. КОҢГЫЗ. Рәсем А28, В29 шакмакларында очрый һәм Къ, К тартыкларын чагылдыра. Мисыр иероглифик язуында да шундый ук бөҗәк (коңгыз) рәсеме бар (26, 82, рәс. 9(1).

35. К — ? Ниндидер яфраклы агач сабагын сурәтләгән бу рәсемнең төгәл атамасын тәкъдим итеп булмый. Түгәрәкнең А ягында 5, В ягында 6 мәртәбә очрый. Къ, К тартыкларын белдерә.

36. С — ? Ниндидер агачнымы, үләннеме белдергән бу рәсемнең төгәл атамасы шулай ук билгеле түгел. Түгәрәкнең В ягында 4 мәртәбә кабатлана һәм С тартыгын чагылдыра.

37. С — ? Бу рәсем дә С тартыгын белдерә. Атамасы билгеле түгел. Түгәрәкнең А ягында 2, В ягында 2 мәртәбә очрый.

38. КАШКАРЫИ. Русча-грекча АСТРА дип аталган чәчәкнең татарча исеме КАШКАРЫИ (93, 244). Түгәрәкнең А ягында 3, В ягында 1 мәртәбә кулланыла, Къ, К тартыкларын белдерә. Чәчәкнең сигез таҗ яфракчыгы бар. Шундый ук КАШКАРЫИ рәсеме Әүвәлге Миной III чорына карый торган таш басмада бар (67, 105, рәс. 12(5). Болгар кабер ташларында да сигез яфракчыклы кашкарыйлар очрый (117, табл. 5, 7, 14, 18, 19, 20, 29).

39. АИР. Түгәрәкнең А ягында 1, В ягында 3 мәртәбә кабатлана һәм Р тартыгын белдерә. Рәсемдә өч җәпле сәнәк сурәтләнгән. Казах телендә «сәнәк» АИР (75, I, 25), алтай телендә АИРУШ (75, I, 31). Татар йола җырларында «сәнәк», «очлы нәрсә» мәгънәсендә АИРЫ сүзе кулланыла. Мәсәлән:

Зеңге, зеңге, зеңге корт,
Айры башлы зеңге корт;
Алтын башлы атасы,
Айры мөгез анасы (92, № 9).

40. АМ. Төрки телләрдә бу сүз хатын-кызның җенес әгъзасына карата кулланыла. Әлеге рәсем шуны чагылдыра. Түгәрәкнең А ягында 3, В ягында 3 мәртәбә кабатлана. Сүз уртасында, сүз азагында АМ, ӘМ, ЭМ иҗекләрен белдерә. М рәвешендәге катлаулы җәя шушы АМ сурәтен хәтерләтә. 1422—1445 елларда Казан ханы булган Гыйясетдин акчаларына лираны яисә кирәше тартылган җәяне хәтерләтүче тамга сугылган (59, 125, табл. XX, 2—6; XIV, 4—11). Шундый ук тамга Кырым ханы Сәгадәт Гәрәй хан мөһерендә дә бар (59, 125). Кайбер детальләрне исәпкә алмаганда, акчаларга сугылган әлеге тамгалар белән Фест түгәрәгендәге 40 рәсем бер-берсенә охшаш.

41. СӨЙӘК рәсеме түгәрәкнең А ягында 2 мәртәбә кабатлана һәм С тартыгын чагылдыра.

42. Бу рәсем В22 шакмагында гына кулланыла, Б тартыгын чагылдыра булса кирәк, ләкин нәрсә аңлатканын белеп булмады.

43. ИЛӘК. Рәсем В25 шакмагында кулланыла. Сүз ахырында К тартыгын белдерә. Рәсем атамасы шартлы рәвештә тәкъдим ителә.

44. ТӨРТКЕ. Рәсем А25 шакмагында кулланыла, Т тартыгын белдерә. Рәсем атамасы шартлы рәвештә тәкъдим ителә.

45. ӘН. Түгәрәкнең А ягында 2, В ягында 4 мәртәбә кабатлана. Тулысынча ӘН дип тә, АН дип тә укыла. Дулкын сыман өч сызык Су билгесе булып исәпләнелә. Бүгенге төрки телләрнең берсендә дә «су» ӘН дип аталмый ахрысы. Борынгы шумерларның алла исемнәрендә ЭН(ӘН) еш кулланыла. Мәсәлән, ЭНКИ (ӘНКИ) — су алласы (35, 177), ЭНЛИЛ (ӘНЛИЛ) — җил-давыл алласы (8, 131). Шумерда, Эриду шәһәрендә ЭНКИ ярым кеше, ярым балык кыяфәтендә сурәтләнгән (42, 111). Татар телендә ӘНКӘЙ (ана) сүзенең ӘНКӘ (90, III, 683) варианты да мәгълүм. Сүзне ӘНКӘ дип тә, ягъни Изге Җир, Изге Ана дип тә, ӘН-КӘ — Су улы Җир яки Ана дип тә аңларга була. Су билгесе шумер чөй язуында өч сызык белән аңлатыла (1, 100). «Су» шулай ук мисыр язуында (70, 54), хет язуында (26, 121), элам язуында (108, 29, рәс. 18; I-7, II-5, III-5) өч сызык ярдәмендә белдерелә. Борынгы Кытайның Инь чорында «тибу» («разлившиеся воды») вертикаль рәвештәге өч дулкынлы сызык белән белдерелә (49, 28), борынгы Кытайда «су», «елга» вертикаль өч сызык белән күрсәтелә (73, 208; 50, 421).

## 13. Фест түгәрәгенең уң ягындагы сүзләрне уку

А3 шакмагындагы сүз АНТЫМ дип укылды. (Шушы мәкаләнең 9 бүлеген кара).

А30. Рәсем атамалары шакмактагы тәртип буенча (уңнан сулга): ЭИ, АМ, КАЛКАН. Нечкә әйтелештә, сәкен юк, Ә сузыгына тәмамлана. Тиешле иҗекләрне җыябыз: ЭИ.АМ.КА. Укыла: ЭИЕМКӘ, исем, берлектә, беренче зат тартым кушымчасы белән төрләнә, юнәлеш килештә.

А29. Рәсем атамалары: ИР, ӘН, ИМИ. Нечкә әйтелештә, сәкен бар, М тартыгына тәмамлана. Тиешле иҗекләрне җыябыз: ИР.ӘН.ИМ. Укыла: ИРӘНЕМ, исем, берлектә, беренче зат тартым кушымчасы белән төрләнә, баш килештә.

А28. Рәсем атамалары: ИР, ИР, КОҢГЫЗ. Нечкә һәм калын әйтелештә, сәкен юк. А сузыгына тәмамлана. Ике тапкыр кабатланган ИР «ирләр» мәгънәсендә кулланыла (тау-тау, өем-өем дигәндәге кебек). «Ирләр» төшенчәсе ИР-АТ сүзе аша белдерелә. Укыла: ИР-АТКА, исем, формасы белән берлектә, мәгънәсе белән күплекне белдерә, юнәлеш килештә.

А27. Рәсем атамалары: АЛАБ, БУЛУН, АМ, КАРАУЛ. Калын әйтелештә, сәкен юк, А сузыгына тәмамлана. Тиешле авазларны, иҗекләрне җыябыз: А.Б.АМ.КА. Укыла: АБАМКА, исем, берлектә, беренче зат тартым кушымчасы белән төрләнә, юнәлеш килештә.

А26. Рәсем атамалары: ТУН, ӘН, ИМИ, КАЛКАН. Шакмакта ике сүз — берсе калын, икенчесе нечкә әйтелештә. Соңгы рәсем астында сәкен юк. Икенче сүз Ә сузыгына тәмамлана. Иҗекләрне җыябыз: ТУ.ӘН.ИМ.КА. ТУ иҗеге аерым әйтелә. ИМ иҗегенең И сузыгы киңәйтеп ИЕ дип әйтелә. КА иҗеге нечкә әйтелешкә күчә. Укыла: ТУ ӘНИЕМКӘ. ТУ — уңай сыйфат белдерүче сүз. ӘНИЕМКӘ — исем, берлектә, беренче зат тартым кушымчасы белән төрләнә, юнәлеш килештә.

A25. Рәсем атамалары: ТУН, ТӨРТКЕ, КАЛПАК. Калын әйтелештә, сәкен юк, А сузыгына тәмамлана. Иҗекләрне, бер авазны җыябыз: ТУ.Т.КА. Укыла: ТУТАКА, исем, берлектә, юнәлеш килештә.

A24. Рәсем атамалары: АЛАБ, МА, МӨГЕШ. Калын әйтелештә, сәкен юк, А сузыгына тәмамлана. Иҗекләрне җыябыз: А.МА.М. Укыла: АМАМА, исем, берлектә, беренче зат тартым кушымчасы белән төрләнә, юнәлеш килештә.

A23. Рәсем атамалары: КОШ, ШӨШЛЕ, К — ? Калын әйтелештә, сәкен юк, А сугызына тәмамлана. Авазларны һәм бер иҗекне җыябыз: КО.Л.К. Укыла: КОЛКА (КУЛКА), исем, берлектә, юнәлеш килештә.

A22. Рәсем атамалары: АЛАБ, СӨЙӘК, ТА, К — ? Шакмакта ике сүз, икесе дә калын әйтелештә, сәкен юк, соңгы сүз А сузыгына тәмамлана. Бер иҗекне, авазларны җыябыз: А.С.ТА.К. Укыла: АС ТАКА. АС — уңай сыйфат белдерүче сүз, ТАКА — исем, берлектә, юнәлеш килештә.

A21. Рәсем атамалары: ТИ, СӨЙӘК, АМ, ИМИ. Нечкә әйтелештә, сәкен юк, Ә сузыгына тәмамлана. Иҗекләрне, авазларны җыябыз: Т.С.АМ.ИМ. Укыла: ТӘСӘМИМӘ? ТӘСӘМЕМӘ? ТИСӘМЕМӘ?

A20. Рәсем атамалары: АЛАБ, САЙКА, Н — ? КАШКАРЫЙ. Шакмакта ике сүз, икесе дә калын әйтелештә, сәкен юк, ахыргы сүз А сузыгына тәмамлана. Иҗекләрне, авазларны җыябыз: А.СА.Н.К. Укыла: АС АНАКА. АС — уңай сыйфат белдерүче сүз, АНАКА — исем, берлектә, юнәлеш килештә.

A19. Рәсем атамалары: АЙР, ИАЙА. Калын әйтелештә, сәкен юк, А сузыгына тәмамлана. Бер авазны, бер иҗекне җыябыз: Р.ИА. Укыла: РАЙА, исем, берлектә, баш килештә.

A18. Рәсем атамалары: Ә-? ТУН, КӘМӘ, ИШКӘК, Н-? МӨГЕШ. Шакмакта ике сүз, икесе дә нечкә әйтелештә, сәкен юк, сүзләрнең икесе дә Ә сузыгына тәмамлана. Авазларны, иҗекләрне җыябыз: Ә.Т.КӘМӘ.И.Н.М. Укыла: ӘТЕКӘМӘ-ИНӘМӘ, икесе дә исем, берлектә, беренче зат тартым кушымчасы белән төрләнәләр, юнәлеш килештә.

A17. Рәсем атамалары: КОЙКА, ТИ. Калын әйтелештә, сәкен бар, Т тартыгына тәмамлана. Иҗек белән бер авазны җыябыз: КО.Т. Укыла: КОТ (КУТ), исем, берлектә, баш килештә.

A16. Рәсем атамалары: АЛАБ, КОШ, ШӨШЛЕ. Калын әйтелештә, сәкен бар, Л тартыгына тәмамлана. Авазларны җыябыз: А.К.Л. Укыла: АКЫЛ, исем, берлектә, баш килештә.

A15. Рәсем атамалары: АЛАБ, ТУН, ТУН, К-? , С-? , КЫРГЫЧ. Калын әйтелештә, сәкен юк, А сузыгына тәмамлана. Авазларны җыябыз: А.Т.Т.К.С.К. Укыла: АТТАКАСКА, исем, берлектә, юнәлеш килештә.

A14. Рәсем атамалары: КАРАУЛ, Н-? Калын әйтелештә, сәкен юк, А сузыгына тәмамлана. Иҗек белән авазны җыябыз: КА.Н. Укыла: КАНА, теләк белдерүче кисәкчә.




*Рәсем 4. Фест дисбесендәге сүзләрне уку үрнәкләре.*

A13. A16 шакмагындагы АКЫЛ сүзе кабатлана.
A12. A18 шакмагындагы ӘТЕКӘМӘ-ИНӘМӘ сүзләре кабатлана.
A11. A17 шакмагындагы КОТ (КУТ) сүзе кабатлана.
A10. A16 шакмагындагы АКЫЛ сүзе кабатлана.

A9. Рәсем атамалары: АЛАБ, ТУН, КАМЫТ, САЙКА, МӨГЕШ, ТУН. Шакмакта ике сүз, икесе дә калын әйтелештә, икесе дә А сузыгына тәмамлана. Беренче сүз МӨГЕШ рәсемендә тәмамлана, соңгы ТУН рәсеме ТА

теркәгечен белдерә. Авазларны һәм бер иҗекне җыябыз: А.Т.КА.С.М.Т. Укыла: АТАКАСЫМА ТА. АТАКАСЫМА — исем, берлектә, беренче зат тартым кушымчасы белән төрләнә, юнәлеш килештә. ТА — җыючы теркәгеч.

А8. Рәсем атамалары: МА, МӨГЕШ, КАПКАЧ, ТА. Шакмакта ике сүз, икесе дә калын әйтелештә, сәкен юк, А сузыгына тәмамлана. Иҗекләрне, бер авазны җыябыз: МА.М.КА.Т. Укыла: МАМАКА ТА. МАМАКА — исем, берлектә, юнәлеш килештә, ТА — җыючы теркәгеч.

А7. Рәсем атамалары: КОШ, ШӨШЛЕ, КАЛКАН. Калын әйтелештә, сәкен юк, А сузыгына тәмамлана. Авазларны һәм бер иҗекне җыябыз: КО.Л.К. Укыла: КОЛКА (КУЛКА), исем, берлектә, юнәлеш килештә.

А6. Рәсем атамалары: АЛАБ, НИЖДАГЪ, ТИ. Калын әйтелештә, сәкен юк, А сузыгына тәмамлана. Авазларны җыябыз: А.Н.Т. Укыла: АНТА. А5 шакмагындагы сүз белән бергә «һәм» теркәгече мәгънәсен белдерә.

А5. Рәсем атамалары: Н—?, ТА, К—? Нечкә әйтелештә, сәкен бар, К тартыгына тәмамлана. Авазларны җыябыз: Н.Т.К. Укыла: НӘТӘК. А6 шакмагындагы АНТА сүзе белән берлектә «һәм» теркәгече мәгънәсен белдерә.

А4. Рәсем атамалары: ИШКӘК, МИҢЛЕ, КАШКАРЫЙ. Нечкә әйтелештә, сәкен юк, Ә сузыгына тәмамлана. Авазларны җыябыз: И.Л.К. Укыла: ИЛКӘ, исем, берлектә, юнәлеш килештә.

А3. А15 шакмагындагы АТТАКАСКА сүзе кабатлана.

А2. Рәсем атамалары: НИЖДАГЪ, ТИ. Нечкә әйтелештә, сәкен юк, Ә сузыгына тәмамлана. Авазларны җыябыз: Н. Т. Укыла: НИТӘ? НӘТӘ? НИ ТӘ? НӘ ТӘ?

А1. А4 шакмагындагы ИЛКӘ сүзе кабатлана.

## 14. Фест түгәрәгенең сул ягындагы сүзләрне уку.

В30. Рәсем атамалары: АЛАБ, ДИ, АМ, ИМИ. Калын әйтелештә, сәкен юк. А сузыгына тәмамлана. Авазларны, иҗекләрне җыябыз: А.Д.АМ.ИМ. Укыла: АДАМЫМА, исем, берлектә, беренче зат тартым кушымчасы белән төрләнә, юнәлеш килештә.

В29. Рәсем атамалары: ТУН, ӘН, ИМИ, К—? А24 шакмагындагы ТУ ӘНИЕМКӘ сүзе кабатлана.

В28. Рәсем атамалары: Ә—? С—? Н—? МАЛАЙ. Шакмакта ике сүз, икесе дә нечкә әйтелештә, сәкен бар, соңгы сүз М тартыгына тәмамлана. Авазларны җыябыз: Ә.С.Н.М. Укыла: ӘС ӘНӘМ. ӘС — уңай сыйфат белдерүче сүз, ӘНӘМ — исем, берлектә, беренче зат тартым кушымчасы белән төрләнә, баш килештә.

В27. Рәсем атамалары: ДИ, КӘМӘ, ТУН. Шакмакта ике сүз, икесе дә нечкә әйтелештә. Сәкен юк, беренче сүз КӘМӘ иҗекләренә, икенче сүз Ә сузыгына тәмамлана. Иҗекләрне, бер авазны җыябыз:ДИ. КӘМӘ.Т. Укыла: ДИКӘМӘ ТӘ. ДИКӘМӘ — исем, берлектә, беренче зат тартым кушымчасы белән төрләнә, юнәлеш килештә. ТӘ — җыючы теркәгеч.

В26. Рәсем атамалары: КАРАУЛ, ӘЙ, ӘМ, КАЛКАН. Шакмакта калын һәм нечкә әйтелештәге ике сүз, сәкен юк. Соңгы сүз Ә сузыгына тәмамлана. Иҗекләрне һәм бер авазны җыябыз: КАРАУЛ. ӘИ. ӘМ. К. Укыла: КАРАУЛ ӘИЕМКӘ. КАРАУЛ сүзе сыйфат ролендә килә. ӘИЕМКӘ — исем, берлектә, беренче зат тартым кушымчасы белән төрләнә, юнәлеш килештә.

В25. Рәсем атамалары: САДАК, Н—? МӨГЕШ, ИЛӘК. Шакмакта калын һәм нечкә әйтелештәге ике сүз. Соңгы рәсем янында сәкен бар, К тартыгына тәмамлана. Иҗекләрне, авазларны җыябыз: САДАК.Н.М.К. Укыла: САДАКА НИМӘК. САДАКА — исем, берлектә, баш килештә, НИМӘК — фигыль.

В24. Рәсем атамалары: НИЖДАГЪ, ТИ, АИР, КАРАУЛ. Нечкә әйтелештә, сәкен юк, Ә сузыгына тәмамлана. Авазларны һәм бер иҗекне җыябыз: НИ.Т.Р.К. Укыла: НИТӘРЕКӘ, исем, берлектә, юнәлеш килештә.

В23. Рәсем атамалары: БАЛТА, ИМИ, НИЖДАГЪ, ТИ, МӨГЕШ. Нечкә әйтелештә, сәкен юк, Ә сузыгына тәмамлана. Авазларны җыябыз: Б.И.Н.Т.М. Укыла: БИНТЕМӘ, исем, берлектә, беренче зат тартым кушымчасы белән төрләнә, юнәлеш килештә.

В22. Рәсем атамалары: ДИ, С—?, Б—?, КӘМӘ. Нечкә әйтелештә, сәкен юк, Ә сузыгына тәмамлана. Иҗекләрне, авазларны җыябыз: ДИ.С.Б.КӘМӘ.

Укыла: ДИСБЕКӘМӘ, исем, берлектә, беренче зат тартым кушымчасы белән төрләнә, юнәләш килештә.

B21. Рәсем атамалары: ИМИ, ЭЙ, АМ, К—? Шакмакта ике сүз, икесе дә нечкә әйтелештә, сәкен юк. Соңгы сүз Ә сузыгына тәмамлана. Иҗекләрне, бер авазны җыябыз: ИМ.ЭЙ.АМ.К. Укыла: ИМ ЭИЕМКӘ. ИМ — сыйфат ролендә килә; ӘИЕМКӘ — исем, берлектә, беренче зат тартым кушымчасы белән төрләнә, юнәлеш килештә.

B20. Рәсем атамалары: Ә—?, ШӨШЛЕ, С—?, АМ. Шакмакта ике сүз, икесе дә нечкә әйтелештә, сәкен юк, соңгы сүз Ә сузыгына тәмамлана. Авазларны җыябыз: Ә.Л.С.М. Укыла: ӘЛ ӘСӘМӘ. ӘЛ — уңай сыйфат белдерүче сүз; ӘСӘМӘ — исем, берлектә, беренче зат тартым кушымчасы белән төрләнә, юнәлеш килештә.

B19. Рәсем атамалары: ТУН, КӘМӘ, КАШКАРЫИ, ТИ. Шакмакта өч сүз. Беренче сүз калын әйтелештә, икенче, өченче сүзләр нечкә әйтелештә. Сәкен юк, соңгы сүз Ә сузыгына тәмамлана. Иҗекләрне, авазларны җыябыз: ТУ.КӘМӘ. К.Т. Укыла: ТУ КӘМӘКӘ ТӘ. ТУ — сыйфат яки сан; КӘМӘКӘ — исем, берлектә, юнәлеш килештә; ТӘ — җыючы теркәгеч. Сүзне ТҮКӘМӘКӘ ТӘ дип тә укырга була.

B18. Рәсем атамалары: ИР, ЭЙ, ЭЙ, ӘМ, К—? Шакмакта ике сүз, икесе дә нечкә әйтелештә, сәкен юк, соңгы сүз Ә сузыгына тәмамлана. Иҗекләрне, авазларны җыябыз: ИР.ЭЙ.Э.М.К. Укыла: ИР ЭИЕМКӘ. ИР — сыйфат ролендә килүче исем; ЭИЕМКӘ — исем, берлектә, беренче зат тартым кушымчасы белән төрләнә, юнәлеш килештә.

B17. Рәсем атамалары: САДАК, КАМЫТ, МӨГЕШ. Калын әйтелештә, сәкен юк, А сузыгына тәмамлана. Иҗекләрне, бер авазны җыябыз: СА.КА.М. Укыла: САКАМА, исем, берлектә, беренче зат тартым кушымчасы белән төрләнә, юнәлеш килештә.

B16. Рәсем атамалары: ИР, КАРАУЛ, ТИ. Шакмакта ике сүз, икесе дә нечкә әйтелештә, сәкен юк, сүзләрнең икесе дә Ә сузыгына тәмамлана. Бер иҗекне һәм авазларны җыябыз: ИР.К.Т. Укыла: ИРКӘ ТӘ. ИРКӘ — исем, берлектә, юнәлеш килештә; ТӘ — теркәгеч.

B15. Рәсем атамалары: МА, К—? САИКА, АИР, КАРАУЛ. Шакмакта ике сүз, икесе дә калын әйтелештә, сәкен юк, сүзләрнең икесе дә А сузыгына тәмамлана. Иҗекләрне, авазларны җыябыз: МА.К.СА. Р.К. Укыла: МАКА САРКА. МАКА — уңай сыйфат белдерүче сүз; САРКА — исем, берлектә, юнәлеш килештә.

B14. Рәсем атамалары: Ә—? БАШЛЫК, ТУН, ТИ. Шакмакта ике сүз, икесе дә нечкә әйтелештә, сәкен юк, соңгы сүз Ә сузыгына тәмамлана. Авазларны җыябыз: Ә.Б.Т.Т. Укыла: ӘБЕТИ ТӘ. ӘБЕТИ — исем, берлектә, баш килештә; ТӘ — җыючы теркәгеч.

B13. Рәсем атамалары: ИР, С—?, ИМИ, КАЛПАК. Шакмакта ике сүз, икесе дә нечкә әйтелештә. Беренче сүз Ә сузыгына тәмамлана, икенче сүз азагында сәкен бар — К тартыгына тәмамлана. Иҗекләрне, авазларны җыябыз: ИР.С.ИМ.К. Укыла: ИРСӘ ИМӘК. ИРСӘ — исем, берлектә, баш килештә; ИМӘК — ярдәмче фигыль.

B12. Рәсем атамалары: ИР, КАЛПАК, НИЖДАГЪ. Нечкә әйтелештә, сәкен юк, И яки Е сузыгына тәмамлана. Авазларны һәм бер иҗекне җыябыз: ИР.К.Н. Укыла: ИРЕКНЕ (ИРЕКНИ), исем, берлектә, төшем килештә.

B11. Рәсем атамалары: ИР, ӘН, ИМИ. Нечкә әйтелештә, сәкен бар, М тартыгына тәмамлана. Иҗекләрне җыябыз: ИР.ӘН.ИМ. Укыла: ИРӘНЕМ, исем, берлектә, беренче зат кушымчасы белән төрләнә, баш килештә.

B10. Рәсем атамалары: ДИ, ИР, С—?, ИМИ, КАЛПАК. Шакмакта ике сүз, икесе дә нечкә әйтелештә. Беренче сүз Ә сузыгына тәмамлана, икенче сүз азагында сәкен бар — К тартыгына тәмамлана. Авазларны, иҗекләрне җыябыз: Д.ИР.С.ИМ.К. Укыла: ДИРСӘ ИМӘК. ДИРСӘ — фигыль, ИМӘК — ярдәмче фигыль.

B9. Рәсем атамалары: ТУН, КОҢГЫЗ, Н—?, КӘМӘ. Нечкә әйтелештә, сәкен юк, Ә сузыгына тәмамлана. Иҗекләрне, авазларны җыябыз: ТУ.К.Н. КӘМӘ. Укыла ТҮКӘНӘКЕМӘ, исем, берлектә, беренче зат тартым кушымчасы белән төрләнә, юнәлеш килештә.

B8. Рәсем атамалары: ИМИ, МӨГЕШ, К—? Нечкә әйтелештә, сәкен юк, Ә сузыгына тәмамлана. Авазларны, бер иҗекне җыябыз: ИМ.М.К. Укыла: ИММӘКӘ, исем, берлектә, юнәлеш килештә.

B7. Рәсем атамалары: ИМИ, ӘН, ИМИ. Рәсем атамалары нечкә әйтелештә булда да, сүз нечкә һәм калын әйтелештә. Сәкен бар, М тартыгына тәмамлана. Иҗекләрне җыябыз: ИМ.ӘН.ИМ. Укыла: ИМАНЫМ, исем берлектә, беренче зат тартым кушымчасы белән төрләнә, баш килештә.

B6. Рәсем атамалары: ИМИ, Н—?, МӨГЕШ, ӘИ. Шакмакта ике сүз, икесе дә нечкә әйтелештә. Сәкен юк, беренче сүз Ә сузыгына, икенче сүз Е (Ә) сузыгына тәмамлана. Иҗекләрне, авазларны җыябыз: ИМ.Н.М.ӘИ. Укыла: ИМНӘМӘ ӘИЕ. ИМНӘМӘ — сыйфат, ӘИЕ — исем, берлектә, өченче зат тартым кушымчасы белән төрләнә, баш килештә.

B5. B10 шакмагындагы ДИРСӘ ИМӘК сүзләре кабатлана.

B4. Рәсем атамалары: БАШЛЫК, КУИ, АИР, МӨГЕШ, ИМИ. Калын әйтелештә, сәкен юк, А сузыгына тәмамлана. Иҗекләрне, авазларны җыябыз: БА. КУ.Р.М.ИМ. Укыла: БАКУРАМЫМА, исем, берлектә, беренче зат тартым кушымчасы белән төрләнә, юнәлеш килештә.

B3. Рәсем атамалары: Ә—?, МА, К—?, Н—?, ИМИ. Нечкә әйтелештә, сәкен юк, Ә сузыгына тәмамлана. Иҗекләрне, авазларны җыябыз: Ә.МА.К. Н.ИМ. Укыла: ӘМӘКӘНЕМӘ, исем, берлектә, беренче зат тартым кушымчасы белән төрләнә, юнәлеш килештә.

B2. Рәсем атамалары: ИР, КОҢГЫЗ, Н—?, КӘМӘ. Нечкә әйтелештә, сәкен юк, Ә сузыгына тәмамлана. Иҗекләрне, авазларны җыябыз: ИР.К.Н. КӘМӘ. Укыла: ИРКӘНӘКЕМӘ, исем, берлектә, беренче зат тартым кушымчасы белән төрләнә, юнәлеш килештә.

B1. Рәсем атамалары: ӘН, ИМИ. Нечкә әйтелештә, сәкен юк, Ә сузыгына тәмамлана. Иҗекләрне җыябыз: ӘН.ИМ. Укыла: ӘНИЕМӘ, исем, берлектә, беренче зат тартым кушымчасы белән төрләнә, юнәләш килештә.

## 15. Фест түгәрәгенең уң ягындагы сүзләр һәм аларның аңлатмасы

A31. АНТЫМ.АНТ. Түгәрәктә бу беренче сүз. Дисбенең ике ягындагы барлык сүзләр диярлек шушы АНТЫМ сүзенә буйсынып килләр. Моннан өч-дүрт мең еллар элек яшәгән кеше АНТ игълан итә һәм антның кемнәргә багышланганлыгын белдереп, нәсел-нәсәбен санап, тезеп китә. АНТЫМнан соң килгән сүзләрнең күпчелеге туганлык терминнары. Арада дини, социаль-иҗтимагый терминнар-атамалар да бар. Монда шулай ук гадәти тормышкөнкүреш сүзләре дә очрый. Сүзләрнең күпчелеге -КА, -КӘ, -МА, -МӘ иҗекләренә тәмамлана. АНТның әлеге термин-атама ияләренә юнәлдерелгәнлеге текстның гомуми төзелешеннән, сүзләрнең үзара бәйләнешеннән яхшы аңлашыла.

АНТ сүзе күпчелек төрки телләрдә бүген дә актив кулланыла. Казах, кыргыз, кырым-татар, казан-татар, кумык, карай телләрендә АНТ (75, I, 237; 38, 69), Себер татарларының Тара диалектында АН (75, I, 226), госманлы-төрек, әзербайҗан телләрендә АНД (75, I, 238) дип атала.

A30. ӘИЕМКӘ. ӘИ. Бүгенге татар телендә ӨИ рәвешендә кулланыла торган сүзнең әүвәлге әйтелеше. Монда ӘИ гади торакны түгел, бәлки дини йолалар башкарыла торган гыйбадәтханәне белдерә.

A29. ИРӘНЕМ.ИРӘН. Бүгенге татар телендә бу сүз актив түгел. «Аңлатмалы сүзлек»тә ИРӘН «аллага якын кеше, изге кеше» дип аңлатылган (90, I, 414). Телдә шулай ук ГАИБ ИРӘННӘР дигән сүз тезмәсе дә бар (60, 173). Гаиб ирәннәр — «изге кешеләр» дигәнгә туры килә. Хәзерге төрек телендә ЕРЕН — алланы танып-белү серләренә төшенүче, игелекле кеше (60, 173). Казахча, кыргызча ЕРӘН — яшь ир кеше, көчле ир кеше, батыр (75, I, 758). Карай телендә ЭРӘН 1) яхшы, дәрәҗәле, күренекле, белемле, көчле, батыр; 2) ир кеше; 3) ир, хатын ире (38, 668). Уйгурча ӘРӘН — яхшы кеше, белемле, көчле, батыр кеше (75, I, 757). ИРӘНнең «сугышчы» мәгънәсе татар телендә «Туктамыш дастаны»нда сакланган. Дастанда:

Йөз баһадир ирәннән
Йорт-җиреңне бастырдың (2, 57), диелә.

Шумерча ЭРЕН И. М. Дьяконов аңлатмасында: сугышчы, эшче (31, 50), А. И. Тюменев аңлатмасында: эшчеләр (101, 232). Әлеге сүз ИРЕН фор-

масында. Геродотта да бар (18, IX, 85). Грекча ИРЕН — 20 яшьтән алып 30 яшькә кадәр булган яшь ирләр, спартаннар (85, 545, иск. 52).

Сүзнең иң әүвәлге формасы Фест дисбесендә, татар һәм грек телендә сакланган. ИРӘНне Ир һәм ӘН кисәкләреннән торган парлы сүз дип аңларга була. 20—30 яшьлек ир кеше, көчле кеше бик борынгы заманнарда, билгеле бер урында, билгеле бер шартларда аллага тиңләштерелгән һәм алланы алыштыра алган. ИРӘН сүзенең хәтта бүгенге телләрдә дә дини сүз буларак кулланылуы нәкъ шул турыда сөйли дә инде.

А28. ИР-АТКА. ИР-АТ. А29 шакмагындагы ИРӘНЕМ сүзе белән ИР-АТ бер-берсен ачыклап киләләр. Хәзерге татар телендә ИР—АТ гомумән ирләр (93, 173). Фест чорында да шундый ук мәгънәдә булгандыр дип фараз кылабыз.

А27. АБАМКА. АБА. Борынгы төрки телдә АБА—тудыручы ата-ана, ата-баба (29, 1). АБАның АБ формасы да бар. АЛАБ сүзенең АБ өлешен шул ук АБА дип аңлыйбыз. АБАның АПА варианты да мәгълүм. Борынгы төрки телдә АПА ТАРКАН (29, 47) титулны аңлаткан. АБА — бик борынгы ата-баба.

А26. ТУ ӘНИЕМКӘ. ТУ ӘНИ. ТУ — уңай сыйфат белдерүче сүз. ӘНИ — ана (93, 730). Сүзне «бөек, изге Ана дип аңларга була, шул ук вакытта бу «беренче, әүвәлге Ана» да була ала. ТУ ӘНИне конкрет ана дип түгел, бәлки мифик ана, бик борынгы ана дип аңлау дөресрәк булачак. ӘНИ сүзе бары казан татарларында гына сакланган. Бүгенге татар телендәге ДӘҮ ӘНИ (93, 141) әлеге ТУ ӘНИнең беркадәр үзгәргән әйтелеше булып тора. Моннан ике мең еллар элек Кече Азиядә, Каппадокиядә сугыш алиһәсе ЭНИО дип аталган (85, XII, II, 3).

А25. ТУТАКА. ТУТА. Татарча ТУТА — түтәй, абыстай (91, 429). Сүзне ТУ-ТА дип таркатабыз. Туганлык термины буларак ТУ-ТА атаның кыз туганын белдергән ахрысы. Татарча ТУТАШ (93, 558) чынлыкта ТУТАның «улын» ягъни атаның кыз туганының кызын аңлата.

А24. АМАМА. АМА. Бу сүз АМның тулырак формасы булып тора. АМА мифик ана түгел, бәлки реаль ана, тудыручы ана, сөйләүченең үз анасы. Татар теле диалектларында АМАМ сүзе бар. Мәгънәсе: апаем, ягъни энем-сеңлем, туганым (91, 37, 40). Сүзне АМА-М дип таркатсак, бу АМА улы булычак. Шумер телендә АМА — ана (31, 242), АМАР — хайван баласы, бозау (31, 50).

А23. КОЛКА. КОЛ (КУЛ). Гомум төрки сүз. Татарча КОЛ (93, 269).

А22. АС ТАКА. АС ТА. АС — уңай сыйфат белдерүче сүз, ТА — хатын-кыз затындагы кеше. Татар теле диалектларында АСТАЙ сүзе бар (91, 50). Сүзнең бүгенге мәгънәсе — «абыстай». АС ТА әлеге АСТАЙның әүвәлге формасы булса кирәк. АС ТАны «өлкән», «яхшы», «изге» ТА дип аңлыйбыз. Конкрет кемнең күз алдында тотылуын әйтеп булмый.

А21. ТӘСӘМИМӘ? ТӘСӘМЕМӘ? ТИСӘМЕМӘ? Бу сүзнең дөрес формасын һәм мәгънәсен ачыклап булмады.

А20. АС АНАКА. АС АНА. АС — уңай сыйфат белдерүче сүз. АНА— әни. АНА монда конкрет ананы түгел, алиһә ананы белдерә. В28 шакмагында ӘС ӘНӘМ сүзе бар. В27 шакмагында ДИКӘМӘ ТӘ диелә. ӘС ӘНӘ сүзе ДИКӘ сүзенә ялганып килә һәм ДИКӘнең кемлеген ачыклый. АС АНА белән ӘС ӘНӘ бер үк сүзнең төрлечә әйтелеше булырга мөмкин. Монда (А20 шакмагыннан соң) ДИКӘ телгә алынмый. Күрәсең, шуңа күрә АС АНА калын әйтелештә язылгандыр диярга була.

Алтай төркиләренең нәсел башы АШИНА дип аталган. Алтай төркиләре бүрегә табынганга күрә, бу сүзне гадәттә «бүре» дип аңлыйлар (21, 22—23). Төрекләрнең килеп чыгышы турындагы легендаларда АШИНА кабиләне тудыручы ана буларак аңлашыла (40, 112). Крит чорында АС АНАның АС ИНӘ формасы да булган ахрысы. Борынгы Греция территориясендә АСИНА топонимы булган (5, 47). Бүре дигән ерткыч ана да, инә дә була алмый, ул бары Ата гына була ала. Шулай булгач, АШИНА (АСИНӘ) яки АС АНА дип аталган алиһәне «бүре» дип аңлау хата.

А19. РАЙА. Җөмлә шушында тәмамлана. Ант бирүче кеше югарыда санап кителгән реаль һәм мифик туганнарына, якыннарына изге теләкләр белдерә. Ул аларга РАЙА тели. Бу сүз хәзерге русча РАИ җәннәт, оҗмах сүзенең тулы варианты булса кирәк. Логик яктан бу бары шулай гына булырга мөмкин. Төрки телләрдәге АЙ әлеге РАЙА—РАЙның кыскарган бер әйтелеше ахрысы. Татарча ОҖМАХ, борынгы төрки телдә УҖМАК (29, 621)

булган сүз кайчандыр, димәк, РАЙАдан соң килгән һәм АЙга (РАЙАга) очуны күз алдында тоткан. Борынгылар: үлгәч, изге кешеләрнең җаны оҗмахка эләгә, начар кешеләрнең җаны тәмугка эләгә дип исәпләгәннәр. Оҗмахка эләгү, оҗмахка керү ОЧУ-ОЧМАК сүзе белән белдерелгән. Алтай төркиләренең атаклы ил-гаскәр башлыгы Күл тәгиннең үлеме турында УЧДЫ (очты) диелә (84, 85, 419). Ятимә кыз Зөһрәнең айга менүе турындагы легендаларда: ятимнәр, ятимәләр изге булалар, үлгәч алар җәннәткә керәләр, ягъни РАЙАга очалар дигән бик борынгы караш ята.

A18. ӘТЕКӘМӘ-ИНӘМӘ. ӘТЕКӘ. ИНӘ. Боларның икесе дә гадәти, гомуми төрки сүзләр. Татарча ӘТКӘ, ӘТКӘЙ — әти (75, I, 844). Алабуга керәшеннәрендә ӘТЕКИ формасы да мәгълүм (91, 548). ИНӘ (әни) шулай ук киң таралган сүз. Татар теле диалектларында бу сүзнең ИНӘ, ИНӘЙ, ИНӘКӘЙ рәвешендәге әйтелешләре билгеле (91, 146—147). Дини татар карчыклары әле дә хәер-садака биргәч, дога калып, «әтекәмә-инәмә» дип багышлап куялар. Хәзерге телдә (диалектларда) ӘТЕКӘ, ИНӘ сүзләре конкрет ананы яки дәү әтине, дәү әнине белдерсә дә, Крит чорында аларның мәгънәсе башкачарак булгандыр кебек. Радлов заманында (моннан йөз еллар чамасы элек) казан татарлары кояшка «Кояш әтекәем-әнекәем» дип эндәшә торган булганнар (75, II, 674). Бәлки Крит чорында да бу сүзләр мифик ата-ана исәпләнелгән Кояшка карата кулланылгандыр?

A17. КОТ (КУТ). Гомум төрки сүз. Татар телендә КОТ җан, рух; нур, ямь; бәхет уңыш (90, II, 168).

A16. АКЫЛ. Гарәптән кергән дип уйланыла торган гомум төрки сүз. Татар телендә сүзнең төрле мәгънәләре бар: 1) кешенең уйлау, фикерләү сәләте, аңлылык дәрәҗәсе; 2) иҗтимагый аң, иҗтимагый фикерләү сәләте; 3) киңәш; 4) уй-фикер һ. б. (90, I, 39). Крит чорында да сүзнең мәгънәсе нигездә шундый ук булгандыр дип әйтәсе килә.

A15. АТТАКАСКА. АТТАКАС. АТТА. Иркәләп, яратып әйтелгән. Конкрет нинди «ата» булуы мәгълүм түгел. «Әтинең әтисе» булса кирәк. Татарда балалар телендә ӘТТӘ формасы мәгълүм.

A14. КАНА. Татар теле диалектларында теләк белдерүче кисәкчә буларак кулланыла (91, 193, мәгъ. 3). Мисал: «Җаңгыр җавармы? Җауса бик кана».

A13. АКЫЛ. A16 шакмагындагы сүз кабатлана.

A12. ӘТЕКӘМӘ-ИНӘМӘ. A18 шакмагындагы сүз кабатлана.

A11. КОТ (КУТ). A17 шакмагындагы сүз кабатлана.

A10. АКЫЛ, A16 шакмагындагы сүз кабатлана.

A9. АТАКАСЫМА ТА. АТАКАС. АТА. A15 шакмагында АТТА булган сүз биредә бер генә Т белән әйтелә. Бу бары «орфографик» хата гынамы, әллә монда мәгънә аермасы да бармы — моны әйтүе кыен. ТА — җыючы теркәгеч.

A8. МАМАКА ТА. МАМА. Әлеге сүз бүгенге көндә төрки түгел сыман аңлашыла. Билгеле булганча, МАМА русча «әни» дигәнне белдерә. Ләкин МАМА сүзе төркиләрдә дә бар. Үз вакытында В. В. Радлов теркәп калдырганча, казан-татар телендә МАМА — әби, дәү әни (75, IV, 2064) булган. Уйгурча МАМА карчык, әби (103, 92), үзбәкчә (диалектларда) МОМА бала имезүче хатын, әби (102, 270). Крит чорындагы МАМА «әнинең әнисе» булгандыр сыман.

A7. КОЛКА (КУЛКА). КОЛ (КУЛ). A23 шакмагындагы сүз кабатлана.

A6. АНТА. Хәзерге татар телендә АНДА буларак мәгълүм. Ләкин АНДА белән АНТАны бер үк мәгънәдәге сүзләр дип әйтеп булмый. АНДА татар телендә башлыча алмашлык буларак кулланыла һәм «кайда?» соравына җавап бирә. «Аңлатмалы сүзлек»тә АНДАның 4 нче мәгънәсе борынгы мәгънәгә якынрак. Мәсәлән, «Тизрәк кыймылдагыз анда!» дигән боерык җөмләдә АНДА сүзе «сез кайда?» соравына җавап бирми, бәлки «сез дә», «шулай ук» дигәнне белдерә. Татар теленең Нократ сөйләшендә АНДА СЫҢРА дигән сүз тезмәсе бар (25, II, 35). АНДА сүзенең СЫҢРА сүзен ачыклап килүе аның (АНДАның) Фест түгәрәгендәге АНТА НӘТӘК мәгънәсенә якынайта (A5 не кара).

A5. НӘТӘК. Бу сүз дә, АНТА кебек үк, теркәгеч булып килә һәм алар икесе бергә карала. Чыгытай телендә НӘТӘК нәкъ шуның кебек «точно так как», уйгурча НӘДӘК тә шул ук мәгънәдә (75, III, 682). Коръәннең XII—XIII гасырларда Урта Азиядә башкарылган тәфсирендә НӘТӘК (7, 228), борынгы төрки телдә НЕТӘГ (29, 358) кулланыла. (Мәгънәләре: шуның кебек үк, шу-

ның сыман). АНТА НӘТӘК сүзләрен тулаем «һәм шулай ук» дип аңларга була.

А4. ИЛКӘ. ИЛ. Төрки телләрдә ИЛ сүзенең төп мәгънәсе: җир-су, дәүләт, кабиләләр берләшмәсе, туган җир. Татарча КОРТ ИЛЕ — бал корты күче (оясы, умартасы) (93, 165), ИЛ-КӨН — халык (90, I, 379); ИЛ булып — бик күп булып, төркем-төркем булып (90, I, 378). Борынгы грек телендә ИЛА, ИЛЕ — төркем, көтү һ. б. (23, 821). Сүзнең борынгы грек телендәге мәгънәләре белән бүгенге татар телендәге мәгънәләре нигездә бер-берсенә тәңгәл. Дисбедәге ИЛ сүзе дә, күрәсең, шул ук мәгънәләрдә кулланылгандыр дип әйтергә була. ИЛ ул чынлыкта ИР (МИР) сүзенең Л варианты. «Кырык мир» күп кешене, кешеләр төркемен аңлаткан кебек, ИЛ дә күп кешене, төркемне һәм халыкны белдерә ала дип фикер йөртәбез.

А3. АТТАКАСКА. А15 шакмагындагы сүз кабатлана.

А2. НИТӘ? НӘТӘ? НИ ТӘ? НӘ ТӘ? Бу шакмактагы сүзнең дөрес әйтелешен һәм мәгънәсен ачыклап булмады. Кол Галинең 1839 елда Казан университеты табыгханәсендә басылган «Кыйссаи Йосыф» китабында (63 биттә):

Бәни ул угыллыкка кабул кылди,
Атама нәтә хаин улам имди,—

дигән юллар бар. Борынгы татар әдәбияты белгече Н. Ш. Хисамов НӘТӘ сүзенә «ничек» дигән аңлатма бирә (108а, 142).

А1. ИЛКӘ. ИЛ. А4 шакмагындагы сүз кабатлана.

## 16. Фест түгәрәгенең сул ягындагы сүзләр һәм аларның аңлатмасы

В30. АДАМЫМА. АДАМ. Бу — дөньядагы бик күп телләрдә кулланыла торган сүз. АДАМ сүзе Библиядән алынган дип, яһүдләрдән гарәпләргә күчкән, ислам дине белән төрки һәм башка халыкларга таралган дип уйланыла. Библиянең иң борынгы нөсхәсе б. э. к. XII гасыр азакларында, XI гасыр башларында барлыкка килгән. Шулай булгач, Библия Фест дисбесеннән кимендә 500 елга соңрак язылган. Библиядә сөйләнелгән миф буенча, Адам — дөньяда иң беренче кеше, Еваны (Һаваны) тудыручы һәм аның ире. АДАМ ның мәгънәсе — «кеше» (46, 14), ЕВАныкы — «тормыш» (46, 16) дип аңлатыла. Төзелеше буенча АДАМ — төрки. Ноль формада: АДА (АТА).

Түгәрәкнең сул ягында АДАМЫМА сүзеннән соң ТУ ӘНИЕМКӘ дигән сүз урнашкан. Бу сүзне без А26 шакмагында очраттык инде. Шуннан алда, А27 шакмагында АБАМКА сүзе урнашкан. Уң яктагы АБАМКА, ТУ ӘНИЕМКӘ сүзләре мәгънәләре буенча бер-берсенә ярашып киләләр. Иң элек АБА — ир затыннан булган нәсел башы, аннан соң ТУ ӘНИ — хатын-кыз затыннан булган нәсел башы телгә алына. Түгәрәкнең сул ягында да шул ук хәл кабатлана: иң элек, АДАМЫМ, аннан соң — ТУ ӘНИ. Димәк, АБА белән АДА бер үк мәгънәдәге сүзләр һәм аларның икесе дә ир затындагы ата-бабаны — нәсел башын белдерәләр. ТУ ӘНИ сүзе ике очракта да үзгәрешсез кала. АБА белән АДАның бер үк мәгънәдәге сүзләр булуын хәзерге татар телендәге АТА-БАБА (93, 43) дигән парлы сүз ярдәмендә исбатларга мөмкин.

Монда шуны да әйтергә кирәк, Фест дисбесе иҗат ителгән чорда ук АДАМ сүзе катып калган бик борынгы формада кулланылган. Дисбе телендә Т ләштерү өстенлек итә. Шулай була торып та, АТА, АТАМ булырга тиешле сыман урында АДАМ формасы кулланылган икән, димәк, бу сүзне Криттән читтәге башка хаким халыкныкы дип яисә Крит чорыннан да элегрәк яшәгән һәм дин-идеология мәсьәләсендә үз карашларын булдырган борынгырак, алдынгырак кабилә-диалект сүзе дип тә уйларга урын кала. Шул ук вакытта Критнең үзендә дә Д ләштереп сөйләшүче башка кабилә булган булуы ихтималын да истән чыгара алмыйбыз.

Татар сөйләм телендә бу сүз ӘДӘМ, әдәби телдә АДӘМ, казах, әзербайҗан, төрек һ. б. төрки телләрдә АДАМ (75, I, 486).

В29. ТУ ӘНИЕМКӘ. А26 шакмагындагы сүз кабатлана.

В28. ӘС ӘНӘМ. ӘС ӘНӘ. А20 шакмагындагы АС АНА сүзенең нечкә варианты ахрысы.

B27. ДИКӘМӘ ТӘ. ДИКӘ. ТӘ — җыючы теркәгеч. ДИКӘ сүзен B28 шакмагындагы ӘС ӘНӘМ сүзе белән бергә карарга кирәк. ДИКӘ — изге, бөек «ана»нең исеме. Борынгы грекларда ДИКЕ (ДИКА) Зевс белән Фемиданың кызы, хакыйкать һәм гаделлек алиһәсе (56, 83). Безнең ДИКӘ дә шул ук ДИКЕ (ДИКА) булса кирәк. Крит чоры төркиләрендә ДИКӘ ниндирәк эшләр белән идарә итүче алиһә булгандыр, әйтүе кыен.

B26. КАРАУЛ ӘИЕМКӘ. КАРАУЛ ӘИЕ. Хәзерге татар телендә КАРАВЫЛ ӨЕ (93, 228). Каравыл өйләре революциягә кадәр һәрбер авылда булган. КАРАУЛЫ — Су улы «балык» дигәнгә туры килә. B26 шакмагында «балык» сурәтләнгән дә. КАРА-УЛЫ сүзен шулай ук Җир дип тә аңлыйбыз. КАРАУЛ ӘИЕн Җиргә, Анага табынучылар өе дип беләбез. Җиргә, Анага багышланган гыйбадәтханәләрнең барысы да — Җир уллары. Мәсәлән, немецча «чиркәү» КИР-ХЕ (61, 337), урду телендә — ГИР-ҖА (22, 40), әзербайҗан телендә — КИЛ-СӘ (28, 93).

B25. САДАКА НИМӘК. Югарыда санап кителгәннәргә, ягъни: адамыма, ту әниемкә, әс әнәм Дикәмә тә, каравыл өемә САДАКА бирү турында сүз бара. Татарча САДАКА (сүзлектә: сәдака) (93, 498), төп мәгънәләре: хәер-сәдака, корбанның бер төре. НИМӘК — фигыль. Сүзне НИ-МӘК дип таркатабыз. НИ фигыле хәзерге татар телендә НИТҮ фигыле ясауда катнаша һәм шактый актив кулланыла (90, II, 444). НИТҮ белән БИРҮ фигыленең мәгънәләре бер-берсенә туры килә. НИМӘК фигыленең дә мәгънәсен шулайрак булырга тиеш дип фикер йөртәбез.

B24. НИТӘРЕКӘ. НИТӘРЕ. Бүгенге төрки телләрдә мондый сүз юк ахрысы. Борынгы мисыр телендәге Н.Т.Р.— алла (45, 98) булса кирәк. Татар телендәге ТӘРЕ сүзе шушы НИТӘРЕнең кыскарган варианты түгел микән дип әйтәсе килә. ТӘРЕ — «крест», ләкин аның «икона» мәгънәсе дә мәгълүм (75, III, 1065; 90, III, 225, 4 мәгънә). Мисырда да, Криттә дә аллалар сынын, сурәтен ясау тыелмаган, киресенчә, аларның сыннарын, сурәтләрен һәркайда (бигрәк тә КАРАУЛ ӘИләрендә) күрергә мөмкин булган. Кайчандыр төркиләрнең борынгы бабалары да алла сыннарын ясаганнар һәм аны НИТӘРЕ дип атаганнар, соңыннан ТӘРЕ сүзе кулланыла башлаган; ислам дине хакимлеге чорында исә «сурәткә табынучыларның» дини символлары — алла сурәтләре, иконалар, хачлар гомумән ТӘРЕ булып аңлашыла башлаган булырга мөмкин.

B23. БИНТЕМӘ. БИНТЕ. Төрки телләрдә моңдый сүз юк дип исәпләнелә. Гарәпчә БИН — ул (сын), БИНТ — кыз, кыз бала (16, 31; 32; 3, 88). Шулай да төрки телләрдә бу сүзнең калдыкларын очратырга мөмкин. Төрекчә БИНТ — кыз, кыз бала (100, 118). Татарда «Гуҗ бине Гонык» дигән сүз тезмәсе мәгълүм. БИНЕ монда «улы» дигәнгә туры килә. Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» китабында БИНТЕ сүзе очрый (41, 124—125, 471). Төрек телендәге БИНТ тә, «Кыйссаи Йосыф»тагы БИНТ тә чыннан да гарәптән алынган булырга мөмкин, ләкин гарәпнең үзенә бу сүз Крит чорыннан калган булырга тиеш дип фараз кылабыз.

B22. ДИСБЕКӘМӘ. ДИСБЕ. Татар әдәби телендәге ТӘСБИХ кайбер диалектларда (Гәйнә, Минзәлә, Камышлы якларында) ДИСБЕ дип атала (91, 126). ДИСБЕ әлеге Фест түгәрәгенең үзе.

B21. ИМ ӘИЕМКӘ. ИМ ӘИЕ. ИМ монда сыйфат ролендә килә. Татарча ИМ — ырым, им-том итү, дәвалау. (90, I, 384). Крит чорында ИМ сүзенең мәгънәсе башкачарак булган. Бу хакта B14—B6 шакмакларындагы сүзләрне кара.

B20. ӘЛ ӘСӘМӘ. ӘЛ ӘСӘ. ӘЛ — уңай сыйфат белдерүче сүз; ӘСӘ башкортча «ана», «инә», «әни» (78, 353). ӘСӘ белән ӘНӘ, АНА сүзләре арасында мәгънә аермасы булгандырмы, юктырмы — билгеле түгел. Ихтимал, бу сүз «дисбе»гә катнашы булган берәр алиһәне күз алдында тотадыр дип әйтергә була.

B19. ТУ КӘМӘКӘ ТӘ? ТҮКӘМӘКӘ ТӘ? Сүзнең мәгънәсен һәм төгәл формасын белеп булмады. B9 шакмагындагы ТҮКӘНӘКЕМӘ (ТҮКӘНӘК) сүзенең М варианты түгел микән?

B18. ИР ӘИЕМКӘ. ИР ӘИЕ. ИР сүзен Күк улы Буга (үгез) дип белсәк, ИР ӘИЕ ул БУГА (үгез) ӘИЕ булачак. Грек мифларында Криттә кеше ашаучы МИНОТАВР дигән үгез булуы турында сөйләнелә. Минотаврның гәүдәсе кешенеке кебек, башы үгезнеке кебек булган, имеш һәм ул Лабиринт дигән сарайда яшәгән, имеш (56, 144). Ләкин бу сүзнең гап-гади «ирләр

« » дигәнне белдерүе дә ихтимал. Әйтик, ИМ ЭИЕ — хатын-кызлар өе һәм гыйбадәтханәсе булса, ИР ЭИЕ — ирләрнең һәм яшүсмерләрнең (ирәннәрнең?) өе булачак.

B17. САКАМА. САКА. Бу сүз монда «патша» мәгънәсендә килә. Кара диңгез буе скифлары үзләрен СКОЛОТ дип атаганнар. Сүзнең мәгънәсе «патша кабиләләре» дигәнгә туры килә (18, IV, 6). Иран кешеләре урта гасырларда үзләреннән төньякта яшәгән күршеләрен (төркиләрне) САКАЛАБ дип атаганнар (4, VIII, 46), Абул Гази мифик Яфәс улларының берсен САКЛАБ дип атый (44, 39). СКОЛОТ сүзен иҗек методы нигезендә САКАЛАТ дип тулыландырабыз. Геродот САКАЛАТларны «пашта кабиләләре» дип атаган, димәк, САКА — «патша»,— ЛАТ — «улы» («кабиләсе») була. САКА-ЛАБ та «патша улы» («патша кабиләсе»). Татарча САКЧЫ (93, 464) шулай ук «патша улы», ягъни патшаның кораллы ире. Гап-гади САКАЛ (93, 463) сүзендә дә САКА — «патша», Л—«улы» дигәнне белдерә. Борынгы халыкларда (мәсәлән, борынгы мисырлыларда) сакал-мыек үстерү бары патшаларга гына хас нәрсә булган. 18 яшендә үлгән Тутанхамон фиргавеннең алтын маскасы сакаллы итеп эшләнгән (37, 44—45). Кайбер халыкларда бүгенге көндә дә сакал-мыек йөртү ирлек дәрәҗәсе билгесе исәпләнелә. Ашык уенында кулланыла торган иң авыр сөяк («сугышчы» сөяк) татарда САГА дип атала (93, 460).

B16. ИРКӘ ТӘ. ИР. Бу сүз монда «сугышчы»ны аңлата ахрысы.

B15. МАКА САРКА. МАКА САР. МАКА сүзе САРны ачыклап, аның уңай сыйфатын белдерә. МАКА — бөек, олуг, изге дигәнгә туры килә. МАКАның мондый мәгънәсе МАКТАУ сүзендә чагыла. МӘХӘББӘТ сүзендә дә МАКА-МӘХӘ иҗекләре уңай сыйфатны белдерә. САР сүзе «патша» дигәнгә туры килә. Дәрәҗәсе буенча САР САКАдан зуррак, бөегрәк «патша» булса кирәк. САРның «патша» булуына мисалларны төрле телләрдән табарга мөмкин. Борынгы мисыр телендә С.Р. — патша, юлбашчы (30, 43), шумер телендә ШАР — патша (114,10), аккад телендә ШАРРУ — патша (52,77), борынгы яһүд телендә ШАР — бәк, патша, хаким (115, 10), гарәп (Мисыр) телендә САР бәк (55, 41). Страбон заманында Гарәбстандагы рамманитлар кабиләсенең патшасы ИЛАСАР (85, XIV, IV, 24), Һиндстан патшасы АБИСАР (85, 650) дип аталган. Библиядә «филистимлян» патшаларының титулы СӘРАН (24, 42) дип атала. Һауса телендә САРКИ — юлбашчы, патша, әмир (85, 252), русча ЦАРЬ — патша (76, 691).

Госманлы-төрек, кырым-татар телләрендә СӘР баш, баш кеше, юлбашчы (75, VI, 456), кыргыз телендә САРА батырлык, көч-куәт (75, IV, 456), казах телендә САРКАДАН — яшь хатын (75, IV, 329). Татарча САРАЙ (93, 469) сүзен САР ӨЙЕ дип аңлыйбыз. Тарихи САРМАТ, САРКЕЛ һәм шулай ук Татарстандагы САРМАН атамаларындагы САР — иҗекләрен «патша» дип беләбез. САР-МАТ белән САР-МАН «патша улы» булса, САР-КЕЛ — «патша өе, торагы, бинасы» булачак.

Борынгы грек телендә САРКОФАГ сүзе баштарак таштан чокып ясалган табутны, соңга таба табут формасындагы каберне белдергән (82, 623). САРКОФАГны татарча САР КАБЫК дип төзәтәбез, бу исә үлгән САРны (патшаны) сала торган КАБЫК булачак. КАБЫК сүзе нәрсәнең дә булса тышчасын белдерә. Шул ук вакытта КАБЫК — «мәетне зиратка алып бару өчен агач кабыгыннан ясалган махсус носилка» (90, II, 12, 6, мәгънә 6).

Шулай итеп, тулаем МАКА САР сүзен «бөек патша» дип аңлыйбыз.

B14. ӘБЕТИ ТӘ. ӘБЕТИ. Татар теленең Чүпрәле, Тау ягы, Тархан, Чистай сөйләшләрендә ӘБЕТИ — «абыстай» (91, 539). ӘБЕТИнең кемлеге B13—B5 шакмакларындагы сүзләр белән бергә генә ачыклана.

B13. ИРСӘ ИМӘК. ИРСӘ — исем, ИМӘК — ярдәмче фигыль ИРСӘ сүзе ИР-СӘ дип таркатыла. ИР — ир кеше һәм шул ук вакытта Ата улы. ИР-СӘ — ир улы, ягъни ИРнең СӘсе. Хәзерге татар телендә ИРСӘнең ИРСӘК формасы мәгълүм. ИРСӘК — шелтә белән, яратмыйча әйтелә торган сүз. ИРСӘК — ирләрне ярата торган, ирләр артыннан чаба торган, ирләргә чамадан тыш омтыла торган хатын-кыз (90, I, 412).

B12. ИРЕКНЕ. ИРЕК. Сүзнең аңлатмасы B10 шакмагында.

B11. ИРӘНЕМ. ИРӘН. A29 шакмагындагы сүз кабатлана.

B10. ДИРСӘ ИМӘК. Төрки телдәге бу иң беренче «ташка басылган» тезмә сүзләрне бергә тикшереп карау отышлырак булачак. B14, B13, B12, B11, B10 шакмакларындагы сүзләрне яңадан күчерәбез: ӘБЕТИ ТӘ ИРСӘ ИМӘК, ИРЕКНЕ ИРӘНЕМ ДИРСӘ ИМӘК. Төп мәгънә шуңа кайтып кала: хәзергечә «абыстай» мәгънәсендәге ӘБЕТИ дә ИРСӘ, ягъни ир кешене яра-

тучы хатын-кыз имеш. ӘБЕТИнең кемлеге һәм аның теләге кыек сөйләм формасында бирелә. Безгә монда аңлашылмаган сүз дә юк сыман. Мәсәлән, ИРСӘ ИМӘК белән ДИРСӘ ИМӘК сүз тезмәләрендәге ИМӘК ярдәмче фигыль булып килә. Хәзергечә моны ИМЕШ дип аңларга була. Бу сүз шулай ук ДИМӘК (93, 130) сүзенең Д тартыгы төшеп калган варианты булырга да мөмкин. ИРӘНнең кемлеге билгеле. Бары ИРЕК сүзе генә беркадәр аптырау тудыра. ИРләр яратучы «абыстай»ның ИРӘНе, имеш, ИРЕК булып чыга. Моны ничек аңларга?

ИРЕК гомум төрки сүз. Татар телендә ИРЕКнең мәгънәләре: шәхси азатлык, бәйсезлек, хөрлек, иркенлек, теләк, ихтыяр һ. б. (90, I, 406). Борынгы төрки телдә ЕРК көч, ихтыяр, көч-куәт, хакимият (29, 179). Җыеп әйткәндә, ИРЕК (ЕРК) ул көч-куәт һәм көч-куәткә ия булу нәтиҗәсендә үзеңне бәйсез, хөр, ихтыярлы итеп тою. Ләкин ирләр яратучы ӘБЕТИнең ниндидер абстракт хөрлекне, абстракт азатлыкны үзенең ИРӘНе дип белүе мөмкин түгел.

ӘБЕТИ үзе кем соң? Әлеге сүз ТӘ теркәгече белән әйтелә. Моны без киңәйтеп: барлык хатын-кызлар кебек, ӘБЕТИ дә ирләр ярата дип аңлыйбыз. Кара диңгез буе скифларының ТАБИТИ дигән алиһәсе булган. ТАБИТИ грекларның ГЕСТИЯ дигән алиһәләренә тиң (18, IV, 59). ТАБИТИ белән ӘБЕТИне без бер үк сүз дип беләбез. Сүз башындагы артык Т грекча әйтү яисә язу өчен яраклаштырып өстәлгән булырга да, шул ук вакытта ӘБЕТИнең бик борынгы «диалекталь» вариантын чагылдырырга да мөмкин. Грекларда ГЕСТИЯ ут-учак алиһәсе, ягъни Ут-ана (56, 67). Шулай итеп, безнең ӘБЕТИ дә Ут-ана, ут алиһәсе булып чыга (Текстның дәвамы В9, В8, В7, В5 шакмакларында).

В9. ТҮКӘНӘКЕМӘ. ТҮКӘНӘК. Татар теле диалектларында ТҮКӘН, ТҮКӘНЕМ, ТҮКӘЛӘ сүзләре билгеле. ТҮКӘЛӘ кечкенә ир балага карата әйтелә (90, II, 286); ТҮКӘН Гәйнә, Камышлы якларында «бүлтерек», «кечкенә буйлы кеше» дигәнне белдерә (91, 448, 110); ТҮКӘНЕМ «кечкенә балаларга иркәләп әйтелә; үскәнем, нәнием» (90, III, 286). Иркәләп әйтелгән ТҮКӘНӘК сүзе дә әлеге ТҮКӘН, ТҮКӘНЕМ, ТҮКӘЛӘ сүзләре белән мәгънәдәш дип уйлыйбыз. Тик шулай да монда ТҮКӘНӘК «кечкенә буйлы», «бүлтерек» була алмый. Монда ул «кече туганым», «сеңлем» дигәнгә туры килә.

В8. ИММӘКӘ. ИММӘ. Сүзне ИМ һәм МӘ кисәкләренә бүләбез. Бөтен мәсьәлә ИМ иҗекләрен ничек аңлауга кайтып кала. ИМне ике төрле аңларга була: 1) ИМ — «ана» дигәнне белдерә. ИМ-МӘ — Ана улы, кыз (хатын-кыз); 2) ИМ — «җенси мөнәсәбәт» мәгънәсендәге фигыль булган очракта, ИМ МӘ — «им эшләре белән шөгыльләнүче МӘ» була. ИМ сүзенең бүгенге татар телендәге мәгънәсе аның күбрәк фигыль булуы ихтималына ишарәли. ИММӘ ул ИРСӘ хатын һәм ул ӘБЕТИнең ТҮКӘНӘГЕ — сөекле «сеңлесе».

В7. ИМАНЫМ. ИМАН. Татар телендә ИМАНның мәгънәләре: аллага, пәйгамбәрләргә, диннең төп нигезләренә ышану: ышаныч, ышану, инану (90, I, 385).

В6. ИМНӘМӘ ЭИЕ. В21 шакмагындагы ИМ ЭИЕнең тулырак формасы ахрысы. ИМНӘМӘ ЭИЕ — им эшләре белән, ягъни дини проституция белән шөгыльләнү өе.

В5. ДИРСӘ ИМӘК. Дүрт юллык тезмә шушында тәмамлана. Ут анасы ӘБЕТИ үзенең сөеклесе ИММӘгә ИМАНын (тулы ышанычын) белдерә һәм ИМНӘМӘ ЭИЕн аның карамагына тапшыра. Икенче төрле итеп әйткәндә, ЭИ хуҗасы Ут-ана ИММӘнең (ТҮКӘНӘКЕнең) эшен хуплый, чөнки ул үзе дә хатын-кыз затыннан.

Криттә, Кнос сарае калдыклары арасында җиде кат бала итәкле озын күлмәк кигән, тулы күкрәкле, озын толымлы яшь, чибәр алиһә сыны табылган (83, табл. 60, 63). ӘБЕТИ дип аталган алиһә шул үзе түгел микән дип әйтәсе килә. Болай дип уйлау өчен кайбер ышанычлы дәлилләр дә бар. Борынгы төркиләр карашынча, җир җиде катлы, күк җиде катлы. Алиһә, билгеле, Җирне чагылдыра. Алиһәнең югары күтәрелгән кулларында — берәр елан, баш киеме өстендә — сакчы эт. Ул чибәр, яшь, ләкин куркыныч. Ул чыннан да Ут-ана булса кирәк. Шушы уңайдан татарның ут турында «күрергә күркәм, тотарга куркам» дигән мәкален искә төшерергә була. Чибәр, булдыклы, дәртле хатын-кыз турында «ут кебек!» дигән сүз дә бар. ӘБЕТИнең бала итәкле күлмәген татар хатын-кызларының милли киеме саналган бала итәкле күлмәк белән чагыштыра алабыз. Дөрес, алиһәнең күлмәге җиде бала итәкле, бүгенге хатын-кызның күлмәге — ике-өч кенә бала

итәкле була. Ләкин алиһә белән гади хатын-кызны тиңләп булмаганлыгы үзеннән-үзе аңлашыла булса кирәк. Аннан соң, Каюм Насыйри әйткәнчә, XIX гасыр татар хатын-кызлары бала итәкле күлмәкләрне бик үк яратмаганнар һәм андый күлмәкне бары җиңел холыклы хатын-кызлар гына кия дип исәпләгәннәр (13, 239). Димәк, алар хаклы булганнар!

B4. БАКУРАМЫМА. БАКУРАМ. Сүзнең төгәл мәгънәсен белеп булмады. Чыгытай телендә БАКУР—зур (75, IV, 1443) дигәнне белдергән. Чыгытай сүзенең БАКУРАМга берәр төрле катнашы бармы-юкмы, әйтүе кыен.

B3. ӘМӘКӘНЕМӘ. ӘМӘКӘНӘ. ӘМӘ.— ана, әни мәгънәсендәге АМАның нечкә әйтелеше, КӘНӘ — Ана улы, кыз. Тулаем сүзне «кыз туганыма» дип аңларга була.

B2. ИРКӘНЕКЕМӘ. ИРКӘНӘК. Сүз башындагы ИР иҗекләре КӘНӘ-(К)нең ир затыннан булуын күрсәтә. Мәгънәсе: «ир туганыма».

B1. ӘНИЕМӘ. ӘНИ. A26 шакмагындагы (ТУ)ӘНИЕМКӘ сүзенең гадирәк формасы.

## 17. Фест түгәрәгендәге (дисбедәге) сүзләрнең тулы исемлеге

**а/ уң як**

A31. АНТЫМ (antym)
A30. ӘИЕМКӘ (ejemkä)
A29. ИРӘНЕМ (iränem)
A28. ИР-АТКА (ir-atqa)
A27. АБАМКА (abamqa)
A26. ТУ ӘНИЕМКӘ (tu äniemkä)
A25. ТУТАКА (tutaqa)
A24. АМАМА (amama)
A23. КОЛКА (КУЛКА) qolqa (qulqa)
A22. АС ТАКА (as taqa)
A21. ТӘСӘМИМӘ? ТӘСӘМЕМӘ? ТИСӘМЕМӘ? (täsämimä? täsämemä? tisämemä?)
A20. АС АНАКА (as anaqa)
A19. РАЙА (raja)
A18. ӘТЕКӘМӘ-ИНӘМӘ (ätekämä-inämä)
A17. КОТ (КУТ) qot (qut)
A16. АКЫЛ (aqyl)
A15. АТТАКАСКА (attaqasqa)
A14. КАНА (qana)
A13. АКЫЛ (aqyl)
A12. ӘТЕКӘМӘ-ИНӘМӘ (ätekämä-inämä)
A11. КОТ (КУТ) qot (qut)
A10. АКЫЛ (aqyl)
A9. АТАКАСЫМА ТА (ataqasyma ta)
A8. МАМАКА ТА (mamaqa ta)
A7. КОЛКА (КУЛКА) qolqa (qulqa)
A6. АНТА (anta)
A5. НӘТӘК (nätäk)
A4. ИЛКӘ (ilkä)
A3. АТТАКАСКА (attaqasqa)
A2. НИТӘ? НӘТӘ? НИ ТӘ? НӘ ТӘ? (nitä? nätä? ni tä? nä tä?)
A1. ИЛКӘ (ilkä)

**б/ сул як**

B30. АДАМЫМА (adamyma)
A29. ТУ ӘНИЕМКӘ (tu äniemkä)
B28. ӘС ӘНӘМ (äs änäm)
B27. ДИКӘМӘ ТӘ (dikämä tä)
B26. КАРАУЛ ӘИЕМКӘ (qaraul ejemkä)

B25. САДАКА НИМӘК (sadaqa nimäk)
B24. НИТӘРЕКӘ (nitärekä)
B23. БИНТЕМӘ (bintemä)
B22. ДИСБЕКӘМӘ (disbekämä)
B21. ИМ ӘИЕМКӘ (im ejemkä)
B29. ӘЛ ӘСӘМӘ (äl äsämä)
B19. ТУ КӘМӘКӘ ТӘ? ТҮКӘМӘКӘ ТӘ? (tu kämäkä tä? tümäkä tä?)
B18. ИР ӘИЕМКӘ (ir ejemkä)
B17. САКАМА (saqama)
B16. ИРКӘ ТӘ (irkä tä)
B15. МАКА САРКА (maqa sarqa)
B14. ӘБЕТИ ТӘ (äbeti tä)
B13. ИРСӘ ИМӘК (irsä imäk)
B12. ИРЕКНЕ (ИРЕКНИ) irekne (irekni)
B11. ИРӘНЕМ (iränem)
B10. ДИРСӘ ИМӘК (dirsä imäk)
B9. ТҮКӘНӘКЕМӘ (tükänäkemä)
B8. ИММӘКӘ (immäkä)
B7. ИМАНЫМ (imanym)
B6. ИМНӘМӘ ӘИЕ (imnämä eje)
B5. ДИРСӘ ИМӘК (dirsä imäk)
B4. БАКУРАМЫМА (baquramyma)
B3. ӘМӘКӘНЕМӘ (ämäkänemä)
B2. ИРКӘНӘКЕМӘ (irkänäkemä)
B1. ӘНИЕМӘ (äniemä)

## 18. Фест дисбесе турында кайбер өстәмә фикерләр

Менә без Фест дисбесендәге серле язуларны төрки телләр нигезендә «укып» чыктык. Дисбедәге язуларның эчтәлегеннән күренгәнчә, бу юка балчык кисәге борынгы гыйбадәтханәдә корбан (ант), хәер-сәдака биргәндә һәм кайбер дини йолаларны башкарганда кулланылган булырга тиеш. Түгәрәкне тотып утырган кеше (ихтимал, хатын-кыз затыннан булган дин башлыгы) аны әкрен генә ике куллап әйләндерә-әйләндерә, бармакларын рәсем-билгеләр өстеннән шудырып, дога сүзләрен әйтеп барган. Доганың эчтәлеге бик гади: корбан, сәдака бирүче иң элек мифик ата-анасына, якын туганнарына, аллага мөрәҗәгать итә һәм шуның белән корбанның (сәдаканың) кемнәргә багышланганлыгын белдерә. Шул ук вакытта ул үлгәннәргә — оҗмах (райа), исәннәргә — бәхет, акыл тели. Болай караганда, язуның эчтәлеге тулысынча дини дип әйтергә була. Шуның белән бергә, түгәрәк балчык кисәгендә санап кителгән һәр төрле исем-атамаларда Крит чоры төркиләренең яшәеше, дини карашлары, социаль катлаулары чагыла.

Дисбедәге күпчелек рәсем-билгеләрнең төрки атамалары табылды дип исәпләргә тулы нигез бар. Мәсәлән, 12 нче һәм 2 нче («калкан» белән «сугышчы») рәсемнәренең бергә АЛАБ сүзен белдерүе бернинди шик тудырмаска тиеш дип уйлыйм. Шулай ук 7 рәсем ИМИ, 9 рәсем БАШЛЫК, 10 рәсем ИШКӘК, 12 рәсем КАЛКАН, 15 рәсем БАЛТА, 17 рәсем КАПКАЧ, 18 рәсем МӨГЕШ, 25 рәсем КӘМӘ, 27 рәсем ТУН, 30 рәсем КУИ, 41 рәсем СӨИӘК һ. б. сурәтләренең исемнәре дә җисемнәренә тулысынча туры килә.

Фест дисбесендә әлегә бик үк аңлашылып җитмәгән рәсем-билгеләр дә бар. Мәсәлән, 35, 36, 37, 42, 43, 44 рәсемнәрнең дөрес атамаларын тәкъдим итеп булмый. Төгәл атамасы билгеле булмаган, ләкин дисбедәге шакмакларда берничә мәртәбә кабатланган рәсемнәрнең нинди авазны белдерүен чагыштыру юлы белән ачыкларга мөмкин. Мәсәлән, ниндидер яфраклы агачнымы, яфракнымы, ботакнымы сурәтләгән 35 рәсем 11 мәртәбә кабатлана һәм һәр очракта Къ, К тартыкларын белдерә. 36 рәсемдә дә ниндидер агач яисә үсемлек сурәтләнгән. Бу рәсем дүрт мәртәбә кабатлана һәм һәр очракта С тартыгын белдерә. 42, 43, 44 рәсемнәр берәр мәртәбә генә кулланыла һәм, әйтелгәнчә, аларның нәрсә аңлатканнары билгеле түгел. Әлеге рәсемнәрнең нинди авазларны чагылдырулары алар урнашкан шакмактагы башка рәсем-билгеләрнең дөрес атамаларына нигезләнеп билгеләнә.

Мәсәлән, A25 шакмагында өч рәсем бар: беренче (27) рәсем ТУН, икенче (44) рәсемнең атамасы билгеле түгел, өченче (8) рәсем КАЛПАК дип атала.

ТУН да, КАЛПАК та дисбедә еш кабатлана һәм аларның нинди авазларны чагылдырулары билгеле. Беренче иҗек ТУ дип, өченче иҗек КА дип укыла. Уртада аңлаешсыз бер яисә бернича иҗек булырга тиеш. А27, А26 шакмакларындагы АБАМКА, ТУ ӘНИЕМКӘ сүзләре туганлык терминнары төренә карыйлар. Димәк, А25 шакмагындагы сүз дә туганлык термины булырга тиеш. Билгесез 44 рәсем Т тартыгын белдерсә, сүзне тулаем ТУ-ТА-КА дип укырга була (һәм ул шулай укыла да). Дөрес, бу сүзнең ТУ-ГАН-КА булуы да ихтимал дип уйларга була. Ләкин ул чагында 44 рәсемнең атамасында ГАН иҗекләре булуын исбатларга кирәк булыр иде. Аннан соң, АБАМКА, ТУ ӘНИЕМКӘ сүзләреннән соң ТУГАНКА сүзе килә аламы һәм гомумән ТУГАН үзе туганлык термины булырга мөмкинме? Тагын шунысы да бар: А27—А24 шакмакларындагы АБАМКА, ТУ ӘНИЕМКӘ, (ТУТАКА), АМАМА сүзләренең урнашу тәртибенә игътибар итсәк, иң әлек АБАМКА — ир затындагы «туган»ның, аннан соң хатын-кыз затындагы «туган»нарның урнашуын күрербез. ТУГАН сүзенең төрки телдә җенес күрсәткече юк — ул кыз туган да, ир туган да булырга мөмкин.

Шулай итеп, 44 рәсем Т тартыгын белдерә һәм А25 шакмагындагы сүз ТУ-ТА-КА дип укыла.

Сүз ясауда башлыча рәсем-билге атамаларының башлангыч авазлары һәм иҗекләре катнаша. Ләкин 3, 26, 39 рәсем атамаларының соңгы авазлары һәм иҗекләре кулланыла. 3 рәсем МИҢЛЕ, 26 рәсем ШӨШЛЕ дип аталды һәм бу рәсемнәр ЛЕ иҗеген чагылдыралар. 39 рәсем АИР дип аталды һәм сүз ясауда аның соңгы Р тартыгы катнаша. Бүгенге тел гыйлемендә төрки телләрдә Л, Р тартыкларына башланган саф төрки сүзләр юк дип исәпләнелә (14, 66). Күрәсең, Крит чоры төрки телдә дә исемнәре Л, Р тартыкларына башланган әйберләр булмаган һәм шунлыктан әлеге тартыкларны рәсем-билге ярдәмендә чагылдыру кыенлык тудырган. Моның өчен Л Р тартыклары сүз ахырына туры килә торган исемле рәсемнәрне сайларга туры килгән. Минә шушы хәл үзе генә дә Фест дисбесе теленең төркилегенә дәлил булып тора дип уйлыйбыз.

Дисбедәге рәсем-билгеләрне сайлауда тагын бер үзенчәлек күзгә ташлана. Бу үзенчәлек Къ, К тартыкларына кагыла. Әйтелгәнчә, бу тартыклар 14 төрле рәсем-билге ярдәмендә белдерелә. Ундүрт рәсем-билге атамасының уникесе калын Къ тартыгын, икесе нечкә К тартыгын чагылдыра. Нечкә К тартыгын белдерүче КӘМӘ сүзендә генә К тартыгы сүз башында килә. 43 рәсем К тартыгын белдерсә дә, аның төгәл атамасы билгеле түгел. Шулай итеп, монда тагын кызык хәл барлыкка килә. Димәк, Фест дисбесен иҗат иткәндә атамасы нечкә К тартыгына башланган һәм рәсемдә чагылдырырга мөмкин булган әйберләрне сайлау шулай ук кыенлык тудырган. Шуңа күрә сүздәге нечкә К тартыгын белдерү өчен исеме калын Къ тартыгына башланган рәсем-билгеләрдән файдаланырга туры килгән.

Кайбер сүзләрнең төгәл әйтелешен ачыклап булмады. А21, А2, В19, В12 шакмакларындагы сүзләрнең дөрес формасы, В4 шакмагындагы сүзнең мәгънәсе билгеле түгел. Шулай ук А28 шакмагындагы ИР-АТКА, В24 шакмагындагы НИТӘРЕКӘ сүзләре турында да башкачарак фикер йөртергә мөмкинлекләр бар кебек.

Хәзер дисбегә беркадәр формаль яктан күз төшереп алыйк.

Ни өчен түгәрәк бу язу? Әйтелгәнчә, аны ике куллап тотып, капшап укуы җайлырак булган, күрәсең. Шулай да төп сәбәп анда түгел. Түгәрәк эчендәге сызыклар спиральне хәтерләтә. Спираль ул — бөгәрләнгән елан һәм кояш символы. Фест түгәрәге дә бөгәрләнгән еланны, ягъни кояш символын чагылдыра. Түгәрәкнең ике ягындагы сызыклар туры мәгънәсендә еланга охшатып эшләнгән. Спираль үзәгенә туры килә торган А1 һәм В1 шакмакларын хасил итүче сызыклар очлайтып, елан башы сыман итеп тәмамланган. Очлаеп торган «башлардагы» рәсемнәр күз сурәтен хәтерләтә.

Дисбенең уң ягындагы спираль 31 шакмакка, сул ягы 30 шакмакка бүленгән. Уң якта А18 шакмагында бергә әйтелә торган, димәк, шул чорларда ук инде фразеологик формулага әйләнгән ӘТЕКӘМӘ-ИНӘМӘ сүзләре урнаштырылган. А12 шакмагында шул ук сүзләр яңадан кабатлана. ӘТЕКӘМӘ-ИНӘМӘне шулай да ике сүз дип исәпләргә туры килә. Түгәрәкнең уң ягына, шулай итеп, 31 сүз түгел, 33 сүз сыйдырылган булып чыга. Без монда ТА-ТӘ теркәгечләрен, ТУ-ТҮ сыйфатларын исәпкә алмыйбыз. Кайбер сүзләр гомумән икешәр мәртәбә кабатлана. Мәсәлән, ИЛКӘ, КОЛКА, КОТ, АКЫЛ һ. б. Мондый кабатлау бары сүз исәбен арттыру өчен генә кирәк булгандыр

дигән тәэсир туа. Түгәрәкнең сул ягында да икешәр мәртәбә кабатланган сүзләр бар. Сул яктагы 30 шакмакка барлыгы 34 сүз сыйдырылган.

Дисбенең А ягын ике мәртәбә әйләндереп, андагы сүзләрне укый-укый санап барсак, барлыгы 66 сүз барлыкка киләчәк. Дисбенең сул ягын бер мәртәбә әйләндереп, сүзләрне санап барсак, 34 сүз барлыкка киләчәк. 66 га 34 не кушсак, 100 булачак. Шушы уңайдан без ТӘСБИХны искә төшерәбез. Тәсбихта 99 төймә була. Һәр 33 төймәдән соң «тәсбих анасы» куела. Тәсбихның эре төймәләр тезеп, чуклап ясалган башы «тәсбих мулласы» дип атала. Тәсбих тартучы дога сүзләрен санап әйтә, ләкин ул «бер», «ике» дип һәр төймәне санап тормый, бер дога сүзен әйтү белән, бер төймәне шудырып кына куя. «Тәсбих анасы» белән «тәсбих мулласы» аңа сан исәбен ялгыштырмаска ярдәм итә.

Фест дисбесе дә, тәсбих та бер үк принципка нигезләнгән. Шуңа күрә Фест түгәрәген балчыктан ясалган беренче ДИСБЕ дип тә әйтә алабыз. Түгәрәктәге сүзләр саны, түгәрәкнең гомуми характеры гына түгел, В22 шакмагындагы ДИСБЕКӘМӘ сүзе дә моның шулай икәнлеген раслый.

## ФАЙДАЛАНЫЛГАН ХЕЗМӘТЛӘР


1. Авдиев В. И. История Древнего Востока. 1953.
2. Бакиров М. Х. Бәет эволюциясенә бер караш.— К-та: Татар фольклоры жанрлары. Казан, 1978.
1. Баранов Х. К. Арабско-русский словарь. Изд. пятое, переработанное и доп. М., 1977.
4. Бартольд В. В. Сочинения, т. VIII, М., 1973.
5. Блаватская Т. В. Греческое общество второго тысячелетия до новой эры и его культура. М., 1976.
6. Бломквист Е. Э. К вопросу о двуязычии и тюркских заимствованиях в говоре «уральцев» Амударьинского оазиса.— «Сборник Музея антропологии и этнографии». XXVIII, Л., 1972.
7. Боровков А. К. Лексика среднеазиатского тефсира XII—XIII вв., М., 1963.
8. Брентьес Б. От Шанидара до Аккада. М., 1976.
9. Буриан Я. Моухова Б. Загадочные этруски. М., 1970.
10. Была ли Атлантида островом в Средиземном море. «Курьер ЮНЕСКО», 1976, июнь.
11. Войтов В. Благосклонное «море муссонов».— «Вокруг света», 1978, № 2.
12. Войтов В. Последние станции.— «Вокруг света», 1978, № 4.
13. Воробьев Н. И. Казанские татары. Казань, 1953.
14. Гаджиева Н. З. О трех этапах изменений анлаутных согласных.— К-та: Тюркологический сборник. 1974, М., 1978.
15. Галанопулос А. Г., Бэкон Э. Атлантида. За легендой — истина. М., 1983.
16. Гарәпчә-татарча, русча алынмалар сүзлеге. (Татар әдәбиятында кулланылган гарәп һәм фарсы сүзләре). Авторлары: Хәмзин К. З., Мәхмүтов М. И. Сәйфуллин Г. Ш. Казан, 1965.
17. Георгиев В. Дешифровка текста диска из Феста.— «Вестник древней истории», 1977, № 1.
18. Геродот. История в девяти книгах. Л., 1972.
19. Гохман В. И. К реконструкции древнекитайской системы терминов родства.— «Советская этнография», 1978, № 6.
20. Грюнберг А. Л. К диалектологии дардских языков (глангали и земиаки).— К-та: Индийская и иранская филология. Вопросы диалектологии. М., 1971.
21. Гумилев Л. Н. Древние тюрки. М., 1967.
22. Давидова А. А. Учебник языка урду. II. М., 1970.
23. Дворецкий И. Х. Древнегреческо-русский словарь, т. I—II. М., 1958.
24. Джаукян Г. Б. Хайасский язык и его отношение к индоевропейским языкам. Ереван, 1964.
25. Диалектологик сүзлек. Төзүчеләре: Борһанова Н. Б., Махмутова. Л. Т., II чыгарылыш, Казан, 1953.
26. Дирингер Д. Алфавит. М., 1963.
27. Долгопольский А. Б. Материалы по сравнительно-исторической фонетике кушитских языков: губные и дентальные смычные в начальном положении.— К-та: Языки Африки. М., 1966.
28. Донидзе Г. И. Об аффиксальном словообразовании в тюркской топонимии.— К-та: Ономастика Востока. М., 1980.
29. Древнетюркский словарь. Л., 1969.
30. Дьяконов И. М. Семито-хамитские языки. М., 1965.
31. Дьяконов И. М. Языки древней Передней Азии. М., 1967.
32. Дэвлет М. А. Большая Боярская писаница. М., 1976.

33. Зайдлер Л. Атлантида. М., 1976.
34. Ипсен Г. Фестский диск (опыт дешифровки).— К-та: Тайны древних письмен. Проблемы дешифровки. М., 1976.
35. История Древнего Востока. М., 1979.
36. История искусства зарубежных стран. Первобытное общество. Древний Восток. Античность. М., 1980.
37. Каир, тысячелетие города, 969—1969 г.г. Министерство культуры ОАР. Организация по делам печати. (Чыккан елы һәм урыны күрсәтелмәгән).
38. Караимско-русско-польский словарь. Под редакцией Баскакова Н. А., Зайончковского А., Шапшала С. М. М., 1974.
39. Ки-Зербо Ж. Мастера каменного века. Предыстория Африки в наскальной живописи.— «Курьер ЮНЕСКО», 1979, сентябрь—октябрь.
40. Кляшторный С. Г. Древнетюркские рунические памятники как источник по истории Средней Азии. М., 1964.
41. Кол Гали. Кыйссаи Йосыф (Йосыф турында кыйсса). Казан, 1983.
42. Кондратов А. Адрес — Лемурия? Л., 1978.
43. Кондратов А. М., Шеворошкин В. В. Когда молчат письмена. М., 1970.
44. Кононов А. Н. Родословная туркмен. Сочинение Абу-л-Гази хана хивинского. М.-Л., 1958.
45. Коростовцев М. А. Египетский язык. М., 1961.
46. Косидовский З. Библейские сказания. М., 1978.
47. Кошгари М. Туркий сузлар девони (Девону луготит турк), I, Тошкент, 1960.
48. Краснов Ю. А. Древнейшие упряжные пахотные орудия. М., 1975.
49. Крюков М. В. Язык иньских надписей. М., 1973.
50. Крюков М. В., Хуан Шу-ин. Древнекитайский язык. (Тексты, грамматика и лексический комментарий). М., 1978.
51. Ленцман Я. А. Ранние рабовладельческие государства в Эгейском бассейне.— К-та: Всемирная история. т. I, гл. XV. М., 1955.
52. Липин Л. А. Аккадский язык. М., 1961.
53. Мазанов А. А. Использование изобразительных материалов для изучения этнографии татарского народа.— К-та: Из истории культуры и быта татарского народа и его предков. Казань, 1976.
54. Мелларт Дж. Древнейшие цивилизации Ближнего Востока. Перевод с английского и комментарий Антоновой Е. В. М., 1982.
55. Мец А. Мусульманский Ренессанс. М., 1966.
56. Мифологический словарь. Авторы: Ботвинник М. Н., Коган М. А., Рабинович М. В., Селецкий С. П. Л., 1961.
57. Молчанов А. А. Таинственные письмена первых европейцев. М., 1980.
58. Мусаев К. М. Лексика тюркских языков в сравнительном освещении (Западно-кыпчакская группа). М., 1975.
59. Мухамадиев А. Г. Булгаро-татарская монетная система XII—XV в.в. М., 1983.
60. Наджип Э. Н. Историко-сравнительный словарь тюркских языков XIV века, книга I. М., 1979.
61. Немецко-русский словарь. М., 1940.
62. Никонова О. Н., Цвиллинг М. Я. Русско-немецкий словарь. Изд. седьмое, исправленное и доп. М., 1977.
63. Ольгин Л. Овчары Крита.— «Вокруг света». 1983, № 4.
64. Ошеров С. Словарь мифологических и географических названий и имен.— К-та: Гомер. Илиада. М., 1978.
65. Пейрос И. И., Старостин С. А. О генетическом сравнении китайского и тибетского языков (фонетические соответствия).— К-та: Ранняя этническая история народов Восточной Азии. М., 1977.
66. Пелих Г. И. Элементы переднеазиатской культуры у нарымских селькупов.— Труды Томского госуниверситета им. В. В. Куйбышева. Сборник научных работ исторических кафедр. Томск, 1963.
67. Пендлбери Дж. Археология Крита. Перевод с английского. М., 1950.
68. Перепелкин Ю. Я. Египет Нового царства.— К-та: Всемирная история. т. I, гл. XII. М., 1955.
69. Петерс Б. Г. О морском деле в Эгейском море.— К-та: История и культура античного мира. М., 1977.
70. Петровский Н. С. Египетский язык. Л., 1958.
71. Платон. Сочинения в 3-х томах. т. 3, ч. I, М., 1971.
72. Плахотная О. Праславяне на Крите? — «Советская Россия», 29 апреля 1984 г.
73. Позднеева Л. Д. Китайская письменность.— К-та: «Древний Восток». Книга для чтения. М., 1953.
74. Прокофьева Е. Д. Представления селькупских шаманов о мире.— «Сборник Музея антропологии и этнографии». XX. М.-Л., 1961.
75. Радлов В. В. Опыт словаря тюркских наречий. СПб., 1893—1911.
76. Резанов И. А. Атлантида: реальность или фантазия? М., 1975.
77. Родословное древо тюрков. Сочинение Абуль Гази, Хивинского хана. Перевод и предисловие Саблукова Г. С. Казань, 1906.
78. Русско-башкирский словарь. Под ред. Дмитриева А. К., Ахмерова К. З., Баишева Т. Г. М., 1948.

79. Русско-татарский словарь. Под редакцией Ганиева Ф. А., М., 1984.
80. Русско-чувашский словарь. М., 1971.
81. Следзевский И. В. Хаусанские эмираты Северной Нигерии.
82. Словарь иностранных языков. Под ред. Лехина И. В. и Петрова Ф. Н. Изд. пятое, стереотипное. М., 1955.
83. Соколов Г. Эгейское искусство. Альбом. М., 1971.
84. Стеблева И. В. Поэзия тюрков VI-VIII веков. М., 1965.
85. Страбон. География. Л., 1964.
86. Стратановский Г. А. Примечания к книге «Геродот. История в девяти книгах». Л., 1972.
87. Струве В. В. Средиземноморские страны Передней Азии и Аравия в первой половине I тысячелетия до н. э.— К-та: Всемирная история. т. I, гл. XIX. М., 1955.
88. Сыромятников Н. А. Древнеяпонский язык. М., 1972.
89. Татарская АССР. Административно-территориальное деление на 1 января 1972 года. Казань. 1973.
90. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Өч томда. Казан, 1977—1981.
91. Татар теленең диалектологик сүзлеге. Казан, 1969.
92. Татар халык иҗаты. Иола һәм уен җырлары. Казан. 1980.
93. Татарча-русча сүзлек. М., 1966.
94. Терещенко Н. М. Ненецкий язык.— К-та: Языки народов СССР, III. М., 1966.
95. Тодаева Б. Х. Язык монголов Внутренней Монголии. Материалы и словарь. М., 1981.
96. Томсон Дж. Исследования по истории древнегреческого общества. Доисторический эгейский мир. М., 1958.
97. Томчина Б. И. Бамана. Терминология родства ду.— К-та: Африканский этнографический сборник. Х. Л., 1972.
98. Топорова И. Н. Материалы к описанию фонологических систем языков манде и гвинейской группы в связи с проблемами типологии.— К-та: Языки Африки. М., 1966.
99. Тувинско-русский словарь. Под ред. Тенишева Э. Р. М., 1968.
100. Турецко-русский словарь. М., 1977.
101. Тюменев А. И. Государственное хозяйство древнего Шумера. М.— Л., 1956.
102. Узбекско-русский словарь. Под ред. Кары-Ниязова Т. Н. и Боровкова А. К. Ташкент, 1941.
103. Уйгурско-русский словарь. Составили Баскаков Н. А. и Насилов В. М. М., 1939.
104. Фельдман-Конрад Н. И. Японско-русский учебный словарь иероглифов. Изд. второе, переработанное и доп. М., 1977.
105. Фрезер Дж. Золотая ветвь. М., 1931.
106. Фридрих И. История письма. М., 1979.
107. Хазанов А. М. Очерки военного дела сарматов. М., 1971.
108. Хинц В. Государство Элам. М., 1977.
108а. Татар әдәбияты тарихы. Алты томда. 1 том. Казан, 1984.
109. Хокс Дж. Первые домашние животные.— «Курьер ЮНЕСКО», 1967, май.
110. Хәйруллин Ә. Галимнең кульязма мирасы.— «Казан утлары», 1984, 1 сан.
111. Чеслинг У. Среди кочевников северной Австралии. М., 1966.
112. Чувашско-русский словарь. М., 1961.
113. Чэдуик Дж. Дешифровка линейного письма Б.— К-та: Тайны древних письмен. М., 1976.
114. Шилейко В. К. Вотивные надписи шумерийских правителей. Пг., 1915.
115. Шифман И. Ш. Финикийский язык. М., 1963.
116. Элиан. Пестрые рассказы. Перевод с древнегреческого, статья, примечания и указатель Поляковой С. В. М.— Л., 1964.
117. Юсупов Г. В. Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. М.— Л., 1960.

## Язучы Нурихан Фәттахның «Фест дисбесенең сере» исемле хезмәтенә карата

1908 елда, Крит утравына урнашкан Фест шәһәре янындагы борынгы сарай калдыкларын казыганда табылган серле «язу»лы диск күп еллардан бирле бөтендөнья галимнәренең игътибарын үзенә җәлеп итә. Андагы «язу»ларны төрле ил галимнәре төрле телләр, башлыча һинд-европа һәм семит телләре нигезендә «укып» караганнар. Н. Фәттах исә бу «башваткыч»тагы серле язуларны төрки телләр ярдәмендә «укып», үз версиясен тәкъдим итә. Аның бу хезмәте В. И. Ульянов—Ленин исемендәге Казан дәүләт

университеты татар теле кафедрасының киңәйтелгән утырышында тикшерелде. Тикшерүдә университетның татар әдәбияты кафедрасы һәм СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты галимнәре дә катнашты. Тикшерүдә чыгыш ясаучылар хезмәтнең уңай һәм кимчелекле якларын билгеләп үттеләр һәм түбәндәге нәтиҗәгә килделәр: язучы Н. Фәттахның бу хезмәте гамәлдәге тел гыйлеме методларына нигезләнмәгән. Ул — Фест дискысы турындагы хезмәтләрне, мифологияне, матди һәм рухи культура тарихын һәм борынгы халыкларның фәлсәфи карашларын өйрәнүгә нигезләнеп, язучының иҗат фантазиясе нәтиҗәсендә барлыкка килгән гипотеза. Ләкин гипотезалар, билгеле булганча, тикшеренүчеләрнең һәм киң катлау укучыларның игътибарын моңа кадәр чишелмәгән катлаулы мәсьәләләргә юнәлтәләр. Бу — беренчедән. Икенчедән, Н. Фәттахның бу «башваткыч»ны чишү логикасы, ягъни ул тәкъдим иткән ысул да кызыклы һәм гыйбрәтле. Өченчедән, мондый характердагы хезмәтләр укучыларны, мәгълүм күләмдә фән дөньясындагы кызыклы фикерләр, ачышлар белән таныштыралар, галимнәрнең игътибар үзәгендә торган проблемалар турында сөйлиләр.

Югарыда әйтелгәннәрне һәм Фест дискысының серен чишү мәсьәләсе күпсанлы журнал укучыларында зур кызыксыну уятканын искә алып, редакция язучы Н. Фәттахның зур күләмле хезмәтенең дискыдагы «язу»ны укуга багышланган өлешен укучыларга тәкъдим итә.

# ЯШӘЕШ ГАМЕ

Күренекле язучыбыз Гомәр Бәшировның «Җидегән чишмә» дилогиясен укучылар ихлас куанып, бик җылы каршы алганнар иде. Әсәрнең фикерле, хисле булуы, һәр җәһәттән килгәнлеге сокландырды аларны. Кешеләр күңеленә ул «Җидегән чишмә» көе моңнарыдай кереп калды.

Шуңа да карамастан, яңа басмасын әзерләгәндә, таләпчән әдип төгәлләнгән әсәрне әле тагын өч-дүрт ел буена камилләштерә килгән икән. Дүрт томлы «Әсәрләр»енең өченче томында ул без белгән яшел-зәңгәр тышлы дилогияне нибары бер китапка калдырган, аны нәкъ ун басма табакка кыскарткан: чын сәнгать әсәре дәрәҗәсендә язылган күренешләрне, отышлы коллизияләрне, мавыктыргыч ситуацияләрне, шул җөмләдән хәтта кайбер ялкынлы мәхәббәт, халәт, кичереш тасвирларын да төшереп калдырган, нигезле тәнкыйть фикерләренә колак салып, шактый картиналарны үзгәрткән, җыйнаклаткан. Яңа басмага боларның тик каймагын, иң кирәклеләрен генә керткән. Шул ук вакытта әсәрнең ваемы, табигать, яшәешкә бәйле гаме арта төшкән. Нәтиҗәдә ул тагы да төзегрәк, пөхтәрәк, җегәрлерәк романга әйләнгән, образлар җанлырак, калкурак гәүдәләнгән, эстетик тәэсир сизелерлек арткан.

Әсәр, барыннан да бигрәк, концепциянең үткенлеге, җитдилеге белән игътибарны тарта. Ул торган җиребез, туган илебез табигатен күз карасыдай саклау, алдагы буыннарга аны сәламәт, бөтен килеш тапшыру мәсьәләсен яктырта, моның тирән-философик мәгънәсен чагылдыра. Мәгълүм ки, техника, промышленность үсеше бер кеше гомерендә генә дә тирә-юньгә байтак йогынты ясап ташлады.

«— Әнә Швеция нинди бай ил инде,— дип сөйли әсәрнең бер герое профессор Фазыл Шәмсиев.— Ул булып ул табигатьнең башына җитеп килә. Аның барлык инеш һәм күлләре, шакшы калдыкларга тончыгып, үле суга әверелгән... Кешелек дөньясы сулыш ала торган һава куркыныч астында калып бара. Кислород кими, ә углекислота елданел арта бара. Американың завод-фабрикалары белән автомобильләре ел саен һавага йөз кырык ике миллион тонна газ, сөрем, төтен очыра. Хәзер Американың үзе өстендәге кислород аның халкына суларга җитми» (195 б.) Табигатьне сөючеләр конференциясендә бер уңайдан үзебезнең Кабан күле һәм Болак та искә алына, аны чистарту, тирәягын ямьләндерү мәсьәләсе күтәрелә.

Төп вакыйгалар Ык буенда, авыл җирендә бара. Әдип монда укучылар игътибарын табигатьнең аеруча гүзәл, поэтик күренешләренә — чишмә, тугайларына юнәлтә. Әсәрдә алар җыр, легендаларга төреп бирелә, ягъни аларның халык күңелендә тирән тамыр җибәргәнлекләре, кыйммәтле рухи хәзинәгә әверелгәнлекләре искәртелә. Романда умартачы Минһаҗ карт, мәктәпне яңа гына тәгәлләп чыккан Гайнан, механизатор Салихҗан Турай, әдип Камил Дусаев, район газетасы редакторы Дәрҗия кебекләрнең Ык буе гүзәллеген саклау өчен көрәшләре тасвирлана. Минһаҗ картның, Гайнанның эше, шөгыле дә турыдан-туры табигать беләмәләрендә уза. Әсәрдәге персонажлар табигатьнең сулышын, катлаулы серләрен сизгер тоючы, тирәнтен аңлаучы зирәк акыл ияләре итеп биреләләр. Алар яшел бишегебезгә саксыз кагылуның, алдын-артын уйламыйча эш итүнең көтелмәгән тискәре нәтиҗәләр бирү ихтималын алдан ук күңелләре белән сизеп торалар. Автор авыл кешеләренә хас булган фикер кыюлыгы, кыргый гүзәллеккә соклану тойгысын бик югары бәяли. Каманың күтәрелүе аркасында Ык буе болыннарын су басу ихтималы, Татарстанда урманнарның унбиш-уналты процентка гына калып баруы роман геройларын тирән хафага төшерә. Тагын шунысы да бар: тирә-юнь матурлыгы турында риясыз кайгыртып йөрүче бу мәрхәмәтле, нечкә күңелле кешеләрнең әхлак принциплары бик югары, саф булуына, илкөн гаме белән яшәүләренә, эшкә талымсыз, намуслы, туры сүзле булуларына басым ясала. Алар кайберәүләр холкындагы, эш-гамәлендәге кечкенә чатаклыклар белән дә килешмиләр. Көндәлек тормышта халык зирәклегенә, сыналган, яхшы дип табылган сәламәт әхлак кануннарына таяналар.

Әсәрдә коммунист Минһаҗ карт илгә азатлык яулап алышкан, колхозны бүгенге югарылыкка күтәрешкән, куркәп үсүче җимеш бакчасы, умарталык тергезүче итеп, Гайнан исә эстафетаны дәвам иттерүче, киләчәккә алып баручы итеп сурәтләнә. Бу тын-

гысыз җаннар эрозиягә каршы көрәшне, су ашаган чокыр канауларны тигезләү, нығыту, инешкә буа буу эшләрен башлап йөриләр. Гайнан тирә-як хозурлыгын саклау турында газеталарда гыйбрәтле, үткен мәкаләләр язып бастыра. Авылдашлары арасында ул гаҗәеп самими, мөлаем, саф күңелле, киң карашлы булуы, эшне җиренә җиткереп, матур итеп башкаруы белән хөрмәт казана.

Камил, Минһаҗ, Гайнаннарга читтән килеп урнашкан колхоз председателе Ризван Чурмантаев белән бигрәк тә кискен бәрелешергә туры килә. Чурмантаев — үтә сай карашлы, бүгенге көн белән генә яшәүче, каптым-йоттым принцибы белән эш итүче туң йөрәкле бәндә. Аны Җидегән авылының киләчәге дә, урман-болыннарыйның иминлеге, ямьлелеге дә кызыксындырмый. Бүген макталса, премия эләксә — шул җиткән. Аныңча, табигать моңарчы үзенең кыргый законнары буенча яшәгән, хәзер аны тәртипкә кертергә вакыт җиткән. Ул, урманга көтү кертеп, яшь үрентеләрне таптата, имгәтә, урманны яңару мөмкинлегеннән мәхрүм итә, Алтынбикә тугаен сөрдереп, кара туфрагын ташкын белән агыза, рентабельле түгел дип (хуҗалыктагы берәр традицион тармакны бетерергә йөргән чакта иң еш телгә алына торган аргумент), алма бакчасын ташландык хәлгә төшерә, җиде тамырдан тибеп чыккан гүзәл чишмәләрне бульдозер белән актарта, суларын торбаларга кертеп, тирә-юньдәге экологик балансны җимерергә ниятли, язгы чәчү өстендә тургайларның, кош-кортларның күпләп кырылуына юл куя, химикатлар, агулы орлыклар белән эш итүчеләрне тәртипкә чакырмый, агротехника кагыйдәләрен үтәүне таләп итми. Бу хәлләр, бигрәк тә чишмәләрнең актарылып ташлануы, әсәрдән күренүенчә, Минһаҗ картның йөрәгенә төзәлмәслек яра сала.

Шуңа да карамастан, Ризван үзен иң белдекле, дөрес фикер йөртүче дип исәпли. Аның хәтта күренекле әдипкә ничегрәк язу турында киңәшләр бирәсе килә, булышырга, уңай геройлар табып китерергә вәгъдә итә.

Әсәрдә Ризванның сөйләм теле бик колоритлы бирелгән. Ул болай ди: «И шулай ук папирос белән обеспечить итү проблемасын да бүгенге көннән башлап, техника кумаенча гына, эш урынында хәл итү чараларын күздән кичерү мәсьәләсе белән оешкан төстә шөгыльләнәбез» (39 б.). Бу фикерне, «папирос сатуны кырга күчерәбез», дип, ике-өч сүз белән аңлатырга мөмкин булыр иде. Ләкин алай анык һәм кистереп әйтсәң, ул вәгъдәне үтәргә кирәк була. Ризванның исә максат башкачарак — күзгә төтен җибәрә тору. Шуңа күрә ул проблеманы хәл итү чараларын күздән кичерү мәсьәләсе белән шөгыльләнү турында гына әйтә — куян шулпасының шулпасы кебегрәк килеп чыга.

Аның теленә фикердәше Фәсхи теле бик якын тора.

«— Сүзегезгә куәт булсын, Ризван Нурмиевич, сез күтәргән мәсьәләне мин барыннан да бигрәк политический ягыннан алга сөрәм!» (59 б.)— дип сөйли ул. Соңгы кырык ел эчендә авыл җирендәге барлык оешмаларда берәр-икешәр тапкыр җитәкче булып әйләнеп чыккан бу агай туган телендә кешечә гади, төгәл сөйләү сәләтен югалтып бара кебек тоела.

Яңа басмада геройларның рухи дәрәҗәсе тагын да тирәнтенрәк ачыла төшкән, Ризванның тупаслыгы, сөмсезлеге гыйбрәтле вакыйгада күрсәтелгән. Хәл эчендә ятучы Минһаҗ белән сөйләшеп торган җирдән ул, аның карчыгы Сөембикәгә дәшеп:

«— Алдан әйтеп куюы читен, конечно. Ну, бәлкем, машина-мазар кирәк булыр, әйттерерсең, яңасын бирербез» (382 б.),— ди, үлмәс борын ук авыруны күмү хәстәренә керешә.

Дилогия варианты Ризван Чурмантаевны колхоз председательлегеннән төшерү белән тәгәлләнә иде. Өченче томда автор мәсьәләне алай җиңелләштереп хәл итү юлы белән китмәгән. Ул авыл халкының Ризванга ачы нәфрәтен, нәләтен сиздерү белән чикләнгән. Минһаҗ аңа җир-суның кадерен дә, рәтен дә белмәве, авыл кешесенең тормыш рәвешен, ничек сулаганын аңламавы хакында әйтә һәм авылдан китәргә киңәш итә. Ләкин Ризван әле позициясен тиз генә бирердәй күренми. Ул әле Җидегәннең кирелеген сындырырга, Гайнан, Турайларны, майлагандай, күндәм машинага әйләндерергә, һәр сүзенә закон көче бирергә хыяллана. Әле аның белән байтак чәкәләшергә туры киләчәк.

Г. Бәширов кешелек җәмгыяте күләмендәге әһәмиятле тема күтәреп, бар җиһанга чаң сугып, үз иҗатындагы һәм дөнья әдәбиятындагы иң күркәм традицияләрне дәвам иттерә, тәҗрибәне иҗади казанышлар белән баета, әдәбиятның яңа мөмкинлекләрен ачып җибәрә. Тик бу җәһәттән бер үзенчәлекне генә ачыклап китәргә кирәк. Табигать — ул, нигездә, статик күренеш. Әдәбият исә тормышны үз барышында, агышында күрсәтергә ярата. Табигатьне саклау проблемасы «Җидегән чишмә»нең хәрәкәтчәнлеген сүрелдерми ме соң? Иң әүвәл шунысын әйтергә кирәк: табигать монда, кайбер әсәрләрдәге кебек, фон итеп кенә бирелми. Ул яшәешнең үзе, төп шарты дип карала. Чөнки табигатьтән башка җан иясе минут та тора алмый. Шул ук вакытта, элекке кайбер карашлардан үзгә буларак, табигтьнең үзенең дә бик нечкә, уалучан, яраланучан күренеш икәнлеге раслана. Биредә аның мөстәкыйль язмышы — кешенең рәхим-шәфкатенә, мәхәббәтенә, сак мөнәсәбәтенә бәйле язмышы тасвирлана. Әсәрдә табигать юмарт, мәрхәмәтле, һәрчак игелекле, ләкин кешеләр ярдәменә мохтаҗ булган яшәеш нигезе, матурлык һәм рухи байлык чыганагы итеп күрсәтелә. Романда, табигатьнең үзеннән дә бигрәк, аңа кешеләрнең мөнәсәбәте тасвирлана, моның тирән мәгънәсе, рухи, эстетик, әхлакый, экономик һәм хәтта патриотик яклары яктыртыла. Ватанга мәхәббәт нигезендә дә бит

туып-үскән якларга мәхәббәт тойгысы ята, дип саный Камил Дусаев. Чишмә, тугайлар геройларның күңелендә, уй-хисләрендә яши, ягъни табигать күпмедер дәрәҗәдә кешеләштерелеп бирелә. Аның язмышы персонажлар яшәеше белән, бәйләнеш-мөнәсәбәтләре белән берлектә, ягъни тормыш процессында күрсәтелә, аның язмышы әсәр геройларының эш-гамәлләренә, бәйләнеш-мөнәсәбәтләренә катнашып бара. Шуңа күрә әсәрнең бер генә урынында да статиклык, торгынлык сизелми. Роман, сабак булырдай язмышларны тасвирлаган башка уңышлы әсәрләр кебек үк, киеренке кызыксыну белән укыла.

«Җидегән чишмә»дә тирә-юнь бөтенлеге өчен көрәшүчеләр белән аңа яра салучылар күрсәтелә дидек. Болардан тыш, әле тагын «арада чайкалучы» өченче категория дә бар: битарафлар, гамьсезләр. Камил Дусаев фикеренчә, киң Россия җирендәге чамасыз муллык, байлык кешеләрдә табигатькә карата элек-электән күпмедер ваемсызлык тәрбияләп килгән. Әсәрдә тасвирланган Дилбәр — зоотехник, комсомол оешмасы секретаре, Фәйрүзә агроном буларак күрсәтелә, әмма бар яшеллек, җан ияләренең нормаль яшәеше хакында чын-чынлап кайгыртырга тиешле белгечләр гамәлдә үтә юаш, пассив булып чыгалар, мещанлык тынычлыгын өстенрәк күрәләр. Минһаҗ карт аеруча әнә шуңа борчыла, Алтынбикәне, чишмәләрне Ризван гына түгел, авылның ваемсызлыгы да харап итте дип саный.

Геройларның табигатькә мөнәсәбәте белән беррәттән, әсәрдә моның икенче ягы да — табигатьнең шәхескә йогынтысы да яктыртыла. Романнан аңлашылуынча, гүзәл, бай табигать, аны олылау хисе күпмедер дәрәҗәдә кеше күңеленә дә күркәмлек өсти. «Табигать сөючеләр арасында,— дип сөйли Камил Дусаев,— мин явыз холыклы, кара эчле әшәке кешеләр очратмадым».

Инде тирә-юнь гарипләнсә, ул эстетик матурлык үрнәгеннән ямьсезлек чыганагына әйләнә, яшәешнең хозурлыгы, мәгънәсе кими. «Нинди кызыгы бар андый шыксыз җирдә яшәүнең?»— ди Гайнанның әнисе Җәүһәрия.— Алайга киткәч, үзебез дә, балаларыбыз да таш бәгырьле җансыз курчакка әверелмәбезме?» (58 б.) Әсәрдә әнә шулай каты күңеллегә әйләнүнең конкрет мисаллары да китерелә. Авылга кунакка килгән, сырадан бәхәсләшеп, карлыгач ояларын җимерүче, балчык атып уйнаучы эшлексез усмерләр кешегә карата да кансыз булып чыгалар, аларга каршы төшкән Гайнанның башына каты әйбер белән бәреп, аны тынсыз итәләр.

Әдип раславынча, акыл иясе, куәтенә масаеп, табигатьтән өстен булырга, аны буйсындырырга тырышкан саен, уйламыйча аңа зыян салган саен үзен көчсезләндерә, мескен хәлгә төшерә бара. Ахыр чиктә кешелек җәмгыятенең киләчәктә нормаль шартларда яши алу-алмавы, исән калу-калмавы да табигатьне саклый белүенә барып тоташа. Димәк, кешелеккә бер генә юл кала — табигать белән тату, дус булу, аны рәнҗетмәү.

«Җидегән чишмә»— безнең әдәбиятта сирәк күренүче, тик шулай да «Ике фикер»ләрдән үк килүче, традицияне тагы да югарырак сәнгатьчә фикерләү дәрәҗәсендә дәвам иттерүче концепция, проблема романы ул. Әсәр структурасында фикерләр көрәше әһәмиятле урын алып тора. Вакыты-вакыты белән персонажларның әңгәмәләренә фән мәгълүматлары да үрелеп киткәли. Ләкин әсәргә һич тә абстрактлылык хас түгел. Аның сәнгатьчә нигезләү, аргументлаштыру куәсе бик көчле.

Геройларның табигатькә каршы бер үк вакытта аларның гомумән яшәешкә мөнәсәбәтен дә билгели, мораль — этик, интеллектуаль асылын чагылдыра. Шулай итеп, тирә-юнь күркәмлеге әсәрдә фәлсәфи-әхлакый планда карала.

Кайчак әдипләр, әсәр язарга керешкәндә, хис, фикерләр, үзенчәлекле характерлар муллыгы алдында калалар. Кайвакыт язучы аларны, сайлап алып, тоташ сюжетка салып тормый, берсе артыннан икенчесен тезә бара. Нәтиҗәдә матур гына, ләкин шулай да сыек буынлы яки бөтенләй буынсыз таркау мозаика чыга. «Җидегән чишмә»дә исә фикер, тойгылар никадәр генә күп төрле булмасын, алар әсәр тукымасына, сюжет барышына иплe, җайлы төстә берегәләр.

Төрле язмышларны, сюжет җепселләрен тоташтыруда персонажларның хезмәт мөнәсәбәтләре, туганлык, мәхәббәт бәйләнешләре дә булышлык күрсәтә. Монда туганлык җепләре бик күп геройларны бергә бәйли. Романда төрле характердагы интим мөнәсәбәтләр, мәхәббәт кичерешләре дә тасвирлана. Алар әсәргә лирик аһәң бирәләр, үзенчәлекле моң сирпиләр. Гайнан — Шәүрәнең яшьлеккә хас беренче самими, әмма сулардан алып утларга сала торган мәхәббәте аеруча тирән кичерешле, татлы-газаплы итеп бирелә. Дилогиядә әлеге мәхәббәтнең «финалы»на ээлеклелек җитеп бетми иде. Борылыш кинәтрәк, әзерлексез килеп чыга иде. Бу басмада автор аны үзгәрткән, дәвамлы, перспективалы булачагын төсмерләткән. Биредә Идрис — Дәрҗия мөнәсәбәтен сурәтләү беркадәр җыйнаклана төшкән, ләкин хисләренең ягымлылыгы кимемәгән. Идриснең гүзәл врач кыз Люда Липатова белән ялкынлы мәхәббәт маҗарларын әдип монда бөтенләй төшереп калдырган. Биредә шулай ук Харис — Җәүһәриянең, Камил-Мәдәниянең өлкәннәрчә сабыр, төпле, тыйнак тойгылары бик җылы бирелгән, аларның тормыш сикәлтәләрендә, кискен борылышларда сыналуы күрсәтелгән.

Фәрит — Язидә мәхәббәтенең драматик финалы уңае белән тагын менә нәрсәне әйтеп китәсе килә. Ризван Чурмантаевның табигатьне күрәләтә бозуын күргән идек инде. Ул тагын яшьләрне җыеп эчерүне, исертүне га-

дәткә кертеп бара. Тегендә тирә-юнь табигате зарарлана, монда кеше табигате бозыла. Байтак әсәрләрдән үзгә буларак, «Җидегән чишмә»дә эчүчелеккә, «бөтен тамырларны агулаган зәһәр сыекча»га, «кан юлларына тулган ачы селте»ге бик катгый караш белдерелә. «Җыен сыек башлы, чиле-пешле гарип балалар исеректән туа» — дип фикер йөртә Минһаҗ карт. Хәмер аркасында Фәрит күз атып йөргән ярыннан — Язидәдән колак кага, тилеләр йортына килеп эләгә.

Әсәрдә күренекле әдип Камил Дусаев образы сурәтләнә. Ул шушы төбәк кешеләре, «Җидегән чишмә» персонажлары арасында күрсәтелә, шулар хакында китап язуы тасвирлана. Моның белән образларның реальлегенә, тормышның үзеннән алынганлыгына басым ясала. Эстетик мәсьәләләр күтәрелә. Шуларның иң мөһиме — әсәрнең сәнгатьчә камиллеге, нәфислеге, укучыны уйландыра, дулкынландыра алу сәләте. Бу образ аркылы тәҗрибәле, таләпчән язучының үзенчәлекле әдәби лабораториясе, сәнгать шөгыленең нечкә серләре, иҗат психологиясенең төрле яклары ачыла. Камил Дусаев тирән фикерле, талантлы каләм әһеле итеп кенә түгел, актив көрәшче итеп тә бирелә. Ык буе гүзәллеген саклауны ул мөһим дәүләт эше дип карый.

Г. Бәшировның тел остасы булуы, сүзгә таләпчәнлеге, ювелир түземлеге белән эш итүе мәгълүм факт. Яңа басманы әзерләгәндә, әдип, гадәтенчә, тел төгәллегенә дә нык игътибар иткән. Дилогиядә «Айгырны агачка бәйләп, а р к а л ы г ы н ычкындырды да алдына бер кочак печән салды» (1 т., 108 б.), — диелә иде. Болай дигәндә ат хуҗасы ничектер эш рәтен белеп җиткермәүче кебегрәк күренә иде. Яңа басмада автор ул җөмләне «аркалыгын төшерде» (89 б.), — дип төзәткән. Гамәл төгәл, дөрес белдерелгән. Аны әле тагын икенче төрле итеп тә, «аркалыгын бушатты» дип тә әйтергә мөмкин кебек. Мин әсәрдәге янә бер-ике сүзгә игътибар иттем. «Ләкин егет т ы н ы ч л ы к таба алмады» дигән мәкаләдә «тынгылык» сүзе, «күбрәк уйлаган саен егетнең б о р ч у ы арта барды» дигәндә «борчылуы» сүзе ятышлырак түгелме икән? Тулаем исә роман, әлбәттә, сүз пөхтәлегенең югары үрнәген күрсәтә, укучыларны телнең байлыгы, образлылыгы, музыкальлеге белән сокландыра. Бу әсәрнең һәр бите тормыш асылын тирән төшенгән акыл иясе һәм шул ук вакытта ягымлы лирик хисләрне яшьләрчә нечкә тоючы шагыйрь җанлы әдип тарафыннан иҗат ителгәнлеген раслап тора.

Романның иң тәүге кисәкләре «Таң беленгәч» исеме белән «Совет әдәбияты»ның 1962 елгы 1—2 саннарында дөнья күргән иде. Шулай итеп, автор бу әсәрен, укучыларга беренче тапкыр тәкъдим иткән көннән алып исәпләгәндә генә дә, егерме ел буена эшкәртә, яхшырта килгән. Әдәбиятыбызның бурычлары, язылган әйберләрнең дәрәҗәсе хакында фикер йөрткәндә, безгә әнә шундый зур иҗади казанышлар югарылыгын күздә тотарга, сокландырырдай сәнгать әсәрләре биеклегеннән карап бәяләргә кирәк.

**Фәрит ХАТИПОВ.**

# КУЛЪЯЗМА МИРАСЫБЫЗ СӘХИФӘЛӘРЕ

Профессор Миркасыйм Госмановның тарих һәм культура мәсьәләләренә, фольклор-әдәбият тарихына бәйле хезмәтләре матбугатта еш күренә. Әмма биредә сүз авторның андый махсус хезмәтләре турында түгел (алар инде фән дөньясында лаеклы урын алганнар), бәлки күптән түгел генә дөнья күргән, халкыбызның кульъязма китап мирасын төрле яклап яктырткан оригиналь бер жанрдагы әсәре хакында бара [1].

Басма китап, ә аңарчы меңләгән еллар буе кульъязма китап — иҗат, фикер, танып-белү, тормыш-хезмәт тәҗрибәсенең иң камил, иң тулы тупланышы ул. Язу, китап халыкларны таныштыра, буыннарны кавыштыра, тарих-мәдәният мирасларын бер бөтен итеп, алгарышлы традиция итеп туплый, кешелек үзе яшәгән кадәр яшәтә, саклый, үстерә, баета бара.

Әмма язу һәм китапка да рәхимсез вакытның тәэсире, һөҗүме котылгысыз. Әлегә исән кадәресен, каядыр билгесез почмакларда сибелеп, тарау, кадерсез ятканнарын саклап калырга кирәк — менә болар әсәрнең үзәк проблемасы. Бу хезмәт археографик сәяхәтләр казанында кайнап чыккан. Аның төп материалы — эзләнүләр тәҗрибәсе, кышкы озын төннәр буе өйрәнү-тикшерү нәтиҗәсе. Китап сәхифәләрен төрле төбәкләрдә очраш кан илгизәр тикшерүчеләр белән кульъязма мирасның йөзләгән хуҗалары арасындагы вакыйгалар тәшкил итә: кайчак күңелле, куанычлы, ә кайчагында борчулы, аянычлы коллизияләр — уйлап чыгарылмаган, һәркемгә таныш хәлләр. Автор шушы мәсьәләнең төрле як-

[1] Миркасыйм Госманов. Каурый каләм эзеннән. Археограф язмалары. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1984, 288 б.

ларын ача, әле бүгенгә, әле ерак тарихи офыкларны күрсәтә, кыскача, әмма үтемле искәрмәләр ясый. Буш сүз аз, информация күп. Гыйбрәтле, мавыктыра, ышандыра.

Китап биш бүлектән тора. Алар һәрберсе әле кыска-кыска парча рәвешен, әле әтрафлы тикшеренү рәвешен алган бүлекчәләрдән гыйбарәт (барысы — 40 лап). Мәсәлән, «Йосыф китабының көен көйләп», «Уртак хәзинә», «Сәяхәтче китаплар», «Җырлар биштәре», «Тирән катламнарга» һ. б. бүлекләр аеруча истә кала.

Эчтәлек бик киң һәм төрле-төрле. Китап «Кырык бакча», «Мең дә бер сәхәр» кебек бер кысага тупланган мәҗмуга тәсендәрәк. Чыннан да автор кулыннан меңләгән кульъязма үткән, аларның тематик төрлелеге, охшашлык-аермалары, хосуси үзенчәлекләре хезмәттә чагылыш тапкан. Ул парчаларның һәркайсына бәя биреп, эчтәлеген тулы ачу өчен, янә бер китап язарга туры килер иде.

Беренче бүлектә кульъязма һәм чыганак белеменең тарихи барышы яктыртыла. Иң әүвәл — Пугачев яулары һәм аннан соңгы ара (1773—1800), XIX йөзнең беренче яртысында Ибраһим Хәлфин, Христиан Френ, Карл Фукс, Мирза Казимбек, Илья Березин һ. б.; икенче ярымында — Иосиф Готвальд, Хөсәен Фәезханов, Шиһаб Мәрҗани, Риза Фәхретдинев, Н. Ф. Катановлар; аннан соң — XX гасырда Сәед Вахиди, Вәли Зәбировлар һәм, ниһаять, 1940—60 елларда: Зәйнәп Мәксудова, Җәвад Алмаз һ. б. шәхесләрнең эшчәнлегенә кыскача, объектив бәя бирелә.

Хезмәттә татар кульъязмасы һәм китабының үзенчәлекләре, социаль җирлеге, географик таралышы, тарихи-мәдәни ареаллар белән бәйләнешы, төрки-татар язма истәлекләр текстологиясенең төрле яклары тегә яки бу дәрәҗәдә чагылыш тапкан. Гомумән, һәр бүлек аерым бер китап рәвешендә: гаять тыгыз эчтәлекле, идея, фикер һәм күзәтүләргә бай — аларны бер кысага салып бәяләү дә кыен... Бәйнә-бәйнә танышуны укучыларның үзләренә калдырып, соңгы елларда үткәрелгән археографик экспедиция нәтиҗәләренә күз салыйк: 60 нчы еллардан алып 1983 елгача Казан дәүләт университетының тарихчы-археографлары тарафыннан 5000 нән артык кульъязма, 1050 сан журнал, 15 исемдә иске газет төпләмнәре һәм 200 ләп сирәк басма китаплар җыелып, университетның фәнни китапханәсенә тапшырылган. Бу уңышлар белән мактану мөмкинлеге җитәрлек булуга да карамастан, автор нәтиҗәләрне объектив бәяли; һәрхәлдә, күп кенә төбәк һәм өлкәләргә моңарчы системалы экспедицияләр чыкмаган булуын искәртә. Әйе, алда юллар, табышкуанычлар күп әле!

Табыш дигәч тә, аныеы алай ансат кына табылып ятмый икән шул. 1962—63 еллардагы «маҗаралар»ны автор җылы бер ирония белән тасвирлый икән, бу бик аңлашыла, чөнки зур, мөһим эшләр кечкенәдән башлана, ялгышулар да табигый булып уза. Үз мавыгуларына тәнкыйть күзлегеннән карый белү исә шәхесне алга үстерә.

«Алтын-көмеш юлда ятмый» диләр, дөрес. Әмма һичбер алтынга да табылмастай кыйммәтле җәүһәр кебек әсәрләрнең өзекләре кайдадыр тузанлы чолан-чормаларда аунап ятуы да очраштыргалый әле. Синең сорашуларыңа еш кына:

« — Һии, гомер булганы юк бездә андый нәрсәкәйләрнең»,— дигән, яисә: « — Картлар үлеп бетте» («Иске өй янды; зиратка китапларын да күмдек; туган-тумачасы читкә алып китте; картлар, әбиләр ташып бетерделәр») кебек җавапларны ишетәсең. Кайберәүләр исә үзенең келәте йә чормасында ни барлыгын да онытккан; әгәр әрсезлегең җитеп, рөхсәт алып керәлсәң, берничә иске китап, йә кульъязма калдыкларына тап буласыңны көт тә тор. Абзый (абыстай) үзе дә аптырап кала: «фәләнемнең төсе итеп саклыйдырием, өй җыйганда яшьләр чыгарып ташлаганнардыр» кебегрәк акланулар ишетелә һәм чыннан да кайбер яшьләрнең ата-баба мирасына мөнәсәбәте «искитмәсизм» (!) вә нигилизмнан да үтә китеп, вандализмга барып җиткән хәлләр дә очрый.

Әмма аңлы, яхшы кешеләр күбрәк, укучы һәм укытучылар, совет-партия-колхоз җәмәгатьчелеге археограф «йомышына» тиз төшенеп, кулдан килгәнчә булышалар. Кайберәве соңыннан һәвәскәр эзләнүче, хәтта хәбәрче булып китә. Мәсәлән, китапта андый ихлас ярдәм итүчеләрнең зур төркеме тирән ихтирам белән искә алынган. Автор археография өлкәсендә тегә яки бу дәрәҗәдә эш күрсәткән, өлкән яки чордаш коллегаларын да онытмый, юлдаш-хезмәттәш шәкертләренә дә рәхмәт сүзен әйтә; остазларына да олы ихтирам саклап, археографик экспедициянең беренче адымнарын оештырудагы булышлык һәм теләктәшлекләрен тәкъдир итә.

Хезмәтнең икенче бүлегендә кульъязмаларга тормыш биргән шәкерт-пишкадәм катлавының иҗтимагый-тарихи урыны, әдәбимәдәни роле ачыла: алар X-XII гасырлардан алып XX гасырга чаклы үз каләм көчләре белән халыкны агартуга өзлексез һәм нәтиҗәле хезмәт итеп килгәннәр: гасырлар буе иҗат ителгән җыр, бәет, дастан, шигырь утын сүндермичә, безгә китереп җиткерү юлында арадашчы ролен үйнаганнар.

Китап нәшрияты оешканчы, сигез-тугыз гасыр буе һәр иҗат җимеше каурый каләм белән күчерелеп таралган, шул таралыш күләменә бәйле дәрәҗәдә генә вакыт һәм тарихның бәла-казасыннан сакланып, исән кала алган. Ленинград, Мәскәү, Казан, Оренбург, Уфадагы 15 меңнән артык татар кульъязмасы һәм хисапсыз документаль-язма фондның, ким дигәндә, 2/3 өлеше гади шәкерт, ярлы хәлфә тарафыннан күчерелгән икән. Ә күпмесе юкка чыккан?!

Шәкерт үзе дә иҗат иткән: бәет авторларының мәдрәсә белән бәйле яшьләр бу-

луын сөекле шагыйребез Г. Тукай һ. б. әдипләребез үзләре күзәтеп, язып калдырганнар. Чыннан да:

> Мәдрәсәләрдә китап киштәсе,
> Сак белән Сокның бәетен ишетәсе.
> Мәдрәсәләрдә пыяла ишек,
> Сак белән Сокның бәетен ишет...

— кебек башлангыч мисраглар ук инде моның нинди даирәдә иҗат ителүенә танык була ала.

Шул ук мәдрәсәләрдә Кол Гали, Мәхмуд Гали углы Болгари, Котблардан алып, Тукай, Дәрдмәнд, М. Гафури, С. Рәмиев, Ш. Бабич, Г. Ибраһимов, һ. Такташ, Х. Туфаннар да укыган бит. Алар да, башлангыч өйрәнчек чорларында, аноним шәкерт иҗаты белән бер ук казанда кайнаганнар. Иске мәктәп-мәдрәсәләрдән тик мулла-мәәзин, ишан-суфилар гына түгел, галимнәр, мөгаллим-хәлфәләр, китапчылар, күчерүче-хаттатлар, тәрҗемәчетылмачлар, сәүдәгәрләр, казый-юристлар, җәмәгать эшлеклеләре, ниһаять, ялкынлы революционерлар да чыккан. Шәрык дәһрилеге (атеизм) дә шул ук мәдрәсәләрдә бөреләнгән.

Крестьян сугышлары, восстаниеләрдә бүтән халыклар белән иңгә-иң торып татар халкының да, шул исәптән шәкерт-талиб һәм укымышлыларның да катнашуы, хәтта оештыручы-идеологлар, гаскәр башлыклары, штабчы-писарьләре, агитаторлары булуы ачыкланды. Мәсәлән, Пугачев явы үткән җирләрдән Казанга кайтып барган 15 хәлфә һәм талиб берьюлы патша ялчылары кулына эләгә һәм Уфа төрмәсенә ябылып, җавапка тартыла.

Китапның өченче бүлегендә халык авыз иҗаты әсәрләренең хронология мәсьәләләре, текстларында борынгы миф, дөньяга караш элементларының чагылышы, дастан-эпостагы тарихилык-сыйнфыйлыкны ничек аңлау-аңлату, фольклор белән борынгы әдәбиятның бер-берсенә катлы-катлы тәэсир итешүләре һәм ул мәсьәләләрне хәл итүгә яраклы алымнар күзәтелә. Мәсьәләнең бу рәвешчә тарихи эзлекле, фәнни-эстетик куелышы, һәрхәлдә, татар фольклористикасында моңарчы безгә очраганы юк иде әле. Шуннан соң теге яки бу әсәрләргә тарихи-текстологик анализ ясала.

Тарихка тирәнрәк кергән саен, татар фольклорында эпос-дастан эзләре күбрәк табыла бара: мәхәббәт, сөйгән яр һәм хатын-кызга карата шәрык рыцарьлыгы мотивлары ешрак чагыла, эпос һәм тарихи риваятьләрнең язма иҗат аша үткән аноним версияләре дә билгеләнә. Бу яктан «Хөкемгә тартылган дәфтәр», «Яр-яр», «Амәт хикәяте» кебек парчалар дикъкатькә лаек. Бу күзәтүләр үрнәгендә фольклор (мифология, эпос) һәм борынгы әдәбият белән тарих арасындагы бәйләнешләрне, шулай ук жанр-стиль, чыганак-сюжет, мотив-форма бәйләнешләрен реконструкцияләү мөмкинлекләре дә ачык төсмерләнә.

Дүртенче бүлек башыннан ахырынача «Түләк батыр һәм Сусылу» дастанының версияләрен текстологик һәм тарихи фольклористик тикшерүгә багышланган. Монда дастанның басма һәм кульязма чыганаклары, төрле телләр һәм халыкларда таралышы, барлыкка килү җирлеге, тикшерелү тарихы, эчтәлек мотивлары һ. б. бик җентекләп бәян ителгән. Мондый алым хезмәтнең фәнни югарылык дәрәҗәсен, текстологик төгәллеген тәэмин иткән. Дастанның тарихи һәм этник-культура базасын ачыкларга омтылу, үзеннән-үзе һәм зарури рәвештә, аны гомумән төрки фольклор, эпос һәм әдәбият бәйләнешләре, этник һәм этногенетик бәйләнешләр яссылыгында карауны сораган. Бу яктан «Нугай мәсьәләсе» дигән парча бик урынлы. Әлбәттә, автор биредә татар халкының (сөйләү һәм әдәби теленең) килеп чыгышы, формалашуы, үсеш-үзгәреше мәсьәләләрен тулысынча карау бурычын өстенә алмый, дастан сюжеты белән бәйле рәвештә генә нугай-кыпчак мәсьәләсенең бер почмагын тәфсиллерәк һәм калкурак ачып күрсәтү белән чикләнә.

Мөстәкыйль фәнни һәм әдәби-эстетик әһәмияткә ия булган «Түләк батыр һәм Сусылу» дастаны хакындагы өлеш аерым бер китап итеп басылырга лаек.

Соңгы бишенче бүлек гомуми йомгак рәвешен алган. Бары бер генә парча — «Йосыф китабы»на кагылышлы «Сабыр тобе» бу кысадан читкәрәк чыга. Сигез гасыр элек яшәгән даһи автор һәм аның үлемсез әсәренә кагылышлы мәсьәләләр даирәсе, әлбәттә, бик киң һәм төрле аспектларны эченә ала. Кайсын гына тикшермә, ерак-тирән тарих төпкелләренә кереп китми мөмкин түгел. Шулай махсус тикшермәстән, аның хакында кыска, популяр язу да читен. Шуңа күрә автор бу парчадагы сабырлык мотивы кебек хосуси күзәтүләр белән генә чикләнмичә, китапның үзгә сәхифәләрендә дә, төрле мөнәсәбәт һәм җай чыккан саен, бик хаклы рәвештә «Кыйссаи Йосыф»ка мөрәҗәгать иткән. Бигрәк тә әсәрнең Болгар-Казан җирлеге һәм татар этносы белән аерылгысыз булуы, бүгенгәчә актив яшәеше, һичкайчан онтылмавы; соңра кульязмаларының киңрәк регионга таралышы (болгар-казан халкының демографик күчешләре белән бәйле рәвештә); казах, башкорт, комык, нугай, терек әдәбияты-фольклорына тәэсире һ. б. аспектларның каләмгә алынуы куанычлы. Җ. Алмаздан ук инде, бу хакта шактый күп һәм җентекле язылып килә, әмма биредә авторның элеккене генә кабатламастан, яңа чыганак һәм фактлар белән эш итүе кыйммәт.

М. Госмановның бу хезмәте тагын бер ягы белән дикъкатьне җәлеп итә: ул жанр мәсьәләсе. Фәнни-әдәби жанр бездә әлегә сирәк очрый торган төрләрдән саналса да, автор өчен бөтенләй үк кул тимәгән өлкә түгел: берничә ел элек, «Серле балбал» китабы белән ул бу өлкәдә дә кызыклы гына чыгыш ясаган иде. «Каурый каләм»не исә

әнә шул юнәлешнең һәм, әйтергә кирәк, әле моңарчы эшкәртелмәгән (димәк, татарча язу өчен аеруча кыен, газаплы булган) жанрның уңышлы бер тәҗрибәсе, яңача үстерелеше дип кабул итә алабыз. Бирелә инде тиешле композицион алымнар, мөмкинлекләр дә эшкә җигелгән: проблемалы сорау, җавап эзләү мажаралары, антитеза һәм парадокслар, тупик юлларга кереп чыгу һ. б. Жанрның хосусый деталь-чаралары да уңышлы рәвештә кулланылган, ягъни максат-фикергә, җөмләдәге сүз сөрешенә, стиль-мәгънә төсмерләренә ярашлы рәвештә сайланып, чарланып текстка кертелгән. Юлара сибелгән киная, ирония, сатира төсмерләре стильне җанландырып, үткенәйтеп җибәрә — бездә бу (аеруча авторның «үз иронияс») сирәк очрый иде әле. Билгеле, һәммәсе бердәй үк нечкә зәвыклы булып та җитмәс, тик шулай да төрле хәл-халәтләргә, факт-күренешләргә авторның үз мөнәсәбәтен искәртә баруы хуплауга лаек.

Шуны да басым ясап әйтергә кирәк ки, бу китап, чын мәгънәсендә, фәнни-әдәби жанр үрнәге булып чыга алган. Предметының фәннилек, тегәллек дәрәҗәсен югалтмаган хәлдә, мавыктыргыч, гыйбрәтле, мажаралы булуы белән фән тирәсендәге фантазияләрдән бик нык аерыла.

«Каурый каләм»нең уңышы, фәнни әдәбият өлкәсендә яңа сүз, яңа төр булуы һичбер шик уятмый. Аның үрнәгендә филология, математика, география, тарих һ. б. тармаклар буенча да югары сыйфатлы фәнни-популяр, фәнни-әдәби әсәрләр иҗат ителүгә юл ачылыр дип ышанасы килә.

Китапның яңа тулырак басмасын — бигрәк тә русча вариантын нәшер итү кирәклеге үзеннән-үзе аңлашыла: чөнки аның гомуми тюркология һәм шәркыят белеме ягыннан әһәмияте бик зур.

**Фазыл ФӘСИЕВ,**
филология фәннәре кандидаты.

## УКУЧЫЛАРЫБЫЗ ИГЪТИБАРЫНА

*Журналыбызның 1985 елгы 8 һәм 9 саннарында басылган Нәби Дәүли повестеның ахырындагы «Дәвамы бар» дигән сүзләрне «Повестьның беренче кисәге тәмам» дип төзәтеп укырга.*

* * *

*«Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреатлары» дигән материалга («Казан утлары», 1986 ел, 4 сан) өстәмә:*

*1959 ел.*

5. Композитор Мансур Әхмәт улы Мозаффаровка — «Тукай» һәм «Мулланур Вахитов» исемле симфоник поэмалары өчен.

# ТӘРҖЕМӘ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШӘБЕЗ

**Журналның быелгы 2 санында укучыларыбыз Р. Сафаров һәм Л. Леронов хатлары буенча сөйләшү башлап җибәргән, анкета урнаштырган идек. 3 санда сөйләшүне М. Рафиков белән Р. Кукушкин дәвам итте. Хәзер сүзне шагыйрь һәм тәрҗемәче Нури Арсланов белән филология фәннәре докторы Рүзәл Юсупов ала.**

## Нури Арсланов:

1. Эчтәлекне мөмкин кадәр тулы килеш саклау да, милли колоритны бирү дә, кинаяләрне төгәл тапшырырга тырышу да тәрҗемәдә бик мөһим. Гамәлдә, әлбәттә, боларны бертигез саклау кыен, үти алмаслык эш. Шуңа күрә бу урында фәкать мөмкин кадәресе турында сүз барырга тиеш.

Шулай да иң заруры — милли колоритны саклау — тәрҗемә ителәчәк әсәрнең рухын, җанын ачып бирү.

2. Тәрҗеменең уңышлы булуы тәрҗемәченең талантына да, тәҗрибәсенә дә, әсәр нинди телдән тәрҗемә ителсә, шул халыкның тарихын, мәдәниятен, бигрәк тә телен белүгә дә нык бәйләнгән. Шуларны белгәндә, югарыда әйткәнемчә, тәрҗемәдә әсәрнең рухын да, җанын да ачып салу мөмкин.

3. Шулай да тәрҗемә оригиналның бөтен үзенчәлеген, нечкәлекләрен төгәл биреп бетерә алмый. Нинди оста тәрҗемә дә, минемчә, төп әсәрнең кайтавазы булып кына яңгырый ала.

Тәрҗемәгә бөтенләй бирелмәүче әсәрләр дә була. Моңа бер мисал: заманында мәрхүм Әхмәт Ерикәй дә, мин дә бөек рус шагыйре Твардовскийның «Василий Теркин» поэмасыннан аерым бүлекләрне тәрҗемә итеп карадык. Тәрҗемәләрдә вакыйгалар да дөрес, батырлыклар да бар, гаҗәп шәп солдат та бар, ләкин легендар Теркин гына юк...

Теркинның афоризмнар белән тулы уйнак теле — русның гади халык теле, шаян әйтемнәр, кинаяләр белән купшы йөгерек теле Твардовскийның алтын каләмендә ялтырап чагылган бер күренеш булып, аның «башы да, ахыры да булмаган» поэмасы бөтен рухы, җаны белән рус халкының милли әсәренә, классик әсәренә әйләнде. Андагы гыйбарәләргә синонимнар табып бетерү мөмкин түгел. Андый әсәрләрне башка телгә тәрҗемә итеп булмый дияр идем мин.

Шул уңайдан, зур талант иясе Сергей Есенин шигърияте турында да бер-ике сүз әйтмичә узып булмый. Дөрес, монда эшләр беркадәр башкачарак тора. Беренче мисалда тәрҗемә итү өчен төп кыенлык әсәрнең телендә булса, Есенин шигырьләрендә ул әсәрнең рухында, тирән сагышында.

Буераки, пеньки, косогоры
Опечалили русскую ширь...— ди ул.

Аныңча бөтен табигать, аның бөтен куакүләннәренә кадәр рус иленең тирән сагышын, хәсрәтен сурәтли. Шагыйрь шуны үз күңеленнән кичерә. Аны тәрҗемә итәр өчен шагыйрь сагышын тирән тоярга, аның кебек үк күз яшьләре белән кичерергә кирәк. Шулай булмаганда тәрҗемә оригиналны укыгандагыча тәэсир итә алмаячак.

Гомумән, әдәбият укучылар бер-берсеннән беркадәр аерылып торалар. Шигырь укучы аз, ләкин ул башкалардан шактый калкурак. Асыл сөяк зур булмас дигәндәй, асыл зат та күп булмый бит инде ул.

Мин Есенин шигырьләрен, әле аның яраткан укучысы буларак та, менә инде ничә еллардан бирле тәрҗемә итеп карасам да, һаман уңышка ирешә алганым юк. Ул рус халкының милли шагыйре, аның тирән хәсрәте...

Бу мәсьәләдә безнең бөек Такташыбыз белән дә эшләр шулайрак. Такташ әсәрләре русчага тәрҗемә ителде. Сүз юк, тәрҗемәләр начар түгел. Аларда барысы да бар, тик Такташ кына юк. Бу — әлеге дә баягы телне белмәү, милли рухны тоймау, мәгънәне мәгънәгә тәрҗемә итүдән килеп чыккан уңышсызлык.

Сергей Есенинның иҗатын искә алгач, Гомәр Хәйям күз алдына килеп басты. Ул дөньяга бәхет өчен туган кешеләрне кайгыхәсрәттә янмаска, кәеф-сафа корырга, бәхетле булырга өндәгән. Чын атеист буларак, дини хорафатларның астын-өскә китерергә, риялы мулла-мунтагайларның үгет-нәсихәтенә колак салмаска өндәгән. Хәтта тәңренең үзен икейөзлелектә гаепләп кыю чыгышлар ясаган. Бу хәлнең моннан тугыз йөз еллар элек булганлыгын да исәпкә алсак — нинди бөеклек, нинди батырлык!

Гомәр Хәйямның онытылмас робагыйларын мин подстрочник белән дә, турыдантуры оригиналдан да тәрҗемә итмәдем. Фарсыдан фәкать сүзлек ярдәме белән генә файдалана алам. Ләкин миңа бу эшемдә башка төрки телләрне яхшы белүем зур ярдәм итте. Үзбәк, казах, каракалпак телләрендәге, аннан рус һәм фарсы телләрендәге Гомәр Хәйям робагыйларын алга куеп, тәрҗемәләрдәге аермаларны фарсы белән чагыштырып эшләдем. Болай итү миңа оригиналга, башкаларга караганда, якынрак килергә мөмкинлек бирде. Моның белән мин тәрҗемә эшләрендә мондый күренешләр дә ят түгел дип әйтмәкче булам.

Тагын бер мисал: француз шагыйре Пьер Беранже моннан инде йөз кырык еллар элек рус теленә, рус демократик шагыйрь В. С. Курочкин тарафыннан тәрҗемә ителгән. Француз телен яхшы белүе һәм демократлыгы тәрҗемәчегә зур ярдәм иткән булса кирәк. Беранже шигырьләре русчада да җырлап, биеп торалар. Соңгы вакытларда күпме генә яңа тәрҗемәләр дөньяга килмәсен, Курочкин тәрҗемәләреннән дә уңышлырагы күзгә чалынганы юк. Әлеге дә баягы мәгънәгә-мәгънә күчерү бәласе.

4. Оригиналданмы, яисә подстрочниктан тәрҗемә итү яхшыракмы? — дигән сорау да бар.

Бу сорауга җавап кебегрәк сүзләр әйтелде бугай инде. Әлбәттә, тәрҗемәче телне белсә һәм шул телдән турыдан-туры күчерсә чагыштыргысыз яхшы! Инде бер дә мөмкин түгел икән, телне белмибез икән, ул чагында подстрочник зарур булачак. Подстрочник ясаучы да, әсәрне шигъри калыпка кертүче дә — икесе дә кирәк.

5. Яхшы подстрочник ясау — үзе бер сәнгать. Анда әдәби тәрҗемә ясаучы өчен мөмкин кадәр барысы да ачык булырга тиеш. Мәгънә, ритм, рифма, сурәтләү чаралары һәм башка хосусиятләре юлга-юл тәрҗемә ясаучы тарафыннан күрсәтелүе, аңлатылуы шарт.

Минем күпләргә подстрочный тәрҗемә ясаганым бар. Шулардан, мәсәлән, Хәсән ага Туфанга да. Нихәтле аңлатмаларыма һәм урыны-урыны белән кирәкле синонимнар табарга тырышуыма да карамастан, автор, әдәби тәрҗемәче һәм мин — өчәүләп җыелышып киңәшә идек. Тик мондый мөмкинлек һәрвакытта да була алмый, әлбәттә. Шулай да әлеге югарыда әйткән шартлар булуына да карамастан, Хәсән Туфан шигырьләре дә әлегә русчада ниндидер бер яктыртуга, җан өрүгә мохтаҗ, минемчә. Хәер, бу бәлки минем артык таләпчәнлегемнәндер дә.

6. Муса Җәлил — бүгенге заман шагыйре. Аның әсәрләре фашизмга каршы көрәш рухы белән, политик лирика белән сугарылганнар. Ул үзенең бөтен барлыгы белән бөтен совет халкына бик якын, бик аңлаешлы. Шуңа күрә дә ул барлык тәрҗемәчеләргә дә бик аңлаешлы. Муса шигырьләренә бернинди дә аерым аңлатмалар (комментарийлар) кирәк түгел. Аның шигырьләре русчада шуңа оригиналдагыча диярлек яңгырыйлар да.

Тукай, Дәрдмәндләргә килгәндә, эш бераз башкачарак тора. Ләкин мин нигилист түгел: бу хөрмәтле шагыйрьләребезнең дә русча уңышлы тәрҗемәләре бар. Шулай да әле без бөек Тукаебызны дөнья күләменә чыгарып күрсәтә алганыбыз юк.

Минемчә, бездә тәрҗемәгә үги бала итеп, яки икенче дәрәҗәдәге эш итеп карау бар төсле. Бу мәсьәләдә әле һаман да без ак белән караны аерып җиткерә алмыйбыз шикелле. Бер үрнәк: литвалылар үзләренең Соломея Нерисларын русчага тәрҗемә итүдә бик күркәм эш эшләгәннәр. Утызлап танылган рус шагыйрьләрен җыеп киңәш уздырганнар. Шул утыз арасыннан егермеләп шагыйрь Соломеяны русчага әйләндергәннәр. Менә ичмасам бу жест! Безгә соң шуңа охшашрак бер егетлек күрсәтергә ярамыймыни?! Әле бит алда Кол Галиләрне, Сәйфи Сараиләрне русча чыгарасы бар. Без һаман шул уртакул тәрҗемәчеләр белән чикләнәбез.

7. Югарыда әйткәнемчә, хәзерге урта буын шагыйрьләребезне дә әнә шундый очраклы шагыйрьләр тәрҗемә итә. Аларның кайберләре хәтта тәрҗемә урынына бөтенләй башка шигырь язып та бирәләр. «Менә фәлән шагыйребезнең рус телендә яхшы җыентыгы чыккан!» — дип әйтерлек китапны табуы кыен. Бәлки бардыр, тик мин генә белмимдер. Әгәр дә шулай икән,— бигайбә.

8. Монда татар прозаикларының русча чыккан китаплары турында сорау бирелә. Мин үзебезнең әсәрләрне, бигрәк тә прозаны, ана телендә генә укып барам. Аларның русча тәрҗемәләре мине кызыксындырмый. Аннан соң аңа бит вакыт та кирәк. Бу сорау чагыштырып уку өчен махсус билгеләнгән кешеләргә генә бирелергә тиеш дип уйлыйм.

9. Илебездәге милли әдәбиятларны үзара якынайту өчен мөмкинлекләр бездә бар. Тик нинди телгә тәрҗемә иттерсәң дә, нинди телдән тәрҗемә итсәң дә, әсәрне сайлый белергә һәм бу эшне планлы рәвештә алып барыр өчен иҗат союзыбыз үзе җиң сызганып тотынырга тиеш. Юкса бу эштә очраклылык өстенлек алып бара. Минемчә, союз каршында тәрҗемә эшләре буенча махсус бер комиссия төзелергә тиеш.

Бер-берсеннән аерылмый торган әйберләрне аерып, аерым сорау итеп куйганга күрә минем җавапларым да кабатланыбрак китте ахрысы. Ләкин ул кабатлануларның зарары булмас дип уйлыйм, чөнки алар бер урында бер ягы, икенче урында икенче яклары белән ачыла баралар төсле.

## Рүзәл Юсупов:

1. Матур әдәбият тәрҗемәсенең төп принцибы — оригиналның эчтәлек һәм форма бердәмлегенә ирешү. Тәрҗемә төп нөсхәнең эчтәлеген, идеясен, мәгънәсен дә, сәнгатьлелек-сурәтлелек үзенчәлекләрен дә, милли колоритын, автор стилен дә мөмкин булганча тулы бирергә тиеш дигән сүз бу.

2. Тәрҗемәнең уңышлы килеп чыгуы күп нәрсәләргә бәйле. Әлбәттә, беренче чиратта тәрҗемәченең осталыгына. Чын, сәләтле тәрҗемәче, язучы кебек үк, зур сүз остасы була, оригинал телен әйбәт, тәрҗемә телен бик яхшы, бөтен нечкәлекләре белән белә. Шуның өстенә ул әсәрдә сурәтләнгән

халыкның тарихын, культурасын, милли үзенчәлекләрен белсә, нур өстенә нур өстәлә — тәрҗемәнең сыйфаты тагын да югарырак була.

3. Тәрҗемә, гомумән алганда, никадәр генә яхшы булмасын, оригиналның бөтен байлыгын биреп бетерә алмый. Ләкин моннан тәрҗемә итү мәгънәсез эш икән дигән нәтиҗә ясарга кирәкми. Тәрҗемә тарихында бер телдән икенче телгә тулы кыйммәтле итеп бирелгән матур әдәбият әсәрләре аз түгел.

Тәрҗемә ителми торган әсәрләр булмый. Хәлбуки, авыр тәрҗемә ителә торган әсәрләр була. Бу бигрәк тә поэзия әсәрләренә карый. Кыенлык шигырь төзелешенең үзенчәлекле булуына да, авторның индивидуаль стиленә дә бәйле.

Татарчадан русчага Г. Тукай әсәрләрен тәрҗемә итү авыр эш диючеләр һәм шуны сылтау итеп начар тәрҗемә итүчеләр дә бар. Ләкин Тукайның русчага яхшы гына тәрҗемәләре дә барлыгы билгеле. Хикмәт, күрәсең, зур көч түгеп, җиренә җиткереп эшләүдә.

4. Бездә ике төрле юл белән тәрҗемә итәләр: турыдан-туры һәм подстрочник аша. Турыдан-туры дигәне һәркемгә аңлашыла булса кирәк: тәрҗемәче берүзе генә, арадашчысыз эшли. Подстрочник аша тәрҗемә исә болай эшләнә: башта бер кеше оригиналны икенче телгә сүзгә-сүз, мәгънәсен төп-төгәл итеп әйләндереп бирә (ул подстрочник дип атала). Аннары икенче кеше (монысын инде тәрҗемәче диләр) әзер текстны әдәби эшкәртеп чыга.

Подстрочник аша тәрҗемә итү, мәсьәләгә принципиаль караганда, нормаль күренеш түгел. Ул оригинал телен белгән тәрҗемәчеләр булмаганлыктан, ягъни башка чара булмаганлыктан гына эшләнә торган эш. Әлбәттә, подстрочниктан эшләнгән тәрҗемә, оригинал телен яхшы белеп, турыдан-туры һәм оста башкарылган тәрҗемәдән калыша. Әсәрнең тел, стиль үзенчәлекләрен аңлап, үзең күреп, сурәтләнгән хәлләрне, вакыйгаларны якыннан тоеп, оригиналдан турыдан-туры тәрҗемә итүгә ни җитсен инде?! Хәлбуки, татарчадан русчага тәрҗемәләрнең күбесе әлегәчә подстрочниктан эшләнә: татарча белгән тәрҗемәчеләр җитмиме, әллә моның башка сәбәпләре дә бармы икән?

5. Ничек кенә булмасын, подстрочник аша тәрҗемә итү татарчадан русчага тәрҗемә эшендә әле зур урын алып тора, һәм болай эшләү якын киләчәктә генә бетмәс кебек күренә. Шулай булгач, тәрҗемәләрнең барысына да — ул турыдан-туры эшләнәме, подстрочник ашамы — инде искә алган төп таләп: оригиналның өчтәлеге белән формасының бердәмлеге икенче телгә мөмкин кадәр тулы итеп бирелергә тиеш дигән таләп куела. Әйтергә кирәк, татар язучыларының русчага подстрочник аша яхшы гына тәрҗемә ителгән әсәрләре аз түгел. Мәсәлән, Муса Җәлилнең рус теленә югары сәнгатьле итеп тәрҗемә ителгән шигырь һәм поэмаларын атарга мөмкин. Шул ук вакытта русчага подстрочник аша тәрҗемә ителгән әсәрләр арасында оригиналның сәнгатьлелек көче шактый киметелгәннәре, андагы образларның төссезләндерелгәннәре дә бар.

6. Аңлашыла ки, тәрҗемәнең ни дәрәҗәдә уңышлы килеп чыгуы подстрочникның сыйфатына да бәйләнгән. Подстрочник оригиналның эчтәлеген, мәгънәсен, мөмкин булганча образлылык-сурәтлелек чараларын да төгәл бирергә тиеш. Бу шарт үтәлгәндә, тәрҗемәнең тиешле югарылыкта торуы өчен мөмкинлекләр зур була, һәм, әйтергә кирәк, татарчадан русчага подстрочниклар гадәттә төгәл эшләнә.

7. Аңлашыла ки, подстрочник, бигрәк тә поэзия әсәрләре подстрочнигы, әле ул чын тәрҗемә түгел, шулай булгач, шагыйрьнең чын тәрҗемәчесе подстрочник ясаучы дип әйтеп тә булмый.

8. Муса Җәлил әсәрләрен гадәттә русчага тырышып тәрҗемә итәләр, һәм нәтиҗәдә аның тәрҗемәләре, гомумән алганда, югары сыйфатлы. Габдулла Тукайның да әйбәт кенә тәрҗемәләре бар. Ләкин аның русча чыгарылган әсәрләренең барысында да шагыйрьнең стиль үзенчәлекләре тулысынча бирелә дип әйтеп булмый.

9. Русчага тәрҗемә ителгән проза әсәрләренә килгәндә, күренекле татар язучыларының уңышлы тәрҗемәләре шактый күп. Г. Әпсәләмов, Г. Бәширов, Ә. Еники, Г. Ахуновларның һәм башка татар язучыларының русчага яхшы гына тәрҗемә итеп чыгарылган әсәрләре бар.

10. Бурыч — киләчәктә татарчадан русчага тәрҗемәләрнең сыйфатын тагын да яхшырту, рус укучыларына татар язучыларының бөтен әдәби осталыгын, иҗади көчен чәчми-түкми илтеп җиткерү. Моның өчен Татарстан Язучылар союзына русча һәм татарча яхшы белгән сәләтле яшьләрне сайлап алырга һәм әзерләргә кирәк. Моннан берничә ел элек эшләгәнчә, бер төркем егет һәм кызларны — татар әдәбиятын яратканнарын һәм каләм осталыгы булганнарын гына, әлбәттә — Мәскәүдәге әдәбият институтының тәрҗемәчеләр бүлегенә җибәреп укытып кайтару начар булмас иде. Аннары русча да, татарча да яхшы белгән язучыларны тәрҗемә эшенә күбрәк тартырга кирәк.

**Хөрмәтле укучылар!**
**Тәрҗемә турында сөйләшү дәвам итә. Сезне анда катнашырга чакырабыз.**

**Әнвәр Хәйруллин,**
Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты фәнни хезмәткәре.
**Фәрит Хәбибуллин**

# ТАТАР ТЕАТРЫНЫҢ РУХЫ

Татар халкының әдәбияты һәм сәнгате тарихында күренекле урын алып торучы шәхесләр бик күп. Алар үзләренең эшчәнлекләре белән халык күңелендә мәңге җуелмас тирән эз калдырдылар. Әйе, мондый күренекле шәхесләрне бик күп санарга мөмкин булыр иде. Шуларның берсенә — татар профессиональ театрына һәм профессиональ режиссурасына нигез салучы һәм үзенең бөтен гомерен сәхнәгә багышлаган Габдулла Кариевка тукталып үтик.

Беренче профессиональ татар театр труппасы «Сәйяр»нең режиссеры, артисты һәм художество җитәкчесе Габдулла Кариевның иҗади эшчәнлеге патша реакциясенең коточкыч авыр шартларында спектакльләр кую белән генә чикләнми. Алдынгы карашлы татар укымышлылары патша хөкүмәте тарафыннан туктаусыз эзәрлекләнгән вакытта Г. Кариевтан да гаять зур рухи һәм физик көч таләп ителә. Иҗади эшчәнлегенең беренче көннәрендә үк ул Россиядәге социал-демократик хәрәкәт белән тыгыз бәйләнешкә керә.

1907 елда Камил Төхфәтуллин үтенүе буенча, Г. Кариев Нижний Новгородка, Мәкәрҗә ярминкәсенә китә. Анда баруның максаты И. Кудашев-Ашказарский җитәкчелегендәге труппаны Уральск шәһәренә чакырудан гыйбарәт була. К. Төхфәтуллин, ярминкәдә сатар өчен, Г. Кариевка шактый күп китап бирep җибәрә һәм шул китап саткан акчага әлеге труппаны Уральск шәһәренә алып килергә куша. Труппаның 9 кешедән торган бер өлешен җылы каршылап, К. Төхфәтуллин аларны кунакханәгә урнаштыра һәм, атаклы сәүдәгәр Х. Гаделшинның губернатор белән дус булуыннан файдаланып, труппага Уральск шәһәрендә татар телендә спектакль куярга булыша...

Шул вакыттан башлап үзенең гомерен сәхнә белән бәйләгән Г. Кариев бераздан соң үзе труппаның җитәкчесе булып китә һәм соңгы көненәчә демократик татар театры тәзү идеясенә тугрылыклы булып кала. Ул үзенең труппасына «мосафир артистлар җәмгыяте» исеме бирә, һәм алар, шәһәрдән-шәһәргә йөреп, татарча спектакль күрсәтәләр.

1905—1906 елларда Уральск эшчеләренең революцион хәрәкәтләрендә әлеге шәһәрдә яшәүче яшь Тукай да актив катнаша. Бу вакытта ул рус революцион газетасы «Уралец» типографиясендә хәреф җыю эшенә өйрәнә. Биредә яшерен большевистик ячейка да эшләп килә. Тукай әлеге ячейка кушуы буенча листовкалар, прокламацияләр, революцион җырлар текстлары тарата, демонстрацияләрдә һәм митингларда катнаша. Аның «Уральскидә хөррият бәйрәме» (1906) дигән мәкаләсе әнә шундый вакыйгаларның берсе турында сөйли.

Бу чакта Г. Кариев белән Г. Тукай инде бик якын дус һәм фикердәш булалар. Алар Уральскида чыга торган газета-журналлар белән хезмәттәшлек итәләр һәм вакытлы матбугатны халык арасында таратуда зур тырышлык күрсәтәләр. Бу эшчәнлеге Г. Кариевның алдынгы карашлы шәхес буларак җитлегүенә хәлиткеч этәргеч ясый. Үз чиратында Г. Тукай да татар труппасы тормышында якыннан торып катнаша: спектакльләргә рецензияләр яза, труппаның шатлыгы белән шатлана, кайгысы белән көенә, гомумән, аның яшәеше белән бик нык кызыксына. Хәтта ул 1910 елда бу труппага «Сәйяр» дип яңа исем дә куша.

1910 елда Г. Кариев «Яшь гомер» пьесасын сәхнәгә куярга тели. Ләкин Г. Коләхметовның бу әсәре тыелганлыктан, Г. Кариев пьесаның тышлыгын алмаштыра һәм шул хәйлә белән максатына ирешмәкче була. Кызганычка каршы, бу хәйлә очраклы гына ачыла, һәм Г. Кариев артыннан, ышанычсыз кеше буларак, яшерен полиция күзәтүе оештырыла.



*Габдулла Кариев һәм Фатыйма Ильская. 1918 ел.*

«Сәйяр» труппасының һәр адымы, Россиянең теге яки бу шәһәрендә күренүе — һәрберсе яшерен күзәтү астында була. 1910 елның августында, труппаның гастрольләре кызган бер вакытта, Нижний Новгород шәһәр полициясе тарафыннан труппаның спектакльләр күрсәтүе тыела. Моның сәбәбен генерал-губернатор Воскресенский Казаннан «театрның үз уеннарыннан җыелган акчаларның 25 процентын яшерен революцион оешмага биреп барганлыгы турында» донесение алуы белән аңлата.

Архив чыганакларын җентекләп өйрәнгән саен, Г. Кариевның алдынгы карашлы кеше булуы, үз чорының җәмгыять төзелешендәге кимчелекләре белән килешмәве, шул вакыттагы Казан губернасында һәм читтә социал -демократик хәрәкәт белән тыгыз элемтәдә булганлыгы тирәнрәк ачыла бара. 1913 елның 13 мартында, Камал Мөхәммәдиев өендә («Өмид» матбагасына каршы), Шиһаб Әхмәров фатирында булып узган Казан яшьләре мәҗлесеннән соң, Казан губернасы жандарм идарәсе әлеге мәҗлесне оештырган Г. Кариевка аеруча нык игътибар итә башлый.

Артистның бенефисыннан соң оештырылган әлеге мәҗлестә Казанның бик күп алдынгы карашлы яшьләре катнаша [1]. Алар арасында В. Мортазин-Иманский, шулай ук Ф. Әмирхан һәм башка әдипләр дә була. Соңыннан бу кичәдә катнашучылардан, шул исәптән, Г. Кариевның үзеннән сорау алулар, тентүләр башлана. Биредә «Россиядәге мөселманнар хәрәкәтең турында сүз барганлыгы да Казан губернасы жандарм идарәсенә мәгълүм була. Бу мәсьәлә буенча тикшерүләр барган вакытта, алдынгы карашлы яшьләр тагын берничә урында җыелышлар уздыралар. Шул ук март аенда учитель Гафур Коләхметов фатирында татар милли яшьләр түгәрәгенең җыелышы булып уза», һәм анда «бай татар сәүдәгәрләре арасында махсус бер фонд булдыру һәм шул фондтан югары һәм урта белем алырга теләүче татар яшьләренә акчалата ярдәм күрсәтү турында көчле агитация алып бару кирәклеге» мәсьәләсе күтәрелә [2]. Бу җыелышта Г. Кариев та катнаша. Димәк, ул Г. Коләхметов кебек күренекле татар революционерлары белән дә тыгыз элемтәдә тора, һәм аларның фикер уртаклыклары булуы бер дә гаҗәп түгел...

1913 елның 4 апрелендә бөек Тукайны соңгы юлга озатканда татар яшьләренең кайгы митингысында сөйләгән чыгышларында бердәмлеккә өндәгән һәм мөселманнарның милли хисләрен уятуга юнәлдерелгән сүзләрнең күп булуы да Казан губернасы жандарм идарәсенең агентура белешмәләрендә теркәлгән.

Г. Кариев оештырган кичәдә, әйткәнебезчә, Ф. Әмирхан да катнашкан. Мәҗлескә чакыру кәгазендә «Казан яшьләреннән үземнең дуст вә аркадашларымны чакырып бер мәҗлес ясау ниятендә идем...» [3] дип әйтелгәннән чыгып, Г. Кариевның нинди мохитта яшәгәнлеген, аның даирәсендә кемнәр булуын күз алдына китерү читен түгел. Бу вакыйгалардан соң берничә ел үткәч, Г. Кариевның таланты алдында баш иеп, аңа сокланып һәм югары бәя биреп, аның белән якын дус булган Фатих Әмирхан болай дип язган иде: «...Татар халкының иң киң гаммәсенең (халык массаларының.— Авторлар) сөеклесе бу зат — татар сәхнәсен оештыру, хәтта аны башлап җибәрүдә, аны тәрәккый иттерүдә иң күп хезмәт иткән, иң күп көч һәм гайрәт сарыф иткән, шул юлда иң күп мәшәкать чиккән бер артист, татар сәхнәсенең мәгънәви атасыдыр... Кариев — чын халык эченнән, ярым пролетарий авыл ярлысы даирәсеннән чыгып, истигъдад (яраклашу), талантны сүндерү,

[1] ТАССР Үзәк дәүләт архивы, 199 ф., 1 тасв., 3612 а эш, 31 б.

[2] Шунда ук, 2848 эш, 32 б.

[3] Шунда ук, 3612 а эш, 31 б.

бетерүдән башкага хезмәт итми торган мохитта тәрбияләнеп, бөтен шартларның каршылыгына зәгъман (карамастан) үз-үзеннән килеп чыккан самородок-талант иде» [4].

1913 елның май башында Г. Кариев, күзәтүләрдән һәм эзәрлекләүләрдән котылып торыр өчен, «Сәйяр» труппасы белән ашыгыч рәвештә Сембер шәһәренә гастрольгә чыгып китә, һәм Казан губернасы жандарм идарәсе үз вакытында сорау алып, тиешле мәгълүматларны үзендә булдыра алмый кала. 4 майда ашыгыч һәм «яшерен» рәвештә Сембер губернасы жандарм идарәсенә хат җибәрелә [5]. Хатның кыскача эчтәлеге моннан гыйбарәт: «...Дәүләт сагы турындагы күрсәтмә тәртибендә, хәзер Сембердә булучы артист Габдулла Кариевтан түбәндәге сораулык буенча сорау алуыгызны үтенәм:

1) Шушы елның 13 мартында Кариев нинди максат белән җыелыш оештырган?

2) Бу җыелышка ул кемнәрне чакырган (чакырылганнарны санап, күрсәтеп чыксын!)?

3) Бу җыелышта нәрсә турында сүз барган?

4) «Хәзерге вакытта мөселманлыкның торышы» турында сүз булганмы?

5) Үткән пасха атнасында Киевта булырга тиешле мөселман студентлары вәкилләренең җыелышы турындагы мәсьәлә тикшерелмәгәнме?

Сезгә шул уңайдан белдерүне кирәк санийм: үткән апрель аеның 17 нче көнендә Киевта мөселман студентларының тыелган җыелышы кулга алынган. Анда рус университетларының, шул исәптән Казан университетының да вәкилләре катнашкан. Бу җыелышта Казан университетының элеккеге студенты Әбүбәкер Имамбаев та булган. Г. Кариев татар укучы яшьләре белән якын мөнәсәбәттә булганлыктан (соңгылары әлеге делегатларның Киевта булачак җыелышы турында белмәскә мөмкин түгел), аның да, ягъни Кариевның да бу турыда белүе турында уйларга нигез бар.

Сорау алу беркетмәсен миңа мөмкин кадәр ашыгыч рәвештә имзагыз белән җибәрүегезне үтенәм. «Сәйяр» труппасы Сембер шәһәреннән Самара, Саратов, Царицын һәм Баку шәһәрләренә китәчәк. Имза».

Шул ук 1913 елның 4 маенда, югарыдагы хат белән бер үк көнне Казан губернасы жандарм идарәсе башлыгы подполковник Добродьев исеменнән берничә нөсхәдә төрле шәһәрләргә бер үк эчтәлектәге хат җибәрелә [6]. «Миңа тапшырылган идарәдә,— диелә хатта,— формаль яктан тикшерелмәгән мәгълүматлар бар. Аларда татар артисты Габдулла Кариевның шушы көннәрдә «Сәйяр» труппасы белән түбәндәге шәһәрләргә чыгып киткәнлеге күрсәтелә: Сембер, Самара, Саратов, Царицын, Әстерхан, Баку, Красноводск, Чарджоу, Мерв, Бохара, Сәмәркәнд, Әндиҗан, Наманган, Коканд, Ташкент, Төркстан, Акмәчет, Козалинск, Оренбург, Нижний Новгород. Бу шәһәрләрдә «Сәйяр» труппасы татарча спектакльләр күрсәтәчәк һәм Нижний Новгородтан кышка аңадан Казанга кайтачак. Артист Габдулла Кариев — алдынгы карашлагы һәм прогрессив юнәлештәге кеше... Казанда яшәп, ул һәрвакыт мөселман студентлары һәм татар укучы яшьләре белән аралашты. Әйтергә кирәк: Кариев югарыда санап үтелгән шәһәрләрдә татар прогрессив элементлары белән күрешәчәк, ә Казанга кайткач, аларны Казан мөселман прогрессистлары белән бәйләнешкә кертәчәк. Язылганнар турында белдереп һәм шулардан чыгып, югарыда аталган Кариев артыннан күзәтү оештыруны һәм нәтиҗәләрен миңа белдерүегезне үтенәм. Имза».

Әлеге хат Оренбург, Сембер, Саратов, Самара, Әстерхан, Баку, Нижний Новгород губерналары жандарм идарәләре башлыкларына, Ашхабадтагы җинаятьләрне эзләү пункты башлыгына һәм Төркстанның район охранка бүлеге башлыгына исемләнеп җибәрелә. Шулай итеп, Г. Кариев үзенең эшчәнлеге нәтиҗәсендә, һәр адымы күзәтү астына алынган атаклы революционерлар кебек, «ил күләмендәге куркыныч шәхескә» әйләнә, аның һәр сүзе, тамашачы алдындагы һәр чыгышы патша хөкүмәте «охранкасын» өркетеп, куркуга салып, зур көрәшкә өндәү булып яңгырый.

Күренгәнчә, Г. Кариев, «мөсафир артистлар җәмгыяте» башында торып, төрле шәһәрләрдә тамашачыларга рухи азык биреп кенә калмый, ә Россиянең бик күп урыннарында яшерен хәрәкәт итүче сәяси оешмаларның эшләре белән кызыксынып, азатлык, демократия идеяләрен пропагандалау эшендә дә турыдан-туры катнаша. Ул үзенең ялкынлы сүзе белән дә, эшчәнлеге белән дә, үзе җитәкләгән «Сәйяр» труппасы куйган спектакльләрдән җыелган акча белән дә, гомумән, һәм рухи, һәм матди яктан, революцион идеяләрнең җиңүе, якты киләчәкне тизрәк якынайту өчен бөтен көчен куя.

1913 елның 16 маенда Казан губерна жандарм идарәсеннән подполковник Прогнаевский язган хатта: «...спектакльдән җыелган акчалар Петербург, Мәскәү, Киев һәм башка шәһәрләрдәге мөселман студентлары түгәрәкләре чыгымнарына тотылды»,— дип әйтелә [7]. «Сәйяр» труппасының революцион фикерле яшьләргә шушылай матди ярдәм күрсәтүе, әлбәттә, бәяләп бетергесез һәм һәртөрле мактауга лаеклы әһәмиятле бер

---

4 «Кызыл Армия» газетасы, 1920, 30 январь, 249 сан.

5 ТАССР УДА, 199 ф., 1 тасв., 3612 эш, 50, 70, 66.

6 ТАССР УДА, 199 ф., 1 тасв., 3612 эш, 49 б.

7 ТАССР УДА, 199 ф., 1 тасв., 3612 эш, 41 б.

күренеш, һәм ул революцион хәрәкәттә-турыдан-туры катнашуга бәрабәр эш дип бәяләнергә хаклы.

Эзәрлекләүчеләр кулына эләкмәс өчен Г. Кариев Сембер шәһәрендә озак тоткарланмый. Сембердә аны кулга алып, сорау алу оештыруны үтенеп язган хатка каршы Казан губернасы жандарм идарәсе башлыгына Сембер губернасы жандарм идарәсеннән полковник Тамилин тарафыннннан мондый яшерен хат җибәрелә[8]: «...3 майда артист Габдулла Кариев «Сәйяр» труппасы белән Сембердә булды һәм бер спектакль куйды. Шул ук көнне Сембердән Идел буенча түбәнгә — Бакуга кадәр чыгып киттеләр. Шунлыктан, аның артыннан күзәтү оештыру мөмкинлеге булмады. Ә Сезнең 4 майда язган 4442 номерлы хатыгыз миңа тапшырылган идарәгә 6 майда гына алынды».

Шул ук хатка өстәмә итеп, шул ук полковник Тамилин имзасы белән Казан губернасы жандарм идарәсенә мондый язу җибәрелә: «...Сезнең 4 майда язылган 4486 номерлы хатыгыздагы Кариевтан сорау алу турындагы таләбегез, башкару өчен, минем тарафтан Баку губернасы жандарм идарәсе башлыгына җибәрелде»[9].

Бакуга барышлый, «Сәйяр» труппасы Саратовта тукталыш ясый. Бирегә Г. Кариев яшерен күзәтү астына алына. Подполковник Добродьев тарафыннан җибәрелгән хатлар тиешле урыннарына бик тиз барып ирешәләр. Казан губернасы жандарм идарәсе башлыгына 1913 елның 18 маенда Саратов губернасы жандарм идарәсе башлыгы тарафыннан «бик яшертен» рәвештә җибәрелгән 45452 номерлы хатта мондый юллар бар: «3 майда язылган 345 номерлы агентура мәгълүматларында искә алынган артист Габдулла Кариев (бу исемне ул сәхнәдә йөртә, ә ачыкланганча, ул Казан губернасы, Чистай өязе, Иске Әлмәт янындагы Күлбай-Мораса авылы крестьяны Миңнебай Хәйруллин булып чыкты), Сембердән Саратовка 6 майда килеп, Ильинская урамындагы... Яңа Үзәк номерларда тукталды. 9 майда «Центральный» кушаматы белән күзәтү астына алынды, яшерен белешмәләр нәтиҗәсендә, аның түбәндәге кешеләр белән элемтәгә кергәнлеге ачыкланды... (Шуннан соң бит ярым күләмендә Г. Кариев белән элемтәгә кергән кешеләрнең исемлеге бирелә, алар арасында Касыйм Шамил, Исмәгыйль Рәмиев, шулай ук артист белән йөрүчеләр һәм Саратовтагы дисталәгән кешеләрнең исемнәре китерелә). 12 майда «Сәйяр» труппасы Саратовтан Әстерханга чыгып китте, бу хакта телеграмма белән Әстерхан губернасы жандарм идарәсе башлыгына хәбәр ителде. Полковник... Имза».

Шулай, бер шәһәрдән икенчесенә күчә-күчә, бер шәһәрдәге яшерен күзәтүләрдән икенчесенә тапшырыла-тапшырыла, «Сәйяр» труппасы Урта Азиягә килеп җитә. Бохара шәһәрендә Г. Кариев үзенең якын дусты, бөтен гомерен азатлык һәм халык бәхете өчен көрәшкә багышлаган Мәхмүт Алиев (1917 елдан башлап — Дулат-Али) белән очраша. Мәхмүт Алиев бирегә 1912 елда, Казан большевикларының бер төркем җитәкчеләре кулга алынгач, аңа да төрмә яный башлагач качып килә һәм шундагы бер байның тире эшкәртү хуҗалыгында эшли башлый. Алар арасында җылы очрашу була. М. Дулат-Али «Сәйяр» труппасы белән аңарчы да тыгыз элемтәдә яши. «Татар театрының оешуына комачауларга маташкан буржуаз милләтчеләрнең һәм фанатик-клерикаль элементларның һөҗүменә кискен рәвештә каршы чыга... М. Дулат-Алиның «Сәйяр» артистлары белән төшкән фоторәсеме бу дуслыкның шаһиты булып калган»[10]. Күренекле большевикның аеруча мөһим йомышларын да үтәргә туры килгәләгәндер Г. Кариевка. Чөнки бер шәһәрдән икенчесенә күчеп йөргәндә, яшерен сәяси оешмалар арасында элемтәче вазифасын башкаруда Г. Кариев җитәкләгән «Сәйяр» труппасыннан да кулайрак «курьер»ны күз алдына китерүе дә читен.

Нинди генә яшерен күзәтүләр оештырылмасын, Г. Кариев, үзенең труппасы белән булган һәрбер җирдә, артта калган халыкларның милли аңын уятып, алдынгы караштагы укымышлылар белән очрашулар һәм әңгәмәләр оештырырга мөмкинлекләр таба. Ул халыкларда әдәбиятка, театр һәм музыка сәнгатенә омтылыш уятуда этәргеч ясый. Нәкъ менә Г. Кариев җитәкчелегендәге татар театры труппасы белән очрашкач, үзбәк халкының бөек улы Хәмзәдә үзбәк театры булдыру хыялы уяна һәм ул шул эшкә үзенең бөтен гомерен багышлый...

Шушындый авыр һәм катлаулы көрәш елларындагы һәртөрле эзәрлекләүләр һәм комачаулыклар Г. Кариевның рухын, ихтыярын һич какшатмый, киресенчә, чыныктыра гына. Ул — халыкка бирелгәнлеге, халык бәхете өчен көрәштә үзеннән лаеклы өлеш керткәнлеге, татарның һәрбер мәдәни хәрәкәтенә каршы төшкән кара көч белән туктаусыз көрәшүче булганлыгы һәм шул юлда күрсәткән фидакарьлекләре белән исән вакытында ук халыкның зур хөрмәтен казанган шәхес.

Февраль революциясе көннәрендә Г. Кариев, капиталистлар ялчылыгындагы бер төркем милләтчеләрдән аерылып, эшчеләр, солдатлар файдасына спектакльләр куя,

---

[8] Шунда ук, 51 б.

[9] ТАССР УДА, 199 ф., 1 тасв., 3612 а эш, 34 б.

[10] «Казан утлары», 1979, 5 сан, 165 б.

Г. Кариев, революция кануннары белән таныш булган сәяси көрәшче булудан бигрәк, артист иде, һәм ул революциянең җиңүендә турыдан-туры революционер буларак катнашмаса да, кулыннан килгәнчә, халыкның күңелен уятып, агартып һәм сафландырып, халыкны зур көрәшкә әзерләү эшенә актив катнашып, әлеге зур җиңүгә сәхнәдән торып булышлык итте. Г. Кариевның катлаулы иҗат тормышын тасвирлап, аның җаны-тәне белән сәхнәгә, халкына бирелгәнлеге турында якын дусты Галимҗан Ибраһимов болай дип язган иде: «...Үзенең шөһрәте белән татар дөньясын яңгыраткан Габдулла Кариев түбәннән, татар тормышының төбеннән, ярлы, караңгы авыл эченнән күтәрелде.

Шуннан күтәрелеп, халыкның аңлавы, салкын караулары, башта һичкемнең тәкъдир итмәве, бетмәс-төкәнмәс ачлыклар, матди кынлыклар, иге-чиге булмаган газаплар, михнәтләр аша барып, татар театр мәданында беренче урынны алды гына түгел, татар дөньясында сәнаигы нәфисәне (матур сәнгатьне.— а в т.) тудыручыларның берсе, беренчесе булды. Кариев өчен тормыш, дөнья, бәхет, сәгадәт юк, тик театр бар, шул театрны үстерү өчен яну, шуның шатлыгы белән шатлану, кайгысы белән көю бар иде» [11].

Язмышның изүен, тормышның искиткеч авырлыкларын үз җилкәсендә татуы Г. Кариевның сәламәтлеген нык какшата. Инде илебез өстендә Октябрь кояшы балкып, иҗат итәргә бөтен мөмкинлекләр ачылгач, ир-егетнең дөнья җимертеп эшли торган вакытында — гомеренең 34 нче елында ул бик нык авырый башлый, ләкин авыру-сырхауларны да җиңеп, сәхнәдә уйнавын дәвам итә. Вафатына нәкъ ике атна калгач, 1920 елның 16 январенда «Советский большой театр» бинасында уйналачак «Сәяси сакал» комедиясендә (Кәрим Тинчурин) Г. Кариев төп рольләрнең берсен башкаруы турында шул чорның матбугатында игълан ителә. Гомеренең соңгы көненәчә татар сәхнәсенә тугрылыклы булып калган, дәваланып, көч туплау турында уйлап та карамаган Г. Кариевның хәле көннән-көн авырая барып, ул 1920 елның 28 январенда сәгать 4 тә вафат була. Мәрхәмәтсез үлем татар профессиональ театр сәхнәсе күгендә балкып торган беренче йолдызны сүндерде. Ләкин аның вакытсыз үлеме ул башлаган эшне яңа биеклекләргә күтәрү юлында армый-талмый иҗат итәргә, ул эшләп бетерә алмаган эшне яңа көчләргә, аннан соңгы буынга башкарырга чакыру булып яңгырады, аның эшенә тугрылыклы булырга ант авазлары булып ишетелде. «...Икенче «Тукай» булып үлде,— дип яза аның үлеменә багышлаган «Татарның бөек артисты Г. Кариев» исемле мәкаләсендә Фатих Сәйфи-Казанлы.— Ләкин Кариев үлсә дә, аның эшләре, аның чиккән газаплары татар мәдәнияте тарихында онытылачак түгел, шуның белән бергә Кариевның татар сәхнәсе өчен көрәш юллары — бик озак вакытлар кызыл юл булып торачаклар» [12].

Г. Кариевның кыска гына гомерендә, нибары 13 еллык иҗат эшчәнлегендәге дәверендә татар профессиональ театр труппасын юктан бар итеп оештыруда, сәләтле һәм бердәм коллектив туплауда титаннарча эш башкаруын күрсәтеп, аңа лаеклы югары бәя биреп, сәхнәдәш дусты һәм якын фикердәше булган Кәрим Тинчурин үзенең «Сәйяр» труппасы һәм Казан артистлары исеменнән Кариевның җеназасы өстендә әйтелгән ахыргы сүзендә болай ди: «Гасырлар буена эшләнә торган зур эшне — татарча театр тудыру эшен, театр эшенең татарлар арасында гражданлык казану эшен гайрәтле Кариев унөч ел эчендә эшләде...

...Татар театры яшәгән мөддәттә Кариев яшәргә тиеш, чөнки Кариев татар театрының рухы ул» [13].

Әйе, Г. Кариевның татар сәнгате тарихында тоткан урыны һичшиксез зур. Татар халкының Г. Тукай, Х. Ямашев, М. Вахитов, Ф. Әмирхан, Г. Коләхметов, Г. Камал, Г. Ибраһимов кебек атаклы шәхесләренең турыдан-туры йогынтысында дөньяга карашы формалашкан, җитлеккән һәм авыр көрәш юлларын үткән Г. Кариев үзе дә алар белән беррәттән торырга лаеклы.

---

[11] «Кызыл Армия» газетасы, 1920 ел, 1 февраль, 250 сан.

[12] «Кызыл Армия» газетасы, 1920 ел, 1 февраль, 250 сан.

[13] Шунда ук.

# АТАКЛЫ ЯКТАШЫМ

Мин, Хәйруллин Шамил Хәйрулла улы, 1886 елда элекке Чистай өязенең Иске Әлмәт волосте, Күлбай-Мораса авылында туганмын. 1905 елда шул авылда Ярулла мулла мәктәбенә укырга кердем. 1909 елда Абруй апа Камалова (соңыннан Абруй Сәйфи), Иж-Буби мәктәбендә укып кайткан Мәрьям апа Хәмитова белән бергәләп, авылда кызлар мәктәбе оештырдылар. Мин дә анда бераз укып йөрдем, чөнки алар яңача укыталар иде.

Мин Габдулла Кариевны шуннан беләм: аның туган энесе Хәйруллин Габдрахман белән без бергәләп укый идек. Габдулла безгә төрле кызыклы китаплар укый торган иде. Аннан соң ул Уральск шәһәренә укырга китте. Мин 1915—1918 елларда армиядә булдым. 1918 елның март башларында армиядән кайткач, авылыбызда «Нур» исемле бер түгәрәк төзеп, спектакльләр, әдәбият кичәләре оештыра башладык. Габдулланың «Артист» исемле пьесасын да сәхнәгә куйдык. Яшьләр һәм, гомумән, авыл халкы безнең спектакльләргә кызыксынып йөри башлады. Ләкин спектакльләр куярга иркенрәк урын булмау безне борчый иде. Габдулла Кариевның эшләрен киңрәк җәелдерү максаты белән, Иске Әлмәт авыл Советы председателе Шакир Әминевтән бояр Островскийдан калган зур агач амбарны безгә бирүен үтендек. Рөхсәт алгач, ул амбарны Күлбай-Морасага күчереп, клуб ясадык. Клубка Г. Кариев исемен бирдек.

Бераз вакыт узгач, бу клубның кечкенә булуы безгә комачаулый башлады. 1924 ел җитте. Драмтүгәрәкнең членнары киңәшеп, Габдулланың иптәшләренә ярдәм итүләрен үтенеп хат яздык. Хатны Казанга үземә алып барырга туры килде. Чөнки ул вакытта Татнаркомземда Фатих Сәйфи-Казанлы эшли, ә Абруй Сәйфи минем укытучым иде. Миңа аларның квартираларына туры барып керү авыр түгел иде. Шулай булды да. Мин хатны аларга алып бардым. Чәй янында эшнең асылын сөйләп бирдем. Фатих безгә якын урманнан бер диләнкә агач кисәргә рөхсәт итте. Соңыннан клуб салу фондына бер спектакль дә куелды. Шулай ук безгә Габдулла Кариевның художник тарафыннан эшләнгән рәсемен дә бүләк иттеләр. Әлеге рәсем хәзер Күлбай-Мораса авыл Советында саклана.

**Шамил ХӘЙРУЛЛИН,**
Октябрь районы, Күлбай-Мораса авылы.

# КАРИЕВ ТУРЫНДА БЕЛГӘННӘРЕМ

1909—1912 елларда, Казанда укып йөргән чакта, безгә (шәкертләргә) Г. Кариев белән еш очрашырга туры килә, чөнки ул безне пьесалар куйганда массовкада уйнау өчен клубка чакыра иде. Шуңа күрә аның рольләрне искиткеч яхшы башкаруы безнең хәтердә бик нык урнашып калган. Мәсәлән, «Безнең шәһәрнең серләре» пьесасыннан Мөхәммәтҗан Хафиз ролен ул нәкъ Мөхәммәтҗан Хафизның үзе булып уйнады. Аның маймылларча кыланышларын искиткеч дөрес күрсәтүе — эч катыргыч, гаҗәеп бер күренеш, гаҗәеп бер оста уйнау иде. Ул бу пьесаны куюдан күп элек, Мөхәммәтҗан Хафизның Печән базары мәчете янындагы киоскысына якын килеп, урамның каршы ягында торган хәлдә, Хафизның үз нярченнәре — кадимчеләр белән ничек сөйләшкәннәрен, ничек кыланганнарын, кыскасы, Хафизның барлык маймыллыкларын җентекләп өйрәнгән һәм шул кыланышларны спектакльгә керткән.

Шушы уңай белән «Сәйяр» труппасында уйнаган тагын бер артист — Бари Болгарский турында да бер-ике сүз әйтәсе килә. Ул карчыклар ролен уйнауда чагыштыргысыз оста бер артист иде. Ул тавышы белән дә, кыланышлары белән дә, сөйләүләре белән дә нәкъ карчыкларның үзләре булып уйный ала торган артист иде.

**Риза ГАЗИЗОВ.**

## *Галия Кайбицкаяга 80 яшь*



Галия Мотыйгулла кызы Кайбицкая 1906 елда Уральск шәһәрендә туган. Кече яшьтән үк ул сәнгатькә гашыйк була һәм үзенең сәхнәдә уйнау сәләтен ача. Өйләрендә җыелган кунакларга Тукай шигырьләрен укый, халык җырларын җырлап күрсәтә. Үзенә унҗиде яшь тулган көннәрдә ул Казанда театр техникумы ачылу хәбәрен ишетә һәм, озак уйлап тормастан, әлеге уку йортына китәргә карар кыла.

Казан театр техникумында Галия, сәнгатькә гашыйк яшьләр белән бергә, Фатыйх Әмирхан кебек күренекле әдиптән дәресләр алу бәхетенә ирешә. Беренче уку елында ук спектакльләрдә катнаша башлый. Яшь артистканың сәләтенә Һади Такташ та, Мирхәйдәр Фәйзи дә игътибар итә. Музыкаль рольләрдә аның иҗат мөмкинлекләре киңрәк ачыла, һәм ул үзенең сәхнә эшчәнлеген шушы юнәлештә алып барырга омтыла.

Драма театрында ун ел эшләү дәверендә (1923—1933) Г. Кайбицкая күп кенә образлар иҗат итте. Шулар арасыннан Мәршидә («Казан сөлгесе»), Сәрвәр («Сүнгән йолдызлар»), Мәйсәрә («Зәңгәр шәл»), Гөлйөзем («Наемщик»), Гөлəндәм («Кандыр бүе») кебек образлар татар театр сәнгатенең казанышлары буларак кабул ителделәр.

1934—1938 елларда Г. Кайбицкая Мәскәү консерваториясе каршында оештырылган Татар опера студиясендә укый, профессор Д. Беляевская классында опера сәнгате серләренә өйрәнә. Яңа туган татар опера театрында куелган беренче әсәр — «Качкын» операсында (Н. Җиһанов) ул төп партияне уңышлы башкара. Татар, рус һәм башка милләт композиторлары әсәрләре буенча куелган спектакльләрдә гомум галереяга кереп калырлык дистәләгән образлар иҗат итә, опера сөючеләрнең зур мәхәббәтен казана. Татар дәүләт опера һәм балет театрында эшләгән елларда (1939—1958) Г. Кайбицкая татар халык җырларын, шулай ук совет композиторларының вокаль әсәрләрен популярлаштыруын да нәтиҗәле төстә дәвам иттерә.

Театр өлкәсендә күрсәткән хезмәтләре өчен 1939 елда Галия Кайбицкаяга Татарстанның халык артисткасы дигән мактаулы исем бирелде, «Почет билгесе» (1950), Хезмәт Кызыл Байрагы (1958) орденнары белән бүләкләнде.

Журнал укучыларга сиксән яшен тутырган күренекле артистка Галия Кайбицкаяның сөекле композиторыбыз Салих Сәйдәшев турындагы истәлеген тәкъдим итәбез.

# БӨЕК ИҖАТЧЫ РУХЫ

Татар музыка тарихында меңа аерата ике күренеш зур тәэсир калдырды һәм әлегәчә күз алдымда җанланып торалар. Берсе — Салих Сәйдәшевкә 50 яшь тулу уңае белән ясалган тантаналы юбилей. Ул көннәр күңелләрдә шатлык тулган көннәр булды. Бу бәйрәмдә С. Сәйдәшевнең иҗатына бәя биреп, музыкабызның үсешенә чиксез куанган идек. Икенчесе — сөекле композиторыбызны күмгән көннәр. Халыкның талантлы улын озатканда, матәм музыкасының кайгылы яңгыравы астында меңнәрчә кеше аның белән саубуллашты. Халкыбызга кояштай җылылык биреп яшәгән композиторыбызның салкын тәне кабергә төшерелеп, туфрак белән күмелгән вакытта, С. Сәйдәшевнең үз васыяте буенча, чиксез оптимистик «Кызыл Армия маршы» яңгырады. Бу очраклы хәл түгел иде. Чөнки аның бөтен иҗаты оптимизм белән сугарылган. Ул җирләгәндә дә, актык сүзен әйткән кебек, үзенең шул оптимистик маршын уйнауны теләде.

Салих Сәйдәшевнең иҗаты халкыбызның героик эшендә һәм көрәшендә юлдаш булып килде. Аның йөрәктән чыккан көйләре кайгыда да, шатлыкта да халык белән бергә булды, иҗаты халкыбызга яңа социалистик тормыш төзүдә булышты. Шуңа күрә дә Салих Сәйдәшевнең иҗади мирасы татар совет музыкасы тарихында гына түгел, бөтен Советлар Союзында яшәүче халыкларның музыка тарихында зур һәм кыйммәтле урын алды. Ул безнең беренче татар профессиональ композиторы булып, үзенең моңлы көйләре, гүзәл иҗаты белән халкыбызның зур мәхәббәтен казанды, аны белмәгән, сөймәгән һәм танымаган кеше булмады. Музыкасы илебезнең бөтен тарафларында көчле яңгырады. Ул үзенең беренче музыкаль әсәрләрен яза башлаган көненнән алып иҗатының иң биек баскычларына менгән вакытларына кадәр һаман бер стильдә — үзенә генә хас булган стильдә иҗат итте. Соңгы көненә кадәр үз иҗади телен баета килеп, серле музыка телендә халык белән сөйләшә белде, халыкка үз күңеленең байлыгын җиткерә һәм халыкның теләкләрен, уйларын гәүдәләндерә алды. С. Сәйдәшевнең музыкаль теле хезмәт ияләренә якын булганлыктандыр ахры, аның музыкасын беренче аккордлардан ук таныйлар һәм рәхәтләнеп тыңлыйлар.

Шунысы характерлы: С. Сәйдәшев музыкасы чын-чыннан саф татар музыкасы булып, бүтән милләт кешеләре тарафыннан да яратылып тыңлана һәм кабул ителә. Бу үзе генә дә аның тумыштан килгән талантлы композитор булганлыгын раслый һәм музыканың интернациональ характерына дәлил булып тора.

Татар музыкасына хас булган пентатониканы баету юлында, әсәрләрен гармонияләштерүдә ул бөтен кешелек тарихы тудырган музыкаль культурадан иркен файдаланды. Халык ул язган һәрбер нәрсәне үзенеке итеп кабул итте. Моны С. Сәйдәшевнең классик музыкаль культураны үзенең таланты аша үткәреп үзләштерә белүенең нәтиҗәсе дип аңларга кирәк.

Бигрәк тә без, җырчылар, С. Сәйдәшев музыкасының рус классик музыкасына якынлашуына, шуның нәтиҗәсендә, үзебезгә дә рус классик музыкасы аңлаешлы булуына сөенә идек. С. Сәйдәшевнең музыкасы халыкчан булуы белән бергә, безне бөек рус композиторлары П. Чайковский, Н. Римский-Корсаков һәм башкаларның музыкаларына якынайта, аларга булган мәхәббәтебезне арттыра иде.

1923 ел. Миңа 17 яшь. Казанда татар театр техникумының оешкан елы. Шушы елның беренче сентябрендә монда укулар башланды. Мин техникумга алынган көнемнән үземне чиксез бәхетле санадым. Үземне хисапсыз иркен хис итеп, техникумны үз йортым күк күреп яшәдем.

Техникумның тулай торагына күчкәнгә өч көнә көн. Әле бергә яшисе кызларым белән дә танышып өлгермәгән. Менә: «Галия Кайбицкаяны кемдер сорый»,— дип, мине чакырып алдылар. Сынау вакытында минем фамилия Тәхфәтуллина булса да, Кайбицкая дип дәшкәнне ишеткәч, «Әдһәм абыем Кайбицкий килгәндер ахры»,— дип йөгереп чыктым. Әдһәм абыем үзенең сәхнә фамилиясен туган авылыбыз Кече Кайбыч исеме белән йөртә иде. Коридорга йөгереп чыксам, минем каршымда бөтенләй башка кеше басып тора. Уртача буйлы, зәңгәр күзле, кара бөдрә чәчле сөйкемле бер яшь егет. Ул миңа: «Исәнмесез! Сез Галия Кайбицкая буласызмы?» — дип, миңа абыем фамилиясе белән эндәште. Кыяр-кыймас кына кулымны кысты да: «Мин театрдан килдем, исәнмесез!» — диде. Исәнләшкәннән соң ул миңа: «Сезне эзләп килүемнең сәбәбе — безнең театрда спектакль көнендә сәхнә артында җырлау өчен бер кыз кирәк иде. Сез җырламассызмы икән дип килгән идем»,— диде.

Бу чакыруга мин хәйран калдым. Казан театр техникумына драма артисткасы булу теләге белән килүемә атна да үтмәде, менә сиңа! Мине театрга җырларга чакырырлар дип кем уйлаган?! Бу чакыруга мин аптырап, ни әйтергә сүз таба алмыйча, чиксез уңайсызланып кызардым, җавапсыз калдым. Мөгаен, бу эшне минем Әдһәм абыем кузгаткан булса кирәк дип уйладым. Әдһәм абыем ул вакытта татар театры артисты булып, Мохтар Мутин, Әсгать Мәҗитовлар белән бергә театр ишегалдындагы тулай торакта яшиләр иде. Абыем минем бала чагымнан җыр яратуымны аңа сөйләгән булса кирәк.

Шуңа карамастан, мин чакырып килгән егеткә: «Юк, мин булдыра алмыйм, Казан театрында җырлар өчен минем мәгълүматым аз»,— дип җавап бирдем. Ул минем бу сүзләремә әһәмият бирмәде. «Мин сезне үзем өйрәтәм, сезгә авырлык китермәм, сәхнә артыннан гына тавыш бирәсе»,— дип янә минем ризалыгымны сорады. Мин катгый рәвештә риза булмагач, ул: «Ярар, кызый, мин иртәгә тагы бер килеп китәрмен әле. Сез дә бераз уйлап карарсыз»,— дип чыгып китте. Мин бик күңелсезләнеп, баскан җиремдә уйланып калдым.

Көннәрдән бер көнне Салих Сәйдәшев: «Әйдә әле, Галия, мин сиңа үзебезнең татар театры бинасын күрсәтеп килим, сез, яңа килгән укучылар, театрны күрмәгәнсездер»,— дип, мине алып китте. Театрга керү белән ул тиз генә пианино янына килеп утырды да төрле көйләр уйный башлады. Билгеле, аның бар нияте, мине театрга алып килеп, җырлатып караудан гыйбарәт булган, әлбәттә. Бераз уйнап алды да: «Сезгә бу

көйләр ошыймы?»— дип сорап куйды. Һичшиксез, композиторның матур уйнавы мине сөендерде. Үземә таныш булган татар көйләрен ихлас күңел белән тыңлаганнан соң, «Менә болар инде мин язган көйләр булыр, яратырсыз микән, тыңлап карагыз әле,— диде дә күп төрле көйләр уйнап күрсәтте. Гаҗәеп хәл, беренче мәртәбә композитор белән танышу көнемдә үк аның музыкасы, аерата матур һәм йомшак уены, үзенә генә хас булган нечкәлектәге моңы, һәр көйгә муафыйк аккордларның яңгыравы минем музыкага булган мәхәббәтемне көчәйтте. Сәйдәш моңына кереп чумдым. Ул уйнаган саен, тыңлыйсым килде, моңнарына кушылып җырлап җибәрәсем килде. Мондый теләгемне композитор да сизде булса кирәк, миңа карап елмайды да, үзе язган көйләрен уйнап шыңшый башлады. Бераз шулай җырлаганнан соң ул миңа: «Сез дә кушылып җырлап карагыз инде»,— дип, минем кушылып җырлавымны теләде. Мин, композиторның әйтүен көтеп кенә торган кук, ихтыярсыз аңа кушылып җырлап җибәрдем. Композитор үзе, минем җырлавымны тыңлап, уйнавын дәвам итте.

Спектакль көнендә сәхнә артында мин җырларга тиеш булдым. Салих Сәйдәшев сәхнә алдында, халык арасында булып, мин сәхнә артында басып, Габдулла Тукай сүзләре белән «Зиләйлүк»не җырладык. Шулай да минем беренче мәртәбә җырлавым, каушаудан-оялудан килгәндер, халыкка ишетелерлек матур чыкмады. Әмма композитор С. Сәйдәшевнең күңеле сүрелмәде. Киресенчә, «Икенче җырлаганда тавыш биребрәк җырларсың»,— дип, мине юатты.

Икенче атнада да сәхнә артында басып җырладым. Көчле тавыш биреп җырлаган идем. Җырлап бетерү белән халыкның кул чабуын ишетеп: «Димәк, минем тавыш халыкка ишетелгән»,— дип сөенеп куйдым. Әмма Салих үзе сәхнә артына кереп, миңа: «Бу халык безгә хөрмәт йөзеннән кул чапкандыр»,— дип гаҗәпсенеп, бүгенге җырлавыбыздан да риза булмады. «Күп тавыш бирелде, урта сызыкны табарбыз»,— диде, миңа үз киңәшен биреп.

Шул кичтән соң без С. Сәйдәшев белән еш очраша торган булдык, күп кенә репетицияләр ясый идек. Репетиция вакытында ул, пианинода уйнап, сәгатьләр буена мине яныннан җибәрми җырлатыр иде. Нинди генә көй җырлатмады, нинди генә көйләр өйрәтмәде! Соңрак зур әсәрләргә ябыштык. Драматург Мирхәйдәр Фәйзинең «Асылъяр» пьесасын алып, андагы һәрбер җырны җентекләп, төрле яңа татар көйләрен өстәп өйрәнә идек. Композитор, пьесада булган җырларның һәрберсенә яңа көйләр табып, аларны минем тавышка үзенчә эшкәртеп, нотага сала иде. Яшь җырчыга уйнар өчен җиңеллек китерү ниятеннән җырларны гына түгел, хәтта сөйләү текстларын да миңа ничек сөйләргә, ничек әйтергә өйрәтә иде. Мин текстны җыр белән бәйләп сөйләгәндә, Салих миңа: «Син Ләләнең нәкъ үзен китерәсең бит»,— дип әйтер иде. Сәйдәшев минем образга кереп җырлавымны мактап сөйли, мине тагы да дәртләндерә иде.

Без 1924 елгы җәйнең бик эссе вакытында татар драма театры артистларының яртысы составы белән (ярты состав артистлар ялга китеп таралган чак) Эрмитаж бакчасында М. Фәйзинең «Асылъяр» музыкаль драмасын күрсәттек. Уйнаучылар: Шәрәф — Габдрахман Камал II, Ләлә ролендә мин булдым. Башка образларны Нәфига Арапова, Мохтар Мутин, Гөлсем Болгарская, Колмәмәт һ. б. артистлар гәүдәләндерде. Сәхнә кырыенда С. Сәйдәшев музыканы пианинода уйнап торды. Эрмитаж бакчасы халык белән тулы булды. Кассада билетлар күптән сатылып беткән иде. Спектакль зур күтәренкелек белән узды. Халык артистларны бик җылы каршы алды, пәрдә төшкән саен аларны кат-кат чакырып, кул чабып зурладылар.

Соңгы пәрдәдә баш иеп торганда залдан берәү — башында салам эшләпә, өстендә җиңел пальто булган, кулына искиткеч матур таяк тоткан урта буйлы бер ир кеше безгә таба елмаеп килә. Шәрәфне уйнаучы Габдрахман Камалдан: «Кем бу, безгә таба очкынланып килә?»—диюемә каршы ул миңа: «Үзең уйнап торган спектакльнең авторы була, Мирхәйдәр Фәйзи килгән бит»,— дип җавап бирде.

Драматург сәхнә артына туры керде дә: «Кая икән минем Ләләм?» — дип эзләнә башлады. Мин шунда баскан килеш, үземнең Ләлә образында икәнлегемне онытып, якягыма каранып, Ләләне эзли башладым. Шул ара автор абый минем янга килде дә: «Яхшы уйнадыгыз, тавышыгыз матур яңгырады»,— диде. Безне берәм-берәм тәбрикләгәннән соң ул, Салих Сәйдәшев янына килеп, күкрәгенә кулын куйган килеш, аңа тирән ихтирам белән рәхмәт әйтеп баш иде, үзен кочаклап алды. Шулай бергә чыгып киттеләр. Аларга сокланып карап тордым. М. Фәйзине мин шуннан соң күрә алмадым. Күп елларга сузылган авыруы көчәеп, ул дәваланырга киткән җиреннән кайта алмады, вафат булды. Әмма үзең уйнаган шундый көчле әсәрләрнең авторын бер күреп калу да үзе бер зур бәхет икән. Аның мөлаем йөзе минем күз алдымнан китмәс булды. Аның әсәрләрендәге образлар уйнаган саен аны искә төшерде.

Миңа, җырчы буларак, Салих Сәйдәшев белән бер чордарак иҗат итәргә туры килде. Мөлаем йөзле Салих бик итагатьле, ягымлы һәм йомшак характерлы кеше булды. Күңелле сөйләшә, кызыклы сүзләр әйтергә дә ярата иде. Аның сөйләгәнен тыңлаган кешеләр «Салих Сәйдәшевнең сөйләшү манерасы нәкъ үзенең музыкасы кук ягымлы

яңгырый»,— диләр иде. Салих үз музыкасын язганда, хәзер бер көй башыма килде дип, җиңел генә җилкәсен бер селкетеп куяр иде дә, шатланып, пианино алдына килеп яза да башлар иде. Әмма ул, клавишларга бармак белән сугып, ниндидер көй эзләп утырмады, «көйләрем үзләреннән-үзләре күңелгә килеп торалар бит»,— дип, пианинода әр-яңа нәрсәне шатырдатып уйнап җибәрә иде.

Җиңел язу турында. Бер көнне татар драма театрында Кәрим ага Тинчуринның «Кандыр буе» әсәрен куярга әзерләнәбез. Беренче бригада башлыгы образын — Ситдыйк Айдаров, икенче бригада башлыгын мин әзерли идек. Салих минем янга килеп: «Галия! Спектакльне кую вакыты килеп җитте, ә син җырлыйсы җырның музыкасы язылып бетмәгән килеш тора. Аны язып бетерергә кирәк бит. Ярты көй булып калмасын»,— диде. Мин: «Ярар, Салих, җиткәне белән туктар»,— дип, кычкырып көлеп куйдым. Ул, ягымлы елмаеп, бераз карап торды да: «Менә, менә, шат Гөләндәмнең үз тавышын бирдең син. Әйдә әле, болай булгач, көйнең ахырын бетереп бирәм мин сиңа»,— диде дә пианино бүлмәсенә чакырып алды. Үзе пианино алдына килеп утыруга, тиз-тиз төрле аккордлар биреп, «минем көлү тавышымны» язылган ярты көенә кушып, бик тиз арада көй китереп чыгарды. Һәм аннары: «Менә хәзер җырласаң да була инде»,— дип, иркен сулап, яңа тәмамлаган нотасын сузды. Күреп торам, хәзер аның күзләре очкынланып яналар, йөзе тагын да яктырып киткән.

Шулай тавышларны кинәт кенә тотып алып, минуты белән музыкага сала белү осталыгын миңа шактый күрергә туры килде. Мондый иҗади тизлек композиторның бик тәэсирләнеп, тирә-юньдәге вакыйгаларны үз йөрәге аша тирән кичерүеннән киләдер.

Татар дәүләт академия театрында күп көч куйган күренекле сәхнә осталарыбыздан берсе Нури Сакаев, көндезге репетиция вакытында сау-сәламәт булган кеше, кичен кинәт вафат булуы белән барыбызны да кайгыга салды. Аны югалту бик авыр булды безгә. Салих бигрәк тә авыр кичерде. Алар бик якын дуслар иде. Сакаев үлгән көннәрдә Салих, кеше күзеннән югалып, ялгыз утырды, йөзе-күзе чиксез кайгылы булды. Менә ул театр бинасының өске катка менә торган баскыч астындагы рояль алдында, башын бер якка авыштырып, акрын гына клавишларга баса. Күрәм, аның йөзе үзгәргән, күзләре ярым йомылган. Нидер яза. Эндәшми генә үтеп киттем. Моннан соң ярты сәгать тә үтмәде, Салих, ноталарын күтәреп чыкты да, үз янына оркестрантларын җыеп: «Менә бу нәрсәне оркестрга салып карыйк әле»,— дип, музыкантларга хәзер генә язган нота кәгазьләрен таратты. Оркестрның уйнап җибәрүе булды, бөтен театрны моңлы «Матәм маршы» яңгыратты. Бу маршны ишетү белән, чиктән тыш әсәрләнеп, бер-беребезгә елышып үкси башладык. Композитор Салих Сәйдәшев үзе дә, күзләрен сөртә-сөртә: «Бу минем Сакайга соңгы бүләгем, «Сакай маршы» дип атарбыз»,— диде.

Музыка үз телебез булып яңгырады. Шушы тел белән, гүзәллек белән композиторыбыз Салих Сәйдәшев, күп сандагы музыкаль драмаларга көй язып, халык каршында мәхәббәт казанды. Шулай ук симфония әсәрләренә дә ул халык җырларын, халык моңнарын нигез итеп алды. Аның язган әсәрләре туачак опера һәм балет жанрына нигез салды дип әйтсәң дә була. Икенче буын композиторларның Салих Сәйдәшев тирәсенә тупланып, аның музыкасы белән тәрбияләнеп үсүләре, шулай ук җырчылар күп еллар татар драма театрында музыкаль әсәрләрдә җырлап, тәрбия күреп, Мәскәү консерваториясендә укып, опера һәм балет театрын ачу дәрәҗәсенә җиттеләр.

Минем бөтен яшьлегем татар драма театрында Салих Сәйдәшев һәм Кәрим Тинчурин тәрбиясендә иҗат итү белән узса, икенче яшьлегем опера театрында күп еллар хезмәт итү белән узды. Опера театрында Нәҗип Җиһанов, Мансур Мозаффаров, Җәүдәт Фәйзи һәм Көнбатыш Европа классик композиторларының операларында Виолетта, Джильда, Маргарита, Рәйхана, Бибисара, Саҗидә, Сусылу, Карлыгач, Алтынчәч кебек зур образлар, кыскасы, опера сәхнәсендә куелган спектакльләрнең һәрберсендә колоратур сопрано партияләрен җырлап баруга ирештем. Миңа шулкадәр партияләр җырлауга һәм катлаулы җитди хезмәт башкаруга сөекле композиторыбыз Салих Сәйдәшевнең йогынтысы, аның музыкасына булган мәхәббәтем гаять зур ярдәм итте. Иҗатта уңышларга ирешүем шулай ук Кәрим ага Тинчуринга һәм чиксез талантлы академия театры артистлары коллективына килеп тоташа.

Галия **КАЙБИЦКАЯ**,

Татарстанның халык артисткасы.

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ПАРТИЯ ОЕШМАСЫНДА

17 мартта Язучылар союзы һәм Татарстан китап нәшриятының берләштерелгән ачык партия җыелышы булып узды. Партиянең XXVII съезды йомгаклары һәм язучылар оешмасының бурычлары турында доклад белән КПССның XXVII съезды делегаты, Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Т. Миңнуллин чыкты. Фикер алышуларда язучы Г. Ахунов, Татарстан китап нәшрияты директоры Г. Н. Шәрәфетдинов, тәнкыйтьче Ф. Миңнуллин һ. б. чыгыш ясап, бүгенге әдәбият, язучылар, нәшрият хезмәткәрләре алдына съезд куйган бурычлар, аларны тормышка ашыруда нәтиҗәле чаралар куллану кирәклеге турында сөйләделәр, тәкъдимнәрен әйттеләр.

## МӘСКӘҮДӘ МУСА ҖӘЛИЛГӘ БАГЫШЛАНГАН КИЧӘ

20 мартта башкалабыз Мәскәүдә, Союзлар йортының Колонналы залында Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты шагыйрь Муса Җәлилнең тууына 80 ел тулуга багышланган кичә үткәрелде.

Президиумда — РСФСР Верховный Советы Президиумы Председателе В. П. Орлов, СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре Т. Н. Ментешашвили, КПСС Үзәк Комитетының культура бүлеге мөдиренең беренче урынбасары З. П. Туманова, КПСС Үзәк Комитетының пропаганда бүлеге мөдире урынбасары В. П. Зарубин, РСФСР Министрлар Советы Председателе урынбасары Е. М. Чехарин, КПСС Үзәк Комитетының оештыру-партия эше бүлеге сектор мөдире Г. Х. Шиляев, РСФСР культура министры Ю. С. Мелентьев, КПСС Үзәк Комитетының оештыру-партия эше бүлеге инструкторы И. А. Абрамов, КПССның Мәскәү шәһәр комитеты секретаре А. А. Низовцева, КПСС Үзәк Комитетының, СССР һәм РСФСР Верховный Советлары Президиумнары, Министрлар Советларының башка җаваплы работниклары, СССР һәм РСФСР Язучылар союзы идарәләре секретарьлары, СССР һәм РСФСР иҗат союзлары һәм оешмалары житәкчеләре, ТАССР Верховный Советы Президиумы председателе Ә. Б. Баһаветдинов, ТАССР Министрлар Советы Председателенең беренче урынбасары М. Х. Хәсәнов, М. Җәлилнең хатыны Әминә Җәлилова, кызы Чулпан Җәлилова, шагыйрьнең фашизмга каршы көрәштәшләре.

Кичәне кереш сүз белән Муса Җәлил юбилеен үткәрү буенча Бөтенсоюз комиссиясе председателе, СССР Язучылар союзы идарәсе секретаре, «Новый мир» журналының баш редакторы, Советлар Союзы Герое В. В. Карпов ачты.

Муса Җәлилнең тормыш һәм иҗат юлы турында КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре Р. К. Беляев сөйләде.

СССР Язучылар союзы идарәсе секретаре, «Юность» журналының баш редакторы шагыйрь А. Д. Дементьев, РСФСР Язучылар союзы идарәсе секретаре, Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Т. А. Миңнуллин, Муса Җәлилнең тормышын һәм иҗатын өйрәнүче ГДР публицисты Л. Небенцаль, Муса Җәлилнең көрәштәше Р. Ш. Хисаметдинов бөек шагыйрьнең иҗаты һәм көрәше, үлемсезлеге турында сөйләделәр.

Кичәнең икенче өлешендә Татарстан сәнгать осталары концерты булды.

## ӘДӘБИ ЕЛ ЙОМГАКЛАРЫ

31 мартта Татарстан язучыларының әдәби ел йомгакларына багышланган җыелышы булды. Анда әдәбиятның төрле жанрлары буенча Г. Ахунов (проза), Л. Зөлкарнәев (поэзия), Р. Мингалимов (драматургия), К. Кәримов (балалар әдәбияты), Б. Камалов (очерк һәм публицистика), М. Скороходов (рус язучылары иҗаты), М. Вәлиев (тәнкыйть), Т. Нурмөхәммәтов (тәрҗемә) докладлары тыңланды.

Фикер алышуларда язучылар И. Нуруллин, И. Юзеев, Татарстан язучылар союзының партия оешмасы секретаре Р. Мостафин, Р. Кәрами, К. Сибгатуллин, «Казан утлары» журналының баш редакторы Р. Харис, А. Хәсәнов, Брежнев язучылар оешмасы житәкчесе Я. Игәнәй, М. Әгъләмов, Р. Миңнуллин, Р. Зәйдуллин, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының баш режиссеры, СССРның халык артисты М. Х. Сәлимжанов, Татарстан китап нәшрияты директоры Г. Н. Шәрәфетдинов һ. б. катнашы.

## ТАТАРСТАН КИНЕМАТОГРАФИСТЛАРЫ СЪЕЗДЫ

29 мартта Казан кинохроника студиясендә Татарстан кинематографистларының II съезды булды. Анда Кинематографистлар союзы идарәсенең ике съезд арасындагы эшчәнлеге турында отчет доклады белән идарәнең беренче секретаре И. Н. Алексеев чыкты.

Доклад буенча фикер алышуда Казан кинохроника студиясе баш редакторы Р. И. Копосов, кинорежиссер Х. Ф. Фәхретдинов, РСФСР Кинематографистлар союзының Идел буе бүлеге идарәсе секретаре Ю. Т. Долженко, РСФСР Госкиносының фильмнар эшләү буенча баш идарәсе начальнигы Ю. В. Симаранов, режиссер, ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт пре-

миясе лауреаты В. И. Беспалов, СССР Кинематографистлар союзы идарәсе члены, Ленин һәм СССР Дәүләт премияләре лауреаты, кинорежиссер А. С. Кочетков һ. б. катнашты.

Съездда КПСС өлкә комитеты секретаре Р. К. Беляев чыгыш ясады.

Съезд эшендә ТАССР Министрлар Советы председателенең беренче урынбасары М. Х. Хәсәнов, ВЛКСМның Татарстан өлкә комитеты беренче секретаре Д. К. Шәяхмәтов, КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире Д. Х. Зарипова, КПССның Казан шәһәр комитеты секретаре Ф. Г. Зыятдинова катнаштылар.

## ЯШЬ ЯЗУЧЫЛАРНЫҢ ЗОНА СЕМИНАРЫ

11—13 мартта Брежнев шәһәрендә яшь Язучыларның зона семинары үткәрелде. Татарстан Язучылар союзы, Брежнев язучылар оешмасы тарафыннан үткәрелгән бу семинарда Брежнев, Алабуга, Түбән Кама, Минзәлә шәһәрләрендә яшәүче башлап язучылар җыелган иде.

Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе урынбасары Р. Хәмид, Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателенең яшь авторлар белән эшләү буенча урынбасары И. Юзеев, язучылар Ш. Галиев, Р. Мингалимов, Р. Гәрәй, Н. Беляев, Р. Хисмәтуллин, Ямаш Игәнәй, К. Сибгатуллин, Н. Алешков, Н. Мадьяров, Г. Кашапов, Равил Вәлиев катнашкан бу семинарда 48 яшь авторның әсәрләре тикшерелде.

Семинарда катнашучылар алдында КПСС-ның XXVII съезды делегаты, Татарстан Язучылар Союзы идарәсе председателе Т. Миңнуллин чыгыш ясады. Ул үзенең съездда алган тәэсирләре белән уртаклашты.

## ЯЗУЧЫЛАР АРХИВКА КИЛДЕ

19 февральдә «Казан утлары» журналының редколлегия членнары, редакция хезмәткәрләре һәм бер төркем язучылар КПССның Татарстан өлкә комитеты партархивында очрашуда булдылар. Архив хезмәткәрләре әдипләргә үзләренең эше һәм табылган кызыклы материаллар, күренекле шәхесләр тормышы хакында сөйләделәр, сорауларга җаваплар бирделәр. Очрашу әдәбиятта тарихи-революцион теманы тагын да үстерүгә багышланган җанлы сөйләшүгә әверелде. Соңыннан очрашуга килгән шагыйрьләр үзләренең яңа шигырьләрен укыдылар, иҗат планнары белән уртаклаштылар.

## СОВЕТ ӘДӘБИЯТЫ КӨННӘРЕ

20—25 январьда Киров өлкәсендә совет әдәбияты көннәре булып узды. Партиянең XXVII съездына багышлап үткәрелгән әлеге бәйрәмдә шагыйрь Равил Фәйзуллин катнашты. Илебезнең төрле төбәкләреннән җыелган кунаклар шәһәр һәм авыл хезмәтчәннәре белән очраштылар, күренекле партия, дәүләт эшлеклесе С. М. Кировның туган каласы — Уржумда булдылар.

## БӨТЕНСОЮЗ КИҢӘШМӘСЕНДӘ

28—29 январьда Мәскәүдә СССР Язучылар союзында поэзия мәсьәләләренә багышлап, съезд алды бөтенсоюз киңәшмәсе уздырылды. Киңәшмәне СССР Язучылар союзы секретаре Е. Исаев алып барды. Анда тугандаш республикалардан шагыйрьләр чакырылган иде. Татарстаннан бу киңәшмәдә шагыйрь Р. Гатауллин катнашып, бүгенге татар совет поэзиясе турында сөйләде. 29 январьда Колонналы залда үткән зур шигырь кичәсендә катнашып, анда шигырь укыды.

## КОРЫЧ КОЮЧЫЛАР ЯНЫНДА

5 апрельдә Магнитогорск төзүчеләр культура сараенда бөек татар шагыйре Габдулла Тукайның 100 еллыгына багышланган әдәби-музыкаль кичә булды. Шигырь һәм җыр бәйрәме төсендә үткәрелгән әлеге очрашуда Татарстаннан язучы һәм галим М. Мәһдиев, шагыйрь З. Мансуров чыгыш ясады. Концертта «Яшьлек» халык татар-башкорт җыр һәм бию ансамбле, металлурглар каласының башка үзешчәннәре катнашты.

## ИҖАТ КИЧӘЛӘРЕ

3 февральдә Мәскәүнең Үзәк Актерлар йортында РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе, РСФСРның һәм ТАССРның Дәүләт премияләре лауреаты Туфан Миңнуллинның иҗат кичәсе булып узды.

Драматургның иҗаты турында СССРның халык артисты М. Сәлимҗанов сөйләде. Мәскәүлеләргә Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артистлары «Монда тудык, монда үстек», «Диләфрүзгә дүрт кияү», «Әниләр һәм бәбиләр», «Моңлы бер җыр» спектакльләреннән өзекләр күрсәттеләр.

15 мартта Әлмәт шәһәрендәге Төзүчеләрнең техника йортында шагыйрә К. Булатованың иҗат кичәсе уздырылды. Кичәне Әлмәт язучылар оешмасының җаваплы секретаре Ә. Гаффар ачты. Шагыйрәнең тормыш юлы һәм иҗат эшчәнлеге турында А. Гафиятов сөйләде.

Кичәдә К. Булатова шигырьләре һәм аның сүзләренә язылган җырлар башкарылды. Тамашачылар шагыйрәнең иҗатына багышланган күргәзмәне кызыксынып карадылар.

17 мартта Казанның Актерлар йортында М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры солисткасы, РСФСРның һәм ТАССРның атказанган артисткасы Рәхилә Мифтахованың иҗат концерты булды. Ул Г. Тукайның тууына 100 ел тулуга багышланган иде.

Г. Тукай сүзләренә язылган җырлар башкарылган бу концертта театрның әдәби бүлек мөдире Р. Такташ тамашачыларга халык шагыйренең иҗат юлы турында сөйләде. Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисты И. Әхмәтҗанов Г. Тукайның шигырьләрен укыды.

# ТЕАТРГА НИГЕЗ САЛУЧЫЛАР

РСФСРның халык рәссамы, СССР һәм ТАССР Дәүләт премияләре лауреаты Лотфулла Фәттахов (1918—1981) культурабыз тарихына сугыштан соңгы татар сынлы сәнгатен үстерүгә зур өлеш керткән күренекле оста буларак кереп калды. Нәкыш сәнгатенең жанр һәм төрләрен баетуга сизелерлек йогынты ясаган әлеге рәссамның таланты авыл тормышына багышланган тематик картиналарда киңрәк ачылды («Сабан туе», «Яңа буралар» һ. б.). Заман елъязмачысы булу белән беррәттән, ул тарихи жанрлар, аерым алганда, Ленин тематикасы буенча да нәтиҗәле иҗат итте. Мәсәлән, Х. Якупов белән берлектә тудырылган әсәр — «В. И. Ленинның Татарстан АССРны төзү турындагы декретка кул куюы» исемле картина, шулай ук «Уйлану. Володя Ульянов Иделдә» полотносы Л. Фәттаховны тарихи-революцион теманы халык тормышы белән бәйләнештә тирәнтен ача белүче күпкырлы иҗатчы итеп танытты.

Кыйммәтле мирас итеп калдырылган нәкыш әсәрләре арасында татар әдәбияты һәм сәнгатенең күренекле вәкилләренә багышланганнары да шактый. Шулардан «Татар театры корифейлары портреты» на гына тукталыйк. Әлеге полотнода татар профессиональ театрын барлыкка китерүдә «беренчеләр» ролен башкарган атаклы шәхесләр гәүдәләндерелә. Үзенең яңа пьесасын укып торучы Галиәсгар Камалны без татар драматургиясенә нигез салучы итеп беләбез. Әнә — татар театрының атасы Габдулла Кариев, менә — «Сәйяр» труппасының күренекле артисты Нури Сакаев, режиссер һәм актер буларак та танылган драматург Кәрим Тинчурин, татар театрының беренче профессиональ актрисалары Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжская, Гөлсем Болгарская... Әсәрдәге төп геройны билгеләү шактый кыен. Хәер, моның кирәге дә юктыр. Монда — барысы да төп геройлар, барысы да беренчеләр. Сюжетның мәгънәви үзәген нәкъ менә шушы беренчелек — күпмилләтле совет культурасын үстерүгә зур өлеш кертүче татар профессиональ театрына нигез салучылар иңенә төшкән җаваплы һәм мактаулы миссия гәүдәләнеше билгели.


**Юрий ГОРШУНОВ,**
Татарстан сынлы сәнгать музееның
өлкән фәнни хезмәткәре.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** күренекле татар совет язучысы, ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Әмирхан Еники.

**Рөстәм МАНСУРОВ фотолары.**

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210



**КАЗАН УТЛАРЫ**
**(ОГНИ КАЗАНИ)**

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ
(на татарском языке)